Мансур Вәли-Барҗылы

Тормыш дулкыннары

әдәби әсәрләрдә ничек чагыла?

КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 2005

УДК 820/89 (470)
ББК 83.3 (2 Рос = Тат)-6
В 97

Вәлиев Мансур

Тормыш дулкыннары: Эссе, язмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.— 287 б.

Соңгы еллар тормышында тетрәндергеч вакыйгалар, кешене тирәннән уйландырырдай хәл-әхвәлләр еш булып тора. Ә менә алар әдәби әсәрләрдә ничек, ни дәрәҗәдә чагыла? Танылган әдәби тәнкыйтьче, Татарстан Язучылар берлегенең Җамал Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты Мансур Вәли-Баржылының бу китабына кергән язмаларыннан әнә шундый сорауларга җавап табарга мөмкин. Алар җиңел тел белән, мавыктыргыч итеп язылганнар.

ISBN 5–298–01458–5

© Татарстан китап нәшрияты, 2005

Алмагачлар чәчәктә

Чорлар чигендә

Бер пәйгамбәребезнең сүзсез генә ике бармак күрсәтүенә карап, «2000 елда ахырзаман җитәчәк!» дигән яман фараз кылучылар һәм шуның белән бөтен кешелек дөньясын зур хафага салучылар бар иде... Бүген инде «Аллага шөкер!» дип әйтә алабыз — әлегә ахырзаман килеп җитмәде кебек. Җир дигән гүзәл планетабызда исән-сау гына яшәп ятабыз.

Ләкин...

Ләкин, шулай булса да, соңгы дистә елларның кешелек тормышына зур һәм кискен үзгәрешләр китерүен беркем дә инкарь итә алмас, мөгаен.

Әйе, егерменче гасырның урталарыннан алып халыкның иң зур күпчелеге шәһәрләрдә: димәк, үзенең тудыручысы булган җирдән һәм табигатьтән аерылып, димәк, тоташтан таш белән тимер һәм ясалма материаллар арасында, димәк, бөтенләй бүтәнчә көн итә башлады. Хәзерге кеше яшәешендә төрле техника, автомат җайланмалар, компьютер һәм телевидение үтә зур урын били.

Аннары, СССР дигән империя таралып, ил чикләре ачылгандай булгач, халыкның зур дөнья белән аралашуы нык артты, активлашты. Бу күренеш, нигездә, уңай бәяләнергә тиеш булса да, аның тискәре якларын да күрми калу мөмкин түгел: куркыныч авырулар күбәйде, наркомания һәм җинаятьчелек үсә, кеше үтерүләр саны үтә нык артты.

Хәзер татар милләте дә бик кызу ритмда яшәүче дөнья агымына кереп бара. Татарстаныбызга атна саен диярлек чит илләрдән делегацияләр килә, күпләгән килешүләр төзелә, безнекеләр дә ерак-ерак илләргә еш йөреп тора.

Җир дигән уртак планетада яшәгәч, бүтәннәргә хас күп нәрсәдән читтә калырга да мөмкин түгелдер... Ләкин шунысы торган саен ныграк борчый бара: мондый актив хәрәкәт, кызу агым эчендә яши башлагачтын безнең милләтнең үз йөзе югалмасмы? Милли холык-психология, бүген дә һәм киләчәктә дә безнең өчен һәм дөньяның үзе өчен дә бик кадерле булырга тиешле гореф-гадәтләр нишләр?

Әлеге сорауларга уңай җавап табарга теләп эзләнә башласак, без ирексездән диярлек рухи дөньяга — әдәбият һәм сәнгать дөньясына — килеп чыгабыз.

Мәңгелек маяклар

Гасыр башына, яңа меңьеллык башына, Хәсән Туфан, Салих Сәйдәшев, Һади Такташ, Гомәр Бәширов кебек олуг затларның 100 еллык юбилейлары туры килү зур символик мәгънәгә ия. Алар, бер яктан караганда, моңа кадәр яшәгән мең еллык гомерле татар мәдәниятенең яктысын һәм җылысын үзләренә туплаганнар, үзләрендә әнә шул олы рухи хәзинәне чагылдырып балкыйлар... Ә инде икенче яктан күз салсак, алар, яңа чорга, яңа заманга кереп баручы яңа юлларга да яктылык сирпеп, безгә юл күрсәтеп торалар.

Әйе, үтеп киткән егерменче гасыр зур-зур вакыйгаларга һәм кискен борылышларга гаять бай булса да (әллә ничә зур сугыш, аларда миллионлаган халык кырылу, шулар өстенә тагын әллә ничә революция һәм тормышның асты-өскә килү, атом һәм химия аварияләре аркасында зур зыян күрүләр һ.б.), әмма гасыр афәтләре барыбер, әдәбиятны төп юлдан — гасырлар буена уңышлы рәвештә атлап килгән олы юлдан — яздыра алмады. Татар әдәбияты барыбер кешенең күңел юлдашы булып, аның иң изге һәм иң мөкатдәс хис-кичерешләрен җырлаучы булып калды.

Әлбәттә, әдәбият-сәнгатьнең кешелек тормышында тоткан урыны хакында төрле һәм кайнар-кайнар бәхәсләр дә тумады түгел ул гасыр дәвамында. Бигрәк тә фән-техника революциясе көчәеп барган елларда әкияттәгечә гүя әле генә чүлмәктән чыккан бу яңа «пәри»гә артык зур өмет баглаулар булды. Физиклар белән лирикларның кайнарланып бәхәсләшүләре дә тарих хәтеренә язып куелды... Еллар үтте, тулаем гасыр үзе дә узып китте... ләкин физиклар да үз урыннарында калды, лириклар да алыштыргысыз миссияләрен үтәп киләләр.

Инде хәзер, әлеге парә-парә килүләр басылгач һәм еллар тузанына күмелә төшкәч, кайбер сөземтәләр дә чыгара алабыз сыман. Аерым алганда менә мондый нәтиҗә. Кешенең күңел дөньясын, аның йөрәген, хис-кичерешләрен бер генә нәрсә белән дә алыштырып булмый икән! Хәтта әле соңгы вакытта галимнәр шуны да ачыклап килә: безнең гасырлар буена «җан» диеп сөйләшә торган хикмәтебез үзе дә кешенең йөрәге тирәсенә тупланып яши икән. Бер кешенең йөрәген алып икенче кешегә куйсаң — аның бөтен холык-фигыле, хис-кичерешләре үзгәрә икән! Димәк, кешелек дөньясы бер дә юкка гына «йөрәк» дигән нәрсәгә гасырлар буена аерым бер игътибар биреп килмәгән икән!

Үзебезнең татар әдәбиятын алсак, анда хисси башлангыч бигрәк тә көчле. Аның бүтән телләргә үтә авыр тәрҗемә ителүе, күп очракларда хәтта тәрҗемә кылына алмавы да әнә шундый асыл һәм нечкә ха-

сияте белән аңлатыла. Халык бәгыренә аеруча якын иҗатчы затлар гомере дә моны тагын бер мәртәбә раслый. Әйе, әдәбиятыбызда мәңгелек маяклар булу — барыбыз өчен дә бик зур бәхет.

Яшьләр килә

Республика матбугаты битләрендә яңа исемнәр еш күренә. Сүзне зуррак күләмле әсәрләрдән башлыйк. Тәвәккәлләп «роман» яисә «повесть» дигән җитди һәм зур җаваплылык сорый торган жанрга тотынучы яшь автор булдымы икән соңгы елларда? Яшерен-батырын түгел: андый тәвәккәллек өчен элеккерәк елларда яшьләргә байтак кына тәнкыйть таягы да эләккәләде. Дөресрәге, тәвәккәллекнең үзе өчен түгел, ә җитәрлек микъдарда тәжрибә тупламаган килеш зур күләмле жанрга кереп киткән һәм уңышсызлыкка очраган өчен сүктеләр күп кенә яшь прозаикларны. Әлбәттә, җитмешенче, сиксәненче елларда тәүге повесте белән үк игътибар казанган Әхәт Гаффар да булды. Ләкин аның уңышы да, нигездә, классик әсәрләргә таянуда яисә караган нәфис фильмнарга ияреп язуда иде. Эпигонлык дигән бу күренеш күп чагында плагиатка якын тора һәм яшь язучылар аннан бик хаклы рәвештә куркалар да. Һәрхәлдә, минем үземә бу юл бик тайгак, ышанычсыз тоела һәм бүгенге яшьләргә дә иҗатның башын аннан алып китәргә киңәш бирәсе килми. Саф күңелле, изге ниятле, зур максатлы иҗатчы юлы түгел ул!

Әлеге хакыйкатьне бүгенге яшь иҗатчылар бик яхшы аңлый, күрәсең, соңгы елларда әдәбиятыбызда андый күренешләр күзәтелми башлады. Бу уңайдан, бер яшь язучыга адресланган һәм «Казан утлары» журналында элегрәк басылып чыккан ачык хатның тәэсире булгандыр диеп әйтәсе килми, билгеле, ләкин шулай да ул елларда — әле прозабыз нык көчле булган чорда — эпигон әдәбият тудыруның зыянлы икәнен күрсәтү кирәк иде, сорала иде. Ул чагында без игътибар иткән әлеге яшь язучының чын иҗат юлына чыгып, сокланып укырдай чын әдәбият әсәрләре тудыра алмавы гына эчне пошыра пошыруын... Ә бит ул — шактый ук талантлы, бигрәк тә үткен тел куәсенә ия автор.

Биредә яшьләр өчен мөһим тагын бер нәтиҗә килеп чыга шикелле: әйе, әсәр язу өчен әйбәт, матур, сыгылмалы, образлы тел бик тә кирәк, бик тә мөһим — ләкин, әнә шул хәзинә белән янәшә үк, изге ниятләр белән рухланган, канатланган чиста, матур, керсез күңел дә кирәк. Дөньяга, кешеләргә бирергә, бүләк итәргә теләгән югары омтылышлар, кешелек өчен кадерле һәм мөһим булган яңа, саф кичерешләр бик тә сорала әдәби иҗатта. Менә шушы соңгысы булмаган тәкъдирдә яшь иҗатчыны кризис, рухи ачлык, тупик дигән яман нәрсә көтә. Икенче төрле итеп әйткәндә, моны яшь язучының актив һәм тирән рухи дөнья белән яшәргә тиешлеге диеп тә белдерергә була.

Әнә шундый эчке «мотор»ың синең күкрәк читлегендә даими рәвештә эшләп тормаса, син — яшь автор — иҗат юлыннан бик әллә ни ерак китә алмыйсыңдыр...

Ләкин шулай да бүгенге яшьләрне кыюсызлыкта гаепли алмыйбыз икән: соңгы ике еллык басмаларны укыганда мин ике яшь автор язган ике повестька юлыктым. Аларның беренчесе Рәдиф Сәгъдинең «Алло, хәлләр ничек?» повесте (Идел.— 1999.— № 11), икенчесе Ләлә Сөләйманның «Гасыр ахырында» повесте (Ватаным Татарстан.— 2000.— 12—14 июль).

«— Алло, алло! Кем бу? Дамир синме? Сәлам, туган! Хәлләр ничек? Яхшы инде, алайса. Бик әйбәт! Малайлар ничек? Ну, әйбәт булгач, бик яхшы! Сәлам әйт егетләрнең барчасына да! Без иртәгә Казанга очабыз, әй! Шул сәгать унберләрдә саунада күрешә алырбыз диеп уйлыйм... Билетын өч бәягә алдык инде, Касап белән. Ну, Мәскәү хәлләрен үзең беләсең бит инде, монда һәрбер җирдә ыштаныңны салдырырга торалар!»

Рәдиф Сәгъди повестеның иң беренче бите үк әнә шулай башланып китә. Укучы күреп өлгергәндер, әсәр башында китерелгән шушы берничә җөмләдән генә дә әлеге сүзләрне әйткән кеше хакында күпме мәгълүмат алабыз: ул Мәскәүдә яши, аның дус егетләре күп, алар бай яши (билетны өч бәягә алырлык булгач!), самолет белән кайтырга уйлагач аларның вакыт ягы да кысан, күрәсең... Шулай ук боларның Казанда да әшнәләре байтак: әнә бит «малайлар ничек?» диеп кенә хәл белешә. Мәскәү шәһәрендәге тормыш белән Казандагы яшәү аермасы да сизелеп ала әлеге җөмләләрдән — Казанның эшләп яшәргә өйрәнгәнлеге, ә Мәскәүнең кеше таларга күнегүе дә күренә.

Әлбәттә, әсәр дәвамында күренәчәк геройлар турында башта ук шуның кадәр хәбәр җиткерә алу һәм ул мәгълүматның укучы хәтеренә сеңүе — болары яшь авторның уңышлы ягы, казанышы. Шушындый кызу темпны, тыгыз динамиканы автор алга таба да югалтмаска тырыша: мажаралы кино карагандагы сыман безнең күз алдына бер-бер артлы замана хикмәтләре килеп баса... Биредә Мәскәүдән килгән егетләр белән Казан кызларының барысы бергә сауна керүләре дә, мускул кабарткан егетләрнең үзара тыныша алмыйча кан коюлары да — һәммәсе дә бар... Ләкин повестьның эчке битләренә үткән саен, күңелне бер тойгы били бара. «Бу хәтле актив хәрәкәтнең, күп вакыйгаларның үзәгендә нәрсә ята соң, автор безгә нинди фикер аңлатырга тели соң?» дип уйлана башлыйсың. Һәм, ни кызганыч, ул сорауга ачык җавапны табып ала алмыйбыз. Билгеле, повестьлар белән бергә сәхнә әсәрләре дә язучы Рәдиф Сәгъдинең каләме талантлы, югарыда әйтеп узуыбызча, ул вакыйгаларны бер-берсенә оста үреп

бара. Катнашучыларның холык-фигыльләре дә укучы күз алдына килеп баса. Ләкин... Ләкин менә «эчтәлекнең җитдилеге, тирәнлеге» дигән хикмәт җитенкерәми әле аңа. Бу повесть Яңарышның беренче елларында язылганмы әллә дигән тәэсир кала. Ул чагында иҗат дөньясына ирек килгәч, «болай да язып була!» диеп, язгы болынга чыккан яшь маллар сыман, күккә ашардай булып сикереп, чабышып йөрүләр бар иде бит... Әмма ирек үзе генә әле ул төп хәзинә түгел икән, аңа ирешкәч тә «эш» һәм «хезмәт» дигән бәхет алга килеп баса икән. Аларның һәр икесенә дә җитди карау, иң нечкә серләренә ия булу, тырышлык, җитдилек, басылып эшләү сорала икән... «Иҗат» дигән дөнья ул эшнең дә иң авыры — ял белән дә, вакыт белән дә, сәламәтлек белән дә санашмый, санлашмый торганы, үзенә бөтен көчеңне, бар җегәреңне суыра торганы икән...

Ерак Мөслим төбәгенең кечкенә генә бер авылында яшәп ятучы яшь автор Ләлә Сөләйман исә үзенең үткән җәйне «Ватаным Татарстан» газетасы битләрендә басылган «Гасыр ахырында» повестен без югарыда телгә алып үткән «Алло, хәлләр ничек?» әсәренә юри капма-каршы рухта башлап китә кебек:

«Ашыкмый гына намазын тәмам иткәч, Шәмсекамал карчык, бисмилласын әйтеп, «Аятел көрси»не укый башлады: — Әгузе билләһи... Бисмиллаһи...

Шул арада шыгырдап урам капкасы ачылды, дисбесен тарткан карчык тәрәзәгә күз салды. Керүче кеше йөгереп үтте — таный алмый калды.

— Шәмсекамал апакай гынам!

Шакымый-нитми генә өйгә бер хатын килеп керде. Чәчләре тузгыган, куллары калтырый, үзе әле ап-ак итеп акшарланган мич артына, әле дәү сандыкка күз сала. Аңлашыла, качар урын эзли күрше хатын...»

Күрәсез булыр: бу әсәрнең тәүге юллары ук намазга игътибарны юнәлтә, әнә шул мәңгелек канун буенча яшәүче Шәмсекамал карчыкны үзәккә куя... Ә инде бераздан күрше хатыны Гөлзирә йөгереп керә. Әсәрнең менә шушы өлеше дә бик мәгънәле. Әнә өлкән кеше — сабыр, тыныч, аның кулында Коръән... Ә менә яшь хатын ни кыяфәттә: ул йөгерә, аның чәчләре тузгыган, куллары калтырый, үзе качарга урын эзли...

Хәтта менә шушы бер эпизод үзе генә дә өлкән буын һәм яшь буын турында бик күп нәрсәне әйтеп, сөйләп тора.

Әйе, гап-гади бер татар авылында яшәп ятучы яшь килен Гөлзирәнең тормышы мәхшәрдәге сыман: ире Идрис көн саен эчә һәм көн саен аңа бәйләнә. Шулай дөньясын онытып эчә торгач, Идрис көннәрдән бер көнне хастаханәгә килеп эләгә, анда байтак кына ята. Әнә шул чагында инде Идрисне кара магия әгъзасы Васил үзенең мәкерле җәтмәләре белән чолгый, аның күңелен, рухын богаулый. Ахырда Идрис куркыныч һәм кешелек тормышын җимерүгә юнәлтелгән көчкә әверелә. Безнең көннәрдә татар авылында яшәп ятучы гап-гади бер ир явыз секта йогынтысына килеп эләгә.

Юк, безнең максат бу ике повестьның эчтәлеген сөйләп бирү түгел, анысын укучының үзенә калдырыйк та, шушы ике әсәрдә чагылган уртак якларны барлыйк, күзәтик.

Иң элек шунысын сөенеч белән билгеләп үтәргә кирәк: яшь авторлар, зур бер тәвәккәллек табып, прозаның күләмле һәм күп көч сорый торган тармагында — повесть жанрында — әсәр иҗат итү эшенә алынганнар. Димәк, бу инде үзеңдә күпмедер көч, илһам ташкыны тою дигән сүздер. Үз-үзеңә шактый ук ныклыш ышанудыр. Әлбәттә, кайсыбер вакытларда графоманнар да зур-зур күләмле әйберләр язып ата, аларны мондый «эч китү»дән дәвалап та булмый. Ләкин без инде бу очракта андый иң түбән дәрәҗәне искә алмаска тырышыйк. Чөнки инде анысы өлкән яшьтәге кешеләрдә күбрәк була һәм, турысын гына әйткән чагында, ул күренеш еш кына очракта медицинаның шизофрения дигән авыруы белән бик якыннан килеп тоташа.

Икенче уңай як: яшь авторлар курыкмыйча заман темасына мөрәҗәгать иткәннәр! Югыйсә элеккерәк елларда яшь авторларның әбиләр һәм бабайлар тормышы турында әдәби әсәр язулары үзенчә бер норма сыман кабул ителә башлаган иде. Моның сәбәбе, күрәсең, чынбарлыкны яхшылап белмәүдә, күбрәк китап тормышы белән яшәүдәдер. Яшь авторларның нинди дә булса әсәр укып яисә кино карап хикәя язарга утыруларын һәм редакцияләргә юллауларын без инде байтак очраттык. Бу очракта исә Рәдиф тә, Ләлә дә үз күзләре белән күргән, үзләре янәшәсендә агып яткан реаль яшәешкә чумганнар. Шуны үз йөрәкләре, үз күңелләре аша үткәреп, әдәби әсәр тудырганнар.

Ике авторга да хас булган тагын бер сыйфат: аларның җөмләләре күп бизәкле, чуклы-чуклы түгел, сокландыргыч чагыштырулар, сынландырулар һәм бүтән төрле телбизәкләр дә сирәк күзгә ташлана. Һәм шунысы кызык — менә шушындый, бер караганда корырак тоелырга тиешле стиль, әсәрләрне укыган чагында бик үк борчымый да. Шулай булырга тиешле нәрсә сыман кабул ителә. Ни өчен шулай? Югыйсә бит безгә: «Матур әдәбият ул матур булырга тиеш, бизәкле һәм матур җөмләләрдән торырга тиеш!» — дигән ижади лозунг сыман сүзләрне дә еш кына ишетергә һәм шуны чынга ашырган әсәрләрне дә күрергә туры килгәли... Ә биредә, менә бу яшь авторлар ижаты уңаеннан, ни өчен соң җөмләләрнең күп бизәкле булмавы сизелми, бу хәл күңелне борчымый?

Мәсьәлә шактый ук җитди, шуңа күрә, әйдәгез, аңа бераз гына озаккарак тукталып алыйк. Башта теге «Җөмләләр дә матур һәм бизәкле булырга тиеш — шуның өчен матур әдәбият бит ул!» дигән сүзне ачыклап китик.

Минем уйлавымча, «матур әдәбият» диеп әйткән чагында без һич кенә дә җөмлә матурлыгын гына күз алдында тотмыйбыз. Биредә «матур» дигән сүзгә: югары максатлар һәм идеяләр белән рухланган матур эчке яшәеш тә, үзе матур рухи дөньяга ия булган һәм рухланган яшәеше белән укучыны да тәэсирләндерә алырдай, чын мәгънәсендәге матур геройлар да керә. Әсәрнең үзе сыман, геройлар да тыштан гына чибәр түгел, ә эчке яктан да матур булсалар гына безнең күңелне яулый ала бит! Менә шуның шикелле «матур әдәбият» дигәндә, без бу сүзне киң, тулы мәгънәсендә кулланабыз диеп уйлыйм. Ә тар, түбәнрәк мәгънәсендә генә түгел. Шулай булгач инде авторларның иҗат җимеше үзләре дә һәрьяктан, шул исәптән җөмлә һәм стиль җәһәтеннән дә, матур һәм төзек булырга тиеш — бусы уңаеннан һич кенә дә ике төрле фикер юк. Димәк, сүзебезнең әлеге өлешен йомгаклый төшеп шуны гына искәртик: матур һәм бизәкле-чуклы җөмлә төзү, шундый стильгә ия булу үзе генә — һич кенә дә төп һәм бердәнбер максат түгел!

Ярый, яңадан яшь авторларның әле генә без күздән кичергән повестьларына әйләнеп кайтыйк. Чыннан да, алар өчен иң мөһиме — вакыйгалар, геройлар һәм аларның эш-хәрәкәтләре. Әсәрләрне укыганда без, нигездә, вакыйгага ияреп барабыз, шуларны күрәбез һәм күңелгә кабул итәбез, шуларга үзебезнең төрлечә реакциябезне булдырабыз. Кыскасы, без әсәрдәге геройлар тормышы, аларның язмышы белән яшибез. Минемчә, менә бу факт, менә шуңа ирешү — яшь прозаиклар өчен төп уңышларның берсе.

Хәзер инде әлеге повестьларда күзгә ташланган кайбер җитешсезлекләргә тукталыйк. Аларның да уртак булганнары шактый.

Иң элек яшь авторларның сюжет төзүдә осталыклары җитмәү нык ук сизелә. Ләлә Сөләйман повестенда, мисал өчен, берничә сюжет сызыгы күренеп тора һәм аларның һәркайсысы үзе бер әсәр сорый сыман тәэсир кала. Билгеле, югарыда әйтеп узганыбызча, автор повестьның баш өлешен бик динамикалы алып китә, әмма уртага җитәрәк вакыйгалар күп тармакларга аерыла һәм күпмедер дәрәҗәдә буталчыклык туа, укучы адаша. Ул бераздан төп юлга килеп чыга чыгуын, ләкин ул чагында инде күңелдә «Теге әйләнмә юлны үтү бик кирәк идеме соң әле?» дигән сорау туа.

Рәдиф Сәгъди исә катнашучыларны артык күбәйтеп, үз укучысын шулар арасында адаштыра. Бусы да сюжет коруда осталык, тәҗрибә җитенкерәмәү билгесе.

Менә шушы беренче кимчелек икенче уртак җитешсезлекне дә китереп чыгара — повестьларның икесе дә күләм ягыннан шактый ук сузылганнар. Аларда артык өлешләрнең байтак булуы «гади күзгә» дә күренеп тора.

Әсәрдәге геройның эчке дөньясы... Безнең яшь авторлар бу өлкәгә ни дәрәҗәдә игътибарлы соң? Ләлә Сөләйманны әлеге мәсьәләдә гаепләве кыен — ул әсәрдәге һәрбер хәрәкәт белән бергә үк кешенең психологик халәтен дә үреп бара. Шулай итеп тышкы тормыш белән эчке дөнья гармоник дип әйтерлек дәрәҗәдә тоташып китә, органик рәвештә тоташкан чынбарлык күз алдына килә. Ә менә Рәдиф Сәгъди тышкы тормышны кинодагыча төгәл һәм образлы итеп тасвирлый, күрсәтә — кешенең эчке яшәешенә исә аның игътибары җитеп бетми. Ләкин гаделлек хакына шунысын да искәртергә кирәк: икенче бер яктан алсаң, «Автор әнә шул ысул аша үз геройларының эчләре буш икәнне күрсәтә бит» диеп уйларга да мөмкин. Хәзерге яшьләрнең рухи дөньялары бик ярлы икәнне күрсәтә ич ул, дияргә дә ярый кебек... Ләкин әдәбиятта, бигрәк тә безнең чорда, әнә шул эчке «бушлык»ны образлы итеп ачып бирү, аны укучының исендә калырлык итеп күрсәтү дә кирәктер. Ягъни әлеге бушлык ул — вакуум булмаска тиеш, ә укучыга тәэсир итә торган, аны дулкынландыра, тетрәндерә торган, йокысыннан уята торган халәт булырга тиеш. Ә битараф, тын бушлык түгел!

Дөнья әдәбияты әсәрләрен күздән кичерсәң, еш кына шундый бер хәл күзәтелә: яшь автор күренсә, ул гадәттә үзе белән яңа герой да, өр-яңа карашлар да алып килә һәм ул карашлар, ул холык-характерлар гадәттә моңа кадәр яшәп килгән тәртипләр белән каршылыкка керә. Шундый конфликтны үзәккә куеп урыс әдәбияты классикасында хәтта «Аталар һәм балалар» дигән роман да язылды. Ә бездә ничек соң?

Рәдиф Сәгъди әсәрендә яшьләрнең яшәү рәвеше бик тә үзләренчә булса да, алар артык зурга дәгъва итмиләр. Үз өерләре куйган тәртип буенча яши бирәләр... Әмма шунысы бар: безнең бүген «яшьләр» дигәнебез берничә елдан инде олыгаеп, урта буын булачак! Алар дөнья дилбегәсен үз кулларында тотачак. Димәк, тормышта үзләре теләгән яшәү рәвеше урнаштырачаклар... Повесть ахыр чиктә әнә шундый пошаманга төшерә.

Ләлә Сөләйман әсәрендәге яшь кешеләр шулай ук мактана алмый. Аларның мәхәббәтләре дә, гаиләләре дә юк һәм кыз белән егет өйләнешеп бергә яшәсәләр дә, бала табарга, бала багарга ашыкмыйлар. Менә бу хәл үзе үк инде бик тә шомлы фал...

Ә хикәядә ничек?

Хикәя жанрында яңа исемнәр дигәндә иң элек «Казан утлары» журналында үткән ел бик әйбәт хикәяләр бастырган Айгөл Әхмәтгалиева һәм Сөмбел Гаффарова, «Идел»дә ике мәртәбә чыгыш ясаган Рәмзия Габделхакова, шулай ук күп кенә газета-журналларда кечкенә хикәяләр белән күренгән Илфак Шиһапов исемнәре телгә килә. Сүз уңаеннан тагын шунысын да искәртеп үтү кирәктер: бүгенге проза үсешенә Мөслим төбәгеннән чыккан иҗат әһелләре бигрәк тә күп көч кертә. Менә берничә исемне генә карагыз. Хәзерге прозадагы иң саллы иҗатчы Фоат Садриев дисеңме, ел саен диярлек кызыклы һәм тирән эчтәлекле роман-повестьлар белән куандыручы Флүс Латыйфины аласыңмы, укучы хәтерендә калган «Соңгы көз», «Гөлҗиһан», «Биек тауның башларында» һ.б. повестьлар авторы Факил Әмәкне әйтәсеңме — болар барысы да әлеге районда туып үскән прозаиклар. Беренче повесте һәм хикәяләре белән безнең игътибарны яулаган һәм без югарыда сүз алып барган Ләлә Сөләйман да шуннан. Инде менә «Соңгы өмет» дигән уңышлы хикәя (Казан утлары.— 2000.— № 2) авторы Айгөл Әхмәтгалиеваны да әлеге төбәк үстергән. Моны бик кызык бер феномен димичә ни дисең инде! Шундый шатлыклы күренешләр тагын да булсын иде дә бит, әмма әдәбиятның үз кануннары шул!

Ләкин шулай да, бүген яшь иҗатчылар үстерү дигәндә, без иң зур игътибарны мәктәпләргә һәм алардагы әдәбият укытучыларына юнәлтергә тиешбездер. Әгәр дә бала укыган мәктәптә матурлыкка һәм әдәби сүзгә сизгер, нечкә күңелле һәм кайгыртучан җанлы укытучы эшләсә, әдәби түгәрәкләр яшәсә һәм стена газеталары чыгарылса — андый җирдә инде үзенә табигать тарафыннан иҗади орлык салынган баланың күңеле үсеп китә, аңа тәүге канатлар чыга, анда иҗади дәрт-илһам туа... Укытучы кеше бит әле ул иҗатчы баланың беренче укучысы да була... Әнә шул чагында ул җылы сүз әйтә алса, бала күңелендәге матурлыкны үсендереп җибәрә алса — аннары китә инде иҗат буасы ерылып! Ягъни мәктәп баласы үзе акрынлап-акрынлап матбугат белән, чын иҗатчылар дөньясы белән тоташып китә. Чын мәгънәсендә инешләр Иделгә кушылгандай була инде шуннан соң!

Үзенең хикәясен:

Баш куям тезләреңә лә
Яшь коям эзләреңә...—

дигән үзәк өзгеч халык җырыннан башлап киткән Айгөл Әхмәтгалиева да, һичшиксез, әнә шундыйрак баскычларны узгандыр. Хикәянең керешендә халык җырының җанны өтә торган юллары белән укучы игътибарын җәлеп иткәч, автор бүгенге авыл тормышының гыйбрәтле күренешләрен нечкә психологик алымнар һәм төгәл тотып алынган детальләр ярдәмендә тасвир кылырга тотына. Шунысы мөһим — Айгөлнең хикәясендә дә яшь буын вәкиле Фагыйлә чорсыз һәм теле-телгә йокмас бер хатын итеп бирелә. Ә өлкән яшьтәге Шәмсенурттәй әнә хискә-моңга бирелеп утыра, аның күңелендә кадерле хисләр, изге уйлар һәм хәзерге хәлләргә аптырау, борчылу. Тормышның ярлы булса да чистарак, матуррак, ышанычлырак, кешеләрнең әйбәтрәк һәм бер-берсенә карата шәфкатьлерәк булган чагын сагыну... Әсәрне укыганда бу изге уйларның автор күңеленнән чыгуына, шуннан — йөрәк түреннән агылуына чын-чыннан ышанып барасың.

«— Син гаепле, барысына да син гаепле, эт баласы! Бет, дөмек!

Бала елый, ярсый-ярсый елый. Ә хатынның йөзендә җиңү тантанасы, үч алу ләззәте. Барысы да ул уйлаганча, уңышлы килеп чыкты!..»

Үзенең «Югалту» исемле хикәясен (Идел.— 1999.— № 7) яшь автор Рәмзия Габделхакова әнә шулай бик тә югары драматизм дулкыннарында башлап китә. Биредә яшь гаилә тирәсендәге хәлләр үзәккә куела: хатын, бәләкәй бала һәм сөяркә. Кечкенә чагында балалар йортында үскән Илгизә үзенә Фәндәснең мәхәббәте сүрелә башлаганын сизгәч, аннан һәм аның хатыны Энҗедән үч алу юлына баса: аларның бәләкәй арбадагы балаларын урлый һәм урманга алып барып тереләй җиргә күммәкче була...

Шул ук журналның 9 санында басылган «Мин гаепле түгел» хикәясендә (1999) бу автор андый ук зур фаҗигане алмый, ә икенче төрлерәк вакыйгага мөрәҗәгать итә.

«Нургали бүген дә кибет төбендә басып тора иде. Зөлфия адымнарын акрынайтты. Бу дивананы күрмәс өчен генә дә әллә ниләр бирер иде! Әйтерсең лә бар дөнья яктысын шушы егет каплап тора.

— Нигә мин, нигә башка берәү түгел? — дип уйлый Зөлфия. Ул үзен чынлап та бу җүләрнең корбаны итеп сизә».

Әйе, Нургали — акылга таманрак егет. Ләкин менә аның яшь кибетче Зөлфиягә күзе төшкән. Егетнең әнисе Кәүсәрия апа да моңа бик газаплана: «Бәхете булмады шул балакайның. Язмыштыр инде... Алай гел җүләр дә түгел бит үзе, әйткәнемне аңлый, кушканны эшли. Бар нәрсәсе дә урынында аның. Ир буларак, дим...»

Кәүсәрия апа үзләренең акчалары күплеген дә әйтә — «мин сезгә машина да, фатир да алып бирә алам» ди... Кыскасы, Зөлфиянең үз улына кияүгә чыгуын тели бәхетсез ана. Ә яшь кыз моны ничек кабул итә соң?

«Икенче көнне эшенә килгәч, ишек төбендә таптанып торучы Нургалине күрде. Хурланды, ярсыды Зөлфия:

— Нәрсә кирәк сиңа, ә? Нәрсә карачкы кебек тагы монда килеп бастың?! Бар, өеңә кайт! Ычкын моннан! Күземә күренмә бүтән! Гарык мин синнән, гарык! Менә моннан гарык! Мунча пәрие! Бар, кайт, өеңдә утыр!»

Әлбәттә, җүләр саналса да, үзе яратып йөрегән Зөлфиядән мондый утлы сүзләрне ишеткәч, Нургали инде түзә алмый — асылына.

Яшь хикәяче безне бүгенге көннең әнә шундый фаҗигале хәлләре эченә алып керә. Ул әсәрендә озынга сузмыйча тасвир кыла, психологик яктан да төгәл эш итә, драматизмны да югалтмый. «Ә мондый әсәрнең язылу максаты нидә соң?» диеп сорасак: «Бүгенге кешегә гыйбрәт бирү, аның күңел күзен ачарга теләү, фаҗигаләрне алдан кисәтергә тырышу»,— дигән җавап алырбыз, мөгаен.

Соңгы елларда бик актив иҗат иткән, китаплар чыгарган һәм хәтта Татарстан Язучылар берлегенә дә кабул ителгән Сөмбел Гаффарова турында без инде «яңа исемнәр» диеп сөйләшергә тиешме икән? Әйе, бу сорауга җавап нинди генә булса да, без барыбер мондый яшь каләмебез булуга сөенү хисен яшерә алмыйбыз. Сөмбел иҗаттагы кыюлыгы, иҗади хыялының көче һәм теленең матур-сыгылмалы булуы белән җәлеп итә. Үткән ел «Казан утлары»ның беренче санында аның өч кенә хикәясе басылган, әмма алардан да үзенчәлекле автор, тормыш күренешләренә һәм кеше язмышларына сизгер йөрәк яшәве күренеп тора. Ә бәлки, хәзер Сөмбелгә үзен повесть жанрында сынап карау чоры да җиткәндер? Әлеге хикәяләрдәге иҗади яктан киң сулыш сизелү, кыюлык һәм җитдилек күренү әнә шундый уйга да этәрә.

Безнең юмористик хикәя өлкәсенә дә менә дигән яшь сәләт килүен шатланып билгеләп үтәргә кирәк. Сүз «Татарстан яшьләре»нең үткән елгы тугызынчы декабрь санында «Карар» исемле, «Казан утлары»ның 1999 елгы җиденче санында «Комган белән самавыр» дигән чын юмор әсәрләре бастырган Илфак Шиһапов турында бара.

«— Их, комган туган,— диде самавыр, ямшәйгән борынын турыларга маташып.— Бар иде безнең дә адәм балаларына кирәк чаклар. Утыра идем бит мин табын түрендә. Көн саен юып, чистартып торалар иде үземне...» Менә шушындый кызыктыргыч сүзләр, үзенчә аһәң, күңел күтәргеч елмаю дулкыны белән башлап киткән бәләкәй генә хикәя укучыда матур тойгы калдыра, автор каләменең уңышы юмордагы уңышы дип кабул ителә. Ә «Карар» дигән әсәрендә исә Илфак, татарның хәзер яңадан актуальләшкән ике хатын алу идеясен үзәккә куеп, шулай ук үткен генә шаяру хисе китереп чыгара. Ахырдан хатын кешенең: «Сания белән Әминәне генә алып кайтма, башкасына мин риза...» — диюе дә һич көтелмәгән яктан уйнатуы белән ситуацияне тагын да көлкерәккә әйләндерә. Кыскасы, Гамил Афзал, Фәнзаман Баттал, Камил Кәримов янына тагын бер яшь авторның килеп кушылуы — бәхәссез сөенеч.

Соңгы елларда безнең прозада Алмаз Гыймадиев дигән яшь язучыбыз да матур гына эшләп килә. Узган 2000 елда Татарстан китап нәшрияты аның «Хуш, Тамчыгөл!» исемле икенче җыентыгын бастырып чыгарды. Газета-журнал битләрендә еш кына күренеп сөендереп торган автор үзенең китабында да иҗади юнәлешенә хыянәт итмәгән: бүгенге мәктәп балалары, яшүсмерләр дөньясы бик мавыктыргыч итеп, кызыклы ситуацияләр, күренешләр аша тасвир кылына.

Үз хикәяләрен үгезне шундук мөгезеннән алып башлый Алмаз. «Мине мәктәптә «Дезодорант Рәсим» дип йөртәләр. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме?» Әсәрнең иң тәүге җөмләсе итеп куелган менә шушы сүзләрдә хикәя эченә чакырып торган тылсымлы тарту көче дә, бүтән язучыларны кабатламаган үзенчәлекле язу стиле дә һәм баштан ук көләсене китергән кызыклы кушамат та бар. Китапта бары тик ике бит күләм биләгән менә шушы бик бәләкәй хикәядә 8 Март бәйрәме тәэсире дә, малайларның кызларга бүләк эзләп Казанга килүе дә һәм андагы мажаралары да, нәрсә икәнен аңлап бетермичә бүләккә дип коңгызларга сиптерә торган сасы дару алып кайтулары һәм бөтен мәктәпкә көлкегә калулары да сыйган.

«Ата-аналар» җыелышы дигән хикәя дә шуннан зур түгел, әмма бусында инде кайсыбер әтиләрдән көлә Алмаз Гыймадиев. Әнә берсенең малае мәктәптә инша язганда өйләрендә ни күрсә, шуны язган, хәтта өйдә кәрт сугуларны да. Ә әтиләре исә җыелышта:

«— Дөрес түгел! — дип кабатлады ул.— Кая ул әкәм-төкәмнәргә мине оту! Язган икән, дөресен язсын. Кичә пеналына хәтле оттырып бетерде бит ул чебеш!»

Шушы кыска гына өзектә дә яшь авторның кеше холкын, тормыш вакыйгасын оста эләктереп ала белүе, шуны үз әсәрендә матур, тәэсирле итеп җанландыра алуы күзгә бәрелеп тора.

Чаллы шәһәрендә яшәүче Айгөл Нуретдинованың «Хикмәтле тартма» дип исемләнгән беренче китабы әллә ни калын да түгел — аңа нибарысы дүрт әкият сыйган, әмма аларның һәрберсе истә кала торган. «Көннәрдән бер көнне, гомере буе балта остасы булып эшләгән Бәдретдин бабайның келәтендә булган ди бу вакыйга...» Әнә шундый ымсындыргыч сүзләрдән башлап китә яшь автор әлеге китаптагы тәүге әкиятен. Айгөл биредә сүзне беренче карашка эш кораллары турында гына алып бара кебек, анда балта:

— Мин гайрәтле,
Мин сәләтле,
Каршы алыгыз түрәне.

Минем аркада салалар
Келәтләрне, өйләрне,—

диеп мактана. Янәшәсендә яткан чүкеч тә аннан калышмый, бераздан пычкы да сүзгә кушыла... Кыскасы, тартмада яткан һәркайсы үзен генә мактый башлый.

Ләкин әкиятне укыганда без инде биредә эш коралларын гына күрмибез, безнең алга үзләренең әнә шундый мактанчык холыклары белән бергә төрле-төрле кешеләр килеп баса. Алар арасында килеп чыга торган хикмәтле хәлләр искә төшә.

Ә инде яшь язучының китаптагы «Кирәмәт» дигән икенче бер әкияте фаҗигале мәхәббәт хакындагы моңсу бер легенда, поэма сыман кабул ителә. Бу әсәрдә Таңсылу исемле яшь гүзәлне сөйгәне Кирәмәттән аералар, башка әкиятләрдән үзгә буларак алар ахырда да кавыша алмыйча кала. «Сагыштан, кайгыдан нәрсә эшләргә белмәгән Кирәмәт кая киткәндер, бу якларда аны башка күрүчеләр булмаган. Тик сагыштан саргайган, өметен өзгән Таңсылу гына һәр таңны Зәңгәр күл буенда каршы ала, ди...»

Китаптагы әкиятләр теленең ягымлы, йомшак, тәэсирле, хисчән булуы, хикәяләүнең мавыктыргыч алып барылуы белән дә күңелгә ошый.

Егетләр кайда?

Соңгы елларда татар прозасында күренгән яңа авторларны күзәткәндә алар арасында егетләрнең аз булуы нык борчуга сала торган күренеш. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

Минемчә, әлеге күңелсез күренешнең иң беренче сәбәбе шул: хәзерге яшәештә ничектер рухи тормыш — җитди күренеш, җитди нәрсә диеп саналмый башлады шикелле. Тирә-юнебездә төрледән төрле техниканың бихисап күбәюе һәм аларның үзенә зур игътибар таләп итүе, безнең чынлыгыбызда зур урын биләве, телевидение белән компьютерларның кешене төрле яктан чолгап алуы, бизнес мөнәсәбәтләренең соңгы елларда шулай ук нык активлашуы, сервис тармагына байтак яшьләр соралу, тамашалар-шоулар күбәю һ.б.— менә болар барысы да хәзер тормышыбызда чамасыз зур урын били башлады һәм нәтиҗәдә рухи яшәеш нык ук кысрыкланды.

Аннары икенче зур сәбәп, минемчә, мондый: әдәбият ул — зур рухи көч, рухи батырлык сорый, иҗатчының әнә шундый көчкә ия һәм үзенчәлекле шәхес булуын таләп итә. Ә безнең соңгы дистә елларда үскән егетләребез андыймы соң? Моңа хәтле тормышта ир-ат биләп торган гаять җаваплы вазифаны үз өсләренә алырга әзерме алар? Гаилә өчен, балалар өчен һәм, ахыр чиктә, тулаем җәмгыять өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырдай хәлдәме алар? Соңгы еллар тормышының шактый иркә шартларында үсеп калыплашкан күп кенә егетләрне күздә тоткан чагында, әлеге сорауларга уңай җавап бирүе шактый ук кыен. Ягъни бик тә гадиләштереп әйткән чагында: бүген үз сүзләрен әйтергә дә куркып яшиме әллә безнең егетләребез? Әллә инде аларның халыкка әйтердәй мәгънәле, мөһим эчтәлекле сүзләре дә юкмы?

Тагын бер мөһим момент бар. Белүебезчә, әдәбият, бигрәк тә аның проза тармагы, автордан язу өстәле янында озаклап һәм басылып утыруны, язган әйбереңне кат-кат укуны һәм җентекләп төзәтүне, аннары тагын әллә ничә мәртәбә күчереп язуны таләп итә. Менә шушындый зур сабырлык, түземлек һәм үҗәтлек сорый торган эшкә хәзерге бик актив хәрәкәт чорында үскән егетләрнең чыдамлыгы җитми кебек. Мондый зур психологик һәм хәтта физик хезмәткә алар әзер түгел, бу — аларның кулыннан килми торган бик авыр вазифа.

Дүртенче бер сәбәп: соңгы еллардагы актив хәрәкәт шаукымы, объектив рәвештә дип әйтерлек дәрәҗәдә, яшьләрнең, бигрәк тә егетләрнең, эчке яшәешен үтә гадиләштерде, примитивлаштырды, аны ярлыландырды. Аларның күбесе «яңа урыс»ка һәм «яңа татар»га әверелде — ә болары хакындагы мәзәкләрне инде хәзер бик тә күп беләбез. Аларның кем икәнлеге хакында озаклап сөйләп торасы да юк... Үзләрендә иҗат өчен иң кирәк булган җан олылыгы, күңел нечкәлеге җитмәгәч, алар нишләп әсәр язарга утырсын соң инде?! Алар машина куа, дөнья куа һәм кай чакларда сирәк-мирәк кенә әйбәт эшләр дә эшләп ташлыйлар...

Менә без югарыда берничә сәбәпне күрсәтеп үттек. Егетләрнең әдәбиятка соңгы елларда ни өчен аз килүен аңларга тырыштык. Әмма бу хәл берәр вакыт үзгәрер микән соң? Югыйсә әдәбиятта ир-ат акылы бик тә кирәк бит! Бу бит зур социаль проблемалар күтәрү дигән сүз, тирән фәлсәфилеккә ирешү дигән сүз, монументаль әдәби образлар иҗат итү дигән сүз, бүгенге чынлыктагы киң масштаблы һәм үткен әхлакый-рухи конфликтларны әдәби әсәргә уңышлы рәвештә алып керә алу дигән сүз.

Минем ышануымча, безнең егетләр яши-яши үзләренең хәзерге яшүсмер чакларын, яшүсмер акылларын узарлар, дөньяның фән һәм техника белән генә алга бара алмаганлыгын аңларлар. Үз яшәешләрендә, үз язмышларында, җәмгыятебез яшәешендә әнә шул ачы хакыйкатьне бөтен акыллары белән һәм үз бәгырьләре аша уздыра-уздыра төшенгәч — әнә шул чагында инде алар үз йөрәкләренә тынычлану һәм ышанычлы бердәнбер сердәш эзләп әдәбиятка киләчәкләр.

Ә моңа кеше бары тик үз язмышы аша гына ирешә ала. Кеше моңа бары тик үз зиһене, үз акылы һәм үз язмышыннан килеп чыккан рухи әхлакый сабаклары, тәҗрибәсе җирлегендә генә ирешә ала. Әнә шул чагында гына кеше җаны, кеше акылы чынлыкта әдәбиятның нәрсә икәнен чынлап торып аңлый, төшенә ала. Һәм әнә шундый чакларда инде уйлап кына чыгарылмаган, ә чын тормыштан алынган чып-чын әдәбият әсәрләре туа. Кеше язмышларына тоташкан әсәрләр барлыкка килә.

Бирсен Ходай, көтик әнә шундый бәхетле елларны!

Татар халкының иң яраткан агачларыннан берсе булган алмагачлар язларын яшь киленнәр сымак ак чәчәккә күмелеп утыра... Дөньяның иң матур, иң күңелле көннәре була ул. Җаннар, йөрәкләр өмет, ышаныч, яктылык белән тулы була андый ямьле көннәрдә...

Безнең прозадагы бүгенге яшьләр дә әнә шул ак чәчәккә күмелгән алмагачларны хәтерләтә. Озакламый чын һәм тәмле җимешләр бирәчәк алар! Алма ашар көннәребез алда әле... Бирсен Ходай!

2001

Ир-ат турында

Моннан миллион еллар элек ат булып яшәдем кебек тоела миңа...

Р.Сибатның
«Ялгызак» романыннан
Заһидулла сүзләре

Соңгы елларда әдәбиятыбызның проза жанры шактый җанлана башлады. Ә бит моннан берничә ел элек кенә бу өлкәдә эшләр бер дә мактанырлык түгел иде. Хәтта «Казан утлары» журналында бастыру өчен әйбәт сыйфатлы әсәр сайлап алуы да шактый ук кыен бер мәсьәләгә әверелеп бара иде.

Аллага шөкер диик, хәзер инде бу чор узды кебек. Әмма әлеге өзеклекнең сәбәпләре нәрсәдә булды соң? Ул яңадан да кабатланмасмы икән? Башта кыскача гына шуңа тукталып узыйк.

Ул чорда прозабызның нык кына сүлпәнәюенә китергән иң зур сәбәп: тәҗрибәле өлкән әдипләрнең безнең арадан китеп баруы. Соңгы елларда гына нинди корифейлар китте бит! Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов...

Прозабызның вакытлыча йомшавына китергән икенче сәбәп: туксанынчы еллар тирәсендә илдә сәяси хәлләрнең нык кына куеруы һәм шуңа бәйле рәвештә безнең татар әдәбиятында, матбугатында да публицистик юнәлешнең үтә активлашуы, күп кенә ижади көчләрнең шуңа тартылуы, проза әсәрләренең азрак язылуы.

Әле алда әйтелгәннәрдән килеп чыгучы өченче бер сәбәп тә бар. Илдәге сәяси үзгәрешләргә һәм алар тудыра торган сәяси тотрыксызлыкка бәйле рәвештә килеп туа торган эчке, рухи тотрыксызлык. Юк, мин биредә кайсыбер ижат кешеләрендә күзәтелгән иман алыштыру турында әйтергә теләмим. Бусы инде аның тәнкыйтьтән түбән нәрсә. Мин биредә ижат кешесе өчен һәрдаим кирәкле эчке тотрыклылык — дөньядагы хәлләрне, күренешләрне, процессларны аңлап һәм төшенеп җитү, аларны аңын һәм йөрәгең белән үзләштерү хакында әйтмәкче булам. Әнә шундый аңлау һәм үзләштерүдән соң бит инде ижатчы күңелендә «әдәби әсәр» дип аталган яңа төрле яшәү, яңа тормыш тудыруга, ижат итүгә теләк, дәрт барлыкка килә.

Прозабызның тиешенчә үсә алмавы турында сүз барганда искә алмый узып китү мөмкин булмаган тагын бер фактор — матди стимулның, этәргечнең юкка чыгуы... Билгеле, соңгы араларда язучыларга түләнә торган каләм хакы бераз гына күзгә күренердәй була башлады.

Чыннан да, совет чорында без бер дә юкка гына «рухи тәрбия», «әхлакый тәрбия» дип сөйләшми идек ич. Тормышның бер дә искерми торган үтә мөһим мәсьәләсе ич ул. Әле беркөнне «Америка тавышы» дигән радиостанцияне тыңлап яттым: Кушма Штатларның бер шәһәрендә халык фикерен тикшерү уздырганнар — «сез нинди коллективта эшләргә теләр идегез?» дип. Җавап бирүчеләрнең иң зур күпчелегенең фикере мондый булган — «гадел әхлак кануннары өстенлек иткән коллективта эшләр идем!» Шулай шул: кеше һәр җирдә дә, һәр вакытта да кеше булып калырга тырыша инде ул!

Бик тә кызганыч, шәһәр тормышы, урам төркемнәре һәм сугышырга, кеше үтерергә өйрәтүче Рәсәй телевидениесе тәрбияләп үстергән бандитлар хәзер безнең арада болай да күпләп арта бара. Кемне гаепләргә дә белмәссең. Гел сугышу һәм яңа җирләр басып алу сәясәте үткәргән Рәсәй җитәкчеләренме? Үзебезнең Татарстанда әхлакый тәрбия буенча зур һәм киң колачлы эш оештыра алмаган түрәләребезнеме? Бүген матур һәм рәхәт яшәүгә омтылып, иман һәм киләчәк турында, яшь буын хакында бөтенләй истән дә чыгаручы шәхсән үзебезнеме?

Шулай, гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр. Ләкин менә бу арада әдәбиятыбызның һәм аерым алганда аның проза жанрының күтәрелә башлавын барыбер әйбәткә юрыйсы килә! Һәм ул күтәрелеш-үсеш озын гомерле булыр дип тә ышанасы килә! Безнең әдипләребез соңгы елларда үз күңелләреннән бик

күп гыйбрәтле хәлләр кичерделәр, бик күп нәрсәне аңладылар, үзләштерделәр һәм менә хәзер ныклап торып Олы Иҗатка тотындылар дип уйлыйсы килә.

Чыннан да, узып киткән 1999 елны гына алсак та, «Казан утлары» белән «Идел» битләрендә генә дә нинди матур проза әсәрләре басылган бит!

Бүгенге көннең иң оста прозаикларыннан берсе булган Фоат Садри «Идел»дә «Өченче кеше» дигән менә дигән повесть бастырды. Соңгы елларда бик тә нәтиҗәле эшләүче Нәбирә Гыйматдинова исә шул ук журналда үз укучыларын «Таң ата да кич була» дигән күләмле әсәре белән сөендерде.

Үзебезнең «Казан утлары»да үткән елда әдәбият сөючеләрне сан саен яңа һәм кызыклы әсәрләр белән таныштырды. Камил Кәримов белән Радик Фәизовның уңышлары бигрәк тә күзгә күренерлек иде. Беренчесенең «Ком сәгате» исемле романы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан берсүзсез зур уңыш диеп бәяләнде, укучылар да аны яратып кабул итте. Радик Фәизовның «Тәңре хөкеме» дигән хыялый повестеның хикмәте исә тирәндәрәк ята. Чөнки автор безне бүгенге кыргый, киләчәктә үз-үзебезне үтерәчәк яшәеш рәвешебезне ташлап, матур һәм гармоник яшәү юлына басарга өнди. Чынлыкта моның бик үк барып чыкмаслыгын аңлаган тәкъдирдә дә бу әсәр барыбер әдәбият күренеше, кешенең рухи, аң дөньясы җимеше буларак бик яратып кабул ителә. Әдип әйтергә теләгән мәгънә безнең йөрәк тибеше белән бик тә аваздаш ишетелә.

Ә инде Айдар Хәлимнең шулай ук былтыр дөнья күргән «Татар вакыты» турында әйтеп тә торасы юк! Ул әсәр авторның үзенең дә, тулаем прозабызның да уңышы иде. Әле бит былтыр шулар өстәвенә Ә.Моталлаповның «Нигез»е дә, Ә.Галиевнең «Чигенгәндә»се дә һ.б. да булды. Менә шушылардан соң ничек инде прозабыз күтәрелә башлады диеп сөенмисең ди?!

Әмма соңгы елларда иҗади активлык байрагын үз кулында ныклап тотучы әдип, ул — Рафаэль Сибат. Бу автор байтак кына каләмдәшләре турында саллы-саллы иҗат портретлары һәм эсселар язды, әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән кыю-кыю чыгышлар ясады. Аның шулай ук «Исабәт» һәм «Атлар рәнҗеше» исемле романнары дөнья күрде. Ниһаять, журналыбызның быелгы апрель-май саннарында Рафаэль Сибат «Ялгызак» дигән моңсу романын бастырды.

Иң башта ук шуны әйтеп китик: бу роман «Казан утлары»нда чыга башлау белән укыган кешеләрдә зур кызыксыну уятты. Минем үземә очраган һәр язучы диярлек шушы әсәр турында сүз кузгатмыйча калмый иде. Һәм аларның роман хакындагы беренче тәэсирләре бик тә әйбәт иде. Шунысы кызык: әсәрне ошату белән бергә алар күңелендә бер үк вакытта төрле характердагы сораулар, автор белән килешеп җитмәгән фикерләр дә байтак булды. Хәтта миңа кайбер язучылар белән әдәбият һәм иҗади дөнья күренешләре хакындагы кызыклы гына бәхәс-дискуссияләргә дә кереп киткәләргә туры килде... Менә болар барысы да, һичшиксез, роман файдасына сөйләүче фактлар.

Ә хәзер, әйдәгез, романның үзенә күчик. Ул кайсы ягы белән кызыксыну уята соң? Бүгенге укучыга нинди мәгънәләр, нинди эчтәлек алып килә?

Әйе, бу моңсу романга «Ялгызак» дигән бик тә кызыклы һәм укучыны ымсындыргыч исем куелган. Ләкин, минем уемча, бу исем бик отышлы булса да һәм үзенә тартып торса да, ул үзенең мәгънәсе белән бары тик әсәрдәге вакыйгаларның бер өлешенә генә туры килә, шуларны гына гомумиләштерә. Ягъни, икенче төрле итеп әйткәндә, ул романга өлешчә генә туры килә.

Ә вакыйгаларга килгәндә, «Ялгызак»та безнең өчен кызыклы нинди хәл-әхвәлләр тасвирлана соң?

Утызынчы еллар. Күмәк хуҗалыкка керергә теләмәгән Заһидулла Нократ елгасының теге ягына чыгып үзенә йорт тергезергә уйлый.

Дөресен әйтим: романның беренче битендә үк күрсәтелгән бу фикер, бу мәгънә укучы өчен бераз сәеррәк тоела. Чөнки авылда аның әле генә һәм бик яратып өйләнгән яшь хатыны Заһидә бар бит. Яшь парның әле сөеп-сөешеп яши башлаган чагы гына бит... Автор безгә Заһидулланың яшь хатыннан туюы кебек нәрсәнең тамчысын да күрсәтмәде, сиздермәде бит әле... Аннан соң, икенче яктан: күмәк хуҗалыкка кермим дисең икән — моның өчен авылдан читкә китү мәҗбүри түгел иде ич. Әнә безнең авылда бер гаилә гомер буена аерым хуҗалык булып яшәде, авыл уртасында йорты һәм каралтысы булган килеш...

Шуңа күрә Заһидулланың Нократ аръягында йорт тергезергә уйлавы утызынчы еллардагы күмәк хуҗалыкка каршы торудан бигрәк үз холкының сәерлеге, ачыграк итеп әйтсәк: аның табигый яшәешкә, табигать кочагында яшәүгә ныграк тартылуы буларак аңлашыла. Хәер, без әйткән менә бу фикер дә үзенең төбендә, үстерелешендә күмәк хуҗалыкка каршы тору белән килеп ялгана инде ахыр чиктә. Кешенең чын яшәүгә, үз хезмәте белән үзе көн күреп яшәүгә омтылуы буларак кабул ителә ул. Бердәнбер дөрес яшәү үрнәге буларак...

Ярый, безнең Заһидулла Нократның теге ягындагы урманда үзенә өй салыр өчен әйбәтрәк урын сайлап йөри... Менә шул чагында инде ул урман аланлыгында чегән баронының кызы Тамараны очрата. Искерәк киемнәр кигән Тамара баштарак егеткә ямьсез тоелса да, сөйләшеп китеп танышканнан соң елмаеп та җибәргәч, Тамара бөтенләй үзгәрә... Аның ерак та түгел куышы бар икән. Алар учак тергезәләр, Тамара Заһидулланы пешкән балык белән сыйлый. Учак янында юка гына киемнән йөрегән Тамарага Заһидулла тәмам гашыйк була. Якындагы куыш алар өчен Мәхәббәт Чатырына әверелә.

Гомер уза, Заһидулла үзе теләгән йортын тергезә. Ул арада авылда калган яшь хатын Заһидә малай таба. Бу шатлыклы хәбәрне ишеткән Заһидулла, сөенеченә чыдый алмыйча, Нократны йөзеп чыга! Ә көймәле Әхмәдулла аны арттан озата бара. Ярга чыгып җиткәчтен дә ул эчке ыштанын гына элэктерә дә, өенә авыл артлап кына чаба. Заһидулланың өйгә килеп керүе дә кызык — ул: «Ник елатасыз баланы?!» — диеп кайтып керә Заһидәсе янына!

Авылда күмәк хуҗалык оештырып йөрүчеләр исә Заһидуллага тынгылык бирми, аны гел-гел чакырып сүгә. Әнә шундый сүгүләрнең берсеннән соң Заһидулла ишекне каты итеп япкач, дивардагы Сталин портреты идәнгә төшеп ватыла. Икенче көнне Заһидулланы килеп кулга алалар. Төрмәдә ул Малмыж мулласы, бик тә ипле-акыллы карт белән таныша. Алар анда үзләрен кыерсытырга теләгән өч урысны кыйныйлар. Ә инде акланып төрмәдән чыккач Заһидулла читкә чыгып китә, бөтен ил буенча йөри. Әмма бер генә җирдә дә озакка төпләнә алмый... Иң ахырда, ул инде нык картайгач, вакыйга безнең көннәргә үк килеп җиткәч, Заһидулла Париждан хат ала — Тамара исән икән, ул әтисенең алтыннары белән чит илгә киткән булган, кияүгә чыккан, ләкин аның малае Заһидулладан икән... Димәк, Парижда да Заһидулланың улы яши...

Роман «Ялгызак» дигән исемле булса да, әнә шундый оптимистик рухта тәмамлана.

Әлбәттә, әле генә әйтеп кителгән вакыйгалар — болар романның төп канвасы гына, скелеты гына. Ә тулаем алганда роман уй-фикерләр һәм хис-кичерешләргә бик тә бай. Бу яклап караганда ул хәтта Нократ кебек кенә дә түгел, олы Иделебез хәтле бар. Тагын шунысы бик тә истә кала: автор үзе дә, аның каһарманнары да чын табигать баласы булып, яшәеш гүзәллеген бик тә нечкә, бик тә тирәннән тоеп баралар. Алай гына да түгел: иң заманча, иң актуаль фикерләргә дә бай бу роман. Һәм шуның белән бергә әсәргә мул булып публицистик агым да бәреп керә, анда бик иркенләп яши. Мондый агым һәр чагында да акланып ук бетмәсә дә, аннан романга тулаем алганда зур зыян да килми кебек. Ни өчен дисәң, әсәрнең бөтен барлыгы, бөтен тукымасы шундый.

Ярый, ә инде бу романның төп мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт соң?

Әлбәттә, әдәбият-сәнгать әсәренә салынган мәгънәләр бик тә күп була. Чөнки бу дөнья, әдәбият-сәнгать дөньясы, ул «образлылык» дигән хикмәти халәткә нигезләнгән. Әнә шул образлы яшәешнең эченәрәк кергән саен, яңа һәм кызыклы мәгънәләр ачыла бара. Синең кеше һәм яшәеш турындагы фикерләрең байый, тирәнәя бара. Юк, әсәр эченә керә барган саен сиңа очраган яңа фикерләр, яңа мәгънәләр алар үз элгәрләрен дә кире какмыйлар, аларны юкка чыгармыйлар. Алар, яңа мәгънәләр, элеккеләрен тагын да тулыландыралар гына. Әсәрнең образлы яшәеш мохитен тагын да тирәнәйтәләр генә алар. «Ялгызак»та да әнә шундый яңадан-яңа мәгънә катламнары бик күп. Мисал өчен менә кайберләре генә: кешенең, шәхеснең үзе теләгәнчә, үзе дөрес диеп санаганча яши алырга тиешлеге, шуңа хакы барлыгы; бүгенге урбанизация бик көчәйткән көтү, төркем, күч психологиясе һәм кешенең табигый рәвештә үзе генә калырга омтылуы, ялгызлыкта калырга теләве — чөнки бу аның исән калуы, сәламәтлеге, алда яши алуы дигән сүз; гаилә һәм шәхес иреге; татар милләтенең үтә нык чәчелгән булуы һәм туган җир проблемасы; төрле милләтләрнең үзләренчә, үзгә холык-фигыльгә ия булуы һәм аларның үзара тату яши алу мәсьәләсе һ.б.

Әмма романның иң үзәгендә, өскә калкып, менә бу югарыда әйтелгән мәгънәләрнең «башларына басып», аларның иңнәренә таянып, татар ир-аты Заһидулланың монументаль образы тора. Ул чын мәгънәсендә Ир-Ат.

Җитмешенче еллар ахырында Г.Камал исемендәге театр Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр» дип аталган әсәрен куйгач, шушы әйбәт спектакльнең исеменә мин бик тә гажәпләнгән идем. Чөнки бу бер дә ишеткән сүзем түгел иде. Безнең якта егет дигән сүз бар, ир дигәне бар, ир-ат бар — ә менә мондый «ир-егет» дигән юк иде. Шуңа күрә мин аны драматург уйлап тапкан ясалма сүз кебегрәк кабул иттем. Тора-бара дус-ишләрдән кайсыбер якта шулай әйткәннәрен ишеткәч тә, бу хакта белгәчтен дә, баштагы әлеге шигем — ул сүзне кабул итә алмавым кимемәде.

Ә инде менә Ир-Ат сүзе бөтенләй башкача. Чын, саллы, төпле сүз ул! Чын ир-атның үзе кебек ул!

Әйе, бу романның үзәгендә дә татар ир-аты Заһидулла тора. Аның язмышы һәм аның холык-фигыле, табигате тора. Алдарак без бу каһарманның башыннан кичкән хәлләрне бераз күреп үттек, хәзер инде Заһидулланың холкын аңларга тырышып карыйк.

Ул үз көченә, үзенең хәләл хезмәтенә ышанып яши торган тырыш, эшчән кеше. Нократ аръягында да ул берүзе өйлек агачларны ега, берүзе өй салып керә. Әлбәттә, бу урында автор өй салу мәшәкатьләренең эченә бигүк кереп тормый һәм мондый алым тулаем әсәр рухы белән аклана да кебек. Шуңа күрә бер кешенең өй сала алуына күңел кайчакларда шикләнебрәк калса да, нигездә, тулаем алганда бу эш мөмкин булгач — авторга аның өчен генә бәйләнеп торасы килми. Заһидулланың бераз үҗәтрәк, бераз башсызрак, бераз хыялыйрак һәм нык ук сәер холык-табигате әнә шуның ише факт-күренешләрдән җыела ич инде ул!

Зур физик көчкә ия, сау-сәламәт ир Заһидулла рухи яктан да таза: ул ихлас күңелле, садә җанлы, саф йөрәкле. Язучының үз героен менә шушындый итеп тасвирлавы, минемчә, бер дә юкка түгел. Бу — безнең еллар өчен үтә актуаль проблема. Чөнки шәһәрдә туып, шәһәрдә үскән адәмнәр бик еш очрак-

ларда физик яктан гына түгел, ә рухи-әхлакый яктан да шактый ук зәгыйфь булалар: үз яшәүләрен алар салкын акылга, сату-сатылуга, хәйләгә, астыртын эш йөртүләргә коралар. Әнә шундый эчке авыруларын алар күп белү, тыштан зыялы булып күренергә тырышу (киенүдә һәм сөйләшү рәвешендә, әлбәттә!) белән капламакчы да булалар.

«Ялгызак» романының герое Заһидулла бүгенге шуның ише типларга юри каршы куела. Ул физик һәм рухи яктан сау-сәламәт булгач, бернидән дә һәм беркемнән курыкмыйча — үзе ничек теләсә, шулай яши. Менә шушындый яшәү мисалында инде без Кеше буларак яшәүнең чын матурлыгын, чын кыйммәтен күреп алабыз! Ирекле яшәү матурлыгын!

Үзе пакь җанлы, чиста күңелле булгач, Заһидулланың кечкенә генә әшәкелеккә дә нык ачуы чыга, ул ярсып кабына, еш кына кызып та киткәли. Ләкин шулай ук тиз суына да үз эзенә кайтып та төшә.

Әмма, Заһидулла үзе кешеләргә бер начарлык эшләмәсә дә, кешеләр аңа әшәкелекне байтак кына эшлиләр. Хәләл көче белән салган өен ут төртеп яндыралар, сөекле хатыны Заһидәне үтереп китәләр, үзен төрмәгә дә ябалар... Боларның барысының да сәбәбе, мотивы ачык — Заһидулланың үзенчә, баш бирмичә яшәргә теләве күпләрнең ачуын китерә. Әсәрне укыган чагында боларны без дә яхшы аңлап барабыз.

Ләкин менә хатын-кызлар белән мөнәсәбәттә әле безгә Заһидулла табигатен аңлап, төшенеп бетәргә кирәк. Бу яклап караганда әсәрдән нинди яңа мәгънәләр килеп чыга икән соң?

Үз хатыны Заһидәгә ул яратып өйләнә. Һәм Заһидәнең соңгы минутларына кадәр шулай ярата да аны Заһидулла. Ләкин ул чагында Тамара белән булган хәлләрне ничек аңларга микән соң?

Әйе, без моңа кадәр, бигрәк тә совет чорында, үрнәк, әйбәт гаиләне ир белән хатынның кайнар мәхәббәте һәм балалар тәрбияләп үстерүе диеп аңладык. Бу, нигездә, дөрес тә. Чөнки ике арада мәхәббәт тә кирәк, матур гаилә булмаса, әйбәт балалар да үсә алмый. Ләкин бүген реаль чынбарлыкка игътибарлы булсак, бу эшнең, бу проблеманың катлаулырак икәнлеген аңларбыз. Инде турысын әйтеп, ачыктан-ачык сөйләшә башласак: элек-электән үк ни өчен күпхатынлылык булган? Хәзер, менә соңгы елларда, бу мәсьәлә нилектән яңадан көн тәртибенә куела башлады?

Җавап шул булыр: бу — реаль чынбарлык, тормыш таләбе! Хатын-кыз һәм ир-ат табигатенең төрлечә булуыннан килеп туа торган күренеш. Табигатьнең үзе тарафыннан, Ходай тарафыннан яратылган мондый үзенчәлек белән санлашу — әлбәттә, һич кенә дә гөнаһ була алмый. Әлбәттә, билгеле бер чикчама сакланган тәкъдирдә.

Хәзер инде күз алдына китереп карыйк: әгәр дә Нократның теге ягында өй салырга урын эзләп йөргән чагында Тамара очрагач Заһидулла аңа карата битараф калса — бу дөрес булыр идеме, бу эш табигый булыр идеме? Шундук һәм кистереп әйтеп була: юк!

Әнә шуңа күрә, чын ир-ат холкына ия булганга күрә, Заһидулланы ярата да инде Тамара. Һәм сөешүләренең беренче мизгелләрендә үк Заһидулла гомере буена оныта алмастай хикмәтле сүзләр әйтә ул:

— ... мой татарский конь!

Беренче карашка тән ләззәтенә генә бәйле булып күренсә дә, тора-бара бу сүзләрнең очраклы гына әйтелмәве дә ачыклана башлый. Заһидә белән бер сөйләшеп утырганда да Заһидулла: «...моннан миллион еллар элек ат булып яшәдем кебек тоела миңа»,— дигән иде бит... Аның әнә шул сүзләреннән соң бөтен Ауразия киңлекләрен бер итеп атта чабып узган борынгы төрки бабайлар да күз алдына килә... Әнә шул күренешләр арасында шифалы яңгыр сыман булып, яңадан да күңелдән «ир-ат» сүзе үтеп китә... Аннары тагын Заһидулла искә төшә — аның ерак Тын океан буендагы Татар бугазыннан алып Балтикага хәтле сәфәр кылулары... Байтак калаларда сөйгән ярлар табуы — йөрәген яндырып алуы... Шушы урында Бакый ага Урманчедан ишетелгән борынгы җырыбыз да хәтергә килеп ала: «Шәһәрләр саен сөйгән ярым бар ие...»

Менә болар барысы да элеккеге татар дөньясының зурлыгын, киңлеген күрсәтеп тора. Шул зурлыкны раслый, безнең күңелләрдә яшәтә.

Ләкин әсәрне укымаган кешедә Заһидулла турында ялгыш фикер кала күрмәсен — мәхәббәт диеп бөтен дөньясын оныта торган зат түгел ул. Әнә бит, дусты Мәкчимнең хатыны Анна үзе аның янына килгәч, Заһидулла аны кискен рәвештә кире бора! Хәтта өйдән үк чыгып китә! Һәм бусы да бик ышандыра, табигый. Чөнки Заһидулла саф күңелле, керсез җанлы кеше!

Кайсыдыр бөек бер философның: «Хатын-кызга һәм табигатьтәге җан ияләренә булган мөнәсәбәтеннән чыгып кешенең нинди икәнлеген әйтергә мөмкин»,— дигән бик акыллы сүзләре бар. Бу фикер «Ялгызак» романының төп каһарманы Заһидуллага бигрәк тә туры килә. Чыннан да, аны хатын-кызлар ярата. Ә бу инде, гомумиләштереп әйткәндә, тулаем тормышның, тулаем табигатьнең аны яратуы, аны үз күрүе дигән сүз. Димәк, Заһидулла — табигатьнең, яшәешнең үз кешесе дигән сүз. Заһидулла — тормыш һәм табигать кушканча баручы, яшәүче дигән сүз Төп юлдан, олы юлдан баручы дигән сүз.

Әсәрдә Заһидулла образына салынган иң зур мәгънә, минемчә, әнә шундый.

Әсәрдә бик кызыклы һәм истә кала торган башка образлар да бар. Тамара белән Заһидәдән соң иң хәтердә кала торганы — керәшен Мәкчим бугай. Аның сүз саен диярлек «чәпчим» диеп сөйләшүе генә түгел, ә бөтен килеш-кыяфәте, холкы-табигате үзенчә сөйкемле һәм яраттыра торган. Тик менә аның

Заһидулла төзегән өйне яндыруы гына ул үзе әйткәнчә: «Тегеләр сине шул утка салып яндырмасыннар дидем»гә түгел, ә бүтәнрәк сәбәптән булып аңлашыла. Хатыны Анна Заһидуллага кызыга башлагач, шуның ачуын Заһидулла өеннән алу дип аңлашыла бу эш роман барышыннан чыгып карасак. Ләкин автор үзе бу турыда анык кына бер сүз дә әйтми — ул күрсәтеп кенә бирә. Биредә безнең үзебезгә уйларга һәм логик фикер йөртергә кала. Әдәби әсәр әнә шундый урыннары белән көчле дә бит инде ул!

Заһидуллага төрмәдә очраган Малмыж мулласы да бик колоритлы фигура булып чыккан. Ул тирән акылы, сабырлыгы, төпле холкы белән истә кала һәм, гомумиләштереп әйткәндә, бер Заһидулла өчен генә түгел, ә безнең күпләгән милли көрәшчеләребез өчен дә үрнәк булып тора. Ул безгә «милли көрәшнең үзәгенә сабырлык һәм акылны салыгыз, егетләр!» дип яши сыман.

Романда төрле милләт вәкилләре шактый күп күрсәтелгән. Урыслар да, яһүдләр дә, Балтыйк буе халыклары да һәм Урта Азиядә яшәүчеләр дә үзләренә хас холык-фигыльгә ия итеп, кызыклы күренешләр аша бирелә. Икенче төрле итеп әйткәндә, татар милләтеннән булган Заһидулла әнә шулар белән янәшә куела, чагыштырыла кебек. Әнә шул янәшәлектә татарның эш сөюе, ихлас ярдәмчеллеге, оптимизмы, сабырлыгы күзгә ташланып ук тора. Билгеле, бүген кайсыбер яшьләр татарның хезмәт сөючәнлегеннән көләргә дә тырыша. Бер каләм әһеле «Идел»дә хәтта бу хакта язып та чыкты. Ләкин, егетләр, шуны онытмыйк: бу безнең милләтебезне гасырлар аша саклап килгән сыйфат! Татарның рухи пакьлеген, чисталыгын һәм хезмәт сөючәнлеген башка милләт вәкилләре дә билгеләп үтте, язып чыкты. Ул әйбәт бәһаләр безгә бер дә зыянга булмады. Хәвефле елларда тулаем халкыбызны өр-яңа һәм зур фаҗигаләрдән да саклап калды! Әлбәттә, әлеге тырыш хезмәтнең җимешләре дөрес бүленмәү — анысы бар һәм ул хакта әйтергә, ул проблеманы дөрес, гадел хәл итәргә кирәк. Ул яктан гаделлек булырга тиеш. Бусы турында ике төрле сүз дә булырга мөмкин түгел! Ләкин моңа карап кына без татарның хезмәт сөюеннән көләргә тиеш димәгән. Мисал өчен, хәзер Татарстан дигән үз йортыбызда, башка милләтләр бигүк эшләргә яратмый сылтавы белән татар үзе дә эшләмәсә — безнең Татарстан дигән бу илебез, бу йортыбыз ни хәлгә калачак соң?! Көлкегә калачакбыз бит дөнья күләмендә!

Кайсыбер яшь әтәчләргә бу яклап та акыл бирә Рафаэль Сибат. Аның үзәк герое Заһидулла бер генә эштән дә чирканмый, курыкмый. Чын ир-ат булып кала!

Әнә шуңа күрә дә Тамара һаман аны сагынып Париждан хат яза.

Көнбатышның алдынгы бер иле Франция башкаласыннан килгән бу хат символик мәгънәгә дә ия кебек. Мәгъриб иленең дөрес яшәү юлын, иманлы һәм табигый яшәү юлын сагынуы, юксынуы кебек тә кабул ителә. Ә инде Заһидулла малаеның анда үсүен белүебез, шулай ук соңгы елларда газеталар хәбәр иткән факт — Ауропада Ислам тәгълиматы тарафдарлары көчәя бару — болар һәммәсе безнең укучыда киләчәккә булган оптимизм хисләрен тагын да көчәйтә.

Әйе, «Ялгызак» романы безнең егерменче гасыр тормышын бик тә киң колачлый. Әсәрнең төп герое Заһидулланың гасыр башында ук тууы (автор моны төгәл әйтмәсә дә, күмәкләшү елларында төп геройга 29 яшь булгач — без уйлаганча чыга ич инде!) һәм бу көннәргә хәтле яшәве дә аның турында «гасыр кешесе» дигән фикер тудыра. Моңа хәтле дә татарның типик бер вәкиле, гомумиләштерелгән үзәк фигурасы дигән тәэсир уяткан Заһидулланың инде вакыт ягыннан да шушындый дәвамлылык алуы укучы күңелендәге масштаблылыкны, монументальлекне тагын да көчәйтә. Безнең көннәрдә яшәүче Заһидулланың күңел көрлеге һәм аның малайлары-оныклары алдында ачыла башлаган зур перспектива — шулай ук укучыга бик тә матур, рухландыргыч тәэсир ясый. Күңелдә яңадан Тукайлар, Әмирханнар, Исхакыйлар чорындагы Яңарыш дулкыннары уйный башлый. Бу гасыр башы да шулай матур башлансын иде, диеп тели йөрәкләр.

Романны укыган чагында «тешкә тия» торган урыннар да байтак кына очрый. Менә әсәрнең башланып китүен алыйк. Беренче биттә үк Заһидулланың күмәк хуҗалык төзүгә кискен каршы чыгуы күрсәтелә. Бәлки, ул реаль чынлыкта шулай буладыр, булгандыр да. Ләкин безнең көннәр укучысы өчен мондый башлам инде артык сәяси булып кабул ителә. Моны бирү бик кирәк булган очракта да нык психологик мотивлаштыру, нечкәләп үрү сорала иде. Ә турыга ярып, примитив сөйләшү рәвешендә түгел! Яңа төсмерләр салып, кызыклырак итеп кирәк иде. Бүгенге көн бәхәсләренә дә саллы дәлил булырдай сүзләр белән. Роман хәтле романның башлануы бигрәк тә шундый эчтәлек сорый ич.

Аннары тагын бер гомумирәк пландагы фикер, теләк туа. Автор биредә утызынчы еллардагы күмәкләшүне берсүзсез гаепләп чыга, вакыйга-күренешләргә шулайрак бәя бирә. Ләкин объектив дөреслеккә якынрак булсак, барыбер «монда тормышның үз таләбе дә көчле булды ич» диярга туры килә. Күмәкләшү үзе түгел, ә ул эшне көчләп оештыру ялгыш булды бит! Авыл кешеләре әле хәзер дә күмәкләшми эшли һәм яши алмыйлар. Чит илләр чынлыгы да шуны күрсәтә: анда да иң зур продукцияне зур хуҗалыклар бирә, ә вак фермерлар түгел.

Романның беренче битләрендә үк сизелгән һәм ышандырып бетермәгән менә шушындый сәяси мотивлар, билгеле, әсәрнең объектив агышына ышануны киметә төшә. Күңел әсәр авторын шактый ук субъективлыкта гаепли. Һәрхәлдә, әдәби әсәр тукымасында сәяси карашлар белдерелгән очракта да, алар инде бөтен катлаулылыгында чагылырга тиеш иде.

«Ялгызак»ның соңгы өлешендә вакыйгалар җирлеге бик нык киңәя. Шуңа бәйле рәвештә катнашучылар саны да шактый ук арта, аларның байтагы истә дә калмый. «Алар кирәк идеме икән соң?» дигән сорау да туа. Билгеле, монда да кызыклы күренешләр бар, «читтә яшәүче татарлар эреп, юкка чыгып бетеп баралар» дигән мәгънәле фикер бар — ләкин романның бу өлеше, урыслар әйткәндәй, «галопом по Европе» дигәндәйрәк тәэсир тудыра.

Ә моннан котылып була идеме соң? Бәлки, Заһидулла йөрегән урыннарны болай ук күп күрсәтмәскә кирәк булгандыр? Ерак Көнчыгышны һәм тагын берәр урынны гына биреп тә шундый ук тәэсир калдырып булмас идеме икән? Кешеләр саны да кимер, нәтиҗәдә алар истә кала торганрак, тулы канлырак образларга әверелер иде. Мәгънәви тирәнлек арта төшәр иде. Бәлки, күләм ягы да байтак кына кимер иде...

Романдагы образлар, нигездә, тулы канлы кеше булып яшиләр. Ләкин менә кайсыберсенең сөйләшүләрен индивидуаль үзенчәлекле итәм диеп Рафаэль Сибат артыграк тырышып җибәргән сыман. Заһидулланың хатыны Заһидәнең (исемнәре дә ничек туры килеп тора — кара әле син аны!) сөйләгәндә сүз саен диярлек «ah, ah!» диеп әйтүе дә бер дә табигый кебек кабул ителми, моңа ышануы да кыен. Аннары ни өчендер бу «ah»лар әсәрнең беренче өлешендә бөтенләй юк, ә инде икенче өлештә җөмлә саен диярлек! Туйдыра башлый, биллəһи!

Мәкчимнең сөйләмендәге «чәпчим» сүзе дә аның хәтле үк кирәк булды микәнни соң?! Биредә дә чама хисе югалган дигән тәэсир кала.

Аннары менә мондый «экзотик» сүзләр шушы ике герой телендә бар, ә бүтәннәрнекендә бик үк колакка чалынмый, күзгә ташланмый. Бу хәлне ничек аңларга? Алайга китсә, һәркемнең сөйләме үзенчә кызыклы кабатланмас сөйләм була бит әле ул... Димәк, бу яктан да авторның эшләп бетерәсе урыннары калган.

Ләкин ничек кенә булмасын: безнең алда бик кызыклы роман, әйбәт әдәби әсәр! Аны тулаем укып чыккач, минем хәтергә җитмешенче еллар башында безнең прозада күзәтелгән бер күренеш искә килеп төште. Үтә талантлы һәм бик үзенчәлекле әдип Мөхәммәт Мәһдиевнең әле яңа гына проза яза башлаган еллары иде бу. Әнә шул чагында редакцияләрдәге һәм нәшрияттагы кайсыбер әфәнделәр «мондый проза булмый» дигән тавыш чыгарды. Ягъни аларга яңа авторның яңача язуы ошамый иде! Күнегелгән, ияләшелгән кануннарның санга сугылмавы ошамый иде! Мөхәммәт Мәһдиевтә лирик башлангыч та бик көчле, субъективлык та алагаем ага, җиренә килеп җитмәгән урыннар да байтак кына күзгә ташлана... Ләкин, ничек кенә булмасын, анда — ирек рухы, иркенлек көчле, тормыш сулышы көчле иде! Төптере кешеләр, характерлар яши иде анда! Шуңа күрә ул бик тиз арада укучылар, халык мәхәббәтен казанды да!

Соңгы елларда Рафаэль Сибатның прозага килүе дә әнә шул чактагы хәлләрне искә төшерә. Чыннан да, аның әсәрләрендәге зур шәхесләр, киң масштаблылык, күп чагында күзгә үк бәрелә торган монументальлек, вакыйгаларның киң агымы һәм тирәнлеге кайсыбер «стиляга-стилистлар»га ошап та җитмәскә мөмкин. Бары тик матур җөмлә төзү уе белән генә яшәүче, стиль турында гына уйлаучы яшь прозаикларны күздә тотам мин әнә шулай дигәндә!

Әмма сез Лев Толстойлар һәм Гаяз Исхакыйлар, Чехов белән Буниннар һәм безнең Еникилар ижатын алып карагыз — аларның һәммәсендә иң башта, иң элек тормыш, яшәеш көче тантана итә! Яшәеш фәлсәфәсе, трагедиясе һәм матурлыгы ургылып ага аларда! Шуңа күрә без, проза әсәрләренә бәя биргән чагында, көзге каршында сәгатьләр буена бизәнгән хатын-кыз кебек «чибәр» әдәби әсәрләр белән Олы Тормыштан килүче әдәби әсәрләрне бергә бутамасак иде... Әйе, бәлки, әдәби әсәрләрнең һәр ике төре дә кирәктер. Хатын-кызның сәгатьләр буена көзге каршында бизәнүен дә начар диеп булмый... Ләкин... Ләкин — барыбер: әсәрдәге зурлык, чынлык, тирәнлек әллә каян сизелә, күренә һәм ул безнең күңелләрне үзенә тарта!

«Ялгызак» романы белән беренче танышу күңелдә әлегә әнә шундый тәэсирләр уята.

2000

Каргышлы еллар

... 1974 елда язучы Рәфкать Кәраминең «Капитан Хәкимов» дигән повесте аерым китап булып басылып чыккан иде. Ул вакытта минем үземнең дә, офицер шинеле киеп, Ерак Көнчыгышта хезмәт итеп яткан чагым, шуңа күрә ялга диеп Казанга кайткач, кибеттә күрү белән сатып алдым мин бу китапны. Белми-күрми дигәндәй генә алсам да, күңелем дөрес сизенгән икән: ул миңа бик күп яктан якын китап булып чыкты. Хәтта андагы вакыйгалар сурәтләнгән урын да мин армиядә хезмәт итеп яткан җирдән ерак түгел иде. Әсәрдәге капитан Хәкимов белән без фәкыйрегез лейтенант Вәлиевне бары тик Татар

бугазы гына аерып тора иде! Ягъни язучы Р.Кәрами үзенең повестенда Сахалин утравында хезмәт итеп ятучы татар офицерының тормышын сурәтли.

Менә хәзер, ул китапны укыганга инде утыз еллап вакыт үткәч, яңадан искә төшереп, хәтердә яңартып карыйм. Совет офицеры тормышын күрсәткән әлеге повестьның эчтәлеге ни дәрәҗәдә «искерде» икән? Ул үзенең кызыклыгын һәм актуальлеген күпмегә югалтты икән? Әле бит шунысы да бар: язучы үзенең бу китабын ул чакта бик тә «модадагы» социаль заказ буенча да иҗат иткән булырга мөмкин бит әле! «Армия тормышыннан әдәби әсәрләр бик аз» дип, Татарстан китап нәшрияты әдипләргә андый заказларны шактый күп биргәләде бит — бусы бер дә сер түгел... Һәм дөресен әйтик: бу алымны хәзерге демократия чорыннан торып караганда да гаепләп булмый! Күрәсең, монда төп хикмәт нинди авторның алынуында булгандыр — «заказ» сүзе ул җәмгыятьнең көткәне, укырга теләгәне дип тә аңлашыла иҗ әле!

Повестьтагы бөтен персонажларны, вакыйгаларны кабат-кабат искә төшереп утырдым һәм ахыр чиктә шундый фикергә килдем: «Капитан Хәкимов»ны бүгенге укучы да яратып кабул итәчәк — чөнки бу әсәр кеше турында! Анда җанлы кешеләр яши, реаль вакыйгалар һәм конфликтлар күрсәтелә. Ерак Көнчыгышның юлбарыслар йөри, йөземнәр, карбызлар үсә торган табигате дә бик матур итеп һәм шактый тулы тасвирлана ул повестьта. Укучы үзе барып күргәндәй була.

Казанга кайтып яши башлагач тагын шуны да белдем: язучы Рәфкать Кәрами иҗаты турында матбугатта шактый әйбәт кенә фикерләр дә әйтелгәләгән икән. Бигрәк тә Фәрваз Миңнуллинның «Кичке уйлар» дигән мәкаләсе (Р.Кәраминең шул исемдәге китабы турында) һәм Барлас Камалов язмалары истә калган. Әлбәттә, Ерак Көнчыгышта ук күңелдә туган кызыксыну белән Р.Кәраминең ул вакытка хәтле чыккан башка китапларын да табып укыдым. «Дүрт кешелек каюта»ны, «Кичке уйлар»ны... Боларны укып чыккач, язучы турындагы фикерләрем тагын да тулыланды, тәэсирләр дә тагын да яхшырды.

«Социаль заказ» дигән нәрсә турында сүз кузгатып алган идек, менә шуңа яңадан әйләнеп кайтмыйча булмый әле. Эш шунда: Рәфкать Кәрами җитмешенче еллар ахырында, сиксәненче еллар башында «Очар кошлар белән янәшә» исемле трилогия бастырды. Язучылар белешмәсендә бу әсәр хакында: химкомбинат коручы төзелеш оешмаларының берсе турында сүз бара диелә.

Әйе, 1978 елда «Казан утлары» журналында басылгач ул трилогиянең беренче кисәген мин дә укыган идем. Дөресен әйтим: һич кенә дә яхшы тәэсир калмаган иде! Чөнки анда үзенчәлекле каһарманнар да, зур вакыйгалар да, мөһим проблемалар да юк иде. Соң уйлап кына карыйк инде. Михаил Шолохов казак егете Мелеховның революция чорындагы олы трагедиясен язды... Алексей Толстой, урыс зыялылары фажигасен күрсәтеп, «Михнәтле заман» трилогиясен тудырды... Аларда зур вакыйгалар, олы каршылыклар, сыйныфлар, социаль агымнар, көчле шәхесләр бәрелеше! Ә безнең язучыбыз исә... химкомбинат тормышыннан алып трилогия иҗат итмәкче! Менә бу очракта инде без «социаль заказ» дигән нәрсәнең чын асылы белән очраштык. Бу инде, үзебезчә тупас итеп әйтмәсәк тә, китапча әйткәндә, бармактан суыру! Билгеле, Рәфкать Кәраминең бу җимгә эләгүе дә гаҗәп түгел. Ул озак еллар буе төзелеш оешмаларында эшләгән, аны бик яхшы белә.

Бу күренеш хәзер безгә нәрсә турында сөйли. Минемчә, ул шул хакта искәртә: шәхес буларак, гражданин буларак язучының буыны ныгып җитмәгән булса — аның сәләте вакыт-вакыт ялгышрак тыкрыкларга да кереп китәргә мөмкин икән. «Эшче темасы» дигән нәрсәнең торгынлык чорында безнең татар әдәбиятында гаять киң таралуын бары тик әнә шуның белән генә аңлатырга була. Ә бит Әмирхан Еники, Нурихан Фәттах, Салих Баттал бу «җим»гә алданмады! Чөнки шәхес һәм гражданин буларак буыннары нык иде аларның!

Тагын шунысы кызык: торгынлык елларында шул ук Рәфкать Кәраминең «Сагышлы кояш» дигән бик уңышлы, чын әдәби әсәре дә басылып чыкты! Аның бу китабын без сокланып укыдык, сәләте өчен сөендек. «Аттан ала да туа, кола да туа» дигән сүз шушы була микәнни инде? — дип эчтән уйландык та...

Менә илдә үзгәртеп кору еллары башланды... Исеме мәгълүм байтак кына әдипләрнең иҗаты туктalып, сөрлегеп калды. Ләкин ул чакта «Кичке уйлар», «Дүрт кешелек каюта», «Сагышлы кояш» сыман кызыклы һәм мәгънәле китаплар чыгарган язучы Рәфкать Кәрами өчен тынлык, тукталыш булырга тиеш түгел сыман иде. Ләкин соңгы ун елда аның иҗаты да шактый гына салмакланды кебек тәэсир кала! Дөрес, матбугатта аның хикәяләре күренгәләде. Мисал өчен, 1995 елда «Казан утлары»ның II санында басылган «Авылдаш» исемле нечкә психологик хикәясен әйтергә мөмкин. Шулай ук Рәфкать әфәнде, матбугат битләрендә милләтебез һәм аның мәдәнияте мәнфагатен кайгыртып, мөһим эчтәлекле мәкаләләр бастырды. Авылларда күп йөрүче әдип буларак ул инде, әлбәттә, халыкның ничек сулаганын бик яхшы белә.

Шулай итеп, «Үзгәртеп кору башлангач, Рәфкать Кәрами дә әдәби иҗатта сүрелә төште» диеп йөри идек, «Казан утлары» журналы үзенең 1992 елгы I һәм 2 саннарында аның «Каргышлы юллар» исемле романын урнаштырды. Ә әсәр ахырында исә язылу вакыты итеп 1989 ел күрсәтелгән. Тукта әле, бу зур гына күләмле роман өчен кирәкле бик күп материал туплауны һәм аны озаклап, җентекләп иҗат итүне дә уйласаң — әдип һич тә тукталып тормаган булып чыга түгелме соң?! Шулайдыр: Сарман ягында ту-

ып, бала чактан ук авыл, крестьян тәрбиясен үзенә сеңдереп үскән егет биредә дә авыл кешесенең әйбәт холкына тугры булып калгандыр — гомерен бушка, әрәмгә уздырмагандыр. 1989 елда язылып беткән роман әнә шуңа бер саллы дәлил. Үткән елны исә бу роман Татарстан китап нәшриятында 6 мең генә тираж белән булса да (шушындый кызыклы һәм тәрбияви әһәмияткә ия әсәр өчен бу бик тә аз тираж, билгеле), аерым китап булып басылып чыкты.

Бу әсәр язучының үзе өчен дә һәм шулай ук безнең бүгенге прозага да хас булган мөһим генә сыйфатларны чагылдыра. Шуңа күрә, әйдәгез, кечкенә пыяла савытка салып диңгез суын тикшергән сыман — шушы бер роман аша үзебезнең бүгенге әдәбиятны, һәм анда уңышлы гына ижат итеп килүче бер әдибебез дөньясын аңларга тырышыйк.

Әсәрнең эчтәлеген кыскача гына әйтеп бирергә уйласак, Сталинның шәхес культы елларында бер гаепсезгә төрмәгә утыртылган намуслы кешеләр турында, диярбез. Әйе, мондый әсәрләр бездә булды. Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү»е, Гурий Тавлинның «Афәт»е... Аяз Гыйләҗев истәлекләре... Болар — үзләре Сталин төрмәсен «татыган» кешеләр. Аларның язганы да документаль әсәр дип кабул ителә, әдипләр үз күзләре белән күргәнне, үз тәннәре һәм җаннары белән кичергән газапны безгә җиткерделәр.

Китап булып басылып чыккан бу әсәрнең жанры «роман» диеп куелган. Журнал варианты белән чагыштырганда исеме дә үзгәргән: тегендә «Каргышлы юллар» булса, монда инде — «Каргышлы этаплар». Авторның роман исемен ни өчен үзгәртүе турында уйланабыз да, мондыйрак фикергә киләбез. «Этаплар» дигән сүз үзе татарча булмаса да, ике мәгънәне белдерүе белән роман исемен шактый тирәнәйтә бугай. Чыннан да, «этап» дигәндә тоткыннарның сөргенгә баруы да күзаллана һәм, шул ук вакытта, икенче мәгънә катламы буларак, тулаем безнең ил үткән тормыш, вакыт этаплары да уйланыла бит.

Романның тышкы төзелеше дә уй-фикернең менә шушындый агышын хасил итә, шуңа юл бирә. Байтак кына бүлекләр алдыннан ил күләмендә барган репрессияләр турында документаль мәгълүматлар, саннар бирелеп бару әнә шундый тәэсир калдыра. Роман үзе Мотаһир Фарукшин исемле гади бер авыл кешесенең ул еллардагы фаҗигале язмышын тасвирлый, ә әлеге җан тетрәткеч, миллионлаган кешеләр фаҗигасен аңлатучы саннар СССР дигән бөтен илнең коточкыч бер төрмәгә әверелгән булуын раслап бара.

Ләкин нинди генә кырыс еллар булмасын, җирдә яшәү дәвам иткәндә, кешеләр үзләренә хас булган сөенү, өметләнү хисләреннән дә мәхрүм булмыйлар шул. Әле алай гына да түгел: биологик дәрәҗәдә һәр җан иясендә була торган әнә шул иң эчкәре, иң нигез тойгылар социаль тормыш авырлашкан чакларда адәм балалары өчен төп терәккә, бердәнбер таянычка әверелеп кала. Караңгы, кара, салкын еллар полосасында аларның җаннарын саклап кала...

«Каргышлы этаплар» романының беренче битләре дә авыл тормышының җанга тынычлык, рәхәтлек бирүче күренешләрен тасвирлый.

«Уртага яткан өч яшьлек Әгъдәсне уятмаска тырышып, Мотаһир шыпырт кына хатынына дәште:

— Мөсәмирә, торасыңмы әле?!

Хатыны уяу икән. Ак яулык бәйләгән башын чак кына калкытып иренә яратып карады.

— Торыйммы соң?»

Бер караганда бу инде гап-гади бер күренеш, дөньяның табигый агышы. Әмма... Әмма... Әйдәгез әле, менә шушы күренешнең чын эчтәлегенә керик, аны тулы мәгънәсендә аңлап бетерик. Сау-сәламәт ир белән хатын... Алар бер-берсен нык, ышанычлы ярату белән ярата... Урталарында мәхәббәт җимеше — малай да мышнап йоклый. Аларның өе җылы, дөньялары тыныч. Тамаклары да тук...

Әле генә без санап киткән менә шушы нәрсәләр, менә шушы хасиятләр — адәм баласы өчен иң зур бәхет, иң олы мәртәбә түгелме соң инде?! Бүген дә: көн вә төн дөнья куганнан соң, әллә никадәр этлекләр эшләгәннән соң һәм кешеләр башына баса-баса күпмедер югары күтәрелгәннән соң да, кайбер адәмнәр өчен әнә шул бәхет ирешелмәгән ерак хыял гына булып кала түгелме?

Язучы Рәфкать Кәрами ижатының бу әсәрдә дә нык чагылган һәм алдарак без искә алган әдипләр, тәнкыйтьчеләр дә билгеләп үткән иң матур сыйфаты да әнә шул: әдип кешеләр яшәешендәге әнә шундый иң нигез, иң мөһим, иң кадерле рухи-әхлакый хәзинәләрне үз әсәрләрендә тирән итеп, тәэсирле итеп сурәтләп бирә белә. Кешелек тормышының үзәген тәшкил иткән нигез хасиятләр, иң төп юлның баганалары гаять тә ачык һәм дөрес тасвирлана аның әсәрләрендә.

Шул уңайдан тагын бер мөһим нәрсәне онытмыйк әле. Әсәр персонажларының исемнәре турында дип әйтүем. Иң үзәктә — Мотаһир, Мөсәмирә. Аларның малайлары Әгъдәс... Менә шушы исемнәрне ишеткәч сезнең күңелдә ниндирәк уй-тойгылар туа? Ә минемчә, болар мондый исемнәр — чынлык, ныклык, ышанычлылык символлары булып ишетелә. Ул исемнәр үзләре үк гади, әмма нык үзәкле һәм ышанычлы кешеләр турында сөйли.

Гап-гади татар авылында беркемне дә җәберсетмичә генә көн күреп яткан менә шушы ихлас, эчкерсез кешеләр дөньясына һич тә көтмәгәндә бәла килеп керә. Бу бәланең чыганагын да, аның чын тор-

мыштагы чып-чын җирлеген дә Р.Кәрами дөрес күрсәтә. Мотаһирны Мәскәүдәге олы җитәкчеләр кушуы буенча түгел, ә шул ук авылда яшәп яткан бер хөсет адәм «чакканга күрә» алалар.

Романның менә бу урыны шулай ук татар тормышы турында тирән уйларга тарта. Гадел һәм ихлас яшәүче кешеләр ни өчен кайберәүләргә ошамый? Бу — ак белән кара төснең бер-берсен фаш итүе кебек күренешме? Үз янәшәсендәге Аклыкны алып атса, үзенең каралыгы күренмәс дип уйлыймы әллә тормыштагы Кара төс? Ә конкрет бу әсәрне алсак, Мотаһир — авылның ревкомиссия рәисе икән. Ул кайберәүләргә урлашырга комачаулый икән!

Татар авылында яшәп яткан бер кешене кулга алу күренеше шулай ук киң гомумиләштерү көченә ия. Биредә Мотаһир гүяки СССР дигән империянең барлык намуслы, гаепсез кешеләрен гәүдәләндерә. Алдашуга, сатуга һәм икейөзлелеккә нигезләнгән бу җәмгыять ул чакта үзенең иң гадел һәм иң фидакарь җаннарын төрмәләргә тыгып бетерде бит. Халык өчен диеп җан атып йөргән иң саф күңелле затларны төрмәләрдә юк итте бу җәмгыять! Империя урнаштырган менә шушы канун хәзер дә тәмам үлгән дип кем әйтә ала?! Хәзер дә югарыда күпчелек икейөзлеләр һәм мәкерлеләр утыра түгелме?! Иң сафлар һәм иң фидакарьләр бүген дә күпләп кырыла түгелме?! Сталин хәйләкәрлегенә, Сталин мәкерлелегенә ия шома кешеләр бүген дә фидакарь затларны теге дөньяга матур-матур сүзләр сөйли-сөйли рәхәтләнеп озата түгелме?!!

Романның беренче өлеше укучы күңелендә әнә шундый гасабилы уйлар уята. Төп каһарман Мотаһир язмышыннан килеп чыгып, бүгенге көн кешеләре яшәешенә килеп ялгана торган мондый уйлар, әлбәттә, әсәрнең бәһасен дә күтәрә, аның тәэсир көчен дә арттыра.

Автор файдасына тагын шуны әйтергә кирәк: ул шомлы утызынчы еллар тормышын бик нык өйрәнгән. Китапны укып барганда, чынлыгына шик туардай, ышандырмастай эш-гамәлләр күренми. Ә менә психологик яктан нечкә тотып алынган һәм шул чор тормышын, шул чор кешесенең күңел халәтен төгәл ачып бирә торган ситуацияләр күп. Менә берсе.

«Ул, туңмас өчен, төрмә каршында әрле-бирле йөренә башлады. Капка төбеннән урам чатына хәтле бара да кире китә. Туктап тора, тагын китә... Ашыйсы-эчәсе килсә дә, туңса да түзде Мотаһир, читкә китмәде, кешеләр белән дә сөйләшмәде. Шулай да бер мәртәбә аңа сүз катучы булды. Күрәсең, болар төрмәдәге туганнары янына килүчеләр иде. Берсе яшь, икенчесе олырак ике хатын аның янында тукталды.

Яшьрәге пышылдап кына:

— Абый, сезнеке ничәнче камерада утыра? — дип сорады.

Ләкин Мотаһир аңа ни дип әйтергә дә белмәде, ярдәме тимәде.

— Юк шул, үскәнем, мин кеше янына килмәдем.

...Конвойчылар район белән элемтәгә кергәннән соң, мәсьәлә көчкә ачыкланды: дүрт-биш сәгать үткәч, караңгы төшкәндә, Мотаһирны кабул иттеләр».

Менә хәзер, туксанынчы елларда — егерменче гасыр инде тәмамланып килгәндә — төрмә капкасы төбендә сәгатьләр буе таптанып, үзен төрмәгә алып кереп китүләрен көтеп йөрүче кешене күз алдына китерүе, башка сыйдыруы да кыен. Әмма илдә Сталин төзегән чынлык нәкъ әнә шундый була шул: кешегә кол психологиясе тәмам сеңдерелә. Бу вакытта инде илдәге бөтен юллар Римга түгел, ә төрмәгә илтә. Романда Мотаһир болай дип уйлый: «Аны барыбер эзләп табачаклар. Ул җир читенә китеп олага алмый бит, китсә дә, килгән юлына кире төшәр — өенә кайтыр. Тагын борчу, тагын шул ук каталажка, этап... Монысыннан да яманрак булыр...»

Әйе, болар — тәмам куркытылган кешенең уйлары. Империядә яшәүче һәр кешене биләгән, богаулаган тойгылар алар. Ләкин романны укыганда без татар кешесенә хас булган сыйфатларны байтак кына табабыз. Димәк, язучы Р.Кәрами үз каһарманнарының милли һәм индивидуаль үзенчәлекләрен дә ача алган дигән сүз бу.

Мотаһирның төрмәдәге беренче төнендә үк ачыла башлый андый хасият. Үзенә бик тә кыен була башлагач ул күңеленнән генә өйдәгеләрне исенә төшерә дә, йөрәгенә бераз җиңеллек тоя һәм шуннан соң болай уйлый: «Бәлки, шушы уй аны чатнама суыкларда җылытып, өметсезлеккә бирелгән чакларда күңелен күтәреп, ач вакытларда җан азыгы булып торыр, гел озата йөрер. Бәлки, Мотаһир бары шушы уйлары аркасында гына исән калыр — кирәк-кирәкмәс адым ясаудан тыелып калыр. Бик күп ялгышлар билгесезлектән, сине көтеп, кылган гамәлләреңне хөкем итеп торучы булмаудан ясала. Әгәр ата-ана, кардәш-ыру, авыл халкы алдында җаваплылык тою, бурычлы икәнеңне аңлау хисе булса, бик күп җинаятьләр эшләнми калыр иде. Кече яшьтән каныңа сеңгән тәүфыйк, әдәп кагыйдәләрен бозмаска тырышу — безнең халыкны һәркайда күркәм итеп күрсәтүче асыл сыйфатлар түгелме соң?»

Тоткынлыктагы беренче төнендә Мотаһир кичергән менә бу уйлар бик тә тәэсирле! Утызынчы еллар кешесе күңелендә туган ул фикерләр романны укыган чагында сине бер мәлгә туктатып калдыра, бүгенге кешеләр, хәзерге күренешләр турында тирән уйларга чумдыра. «Бүгенге кешеләрнең тәүфыйксызлыгы каян килә?» дигән үткен сорау тирәсендә бөтерелүче уй-фикерләр алар.

Әйе, безнең татар әдәбияты бу олы сорауга җавапны инде озак еллар буена эзли. Иң җитди иҗат көчләребез әнә шул өлкәдә тырыша. Чөнки бездәге әдәбият ул — Көнбатыш илләрендәге кебек мавыгу,

күңел ачу чарасы гына түгел. Бездә әдәбият — тормышның иң җитди яклары, аеруча кешенең рухи-әхлакый яшәеше турында ихластан һәм газаплы уйлану, эзләнү ул.

Менә хәзер, безнең көннәрдә, әдәбият өчен шактый зур ирек килде. Ирек ул, әлбәттә, үзең теләгәнчә эшли алу дигән сүз. Ләкин дөрес рухи-әхлакый кыйбласы булмаган кешенең иреге ул нинди була соң? Ул — телеңә ни килде, шуны сөйләү, алдын-артын уйлап тормыйча нәрсә эләгә, шуны язу, кешене көлдерү өчен теләсәң ничек кылану-кылтаюмы?

Әйе, әле татарлыгы бетмәгән чын авыл тормышында туып үскән өлкән һәм урта буын әдипләре безне зур рухи кыйммәткә ия әдәби әсәрләр белән куандыралар, милләтне эстетик һәм рухи яктан тәрбияләр. Ләкин шуның белән бергә яшь буын иҗатчыларда әхлакый юнәлеше аныкбулмаган, бары тик кызыкка яисә тупас натурализмга гына корылган язмалар да шактый күренә башлады. Иҗат кешесенә карата мондый фикер әйткәндә совет чоры тормышыннан калган КПССның өлкә комитеты карарлары да искә төшә, билгеле. Алар да бит язучыларга һәм башка төр иҗат кешеләренә карата әнә шундый: «халык массаларын тәрбияләүгә хезмәт итми» дигән авыр сүзләрне куллана иделәр. Әмма чагыштырып карыйк.

Инде менә без хәзер ун еллап шактый ирекле хәлдә яшибез. Теләгән фикерләрне шактый ук күләмдә яза алабыз. Хәтта теләгән һәр нәрсәне диярлек яза алабыз. Ләкин... Ләкин ныклап уйлап карыйк әле: тормыш куйган мәсьәләдән, үз милләтең көткән проблемадан «ирекле» булган иҗатчының бәһасе нинди? Иҗатчының шәхси иреге белән чагыштырганда үз милләтең, дөрес рухи тормыш, гуманизм хакына ирексезлек ничегрәк күренә икән?!

Биредә ирексездән студент чакта философия фәненнән укыган шундый сүзләр искә төшә: «чын ирек — ул аңланган зарурият» (подлинная свобода — эта осознанная необходимость!). Татар әдәбиятының бүген иҗат итүче иң җитди көчләре дә, минемчә, үзләрен ирекле рәвештә милләткә хезмәт итүче дип саныйлар. Милләт белән шәхеснең иң гармоник берлеге дә әнә шулай барлыкка киләдер ул.

Бу роман каһарманы Мотаһирга авыр чакта ныклык бирүче уйлар безнең дә фикерләрне милләт һәм аның өчен көрәш идеясенә китереп чыгара. Әдипләр, зыялылар өчен генә түгел, ә һәр татар кешесе өчен үтә дә мөһим булган идеягә!

Романдагы икенче мөһим персонаж — Мөсәмирә, тоткын Мотаһирның кечкенә малае белән һәм әле тагын бер баласын табарга җыенып авырлы килеш авылда калган хатыны. Аның образын иҗат итүгә язучы бөтен күңел җылысын салган һәм илһамын да иң тулы көченә эшкә җиккән. Нәтиҗәдә Мөсәмирә укучы күңелендә истә кала торган, үзенчәлекле, җанлы образ булып чыккан. Ирен кулга алып, өйдән алып чыгып барганда, Мөсәмирә әйткән сүзләрне карыйк.

— Мотаһир, чәй өлгерде бит!

Гади авыл хатынының үзенә иң авыр вакытта әйткән әлеге сүзләренә автор мондый аңлатма бирә: «Кияүгә чыкканнан алып, кара гүргә кергәнче гомерен ихатада кош-корт тирәсендә, кече якта аш-су белән әвәрә килеп үткәрүче татар хатыннарының иң кирәкле һәм урынлы дип санаган сүзе иде бу. Чөнки беркем дә аштан олы була алмый: мулламы ул, колхоз яисә авыл советы рәисеме, Казаннан яки районнан килгән түрәме, туган-тумача яисә бала-чагамы, хәтта наган таккан милиционер да...»

Әнә шулай итеп, үз әсәренең иң киеренке, иң истә кала торган урыннарында язучы безнең күңелгә милләтнең асыл сыйфатларын салып куя. Ә инде бүгенге яшь буын укучылар өчен менә моның ише нечкә алымнар белән әхлакый тәрбия бирү бигрәк тә мөһим бит.

Әсәр, бер яктан, салкын төньяктагы төрмәгә озатылган Мотаһирның газаплы язмышын сурәтләсә, икенче яктан, үз авылында калган Мөсәмирәнең башыннан кичкәннәрне тасвирлый. Ә ике арада күзгә күренмәс, ләкин ныклы җепләр сузылган... Менә тоткын Мотаһир тал чыбыкларыннан кәрзин үрә: «Әнә бит тоткасын ничек җайлы итәргә тырышты ул аның, хатын-кыз кулына эләгәсен белгәнгә шулай пөхтә итеп үрде. Билгеле, ул хатын моның кайда ясалуын, кем үрүен белмәс тә, шулай да, миннән булсын яхшылык дигәндәй, Мотаһир йөрәк җылысын салып эшләде».

Сугыш чорында авылда калган татар хатыннарының героик хезмәте турында безнең матбугатта күп һәм тәэсирле итеп язылды. Рәфкать Кәрами дә үз әсәрендә алар батырлыгын тасвирлауның үзенчәлекле күренешләрен таба.

«Бервакыт Мөсәмирә кычкырып җибәрде:

— Зәһлүл, тәгәрмәч таптым!

— Нинди тәгәрмәч тагын? — диде Зәһлүл аптырап.

— Сабан тәгәрмәче,— дип, Мөсәмирә җиргә төртеп күрсәтте.

Зәһлүл шикләнебрәк әле аңа, әле сабанга карап:

— Үзеңнеке бармы соң? — дип сорады.

Мөсәмирә караса — аптырап китте: үз сабанының бер тәгәрмәче юк икән. Тәгәрмәчсез ничек әйләнгәндер ул?»

Кычкырып көләрсең дә, утырып еларсың да моңа! Бу бит инде көн-төн басуда эшләүче хатын-кызның тәмам ару билгесе. Һәм шул ук вакытта ир-ат эшенә хатын-кызның кулы да, күңеле дә ятмавын

күрсәтә ул. Менә моның ише күренешләр әсәр идеясенә бик нәтиҗәле «эшли», эчтәлекне тирәнәйтә. Ә инде романда язучының турыдан-туры болай дип мөрәҗәгать итүен карагыз:

«Аналар, апалар, сеңелләр! Мин, шушы китапны язучы, хәсрәтле көннәрегезне йөрәгем белән тоючы, барча авырлыкларыгызны йөрәгем аша үткәрүче, еллар аша сезгә карасам — күзләрем дымлана, күңелләрем тула, җәбер-җәфа кичергән чорлар өчен, кешеләрнең шәфкатьсезлеге өчен сездән гафу сорыйм. Күпләрегезгә авыр туфрагыгыз җиңел булсын, дип телим. Җиңү көннәрендә олылап сезне искә алырга тырышам, иртә-кич намаз вакытларында картлар сезгә багышлап дога кылсыннар иде, дип телим».

Әйе, шик юк, роман салкын акыл кушуы буенча гына түгел, ә йөрәк кушуы буенча һәм бөтен күңелне биреп, ихластан тырышып, изге җаннарның язмышы өчен тетрәнеп һәм рухланып язылган. Төньякның кырыс табигате дә, тоткынлыкта Мотаһир очраткан яңа шәхесләр дә сәнгать чаралары аша тәэсирле итеп бирелгән. «Әрекмән белән кычыткан үскән һәр җирдә татар бар» дип язуы да урыс милләте кешесен күздә тотып, «мин сине аркылы таккан дип торам» дип әйтү дә хатын кешенең ирен уйлап «алтын бусагам юк шул» диюе дә, «йомыркадан җөй эзләп йөрмә, яме» дигән кызыклы гыйбарәләр дә һәм уңышлы кулланылган төбәк сүзләре дә әсәрнең кызыклылыгын, үзенчәлеген арттыралар.

Әмма шундый матур-матур тезмәләр үрә белгән әдипнең 171 нче биттә: «Кайчагында бик соң гына да минем арттан киләләр. Ә мин авыруны ташлап китәргә мәҗбүрмен»,— дип куюы гажәпләндерә. Татарча сөйләшкән кеше «алмага киләләр» «чакырырга киләләр» ди бит инде ул... «минем арттан» дими.

Әйе, бу романның күзгә ташланган кимчелекләре турында сүз кузгаттык. Минемчә, алар күп түгел. Ләкин китапның беренче битендә үк: «...Унсигезенче декабрь — якшәмбе иде. Ял көне икәнен белгәндәй... бүген кояш та иртәрәк чыкты...» дип төгәлсезлек җибәрү дә килешми. Чөнки көн озынлыгы егермеләреннән соң арта башласа да, кояшның чыгуы әле Яңа ел җиткәндә генә иртәрәк була. Монда инде, бәлки, автор башта «28 декабрь» дип дөрес язгандыр да, соңрак вакыйганы Яңа елдан ерагайту өчен җиңел кулдан гына «18 декабрь»гә үзгәрткәндер дип уйларга да мөмкин.

Бүлекләр алдыннан документаль хәбәрләр, төгәл саннар бирелеп бару илдәге фажигаләрнең зурлыгын, колачын белдерә дигән идек. Әмма ул белешмәләр урыны-урыны белән озынгарак китә дә, аларның тәэсир көче кими башлый. Әдәби текст арасында урнаштырылган булгач, аларның озынлыгы бигрәк тә сизелә. Минемчә, ул белешмәләр бик тә кыска һәм тәэсирле булырга тиеш иде. Әдәби җөмләләр дәрәҗәсендә булырга тиеш иде алар! Саннары, мәгънәләре белән!

Һәм тагын бер мөһим нәрсә. Романның ахыры болай төгәлләнә: «...Мотаһир онытылып укып утыра. ...Ләкин шулчак кемдер кинәт ишек шакый калса, Мотаһир сискәнеп китә, чөнки тагын аны алып китәргә килгәннәрдер төсле тоела...»

Әйе, роман каһарманы Мотаһир әнә шулай бүген дә, безнең көннәрдә дә куркып яши. Авторның үз әсәрен безне тәмам тыныч ландырып, бөтен кайгыларны юлдан алып ташламыйча бетерүе — әйбәт. Чөнки бит әле бүген дә фашистик һәм шовинистик карашлы кешеләр югары хакимияткә үрелә. Мотаһирныкы ише курку әле бүген бик күпләрдә, миллионнарда яши. Һәм ул куркуны бөтенләй җирлексез, сәбәпсез курку дип әйтергә дә ярамый. Нәкъ менә шуңа күрә дә биредә язучыга бер тәкъдим, теләк белдерәсе килә. Бу роман тарихта булганны гына язып калмаган булса, әсәр тагын да яхшырак чыгар иде. Чөнки үзләре төрмәдә утырып кайткан кешеләр документаль жанрда язды — аларныкы чын тарихи-документаль әсәр буларак кабул ителде. Шулай дөрес иде, шулай аңлашылды да. Ләкин биредә «Каргышлы этаплар»ның жанры «роман» дип билгеләнгәч, тарихи һәм документаль чынлык бераз чикләнсә дә, яисә үзгәрсә дә ярар иде. Авторның хыялы, бәлки, андагы вакыйгаларны бүгенге тормыш белән дә бәйли алган булыр иде. Ягъни әсәрнең вакыт ягыннан колачын киңәйтү, перспективада сурәтләү әдәби әсәр буларак романның идея-эстетик җегәрен арттыру турында сүз бара. Билгеле, бу очракта инде язучы кешедән тирән фикерләү, талант зурлыгы һәм фәлсәфи көч тә таләп ителә. Ләкин күңел биреп һәм ныклап уйланганда чын язучы таланты боларның байтагына ирешә алган булыр иде. Бары тик әнә шундый олы максатны алга кую гына кирәк иде.

Билгеле, безнең бу тәкъдимне, бәлки, урынсызрак дип тә санарга буладыр. «Роман ничек бар — шулай кабул итегез»,— дияр, бәлки, автор. Әмма шулай да икенче як фикерен дә бераз уйлап карагыз әле, егетләр. Чөнки безнең татар прозасы вакыты-вакыты белән бигрәк тә «җиргә төшеп» бетә бит! Әлбәттә, бу — әсәрләргә реализм көчен бирә, ышандыруны арттыра. Ләкин без биредә әдәбият турында, образлы фикерләү турында сүз барганын да истән чыгармасак иде!

Әсәрләребезгә алынган каһарманнар моңа кадәр әдәбиятта яктыртылмаган рухи һәм фәлсәфи мәсьәләләр турында уйланып яшәсәләр, аларның ул яшәүләре безнең өчен укырга кызыклы да һәм мәгънәле дә булса, китаплар укыгач без үзебезгә өр-яңа дөнья ачкандай сөенсәк — милләтебез тормышы тагын да матураеп, баеп китәр иде бит.

Әйе, аңлыйбыз: соңгы елларда проза жанрының хәлләре җиңел түгел. Заманы да утырып, басылып эшләүгә, ижат итүгә дәртләндереп тормый. Хөкүмәтебез дә милләтнең ижат көчләренә тиешле игътибар бирми. Шуларның барысы өстенә, прозада ижат итүче көчләр дә хәзер бик-бик сыекланды: өлкән буыныбыз бик тә нәтиҗәле эшләгәннән соң хәзер табигый рәвештә сүлпәнләнде — аларга инде болай

да зур рәхмәт әйтергә кирәк! Ә урта буыннан җигелеп эшләүчеләр шулай ук бик тә әз — бер кулның бармаклары җитәрлек санда гына... Яшьрәкләр исә тагын да сирәк. Монда инде әсәрләрнең сыйфат ягы да бүтәнчәрәк: шәһәр җирендә туып үскән татарларныкы төслерәк...

Менә шушындый хәвефле диярлек бер вакытта басылып чыккан Рәфкать Кәрами романы безне, әлбәттә, нигездә сөендерде. Аны чын әдәбият әсәре буларак онытылып, бирелеп укыйсың. Заман шаукымына бирелеп авторның әсәр сыйфатына игътибарны киметмәве дә — мактауга лаек. Алга таба бәлки әле үз чорыбыз тормышыннан да менә шушындый әйбәт роман иҗат итәр безнең бу язучыбыз!

1998

Яңа исемнәр, яңа әсәрләр...

Әдәбиятыбызның проза тармагындагы яшь көчләр турында сүз башлаганчы, алар иҗат иткән кайбер әсәрләр хакында фикер йөртергә керешкәнче, мәсьәләгә турыдан-туры бәйләнеше булган шундый бер борчулы хәлне искә алмый мөмкин түгел. Соңгы ике ел эчендә татар әдәбиятының проза жанрыннан әле чагыштырмача яшь саналган талантлы ике язучыбыз китте. Кире кайтмаска, бөтенләйгә... Сүз фаҗигале төстә әрәм булган Фәрит Гыйльми һәм Альберт Сафин турында бара.

Болар икесе дә телне яхшы белүче, нечкә тоючы, тормыш күренешләренә карата сизгер күңелле һәм инде чын мәгънәсендә әдип булып җитлегеп килүче иҗатчылар иделәр. Фәрит Гыйльми әле үткән елны гына безнең журнал укучыларын «Зәйтүнәкәй, акчарлагым» хикәясе белән куандырды. Кыска гына күләмле шушы бер хикәядә без соңгы еллар авылының чын тормышын һәм аның олы трагедиясен — бигрәк тә авылда калган яшьләрнең фаҗигасен күрә алдык. Колхозда бары тик центнерлар һәм тонналар артыннан гына куучы, шуңа ирешә калсалар, бөтен җирдә макталучы бүгенге түрәләрнең асылда ни рәвешле яшәүләрен һәм аларның чынлыкта кем икәнлекләрен, аларның яшьлек матурлыгы, сафлыгы, аның олы максатлары белән көчле бәрелешен күрдек без бу язмада. Кызганыч, әсәрдә әлеге конфликт яшь кыз өчен үлем белән тәмамланды... Әмма бу әсәрне укыган кеше күңелендә өмет уты барыбер сүнми. Чөнки әле тормыш дәвам итә. Бүген халык җелегенә төшкән, үзенең бик якындагы киләчәген уйлый алмаган түрәләр дә бер заманны мескен хәлдә калачак бит! Гаделлек урнашачак бит әле! Кемнең ниләр кылганын халык искә төшерәчәк әле.

Ф.Гыйльми хикәясе белән аерылышканда укучы күңелендә әнә шундый кичерешләр кала. Алар — бүгенге тормышта меңләгән кешеләр тарафыннан раслана алырдай хисләр.

Альберт Сафинның «Юлда» исемле җыентыкка кергән хикәяләре дә хәтердә озак сакланырлык. Арада иң кыска «Исәнме, әни» дигән хикәя шикелле. Берничә биттән генә торган шушы әсәрдә яшь буын вәкилләренә хас булган күңел катылыгы, якын кешеләреңә карата битарафлык тәэсирле күренеш аша нечкә ачылган. Аны бер мәртәбә укып чыккан кеше оныта алмас. Ул күңел түренә гүяки йөрәк ярасы булып урнаша, гел әрнеп йөри.

Әйе, әнә шундый югары сәнгатьчә әсәрләр яза алган бу каләм ияләре хәзер безнең арабызда юк инде. Татар әдәбиятының болай да шактый сирәк булган яшь прозаиклар сафы алардан соң тагын да бирешә, хәлсезләнә төште. Мондый хәл күңелсез уйларны да көчәйтә. Ләкин алмашка килүче яңа көчләр турында сөйләшә башлаганчы, әйдәгез әле, менә бу хакта да уйланып алыйк.

Табигать тарафыннан бирелгән шактый зур талантлы менә шушы ике каләм иясе нишләп соң татар әдәбиятының атаклы, көчле хикәячеләре булып китмәделәр? Әйдәгез, чагыштырудан курыкмыйк: урысның Антон Чеховы әнә 44 яшендә бу дөньядан үтсә дә, үзеннән соң дистә-дистә том әдәби әсәр һәм бик күпсанлы башка кызыклы язмалар калдырган бит. Безнең талантлы егетләребез дә шул яшькә җиткән иделәр, ләкин нишләп соң алар бик аз әсәр калдырдылар?

Юк, бу сөаль — аларга гына кагыла торган сорау түгел! Бу — бүгенге татар әдипләренең барысына да, һәммәсенә дә кагыла торган сорау.

Билгеле, биредә «моның җавабы күптән билгеле бит инде!» дип, мәсьәләнең үткенлеген киметергә тырышучылар яисә «аларның үзләрендә гаеп!» дип, бу сорауның милли мәдәният өчен ни дәрәҗәдә мөһимлеген аңламамышка салынучылар яки чынлап та аңлый, төшенеп җитә алмаучылар да табылырга мөмкин. Чөнки торгынлык елларында алга килеп баскан үткен проблемаларны күрмәмешкә салышып урап үтәргә, яисә инде аны бик тә шомартырга, ай-һай, остарып беттек без! Хәтта үзебезнең яшәү яки үлемебезне хәл итәрдәй мәсьәләләрне дә күрмәскә өйрәндек без ул елларда. Аның шаукымы әле хәзер дә бик көчле.

Шуңа күрә биредә безнең ике хикәячебезне урысның атаклы әдибе белән янәшә куеп карау бик тә кирәк! Ике төрле савыттан алынган ике тамчы сыман — Чехов язмышы һәм безнең ике яшь әдип язмышы — ике халыкның ике төрле язмышын аермачык күрсәтеп, кычкырып тора.

Безнең әдипләрдә — күп гасырлар буе колониядә яшәгән, үтә нык изелеп яшәгән халык язмышы, кеше холкы. Милләтнең талантлы вәкиле дә барыбер ярымкол хәлендә. Бүгенге тормыш чынбарлыгы аны әнә шундый хәлгә куя.

Шуның өстенә талантның тиешенчә бәяләнмәве дә килеп кушыла. Ягъни бездә, татарда, яшьтән үк язу сәләте сизелгән кеше бары тик иҗат эше белән генә шөгыльләнә алмый. Үзенең осалыгын бары тик шушы юнәлештә генә камилләштерә һәм әсәр арты әсәр иҗат итеп, милләтне, укучыларны сөендерә алмый. Татар әдәбиятының үлемсез саналырга тиешле әсәрләре тумыйча ук кала. Шартлар булмау, иҗатка олы ихтыяҗ күренмәү аркасында...

Бу ике хикәяченең трагик язмышы турында уйланган вакытта тагын шуны да басым ясап күрсәтмичә булмый: безнең матбугат әлегә кадәр «кыскалыкта — осталык» дигән принципка каршы тора. Ягъни матбугатыбыз әлегә кадәр бары тик күләм өчен генә түли! Димәк, без авторларны күләм куарга үзебез үк мәҗбүр итәбез! Ә әсәрнең сыйфаты өчен түләү кая?! Язучының чын осалыгына, олы талантына бәя бирү кая?! Хикәячеләр нишләргә тиеш? Ә бит Тукай һәм Исхакыйлар, Чеховлар чорында бу һич тә алай булмаган! Шуңа күрә ул заманда талантлар табигый рәвештә ачылган. Димәк, безгә хәлне бу җәһәттән тиз арада төзәтү сорала.

Проблеманың тагын бер ягы бар. Торгынлык елларында һәм әле соңгы елларда да без үзебезне тагын да ялкауландыра, рухи яктан үшәнләндерә торган мондый сүзне дә әйтергә бик яратабыз: «Һе, аларда бит ул! Син, агайне, алар белән чагыштырма! Аларның хәл бөтенләй башка!» янәсе. Менә шулай диеп, шушындый бер тылсым белән үз-үзеңне юату, үз-үзеңне тынычландыру... Юк! Хәзер инде безгә дә: «Аларныкы кебек булсын!» — дияр чак җитте! Булсын! Татарда да зур талантлы әдипләр әдәбиятка бөтен көчләрен салып иҗат итсеннәр! Үз көчләрен тормышның вак-төягенә түкмәсеннәр.

Бүген без сагынып искә алган ике язучы да кыска жанр осталары иделәр. Дөресен әйткәндә, күпмедер дәрәҗәдә алар безнең игътибарсызлыгыбыз корбаннары да булдылар. Димәк, чын талантны гадел бәһаләү, аның кадерен югалтмау турында безгә ашыгыч рәвештә үк эзләнергә һәм аның юлларын табарга кирәк!

Уйлый китсәң, күңелсез фикерләр байтак кына җыела шул... Җитмешенче елларда зур гына өмет уяткан яшь прозаикларыбыз да хәзер, егерме ел үткәннән соң, әдәбиятның бу иң авыр йөген төпкә җигелеп тартучылар булып әверелмәделәр. Ул елларда гомум соклану белән каршы алынган талантлы прозаик Азат Ганиев тә ике-өч повестьтан соң (яхшы әсәрләрдән соң!) шактый гына пассивлашты. Хәер, аның яңа китабы, ниһаять, чыгып килә дигән хәбәр бар. Азатча үзенчәлекле, диләр аны. Көтик. Бергәләп куанырга язсын!

Аның белән бергә әдәбият мәйданында күренгән Марсель Гали һәм Әхәт Гаффар да, Яңарыш чоры килгәч, прозаик буларак ничектер тыныбрак калдылар шикелле. Дөресрәге, алар ижади яктан үзгәреш кичерде бугай. Әхәт үзенең публицистикада көчлерәк икәнен сизде, ә Марсель Гали кыска хикәя жанрын уңышлы иярләде дияргә була. Ләкин әлеге дә баягы һаман бер сүз дигәндәй, бездә ул жанрга тиешле игътибар булмаса, килгән авторлар да анда озак тора алырлар микән? Кыска күләмле әсәрләргә күләм буенча гына гонорар бирү «хикәя язмагыз сез» дип әйтү белән бер бит инде ул!

Әйе, безнең бүгенге чынбарлыгыбызның объектив һәм субъектив кануннары әлегә әдәбиятны үстерүгә булышмый. Ләкин аңа карап кына халыкның, милләтнең рухи ихтыяҗлары бетми, югалмый! Безнең татар укучысына бүген укырга әдәби әсәрләр кирәк. Хәтта әле бик кирәк! Менә шушы бушлыкны ничек тутырырга? Югыйсә безнең халык көн-төн телевизор экраныннан күрсәтелә торган Америка фильмнарына ияләнеп бетәчәк. Андагы кебек сугышырга, алдашырга, урлашырга, булганны җимерергә һ.б. әшәкелекләргә бик тиз өйрәнәчәк ул. Әгәр әдәбият-сәнгать әһелләре бүгенге көндә татар милләте өчен рухи һәм әхлакый бушлык хасил итсә, шуңа канәгать булып торса!

Әдәбиятыбызның һәм аерым алганда андагы яшь көчләрнең уңышлы үсүе өчен мөһим тагын бер мәсьәлә бар әле. Сүз матбугатта әдәби әсәрләр һәм публицистик язмалар нисбәте турында бара. Яшь иҗатчыга караш, аның хезмәтенә реаль ихтыяҗ сизелү дә шуңа бәйле.

Минемчә, кайбер җитди генә басмалар бүген публицистика белән артыграк мавыга. Чоры да шундый: кычкыру, ярсу, өндәү — боларның һәммәсе инде тормышта болай да чамасыз күп. Хәзерге кеше алардан ничек итеп качарга, кая кереп котылырга белми! Бүгенге кеше үз яшәвенең көе киткәнгә, гармония бозылганга изалана, аптырый. Ә мондый эчке халәттәге кешегә исә әдәби әсәр күбрәк тәэсир итә. Образлы сүз ярдәмендә бүгенге кеше күңеленә үтү җиңелрәк. Киң катлау укучылар үзләре дә әдәби әсәрләрне яратарак төшәләр. Минемчә, журналларның бүген ничек таралуы, ягъни тиражы әнә шул хакта сөйли.

Ә менә икенче яктан караганда, Яңарыш еллары килгәч, әдәби журналларның портфеле шактый юкара төште дип беләм. Моның сәбәбе нидә?

Беренчедән, үзгәреш чоры башлангач, милләтне һәм җәмгыятьне борчыган үткен мәсьәләләр көн тәртибенә куелды. Алар турында уйлану һәм язу байтак зыялыларыбызның акылын, вакытын биләде. Икенчедән, китап басу һәм матбугат эшендә дистә еллар буена чарлана килгән тәртип бозылу сәбәпле, китапларның дөньяга чыгуы вакыт ягыннан нык тоткарлана башлады. Ә бу исә иҗатчы кешегә зур тәэ-

сир ясый, аны чыгырдан чыгара. Өченчедән, нәшриятлар һәм газета-журнал редакцияләренең матди яклары бик нык кысылу аркасында, әсәрләргә гонорар түләү нык кимеде. Каләм иясе элек повесть яки роман бастырып, шулар хисабына тормышының очын очка ялгый алган булса, Яңарыш елларында аның каләм хакы көлке дәрәҗәдә аз килеп чыга. Иҗатчы башка чыганак эзләргә, читтә эшләргә мәҗбүр була. Димәк, тагын әдәбиятка зыян.

Әле тагын җитди бер фактор бар. Соңгы елларда дөньяның рәте китү сәбәпле, бөтен җирдә сугышлар һәм зур социаль конфликтлар күбәю аркасында, иҗат кешесенең дикъкате иректән шуларга да юнәлә. Аның игътибары таркала, уйлары чәчелә, сибелә. Тулаем яшәеш турында «тотрыксыз» дигән тәэсир көчәя. Байтак язучының күңелендә эчке ышаныч кими, киләчәккә өмет какшый... Болар әдипне эчтән җимерә, аның рухи энергиясен киметә, хәлсезләндерә.

Саный китсәң, сәбәпләр тагы да булырга мөмкин. Ләкин хәлнең авыр булуы ачык. Хәер, бүгенге тормыш, бер-ике даирәдән кала, берәүгә дә җиңел түгел.

Әмма төп хикмәт шунда: мондый авыр чорда кеше күңеле тотрыклылык нигезләрен бигрәк тә нык юксына. Безнең татар укучысы да үзенә көч бирердәй рухи азыкны бик көтә. Бу — милләтнең олы рухи ихтыяҗы.

Ә соңгы елларда матбугатта безнең игътибарны җәлеп итәрдәй нинди яңа исемнәр һәм кызыклы әсәрләр күренде соң? Алар татар укучысының зиһенен нинди яңа уй-фикерләр, хис-кичерешләр белән баетты?

Яңа исемнәр дигәндә, иң башта Чаллы шәһәрендә яшәп иҗат итүче Факил Әмәк хәтергә төшә. Бу автор матбугаттагы беренче адымнарыннан ук эшкә шактый киң колач белән тотынды. Аның шигырь һәм пародияләре дә, эпиграммалары да булды, шулай ук әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм шаян хикәяләре дә күренде. Укылган язмаларының һәммәсе диярлек хәзер дә хәтердә тора. Минемчә, менә шушы нәрсә үзе үк байтак мәгънә сөйли. Димәк, ул чакта Факил Сафин исеме белән язган бу автор истә калырдай кызыклы язмалар чыгарган.

Күптән түгел Факил Әмәкнең беренче китабы да басылып чыкты. «Соңгы көз» дип исемләнгән ул. Җыентыкка, шул исемдәге повестьтан тыш, шактый гына хикәяләр дә тупланган.

Кереш сүзендә автор безнең игътибарны үзенең юмористик хикәяләренә юнәлтсә дә, остазы дип Фаил Шәфигуллинны санавын һәм аның юлыннан барырга теләге барлыгын әйтсә дә, шуның өчен күп көч салуын белдерсә дә — ул хикәяләрнең повестька караганда йомшаграк килеп чыгуын әйтмичә үтеп булмый. Әйе, Факилнең хикәяләрендә матур һәм җиңел тел бар, юморга бик якын күренеш-ситуацияләр тасвирлана — ләкин аларны укыганда, ничектер яңалык тойгысы кичермисең. Шартлап, чатнап киткән юмор очкыннарын аз табасың. Икенчеллек тойгысы кала, остазга ияргә сизелә.

Хәер, Факил Әмәкнең юмор язу һәм бастыру мөмкинлеген беркем дә чикли алмый. Мин монда китаптагы юмористик хикәяләрдән чыгып кына әйтәм. Каршы чыгучылар табылса, рәхим итсеннәр. Ләкин шунысын да искә алыйк: авторыбызның үз холкы-табигате дә юмористларча түгел шикелле...

Ә инде бу китапта төп урынны биләп торган «Соңгы көз» повестена килгәндә, биредә эшләр бөтенләй башкача. Монда инде без чын мәгънәсендә үзенчәлекле иҗатчы белән очрашабыз. Әсәрнең беренче битләрендә үк моңа ышанабыз да.

Татарның яшәгән нигезе авыл инде аның. Хәзерге көндә милләт буларак исән булуыбызның да, туган телебезне саклап кала алуыбызның да, әхлакый яктан чистарак-сафрак булуыбызның да һәм әле әйтеп-санап бетерелмәгән башка бик күп яхшы сыйфатларыбызның да нигезендә, төбендә авыл һәм аның тәрбиясе ята. Әлбәттә, бүген күрсәтергә мөмкин булган байтак кына җитешсезлекләрнең дә: мисал өчен, кешегә заманча чослык җитенкерәмәү, бер-берең белән килешеп һәм җайлап эшли, көн итә белмәү, бер-береңә ярдәм итмәү, җитәкчелек эшенә бик атлыгып тормау, аңа авыр өйрәнү һ.б. нәрсәләр дә авылга бәйле шикелле.

Факил Әмәк тә үз повестена җирлек итеп авылны ала. Ә кайсы яктан күрсәтә соң автор бүгенге авылны? Яшь язучы анда нинди көчләр бәрелешен күрә? Хәзерге көрәшләрнең эчтәлеге аныңча нәрсәдән гыйбарәт?

1993 ел дәвамында «Казан утлары» журналы алып барган әдәби дискуссиядә катнашучыларның күбесе Фоат Садриевның «Таң җиле» романына тукталган иде. Сөйләшүдә шул әсәр уңаеннан бүгенге авыл хәлләре шактый ачылды, андагы байтак социаль тенденцияләр төсмерләнде. Укучылар әсәрне байтак кына яктан тулыландырды, аның фикер сөрешен киңәйтте. Факил Әмәкнең «Соңгы көз»е әлеге романга күпмедер аваздаш дияргә дә була. Ләкин бу әйбәт мәгънәдәге аваздашлык. Ике җитди авторның бүгенге авылдагы конфликтларга багышлап ике җитди әсәр язуына һәм бер-берсен һич кенә дә кабатламавына «яхшы»дан бүтән бер сүз дә әйтеп булмый.

Повесть болай башланып китә: колхоз рәисе Тимерхан әле яңа гына көньяктан кайтып төшкән. Ялдан. Аңа кадәр ул «...башта Казанда зур җыелышта булды. Аннан Мәскәүгә, РСФСР Югары Советы сессиясенә очты. Сессия беткәч, өлкә комитетының рәхим-шәфкате белән пайтәхеттә, иң зур түрәләр өчен салынган шифаханәдә сәламәтлеген ныгытып алды... Шифаханәдән чыккач, Кырымга, ял йортына юллама тоттырдылар...»

Менә шушындый сүзләрне укыгач, ничәмә еллар буе бөтен ил халкы күз текәп торган җитәкчеләр күз алдына килә. Колхоз, район, өлкә һәм ил җитәкчеләре... Гүяки Тимерхан (җитмәсә әле, үзенең исеме белән дә!) әнә шул бөтен түрәләрнең бер җыелма образы буларак укучы хөкеменә чыгарылган.

Әсәр идеясе җанлы тормыш, тере кешеләр аша ачыла. «Гөлчирә, күз яшьләрен кул аркасы белән сөртеп, әрнү катыш гаҗәпсенеп, иренә карады. Әгәр Исрафилдә ирлек горурлыгы дигән нәрсә булса, хатынының шушы минутта аны җаныннан чыгарып атканын сизәр иде ул...

— Нәрсә булганын аңламый азапланасыңмыни соң?! — диде хатын, көтелмәгән зәһәрлек белән.— Менә кара, күр! — Ул изүен чишеп җибәрде...»

Яшь әдип сурәтләгән шушы кыска гына бер күренештә дә ничә кеше һәм ничә төрле көч бергә, тыгыз тупланган!

Монда ире тарафыннан яклана алмаган хатынының көчле нәфрәте ташый. Юк, бу нәфрәт хатынны көчләргә маташкан колхоз рәисенә генә түгел. Әлеге нәфрәт Гөлчирәне яклап берни эшли алмаган Исрафилгә дә! Ачуның менә монысы әле иң куәтлеседер дә. Ни өчен дигәндә, үзен дә һәм үзенең хатынын да яклый алмаган әнә шундый җебегән ирләр үсендерә бит инде теге рәис ишеләрне...

Хәер, андый Исрафилләрнең бүген кол хәлендә булуын искә алсаң, бәлки, ул колларның гаебе кими дә төшәдер. Кол хатынына колбиләүченең кул сузуы гажәп түгел кебек бит инде ул...

Менә шулай! Әдәби әсәр үзенең бер күренеше белән генә дә безнең яшәүне ни дәрәҗәдә тирәннән яктырта. Кемнең кем икәнен әйтә дә бирә! Теге киң таралган мәзәктәге шикелле инде: илнең «хуҗалары» тирес түгә, ә «халык хезмәтчеләре» машинада гына җилдерә!

«Соңгы көз» авыл тормышын күп яклап колачлый. Биредә рәис тирәсенә укмашкан куштан белгечләр дә, райондагы һәм Казандагы элек сабакташ булган җитәкчеләр дә бар. Шулай ук гомер юлларын әле яңа гына башлаган яшүсмерләр дә һәм алар арасында без күреп үткән хатынның чибәр кызы Рәхилә дә. Биредә колхоз рәисенең шома ерткычлыкларына каршы торырга тырышкан, баш бирмәскә теләгән яшь мәктәп директоры да... Монда икенче бер яшь түрә тарафыннан шактый гына «талкынган» кызны үзенә хатынлыкка алган авыл советы рәисе дә. Колхоз хуҗасының шәһәрдә аерым фатирда типтереп, юлдан язган үз малае да...

Санадык, санадык та, хәзер инде барысын бергә җыеп карыйк — артык күпкә китмиме соң? Кимчелек ачу, җитешсезлек күрсәтү белән без болай да еш мавыгабыз түгелме соң?!

Юк, «Соңгы көз»не укыганда андый тәэсир тумый. Киресенчә, безнең халыкны, бигрәк тә гади халыкны, әнә шундый коллык хәленнән чыгару өчен дә, ай-һай, күп кирәк! Хәтта үзенең газиз хатынын көчләүгә дә ризалашкан һәм каршы бер сүз дә әйтә алмаган кешеләрне, чыннан да, Кеше итү өчен әле никадәр көч салырга кирәк булачак безнең милли әдәбиятка, безнең милли матбугатка!

Монда әле ярдәмгә Фәнзаман Баттал сатирасы да, Зөлфәт Хәкимнең ачы итеп көлүе дә, Фоат Садриевның соңгы романы сыман киң колачлы әсәрләр дә кирәк булачак. Гамил Афзалның иҗат ялкынын инде әйткән дә юк!

Әйе, Факил Әмәк бу повесте белән укучы каршындагы имтиханны уңышлы тапшырды. Аның иҗатына хас уңай якларны бергә җыйнап карасак, мондый нәтиҗәгә киләбез: автор заманча үткен мәсьәләләр күтәрә. Әсәр безнең тарафтан бик мавыгып, бирелеп укыла. Аның повестендагы геройлар тормышчан, җанлы — тере кеше сыман күз алдына киләләр. Әсәренең сюжеты киң колачлы, аңа бик күп вакыйгалар сыйган. Яшь каләм иясенең язу теле дә ипле ага. Диалоглары тыгыз һәм үзенчәлекле. Төбәк сүзләре әсәр тукымасында табигый яшәү таба.

Шул ук вакытта повесть безнең күңелдә уяткан кайбер теләкләрне дә әйтми булмый. Әллә инде замана чире чагыла: бу повестьта да тормышны өзек-өзек сурәтләү, фрагментарлык теңкәгә тия. Автор болай эшләп киңлеккә ирешмәкче, әлбәттә. Ләкин әйбәт агышлы реалистик проза алымы булгач, әлеге фрагментарлык белән килешүе кыен. Алар бер-берсе белән ярашмый шикелле. Җитәрлек дәрәҗәдә уйланган булса, минемчә, әсәр тоташ агымга да әйләнә алыр иде.

«Соңгы көз»нең төп герое, тискәре тип Тимерхан үлеме дә төрле уйлар кузгата. Бер яктан караганда, күпме әшәкелек эшләгән әнә шул типның ахырда зират коймасында асылынып калуы, шулай үлүе дөрес тә шикелле. Повестьнең логикасы укучыны шуңа алып килә иде. Бөтен әсәр буена Тимерханга ачуы кабара килгән укучы моңа, бәлки, канәгать тә калыр... Әмма бу мәсьәләнең без искә алырга тиешле тагын бер мөһим ягы бар бит әле.

Тормышта һәм безнең күз алдында никадәр җинаять эшләгән кешенең болай очраклы рәвештә генә үлүе бездә нинди фикер калдыра соң? «Күпме җинаятьләр кылсаң да, барыбер бер килеп дөмегәсең син. Ә без синең белән көрәшеп маташмыйбыз, кулыбызны пычратмыйбыз»,— дигән нәтиҗәме?!

Ай-һай, укучыда мондый фикер уяту, аңа хәзер шундый әхлакый сабак, тәрбия бирү тормышыбызны яхшыртырга булышыр микән?! Мин моңа бик тә нык шикләнәм.

Сүз уңаенда әйтеп китик: бер аксакал әдибебезнең моннан шактый еллар элек басылган әсәрендә дә күп әшәкелекләр эшләгән берәүне әсәр соңында ат тибеп үтергән иде. Бик яхшы язылган ул әсәрнең менә шушы урыны ничектер күңелгә ошап бетмәде. Менә хәзер биредә яшь авторда да явызлыклар эшләүчегә карата шундый караш чагыла. Ике әсәрне бергә алып караганда — нәрсә, нинди күренеш бу?

Табигатьнең бөек фәлсәфәсеме, әллә безнең коллык психологиясеме? Килешергә, баш иргә өндәүме? Минемчә, авторлар соңгысына якынрак шикелле... Әйе, түзү, чыдау безгә хас инде ул!

Әмма Факил Әмәкнең әлеге повесте яшь прозаиклар иҗат иткән иң уңышлы әсәрләр рәтенә керә. Бу авторның иҗат дөньясы белән саубуллашкан вакытта аңа даимилек, язу куәсе телисе килә. Чөнки тормышта темалар, проблемалар күп. Каләм иясен яңа каһарманнар көтә.

Сиксәненче елларның ахырыннан башлап уңышлы рәвештә яза һәм басыла килүче икенче яшь прозаик — Флүс Латыйфи. Аның хикәяләр белән бер повестьтан торган тәүге китабы «Кырагай» 1988 елда дөнья күргән иде. 1992 елда автор «Ак-карага тимәскә» дигән яңа җыентык чыгарды. Үткән 1993 елда исә аның «Хыянәт» исемле романы китап булып басылды.

Яшерен-батырын түгел: моңа кадәр исемен ишетмәгән һәм үзен күрмәгән бүтән автор булса, аның шундый аз вакыт эчендә өч җитди китап бастырып чыгаруына шактый да гаҗәпләнгән дә булыр идек. Ул язган әйберләрнең сыйфатына карата да шундук шик уяныр иде, мөгаен. Тумыштан ук скептик чырай алган кайберәүләр бигрәк тә тантана итә иде. Әнә ич элеккерәк елларда, Язучылар берлеге яшь талантлар эзләгәндә, «Бездә 700 ләп яшь язучы бар» дигән сүзгә ироник төстә елмаючылар табылды. Шуның кадәр язучы буламыни, янәсе! Эшләгәч, эзләгәч, оештыргач — була иде шул, була иде! Биредә дә шуның шикелле. Без Флүс Латыйфиның вакытлы матбугатта дөнья күрә килгән язмаларын укып белгәч, аның нәрсәгә сәләтле икәне күз алдында раслана килгәч — бер-бер артлы диярлек басылган өч китап бездә гаҗәпләнү тудырмый. Киресенчә, әдәбиятка чагыштырмача соңрак килгән бу каләмдәшебезнең беренче уңышларына без сөенәбез генә.

Хәзер инде ул язган әсәрләргә күчик. Яшь прозаик үз иҗатында кайсы як, нинди сыйфатлар белән алдыра?

Ф.Латыйфиның беренче китабы өчен иң типик бер хикәяне алыйк. Аның исеме «Чүчинкә». Аңлагансыздыр, төшенгәнсездер — биредә сүз авыл җирендә генә киелә торган аяк киеме турында бара, ә ул чүчинкәгә нинди фәлсәфә сыйдыра алган соң автор?

«Мәскәүдән килгән группаның башлыгы доктормы, кандидатмы... Өстәвенә яшь тә, чибәр дә, ди...»

Хикәя әнә шул хәбәр белән башлана, вакыйгалар шуның аркасында куера. Чөнки коллективта, нигездә, хатын-кызлар эшли. Алар арасында яше кырыкка җитсә дә, кияүгә чыкмаган Эльвирочка да бар. «Ничек итсәм итәм, бу докторны үземә каратмый калмыйм,— ди ул хезмәттәшләренә, уенын-чынын бергә кушып».

Юк, хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Шушы уңайдан без һәрбер камил әйбернең гади тоелуын да искәртеп үтик әле. Ә әсәргә күз салсак, Мәскәүдән килгән тикшерүчеләр группасын Эльвирочканың элекке сабакташы Фәсхетдин җитәкләве мәгълүм була. Алар кайчандыр институтта бергә укый башлаганнар, шунда бер җай чыкканда, Эльвирочка Фәсхетдинне кинога чакырган. Ә тегесе — «авыл гыйбады» — кинога ак чүчинкә киеп килгән! Шәһәрдә! Моңа бик тә гарьләнгән Эльвира ул чагында Фәсхетдин яныннан тая. Дөресрәге, аны алдап китеп бара... Инде менә еллар үткән. Эльвира һаман ялгыз, ә Фәсхетдиннең гаиләсе дә бар, яраткан эшендә дә ул хөрмәтле кеше.

Менә шундый эчтәлек. Гади, әмма һич тә искерми торган мәгънә.

Әйе, чын татар укучысы чүчинкәле Фәсхетдиннәрне дә, кәпрәеп йөреп ялгыз калган Эльвирочкаларны да яхшы белә. Беренчеләре халыкны, илне туендыра, киендерә. Иң авыр эшләргә дә алар бара. Дошман килсә дә, илне якларга дип иң алгы сызыкка алар барып баса, күкрәген куя... Ә икенчеләренең исеме Эльвирочка гына булмаска да бик мөмкин. Боларының женесе ир-ат булуы да бар. Исемнәренең дә модный, заграничный булуы мөмкин... Ләкин аларның холык-табигатьләре нәкъ менә бу хикәядәге кызныкы сыман: алар гадилектән курка, чиркана, болар ялтыравыкка, купшылыкка мөкиббән! Андыйлар читнекенә генә баш ия. Болар данлы һәм дәрәҗәле адәмнәрне генә күрә, санлый... Гадилек — болар өчен иң зур начарлык сыман кабул ителә.

Әмма татарның милли психологиясе бу карашны кискен кире кага. Ул эчкерсезлекне, риясызлыкны, беркатлылыкны шәхеснең иң яхшы сыйфатларыннан дип саный. Кызык — ә безнең белән күрше яшәүче милләттә «простота хуже воровства» дигән сүз бар. Менә бит ул ничек: аларча — урлашсаң, кеше таласаң да ярый, тик син гади генә булма! Күргәнебезчә, без биредә ике төрле караш, ике төрле фәлсәфә бәрелешен очратабыз. Ә киңрәк алып караган чагында Бөек Шәрык һәм Көнбатыш фәлсәфәләре — ике төрле яшәү, уйлау рәвеше бу.

«Рустик» һәм «Кырагай» хикәяләрендә дә Ф.Латыйфи безнең татар укучысы күңеленә хуш килә торган бу фикерне үстерә, дәвам итә. Югарыда әйткәнебезчә һәм кайберәүләр уйлаганча, биредә һич тә тарлык, татарлык түгел — ә безнең милләтне гасырлар буена тотып, саклап торган асыл сыйфатлар хакында сүз бара. Эльвирочкалар холкы инде бездә болай да көчәеп бара. Ул тенденция — татарны бетерәчәк, туздырачак көч. Ә безгә ата-баба юлыннан бүтән юл юк. Аны бары тик замана сыйфатлары белән тагын да ныгыту гына кирәк.

Авторның әсәрләре үзебезнең халкыбыз сыман гади, ләкин тәэсирле сөйләмгә, тормышчан күренешләргә һәм кешеләргә таяна. Яшь әдипнең теле кичерешләр һәм күренешләрне ипле генә тасвирлап бирсә дә, хикәяләрнең агышы тыныч елга шикелле җай гына сузылып китсә дә — болар берсе дә әсәр-

ләрдә сүлпәнлек, сайлык тудырмый, укучыны үзеннән читкә этәрми. Чөнки болар безнең авыл яннарындагы ямь-яшел чирәмлек шикелле, талгын гына агып яткан инеш кебек, тал-тирәкләрнең зифа ыспайлыгы сыман гадилек. Әнә шул табигать күренешләре никадәр генә карасаң да, һич туйдырмый, ялыктырмый бит. Ә күпме көчәнеп, баш ватып төзелгән таш биналарга яисә һәйкәлләргә исә озак карап тора алмыйсың. Ни өчен? Чөнки алар — җансыз!

Шуның шикелле, Латыйфи әфәнде дә әдәби әсәрләрен безнең гап-гади татар тормышыннан алып иҗат итә. Гадилеккә бөеклек бирергә омтыла. Икенче китаптагы «Көмеш беләзек» тагын бер мәртәбә шуны раслый.

Монда да сюжет җебе гап-гади чуар тавык «аягына уралып» сүтелә башлый. «Бу тавык — үзенә ипташкә дип калдырганы. Авылда бердәнбер чуар тавык әле ул, җитмәсә. Бөтен күрше-тирәнеке озын торыклы, юан ботлы таза ак тавыклар. Инкубатор тавыклары. Элегрәк Җиһан да шундыйларга кызыккан иде. Тик ата-бабадан калган нәселне юк итәсе килмәде. Гомере буе шушы талымсыз чуар тавык белән көн күргән ләбаса. Аннан инкубаторныкыларның сәер ягы да бар икән: йомыркасын теләсә кая салалар, чөрләмиләр, утырмыйлар, чеби чыгармыйлар. Әллә нинди кысыр тавык алар. Чын тавык кебек тә түгел».

Бу өзекне укыганда уйлый башлыйсың: биредә сүз тавык турындамы соң, әллә хәзерге кешеләр хакында фикер йөртәме автор?

Сәнгатьле әсәрнең теле әнә шундый инде аның. Андагы күренешләргә кат-кат мәгънә салынган була. Биредә дә без шул хәл белән очрашабыз. Кешелекне, милләтне киләчәктә дәвам итә алырдай затлар хакында әнә шулай сүз башлый автор. Әсәрдә гадилек һәм аның артындагы күп мәгънәлелек, табигыйлек һәм образлылык бергә үрелә. Хикәяләү рәвешендә реальлек һәм тылсым кушыла. Ләкин бөтенлек саклана, сәнгати дөреслеккә зыян килми. Әсәрдән мондый идея чыга: олылар күңеле безнекенә караганда күпкә баерак, тирәнрәк. Анда әллә никадәр мөһим хакыйкатьләр ята, алдагы юлларда, киләсе елларда безгә бик тә кирәк буласы рухи хәзинәләр бар анда. Шуңа күрә безгә ул рухи-әхлакый хәзинәләрне яхшылап үзләштерергә, киләчәккә үзебез белән алып китәргә кирәк.

Әлеге хакыйкать «картлар турында артык еш язасыз» дип гаеп ташлаучыларга ышанычлы җавап шикелле дә яңгырый. Безнеке сыман болганчык елларда, чыннан да, картлар тәҗрибәсе икеләтә, өчләтә кыйммәтләнә түгелме соң?! Флүс Латыйфи үзенең көчен повесть жанрында да сыный. Аның һәр ике китабында да бу төр әсәрләр бирелгән. Ләкин аларда шундый кызыклы үзенчәлек күзәтелә: беренче китаптагы повесть бераз сыеграк, ә хикәяләр көчлерәк булса, икенче җыентыкта инде хәл киресенчә — биредә урнаштырылган ике повесть үзләре генә дә мәгънә ягыннан да, күләм буенча да иң зур урынны алып торалар. Кыскасы, авторның күләмле әсәрләр иҗат итү буенча осталыгы арта бару күз алдында.

«Ак-карага тимәскә» дигән повесть безнең әдәбиятта моңа кадәр тасвирланмаган өлкәне — республика радиосында эшләүче журналистлар тормышын күрсәтә. Вакыйгалар торгынлык чорында бара. Яшь журналист Рәис йөрәгендә Гаделлек белән Ялагайлык, Намус белән Алдашу канга-кан килеп бәрелешә. Югарыдагыларга ялагайлану буенча озак еллар буена зур тәҗрибә туплаган куштаннарның әле яңа гына университет тәмамлаган яшь кешене нинди хәйләләр белән үз юлларына кертергә маташуы әсәрдә кискен күренешләр аша бирелә. Гаделлек өчен көрәшеп йөргән Рәиснең повесть ахырында каты кыйналып, хастаханәгә эләгүе исә теге түрәләрнең һәм күпсанлы ялагайларның әле һаман да шулай яши бирүләрен раслый. Мондый азак, әлбәттә, укучыны да сискәндерә, аның тынычлыгын ала. Чыннан да, демократия чоры башланса да, әле безнең тирә-юньдә никадәр гаделсезлек эшләнә бит. Димәк, Рәис кебек сатылмый торган журналистлар, көрәшчеләр әле күп кирәк безнең милләткә. Ф.Латыйфиның икенче повесте — «Тәгәрмәчсез арба». Игътибар итегез: автор үз әсәрләренә исемне бик тә уйлап куя. Биредә дә исем башта ук көйсез, авыр тормышны искә төшерә. Сугыштан соңгы елларның яшүсмере — әсәрнең төп герое. Аның бәгырь әрнүләре, җан газаплары, бөреләнә башлаган мәхәббәт хисләре китапта биттән биткә озата бара. Һәм аңа җылы, кешелекле хис иярә. Ә инде повесть ахырындагы менә бу юллар: «Сагынам да уфтанып куям: бөтен тормышым тәгәрмәчсез арбага охшаган икән ләбаса! Һаман да шул тәгәрмәчсез арбаны сөйрәп яткан чагым...»

Бик күпләребезнең хәле, эчке халәте, бөтен язмышы диярлек чагыла түгелме соң әсәрнең соңгы һәм моңлы аккорды булган әлеге юлларда?!

Авторның менә шушындый уңышлары турында сөйләгәннән соң, аңа булган кайбер теләкләребезне дә җиткерәсе килә. Татар зыялыларын борчыган бүгенге рухи һәм әхлакый проблемаларга кыюрак үтеп керсен иде ул. Югыйсә, чыннан да, безнең татар әдәбиятыбызның иң күп әсәрләре авыл тормышына багышланган. Моны без уңай факт буларак билгеләп тә үттек. Ләкин бит хәзер шәһәрдә дә миллионлаган татар яши. Анда безнең укучы бик тә кызыксына торган зыялылар мөхите, алар тормышы бар. Флүс Латыйфиның дөньяны күрү һәм тасвир алымнары татар зыялыларының бүгенге яшәвен оста һәм тулы чагылдыра алыр иде. Мин, бәлки, ялгышамдыр: ләкин ни өчендер шулай тоела — Флүс Латыйфи хәзерге көндә бүгенге татар зыялылары турында яңа роман язадыр шикелле.

Иң башта мәкаләләр, аннары хикәяләр язып каләм чарлаган, шуннан соң повесть жанрында да көчен сынаган һәм матур гына нәтиҗәләргә ирешкән Ф.Латыйфиның романы дөнья күрде дигән идек. Ос-

талыкка акрынлап һәм ашыкмыйча, каударланмыйча баруы аркасындадыр, күрәсең, уңышлар бу өлкәдә дә сөенерлек килеп чыга. «Хыянәт» романы турында матбугатта бары тик уңай фикерләр генә әйтелде.

Юк, бу роман безнең милләтнең үткәне белән хәзергесен генә тоташтырмый. Анда бер елга буенда янәшә яшәү тапкан, янәшәдә гомер иткән ике милләт кешеләре күрсәтелә. Урыс егете Александрның татар кызы Гөлйөземгә мәхәббәте әлеге әсәрдә күп кенә киреңке вакыйгаларны бер җепкә терки. Әнә шул мәхәббәт хисе романның буеннан-буена укучы игътибарын җәлеп итеп тора.

Безнең кайбер тарихи әсәрләрне уку зыялылар өчен генә кызыклы булса, шулай итеп тарихи роман үз даирәсен үзе үк тарайтса, биредә исә авторның мавыктыргыч хикәяләү рәвеше һәм бүгенге әдәби телнең казанышларына нигезләнгән матур, сыгылмалы сөйләме тарихи тема эченә киң катлау әдәбият сөючеләрне дә алып керә. Аларны тарих эчендә күрше авылда йөргән шикелле иркен һәм кызыклы сәяхәт иттерә. Әсәрдә укучы өчен психологик һәм бүтән төрле киртәләр, каршылыклар тумый.

Кайберәүләр менә шул сәбәпле әсәрнең танып-белү ягыннан әһәмияте аз диярләр, бәлки. Әмма аларга җавап итеп без шуны әйтик: тарих әдәбият эчендә эреп бетми икән, ул коры бер фән булып кына кала. Ә әдәби әсәр тукымасында эреп бетә алса, тарих үзенә мәңгелек яшәү таба ала. Киләсе гасырларга да җанлана ала, яши ала. Әдәби әсәр ул үлми торган тормыш тудыра, иҗат итә.

Флүс Латыйфи романының да төп уңышы әнә шунда. Хәер, җитди бу әсәр турында галимнәр дә, тәнкыйтьчеләр дә аерым тукталып фикер әйтерләр әле. Әдәби иҗатка чагыштырмача күптән тотынмаган авторның юл башында ук мондый уңышка ирешүе бездә бик еш очрый торган хәл түгел бит.

Проза өлкәсенә яңа авторлар бөтенләй уйламаган-көтмәгән яктан да килеп керә. Әнә Зөлфәт Хәким татар эстрадасы йолдызы булган җирдән, бер дә кыенсынмыйча, прозаик дусты Нияз Акмал янәшәсенә сикереп төште. Ни өчен бу ике исемне янәшә куябыз: чөнки алар икесе дә бер үк елларда проза китаплары чыгардылар. Һәм шәп китаплар чыгардылар! Ләкин биредә безнең сүз, яңа автор буларак, Зөлфәт Хәким әсәрләре турында гына.

Укучы бу исемне иң башта «Татарстан яшьләре» газетасында күрде шикелле. Күрде һәм аның язганнарын шундук ошатты. Моны редакция дә тиз чамалап өлгерде. Зөлфәтнең язмалары бер-бер артлы тезелеп китте. Арада сирәк-мирәк кенә тозсызраклары яисә артык тупаслары, начар «ис килеп» торганраклары очраса да, уңышсызлары һәм барып чыкмаганнары күренмәде. Кыскасы, бүген, минем уйлавымча, юмор һәм сатира өлкәсендәге беренче урынны Гамил Афзал алса, икенче урын Фәнзаман Батталга эләксә, өченче урын, һичшиксез, Зөлфәт Хәкимгә тиеш! Әгәр дә моңа шикләнүчеләр табылса, алар юмористның өр-яңа әсәрен — «Агымсуда ни булмас...»ны укып карасыннар! Әлеге сатирик романның беренче юлларында ук кояш җиз тазга охшатыла, ә күктәге болыт исә, колак чистартырга дип иске матрастан йолкынган мамыкка тиңләнә. Биредә авыл исеме дә гади генә түгел — Җырыклы. «Алты керәшен авылы уртасында яшәп тә әле һаман чукынмаган татар авылы»,— ди моны автор. Әсәрнең тәүге битендә үк күренгән беренче герой — милиция капитаны Миңлебаев та — бу авылның кичә сугышкан егетләрен эчтән генә сүгә-сүгә: «Мин сезне чукындырам!» — ди-ди килә. Күрәсез, оста юморист кулына эләккәч, ни куркыныч сүзләр дә бүтәнчә балкый башлый: көлдерә, зиһенне һич уйламаган тыкрыкларга алып керә.

Татар дөньясында бик сирәк кунак булган бу сатирик роман фантастикага һәм халык иҗаты әсәрләренә нигезләнгән. Әмма аны укыган чагында үз авылыңдагы кәмитләр искә төшә. Милли юмор һәр адымда тормышчанлыгын, халыкчанлыгын раслап бара.

Менә Су анасының бер үтенечен генә тыңлап багыгыз:

«— Ә-ә-ә, тагын бер үтенечем бар икән сиңа... Анысын әйтергә оялам.

Мәрданша, өметләнеп, тезләре белән аңа таба шуышты:

— Әйт, әйт, оялма! Мин бит сиңа ят кеше түгел! Әйт инде, оялма!

Су анасы бу үтенечен дә әйтергә батырчылык итте:

— Нуретдинегезгә әйт, елгага бүтән печ итмәсен!»

Күрәсез, автор ситуацияләр белән бик тә кыю эш итә, юмор дилбегәсен ышанычлы кулда тота. Шуңа күрә әсәр бер түмгәктән икенче түмгәккә гаять оста «сикерә».

Яшь язучыга теләк төсендә шуны гына әйтәсе килә: авыл һәм көнкүреш темасында яхшы ат уйнаткан сатира каләмен, бәлки, бүтәнрәк сферада да сынап караргадыр аңа? Мәсәлән, әле өр-яңа дөнья — бүгенге шәһәр тормышы бар, хәзерге сәясәт кешеләре... Сатира өчен менә дигән кәһарманнар күренеп үк тора түгелме соң. Шундый сатирик романнар тагын да язылсын иде дигән теләк бу.

Әйе, халкыбызның талантлар чишмәсе, хәзер сирәгрәк булса да, каләм ияләрен һаман тудырып тора. Әдәби иҗатка озак еллар буе мәхәббәт саклаган шәхесләр осталык үрләрен әкерен-әкерен генә яулый бирәләр. Яшь прозаик Мансур Шәһимәрдән дә әнә шундыйлардан. Моннан күп еллар элек аның бер хикәясе «Идел» альманахында басылып чыккан иде. Безнең бик таләпчән әдибебез Нурихан ага Фәттах та әлеге хикәяне матбугаттагы чыгышында билгеләп үтте. Шуннан соң бу авторның төрле жанрдагы язмалары республика матбугатында күренгәләп торды. Ә менә 1992 елда автор «Казан утла-

ры»нда үзенең зур күләмле беренче әсәрен бастырды. «Кеше күңеле — карурман» дип исемләнгән ул повесть.

Мансур Шаһимәрдәннең көче нәрсәдә? Моны ачыклау өчен башта аның повестеннан өзек укып алыйк:

«Ә сәгать ярымнан соң инде кичке тын һавада Әргәннең исерек тавышы яңгырый:

— Кияү-үү! — һәм аны очкылык тотып куя.

— Әкрен, Вафатдин абзый, шаулама,— дип карый Габделбәр, эсселе-суыклы булып, як-ягына каранып. Әмма Вафа аның саен катырак кычкыра...»

Менә шушы кыска гына өзектә чын язучы сәләтенең байтак яклары чагылып ала. Монда ике төрле холык-фигыль дә ялтырап китә. Монда әлеге холыкның бер сүздәге төгәл бирелеше дә бар. Һәм шунда ук чын, кызыклы, каршылыклы тормыш үзе дә! Аны инде бүтән бизисе дә, арттырасы яки киметәсе дә юк! Моны бары тик ничек булса шулай кабул итәргә генә кала... Һәм тагын шуңа карап уйланырга, фәлсәфәсен чыгарырга.

Билгеле, әле Мансур Шаһимәрдәнгә әсәрне кора белү осталыгы җитми. Ул үзенең күпсанлы каһарманнарын бер «уенга» берләштерә, оештыра белми. Әмма алар — аның әсәренә кергән кешеләр — һәммәсе дә диярлек кызыклылар, гыйбрәткә һәм мәгънәгә ияләр. Аннан соң авторда тел стихиясе шактый куәтле. Аның шомармаган, ялтыратылмаган сөйләү һәм язу рәвеше үзенчәлекле һәм кызыклы. Ул җанлы тормышны әнә шул җанлылыгы, кызыклылыгы белән әсәргә кертеп җибәрә ала... Шуңа күрә аның повестен укый башлагач, ташлап булмый. Әллә нинди зур вакыйгалар һәм мәгънәләр тапмасаң да — мавыгып укыйсың. Кызыклы чынбарлык, үзенчәлекле тел-сөйләм агышы тота, күрәсең.

Күптән түгел үткән семинарда өлкән әдипләр аңа байтак кына киңәшләр биргән иделәр. Хәзер инде яшь авторның әнә шул теоретик сабакларны язу өстәле янында, үзең генә газаплана-газаплана үзләштерү чоры башланды бугай. Ягъни йөрәгең белән күзгә-күз калып, иҗат дөньясы серләрен ачу һәм осталыкка өйрәнү дәвере.

Әйе, уңышлы гына иҗат итүче яшь прозаикларыбыз бар. Ләкин аларның бөтенесе турында да биредә сүз алып бару мөмкин түгел. Ә менә югарыда сөйләнгәннәргә кыскача йомгак ясарга тырышсак, нинди нәтиҗә килеп чыгар икән?

Иң беренче нәтиҗә, мөгаен, шундый булыр: соңгы елларда әдәбиятка килгән яшь прозаиклар үз әсәрләрен нәкъ менә татар халкына карап һәм аның күңелен, җанын күз алдында тотып язалар. Элеккерәк елларда кайбер яшь прозаиклар иҗатында чагылган «әдәби космополитизм» боларга хас түгел.

Аннан соң болар иң элек традицион һәм реалистик прозаның озак еллар буе сыналган алымнарына таяналар. Тел-стиль ягыннан да алар татар теленең табигый, халыкчан агышына йөз тота: бер әдәби чара өстенә икенчесен өеп «мөгез» чыгармый, «яңача булсын!» дип һәм бары тик шуның өчен генә генә баш ватып көчәнми. Болар иң башта укучының күңеленә үтүне максат итә, төп көчләрен шуңа юнәлтә. Ә аның фикер, зиһен ягына түгел.

Мондый сыйфатлар, һичшиксез, хупланырга тиеш. Чөнки татар әдибе өчен иң беренче һәм иң төп укучы булып татар халкы тора.

Билгеле, аларның юл башлау вакыты замананың да авыр чорына туры килде. Бүген тормыш кыенлыклары аркасында хәтта җитди генә әдипләр дә иҗаттан тукталып тора бит әле... Әмма яшьләр үзләрендә иң элек милләтебезнең олы рухи ихтыяҗын тойсыннар иде. Эчке омтылышлары, изге омтылышлары аларга иҗатта иң беренче һәм төп таяныч булсын иде! «Татар халкы» дигән олы маякны алар һич кенә дә югалта күрмәсеннәр иде!

Гомумән, «татар милләтенең рухи һәм әхлакый үсеше өчен!» дигән теләк, әнә шул омтылыш бүген безнең барыбыз өчен дә уртак максат, уртак юнәлеш булсын иде! Әнә шул чагында гына безнең һәммә эшебез алга бара алыр.

1994

Америкада татар әдибәсе

Әле генә үтеп киткән егерменче гасыр безне тора-тора уйландыра. Һаман ныграк, җитдирәк уйландыра. Вакыт ягыннан инде төгәлләнгән әнә шул дәвернең чын асылын аңлыйсы, аның бары тик үзенә генә хас булган сыйфатларын, билгеләрен беләсе килә.

Минемчә һәм башка бик күп авторлар язып чыкканча, кешелек җәмгыятенең яшәешен тулаем күзаллаган чагында тизләнеш, актив хәрәкәт, кискен үзгәрешләр чоры булды шикелле әлеге егерменче гасыр. Кешелек акылы төрле тармакта ясаган зур-зур ачышлар да, социаль тетрәнүләр, революцияләр

һәм сугышлар да, галәм киңлегенә чыгулар һәм матдәнең эченә һаман тирәнгәрәк үтеп керүләр дә — һәммәсе, һәммәсе дә истә тотыла болай дигәндә. Гомумән, бу гасырда яшәгән адәм баласының җыелма сурәте еш кына очракта мәктәптәге физика дәреслекләрендә күрсәтелә торган Броун хәрәкәте эчендәге бер бәләкәй нокта буларак күз алдына килә. Бертуктаусыз һәм бик кызу рәвештә арлы-бирле йөренә: ары сугыла, бире бәрелә торган бер бәләкәй кисәкчек сыманрак.

Ләкин физика дәреслегендәге әлеге күренештән аермалы буларак, адәм баласында Җан, Йөрәк дигән хикмәти бер үзенчәлек бар шул! Һәм әлеге хикмәти хәл кеше башыннан, йөрәгеннән кичкәннәрне бик сизгер кардиограф шикелле ак кәгазьгә теркәтеп, төшереп бардыра.

Моңа кадәр талантлы шагыйрә буларак танылган Нурия Измайлованың бүгенге Америка тормышыннан алып иҗат ителгән «Язылмаган хатлар» исемле китабын (Казан: Татар. кит. нәшр., 2001) күңел әнә шулайрак каршылады.

Әйе, «Татарлар һәм Америка» дигән темага уйлана китсәң, уйланырлык нәрсәләр байтак икән. Әнә бит соңгы елларда гына да милләтебезнең әллә ничә күренекле улы әлеге илгә китеп барган: галәмне яулау буенча иң зур галимнәрдән саналган белгеч, космик тикшеренүләр институтының элеккеге директоры Роальд Сәгъдиев дисеңме, шахмат дөньясының зур таланты Гата Камскимы... Һәм инде менә танылган химик Вил Мирзаянов белән бергә безнең шагыйрәбез Нурия Измайлова да.

Искә төшкән беренче исемнәрдән генә төзелгән һәм әле һич тә тулы булмаган менә шушы исемлекне укып чыкканнан соң күңелгә килгән беренче уй нинди соң? Яшерен-батырын түгел — бездә инде хәзер утраклык тойгысы шактый ук көчәйгән икән. Шуңа күрә хәзер инде без татар кешесен үз җирендә, үз дәүләтендә матур тормыш корган бәхетле зат буларак күрергә телибез икән. Әнә шундый уй-тойгыларның дәвамы буларак әлеге исемлеккә карата минем мөнәсәбәтем дә күңелдә болайрак булып туды — «Читнең чите корысын!» Халык мәкале белән әйтелгән бу үтә катгый карашка нинди газаплы язмышлар һәм фаҗигаләр аша килүебезне барыбыз да яхшы белә булыр — чөнки милләттәшләребезнең читтә бәхет эзләп йөрүләре хакында инде байтак кына әдәби әсәрләр язылды һәм языла тора, документаль язмалар да шактый гына күренде.

Ләкин, исемнәре югарыда искә алынган атаклы шәхесләргә күз салсак, аларның илне ташлап китүенә китергән объектив сәбәпләр булганлыгын да күрербез. Мисал өчен, Гата Камский шахмат дөньясында ирекле рәвештә көрәшеп кararга теләде, Вил Мирзаянов, Россия хәрбиләренең куркыныч химик коралларын дөньяга фаш иткәннән соң, ил белән хушлашырга мәҗбүр булды, ә Роальд Сәгъдиевнең исә безгә мәгълүм хәбәрләргә караганда беренче урында гаилә мәсьәләсе торды шикелле... Элегрәк Европада яшәп калган Рудольф Нуриев мисалы инде ул, гомумән, төрмәдән иреккә качу сыман иде — моны бөтен демократик матбугат шулай дип бәяләде дә.

Әйе, татарларның берсенең генә дә бу илдән китүе тикмәгә түгел — кайсыберәүләр шикелле дөнья күрәсе, чит илләр күрәсе килүдән генә түгел! Үзебез күнеккәнчәрәк итеп әйтсәк, язмыш кушуы буенча килеп чыкты ул хәлләр. Бер моңлы җырыбызда:

Китәсе килеп китмимен,
Туган илдән кем туйган? —

дип әйтеләме әле?!

Әмма икенче яктан алганда, адәм баласы анысы гел хәрәкәт ярата инде ул: иң әүвәл, тәпи йөри башлап, ишегалды чирәменә аяк баскач, аның урамга чыгасы килә; аннары аны «урамнар артындагы яшел болын» үзенә чакыра башлый... тагын да бераз исәя төшкәч инде адәми затны урманнар артында ниләр булуы да кызыксындыра... Китә шулай, китә шулай... Һәм, әнә шулай итеп, кешеләр яңа Америкаларны ачалар. Үзләре өчен һәм кайчагында бик күпләр өчен дә «яңа Америка» була ул ачышлар!

Менә хәзер безнең алда татар шагыйрәсе Нурия Измайлова ачкан Америка ята. Ул нинди икән соң?

Ышанам — мин юк җирләрдә
Могҗизалар барына,—

дип язган иде моннан нәкъ егерме ел элек басылып чыккан «Яратам» исемле беренче китабында Нурия Измайлова. Чыннан да, бу аның бөтен язмышыннан чыгып әйтелгән сүзләр булган икән. Менә үзегез генә уйлап карагыз: Нурия Башкортстанда туып үсә, Казанга килеп югары белем ала. Үзбәкстанда укыта, Мәскәүдә яши һәм инде менә хәзер, бу елларда, Американың Принсетон дигән кечерәк кенә бер шәһәрендә (Нью-Джерси штаты) көн күреп ята.

Әлбәттә, Америка турындагы бу китапны кулга алгач, аны укый башлаудан элек мин «Нуриянең бу шәһәре кайда икән» дип, картага бактым һәм Принсетонның Америка материгының безгә карап торган ягында, ягъни Атлантик океан яры буенда ук — Нью-Йорк белән Вашингтон шәһәрләре арасындарак урнашкан икәнен күрдем. Моны белү белән, күңел ничектер Нурияне, ап-ак күлмәк кигән килеш әнә шул Атлантик океан ярына баскан һәм менә-менә кузгалып китәргә торган җилкән сыманрак итеп, омтылып, безгә таба карап торадыр кебек итеп күз алдына китерде.

Нурия үзе китабында бу шәһәр турында бик яратып, хәтта үз күреп яза. «Әйе, оҗмах белән чагыштырыр идем Принсетонны иң беренче чиратта» дип яза ул һәм бераздан безне шәһәрнең менә мондый

күренеше белән дә таныштыра: «Иртән торып чыксаң, ялт итеп торган кояш, дымсу җылы, йомшак һава, зәп-зәңгәр күк, ямь-яшел җир, зур-зур агачлар, аллы-гөлле чәчәккә чумган куаклар, уенчык шикелле ялтыр-йолтыр итеп торган кошлар, җәннәттә икәннәрен белгәнгәдер, беркемнән дә курыкмаучы исәпсез-сансыз әрсез тиеннәр һәм... тирән тынлык... Шулкадәр тын, һава хәтта зыңлап торган кебек; шулкадәр тирән ул тынлык, хәтта кое төбендәге кебек. Әкияттә бар бит әле: коега төшәсең дә күз күрмәгән гүзәллекләр эченә чумасың, яшел үләннәр дисеңме, чәчкә-гөлләр дисеңме, асыл кошлар, алтын-көмеш сарайлар дисеңме! Сез ничектер, мин үзем югыйсә оҗмахны гел шулай күз алдына китерәм. Менә Принсетонның урамы (төнлә дөм караңгы — нәкъ безнең авыл): чип-чиста, буп-буш, тып-тыныч, хәтта җирдә икәнеңә һәм исән икәнеңә дә ышанырлык түгел».

Күрдегезме, Нуриянең шагыйрьлеге хәтта чәчмә белән язганда да күзгә бәрелеп тора — аның җөмләләре хисле, тынычсыз, алар гел уйнап тора: гүяки автор белән безнең татар укучысы арасында яткан тынгысыз Атлантик океан дулкыннары бу китапның эченә дә үтеп кергәннәр! Юк, бу океан дулкыннары түгел — ә океан артында яшәп яткан шагыйрә Йөрәгенең дулкыннары! Китап әнә шул дулкыннарны китереп җиткерә безгә.

Бу — әдәби әсәр түгел. Анда үз башыннан зур вакыйгалар кичергән геройлар да, кемнәрнедер гомумиләштереп биргән типик образлар да, сюжет җебе белән тоташтырылган кызыклы вакыйгалар чылбыры да юк. Нурия үзенә бертөрле ирекле язу рәвешен сайлап алган да, болында, табигать кочагында хозурланып йөрегән сабый бала сыман, ипләп кенә барысын да күзәтә һәм күңеленә сеңдерә килә. Шулай ашыкмыйча, кабаланмыйча гына йөри бирә.

Татар шагыйрәсе атаклы Американы ничек итеп, нинди итеп күрә соң? Югарыда китерелгән өзектән күренгәнчә, автор бу илне иң башта оҗмах белән чагыштыра, аның бик күп әйбәт якларын тасвирлап үтә. Байлык, матурлык, тәртип, кешеләрнең гел шат йөзле йөрүләре... Әйе, болары шулай. Ләкин тагын менә монысы да бар: Америка иленең әйбәт якларын биредә Нуриягә ияреп санап китү безнең өчен кызык булмас, чөнки без телевизордан да көн-төн Америка киноларын карыйбыз. Аннары, Рәсәйдә Ельцин хакимлеге башлангач, тулаем илдә дә әнә шул Америкага йөз тотып килә, бары тик әнә шул илне генә үзенә үрнәк итеп саный кебек.

Әмма бу ил безгә бөтен яктан да үрнәк була аламы соң?

Әнә шул сорауга җавап эзләп, Америка тормышына Нурия күзе белән карыйк әле. Ул бу очракта безнең яңа илгә җибәрелгән разведчигыбыз булсын!

«Бу илдә гариплек дәрәҗәсенә җиткән юан-килбәтсез гәүдәләр (халыкның 73 проценты) арта баруы тормыш стиленең гариплек дәрәҗәсендә гайре табигый булуына бәйләнгән — берсүзсез. Хәрәкәт итү, саф һава булу, дару шикелле, сәламәтлекне яхшырту чарасына гына әйләнеп калган, ә гадәти тормыш — утыру да яту: өйдә, эштә, машинада. Җәяү йөрү юк дәрәҗәсендә. Тормыш уңайлыкларына күнегеп, чистый ялкаулыкка күнеккән халык барлы-юклы физик эшен дә акча түләп эшләтә...» «Ә монда ашаган саен агу йоткандай — бөтен нәрсәдән курык, хәтта үзеңнән үзең дә курык!..» «Елаганыңны да, чирләгәнеңне дә, үлгәнеңне дә кешегә күрсәтмәү — болар барысы да үзенә күрә бер зыялылык, әдәплелек, югары белем һәм культура күрсәткече... Шулай итеп, ихласлык, эмоциональлек, ачыклык каралар өлеше булып, акларга, аристократларга икейөзлелек кала...» «Бокалларын, тәлинкәләрен күтәреп, йөренеп тә торалар, бер-берсе белән сөйләшеп тә алалар, тик бер бик зур нәрсә җитми — күңел ачу юк! «Күңел ачу» — шулкадәр мәгънәле сүз бит ул, бергә җыелуның, аралашуның бөтен гыйлләсе дә шунда бит инде...» «Ярамый шул, монда алай ярамый. Елмаю да, якын итеп эндәшү, ярдәм тәкъдим итү, хәл сорашу да — тик әдәп кагыйдәләре генә... Шуңа күрә ярдәмгә мохтаҗ кешеләр белән бәйләнергә дә тырышмыйлар, бәйләнсәләр дә, елмаеп исәнләшү дәрәҗәсендә генә...» «Безнең күңел күбрәк тели инде ул — әллә киңрәк, әллә комсызрак... Үзебезнең күңелне дә ачып куясы килә, кешенекенә дә кереп чыгасы килә. Ә менә монда нәкъ шушы нәрсә «прайваси» («шәхси тормыш») дип аталып, зур йозак астында тотыла: үз эченә дә кертмисең, кеше эченә дә кермисең, гайбәт тә сатмыйсың. Әйттем бит инде күңелсез, дип. Үләрсең!»

Кабатлап әйтәм — Нурия үзе, Америка турында язганда, уңай якны да, ошамаган якны да бертигез дәрәҗәдә яктыртып бара: күзе ни күрсә, йөрәге ни кушса — шуны яза. Һәм бу китап әнә шул гаделлеге, ихласлыгы белән безгә кыйммәт тә. Ул бездә Америка турында дөрес күзаллау булдырырга тырыша.

Ләкин биредә безне әлеге дә баягы сорау кызыксындыра: Америка бүген безгә үрнәк була аламы икән? Тагын да ачыклабрак әйтсәк: хәзерге тормышыбызны, яшәешебезне коруда үрнәк була аламы ул безгә?

Иң башта шуны искә төшерик — Америка ул — читтән килгән кешеләрнең җирле халыкны кырып, хәйлә һәм көч, салкын акыл һәм корал ярдәмендә төзелгән җәмгыять. Озак еллар дәвамында табигый тормыш процесслары нәтиҗәсендә төрле-төрле каршылыкларның табигый юл белән көрәше һәм үзара керешүе, шулар нәтиҗәсендә органик рәвештә диярлек кушылып китүе процессында барлыкка килгән җәмгыять түгел ул. Тормышта табигый рәвештә барлыкка килмәгән мондый күренешне гадәттә «эклектика» диеп атыйлар һәм күбрәк очракта «минус» тамгасы белән тамгалыйлар.

Америка тормышына мөнәсәбәттә дә әнә шул «эклектика» төшенчәсе бик тә туры килә. Ягъни ясалма юл белән барлыкка китерелгән, табигый юл белән үсмәгән! Димәк, табигый тамырланып үсү булмагач, анда акыл үзе генә белеп, аңлап, сизеп бетермәгән ниндидер бик мөһим нәрсәләр искә алынмый кала дигән сүз. Ә кеше җаны, аның йөрәге һәм гомумән аның табигате, натурасы яши-яши барыбер әнә шул җитмәгән нәрсәләрне талымлый, юксына, сагына башлый ул! Ана карынында бәләкәй бала үскән чагында, әни буласы кешенең организмы теге яки бу азыкны бик тә теләгән сыман — хәзер Америка җәмгыяте дә үзенә җитмәгән нәрсәләрне эзләп капшана, уйлана, баш вата. (Гүяки аның карынында да дөрес яшәү рәвеше җитлегеп килә!) Нуриянең бу китабында кайбер галимнәрнең фикерләре дә китерелә: «Бүгенге цивилизация балаларының тормышын «агуланган балачак» дип атап, бик күп дәлилләр китереп, моның дөреслеген исбатлыйлар: физик авырулардан башлап, робот дәрәҗәсенә җиткән рухи бушлык... Кушма Штатлардан һәм Германиядән алынган хәбәрләр бүгенге көн балаларының хәле нервлылык, стресс, гиперактивлык, ашау, йоклау авырулары, экзема, аллергия, астманың үсү дәрәҗәсе бик нык югарыга сикерүен күрсәтә...» «Коммерциализм, технология, хәбәрләшү массакүләм чараларының үсә баручы һөҗүме астында балалар таза булып кала алмый, бигрәк тә болар бала табигатенә ярашсыз тәрбия һәм белем бирү белән кушылган булганда», «Көчле тавышлы музыка, үтерешле-кан коюлы фильмнар, тиз-тиз компьютер уеннары, күз явын алырдай ачык төсләр, көчле дарулар һәм наркотиклар — безнең заманда сиземлекне төшерә торган сәбәпләрнең кайберләре шушылар икән...»

Күрәсез, бу хәбәрләрне безгә Америка җәмгыятенең үз эчендәге кешеләр җиткерә. Боларны укыгач хәтта мондый фикер дә башка килә. Бүгенге Америка иле ул — кеше җанын үзенчә бертөрле сынап карау полигоны кебек кабул ителергә тиештер инде. Лабораториядә яңа төрле химик эремә ясалганнан соң, аның нинди икәнлеген белү, аңлау өчен, аңа лакмус кәгазе салып карыйлар бит әле — минемчә, бүгенге Америка да кешелек өчен әнә шундый бер эксперимент, тәҗрибә кебек.

...Китаптагы ир-ат белән хатын-кыз һәм гаиләгә бәйле хәлләр дә кызыксынып укыла, безне тирән уйга сала: «Ирләр импотентка яки кыз тәкәгә әйләнеп бетә бара, чөнки тигез хокук, тигез белем, җәмгыятьтә тигез дәрәҗә алган, ә җәмгыять, законнар тарафыннан ныграк якланган хатын-кыз өммәте алардан көчлерәк булып, үзенә тартып торучы гүзәл чәчәк булудан туктап, бер дәһшәткә әверелгән, һәм алар бу кыз тәкәләр каршында үзләрен ир итеп сизә алмый, күп булса, кыз тәкә генә булып кала. Нәтиҗә буларак хатын-кыз ялгызлыкка дучар...»

Әйе, тыштан караганда барсы да җитеш һәм камил тоелган Америка җәмгыятенең дә җитди генә җитешсезлекләре бар һәм без юри биредә әнә шуларга күбрәк тукталдык. Аны мактаучылар, аңа сокланучылар болай да, бездән башка да байтак булганга күрә шулай эшләдек. Чыннан да, бүгенге Америка безгә тулаем алганда маяк була алмый шул. Безнең өчен, күрәсең, урта юл кулайрак буладыр — үзебезнең элеккеге традицияләргә ялганыбрак киткән юл, үзебезнең тамырларның дәвамы булган юл. Үзебезчәрәк һәм кешечәрәк булган юл — милли юл!

Нурия Измайлованың «Язылмаган хатлар» китабын укып чыгуга күп тә үтмәде, журналыбызның быелгы июль санында аның тагын «Океанның аръягында...» исемле зур гына күләмле яңа язмасы да пәйда булды. Инде аталышыннан ук аңлап алгансыздыр — шагыйрәбезнең бу әсәре дә Америка турында, дөнья халыклары теленә «ирекле ил» буларак кергән әлеге җәмгыятьнең тәртипләре, кануннары хакында.

Ике әсәр арасындагы аерма, үзенчәлек тә күренә. Китап булып чыкканында автор яңа илнең көнкүреше, көндәлек тормышы белән күбрәк кызыксына, үзенең күзенә чалынган кызыклы фактларны, яңалыкларны документаль кинодагыдай күрсәтеп, безнең хәтергә сеңдереп бара. Ә инде безнең журналда басылган язмада исә аерым күренешләрдән, фактлардан өскәрәк күтәрелү, гомумиләштерүләр, кайбер нәтиҗә ясаулар күбрәк күзгә ташлана. Биредә публицистик рух, аһәң көчлерәк.

Ә иң мөһиме биредә Нурия Измайлова «чын мәгънәсендә ирекле булган кеше нинди була?» дигән сорауга җавап бирергә тырыша.

Әйе, бу мәсьәлә, бу сорау безнең татар халкы өчен үтә дә актуаль. Ни өчен икәнен укучы үзе дә бик яхшы белә. 450 еллык коллык психологиясе безнең милләткә бигрәк тә нык сеңгән. Шуңа күрә әлеге язманың менә мондый бүлек исемнәре дә татар укучысы өчен чын азатлыкка чакыручы өндәмә буларак ишетелә: «Ирекле Америка», «Дәртлеләр, гайрәтлеләр иле», «Дискриминейшен», «Үзеңә-үзең ярдәм ит» һ.б.

Ирек темасы авторны ике яктан уйландыра: шәхес иреге һәм милләт азатлыгы. Беренчесенә караган фактлардан миңа бигрәк тә менә монысы тәэсир итте. Нурия үзенең малае турында язып, аның хоккей уйнарга өйрәнгәндә аягын кырдыруын әйтә дә болай ди: «Иртәгә бу аягың белән хоккейга бара алмассың инде»,— дигән идем, ул миңа бик гайрәтләнеп: «Ноу гивиң ап!» — дигән булды: «Бирешү юк!»

Менә бу инде безнең илдән китеп Америкада яши башлаган яшь буын вәкиленең сүзләре. Яңа төрле психологиянең, менталитетның яшь кешегә ничек тәэсир ясавын күрсәтүче сүзләр! Җитмәсә, автор үзе дә болай дип өстәп куя бит әле: «Безне дәртсез, гайрәтсез — пассив булырга совет системасы күнектергән».

Шул ук вакытта шагыйрә үз милләтендәге зур потенциаль мөмкинлекләрне дә исеннән чыгармый: «Хәрәкәттә —бәрәкәт»,— дип, безнең ата-бабалар әллә кайчан әйткән әйтүен, андый гына сабакны алыр өчен Американы өйрәнеп торасы да юк. Шунысына гына эч поша — безнең бабайлар әйткән, болар ишетеп тә алган, хәрәкәт тә итә башлаган. Ә без... без хәрәкәтне дә яратабыз, бәрәкәтне дә яратабыз — хәрәкәт итәргә көч җитми. Хәрәкәте дә һаман бер урында таптану килеп чыккач, бөтенләй җен котыра!»

Америкада күптөрле милләтләр яши. Әмма алар үзләренең теге яки бу милләттән булуы өчен һич кенә дә уңайсызланмый, оялмый. Шул исәптән кара тәнлеләр дә, африкалылар да үзләрен башкалар белән тигез тоя, тиң саный. Автор иректән үзе белгән Рәсәй чынбарлыгын искә төшерә: «Бер чуаш кызының: «Шул нацияне күрә алмыйм, бер авыз чуашча белмәсәк тә, нишләп чуаш диләр икән безне?» — дип зарланганын мәңге онытмам». «Һәм тагын менә мондый җан әрнеткеч вакыйга: «22 яшьтә идем, ял көне, троллейбуста, Уфада. Бер башкорт радиосын ачкан, көндезге башкорт концерты бара. Артымда басып торган хатын очып кунмасынмы бу кешегә: «Это тебе что, татарский клуб?! Может никто не хочет слышать твою дурацкую гармошку! Заткни свое радио сейчас же!» — ди. Андый гына тупаслыкларны колакка да элмәскә өйрәнгән, ахрысы, теге абзый, бер сүз эндәшмәде, радиосын да сүндермәде. Мин әлеге хатынның «татарский» дигән сүзенә чыдамадым: «Не башкиры пришли на русскую землю, русские пришли на башкирскую, пусть слушают!» — дип яңгыратып җавап бирдем. Теге хатын аптырап калды. Интеллигент кыяфәтле хатын иде ул һәм... татар хатыны иде! Валлаһи, татар иде! Телен онытkан маңкорт! Менә шулай. Милли дискриминация көчле милләтнең көчсез милләтне рәнҗетүе генә түгел ул, ул күпкә шакшырак!»

Рәсәй яшәешен Америка белән чагыштырып, күпсанлы гыйбрәтле мисаллар китергәннән соң, авторга инде үзенең тел төбендәге төп фикерне әйтеп бетерү өчен бер генә җөмлә җитми кала:

«Җәмгыятьтә милләтләргә чын тигезлек урнаштыручы һәм реаль көче булган кануннар яшәргә тиеш!»

Әйе, чынлыкта Россия дигән бу ил әле ул яктан алганда һаман ярым кыргый хәлдә яши. Шуңа күрә җанны әрнетә, җенне чыгара торган менә мондый очраклар биредә еш очрый: «Уфада Динә исемле дус кызым белән троллейбуста сөйләшеп утыра идек, чучка кебек пычракка баткан бер исерек урыс: «Чево на весь троллейбус разошлись, татарки наглые!» — дип кычкыра башламасынмы! Татарча пышылдап кына сөйләшергә кирәк икән!»

Шунысы сөенечле: язмада китерелгән менә шушындый тормыш фактларына автор үзенең дөрес һәм публицистик кайнар рухта булган бәясен биреп бара. Димәк, ул укучыларны милли һәм әхлакый, сәяси яктан тәрбияләүдә дә җитди эш башкара дигән сүз.

Менә без Нурия Измайлованың ике әсәрен — «Язылмаган хатлар» китабын һәм «Океан аръягында...» язмасын укып чыктык. Күреп узганыбызча, аларда безнең өчен яңа булган яшәеш, көнкүреш, кануннар... Безнең әдибебез ул дөньяда үзе яшәп, безгә үзенең күргәннәрен һәм белгәннәрен, уйларын һәм тойгыларын хәбәр итте. Аның әйтергә теләгәннәре безнең аңга, зиһенгә, рухыбызга килеп җитте. Хәзер инде без, әнә шулардан чыгып, үзебез өчен дөрес нәтиҗә ясарга тиеш. Ә нинди нәтиҗә?

Беренче нәтиҗә. Соңгы елларда Россиядә урнашкан демократиянең байтак кына әйбәт яклары белән бергә бик күп начар яклары да булды. Бигрәк тә гади халык өчен. Аеруча яшьләр өчен. Мисалга матбугаттан алынган берничә сан. Хәзер Россиядә яшьләрнең 40 проценты психик яктан тайпылышлы, 70 проценты хроник авыру, 30 проценты эшсез, һәм яшь хатыннарның 30 проценты бала табарга кыймый! Җинаятьчелек турында инде әйткән дә юк! Болар барысы да, нигездә, әлеге демократиянең, Америкага охшарга азаплануның җимешләре.

Икенчедән, Америкадан аермалы буларак, безнең татар халкының ерак гасырларга киткән тамыры: рухи, әхлакый, психологик һ.б. традицияләре бар. Аларның бик күбесе әле хәзер дә исән, кешеләр күңелендә яши һәм алар, бүгенге чынбарлыкны искә алганда, тагын да өметлерәк, перспективалырак күренәләр. Ислам диненең асылда көчле рухилыкка нигезләнүе дә безнең киләчәккә булган өметләрне арттыра.

Өченчедән, татарның ерак гасырлардан ук килгән даны да бар. Исеме бар. Соңгы елларда безнең республика җитәкчелеге алып бара торган курс — Ауропага «йомшак керү» курсы — бу данны заманча итеп яңартырга, Ауропа мәйданында яңадан да балкытырга мөмкин. Ауропа бердәмлеге илләрнең соңгы вакытта Россияне үз кочагына алырга тырышулары фонында безнең мондый омтылыш тагын да мәгънәлерәк күренә, милләтебезгә яңа мөмкинлекләр вәгъдә итә.

Әйе, хәзер без яши башлаган «...беренче гасыр», «...беренче ел» күп яктан сискәндерә, игътибарыбызны уята, яңача уйлый-фикерли башларга куша. Тирә-юнебездәге һәм дөньядагы бик күп вакыйгаларга, тенденцияләргә өр-яңа күзлектән карарга мәҗбүр итә ул. Язмабызның башында без үтеп киткән егерменче гасырны тизләнеш, актив хәрәкәт, кискен үзгәрешләр чоры булды дигән идек. Ләкин тулы бер гасыр — йөз ел буе яшәп караганнан соң, кешелек җәмгыяте инде үзенә андый гына хәрәкәтнең җитенкерәмәвен нык итеп аңлый башлады. Хәзер кешелек җәмгыяте тормышында эчке байлыкның, ру-

хи байлыкның җитмәве үтә дә нык сизелә. Нурия Измайлованың Америка турында язганнарын укыганнан соң да күңелдә әнә шул фикер ныгып кала.

Әлбәттә, бу уйлар, бу фикерләр, иң беренче чиратта, безнең татар халкы турында. Башланып киткән менә бу чорда милләтебезне рухи яктан үстерүнең, аны эчтән ныгытуның, активлаштыруның үтемле юлларын, чараларын табарга иде. Шул юнәлештә көчле эш, хәрәкәт башларга иде!

2001

Оя тойгысы

Сөенечле хәл: яңа гасырга, яңа меңьеллыкка безнең татар әдәбияты үзенә бертөрле күңел күтәренкелеге белән килеп керде. Замандашларның хис-кичерешләрен чагылдыруда бер генә чорда да алдынгылыкны бирмәгән шигъриятне инде әйткән дә юк, әле бит хәтта әдәбиятның авыр артиллериясе саналган проза тармагы да, туксанынчы еллар уртасындарак күпмедер дәрәҗәдә хәлсезлек кичереп алганнан соң, гасыр ахырына таба яңадан да җанлана һәм үзенең элеккеге еллар традициясенә лаеклы мәртәбәле урынына күтәрелә башлады. Шулай ук публицистиканың да киң даирә авторлар көче белән көн таләпләренә аваздаш кайнар рухлы язмалар биреп баруын хупларга кирәк. Соңгы елларда театрларда куелган аерым спектакльләр уңаеннан үз адресына байтак кына төртмәле сүзләр ишетсә дә, нигездә, драматургиябезнең хәлен дә начар дияргә тел бармый — чөнки анда даими рәвештә яңа авторлар күренеп тора, кызыклы яңа әсәрләр еш пәйда була. Әдәби тәнкыйть тармагында да күпмедер җанлылык күзәтелә дияргә мөмкин сыман. Сирәк кенә булса да, биредә дә яшь көчләр күзгә ташлана, алдагы елларда әдәбият мәйданын ат уйнаткан һәм аннары бермәл пассивлашып алган тәнкыйтьче кадрлар соңгы арада яңадан иҗади яктан активлаша төште.

Бу елларда төрле нәшриятларда басылып чыккан әдәби китаплар санының һаман арта баруы да безне сөендерергә тиеш дип уйлыйм. Әйе, анысы сер түгел: сыйфат ягыннан алып караганда, алар бербөтенне җир белән күк кебек аерыла — биредә безнең әдәби тәнкыйтьне иге-чиге күренмәгән «эш фронты» көтеп тора! Әмма, мәсьәләгә икенче яктан күз салсаң, бүген татар телендә әдәби китапларның шактый ук мул басылуы ул — милләттәшләребезнең китапка, басма сүзгә булган зур ихтирамы дигән сүз дә бит әле. Димәк, безнең замандашлар үзләренең иң кадерле уй-кичерешләрен, гомерләре дәвамында үз башларыннан кичкән гыйбрәтле хәл-әхвәлләрне китапка ышанып тапшыралар дигән сүз бит әле бу! Димәк, алар китапның, әдәбиятның киләчәгенә зур өмет баглыйлар дигән сүз! Шулай икән — димәк, аларның рухи дөньялары, күңел омтылышлары дөрес юлдан бара.

Менә шушындый оптимистик уйлар яңа гасыр башында барыбызны да дәртләндерә, канатландыра. Һәм, әлбәттә, гасыр башында басылып чыккан китапларга без бүген бигрәк тә игътибарлы. Чөнки беренче ел китаплары бит алар! Алар хәтта күпмедер дәрәҗәдә киләчәктән — алда торган еллардан килгән яңа мәгънәләрне, серле аһәңнәрне дә үзләрендә чагылдыра сыман.

Шулай итеп, алдыбызда яңа гасырның — беренче елның — беренче китабы ята. Шигырь китабы ул. Бу хакта аның исеме үк әйтеп тора: «Ярату яралары». Ә авторы — инде хәзер танылып өлгергән шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова. Алдыбыздагы китап — аның беренче китабы. Димәк, әнә шул яктан да игътибарга лаек бу җыентык.

Кемгә ничектер, ә минем үземә бу шагыйрәнең исемен әйтү белән менә шушы җыр сүзләре хәтергә килә:

Алкаларым сыңар-сыңар,
Йә югала, йә сына...

Алкалар... Татар хатын-кызының тулы, түгәрәк бәхете һәм әнә шул бәхетнең кояш сыман битләрдә, йөзләрдә балкуы булып гәүдәләнә ул алкалар... Ә инде шуңа иярәп килгән икенчерәк мәгънәле сүзләр: «сыңар-сыңар», «югала», «сына»... Табигатьтәге һәм тормыштагы бөек бер гармония булган парлылыкны юксыну, шуны тансыклау тойгысы биредә сизелер-сизелмәс киная, тел төбендәге уй, әкрен генә исеп киткән җил рәвешендә генә — скрипканың нәфис моңы сыман гына ишетелеп куя түгелме? Әйе, шагыйрәнең талантлы күңеле биредә бик матур һәм укучыда тирән ассоциацияләр уята торган образга юлыккан. Шушы ук шагыйрәнең тагын менә мондый җыры да бар бит әле:

Күзләреңнән күзем алмый
Карап торасым килә.
Үзем яраткан кадәрле
Яраттырасым килә.

Биредәге беренче ике юлда сүзләр бик матур, ягымлы булса, аларда әллә ни яңалык юк, ә менә инде өченче-дүртенче юллар үзләрендәге мәгънә яңалыгы, үзенчәлеге белән ничек балкып, яктырып тора. «Үзем яраткан кадәрле» дигән өч сүзгә бу дөньядагы бөтен гашыйкларның нурлы күз карашлары яктысы, йөрәкләренең һәм җаннарының кояштай балкулы, барча өмете һәм темпераменты сыйган шикелле. Чыннан да, гашыйк кешенең йөрәк психологиясе ничек төгәл һәм нечкә тотып алынган әнә шул «үзем яраткан кадәрле» дигән сүздә! Биредә инде мәхәббәтнең бөтен көче һәм шул ук вакытта субъективлыгы да, фаҗигаи ялгызлыгы да — кыскасы, бөтен-бөтен язмышы... Әнә шуңа күрә ул сүзләрнең укучы, тыңлаучы күңеленә тәэсире дә бик зур.

«Ярату яралары» дип исемләнгән бу китапта менә шушы җырлар шикелле тирән һәм үзенчәлекле хискә ия шигырьләр күп. Алар укучыга өч бүлеккә бүлеп тәкъдим ителгән: «Гамь», «Гөлләр сере», «Алма бакчасы».

Беренче бүлекнең нинди эчтәлеккә ия булуы турында инде исеме үк әйтеп тора — биредә бүгенге тормыш чынбарлыгы китереп чыгарган рухи-әхлакый проблемалар, аларның нечкә күңелле кешеләргә булган тәэсире һәм яшен уты кебек балкып-балкып китүче яшәеш фәлсәфәсе.

Тулаем шушы бүлекнең нигезе булырдай, шагыйрәнең үзе өчен дә программ характердагы әсәрләр дә бар. «Оя» дигән шигырьне мин, мәсәлән, шулай кабул иттем.

Көннең бүген күңеле тулган
Яшь коя да яшь коя.
Качар идем бу сагыштан
Тапсагызчы бер оя.

Әйе, оя... Кошлар өчен генә түгел, кешегә дә оя кирәк. Ә инде хатын-кызга бигрәк тә! Аның өчен оя бигрәк тә мөһим. Оя ул — җил-яңгырдан ышыкланырдай коры һәм ышанычлы почмак та. Оя ул — гаилә кору һәм балалар үстерү, бергә-бергә яшәү бәхетен тату җирлеге дә. Оя ул — сөйгәнеңнең җан һәм тән җылысы тоела торган бердәнбер кадерле нокта да...

Әмма ни кызганыч: якынча алганда егерменче гасырның икенче яртысында әнә шул кадерле җирлекне, ышанычлы нигезне табу һәм тапканнан соң аны саклый алу, озак яшәтә алу яшәешнең иң зур проблемасы булып әверелде. Кешеләр тормышының бик кызу темплар белән шәһәрләшүе, фән-техника һәм сексуаль революция нәтиҗәләрендә хәзер гаилә адәм баласы өчен кирәкле, әмма бик тә дефицит булган күренешкә әверелеп китте.

Замананың бу фаҗигаи тенденциясе тормышта төрле чагылышларда, вариантларда яши. «Иске өй» дип аталган шигырендә Ф.Мөслимова аны болайрак күрсәтә:

Балалары үсеп, канат ярган
Җылыдан да җылы оя бу.
Дулкын каккан, давыл искән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу.

Әнә шул өйне хәзер сүтеп яталар... Биредә шагыйрә күзе бик зур фаҗига күрә, аны замананың бер начар чагылышы дип кабул итә, шуңа күрә шагыйрә җаны кайта-кайта өзгәләнә:

Карлыгачлар оя корган нигез,
Үрмә гөлләр үскән бакчасы.
Ишегалларында яшел чирәм —
Юкка чыга менә барчасы!

Күрәсезме, шагыйрә югалып баручы гармонияне ничек итеп күз алдына китереп бастырды. Менә шундый гүзәллекне югалтуны бары тик үз әниеңне югалтуга гына тиңләргә мөмкиндер! Хәтта әле биредә аннан да зуррак фаҗига турында сүз бара бугай: ничәмә-ничә буын кешеләрне тудырып үстерәчәк Ана — Табигать-Ана хакында сүз бара ич монда!

Шул ук рухтагы «Күчә комнар...» шигыре исеме белән Дәрдемәндне искә төшереп алса да, биредә инде чын безнең заман фаҗигасе күренә:

Ишәлтауның инде яртысы юк,
Бульдозерлар һаман кимерә.
Шул тавымның ком бөртеге итеп,
Җилпеп атты язмыш мине дә.

Әйе, безнең чор тормышының иң зур тетрәнүе — адәм баласы өчен ышанычлы ояның югала баруы — шагыйрәнең күп әсәрләрендә чагыла. «Капка», «Ике фәлсәфә», «Бу заман» шигырьләре дә әнә шуңа мисал була ала. Ә инде «Китәләр...» әсәре боларның һәммәсенә лирик-фәлсәфи сөземтә сыман яңгырый:

Нигә соң һаман да югалтам?
Нигә соң китәләр, китәләр?

Бу юлларны укыгач, Э.Хемингуэйның «Кем рухына чаң кагалар?» әсәрендәге тирән мәгънәле мондый сүзләр дә искә төшеп куя: «Кем рухына чаң кагалар, дип сорама, синең рухыңа да чаң кагу бу».

Шулай шул — барыбыз бергә уртак Оябызны, Табигать дигән бердәнбер һәм ышанычлы җирлегебезне югалта барабыз шул! Әнә шундый фаҗигаи хәлләр уртасында калган бүгенге шәхеснең җан трагедиясе менә бу рәвештә дә ачыла:

Калып булмый, җитеп булмый,
Йөзмичә дә юк чара.

Шушы юллардагы шикелле хисси киеренкелек, рухи һәм психологик тирәнлек әлеге әсәрләрне укучыга кадерле, кызыклы, кирәкле итә. Шуның белән тулаем китапның да рухи-эстетик кыйммәте арта, ул безнең күңел сердәшенә әверелә.

Инде баштарак әйтеп үтелгәнчә, бу китапның икенче бүлеге бик тә мәгънәле рәвештә «Гөлләр сере» дип исемләнгән һәм ул үзенә тупланган шигырьләре белән бүгенге көндә очынып-дәртләнеп тә, еш кына вакытларда сөю утларыннан янып-газапланып та яшәүче гашыйк Йөрәкнең үз сөйгәненә атап язылып, ни сәбәпледер җибәрелмичә калган ялкынлы хатлары кебек кабул ителә. Бер шигырендә шагыйрә хәтта бу хакта болай дип әйтеп тә уза:

Айлы төндә шигырь генә язам,
Хат язарга сиңа оялып...

Әйе, хатка языласы иң кадерле сүзләр, иң садә-керсез кичерешләр, күңелнең иң-иң тирән катламнарындагы, иң төбендәге аеруча кадерле тойгылар, омтылышлар, күңел җилпенүләре-талпынулары бирелә. Әлеге шигырьдә әйтелгәнчә, шагыйрә турыдан-туры сөйгәненә ачылырга ояла, кыенсына (биредә без тагын бер мәртәбә татар хатын-кызының рухи чалымнарын тоеп алабыз, танып алабыз), ләкин ул, шигырь язам диеп тотынгач, сөйгәненә булган бөтен-бөтен хисләренең үзләреннән-үзләре түгелгәнен, елга-ташкын булып агылганын, ташып китүен сизмичә дә кала... Шуның кадәр дә тулган-тулышкан икән алар йөрәк түрендә — кечкенә генә тамчы тамса да, кичерешләрнең галәмәт зур буасын ерып, ачып, агызып җибәрергә генә тора:

...Кочаклармын елап,
Очрый гына күрмә!

Ләкин күп чагында Фәйрүзә Мөслимова гашыйк Йөрәкнең холык-табигатен бу рәвештә түгел, ә шигъри ишарә, матур киная, тирән мәгънәле ымнар белән белдерә:

Бәйләмә инде кара атыңны
Капка төбенә, су өчен генә.
Үзем дә беләм: көям дә кибәм
Юк өчен генә, юк өчен генә.

Шигырьдән өзеп алынган менә шушы дүрт юлда да матур эчке мәгънәле бер шигъри күренеш килеп туды түгелме? Капка төбенә бәйләнгән ат инде ул — кызлы өй өчен бик зур ишарә, димәк, бу тирәдә бик хикмәтле «кунак» йөри дигән сүз... Әле ул «кунак»ның йөрәге дә яна икән, югыйсә су эчәргә туктар идемени?! Ә соң кыз? Ул да әнә «көям дә кибәм» дип әйтеп тора — димәк, аның да күңеле су юлына таба тарта... Бик якын көннәрдә (яисә инде матур кичләрдә) беренче очрашу булачагы да сизелеп тора — чөнки ике йөрәкнең дә омтылышлары уртак ич! Ләкин, шул вакытта, татар кызына хас оялчанлык, хәтта кырыслык та сизелеп куя: ул боларның барысын да «юк өчен генә» дигән булып бәяли. Ә чынлыкта монда без хатын-кызның бөтен язмышын хәл итәчәк мәсьәлә — Мәхәббәт турында сүз барганын бик яхшы белеп торабыз.

Әйе, безнекеләр хис-тойгыларын сөйгән кешесенә турыдан-туры ачарга ояла инде алар. Эчкә, күңел түренә җыя бара, туплый, тутыра инде алар! Әллә соң әнә шуңа күрәме безнең татар хатын-кызларының мәхәббәте көчлерәк, куәтлерәк һәм... бөтен нәрсәне (шул исәптән үзара татулыкны да!) бөтереп агызып китәрдәй дәһшәтле агымга әверелә микән?

Синең өчен, синең хакка
Күңелләрем күбәләктер.
Белмәсәң дә, сизмәсәң дә,
Бәхетләрем түгәрәктер.

Бу юлларны укыгач, хәтта шагыйрь Тукайның кызларга булган оялчан, ләкин көчле эчке мәхәббәте искә килеп төшә.

Ләкин Фәйрүзә Мөслимованың бу китабы бер дә юкка гына «Ярату яралары» дип аталмаган — аның иң зур өлешен мәхәббәт, сөю драмаларына багышланган һәм үзләреннән вулкан аткандагы сыман ут, ялкын чәчеп торган чын мәхәббәт шигырьләре тәшкил итә. Биредә безнең еллар мәхәббәтенең киң гаммадагы чагылышы яши.

Синең — минсез, минем синсез үтәр
Киләчәккә калыр бер хатирә.

* * *

Җан авазым йолдызларга аша:

— Авыр булыр сиңа миннән башка-а!

* * *

...Елларыңның елап агышымы...

* * *

Күлдәй тыныч һәм... куркыныч!

Әле генә күреп киткән менә бу юллар — инде Мәхәббәт белән саубуллашканнан соңгы күңел халәтен белдерүче көчле ут көлтәләре. Якындагы янгынның безне дә пешерә, куыра, яндыра торган ялкыннары алар! Китаптагы әлеге шигырьләр безгә шулай тәэсир итә. Биредә иректән Мостай Кәримнең:

Әмма мине шагыйрь ясадылар
Югалтулар белән сагышлар,—

дигән классик юллары да искә төшә. Французчалап: «Си ля ви...» — дип тә әйтеп куясы килә... Чыннан да, яшәү әнә шундый бәхетле очынулары һәм газаплы тетрәнүләре белән барысын бергә алганда, гүзәл бер симфония булганга күрә матур һәм тәмле шул инде ул! Бу китап яшәүнең әнә шундый киң диапазондагы гүзәллеген әйбәт, тулы чагылдыра.

Ә инде китапның соңгы бүлеге — «Алма бакчасы» — алдагы ике бүлектә без кичергән бөтен хисләрне, тойгыларны бергә бәйләүче, берләштерүче аерым бер поэма сыман кабул ителә. Гүяки алмагач һәм алма образы аша шагыйрә кешеләр, гашыйклар язмышын бирә. Алмагачның язын балкып чәчәк атуы да, алмасын үстерә-үстерә куануы да, ә инде көзләр килгәч, алмаларның коела, ботакларның сына, яфракларның коела башлавы да — биредә һәммәсе дә кеше башыннан кичә торган сөенечле һәм көенечле, әмма тәэсирле тормыш күренешләре булып кабул ителә.

Ә инде халкыбызның яратып җырлый торган:

Әй алма бит, алма бит,
Алма битләр кала бит...—

дигән үзәк өзгеч җырын без бу бүлекнең эпиграфы итеп ишетәбез. Бу бүлектәге «пар алма», «сыңар алма», «ярты алма» кебек сүзләрдән соң әлеге җыр бигрәк тә мәгънәле кабул ителә.

Алдарак китерелгән шигырь юлларыннан укучы инде үзе дә күргәндер, аңлагандыр: шагыйрә Фәйрүзә Мөслимова, әсәр иҗат иткәндә, шигырь тукымасын матур-матур сүзләр белән, купшы-купшы телбизәкләр белән, истә кала торган поэтик детальләр белән әллә ни бизәп, чуарлап тормый. Шигырьләрне укыган чагында, бик тиз күзгә ташлана торган әнә шул тышкы билге шагыйрәнең шәхсән үз холкын да һәм әнә шуңа бик тә бәйләнгән иҗади табигатен дә сиздереп тора. Әйе, дисең — бу шагыйрә халыкта кайсыбер иҗатчыларга карата әйтелә торган «тел бистәсе» дигән төшенчәгә һич кенә дә туры килми. Бу шагыйрә тәмле-тәмле сүзләр белән сыйпап-юмалап һәм шул ук вакытта... алдашып та яшәүче түгел. Ул — ихлас кичерешләр, җитди, тотрыклы, тирән һәм көчле хисләр кешесе!

Язган чагында да шагыйрә үзенең төп игътибарын хис-кичерешнең үзенә, аның асылына, чын табигатенә юнәлтә. Әнә шул кичерешне, шул давылны төгәл һәм тулы итеп, бар катлаулыгында һәм тирәнлегендә ачып салырга тели, шуңа омтыла. Һәм аның бу төп теләге уңышлы рәвештә тормышка да аша. Китаптагы күпсанлы уңышлы мисаллар шуны раслап тора.

Әлбәттә, тормыш булгач, җанлы иҗат процессы булгач — әсәрләр бер югарылыкта гына килеп чыга алмый. Йөрәктәге хисләр дә төрле чакны төрле кайнарлыкта, төрле экспрессиядә була ич! Бу китапта да ара-тирә тиешле кайнарлыкка ирешеп үк җитмәгән әсәрләр очраштыра... Аннары урыны-урыны белән артык шәхси үпкә хисләре дә күренгәләп ала. Укучы өчен аларның зур әһәмияте юк, билгеле.

Ләкин андый шигырьләр бу китапта бик аз. Шуңа күрә алар шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың шигъриятенә уңышына һич кенә дә күләгә төшерә алмый.

...Менә без шагыйрә Фәйрүзә Мөслимованың беренче китабын укып чыктык. Әйе, моңа кадәр газета-журналлар аша таныш булган бу иҗат, чыннан да, җитди, тирән дөнья икән! Ул безне җан, рух өчен бүген бик тә мөһим булган хәзинәләр белән баетты, безне әхлакый һәм рухи яктан көчәйтте. Ә иң әйбәте — бу шигырьләрне укый-укый безнең күз алдында бүгенге көн татар хатын-кызының рухи портреты хасил булды. Ул нинди соң?

Туган нигез, туган туфрак, гаилә җылысы — ә гомумиләштереп әйткән чагында, оя тойгысын белдерүче төшенчәләр аңа бәләкәйдән үк әби-бабай, әти-әни тәрбиясе аша, авыл җиренең әнә шуңа булышучы эчке климаты аша, ана сөте белән үк сеңгән. Бу — аның өчен иң зур һәм киләчәктә иң кирәк булачак эчке рухи байлык.

Бу нигезнең, бу ояның бары тик мәхәббәт җепләре белән генә исән-сау сакланып тора алачагын ул бик яхшы аңлый, белә, сизә — шуңа күрә мәхәббәт хисен ул әлеге нигезнең иң беренче, иң мөһим ныргәсе дип кабул итә, шуңа нык ышанып яши.

Аның менә шушы ныклы ышанычын, иманын кемдер аңлап җиткерми икән яисә үзенең яшәү рәвеше белән ул иманны кире кагарга тели икән, андый хисләргә ничек тә булса хыянәт итә икән — бу зат

безнең шагыйрә өчен инде дөньядагы иң әшәке көч сыман күренә башлый, ул аны бөтен дөньяны, аның матурлыгын, камиллеген җимерә алырдай көч дип карый.

Һәм бу очракта безнең шагыйрәне ялгыша диеп тә булмый. Чыннан да, бүгенге бөтен начарлыкларның нигезендә әнә шул Оя җылысы җитмәү, Оя тузган булу, кешеләрнең кайчагында бәләкәйдән үк әнә шул шифалы тәэсирне тоймыйча — каты бәгырьле булып, тимер-бетон сыман җансыз, тойгысыз булып үсүләре сәбәпче түгелме соң инде?!

Шуңа күрә Фәйрүзә Мөслимованың бу китабындагы күпчелек әсәрләр укучы күңелендә гаилә, оя тойгысын көчәйтүгә, шуны ныгытуга булыша дип әйтәбез икән — хәзерге иҗат өчен бу зур казаныш, мәртәбә.

2001

Халыкчанлык

Еллар узган саен, кешелек дөньясының ипле, имин һәм тотрыклы хасияте турындагы уйлар һаман ныграк били бара. Үзебезгә ата-бабалардан кыйммәтле мирас булып калган табигый гүзәллекне югалтмыйча, ямь-яшел болыннары, серле кара урманнары һәм саф сулы тирән күлләре булган Җиребездә ямьле итеп, кешелекле итеп гомер кичерү турындагы кадерле уйлар алар...

Алтмышынчы еллар ахырында үзенең «Без — кырык беренче ел балалары» исемле беренче повестен бастырып, шундук укучыларның мәхәббәтен яулап алган язучы Мөхәммәт Мәһдиев иҗатының да бөтен мәгънәсе әнә шуңа — безнең имин тормышыбызның чиксез ямен һәм кабатланмас гүзәллеген, замандашларыбызның үтә кызыклы образларын күңелгә үтәрдәй тәэсирле итеп сурәтләүгә багышланган. Әдипнең әсәрләрендә тасвирланган һәрбер күренеш һәм һәрбер герой укучыга әйтерсең лә болай ди:

— Күрәсезме, тыныч дөнья нинди гүзәл! Сизәсезме, имин яшәү нинди татлы!

Беренче әсәрләреннән үк авторның язу рәвешен яратып өлгергән безнең укучы М.Мәһдиевнең журналларда басылган һәр яңа повестен, китап булып дөнья күргән һәр яңа җыентыгын зур түземсезлек белән көтте. Кайбер әдәбият галимнәре һәм редакторлар, әдип алып килгән ижади яңалыкка гаҗәпләнеп: «Мондый проза әсәре буламы, юкмы?» — дип, кирәкмәгән бәхәс куертып яткан арада, язучы үзе иҗат өчен иң кирәк нәрсәне — укучы игътибарын сизеп алды һәм зур күләмле икенче әсәрен — «Фронтовиклар» романын да өлгертте... Аннан соң тагын «Кеше китә — җыры кала» булды... Бераздан «Торналар төшкән җирдә» һәм «Исәнме, Кәшфи абый!», «Мәңгелек яз» киштәләрдә урын алды...

Күрүебезчә, укучы күңеленә язучы М.Мәһдиев исемен нык итеп сеңдергән бу әсәрләр чагыштырмача кыска гомер, якынча унбиш еллап вакыт эчендә язылганнар. Шундый соклангыч әсәрләр өчен шактый аз ара түгелме соң бу? Җитмәсә, автор бит әле бу елларда, Казан дәүләт университеты доценты буларак, бик мәшәкатьле укыту эшен дә алып барган, фәнни эзләнүләрен дә туктатмаган. Шулай ук республикабыз матбугатында без аның бүгенге тормыш белән тыгыз бәйләнештә, алгы сызыкта торып язылган ялкынлы публицистик мәкаләләрен дә даими укып барабыз. Шундыйлардан узган ел «Социалистик Татарстан» битләрендә дөнья күргән «Кесмәс үзәненнән хатлар» үзе генә дә ни тора!

Әдипнең мондый ижади активлыгының сере нәрсәдә соң?

Һәрбер бөек сернең җавабы шактый гади булып чыккан шикелле, биредә дә хикмәт әллә кайда, җиде тау артында түгел. Эш бары тик шунда гына: язучы һәрдаим актив күңел белән, күп кенә яшьләрне көнләштерә алырдай иҗат ялкыны белән яши.

Татарстан Язучылар союзының ул җитәкләгән проза секциясе эшендә катнашкан каләмдәшләре М.Мәһдиевнең бу сыйфатын бик яхшы беләләр. Ул үзе илнең һәм хәтта дөньяның әллә кайсы ерак почмакларында йөреп, әллә нинди кызыклы кешеләр белән танышып кына калмый (мәсәлән, ул күптән түгел ерак Мурманскига, Хәрби диңгез флоты сугышчылары янына барып кайтты), каләмдәш язучылары белән очрашуга да гаять кызыклы шәхесләрне табып китерә, хәтердән чыкмастай әңгәмәләр оештыра. Республиканың алдынгы колхоз председательләре белән язучы-прозаиклар очрашуы нәкъ әнә шундый иде.

М.Мәһдиевнең тынгысыз ритмда яшәвен башка бик күп мисаллар да раслый алыр иде... Әйе, берсеннән-берсе кызыклырак эчтәлекле яңа повестьларның туып тору сере дә әнә шунда — тынгысызлыкта. Әйе, тормышның гел хәрәкәттәге үзәгеннән алып язылган публицистик чыгышларның бәрәкәтле җирлеге дә әнә шул — актив эшчәнлек.

Бу сыйфат аның әсәрләренең дә иң төп үзенчәлеген билгели. Ул язган һәм укучы яратып кабул иткән барлык әсәрләрне җыйнап, янәшә куеп карасаң, шундый бер нәтиҗәгә киләсең: аның әсәрләрендә

һәрчак хис һәм фикер ташып тора, уйнап тора. Ул роман-повестьларда тышкы һәм эчке дөньяларның актив хәрәкәте бара. Аларда яшәү пульсы язгы дәрт һәм язгы көч белән тибә! Кыскасы, һәммә яктан алганда да динамизм, дәртле тормыш агышы бар аларда!

Менә авторга иң зур дан китергән әсәр — «Фронтовиклар» романы... Андагы яшь укытучы Рушадның катлаулы уй-кичерешләре... Сугыштан соңгы авылның әле моңа кадәр әдәбиятта күренмәгәнчә оптимизм һәм моңсулык катыш сурәтләнүе... Колхозчы крестьян тормышының авыр да, шигъри дә булган чынбарлыгы... Күпсанлы, ләкин кабатланмас холыкка ия балалар... Кеше буларак гаять тә оста ачылган укытучылар... Яшьләр... Картлар...

Язучы кешеләр яшәешен киң планда ала, масштаблы итеп колачлый, һәм тормышның кайсы төбәген, кайсы тармагын гына сурәтләргә алынса да, хәтердә калырдай детальләр, үзенчәлекле штрихлар таба әдип. Менә аудиториягә гармун уйнап килеп кергән дуамал Гата... Менә бер сүзе онытылганнан соң гына икенчесен әйтүче Галиәхмәт карт... Менә үзен гел гаепле санарга күнеккән Сабир Ишморатович...

М.Мәһдиев әсәрләрендә гап-гади тормышның гап-гади хәл-әхвәлләре генә алына. Ләкин язучының күңел күзе бик тә үткен. Безнең әйләнә-тирәбездәге драмалар һәм комедияләр аның игътибарыннан читтә кала алмый. Һәм әдип алар турында яза. Сызланып та, елмаеп та, уйланып та, моңланып та яза ул. Аның тылсымлы каләме тәэсирендә укучы да сызлана һәм елмая, уйлана һәм моңлана. Мәскәүгә олы киңәшмәгә барган җиреннән да авылдагы тракторы турында уйланып йөрүче Кәшфи («Исәнме, Кәшфи абый!»), ачлы-туклы яшәүче сеңелләрен күчтәнәч алып кайтып сөендерергә теләгәндә, чүт кенә үзе һәлак булмый калган Баязитова дигән кыз («Без — кырык беренче ел балалары»), «яшьтәш, бер сөйләшеп куныйк» дип инәлгән моңлы җан Рәкыйп («Торналар төшкән җирдә...»). Менә бу кызганыч та, драматик та, урыны-урыны белән мәзәгрәк тә тоелган хәлләр — барысы бергә алар тормыш үзе бит инде! Әнә шундый күптөрле тормыш көчләренең гаять тә муллыгын, ишлелеген күрәбез без язучы иҗатында.

Ә шулай да М.Мәһдиев иҗатының тиз арада киң катлау укучылар мәхәббәтен яулап алуын ничек аңлатырга була соң? Кыска гына итеп әйткәндә, мөгаен, шуның беләндер: язучының образлы фикерләү рәвеше, язу юнәлеше туган халкыбызның меңнәрчә еллар буена тудырылып килгән авыз иҗаты әсәрләренә бик тә якын. Хәтта М.Мәһдиев әсәрләрен халкыбыз иҗатының бүгенге үзенчәлекле дәвамы дип тә карарга мөмкин сыман. Бу — икенче төрле итеп әйткәндә, меңләгән, миллионлаган кешеләрнең рухи дөньясына, аларның уйлау, фикерләү рәвешләренә якынлык дигән сүз. Бу — һәрбер иҗат кешесе бик тә теләгән нәрсә — халыкчанлык дигән сүз.

Чын әдәбият, зур сәнгать һәрвакытта, һәр чорда укучының күңел юлдашы булды, аны четерекле борылышларда ялгышмаска, адашмаска өйрәтте, укучының күңел күзен үткенәйтте. М.Мәһдиев иҗаты да — бүгенге шәхеснең табигый һәм гармоник үсешен яклап, халыкчанлык, тормышчанлык төпкеленнән бәреп чыккан куәтле дәрья ул.

1994

Еники дәресләре

Әмирхан Еники... Бу исем бүген безнең күңелләрдә шулкадәр күп уйлар уята ки, ул уй-фикерләрнең күплеген, муллыгын, мөгаен, бик тә киң дәрья белән генә чагыштырып карау мөмкиндер... Ә соңгы елларда тормышыбызда башланып киткән яңарыш хәрәкәте исә Әмирхан Еники исеме һәм әдип иҗаты кузгаткан андый уй-фикерләр агымын тагын да көчәйтә, куәтләндерә төшә. Шуңа күрә хәзер Әмирхан Еники иҗаты хакында сүз алып бару үзе үк зур мәгънә ала һәм уйларны тагын да эчкәрәк, тирәнгәрәк тарта.

Ни өчен шулай? Ни өчен Әмирхан Еники иҗаты белән яңарыш хәрәкәте бер-берсен бигрәк тә көчәйтәләр, бер-берсен тулыландыра төшәләр?

Ә бит һич тә сер түгел: хәзер, илебездә киң колачлы үзгәртеп корулар башлангач, үз иҗатын, үзенең элегрәк язганнарын өр-яңадан карап чыгарга тиешле шактый исемле язучылар, сәнгать әһелләре бар! Хәтта үзләренең моңа кадәрге яшәвендә тоткан әхлакый һәм социаль ориентирларын бүген халык йөрәгенә карап дөресләргә, аны яңадан көйләргә тиешле иҗатчылар бар!

Ә менә Еники иҗаты нинди? Ул, бүгенге саф җилләр искәндә, үзен ничек сизә? Ничек булып күренә?

Океан гизүче диңгезчеләр, давыл-гарасат вакытында компаслары сафтан чыкса, һавадагы йолдызларга карап дөрес юнәлешне табалар... Безнең халкыбыз да бу шаулы егерменче гасырда андый көчле

гарасатларны байтак кичерде... Куллардагы һәм уйлардагы компас укларының да тегеләй-болай уйнаган чаклары булгалады.

Әмирхан Еники иҗаты халыкны әнә шундый аптыраулы вакытларда адаштырмый торган якты йолдызлар кабызды. Һәрбер әсәре белән бер якты йолдыз кабызды ул халкыбызның мәдәният күгендә! Һәм әнә шул йолдызлар ил, халык тормышында адаштыручы томан аеруча куерган вакытларда да кешеләргә күңел күзләрен текәп бару өчен рухи, әхлакый маяклар булдылар! Күңелләрдәге, яшәештәге томанны таратышырга булыштылар!

Нигездә, кыска күләмле жанрда эшләп дан алган бу язучының мәхәббәткә багышланган зур күләмле өч әсәре — өч повесте бар! Менә шуларның берсе — «Йөрәк сере». Анда тирән социаль эчтәлек ята. Зөһрә исемле яшь кыз мәхәббәте каршында ике холык-характерлы, ике төрле кеше сынау тота. Аларның берсе — үтә коры, үтә дә җитди кеше, яшь кенә килеш зур түрә булган тип. Ә икенчесе исә — гади һәм табигый яшәүче, ачык күңелле, беркатлы Бәхетгәрәй.

Биредә сәнгатьлелек шулкадәр көчле, тәэсирле — әсәрне укыган чагында синең күңелеңдә шундый бер тойгы да туа: гүяки яшь Зөһрә аша, аның күңел күзләре белән бу ике типка халык үзе карый, гүяки аларны кешелек идеалы үзе күзәтә. Укучыда хасил булган менә мондый фикердән соң инде бу образларның кайсы кем икәнлеген ачыклауга да ерак калмый. Аларның берсе — Сталин чоры һәм аның традицияләре тәрбияләп үстергән хиссез, җансыз түрә, үзенең кешелек үзәге булмаган функционер. Җанлы тормыш агышына таш стена булып аркылы төшкән кресло корты... Ә икенчесе — халыкның үз вәкиле — табигый бер җан! Үзе белән тормышка кайнар мәхәббәт, кайнар хисләр алып килә торган зат. Бөтен фидакарьләрне, каһарманнарны бер-бер артлы тудырып тора торган бәрәкәтле социаль катлам бу. Туган җирнең уңдырышлы туфрагы сыман уңдырышлы җирлек! Без әле генә күреп киткән кешеләргә аваздаш образлар әдипнең күп кенә бүтән әсәрләрендә дә очрый. Аларның нинди булуларын, кем икәнлекләрен ачыкларга еш кына очракта әлеге дә баягы гүзәл мәхәббәт хисе ярдәм итә. Мисал өчен, «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә (1975) төп героиня яшьлегендә Салих белән ике арадагы мәхәббәтне саклый алмавы, тормышта дөрес юлын югалтуы өчен, еллар узгач, менә ничек зар елый: «Әйтегезче, ни эшләдем мин, ни эшләдем?.. Ни булды соң миңа, Ходаем, ни булды?.. Нәрсә, нинди явыз шом мине шулхәтле өркетте, акылымны тартып алды, ихтыяр көчемне сындырып ташлады?..»

Ишетәсезме, мәхәббәткә каршы килгән көч биредә нинди төгәл сүзләр белән атала: явыз шом, өркетте, ихтыяр көчемне сындырып ташлады... Болар барысы да без югарыда күреп үткән яшь түрә сыман типлар тудырган ямьсез социаль сыйфат — яшәүне, тормышны үтерә торган көч.

Бу — мәхәббәттән кала әдип өчен икенче үтә мөһим мәсьәлә, бик җитди тема. Ә. Еники хәзерге чынбарлыктагы мәхәббәтне, табигыйлекне, кешелекне бетерергә юнәлгән әлеге зур дошмани көчне төрле-төрле яклап сәнгатьчә тасвирлый. Халык тормышының шәһәрләшүенә, торгынлыкка һәм тагын башка сәбәпләргә бәйле рәвештә соңгы унъеллыкларда пәйда булган ул көчле дошманны тәжрибәле әдипнең сизгер күңел күзе гаять күп чагылышларда күрә.

Әдипкә зур дан һәм бер үк вакытта бихисап борчу, бимаза алып килгән атаклы «Рәшә» повесте... Торгынлык чоры юлбашчыларының котын очырган әсәр... Биредә дә үзәктә хатын-кыз образы һәм мәхәббәт... Артистка Рәшидәне күрәчәге Зөфәр Сабитов дигән берәү белән таныштыра. Икесе ике иманлы, дөньяның һәм тормышның икесе ике полюсына карап яшәүче ике кеше, шулай итеп, бер мәхәббәт җебе белән бәйләнә. Повесть битендәге мавыктыргыч вакыйгаларга ияреп бара-бара, Рәшидәнең генә түгел, ә укучының да күңел күзе ачыла. Яшәешнең бары тик тышкы ягы — матди ягы турында гына кайгыртучы мескен һәм шул ук вакытта куркыныч та булган бер тип гәүдәләнә.

Бүген, сиксәненче еллар ахырында, безнең өчен тәмам бәлагә әверелгән мондый Сабитовларны сизгер йөрәкле язучы Ә.Еники инде 1962 елда ук күреп алган! Андый кешеләрнең әхлакый һәм социаль яктан җәмгыятькә бик зур зыян китерәчәкләрен аңлаган! Ә безнең торгынлык юлбашчылары ул вакытта бу әсәрне чын-чынлап дошман күрделәр, штыкка алдылар! Хаким шәхесләрнең андый мөнәсәбәте һәм әдәбият-сәнгать фикерен санга сукмаулары тормышта күпләгән Сабитовларның көчәюенә китерде. Нәтиҗәдә җәмгыятебездә әхлакый череклек тагын да артты. Еники шикелле нечкә күңелле һәм намуслы кешеләргә, шундый әдипләргә яшәү, иҗат итү тагын да кыенлашты. Власть ияләре алдында үзенең шәхси дәрәҗәсен күтәрергә теләгән карьеристик омтылышлы һәркем Әмирхан Еникине тәнкыйтьләде, аңа карата сизелердәй салкын караш тудырды һәм шул юл белән үзенең биләгән урынын ныгытты. Хәтта республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясен дә бу олы әдип бөтен урындагы кешеләрдән соң гына ала алды! Ул чагында безнең иҗат союзыбызда әнә шундый хәл иде...

Ә бит бу күренекле әдипнең бер генә хикәясен укыган кеше дә гаять сирәк очрый торган көчле талант иясе белән очрашуын тиз аңлый. Мисал өчен, берничә биттән генә торган «Ялгызлык» хикәясе. Бер укыган кеше аны һичкайчан оныта алмый. Чөнки бу әсәрнең нигезенә романга торырлык зур бер вакыйга, гыйбрәтле тарих салынган. Сугыш чорында Ленинградтан эвакуация белән безнең Бөрелегә килгән Тамара Сергеевна исемле яшь ханым турында ул. Гаять тәрбияле бу ханымның мәхәббәттә алдануы — авыл кешеләре каршында хурлыкка калу трагедиясе анда... Әнә шул хәл күздән яшь китерердәй тирән итеп тасвирланган.

Язучының 1965 елда ук иҗат ителгән «Әйтелмәгән васыять» әсәре үзенең эчтәлеге һәм сәнгать дәрәҗәсе белән бөтен совет әдәбиятында зур вакыйга булырга тиешле күренеш иде. Ч.Айтматовның, В.Распутинның һәм В.Беловның бу темага шактый соңрак иҗат иткән әсәрләре ил һәм дөнья күләмендә шауладылар. Ә безнең республикада «Әйтелмәгән васыять» басылып чыккан чордагы иҗтимагый-политик шартлар бөтенләй бүтәнчә иде — ул әсәрне ил масштабына күтәрердәй, тәкъдим итәрдәй түгел иде. Ләкин дөнья күләмендә югары бәһа алырга лаек бу әсәргә юлны ябарга теләсәләр дә, ул халык йөрәгенә сары май булып ятты. Чөнки безнең халкыбызны үтә ягымлы образ Акъәби итеп гәүдәләндергән бер гүзәл поэма иде ул! Анда халкыбызның бүгенге четерекле хәле, язмышы сурәтләнгән иде! Туган туфрагыннан куптарылып, башта шәһәргә китерелгән, ә анда үз балаларына хәтле кирәксенми башлагач, ахыр чиктә больницага кертеп ташланган Акъәбине исегезгә төшерсәгез, бер карчык язмышы аша халык тәкъдире чагылганын тиз үк аңларсыз... Әдип талантының көченә сокланмыйча, баш имичә һич мөмкин түгел!

Югарыда әйтелгәнчә, әдипнең һәр әсәре әдәбиятыбыз күгендәге йолдыз сыман балкый. Аларның берсен генә күрмәү дә мөмкин түгел! «Тынычлану», «Матурлык», «Шаяру», «Кем җырлады», «Бер сүз»... Һәммәсендә гаять тә тирән һәм беркайчан искерми торган, һәрчак кешеләрне дулкынландыра торган эчтәлек! Һәммәсендә синең бөтен барлыгыңны, рухи дөньяңны тетрәтә торган сәнгатьчә тәэсир көче! Аларның һәммәсен укыйсы, тагын-тагын, кат-кат укыйсы килеп тора! Үзләрендә тупланган моң һәм сәнгать көче ягыннан Әмирхан Еники әсәрләрен бары тик халкыбыз җырлары белән генә чагыштыру мөмкиндер. Бик тә үзебезчә, үтә дә милли, үтә дә үзәккә үтә торган моң белән генә... Аның әсәрләре, чыннан да, шундый бит!

1989

Яктырта да яшен, яндыра да...

Яшь шагыйрь Рөстәм Сүлтинең 1992 елда Казанда басылып чыккан «Мин — шигырьдән» исемле беренче китабы турындагы сүзне менә бу әсәреннән башлап китәсе килә:

Чатыр корыйк, әйдә, казан асыйк.
Кадап куйыйк әле яшел әләм.
Күздә шатлык яше...
Иделкәйдән
Су китерәм кәләпүшем белән.

Китаптагы байтак әйбәт шигырьләр арасыннан нәкъ менә шунысына тукталуыбызның сәбәбен кайберәүләр, бәлки, бүтәнчә аңлатуны көтәдер. Чөнки биредә безнең күңелне публицистика юлына алып кереп китәргә ымсындырып торган «яшел әләм», «кәләпүшем» һ.б. гыйбарәләр бар. Ләкин, газета-журналларыбызда соңгы елларда шактый актив рәвештә алга сөрелгән милли идеяләргә һич тә кырын карамастан һәм бу шигырьдә андый «үтә милли» сүзләрнең кулланылуын бер генә дә артыксынмыйча, шулай да әсәрнең иң төп уңышы башка нәрсәдә дип аңлатасы килә.

Ә нәрсәдә соң? Минемчә, эш шунда: яшь шагыйрь безнең чор тормышында һәм күңелләрдә кайнаган идеяләрне, уй-хисләрне бик тә шигъри, тәэсирле күренеш итеп җанландыра алган. Автор публицистик чакырулар, өндәүләр һәм мөрәҗәгатьләр яссылыгыннан өскәрәк күтәрелгән һәм әйтер сүзен югалтмаган хәлдә, шигъри кичерешләр, күренешләр биеклегендә поэтик яшәү таба алган.

Мөгаен, шуңа күрәдер яшь шагыйрьнең беренче китабын ачып җибәрүче ижаты да чын публицистик әсәрләр түгел, ә җанга, бәгырьгә, җырга, моңга багышланган шигырьләр. Шулардан берсе — «Мәрхәмәт» дип исемләнгән:

Учагына, кочагына алган,
Таныш-туган түгел, чит кеше.
Даны да юк, малы да юк аның,
Ул бит бары — Вәли-читекче...

Сәяси гарасатлар һәм экономик кризислар чоры шагыйре Рөстәм Сүлти әнә шундый юллар белән безнең игътибарыбызны Тукайны тәрбиягә алган Вәли абзыйга юнәлтә. Менә шушы хәл үзе үк яшь ижатчы хакында күп нәрсә сөйли түгелме?! Ижатчының ныклы иманы, әхлакый мәккәсе, гуманистик идеалы — барысы да ачык чагыла түгелме шушы күренештә?

Юк, көндәлек тормышта безне борчыган сәяси һәм социаль вакыйгаларны да икенче планга күчермәи Сүлти. «Мәскәү феномены» шул хакта сөйли:

Саумы, Мәскәү, килдем менә сиңа.
Мин әле бу — «Казан феномены».
.....
Кем теләге кабул?
Саумы, Мәскәү,
Гаҗәпләнмә, бу мин — феноменың.

Биредә шигърият ягыннан алганда әллә ни мактанырлык урын күренмәсә дә, укучыны гадел һәм намуслы сүз пафосы, ялкыны җәлеп итә. Монда без Маяковский һәм Евтушенколар, Такташлар ижатында балкыган көрәшче йөрәк ритмын тоябыз. Әнә шундый йөрәк дулкыннары укучы күңелен битараф калдырмый.

Өченче бер мизгелдә инде Р.Сүлти, гасырларны кичеп, гаять зур акыл-тәҗрибә туплаган аксакал тавышы белән сөйли башлый:

Олы юлдан килә ялгыз кәрван,
Алыслардан бугай, бигрәк арган.
Ашыгасың кая, юлың кайдан,
Әйтче, зинһар, әй, адашкан кәрван?

Шигырь сөючеләр өчен бу кәрван — гади төркем генә түгел. Бүгенге сәяси хәлләрне истә тоткан укучы өчен әлеге кәрван — барыннан да бигрәк — милләт! Биредә дә яшь шагыйрь үзе әйтергә теләгән фикерне чакыру-өндәү юлы белән түгел, ә бәлки шигъри күренеш аша җиткерә. Милли моңга, шәрык аһәңенә төреп бирә ул үз идеясен! Әнә шуңа күрә — татар укучысының милли хасиятен һәм аның шигъри «организмы»ның аерым үзенчәлекләрен нык искә алып эш иткәнлектән — аның безгә йоттырырга теләгән «ризыгы» да теләбрәк кабул ителә һәм безнең аңыбыз тарафыннан яхшырак үзләштерелә.

Менә шушындый күзәтүләр бу китаптагы байтак әсәрләрне укыганда күзгә ташлана. Вакыты-вакыты белән, кайбер башка яшь шагыйрьләрне дә искә төшерә-төшерә, шулай уйлап куярга да җөрьәт итәсең: «Безнең әдәбиятта һәм шигърияттә милли тематиканы үзләштерүнең икенче баскычына күтәрелү процессы бара, ахрысы... Сүзләр һәм өндәүләр яссылыгыннан, шигъри кичерешләр һәм күренешләр биеклегенә күтәрелү...»

Әйе, китапка «Мин — шигырьдән» дигән бик тә яңача яңгырашлы һәм кыю исем куелса да, гәрчә бу исем үзенең эчтәлеге белән шигърияткә таба гына ымласа да, ләкин чынлыкта андагы әсәрләр — бүгенге сизгер күңелле кешенең йөрәк тибешен киң чагылдырган шигырьләр. Анда замананың гамьле шәхесен борчыган бик күп кичерешләр сыйган, урын алган. Әмма шулай да иң уртадагысы, иң үзәккә үткәне — милләт язмышы.

Бу язмабызны башлап киткән «Зимагуркай, кайт илеңә» шигырендә тагын менә мондый юллар бар: «Кайт илеңә, кайт денеңә. Кайт телеңә, зимагур».

Игътибар итәсезме: безнең бүгенге газеталарда адым саен диярлек кабатлана торган «маңкорт» дигән төшенчә яшь шагыйрь ижатында нинди авылча, нәкъ үзебезчә яшәү таба алган. Чыннан да, әлеге әсәр маңкортларга багышланса, коры бер өндәмә генә булып калыр иде. Ә яшь шагыйрь аның, әлеге маңкортның, безнең авылларга килеп ялганучы язмыш сукмагының башын таба алган.

Зимагурлык, маңкортлык... Татар халкының кара язмышыннан килеп чыккан кара сакалы... Без үзебезнең язмаларда: «Нишләп соң безнең милләт бик тә чәчелгән?» — дип сорау куябыз да, ни өчендер шул соравыбызга җиңелчә генә җавап биреп үтәбез. Янәсе, безнең бабайларга акыл җитмәгән... Ә бит биредә шактый объектив сәбәпләр дә күренеп тора. Галимнәрнең өлешенә кермәстән, сүз уңаеннан үз фаразымны белдереп китим. 1. Безнең геннардагы күчеп йөрү традициясенең чагыштырмача озак сакланuы. 2. Төрле кабилә һәм ырулардан оешкан милләтнең тарихи шартлар мөмкинлек бирмәү һәм, моңа вакыт җитмәү сәбәпле, тәмам укмашып, ныгып бетә алмавы. 3. Татарның урыс өчен бик көчле һәм мәңгелек көндәш булу сәбәпле, урыс хакимияте тарафыннан аның аеруча нык изелүе, кысылуы — шуның аркасында төрле җиргә чәчелергә мәҗбүр ителүе. 4. Зур халыкның, күпсанлы татарның үзенең дә кечкенә Татарстан республикасы кысасына гына сыеп, сыешып бетә алмавы... Менә шушы дүрт зур сәбәп, минемчә, татарның бик нык чәчелүен китереп чыгара. Язмыш. Тәкъдир!

Шагыйрьнең зимагурлар турындагы бер шигырен укыганда, күңелдән әнә шундый уйлар йөгереп үтә. Шул ук вакытта бу әсәр безнең һәммәбезнең кечкенә чагында Идел, Чулман буйларында көймә көтеп, учак ягып, казан асып ятуларыбызны да күз алдына китерә. Ягъни без дә кайчандыр нәни зимагурлар булмадыкмыни да, һәм менә хәзер үсә-үсә генә чын татарга әйләнә бармыйбызмыни?! Шушы шигырь мисалында без поэтик фикернең төрле яссылыкларда үсүен, яшәвен күрәбез. Алар бер-берсен тулыландыра, көчәйтә, баета. Тематик яктан алып караганда, Рөстәм Сүлти китабында бик зур яңалыклар бар дип әйтеп булмыйдыр, мөгаен. Һәм моның өчен аны битәрләргә дә ярамый. Чөнки вакытлы матбугатның давыллар куптара-куптара шаулаган мондый чорында, инде беркем тарафыннан да әйтелмәгән сүзләр, кузгатылмаган темалар калдымы икән? Юктыр!

Шулай да яшь шагыйрьнең бу китабында чор тормышының социаль каршылыкларына һәм милләтебезнең хәленә аерым игътибар бирелгәнен күрми калу мөмкин түгел. Иҗатчының социаль һәм сәяси фикерләү сәләте дә көчле, андый мәсьәләләр күтәрелгәндә, уйлар гел дә гаделлек һәм объективлык бизмәне аша үткәрелә. Ниндидер субъективлык төсмерләре сизелми. Чын иҗатта бусы да мөһим. Югыйсә вакыт узу белән әсәрләрең искерергә дә мөмкин.

Шагыйрьне үзенең һәм милләтенең өч төрле бәйләнештәге урыны, хәле кызыксындыра: галәм тормышы һәм без, ата-бабалар юлы һәм без, башка милләтләр яшәве һәм без. Күренеш һәм вакыйгаларны әнә шундый күпьяклы бәйләнештә карау һәм тикшерү аңа үз әсәрләрендә дөрес кыйбланы табарга да булыша.

Арадан берсе — аталар һәм бабалар юлына тугрылык — әсәрләрдә бигрәк тә еш күтәрелә.

Баса җирне иман буар туфан.
.....
Исән калсын халкым,
Әй, пәйгамбәр,
Коткар безне, коткар, Рух көймәсе!

Тереклек ияләрен су басудан саклап калган Нух пәйгамбәргә аваздаш итеп, Р.Сүлти әнә шундый яңа образ — Рух пәйгамбәрне иҗат итә. Безнең татар милләте өчен бигрәк тә кирәк бу. Чөнки матди яктан бик алга киткән Көнбатыш та бүген рухи кризис кичерә. Алар күбрәк товар җитештерүдән башканы белмиләр. Рухи кыйблалары юк. Рәсәй дигән йөгәнсез ил, стихия безне дә әнә шундый юлга таба тарта, этәрә.

Ә менә чын иҗатчыларыбызның һәм аерым алганда Р.Сүлтинең әлеге шигырьләре безнең милләтне дөресрәк юлга юнәлтә. Матуррак, иманлырак юлга. Гаделрәк яшәү юлына. Ата-бабаларыбыз юлы да рухи яктан бай һәм иманлы яшәүгә таба ымлый, чакыра.

Гомумән, яшь шагыйрьнең иң яхшы әсәрләре безнең халкыбызга һәм традицион поэзиябезгә хас булган асыл сыйфатлар белән бизәлгән.

— Күбәләк булып кайтырмын,
Елама, балам,— диде.
Җәй җитте... Сабый һәрвакыт
Нәрсәдер эзли иде.
Көз инде... Шыксыз зиратның
Почмагына чүгәләп,
Кайнар тынын өрә сабый —
Учларында күбәләк.

Барысы дүрт куплеттан торган шигырьнең уртадагы ике строфасы гына бу. Күргәнегезчә, автор, кайбер яшь каләмдәшләре шикелле, гади халыкның гади яшәешеннән дә читләшми. Кайбер иҗатчылар «примитив» тамгасы сугарга ашыккан яисә «мелодрама» бәһасен бирергә теләгән күренешләргә Р.Сүлти өлкәннәрчәрәк, сабыррак карый. Кылтымлыктан һәм «отышлы» позалардан ерак торган әнә шундый холкы белән ул иҗатта зуррак перспективалар турында уйлата, күңелне әнә шундый ераклыкларга ымсындыра...

Хәзерге шигырь турындагы уйлануларда бу темага шактый еш кагылырга туры килә. Моны тормыш үзе дә мәҗбүр итә шикелле. Чөнки без бүген реаль чынбарлыкта да, әдәбиятта да иң чын, иң ышанычлы һәм иң үзебезчә булган юлларны эзлибез. Элеккерәк елларда өзелгән юлларның кайсысын дәвам итеп китәргә, дип баш ватабыз. Әмма соңгы еллар чынбарлыгы ышанырлык итеп шуны раслый: татар халкы өчен дә, татар әдәбияты өчен дә иң ышанычлы юл — традицион юл, аталарыбыз һәм бабаларыбыз барган юл! Һавадагы торнага кызыгу безне бары тик адаштырачак кына, читкә генә алып китәчәк! Без үз халкыбыз белән бергә һәм аның юлыннан барырга тиеш!

Әйе, мондый теләк матур, билгеле. Ләкин менә ул чынлыкта ничек тормышка аша соң? Соңгы елларда поэзиягә килгән яшь шагыйрьләр безнең поэзиянең халыкчанлык, тормышчанлык көчен арттырдылармы? Хәзерге татар шигъриятенә тагын да тирәнрәк һәм драматиграк Моң алып килдеме алар? Шигъриятнең үзәгенә булган Хисне, Кичерешне көчәйттеме?

Биредә кыска гына итеп әйтсәк: «Без теләгәнчә үк түгел!»— дияргә туры килә. Замананың кырыслыгы, рациональлеге, артык практиклыгы — яшь шагыйрьләребез иҗатында үзен бик нык сиздерә шул. Мөдәррис Әгъләмовлар һәм Зөлфәтләр язган беренче шигырьләр белән Ркаил Зәйдуллиннар, Газинур Моратовлар һәм инде менә безнең Рөстәм Сүлтиләр язган әсәрләрне чагыштырып, янәшә куеп карасаң — хисләрнең нык саегуын, гармониянең шактый җимерелүен, моң дигән тирән дәрьяның да «логик фикерләү» дигән салкын таш ярга таба авышуын чамалыйсың... Әйе, моңа тормыш агышы гаепле, ул сәбәпче. Ләкин мондый аңлату гына әсәрләрдә шигърият җитмәү дигән яман чирне аклый аламы соң? Бу инде шәһәр җирендә кислород җитмәгән шикелле. Сәбәбен дә белеп торасың — ләкин түзүе, шуңа күнегүе кыен!

Шәһәр җире дигәч, җәйге дачалар искә төшә... Җәйге болыннар хәтердә яңара... Чын яшәү, чын тормыш күз алдына килә! Безнең бүгенге поэзиядә кызлар иҗаты да әнә шулай: тынчу һавалы шәһәрдән табигать кочагына чыгу кебек тәэсир калдыра! Биредә табигыйлек, гүзәллек, ихласлык. Моң һәм сөю, моң һәм чын трагедия дә, кешечә кайгыру һәм кешечә сөенү дә биредә күбрәк, мулрак!

Шуңа күрә Р.Зәйдулланың әдәби ел йомгакларында хатын-кыз шагыйрәләр иҗатына карата әйткән сүзләре белән күпләр килешмәс дип уйлыйм. Хатын-кыз шагыйрәләр хискә-кичерешкә сизгеррәк алар. Нечкәрәк һәм тирәннәнрәк килгән моң саркый аларның әсәрләрендә. Салкын акыл һәм рационализм да (яшь шагыйрьләр иҗатына иң зур зыян китерүче нәрсә!) аларда бөтенләй булмый диярлек!

Сүз уңаеннан, 1992 ел поэзиясе хакында телмәр тоткан шагыйрьнең тагын бер фикере белән килешмим. Безнең бүгенге шигърияттә һич кенә дә кризис юк! Тормышта кризис бар, Рәсәйнең сәясәтендә кризис бар. Әмма безнең татар әдәбиятында һәм бигрәк тә поэзиясендә андый хәлнең булганы юк. Бик күп тавыш куптарган «Шигъри бушлык» исемле мәкаләдә дә, байтак шагыйрьләрнең көпшәк әсәрләре телгә алынуга карамастан, хәтта торгынлык елларына карата да андый нәтиҗә ясалмаган иде! Ә биредә Р.Зәйдулла соңгы елларны «поэтик кризис чоры» дип атамакчы! Моның дөрес түгеллегенә ышану өчен «Казан утлары»нда басылган шигырь тәлгәшләрен һәм «Ватаным Татарстан» алып барган «Шигъри бәйге»не белү дә җитә... Кыскасы, байтак кимчелекләре булган хәлдә, татар поэзиясе барыбер әдәбиятның иң көчле тармагы ул! Бу — бәхәссез хакыйкать!

Рөстәм Сүлтинең без сүз алып барган бу китабында яшьлек рухы нык сизелә. Һәм ул рух менә мондый рәвештә дә күренеп ала:

Күк карынында яшен тыпырчына,
Туасы шул килә, күрәсең...
.....
Гомер — мизгел... Тик туасы килә
Яп-яшь яшен, яшә...
Һай, әрсез,
Мизгел гомере белән мең яшәгән
Имәннәрне итә гомерсез.

Кичерегез, беркемнең дә гомерен
Күпсенмимен...
Ләкин ян, имән.
Шушы дегет-төннең бер мизгеле
Көндә кушылганда
«Эх» димәм...

Биредә, имәннәр януын хуплауны күргәч, безнең матбугатта кырмыска оясын туздыруның зыяны турындагы бәхәс искә төшә. Т.Миңнуллин бер яшь шагыйрьне төзәткән иде. Ул чакны мин үзем дә өлкән әдип ягында булдым. Әмма менә хәзер, икенче бер яшь шагыйрьнең тегеңә аваздаш бүтән әсәре уңае белән, мондый фикер дә белдерәсе килә: «Яшьлек» дигән ташкын ул, күрәсең, яхшылык һәм гаделлек кысаларына, ярларына гына сыеп бетә алмый. «Файда» яисә «зыян» дигән кануннар яшь кешегә күп чагында ят тоела. Аның боларга баш иясе килми, баш бирәсе килми! Әле ул тәртә арасына кермәгән яшь тай бит! Шагыйрь бер дә юкка гына: «Яшиселәр килә, күрәсең!» — дими ич... Димәк, аның өчен һәм, гомумән, яшьләр өчен, яшәү процессы үзе мөһим, үзе кадерле! Ә инде «дөрес яшәү» — монысы инде соңрак!

Тормышның төрлелек белән матур булуын истә тотсак, без дә яшьлекнең байтак гөнаһларын кичерергә тиеш булырбыз...

Монысы шулай, ләкин менә яшь шагыйрь иҗатында мәхәббәт хисенең көтелгәннән азрак күләмдә булуын кичерергәме соң?! Сүз чыкканда, тагын бер гомумиләштерү ясала: ә бит бүтән яшь шагыйрьләрдә дә хәзер мәхәббәт тематикасы бик тә саекты! Куркыныч дәрәҗәдә саекты! Ә менә кызларыбызда бу агым, Ходайга шөкер, көчле. Алар поэзиясенең иң көчле ягы да әнә шулдыр әле — мәхәббәттер. Мәхәббәт бәхетләре һәм трагедияләредер.

Безнең кайбер шагыйрьләребез аларны әнә шул мәхәббәт шигырьләре өчен яратмыймы икән әллә? Алай дисәң — бу бит ясалма тормыш китереп чыгарырга маташу сыман! Тормыш мәхәббәткә нигезләнеп, табигый рәвештә һәм матур дәвам итә алганда, нигә әле салкын акылга гына таянган яңача «тормыш» уйлап чыгарып маташырга икән?!

«Мин — шигырьдән» дигән китапта, көчле мәхәббәт һәм аның трагедияләре хакында әсәрләрнең бик аз булуы автор тарафыннан исем итеп куелган сүзләргә бераз шик тә уята. Мәхәббәтсез шигърият була димени?!

Табигать турында да шундыйрак нәтиҗә ясарга туры килә. Яшь шагыйребез татар милләтенең «яшел бишеге»н бөтенләй диярлек күрми. Әллә аның табигатькә багышланган гүзәл әсәрләре булганмы? Алар бары тик бу китапка гына керми калганмы? Ай-һай, моңа ышануы кыен...

Туган табигатьтән аерылганлык һәм мәхәббәт темасының үтә сайлыгы — болар икесе дә бүгенге шигъриятнең бер үк авыруы. Дөресрәге, болар бер авыруның ике төрле исеме. Ә ул авыруның исеме:

табигыйлек, ихласлык, эчкерсезлек кимү... Иң олы кешелеклелек тә әнә шулар янәшәсендә генә. Югалып баручы шул асыл байлыклар, хәзинәләр янәшәсендә генә...

Яшь шагыйрьнең бу китабында «җырлап торган» шигырьләрнең азрак булуы, көтелгәннән кимрәк күренүе дә, әлеге дә баягы табигыйлек, гармония, шигърият кимрәк булганга күрә. Замана бәласе!

Китапта урын алган зур күләмле әсәрләрдән «Кый-гак-к!» дигән балладаның һәм «Тәрәзә» дигән поэманың уңышлы чыгуын әйтергә кирәк. Р.Сүлтинең эпик жанрда эшләү сәләте зуррак дигән нәтиҗә ясарга да мөмкин. Бу юнәлештә аңа кыюрак иҗат итәргә кирәктер.

Соңгы сүз дип нәрсә әйтергә?

Әйе, безнең алда замана шагыйре үзенең бөтен кимчелеге һәм яхшы яклары белән — ул менә шундый. Рөстәм Сүлтинең шигырьгә, иҗатка җаваплы каравы күренә. Хәтта артыграк җаваплы карап, ул үзенең беркатлы һәм иң саф, иң садә хис-кичерешләрен йөгәнләмиме дә икән әле?! Кайвакыт шундый тойгы да туып куя. Әдәбият ул — күңел дөньясы, анда бернинди дә чикләү, курку һәм үз-үзеңне тыю булмаска тиеш! Безнең чорда көчле акылның тыюы — бигрәк тә начар! Хисләрнең табигый ташкыны гына булырга тиеш шигырьдә!

Әнә шул чагында ерактагы яшеннәр безне җылыта торган утка әверелер. Әнә шул вакыт шигырь үзе дә җылырак һәм моңлырак булыр...

2001

Бергәлек бәхете

Авылда үткән безнең гүзәл балачакның җәйге җылы кичләреннән берсе иде. Без — өч-дүрт малай — үзебезнең Урта урам белән Иш буе урамын тоташтыручы ямь-яшел чирәмле киң генә тыкрыкта уйнап йөрибез... Инде көтүләр дә кайткан, анда-санда адашып калган мал-туар да эзләп табылган, абзарга алып кайтып ябылган... Шәһәрләрдән бик тә ерактагы безнең авылга ипләп кенә илаһи бер кичке тынлык, моңсулык иңеп килә...

Менә шундый кабатланмас татлы тойгылар уята торган минутларның берсендә безнең колакка акрын гына агылучы моңлы җыр авазы ишетелеп китте. Әйе, әйе, ялгышмадык кебек — ул җыру авазы безнең укытучыбыз Юныс абый ихатасыннан ишетелә иде.

Бала-чага кызыксынуы, бала-чага түземсезлеге безне шунда ук аларның өр-яңа тәбәнәк рәшәткәсе янына китереп бастырды һәм без шундый күренешкә тап булдык.

Юныс абый үз өйләренең бакча як тәрәзәсен киереп торып ачып куйган да, җайлап кына тәрәзә төбенә менеп утырган һәм... тыенкы гына, урамга ишетелер-ишетелмәслек итеп кенә җыру суза. Ялгызы гына моңланып утыра.

Юк, балачак хәтеренә бик озакка сеңгән бу кичне Юныс абый җырлаган җырның сүзләре дә истә калмаган, аның нинди көй сузганын да белмим. Ул чагында без, бала-чаганы иң гажәпләндергәне: өйрәтеп, белем һәм тәрбия биреп, авылда зур абруйга ия булып яшәгән укытучыбызның үзенең әнә шулай ихлас хискә чумып, тирән кичерешләр кочагында онытылуы иде... Авылның ул чагындагы гадирәк, кырысрак тормышын гына күреп үскән бала-чага өчен бу яңа да, сәер дә һәм серле дә күренеш иде.

Әйе, без инде моңа кадәр дә Юныс абыйның язучы икәнен белә идек, аның төннәрен мунчада ялгызы утырып пьесалар язуы турында да өлкәннәр авызыннан ишеткәнебез бар иде һәм без моңа бик сәерсенә дә идек. «Шунда үзе язганнарны үзе артист булып уйнап та карый икән» дигән сүзләр инде безнең колакларны бигрәк тә торгыза, бигрәк тә хәтергә сеңеп кала иде... Аннары Юныс абый турында: «Аның язган пьесаларын куярга куркалар икән, син нимес әсирлегендә булган кеше бит, дип әйтәләр икән!» — кебек сүзләр дә йөреп алды... Шуннан соң тагын бераздан авылда: «Юныс абый Мәскәүнең үзенә барган икән, бер бик зур кеше янына кергән дә ул аның пьесаларын куярга, ниһаять, рөхсәт биргән икән»,— дигән хәбәр дә таралды.

...Юныс абыйның Минзәлә театры белән иҗади дуслыгы илленче елларда башланды бугай. Безнең Баржы авылына ул театрның атаклы режиссеры Сабир ага Өметбаев еш кына килеп йөрде — күрәсең, алар, ике иҗатчы, сәхнә әсәрен бергәләп тагын да камилләштерә, шомарта, яхшырта иделәр... Авыл китапханәсеннән мин алып укыган пьеса китаплары эченнән кайчагында Сабир Өметбаевның Юныс абыйга җибәргән телеграммалары да килеп чыга иде әле. Күрәсең, аларны Юныс абый китап эчендә онытып калдырган булгандыр инде.

Ә инде авылга театр килеп, аның Юныс абый иҗат иткән «Язылмаган законнар» спектаклен куюы — бусы безнең Баржы авылы тарихында иң зур вакыйга булгандыр, мөгаен! Халык инде зур клубка шыгрым тулган, башланырга әле байтак кына вакыт калса да, анда шундый гадәти булмаган тынлык —

гүяки бөтен кеше менә-менә башланачак чын могҗизаны көтә! Үзебезнең авыл кешесе тудырган, ул китереп чыгарган могҗизаны!

Шулай шул: Юныс абый Әминов язган драмалар һәм комедияләр алар, чыннан да, могҗизага тиң әсәрләр! Менә хәзер инде алар ижат ителгәнгә дә илле еллап вакыт узды, ләкин шуңа да карамастан ул пьесаларга салынган тормыш көче һаман да тылсымлы бер чишмә сыман бәреп тора. Аның әсәрләре укыла да, карала да!

Юныс Әминовка зур дан китергән һәм 1957 елда Мәскәүдә уздырылган Татарстан әдәбияты-сәнгате декадасы вакытында гаять күтәренкелек белән күрсәтелгән «Язылмаган законнар»ны гына алыйк. Биредә бит авылның уңган егете Шәйхенур белән шулай ук чибәр, булган кыз Фәридәнең мәхәббәтләре һәм алар гаиләсенең язмышы гына түгел. Гәрчә, ныклап торып уйлаганда, 1948 елда языла башлап 1954 елда тәмамланган пьеса өчен бусы да зур казаныш түгелме соң әле?! Чөнки ул елларның югарыдан төшерелгән боерык-карарлары кешедән бары тик колларча хезмәт итүне генә көтә иде бит! Кешенең эш машинасы булуын, көн-төн эшли торган әнә шул машинада бер тыңлаучан шөрепкә әверелүен!

Ә биредә, бу әсәрдә, үзәккә әнә гаилә, мәхәббәт мәсьәләсе куелган! Әлбәттә, ул да эш кешеләренең мәхәббәте, аларның гаиләсе. Ләкин, икенче яктан алып карасак, эшләми торган зур шәхес гомумән була аламы соң әле ул?! Барыбыз да эшлибез, хезмәт итәбез ләбаса: игенче дә, эшче дә, журналист та, төн белән көнне алыштыра-алыштыра ижат итүче әдәбият-сәнгать әһелләре дә...

Бу пьесада механизатор Шәйхенурның — инде өйләнгән Шәйхенурның — авылга яңа килгән фельдшер кыз Назлыбикәгә күзе төшә. Әсәрдә бу эш бик тә мотивлаштырып бирелә: яңа фельдшерны болар үзләренә фатирга да керткәннәр — димәк, ул Шәйхенурның күз алдында йөри дигән сүз, икенчедән, Фәридә көндезләрен генә түгел, ә кичләрен дә колхоз эше диеп өйдән югала — йә идарә утырышына, йә җыелышка китә, йә бүтән бер мәшәкате чыгып тора аның...

Шулай итеп, драматург тамашачыны да, укучыны да тормышның реаль вакыйгалары, персонажларның конкрет адымнары аша уйландыра. Әнә шул уйлар алга таба куерачак вакыйгаларның оеткысы да булып тора.

Алдынгы да, чибәр дә Фәридә шулай итеп ялгызы кала. Әсәрдә аның хисләре, психологиясе гаять тирәннән ачыла: «Мин гарьләнүдән ут кебек кызышкан йөземне бәхетсезлектән калтыранган кулларым белән каплап, тын, караңгы урамнар буенча ялгызым киттем. Әткәйнең таныш капкасын ачып кердем. Баскычка мендем, ләкин ишек шакырга көчем җитмәде. Кире төштем. Шул вакыт кинәт күз алдыма кара дулкыннарын ярга бәреп аккан Иш елгасы килде. Аның төпсез упкыннары миңа яшьтән таныш бит. Капка тавышына гажәпләнгән әткәй үзе килеп чыкмаса, белмим...»

Тамашачы белән укучы менә шулай алдынгы һәм чибәр Фәридәне генә кызганып, аны гына яклап утырганда, яшен кебек ялтырап, Фәридәнең әтисе Фазыл сүзләре балкып китә:

«— Гаепнең Шәйхенурда гына булуы мөмкин түгел. Фәридәнең үзендә дә, бездә дә гаеп юкмы икән?.. Кызыбызны җиленә дә, давылына да сыгылмаслык нык итеп үстерә алмадыкмы әллә? Габдри кызы Сараны ал, юлдан язган адәм актыгын да кеше итте бит. Ә безнең кызыбыз авылның мактаулы егетен дә кулында тота алмады».

Күрәсезме, алдынгы колхозчы, идарә әгъзасы булган Фәридә турында аның әтисе нинди җитешсезлеген әйтә. Аның кеше, шәхес буларак йомшак ягын ачып сала. Фазыл абзыйның мондый акыллы сүзләре гүяки бер Фәридәгә генә түгел, ә бөтен бер җәмгыятькә һәм аерым кешеләргә сизелерлек тәэсир итүче әдәбият-сәнгать әсәрләренә дә карый иде. Аңлыйсыз булыр, сугыштан соңгы еллар идеологиясе өчен бу яңа күренеш, яңа омтылыш.

Әйе, әсәр ахырында без Шәйхенур белән Фәридәнең яңадан кушылачагына ышанабыз. Ләкин бусы да пьесада бик нечкә алым белән күрсәтелә. Персонажларның икесе дә балага таба ымсына, шуңа якыная. Димәк, зур сынау үткән яшьләр инде киләчәктә бәхетнең, бергәлекнең кадерен белерләр, дип уйлый күңел.

Юныс Әминов пьесаларының персонажлары — гади авыл кешеләре. Ләкин аларның тормышы кызыклы, мәгънәле. Драматургның жанр ягыннан «комедия» диеп куелган әсәрләрендә дә без сугыштан соңгы авылның йөзен, аның кешеләрен күрәбез. «Өти балак» комедиясенең вакыйгалары колхоз фермасында бара, ләкин шулай булса да, монда эш күренешләре түгел, ә кешеләрнең холык-фигыльләре, аларның үзара мөнәсәбәтләре, кызыклы сөйләшүләре хәтердә кала. Комедиянең төп героинясы Гөлүзә башта үзен-үзе дә карамый торган, шапшаграк һәм пырдымсызрак кыз итеп бирелә. Эшендә дә эленке-салынкы гына йөри ул, башкаларның алда баруына да исе китми аның. Әмма... Әмма көннәрнең берендә фермага яңа зоотехник, яшь, чибәр егет килә. Менә шунда инде безнең «өти балак»ның бөтен холык-фигыле үзгәрә: аның йөрәгенә мәхәббәт иңә!

Игътибар итегез — бу әсәрдә кешене югарыдан төшкән ниндидер үтә җитди карарлар, боерыклар түгел, ә аның үз йөрәгендә шытып чыккан мәхәббәт үзгәртә!

Билгеле, бу комедиядә сыер савучыларның җәйләүдәге тормышы байтак күрсәтелә, социалистик ярыш баруы да үзәктә тора. Ләкин эш кешеләрен күрсәтүне, аларның үзара ярышып хезмәт итүен тасвирлауны кем начар дип әйтә соң әле?! Эш эшләмәгән кеше бик сирәк ич инде ул! Ә инде эшләгәндә

ярыш килеп чыгу — бусы да бик табигый нәрсә... Димәк, бүгенге көн өчен дә биредә барысы да дөрес һәм табигый дигән сүз.

«Тамырлар» комедиясе исә бераз башкачарак. Анда кешеләрдәге «минеке» дигән тойгы белән «безнеке» дигән хис каршы куела. Белүебезчә, хәзер бездә бу мәсьәләгә карашлар бик үзгәрде. Ләкин... Ләкин, әйдәгез әле, әлеге проблеманың үзәгенәрәк төшеп карыйк. «Минеке» дигән хис нәрсә ул? «Безнеке» дигән тойгы ни ул?

Юныс Әминов комедиясендә яшьләр авылның горурлыгы булырдай алма бакчасы утырту нияте белән янып-көеп йөриләр, ә Гапсаттар абзый белән аның карчыгы исә үзләренә мунча салу уе белән жәнләнгән. Комедиянең асылын менә шушы каршылык тәшкил итә. Бик тә озын гомерле, хәтта безнең көннәргә үк килеп ялганган проблема бу. Бөтен ил, дәүләт байлыгын үзләштереп бетерергә теләүче бүгенге түрәләр дә бик әйбәт гәүдәләнә ич монда! Алар да бит үз ояларына ташу, үз-үзләрен генә кайгырту дигәндә, бөтен оятларын, чик-чаманы оныталар. Барча халык, бөтен җәмгыять тик алар өчен генә эшләргә тиеш дип уйлыйлар алар. Тәмам комсызланып бетәләр — ил, халык алдында көлкегә калуларын да уйлый алмас хәлгә төшәләр. Әсәрдәге мүк җыям дия-дия сазга баткан Хәерниса — әнә шундый мескен адәмнәрнең җыелма тибы булып гәүдәләнә. Ул, көлке тип булса да, бик масштаблы образ булып чыккан.

Әлеге идея драматургның «Умырзая чәчәкләре» дигән эпик драмасында тагын да калкурак күтәрелә. Билгеле, авторның бу әсәргә булган кереш сүзендә драманы Совет хакимиятен урнаштыру өчен көрәшүче каһарманнарга багышлавын белдерүе әсәрне бераз берьяклырак аңлауга да урын калдыра. Драма урыны-урыны белән Шамил Усмановның кайсыбер әсәрләре шикелле артык «кызылланып» та куя кебек. Ләкин ул әсәрләргә мөнәсәбәттә без объективлыктан читләшмәскәрәк тырышсак иде. Ачыграк әйтсәк: егерменче гасыр башында илне һәм халыкны изә-изә, талый-талый шушы фаҗигале хәлләр килеп чыгуга сәбәпче булганнар икән — димәк, Рәсәй патшасы һәм, гомумән, байлар, хакимнәр катламы фәрештә кебек изге булмаган инде алар! Әнә ич бүгенгеләр дә халыкны, илне талауда, ерткычлыкта чик-чаманы искә алмыйча, вакыйгалар агышын шул якка таба борып җибәрергә маташа. Аз гына алгарак карый алмыйча! Үз янәшәсендәге адәмнәрнең ничек авырдан яшәүләрен аңлый алмаганга күрә — әхлакый һәм сәяси яктан «күрә карау» булганга күрә!

Менә драматургның тагын бер әсәре — алтмышынчы еллар ахырында язылган «Гөлҗәннәтнең җәннәте». Автор аның жанрын психологик драма дип билгеләгән. Ә нинди драма турында сүз бара соң?

Колхоз рәисе Лотфулла үзеннән күпкә яшь булган кызга өйләнә. Үзе чынлап та яраткач, яшь хатынны бүләкләр белән сөендереп торгач, ул бәхетле булырбыз дип уйлый, шуңа өметләнә. Баштарак кыз үзе дә моңа ышана, өйләренә зур бәхетнең килүен көтә. Әмма бу тормыштагы кайсыбер нәрсәләргә тырышлык һәм көч кую белән генә, зур акча белән генә ирешеп булмый бугай шул... Психологик драма бездә әнә шундый характердагы тирән уйлар уйлата, җитди фикерләргә алып кереп китә.

Ул елларда хезмәт темасына язылган бик күп әсәрләрдән аермалы буларак, биредә Юныс Әминов бүген дә актуаль яңгырый торган социаль-әхлакый проблеманы иң үзәккә китереп куя. Ягъни ир белән хатынның гаилә бәхете нәрсәдән гыйбарәт? Гаиләдә бәхетле булу өчен бер якның яратуы гына җитәме? Матди байлык мул булу тормышның бүтән җитешсезлекләрен онытыра, каплый, яшерә аламы?

Менә шушындый сорауларга җавап табу өчен драматург әсәрдә күрше яшәгән тагын бер гаиләне — Гайсә белән Мөслимәне — тамашачы күз алдына китереп бастыра. Аларның да тормышы майлаган кебек кенә бармый, җитмәсә, әле башта балалары да булмыйчарак тора...

Күрәсез, драматург ситуациянең чынлап та җитдиен кора. Анда уңай чишелешкә ирешү өчен кешеләрнең үзләренең тырышлыклары гына да җитми кебек, язмыш дигән «кырыс бабай»ның катнашуы да шәйләнеп ала... Менә болар барысы да әсәрнең мәгънә тирәнлеген, тәэсир көчен арттыра, Юныс Әминов драматургиясенең колачын киңәйтә. Ә тулаем алып караганда, бу — чынбарлыктагы җанлы, тере кешегә якынаю, аның күңел төпкелләренә эчкәрәк үтеп керергә тырышу, катлаулы рухи-эмоциональ тормыш белән яшәүче замандаш йөрәгенең чын һәм ихлас юлдашы булырга омтылу иде. Бөтен татар драматургиясе өчен дә мактаулы адым, дөрес юнәлештә хәрәкәт итү билгесе иде.

Әйе, драматург Юныс Әминовның илленче, алтмышынчы һәм җитмешенче елларда язылган драма һәм комедияләрендә социаль мотивлар бик көчле чагыла. Бу, бер яктан, шул чорда хөкем сөргән коммунистик идеаллар тәэсире белән аңлатылса, икенче яктан карасаң, авторның үзенең дә кешелек карашлары бик тә гуманистик, бик тә кешелекле иде. Гади генә итеп әйткәндә, кешеләрнең матур яши алуын, аларның бәхетен дә ул бары тик бергәлектә, бердәмлектә генә күрә иде. Югарыда күреп узган бүтән юлларны, социаль тигезсезлекне аның иманы кабул итә алмады.

Шул уңайдан 1963 елда безнең Баржы авылында булып узган бер тетрәндергеч вакыйга искә төшә.

Бик тә эссе килгән май ае иде ул. Әле мәктәптә укулар да тәмамланмаган иде, безнең, сигезенче сыйныф балаларының, нәкъ менә дәрестә утырган вакыты иде. Кинәт елганың аргы як урамыннан «ут бар!» дигән дәһшәтле тавыш ишетелде. Без әлеге куркыныч сүзнең мәгънәсен аңышу белән, сыйныф бүлмәсенең ачык тәрәзәләреннән тиз генә урамга коелыштык та, шомлы аваз килгән якка чаптык. Килеп җитсәк — бер өйне ялкын инде тоташ ялмап алган, күршедәге икенче өйнең түбәсе дә инде янып

ята. Бездән алдарак җитешкәннәр әнә шул өйдән әйберләр чыгарыша. Озак уйлап тормыйча, без, малайлар да, шуларга булыша башладык. Ут эссесе битләрне, колакларны пешерә — куе төтен тынны буа, күзгә каплана. Аның бит әле ул чагында юньле су сиптергечләре дә юк! Ә коры кул белән генә андый дулап котырынган ут стихиясенә каршы нәрсә эшли аласың соң?! Кыскасы, ул көнне безнең авылның сигез хуҗалыгы янып бетте. Бик зур афәт килде.

Әнә шул кайгылы көннең кичен үк, Юныс ага үзе янган кешеләр янына килеп, аларга акчалата ярдәм күрсәтәчәген әйткән. Һәм ул сүзендә торган да.

Хәер, Юныс аганың бик тә ярдәмчел, кешелекле икәнлеген мин үз гаиләбез мисалында да раслый алам. Торып яткан өебез искергәч, безнең алга йортны яңарту мәсьәләсе килеп басты. Әмма бит моңа бик күп акча кирәк. Ә ул чагында гади колхозчыда андый акча каян булсын?! Бары тик «хезмәт көненә» генә эшләп... Әнә шундый авыр чагында безнең әти-әни ярдәм сорап шулай ук Юныс абыйга мөрәҗәгать итте. Ул, ике дә уйламыйча, безнең гаиләгә бурычка зур гына суммада акча биреп торды.

Әйе, озак еллар буена Әгерҗе төбәгенең Баржы урта мәктәбендә балалар укыткан драматург Юныс ага Әминовның әнә шундый яхшылыклары санап кына бетерерлек түгел. Ул әдип буларак кына түгел, ә кеше буларак та үрнәк биреп — якты күңел, киң күңел белән яшәде.

Менә хәзер Юныс ага Әминовның 80 еллыгы уңаеннан аның иҗатын, аның яшәү рәвешен күз алдыннан үткәрәм дә аны бүгенге татар язучыларының яшәеше белән чагыштырып карыйм. Кешелеклелек, ярдәмчеллек ягыннан нишләп соң бүгенгеләр бик тә калыша икән? Ярый, хөрмәтле Гариф ага Ахунов улы Рәшит белән бергәләп иҗади яктан да, башка мәсьәләләрдә дә бик күпләргә ярдәм итте. Аны шулай дип хөрмәтләп искә алалар да. Мәрхүм Фәрваз абый Миңнуллин да бары тик әдәбият мәнфәгате белән генә яшәде — шуңа күрә гадел һәм кешелекле булды... Бүген исәннәрдән Туфан ага Миңнуллинның укучы балалар өчен махсус стипендия булдыруын да ишетеп бик сөендек. Рәхмәт аңа!

Әмма бүгенге иҗатчылар арасында ни өчен бүтән иманны кыйбла итүчеләр күбәя бара соң? Алар үзләре тормыш авырлыгын күрмичә үскәнгәме? Гаиләсендә дә кечкенәдән үк әрләп кебек үз ояңа ташу галәмәте генә күреп, шуңа өйрәнеп үскәнгәме? Бәләкәйдән үк бүтәнчә тәрбия алмагангамы? Яки иҗатны бары тик сүзләр белән генә эш итү дип, тел бистәсе булу дип, тар мәгънәдә генә аңлагангамы? Һәрбер зур иҗатның бары тик Зур Яшәү җимеше генә була алганын белеп бетермәгәнгәме?

Бүген, татар милләтен бергә туплау, бер максатлар тирәсенә җыйнау үтә актуаль бурычка әверелгән чагында, халыкның рухи юлбашчыларыннан аеруча зур җаваплылык сорала лабаса!

...Менә авыл урамыннан ашыкмыйча гына бер ир-ат атлый. Ул уртача буйлы, уйчан-сабыр йөзле, күзлек кигән... Бигүк күрсәтмәскә тырышып, тәмәке дә пыскыта, ахрысы...

Бу — Юныс ага Әминовның, көне буена мәктәптә балалар укытканнан соң арып-талып, өенә кайтып баруы. Аның юлы көн саен безнең тыкрык каршыннан үтә. Шуңа күрә мин аның күзенә күренергә кыймыйчарак кына, әмма бик тә зур кызыксыну белән аны карап, озатып калам.

Менә хәзер, бу еллардан соң инде бик күп сулар аккач, Юныс ага үзе дә мәңгелек дөньяга күчкәч, ул чакларны искә төшереп, уйлап утырам.

Көне буена мәктәптә бала-чага белән мәш килгәннән соң, тагын төннәр буена утырып, менә дигән драма әсәрләре язарга каян көч тапты икән Юныс ага? Күрше авыл Баржы-Умгада туып үскән классик әдип Тажи Гыйззәт үрнәге аны иҗатка дәртләндереп, авырлыкларны җиңәргә рухландырып торганмы? Әллә үзебезнең авылда туып үсеп ерак Казакъстан якларына юл алган һәм соңрак шулай ук аларның классигына әверелгән (хәзер аңа Алма-Атада һәйкәл тора), легендар тормыш кичергән Сабир Шәрипов мисалы маяк булганмы аңа? Кызганыч, ул үзе исән чагында, мин аңардан боларның берсе турында да сорап кала алмадым.

...Авырып, Казан хастаханәләренең берсендә ятканда, без аның янына шагыйрь Әхмәт Рәшит белән бергә барган идек. Әллә ничек, әллә яшьлегебез белән шунда, әллә шулай тиеш диеп уйлап, аңа чәчәк тә алып килгән идек. Ә ул исә без алып килгән ул чәчәкләрне шундук хастаханәдә эшләүче кызларга бирде...

Мин шаһит булган менә шушы күренеш тагын бер мәртәбә Юныс аганың холкын, табигатен ачып сала. Әйе, ул кешеләр өчен дип яшәде — тормышны, дөньяны бизәп, анда якты нур булып яшәде!

2001

Туксанынчы еллар әдәбияты

«Туксанынчы еллар» дип, вакытны шактый ук анык куйдык, әлбәттә. Ләкин бөтен Җир шарындагы кешелек җәмгыяте менә-менә 2000 ел бусагасын атлап керәм дип дулкынланып торган чагында, күңел-

нең һич кенә дә соңгы унъеллык белән генә чикләнәсе килми шул! Бигрәк тә зур биеклек, ничәмә-ничә буыннар үз хыялында, уенда йөрткән һәм бик тә тирән символик мәгънәгә ия булган гаять кызыклы бер фәлсәфи үр дә бит әле ул — 2000 ел. Шуңа күрә, яңа меңьеллык биләмәләренә аяк басканчы, башта үзебезнең артта калган юлыбызга күз салып аласы килә. Иң ким, иң аз дигәндә дә, үтеп баручы менә шушы егерменче гасыр турында гына булса да, бер гомумирәк фикер, нәтиҗә чыгарасы килә.

Гасыр башында татар милли матбугаты тууның әдәбиятыбыз үсеше өчен көчле этәргеч, бәрәкәтле нигез булуын инде барыбыз да белә. Ләкин биредә, менә шушы бик тә таныш хакыйкатьне искә төшерү белән бергә, без бүгенге көнебез өчен үтә мөһим булган бер закончалыкны ассызыклап үтәргә дә онытмаска тиешбез. Аны тиешенчә аңлап, хәтеребезгә сеңдереп китәргә кирәк. Ул чагында — гасыр башланган елларда — бездә чын мәгънәсендә ирекле матбугат булу, төрле юнәлештәге ирекле басмалар тирәсенә шулай ук төрле рухтагы, төрле караштагы шәхесләр туплану һәм аларның чын-чынлап үз сүзләрен әйтеп, үз фикерләрен белдереп яшәүләре турында искәртергә телим мин. Чын, ихлас иҗади атмосфера булу, үзеңнең йөрәк сүзеңне әйтүгә, шуны халыкка җиткерүгә мөмкинлек бирүче сәламәт мохит булу хакында. Менә шушындый хәл — гәрчә, матди яктан алып караганда, иҗатчы шәхесләр үзләре әллә ни шәп яши алмасалар да, иҗатны, әдәбиятны бик тә алга этәргән, югары күтәргән.

Егерменче гасыр башының әнә шул иреген без бүген үзебезгә үрнәк итеп куярга тиештер. Чөнки әле хәзергә безнең чыннан да ирекле булган милли матбугатыбыз юк. Басмаларыбызның барысы да хөкүмәт кулында. Аларга җитәкчеләр дә шул ук бер хөкүмәт, бер кешеләр тарафыннан билгеләнеп куела. Шулай икән, димәк, инде чын ирек турында бернинди сүз була алмый. Димәк, бүген безнең белән янәшәдә яшәгән бик кызыклы һәм талантлы шәхесләрнең ялкынланып, ышанып язган, ләкин югарыдан куелган кысага сыймаган байтак кына язмалары, әдәби әсәрләре дөньяга чыга алмый, халыкка барып ирешә алмый кала дигән сүз. Димәк, әдәбият тулы кан белән яши алмый дигән сүз.

Без бүген гасыр башында пәйда булган Тукайларның, Әмирханнарның, Исхакыйларның бөеклегенә, вулкандай рухи көченә сокланабыз икән — алар, иң беренче чиратта, әнә шул ирекле матбугат тудырган титаник фигуралар! Иҗатта бары тик гаделлекне генә, ихлас йөрәк сүзен генә алга кую аларны чыннан да зур, чыннан да бөек шәхесләр итеп үстергән.

Аларның бер-берсе белән ихластан бәхәсләшүләре дә үзләренең үк рухи һәм фикри яктан үсүләренә ярдәм иткән. Бу нәрсә иҗтимагый аң өчен дә файдалы, кирәкле күренеш булган. Чөнки җәмгыятьне борчыган мәсьәләләр төрле яктан яктыртылган, төрле аспектта каралган һәм өйрәнелгән.

Һәм тагын бер мөһим фактор. Янәшәдә икенче бер көчле иҗатчы яшәү, аның карашлары матбугатта чыгып тору бүтән иҗатчыларны да ирексездән диярлек эчтән кыздырып, эчтән дәртләндереп, аны иҗади актив, «кайнар» хәлдә тота. Кызыклы һәм бик үзенчәлекле яңа әдәби әсәрләр туу өчен менә дигән стимул була ул!

Егерменче гасыр башында безнең әдәбиятыбыз узган менә шушы якты үр турында уйланган чагында, без әлеге олы хакыйкатьне һич тә истән чыгармасак иде. Чын иҗат, зур иҗат, тирән иҗат өчен аның никадәр кирәкле, мөһим булуын онытмасак иде.

Әйе, үткән юлларда үзебез очрашкан күренешләр безнең киләчәк тормышыбыз өчен кирәкле сабакны да, гыйбрәтне дә, үрнәкне дә мул бирә. Бары тик аларга игътибар итү генә кирәк.

Тарихка «совет чоры» дигән исем белән кереп калачак чор да җитди уйлануларга этәрә. Бу еллар турында уйланган чагында да, кайбер кызыклы закончалыклар һәм алдагы көндә кирәк булырдай мөһим рухи ориентирлар ачыклана.

Әйе, ил белән Сталин идарә иткән чорны алмаганда, «совет дәвере» дип аталган бу елларда да безнең әдәбиятыбыз бик күп гүзәл әсәрләр тудырды. Каты цензура булу еш кына үтә алмаслык киртә, каршылык китереп куйса да, совет чорында актив иҗат иткән һәм хәзер дә сокланып укырдай әдәби әсәрләр язган бик күп әдипләребез бар безнең. Минемчә, бусы — бәхәссез хакыйкать, барыбызга да билгеле нәрсә. Ләкин биредә дә менә шушы бәхәссез хакыйкатьнең төбенә төшәргә, аның нигезендә ни яткан ын аңлап үтәргә онытмыйк әле.

Ил башында торган хакимият үз җәмгыятенең рухи-әхлакый сәламәтлеге турында нык кайгыртырга тиеш һәм, әнә шул эшне башкаручы мөһим көч буларак, әдәбиятны үстерү турында да борчылырга, кирәкле чаралар күрергә тиеш! Әгәр дә без сүз алып барган совет чоры татар әдәбиятына бихисап күп иҗади шәхесләр биргән икән — бу, иң беренче чиратта, әдәбиятка әнә шундый җитди мөнәсәбәт булуның матур җимеше диеп каралырга тиешле күренеш. Күп кенә совет җитәкчеләре авызыннан: «Каләм ияләре алар — партиянең алтын фонды», «Каләм ияләре — безнең уң кулыбыз» дигән сүзләр әйтелгән икән, бу чыннан да шулай иде бит. Халыкның да, җитәкчеләрнең дә әдипләргә мөнәсәбәте яхшы иде. Җәмгыять аларны тиешенчә зурлый һәм алардан кеше җаныңың инженерлары буларак тиешле рухи-әхлакый кимәлдәге әдәби әсәрләр көтә иде.

Язучы кеше менә шушы таләпне, ихтыяҗны сизеп, иҗатка, эшкә дәртләнә иде. Хәтта ул елларда телдән төшмәгән «коммунизм төзүченең әхлак кодексы» да һич кенә дә начар нәрсә түгел иде бит ул, егетләр! Җәмгыятьне тазартуга, көчәйтүгә, кешеләрне матуррак күңелгә ия итәргә теләп эшләнгән

чара иде бит болар. Әлеге кодексның изге Коръән белән уртак урыннары күп булу турында инде әйтеп тә торасы юк!

Ул чорда иҗади мохитнең үтә җанлы булуы, яңа әсәрләр хакында матбугатта да, язучыларның җыелышларында да фикер алышулар бару, бер-береңнең язганы белән ихлас кызыксынып яшәү — шулай ук кешедәге иҗатка дәртне арттыра иде ич.

Моны, бәлки, кайберәүләр «үткән этап» дип әйтер, ул хакта инде хәзер сөйләшү файдасыз диярге теләр. Ләкин әгәр дә без барыбыз да шулай эшләү тулаем җәмгыять өчен кирәк, файдалы дип саныйбыз икән — әгәр дә халык үзе шуны дөрес дип таба икән — ул чагында без, ягъни халык, сайлап куйган хакимият ни өчен халык таләбен үтәмәскә тиеш соң?! Ил таләбе, җәмгыять таләбе шундый булса, андый эш, һичшиксез, эшләнергә тиеш бит инде ул!

Әйе, совет чоры татар әдәбиятында без бик тә югары бәяләргә тиеш әдипләр бар. Әмма арадан берсен минем аерып күрсәтәсем килә. Бу — Әмирхан Еники иҗаты. Үзенең чагыштырмача кыска күләмле әсәрләре белән безнең әдәбиятыбызны сәнгати һәм фәлсәфи яктан бөтендөнья әдәбияты биеклегенә күтәргән әдип ул! Әлегә әдипнең әсәрләрен чын мәгънәсендә үзләренә тәңгәл дәрәҗәдә тәрҗемә итә алмавыбыз аркасында безнең бу олуг әдибебезне башка халыклар бөтенләй белми диярлек. Ләкин килер бер чор: Әмирхан Еники әсәрләренә аның үзе сыман зур талантка ия тәрҗемәчеләр алыныр, алар, күңел күзләрен киң итеп ачып карап, бу әсәрләрдәге бихисап зур рухи хәзинәләрне күрерләр һәм ул энҗеләрне түкми-чәчми, бар булган эстетик-рухи куәтендә, башка халыкларның әдәбият сөючеләренә дә илтеп җиткерерләр. Бу — безнең татар халкының, татар әдәбиятының зур тантанасы булыр.

Әмма биредә тагын бер мәсьәлә бар. Әмирхан Еники кебек «хакимияткә карата мәңге оппозициядә» торучы әдипнең совет чорында ничек уңышлы иҗат итә алуы уйландыра. Күңелдән әнә шундый хикмәтле сорау китми. Ничек алай була алды соң ул?

Әйе, Еники социаль чыгышы белән дә, тоткан мәсләге белән дә һич кенә дә советча түгел иде. Ләкин аның чын милли әдип булуы һәм, минемчә, барыннан да бигрәк югары профессиональ дәрәҗәдә иҗат итүче әдип булуы, холкының да сабыр-тыйнаклыгы һәм чыдам-түземлелеге — менә шул сыйфатлар аңа совет чорында да уңышлы иҗат итә алу мөмкинлеге бирде. Үз әсәрләрендә халыкның, җәмгыятьнең рухи-әхлакый сафлыгы мәсьәләсен күтәрүе дә аның эшен бөтен ил, димәк, ул чактагы партия эше, партия юлы белән бер юнәлештә итә иде. Бу кеше чыгышы һәм тәртибе белән коммунистларча булмаса да — аның эше, аның иҗаты, киң мәгънәсендә алганда, һичшиксез, әйбәт мәгънәсендәге коммунистларча иде. Пычранмаган һәм кешелек бәхете турында ихлас борчылып яшәгән большевикларча иде бу иҗат.

Әйе, ныклап торып уйланган чагында, без үз әдәбиятыбызның башкалардан һич кенә дә ким булмавын күрербез. Ләкин шул ук вакытта иҗат ителгән байтак кына әсәрләргә карата үзебезнең игътибарыбыз җитмәвен дә беләбез. Мисал өчен бер генә язучыбызны алыйк. Арчада яшәп иҗат итүче прозаик Радик Фәизовны. Инде ничә еллар буена актив иҗат белән шөгыльләнеп, менә дигән әсәрләр тудырган кеше ул! Җитмешенче елларда аның «Әбигә кунакка» исемле кечкенә генә бер хикәясе турында мин махсус мәкалә язып, аны «Социалистик Татарстан» газетасында бастырган идем. Моннан соң да Радик абый бик күп матур хикәяләр, повестьлар иҗат итте. 1995 елның гыйнвар санында «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Телсез» дигән хикәясе аеруча уңышлы чыккан иде аның. Нинди тирән мәгънә, нинди нечкә психология, нинди көчле хисләр бит бу әсәрдә! Үзе бер гүзәл симфония сыман кабул ителә торган чын сәнгать әсәре ул! Бер укыган кеше һич кенә дә оныта торган түгел. Бу әдипнең «Тәңре хөкеме» повестен да мин бик уңышлы әсәрләр рәтенә кертер идем. Бер безнең халык өчен генә түгел, ә бөтен кешелек җәмгыятенә кирәкле, мөһим идея күтәрелә бу фантастик повестьта. Хәзерге ситуациядә — Җир шарындагы кешелек җәмгыяте үзенең алдагы юлы тупикка терәлгәнен һаман ныграк аңлый барган драматик елларда — татар язучысының кешелеккә бер альтернатив юл тәкъдим итүе зур мәгънәгә ия булган фәлсәфи һәм эстетик күренеш. Менә хәзер, уңышлы тәрҗемә ителеп дөнья күләмендә таратылган тәкъдирдә, бу әсәр, һичшиксез, зур яңгыраш алыр иде.

Әйе, әнә шундый зур фәлсәфи идеягә корылган әсәрләр бөтен халыклар өчен дә кызыклы була. Мисал өчен, сиксәненче елларда болгар язучысы Павел Веженовның «Барьер» дигән повесте дөнья күләмендә киң яңгыраш алган иде. Аның эчтәлеге, идеясе әле һаман да истә тора. Бәхетебезгә күрә, андый онытылмый торган һәм бик тә үзенчәлекле әсәрләр үзебездә дә бар бит алар! Шул ук сиксәненче елларда «Казан утлары» журналы Фәүзия Бәйрәмованың «Күл балыгы» дигән ифрат кызыклы кечерәк кенә повестен бастырды. Тирән һәм оригиналь фәлсәфәгә ия булган, шул идеясе әсәрдә уңышлы сәнгати гәүдәләнеш тапкан менә шушы повестька безнең игътибарыбыз тиешенчә булмады. Хәтта бөтенләй дикъкат тә ителмәде кебек бу гүзәл әсәргә! Ә бит менә шушы әсәргә нигезләнеп менә дигән бер балет та иҗат итәргә мөмкин иде безнең композиторларыбызга! Мәсәлән, балет-феерия! Күз алдыма килә: нинди гүзәл музыка, нинди соклангыч күренешләр, нинди кызыклы эчтәлек килеп чыгар иде бу әсәрдә!

Менә шундый уфтанырлык хәлләрне уйлагач: «Нишләп соң без үзебездә булган рухи-эстетик байлыкны күрә, аны тиешенчә бәяли алмыйбыз?!» — дигән әрнеткеч сүзләр дә телгә килә. Без соң әллә кайчагында чын әдәбиятның ни икәнен, нинди икәнен аңлап җитмибезме?!

Әнә шундый — бүтән төр сәнгать әсәрләре тудырырга да җирлек, нигез була алырдай әсәрләрдән тагын берсе — Флүс Латыйфиның «Хыянәт» романы. Моннан күп еллар элек укылса да, ул, бер кызыклы кино сыман булып, һаман күз алдында тора, андагы персонажлар укучының хәтерендә бүген дә яшәп яталар. Әгәр дә алынучы булса, менә дигән нәфис фильм килеп чыгар иде бит бу әсәрдән! Мәхәббәте дә, тарихы да, әхлагы да, мажарасы да — без күрергә теләгән бөтенесе дә шунда ич аның!

Ә шигърият өлкәсенә күз салсак, ул «күз генә тимәсен» диярлек хәлдә, минемчә. Соңгы елларда бигрәк тә Лена Шагыйрьҗанның ижади уңышлары сөендерә. Никадәр кайнар хис, безнең йөрәк кичерешләренә дә бик аваздаш булган тирән социаль һәм әхлакый мәгънә аның ялкынлы, кайнар шигырьләрендә! Аның әсәрләре сине шуның хәтле көчле кичерешләргә сала ки, хәтта бер шигырен укып чыккач, кинәт кенә бүтәненә күчү мөмкин дә түгел. Ирексездән, үзеннән-үзе озак тотып, синең бар күңелеңне, җаныңны, рухыңны биләп, тотып тора аның һәр басылган әсәре! Үз каләмдәшләре алдында ясаган чыгышлары һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән Лена Шагыйрьҗан ижаттагы эстетик казанышларын, үзенең поэтик югарылыгын, дәрәҗәсен тагын да ныгыта, күтәрә.

Бүгенге драматургия турында төрле фикерләр ишетелә. Ләкин анда аксакалларыбызның да уңышлы ижат итүе, күпсанлы яшьләр дә булу — бусы бәхәссез нәрсә бит! Соңгы елларда сәхнә күргән әсәрләрдән миңа Туфан Миңнуллинның режиссер Фәрит Бикчәнтәев тарафыннан Г.Камал театрында куелган «Җанкисәккәем» спектакле гаять тә көчле тәэсир иткән иде. Ул спектакльне караган кич минем өчен чып-чын бәйрәмгә әверелде! Олы бәйрәмгә! Ләкин андый тантаналар сирәгрәк була шул бездә... Хәзер эш, нигездә, режиссерларга килеп терәлә сыман. Безнең мәдәниятебезнең әнә шул баскычы нык ук түгел кебек бүген. Милли драматургияне яңа дәрәҗәгә күтәрү өчен, хәзер безгә көчле яңа режиссерлар җитми сыман. Эш әнә шунда шикелле...

Соңгы елларда, ягъни сүз бара торган туксанынчы елларда, безнең әдипләребез үзләрен иреклерәк хис итеп яза башлады. Ләкин бу әле шулай да тоткын иреге белән чагыштырып караганда гына зуррак тоела торган тойгы. Без бүген әле барыбыз да кичә генә тоткынлыктан котылган коллар хәлендә. Әле безнең рухыбыз, күңелебез, дөньяны аңлавыбыз һәм кабул итүебез, шушы зур һәм иркен дөньяда үзүзебезне күрүебез һәм тотуыбыз — болар барысы да әле безнең һаман кичәге колларча килеп чыга. Үпкәләштән, гаеп итештән булмасын, чыннан да әнә шулай безнең хәлләребез!

Аңлаешлырак булсын өчен икенче төрлерәк итеп әйтсәк, безнең эчтә, безнең күңелдә, безнең җанда ниндидер тар кыса яшәү була инде бу, ягъни мәсәлән. Элек андый кысаны «партия куя, партия таләп итә» дия идек. Ә хәзер, чагыштырмача ирекле яшәгән чагында, каян һәм ничек килеп туа соң ул эчке кыса дигән нәрсә?

Әйе, бер караганда, адәм баласы тулысынча ирекле була да алмый инде ул. Чөнки һәрбер адәми затны тудырып үстергән ата-ана, гаилә бар. Шулар кебек үк кадерле булган туган халкы, милләте бар. Аннары тагын һәркемнең туган җире, туган иле була... Болар, билгеле, безнең рухны, безнең йөрәкләрне кечкенәдән үк үз «биләвенә» били. Аның кайсыдыр җепләре бөтенләй үк гомер буена өзә дә алмастай була. Андый җепләрнең ныклыгы — бары тик яхшы күренеш кенә.

Ләкин әнә шуңа да карамастан мин биредә барыбер язучы күңеле югарырак кимәлдә яши алырга тиеш дип исәплим. Шулай дип уйлыйм. Ни өчен?

Чөнки, Аллага шөкер, безнең күз алдыбызда Җир Йөзе дип йөртелгән гүзәл Дөнья, соклангыч бер Яшәеш бар. Әнә шул гүзәл Яшәешнең чиксез күптөрле чагылышы, балкышы, бәхете, тәме, ләззәте, рәхәтлеге бар! Бу дөньяга яратылган җан иясе, адәм баласы татырга тиешле Олы Бәхет бар! Безнең яңа әдәбиятыбыз хәзерге адәм баласына әнә шул кадерле тойгыларны тоярга ярдәм итсен, аны бәхетле яшәргә өйрәтсен иде. Аңа Җир Йөзендә чын-чыннан бәхетле, ирекле Кеше булып яшәргә ярдәм итсен, аны әнә шундый зат итеп үстерсен, тәрбияләсен иде! Югыйсә безнең әдәбиятыбыз үзе дә күп чагында «эш аты»на охшап кала. Юк, мин, болай дигән чагында, хезмәт, эш турында язуны гына кертмим. Киңрәк мәгънәдә алам мин бу сүзне — әдәбияттә гел дә проблемалар белән генә, гел шуларны чишү турында баш ватып кына яшәү, димәк, гел эш белән тулган яшәү турында әйтергә телим мин. Яшәү дигән бәхетне әдәбиятта бары тик эшләүгә генә кайтарып калдыру хакында әйтергә телим. Бары тик шуңа гына өндәүче, шундый кеше тәрбияләргә, үстерергә теләүче әдәбият турында минем сүзем.

Без, бигрәк тә әдәби тәнкыйть тирәсендә кайнашучылар, әдәби әсәрләргә зур-зур таләпләр куярга бик тә ашыгабыз. Әйткәнемчә, элек ул таләпләр күбрәк очракта югарыдан төшә иде. Ә хәзер менә «миллилек» дигән бик әйбәт идея дә кайчагында ниндидер бер тарлык, кысанлык тудыра сыман. Безнең кайсыбер тәнкыйтьчеләребез, әдәби әсәргә карата артык дөрес таләпләр куеп, аның күп бизәклелеген, кызыклыгын, аның тормыш һәм яшәү чынлыгына тугрылыгын — димәк, укучыны тарту көчен, эстетик күренеш буларак тулы канлылыгын киметергә телиләр кебек. Моны үзләре дә аңышмастан! Бу инде, баланы тәрбияле итәм диеп, аның шәхес һәм кеше буларак мөстәкыйльлеген санга сукмау сыманрак аңлашыла. Әдәбиятка карата элеккеге партия диктаты кебек кабул ителә. Шуңа күрә әдәбиятка куелган андый артык җитди, артык сәяси таләпләрне күңел кабул итми. Кемнеңдер карьеристик омтылышы сыманрак аңлашыла мондый адымнар. Чираттагы конъюнктура шикелле кабул ителә.

Алдагы еллар әдәбиятын киңрәк колачлы һәм кызыклырак, сәнгати яктан камилрәк итеп, артык натуралистик күренешләрдән азат итеп, укыган кешегә тәэсире көчле булырдай итеп күрәсе килә. Телевидение белән көндәшлек әдәбиятта тагын да зуррак үзгәрешләр китереп чыгарачак. Проза әсәрләренең күләме бик нык кимер дип уйлыйм. Димәк, аларның фәлсәфи һәм эстетик көче артырга тиештер...

Чын әдәби әсәр ул яңа заман кешесенең дөньяны иңләгән фәнни-техник процесстан арыган-алҗыган җанына шифалы яңгыр сыман яварга тиештер... Әдәбиятның, кеше күңеленең төп юлыннан читкә таба өстерәүче төрле-төрле экспериментлар, яңа «изм»нар да яңа гасыр әдәбиятында азрак булыр сыман тоела. Чөнки аларның байтагы экспериментлар гасыры булган егерменче гасырда инде үзләренең озак яшәү көченә ия түгел икәнлеген күрсәтте. Тулаем кешелек җәмгыяте үзе барыр өчен иң чын, иң ышанычлы, иң ныклы һәм перспективалы юлны табып алырга бик тә, бик тә теләгән сыман, әдәбият-сәнгать дөньясында да кешелек чын, табигый, дөрес нигездәге әсәрләрне генә кабул итәр шикелле тоела. Ихлас кешелек хисләренә, кызыклы язмышларга, йөрәкләрне кузгатырдай кичерешләргә ия булган әсәрләрне генә.

Озын сүзнең кыскасы: алдыбызда торган яңа гасырда заман кешесенең күңеленә үтеп керә алу өчен язучыга үз эшенең чын остасы булырга туры киләчәк. Аннан чын профессиональлек соралачак, таләп ителәчәк.

1998

Мулла абзый китап яза

Кемгә ничектер, әмма соңгы араларда минем үземә традицион алым белән язылган реалистик проза әсәрләре торган саен якынрак, кадерлерәк, тансыграк була бара... Мөгаен, бу хис, мондый тойгы бер миңа гына хас түгелдер дип уйлыйм. Соңгы елларда тулаем яшәешебездә дә әнә шуңа якын теләк — Олы Чынлыкны сагыну хисе көчәя бара кебек. Җәмгыятьтә кискен һәм зур үзгәрешләр күбәйгән саен, күңел үзе өчен ышанычлырак нигез булган тотрыклылыкны ныграк юксына, тели бара. Үткән егерменче гасырның башыннан алып бүгенгәчә дәвам иткән социаль һәм сәяси тәҗрибәләр, революцияләр кешене инде тәмам туйдырды кебек.

Ә бүген безнең күңелләр теләгән ул тотрыклылык кайда микән соң?

Минемчә, безне тудырып үстергән табигатьтә, туган җиребездә ул! Әнә шул бердәнбер ышанычлы нигезнең, бәрәкәтле туфракның бетмәс җегәре, мәңге яшәүчән көче хәзерге шәһәрләр һәм алар тудырган тормыш белән чагыштырып караганда бигрәк тә ачык күренә.

Рәсәй дигән илдә килеп чыккан зур үзгәрешләрнең җанга якыннары бик аз булу да, бу илдә һәм дөньяда «күсәк сәясәте»нең беренче урынга чыгуы да, җәмгыятьтә гаделсезлек, ачлык, ялангачлык көчәю дә, илдәге зур-зур җитәкчеләрнең халык, милләт мәнфәгатьләреннән бигрәк иң башта үз кесәләре турында кайгыртуы һәм бу юнәлештә көннән-көн ныграк азына баруы да — болар барысы да безгә якын үткәнебездәге гуманистик идеалларны искә төшерә.

Күңел тансыклаган әнә шундый кешелекле идеалларны, әнә шундый яшәешне табарга теләп, без бүген әдәбиятка һәм анда да күбрәк өлкән буын каләм ияләре ижатына мөрәҗәгать итәбез.

Ә ни өчен нәкъ менә алар ижатына?

Чөнки өлкән буын ижатчыларның күбесе кечкенәдән үк авыл тормышының, авыл табигатенең гармониясен үзенең җанына, күңеленә, рухына сеңдереп үскән... Менә мондый шәхеснең эчке дөньясы, аның үзенең кем икәнлеге, нинди икәнлеге ул язган әсәрне укыган чагында шундук сизелә бит аның. Аннары тагын шунысы да бар: өлкән буын каләм ияләре озак яшәү дәверендә үз күзләре белән бик күп гыйбрәтле һәм тетрәндергеч вакыйгалар күргәннәр, шулар белән нык тәэсирләнгәннәр — аларның хәтерендә онытылмаслык һәм үзенчәлекле бик күп язмышлар яши... Мондый ижатчы инде язарга утырса, кайсыбер яшьләр сыман, сиңа үзенең күргән киносын яисә укыган китабын гына сөйләми. Ул инде сиңа олы чынбарлык хәлләрен бәян итә!

Алтмыш-җитмеш яшьлек әнә шундый прозаикларыбызның һәр язган әсәрен диярлек кызыксынып һәм сокланып укып барам: Фоат Садриевныкын, Радик Фәизовныкын, Зәки Зәйнуллинныкын...

Соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында берничә проза җыентыгы чыгарган Габдулла ага Галиевне дә, һичшиксез, әнә шулар янәшәсенә язарга тиешбездер. Аның «Хәзрәт малайлары» дигән китабы моңа саллы гына дәлил булып тора.

Китапка уртача күләмдәге өч повесть һәм тугыз хикәя кергән. Повестьларның исемнәре мондый: «Сандугач», «Үкенү», «Терсәк якын да бит...» Ә шулай да сүзебезне китапка исем биргән хикәядән — «Хәзрәт малайлары»ннан башлап китик әле. Бу хикәягә һәм тулаем китапка ни өчен шундый сәеррәк исем кушылган икән соң? Әллә инде бу замана агымына бер иярү генәме?

Хәер, замана агымына ияръ генә түгел икәнлеген Габдулла ага Галиевнең үзенең Әгерҗе төбәгендә инде менә күп еллар буе фельдшер булып эшләве һәм хәзер Кырынды авылында мулла вазифасын башкаруы ук әйтеп тора. Боларның һәр икесе дә кеше турында, аның физик һәм рухи сәламәтлеге хакында иң ныk кайгырту таләп итә торган изге вазифа бит. Димәк, кешенең бөтен тормышы, тулы язмышы дигән сүз.

Ә инде бу китаптагы «Хәзрәт малайлары» дигән хикәяне укыгач, без моңа тагын бер мәртәбә ышанабыз.

Сугыш алды еллары. Миншәех хәзрәт белән Мәрьям остабикә икесе дә вафат булган да, аларның ундүрт һәм унбер яшьлек малайлары авылда үзләре генә яшәп, көн күреп яталар. «Хәзрәтнең каралты-курасы буп-буш, сыер мөгрәгән, сарык бәэлдәгән, тавык кытаклаган тавыш та юк. Абзарларның каерылып ачылып калган ишекләреннән җилләр генә сызгырып тора. Терлекләрнең барысын да сәвит алып колхозга тапшырган. Әмма шушы йортта яшәп ятучы ике ятимне авыл халкы онытмый. Аталарының исән чакта игелекле хезмәте күп булды диеп, мич ашын, хәер-сәдакасын китерештереп тора. Әмма ул ярдәм белән генә җан асравы җиңел түгел шул аларга».

Юк, бу ятим балалар үзләре дә кул кушырып утырмыйлар анысы. Олырагы, бер торбага зурайткыч пыяла көйләп, төсле рәсемнәрдән кино күрсәтә башлый... Аннары, скрипкада уйнарга өйрәнеп, авыл балаларына концерт куя... Боларның барысы да бер-ике телем ипи, бәрәңге бәрабәренә... Тамак ялына!

Әмма көннәрдән бер көнне ятимнәрнең хәле тәмам авыраеп китә, алар бөтенләй ач кала. Шунда күрше малае Хәкимҗан керә дә болай ди:

— Кичә Минһаҗ абзый бер капчык он тартып кайтты. Келәтләренә кертеп куйганын үз күзләрем белән күрдем... Онның берәр потын чәпәргә кирәк!

Бу тәкъдимне хәзрәт малае баштарак аңламый, төшенми тора... Аннары аны умачлы аш бераз кызыктырып та ала... Ул инде менә ничә көн энесе белән бергә ач тора бит!

Ләкин шулай да хәзрәт малаеның Хәкимҗанга биргән җавабы менә мондый була:

«Ходай кушканы булыр... Телем ачылган көннән алып атам белән анам мине Аллаһыдан, кеше хакына кагылудан куркырга өйрәттеләр... Юк, угрылык кыла алмыйм мин! Ул эштән соң ничек Аллаһы каршына барырмын? Авылым халкы күзенә ни йөзем белән күренермен? Атам-Анам рухы алдында ни дип җавап бирермен? Юк, Хәкимҗан, юк — йөз кат юк! Мин ул эшкә бара алмыйм!»

Хикәя героеның менә шушы — көчле рух балкыган сүзләрен укыган кеше инде шуннан соң китапка ни өчен мондый исем куелуга аптырап тормый. Әйе, бу сүзләр безнең чор кешеләре өчен дөрес яшәү юнәлеше күрсәтердәй якты маяк шикелле.

«Атам-Анам рухы... Авыл халкы... Аллаһы каршына...»

Бу сүзләрдә безнең җәмгыятебез рухи нигез итеп алырга тиешле асыл мәгънә дә чагыла — якты рухлы һәм ныклы иман да. Ә инде бүген без бу юлның капма-каршысын сайлыйбыз һәм шул юлдан китәбез икән — ул чагында әйләнә-тирәдәге, җәмгыятьтәге хәзерге каршылыклар тагын да тирәнәя барачак, кеше кешегә бүре булып күренә башлаячак дигән сүз — без бүре законы буенча яши башлаячакбыз дигән сүз! Бу юл — Рәсәй иле инде ничә мәртәбә кичергән сыйнфый бәрелешләр, революцияләр юлы дигән сүз!

Ләкин шунысы бар: әлеге сыйнфый бәрелешләргә алып килми торган, менә бу хикәядә хәзрәт малае әйткән бердәнбер гадел юлны сайларга бүген безнең җәмгыятьнең көче җитәрме? Гаделлек һәм татулык хакына үз нәфесләрен, үз амбицияләрен тыя алучылар күпме бүген?

«Хәзрәт малайлары» дигән кечкенә генә күләмле бер хикәя әнә шуларның һәммәсе турында да уйлата, фикер кузгата.

Әнә шундый актуаль һәм җитди эчтәлек салынган әлеге хикәядә әдәби-сәнгати яктан караганда әллә ни зур яңалык бар дип әйтеп булмый. Хәтта аның исеме астына «булган хәл» дигән сүзне язып куярга да мөмкиндер сыман. Ләкин шулай да бу — примитивлыкка алып килгән гадилек түгел. Бу — чын тормышның үзендәге кебек — бөеклекнең гадилектә чагылышы. Олуг әдип һәм фикер иясе Лев Толстой бер дә юкка гына: «Килер шундый заман — әдипләр бары тик булган хәлләрне генә яза башлар-лар»,— дигән алтын сүзләрне әйтмәгәндер! Чынбарлыкның теләсә кайсы бөек язучыга караганда да көчлерәк, бөегрәк иҗатчы булып торуын тану дигән сүз бу!

Габдулла ага Галиев тә, үз әсәрләрен язганда, иң элек үзе күргән яисә ишеткән реаль вакыйгаларга таяна, чынбарлыкның Лев Толстой әйткән бөек иҗади көченә ышанып, шуңа ияреп бара.

«Хәзрәт малайлары» дигән бу китапта өч повесть бар, дидек. Алар укучыга нинди эчтәлек сөйли һәм алар әдәби әсәр буларак нинди сыйфатларга ия соң?

Китапка кергән өч повестька да хас булган иң беренче билге — алар бик тә мавыктыргыч һәм тыгыз сюжетка ия. Вакыйгалар кызыклы кинодагы сыман синең күз алдыңнан бер-бер артлы агыла тора һәм син алардан аерыла алмыйсың. «Сандугач»та безнең күз алдыннан немецларга әсир төшкән Абдулла абзыйның аянычлы язмышы үтә. Концлагерьдан ул ничә генә мәртәбә качмый, немец овчаркалары аны талап үтерә яза... Соңгы качуыннан соң, аны тоталар да, үз-үзенә кабер казытып, шунда ук атарга да җыеналар.

«...ышанасыңмы, энекәш, миңа әнә шул тетрәндергеч минутта кинәт илһам килде. Башымны югары күтәрдем дә, бар көчемә сандугач булып сайрый башладым. Яшел аландагы тынлыкны ярып сайраган сандугач тавышы фашистларны бер мәлгә өнсез калдырды. Немец офицерының атарга команда бирергә күтәрелгән кулы һавада асылынып калды... Ә мин, бөтен осталыгымны җигеп, өздерә-өздерә сайрадым да сайрадым. Бу минем газиз туган илем белән, сөйгәнем Гөлчирә белән хушлашуым иде. Бу минем якты кояшым белән, җиһан белән хушлашуым иде».

Әнә шундый таланты Абдулланы үлемнән коткара — немец офицеры бу «сандугач»ка яшәү бүләк итә... Ә качуын барыбер кача ул әсирлектән. Сандугач читлектә яши аламыни соң?!

«Үкенеч» повесте исә шул ук сугыш чорында авылда ачлы-туклы яшәп ятучы яшүсмер балалар турында. Шуның өстәвенә әле, җитмәсә, ягарга утыннары да юк... «Ике яшүсмернең күз ачкысыз буранда ерактагы урманга барып, көч-хәл белән исән кайтулары биредә тетрәндергеч кичерешләр аша тасвир ителә. Ә шулай да иң үзәккә үткәне — ачлык... ачлык... Ул явыз халыкны көн дә, төн дә газаплый, тилмертә. Әсәрнең бу битләрен укыганда, күздән яшьләр килә.

Көннәрдән берсендә авылга сөенечле хәбәр кайта: күрше авылдагы сепаратордан бераз эремчек һәм әйрән бирергә тиешләр, ике ат белән шуны барып алырга кирәк!

Көтелмәгән әлеге «күчтәнәч»не алырга Зиннәт дигән абзый белән яшүсмер Рафик китә. Әмма кайткан чагында, боларга ике кеше очрый, аркаларындагы биштәрдә спиртлары да бар... Һәм шул чагында Рафикның юлдашы, Зиннәт, спиртка кызыгып, авылның ачларына дигән эремчекне бүлеп бирә... Рафик та ныклап каршы тора алмый, чөнки башта аның үзенә спиртны авыз иттерә теге явызлар... Ә авылда исә ачлыктан берәм-берәм кешеләр кырыла. Рафикның яратып йөргән кызы да, ачлыкка тилмереп, күзләрен мәңгелеккә йома... Малай йөрәгендә шулай итеп мәңгелек яра кала: ул үзен бик нык гаепле саный!

«Терсәк якын да бит...» дип исемләнгән өченче повесть та җитди проблемага багышланган: анда Мансур белән Аннаның яшь чагындагы мәхәббәте һәм олыгайгач ике милләт вәкилләре арасында килеп туа торган четерекле хәлләр ышандырырлык, дулкынландырырлык итеп тасвирлана. Егерменче гасыр башындагы милли идеологыбыз Гаяз Исхакыйның шушыңа охшаш сюжетка корылган «Ул әле өйләнмәгән иде» дигән хикәясе бар, биредә исә без проблеманың бүгенге яшәеше белән очрашабыз: ике милләтле гаиләдә балаларга нинди исем кушу, аларны чукындыру-чукындырмау, картаеп үлгәч, нинди зыяратка күмелү...

Күреп үткәнебезчә, Габдулла ага Галиев үз әсәрләрендә замана куйган сорауларның иң-иң җитдиләренә мөрәҗәгать итә һәм аларга тормыш ягыннан да, сәнгатьчәлек таләпләреннән чыгып караганда да ышандырырлык җаваплар бирә. Аның фикер сөрешенә без дә ышанып барабыз.

Баштагы ике повесть уңаеннан, бәлки, кайсыберәүләр: «Һаман шул сугыш хәлләре, ачлык, ятимлек күренешләре...» — дип йөз чөерергә дә теләр. Бездә шундый артык «эстет»лар — дөнья агышына исе китмичә, бары тик кәгазьдәге хәрефне һәм җөмләне генә күрүчеләр бар бит әле.

Бу уңайдан андыйларга болай диясе килә:

— Ә сез илдә чын сугыш барганын оныттыгызмыни? Инде ничә ел сугыш бара бит... Ә ятимнәргә килсәк: бүгенге көндә Россиядә официаль рәвештә белдерелгән 3 миллион ятим бала бар икән! Ачлык белән ялангачлыкны, җинаятьчелекне инде әйткән дә юк! Болары белән адым саен очрашып торабыз!

Моннан чыгып шуны әйтәсе килә: димәк, Габдулла ага Галиевнең без югарыда телгә алган әсәрләре алар нәкъ менә бүгенге мәсьәләләр, бүгенге кешеләр хакында! Аларны бары тик аңлый белергә, күңел күзен ачыбрак карый алырга кирәк!

Инде яңадан хикәяләргә әйләнеп кайтсак, бу китапта алар тугыз кисәк. Тугызында да, әлбәттә, авыл тормышы — кош-корт, мал-туар белән бәйле яшәеш. Ләкин шулай да атлар аерым урын алып тора. Биредә хәтта «Атлар да елыйлар икән» дигән хикәя дә бар. Сугыш чоры малайлары Гали белән Рәсим илле чакрымдагы нефтебазадан авылга керосин алып кайтырга тиешләр. Хәлсез, ябык, ач атлар белән. Җитмәсә, өстән яңгыр коя — салкын, җилле яңгыр. «Ат кузгалды кузгалуын, әмма аның атлавында һич тә рәт-чират юк, аяклары йомшак тирән кардан чаңгы тагып барган кебек сөйрәләләр иде». Бераздан Галинең аты тәмам туктап кала — аның алга барыр хәле дә юк инде. Һәм аптыраган-йөдәгән малайлар, инде бүтән ни эшләргә дә белмичә, үзләре тәртә арасына кереп басалар, көч-хәл белән кузгалып та китәләр... Ә арбада дәү-дәү мичкәләр... Юл пычрак.

Ике тәүлек буе яңгыр астында йөргән ач-ялангач әнә шул малайларны колхоз рәисе мондый сүзләр белән каршы ала:

— Нәкәнис кайттыгызмыни?! Нигә тагын берне кунмадыгыз?!

Язучы Габдулла ага Галиев тасвирлаган менә шушы күренеш озакка күз алдында кала. Ач-ялангач балалар һәм чыбыркылы явыз түрә... Андый адәм әлеге ач, хәлсез балалар хәтерендә Гитлерга караганда да әшәкерәк булып кала торгандыр инде ул! Хәер, дөнья бүлү өчен сугыш башлаган Гитлер белән Сталин үзләре дә әнә шундый адәмнәр токымыннан бит инде алар!

Ә менә язучының «Хыялый мәхәббәт» дип аталган хикәясе гади җир кешеләренең күңел байлыгы, кешелек хисләренең тирәнлеге, садәлеге, көче турында сөйли. Буе кечерәк булганга күрә сугышка алынмаган Хәмәт дигән егет урманнан кузгалаклар, юалар алып чыгып, Рәсимәгә биргәч, кыз болай ди:

— Минем өчен ниләр генә эшләмисең инде син! Рәхмәт, Хәмәткәем! Ярый әле син бар бу дөньяда!

Бу сүзләрдән Хәмәт абыйның күзләрендә мөлаемлык тагын да арта төште, дулкынланудан бит очлары кызарды, кинәт бөтен гәүдәсе белән кызга таба тартылып куйды.

Җылы сүзнең, кешелекле мөнәсәбәтнең тылсымлы көчен язучы әнә ни рәвешле җиткерә! Озак еллар буе авыл фельдшеры булып эшләү һәм мулла вазифаларын башкару дәверендә Габдулла абыйга мондый очраклар белән бик күп очрашырга туры килгәндер шул! Үзенә ярдәм сорап килгән йөзләгән, меңләгән кешегә шәфкатьле мөнәсәбәтен, җылы сүзен һәм якты йөзен кызганмаган ул. Ә менә хәзер Габдулла ага кешеләр күңелен дәвалауны әдәби әсәрләр аша дәвам итә.

Табиб һәм мулла абзыйның әдәби осталыгы ни дәрәҗәдә соң?

«...атлар әкрен генә сөйрәлә, агач очлары арасыннан кичке алсу уклар белән бизәлгән күкнең сыек зәңгәрлеге күренеп китә. Тагын кич килеп җиттемени соң әле дигән төсле, юл буендагы агачлар безне боегып кына озатып кала...»

Сугыш чоры тормышының авырлыгы, төшенке, боек күңелләр, ачлык, хәлсезлек — Габдулла Галиев язган берничә юлда болар барысы да төсмерләнә, сизелә, күренә.

Менә икенче бер хикәядән өзек:

«Күккә күтәрелеп караган саен, малайларның йөрәкләре кысылып куя, болай да борчылудан алҗыган күңелләренә бу болытлар ташкынының азагы юктыр, алардан җир өстенә иңгән сыек караңгылык мәңгелектер, инде бервакытта да зәңгәр күк йөзе ачылмас, җирдәге тереклекне куандырып кояш та балкымас, кошлар да сайрамас кебек тоела. Кая карама — баш түбәсендә дә, аяк астында да — су. Табигатькә кушылып күз яшьләрен агыза-агыза, үксеп-үксеп елыйсы килә».

Китаптагы шушының ише җөмләләрдә әсәр геройларының эчке кичерешләре дә тирәннән һәм дулкынландыргыч итеп ачыла, шул ук вакытта укучы күңеленә көчле тәэсир дә ясала һәм аларда без авторның үзенең кем икәнлеген, нинди шәхес икәнлеген дә бик ачык тоемлыйбыз. Әйе, авыр чорның бөтен кыенлыгын үз җилкәсенә салган, ачлы-туклы гомер итүче сугыш чоры яшүсмерләре һәм агай-апалары авторга бик тә, бик тә якын һәм кадерле — чөнки алар арасында ул авыр елларда яшүсмер Габдулла үзе дә булган бит. Биредә сурәтләнгән вакыйгаларның бик күбесе аның үз башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләр бит!

Гадәттә дөньяны күп күргән, аның ачысын-төчесен мулдан татыган каләм ияләренең язганнары ныклы сюжетка, эзлекле вакыйгалар чылбырына корылган була. Габдулла ага Галиевнең бу китабындагы хикәя һәм повестьлар да әнә шундыйлар. Алар шуның белән нык оталар да. Ә гомумиләштереп карасак, бүген — үзенең янәшәсендә көне-төне телевидение эшләп ятканда — безнең әдәбият, бигрәк тә аның проза жанры, әсәрләрдә ныклы һәм мавыктыргыч сюжет җебе булуны төп һәм иң кирәкле таләпләрнең берсе итеп куярга тиештер, минемчә. Әнә шуннан башка безнең әсәрләр бүгенге укучының «азгын» күңелен биләп тора алмаячактыр.

Габдулла аганың әсәрләрендә бик тә күзгә ташлана торган тагын бер үзенчәлек бар. Аларда рухиәхлакый фон, аһәң әсәрнең тулаем матур агышына бер дә зыян китермичә генә, нәкъ менә тиешле микъдарда гына, тамып-тамып бара. Дөресрәге, аның әсәрләренең тулаем эчке һавасы, климаты әнә шундый: кешелекле, шәфкатьле, җылы. «Язган әсәре — авторның баласы кебек» дигән сүз бу очракта бигрәк тә туры килә. Бу каләм иясенең муллаларга һәм табибларга бигрәк тә хас була торган күркәм шәхси сыйфатлары әсәрләргә мулдан күчкән.

Мавыктыргыч сюжет корып һәм җитди эчтәлек сурәтләп, бүгенге укучыны үз эченә алып кереп китүче менә мондый әдәби әсәрләрнең кешегә тәэсир көче зур булуын тагын бер мәртәбә басым ясап әйтәсе килә. «Хәзрәт малайлары» китабында исә бүген безнең өчен аеруча мөһим булган милли һәм әхлакый тәрбия дәресләре бар. Мондагы әсәрләрнең һәммәсе укучыга менә дигән сабак бирә, аның күңелен аз гына булса да сафлык, гаделлек, кешелеклелек юлына якынайта.

Бу китапны укып чыккач ябып куясың да, тагын бер мәртәбә аның тышындагы төсле рәсемгә күз саласың. Ә анда авылга таба кайтып килүче җигүле ат сурәтләнгән... Алда мәчетле, матур, төзек татар авылы күренеп тора...

Эчтәге әсәрләрне укыганнан соң, әлеге рәсем бигрәк тә символик булып күренә башлый. Чыннан да, бу китап безне дә үзебезнең туган үскән нигезебез булган иманлы һәм денле татар авылына алып кайтты бит! Без, азга гына булса да, әнә шул мохитнең шифалы һавасын суладык, җегәр бирә торган туфрагына аяк бастык, чиста суларында юындык — эчкерсез кешеләре белән аралашып, үзебезгә яшәү дәрте, дәрман алдык.

Һәм күңелебез белән без әле һаман да әнә шунда яшәп ятабыз... Аннан һич кенә дә китәсе килми!

2004

Сатира батыры

Хәзерге татар язучысы иреклеме, түгелме?

Әйе, бер караганда ул, чыннан да, ирекле шикелле. Тулаем Рәсәйдәге сыман хәзер бездә дә үзең ни теләсәң, шуны язарга мөмкин кебек. Бастыру өчен дә матбугат шактый иркенәйде, газета-журналларның саны артты.

Ләкин болар — беренче карашка күзгә ташлана торган тышкы факторлар. Ә соң эчкәрәк кереп, ныклабрак уйланганда, эшләр ничегрәк тора?

Иң башта «үзең теләгәнне язу» дигәнгә тукталыйк әле. Безнең бүгенге татар язучысының теләк-омтылышлары нинди соң? Ә, гомумән, дүрт гасыр буена коллыкта һәм изелүдә яшәгән зат нинди була алсын соң инде ул?! Аның бүгенге рухи халәте дә Рәсәй империясе коллыгында ата-бабаларыныкыннан әллә ни нык аерылмый әле. Бүген дә «курку» дигән хис гаять күп кешеләр өчен хәлиткеч дәрәҗәдә мөһим булып кала бирә. Әнә шул хис идарә иткәнгә күрә, тормыш-көнкүрешләре дә тар кысада һәм колларча бара, уйлары һәм хис-кичерешләре дә әнә шул тар мохиттән ерак китә алмый. Көнен һәм төнен баш булган курку хисе уйларын да тышаулый, тезгенли, билгеле. Шулай булгач, хәзерге «үзең теләгәнне язу» дигән нәрсә дә озак еллар буе зоопаркта яшәгән филнең, ирекkә чыккач та, бер урында гына таптанып торуына тиң.

Инде хәзер «матбугатның иркенәюе» дигәнне аңларга тырышыйк. Әйе, Аллага шөкер, соңгы елларда басмалар саны шактый артты. Ләкин шуның артыннан ук биредә дә ике зур «дошман» пәйда булды. Бердән, басмалар бөтенләй диярлек каләм хакын түләми башлады — иҗатчы өчен матди кызыксыну бетте. Ә икенчедән, безнең бөтен басмалар да диярлек хөкүмәт акчасына яшәгәнлектән, үзеннән-үзе диярлек югарыда утырган чиновникларга бәйлелек килеп туа.

Менә боларның барысын да күздән кичерсәң, хәзерге татар язучысына иҗат ирегенең һәм басылу мөмкинлегенең бик тә аз калуын күрербез. Һәммәсен бергә кушып уйласаң, совет чорыннан әллә ни алга китеш тә юктыр әле, бәлки?!

Әнә шуңа күрә бүген безнең иҗат кешеләре арасында чын-чынлап ирекле булган, шуның белән иҗатта зур үзенчәлеккә ирешә алган әдипләребез күп түгел. Сирәк, бик сирәк алар!

Фәнзаман Баттал — әнә шул сирәкләр арасында да күзгә бәрелеп, үз иҗатына игътибарны әллә каян ук тартып торган иҗатчы.

Элегрәк аны шигырьләр язган, диләр... Үзгәртеп кору башлангач, матбугатта аның ялкынлы-ялкынлы мәкаләләре дә байтак кына булып алды. Һәр очракта аның белән килешмәсәк тә, ул язмалар тиз онытылмый иделәр. Күпләрдә ризасызлык, каршы хисләр тудыра иде кайберләре. Минемчә, алар Фәнзаман Батталның үзе өчен дә иҗаттагы төп юнәлеш түгел иде шикелле.

Бу иҗатчының иң төп юнәлеше — юмор һәм сатира. Әле аның «сатира» дигәне әйбәтрәк бирелә авторга. Моңа кадәр басыла килгән язмаларын һәм китапларын янәшә куеп, чагыштыра-чагыштыра уйланганда, ирексездән әнә шундый уйга килеп чыгасың.

Берничә ел элек Фәнзаман Батталның «Сакалыңа ут капса» исемле сатира-юмор җыентыгы басылып чыкты һәм бик тиз арада кибет киштәләрендә күренми дә башлады. Әлеге китап хакында матбугатта да, шулай ук аның каләмдәшләре арасында да бары тик җылы сүзләр генә ишетергә туры килде.

Инде менә 1995 елда бу авторның «Бака да бата» дигән кыска хикәяләр китабы дөнья күрде. Шуңа күрә бу уңайдан безгә сатирик иҗаты турында җентекләбрәк сөйләшергә, уйланырга җай бар.

«Бака да бата» (исеме генә ни тора!) китабын кулга алып, аның эчендәге сатирик һәм юмористик хикәяләрне (әле аларны автор шулай ук бик үзенчә итеп «хи-хикәяләр» дип атаган) укый башлагач, Фәнзаман Батталның дөньясын, бу мохитнең үзенә генә хас хикмәтләрен тагын да күбрәк күрәсең.

Китапны ачып җибәргән беренче ике әсәр болай дип аталган: «Азгын ирне ничек үтерергә?» һәм «Иптәш Сталин булсамы?» Җыентыкны кулына алган кеше мондый исемле әсәрләрне күргәч, ничек инде укымыйча калсын ди?! Хәзер безнең чорда телевидение белән китап арасында гаять зур көрәш, тартыш бара. Телевидение бүгенге кешегә сәгать саен кызыклыдан-кызыклырак тапшырулар тәкъдим итеп тора. Ул кешене хәзер тулаем яулап алып килә. Безнең замандашның телевизор карамый торган вакыты бик аз. Хәзер әнә шундый бик аз вакыт эчендә дә үзен укыта алырдай әсәрләр кирәк. Ә кызыклы булу исә әсәрләрнең исемнәреннән үк башлана.

Беренче хикәянең тәүге юлларында ук автор аз да түгел, күп тә түгел, менә болай дип белдерә: «Бик дөрес әйтәләр — азгын ирне, һичшиксез, үтерергә кирәк! Хатынына бер генә мәртәбә хыянәт иткән булса да, аның дөньяда яшәргә хакы юк». Әнә шулай көтелмәгән, без һич уйламаган киңәш-тәкъдимнәрне тезә генә сатирик: азгын ирне, тиз генә үлеп котылмаслык итеп, акрын-акрын үтерергә кирәк! «Монысы нәрсә икән тагын?» дип аптырап каласың да әсәрдән җавабын да табасың: тәмле ашата-ашата, өс-баш киемнәрен юа-юа, чиста итеп карап йөртә-йөртә — ир-атны әнә шулай итеп озак яшәтә-яшә-

тә «газаплау» ята икән бу хәйләнең төбендә! Фәнзаман Баттал хәзерге хатыннарга шундый киңәш бирә. Һәм, сатирик буларак, ул күп яктан ота, үз дигәненә ирешә.

Аннан соңгы хикәядә язучының иҗади үзенчәлеге аеруча калку булып чагыла. Ул әсәрнең иң беренче җөмләсе менә нинди: «Каяле, энем, тагын бер төреп җибәрик әле синекен!» Шулай дип сүз башлаган абзый үзенең әңгәмәдәшенә иптәш Сталин белән әшнә булуы турында бик тә мавыктыргыч итеп «борчак сибә». Имештер аны, Мәскәү заводында кәчигәр булып эшләгәндә, Сталин, үзе чакырып алып, йомыш кушкан!

Ярый, эчтәлеге калып торсын, без биредә Фәнзаман Батталның сатирик буларак үзенчәлеген табарга тырышыйк. Аның иҗади үзенчәлекләре нәрсәдә аеруча ачык күренә соң?

Авторның сатира угы түбәнгә таба гына түгел, югарыга таба да шундый ук кыюлык белән һәм шундый ук осталыкта оча. СССР һәм КПСС та, Сталин һәм Хрущев та, Ельцин һәм башкалар да эләгәләр сатирикның «агулы» теленә. Бүген байтак әдипләр һаман алны-артны карап кына язганда (коммунистлар хакимияткә кайтса, дигән куркудан) һәм баш саклауны иҗатта да төп кагыйдә итеп алганда, Ф.Батталның мондый иҗади кыюлыгы зур хуплауга лаек.

Алай гына да түгел: бүгенге заман тудырган бушбугазлык та китапта матур чагылыш таба. «Алланың кашка тәкәсе» дигән хикәядәге Иргали, мәсәлән, дөньяның иң зур кешеләрен сүгә, аларны хурлап газеталарга хатлар яза, алар басылып чыккач, Иргали «батыр, курыкмый» дигән дан ала. Тик менә үзенең директоры янында ул иң мескен кеше икән. «Директор турында яз, имеш. Син нәрсә?! Әллә башыма тай типкән дип белдеңме?»

Әнә шулай итеп, безнең чор тудырган күп персонажлар килеп керә сатирикның китабына. Хөкүмәт кулындагы оешма һәм предприятиеләрдә тир түгүче адәм балалары тамак хакына бүген нинди генә түбәнлекләргә бармыйлар да иҗатчылары юмор һәм сатираның мөмкинлекләрен ничек кенә арттырмыйлар! Курыкмыйча язучы һәм күңеле тар булмаган мөхәррир генә табылсын!

Фәнзаман Баттал язган вакытта укучыга тәэсир итүнең бик күптөрле ысулларыннан актив файдалана. Сүз сөрешендәге һич тә уйланмаган, көтелмәгән борылышлар дисеңме, өр-яңа гыйбарәләр һәм сүзтезмәләр дисеңме — болар барысы да әсәрләрдә бик оста кулланыла. Шул ук «Иптәш Сталин булсамы?» дигән хикәяне генә алсак та, анда «сакаллы бәрәңге», «тел белән торна мамыгы җәю», «сыер дагалау», «тилегә думбыра каккандай» һәм башка үткен гыйбарәләр тулып ята! «Мидәлә базарыннан алган кирза итегемне салидул белән майлап» дигән бер тезмә үзе генә дә ни тора!

Ә Сталинны менә ничек итеп сөйләтә оста сатирик: «Сезнең хакта заводской гәҗиттән укып беләм мин, иптәш Сәмигуллин. Партритыгызга да озак карап утырдым». «Ал, ал,— ди бу миңа төребкәсен.— Шикләнмә, мин чирле түгел, врачлар карап кына торалар». «Аптыраш инде, малай,— ди. Үзе бик моңсу итеп елмая, мәрхүм...»

Әйе, Фәнзаман Баттал иҗатта заманча эш итүе белән алдыра: ул кыска яза, әсәрнең сюжетын үтә дә динамик итеп төзи, җөмләләрдә укучыга нык тәэсир ясый алырдай, аның колагын торгызырдай һәм әнә шул юл белән уйландырырдай сүзләр-гыйбарәләр куллана. Аның әсәрләрен укыганда, үзеңне кино экраны янында «Безнең тормыш» дигән сатирик фильм карап утыргандай хис итәсең.

Арадан тагын бер хикәягә — «Никахлы мафия» дип исемләнгәненә күз салыйк. «Көпә-көндез хатынны урладылар... Эштән кайтсам, юк теге. Ике-өч сәгать сыраханә ларегы төбендә чират торып кайтсам, тагы юк. Йокларга яттым — һаман юк...»

Әсәр әнә шулай алып кереп китә үзенә. Менә бу беренче юллар үзләре үк инде оста сатирикның уйфикер буразнасына төшерә дә куя. «Урладылар» дигән сүзнең мәгънәсе белән «сыра ларегы янында чират тору», «йокларга яту»ларның мәгънәсе кара-каршы килеп, маңгайга-маңгай бәрелешә дә, безнең уйда иректән ачы итеп көлүнең беренче дулкыннарын кузгата... Сарказм белән көлүнең куәтле дулкыннарын тудыра!

Аннан ары килгән күренешләр исә беренче туган әлеге дулкыннарны яңадан-яңа биеклеккә күтәрә бара: төнен бик тә тыныч(!) йоклаган бу абзагыз янына иртән рэкетчы килеп, урланган хатынны кире кайтару шарты белән, аның өчен ирдән акча сорый. Шул вакытта инде бу абзагыз уйлый: «Яле, исәпләп карыйк: ничә сум тора икән минем хатын?.. Тәк-тәк... Йөзеге 500 сум, алкасы 200... Ну, күлмәге-мазары 300 сумдыр тагын, туктале, 1000 сумга гына җыела түгелме соң? Ә бу дивана (ягъни рэкетчы) биш мең сорап тора». Әнә шуларны җәһәт кенә уйлап өлгергән абзагыз рэкетчыга да болай ярып сала:

«Махмырга биш тәңкә бирсәң, тагын биш хатын табып җибәрәм үзеңә!»

Көтелмәгән, беркем дә уйламаган җавап бит, ә!

Гомумән, сатирик автор мондый көтелмәгән ысуллары белән рэкетчыларны гына түгел, әсәр укучыларның да башларын әйләндерә яза. Ул, оста күз буучы шикелле, тыгыз мәгънәле күренеш-эпизодларны күз алдында бик тә җитез рәвештә уйнатып кына тора. Рэкетчылар бу абзагызның явыз хатынныннан ничек котылырга белми азапланганда (чөнки хатын кулына автомат, авызына пычак кабып, туфли очы белән шартлаткыч кнопкасына басарга җыенып аларның котларын ала!), абзагыз килә дә аңа менә мондый сүзләр генә әйтә:

«Давай юләр сатма монда! Тамак ачты, кайтып ашарга пешер!

Хатыным җебеде дә төште. Авызындагы кинжалын төкереп ташлагач, елый-елый:

— Автоматымны кулдан ычкындырмыйм, Мысыргали,— ди».

Сатирик хикәянең бер персонажы авызыннан әйтелгән менә шушы сүзләр үзләрендәге психологик ачкыч белән, ярсыган хатын-кызны тиз генә җебетеп төшерә алырдай көчкә ия булулары белән әсәрне язган автор файдасына безнең күңелдә зур-зур «очколар» яздыра. Тулаем әсәр өчен дә «5»ле билгесе куймыйча булдыра алмыйбыз без аңа.

Әйе, Фәнзаман Баттал әсәргә бик кыю тотына һәм хикәяләүне ныклы кул белән, ахыргача оста итеп алып бара ала. Ә вакыт-вакыт шундый четерекле урыннар килеп чыга — автор өчен борчылып, икеләнеп-шикләнеп тә каласың. Мисал өчен, «Изге эш» хикәясендә укучы күңелендә шундыйрак бер психологик шок булып ала:

«Дөньяда иң изге нәрсә — басу! — диде Хәтмулла, кул аркасы белән баш түбәсен ышкый-ышкый...»

Ташка басылып чыккан китапта мондый сүзләрне укыган татар кешесенең хәлен чамалыйсыздыр. Аның уеннан ниләр генә узмый, бу әсәр авторына карата нинди генә сүзләр әйтеләм-әйтеләм дип тормый шул мизгелдә тел очында... Әмма Ф.Баттал, психологик трюклар ясый-ясый, тәки судан коры килеш килеп чыга ала бит! Чөнки ул әлеге четерекле теманы менә болай итеп төгәлли белә:

«Әйтик, игеннәр үсә торган басуны үзеңнең дә күргәнең бар. Ипекәй бит ул, юл-ләр, ипекәй!..»

Менә шушындый азакны укыгач, кем юләргә кала инде? Әлбәттә, без — автор турында эчтән генә әллә нинди «бозык» уйлар уйлап өлгергән кеше — жүләргә кала! Сатирикның зур сәләткә ия булуына менә дигән бер мисал бу психологик трюк. Шуңа охшашрак хәлне алда сүз барган хикәядә дә искә алган идек.

Әле алай гына да түгел: хикәя башында ук безнең башны әйләндереп алу һәм үзебезне үк көлкегә калдыру белән генә канәгатьләнми автор, ул хәйләкәр төлке сыман, эз чуалтып алга таба чаба һәм безне уйламаган-көтмәгән җирдән «ялган акча басу» дигән ачы, зәһәр көлке төбәгенә алып чыга. Хәзерге акчаның мескенлегеннән эчләрне тотарлык итеп көлдерә ул, Ленин башы урынына Хәлим Җәлал һәм Равил Шәрәфи, Батулла башларын куеп акча басучылар турында искиткеч мәзәк итеп сөйли. Акча басучылар өенә милиция дә килеп керә. Тик алар... азык талоны басучыларны эзли икән, акча басучыга исе дә китми хәзерге милициянең! Вәт заманнар! диеп, көлә-көлә саубуллашасың сатирикның бу әсәре белән дә.

Әнә шулай итеп, китап бүгенге тормыш күренешләреннән рәхәтләндереп көлдерә. Хәер, бик үк рәхәтләнеп көлү түгелдер бу. Яшь аралаш көлүдер бу! Җаның сыкрый-сыкрый, бәгырең телгәләнә-телгәләнә, әрни-әрни көлүдер бу... Чөнки бу китапка кергән бөтен хикәяләрне укыган чагында безнең күңел төбендә һаман бер уй, бер тойгы талпынып тора. «Их, нигә соң без шундый!» дигән ачыну катыш борчылу тойгысы ул. Көлү дигәнебез дә кешедән түгел, ә еш кына үзебездән һәм үзебез ишеләрдән көлү булып чыга анда. «Тормышыбыз шулай булгач, нишлисең инде» дияргә туры килә ахыр чиктә, тынычлану өчен...

Сүз барган китап турында тулы мәгълүмат булсын дисәк, шунысын да әйтми ярамас: биредә татарның хәзерге зыялылары хакында да кыска гына мәзәкләр кертелгән. Соңгы вакытта бездә бу жанр матур гына булып җанланып китте. Элегрәк Батулла шундый язмалар бастыра иде. Шамил Маннаповның газеталарда чыккан мәзәкләре милләтнең бүгенге мәдәни тормышына матур-матур бизәк булып чигелеп бара. Бу китаптагы кыска хикәяләре белән Фәнзаман Баттал да әдәби-мәдәни мохитнең үзенчәлекле елъязмасына үз өлешен кертергә булган.

Соңгы елларда әдәбиятның, мәдәниятнең хәлләре бик тә кыенлашканы һәммәбезгә мәгълүм. Әмма шуңа да карамастан татар әдәбияты һаман үз укучыларын сөендерүне дәвам итә. Фәнзаман Батталның менә бу яңа җыентыгы да безне куандыра торган китаплар рәтендә. Безгә әнә шундый гадел язучылар, чын күренешләрне тәэсирле итеп ачып салган әсәрләр бик тә кирәк. Намуслы һәм тырыш татарның тормышында кычкыра-кычкыра көләрдәй хәлләр бихисап күп ул! Бүгенге сатира безгә көлә-көлә яшәвебезне әзме-күпме төзәтергә булыша. Фәнзаман Баттал ише сатира батырлары тагын берничә генә булса да табылсын иде!

1996

Якты эз

Татар баласының өлешенә туры килә торган кара язмыш микән инде бу — Казан университетын тәмамлагач, мине дә Ерак Көнчыгышка «сөрделәр». Шунысы бик гажәп иде: миннән яшьрәк һәм әле гаи-

ләсе дә булмаган менә дигән егетләр Казанда калды, ә мине — гаиләсе һәм алты айлык яшь баласы булган, минус тугызлы калын күзлек киеп йөргән кешене тоттылар да офицер итеп алып киттеләр! Дусларымның: «Университетта яшь татар журналистларыннан «Яңаваз» берләшмәсе оештырып, анда укытучыларга баш бирмичә, әллә нинди үткен-үткен бәхәсләр үткәреп йөргәнең өчен бу сиңа»,— дигән сүзләренә ирексездән ышанырлык иде шул!

Ярый. Тын океан яры буендагы сопка араларында офицер шинеле киеп йөреп, ике ел гомер көч-хәл белән үтеп тә китте. Сагынып, җирсеп, атлыгып Казаныма кайттым. Ә анда кайтсам... Казан шәһәренең паспортлар бүлегендә утыручы бер зур гына түрә миңа:

— Ерак Көнчыгышны калдырып, ни өчен нәкъ менә безнең Казан шәһәренә кайтырга булдыгыз әле сез? — димәсенме!

Мин — офицер киемендә йөрсәм дә, җаным белән гел Казанга атлыгып яшәгән яшь татар журналисты — бу сүзләрне ишеткәч, ачудан нишләргә дә белмичә, бер мәлгә тораташ кебек катып калдым. Шушында укып, шушыннан киткән яшь татар журналистына әлеге бик сәер сүзләрне әйтсеннәр әле!

Хәзер инде бераз аңлыйм: рәсми яктан караганда, әлеге түрәнең миңа бәйләнер урыны да булган икән. Безнең Казанга кемнәр генә һәм каян гына килми бит! Җитмәсә әле, мине үзенең кысан фатирына сыендырырга теләгән журналист-сабакташым Габделбәр Ризвановның да торак мәйданы 11 генә кв. метр...

Казан каласы үзенә кабул итәргә теләмәгән менә шушындый бик тә кыен чакта миңа юрист-язучыбыз Мәгъсүм ага Насыйбуллин ярдәм итте. Тора-бара әдәби тәнкыйть өлкәсенә кереп китеп, язучылар һәм гомумән зыялылар белән киңрәк аралаша башлагач, мин аның әнә шундый авыр чакларда күп кешеләргә ярдәм иткәнлеген белдем...

Әйе, безнең арабызда Мәгъсүм ага Насыйбуллин исемле әнә шундый ярдәмчел юрист-язучы бар.

Аның күпсанлы китаплары татар укучысына үтә дә яхшы таныш. Мәгъсүм аганың китаплары ел саен үткәрелә торган бәйгеләрдә иң күп укыла торган булып чыга. Шуңа күрә китапханәләрдән аның китапларын таба алмыйсың, яисә инде алар кулдан-кулга йөри-йөри тузып, таушалып беткән була. Язучы кеше өчен гаять тә шатлыклы күренеш!

Дөрес, анысы бар: детектив әдәбият байтак кына халыкларда шулай ук күп укыла, яратып укыла. Биредә кеше психологиясенең үзенчәлеге дә үз сүзен әйтми калмый торгандыр инде, әлбәттә.

Әмма шулай да бу язучы әсәрләрен укыган вакытта күңелне җәлеп иткән башка уңай сыйфатлар да байтак күзгә ташлана.

Менә минем кулымда Татарстан китап нәшрияты 1985 елда бастырып чыгарган «Алтын алка» дигән җыентык. Аңа язучының «Телсез шаһитлар», «Яшерен касса», «Капкын» һәм «Алтын алка» дип исемләнгән дүрт хикәяте кергән. Сүз уңаеннан гына булса да шунысын искәртеп үтик: әлеге китапның тиражы 50000 данә. Бу инде безнең бик күп язучыларыбыз хыяллана торган зур тираж иде ул елларда!

Җыентыкка исем биргән хикәятне ачып, таныш әсәр битләре буйлап яңадан сәяхәт итәм, һәм шунысы сөенечле: кабат кайтып укыган чагында да биредә маҗара эзләп кенә бармыйсың, үз алдыңда әдәби әсәр икәнлегенә тагын бер мәртәбә төшенәсең. Әсәрдәге күп образлар, күренешләр сине әнә шуңа ышандыра.

«Алтын алка»ның беренче бүлеге «Казан» ресторанын, аның да бер затлы залын сурәтләүдән башлана. Бер өстәл артында дүрт егет утыра, алларында мул ризык, аракы тулы графин һәм нечкә билле рюмкалар. Әмма болар эчеп исерергә бик ашыкмыйлар — талау операциясенең чираттагысына әзерләнеп, киңәшеп, план корып утыралар. Бер-берсенә исемләп эндәшү дә юк — бары тик кушаматлар гына.

Ә инде бу әсәрнең икенче бүлегендә тикшерүче Искәндәр Бәхтияров белән танышабыз. Күрү белән аның менә мондый сыйфатларына игътибар итәбез. «Бу юаш булып күренгән, һәрвакыт ияк-яңаклары чиста итеп кырылган, пөхтә киенгән кеше бала чактагы сыман чирәмгә ятып аунарга әзер». «Кар эреде, чаңгы белән йөреп булмый дип өйдә утырмаган, гадәттәгечә ял көннәрендә дачага бару юлын тапкан. Кайтырга чыкканда, улының аркасына эленгән биштәре варенье, тозлаган помидор, кыяр банкалары белән кабарып тулган иде».

Күрәсезме, игътибар иттегезме: берәүләр ресторанда кеше талауга план корып утыра, икенчеләр табигать кочагында эшли-эшли ял итә. Тормышта ике төрле яшәүнең ике төрле нигезе менә шулар түгелме соң инде? Кичә дә, бүген дә, иртәгә дә менә шушы ике төрле туфрак, ике төрле нигез үзләренең җимешләре итеп ике төрле кешеләрне үстереп торачак бит! Язучы М.Насыйбуллин каләме сурәтләгән әнә шундый ике төрле нигез безнең өчен тирән мәгънә ала, әсәр башында ук укучы хәтеренә сеңеп кала.

Алга таба вакыйгалар куера, шуңа бәйле рәвештә яңа кешеләр күз алдына килеп баса. Ләкин шунысы куанычлы: әсәрдә артык персонажлар, кирәкмәгән каһарманнар юк. Кайсыбер китапны укыган чагында, кемнең кем булуын да оныта башлыйсың бит — алар шулкадәр күп була!

Мәгъсүм ага Насыйбуллин хикәяләрендә тагын шунысы күзгә ташлана: әсәрнең идеясе һәм эчтәлеге туп-туры сызык буенча гына үсеп бармый. Повесть нигезен тәшкил иткән бер яисә берничә җинаять-кә бәйле рәвештә анда киң тормыш чынбарлыгы ачыла, сурәтләнгән еллардагы реаль күренешләр укучы күз алдына килеп баса. Без искә алган повестьтагы төп каһарман Бәхтияровның әтисе дә авылның

хөрмәтле кешесе, балта остасы итеп бирелә. «Яңа өй саласы булса, иң беренче итеп Гафиятулла Бәхтиярын искә төшерәләр, эшкә чакыралар. Авылларны матурлап, әллә каян ук балкып торучы челтәрләп бизәлгән, төрле төсләргә буялган, юан, таза бүрәнәләрдән салынган чардаклы йортларның һәммәсенә диярлек Бәхтиярның да тире тамган».

Менә шушындый нәсел, шушындый уңган атаның баласы итеп бирелгән уңай образ. Әмма яхшы нәселдән, әйбәт гаиләдән чыккан булу һәрчакта да бәхет нигезе итеп каралмый язучының әсәрләрендә. Чөнки тормышыбыз чынбарлыгы шундый, кешеләрнең язмыш юллары шундый. «Алтын алка»да да, бүтән әсәрләрдә дә без матур гаиләдә туып, яши-яши сынган, бирешкән һәм җинаять юлына баскан адәмнәрне дә очратабыз. Бу — тормышны дөрес яктырту билгесе.

Мәгъсүм Насыйбуллин әсәрләрен укып чыккач, бик күп нәрсәләргә күзең ачыла. Иң беренче чиратта, әлбәттә, закон сагында торучылар тормышын үзең өчен ачасың, алар белән якыннан танышасың. Аларның авыр һәм җаваплы хезмәтләрен, ул шәхесләрнең фидакарьлекләрен күрәсең. Чын егетлек үрнәкләре белән рухи байыйсың, әхлакый яктан ныгый төшәсең. 1987 елда басылып чыккан «Син — тикшерүче бит» дигән хикәяләр һәм повесть китабы бу яктан бигрәк тә истә кала. Биредәге каһарманнар чын мәгънәсендә җиде кат үлчәп кенә билгеле бер карарга килә торган кешеләр. Алар үз күңелләрендә туган шик-шөбһәгә таянып түгел, ә дәлилләр табып, шулар нәтиҗәсендә генә теге яки бу кешенең җинаятьче икәнен раслыйлар.

Ә шулай да, минемчә, Мәгъсүм ага Насыйбуллин повестьларының зуррак әһәмияте — җинаятьчеләрнең ничек, ни сәбәпле барлыкка килүләрен ачыклау. Әсәрләрдә укучыга, халыкка әнә шуны күрсәтеп, аңлатып бирү. Биредә кешенең кечкенәдән үк иркәләнеп үсүе, эшләмичә генә тәмле ашарга, җиңел яшәргә өйрәнүе кебек сәбәпләр төп урынны алып тора. Повестьларда сурәтләнгән тискәре персонажларның байтагы әнә шундыйлар.

Әмма бу язучының әсәрләрен укыганда, мин тагын бер нәрсәгә игътибар иттем: җинаять кылучыларның байтак өлешен безнең якта тамыр җибәрмәгән, тегеннән-моннан килгән адәмнәр тәшкил итә.

Повестьларда әнә шундыйлар шактый очрый. Бу күренеш шулай ук язучы иҗатының ныклы һәм тирән фәлсәфәгә нигезләнгән булуы, олы хакыйкатькә таянуы турында сөйли. Ягъни «тирән тамыры булмаган агачның кәүсәсе дә биек, мәһабәт була алмый!» дип әйтә төсле безгә язучы. Җилләр, гарасатлар андый агачны бик тиз аударып ташлый!

Мавыгып укылып та, шуның белән онытылса, андый әсәрләр әдәбиятта әллә ни озак яши алмас иде. Чын әдәби әсәрләрнең бит аларның тәрбияви яклары да бик көчле була. Эстетик ләззәт бирү, тормышны танып-белергә булышу һәм тәрбияви яктан әһәмият — менә бу өч сыйфат инде күптәннән бирле чын әдәби әсәрләр өчен төп таләп итеп куела килә. Ләкин, кызганыч, соңгы елларда бездә эстетик як белән тәрбияви әһәмият еш онытыла. Шушы ике мәсьәләдә безнең әсәрләр соңгы елларда нык кына аксый башлады.

Ә менә Мәгъсүм аганың хикәят һәм хикәяләрендә тәрбияви як иң төп максатларның берсен тәшкил итә. Аларда тәрбия, начар мисалларны күрсәтеп, гыйбрәт бирү аша да, намуслы һәм тырыш җаннарны якты үрнәк күрсәтү белән дә башкарыла. Һәр ике ысул да тәэсирле, нәтиҗәле килеп чыга. Әсәрләрне укыган чагында, әле генә күз алдыннан үткән вакыйгалар турында туктап-туктап уйга каласың.

Юрист-язучыбыз иҗатының тагын бер мөһим ягы — аның әсәрләре бүгенге укучының хокук һәм кануннар буенча аң-белемен дә арттыра. Җәмгыятьтәге һәр кешенең үз адымнарын уйлап һәм үлчәп ясарга тиешлеген искәртә алар.

Мәгъсүм аганың чын-чыннан мактана алырлык зур иҗаты бар. Аның әсәрләре бик күп чит телләргә дә тәрҗемә ителгән. Күрше башкорт һәм рус теленнән тыш, алар тагын үзбәк, казах, каракалпак, чуаш, якут, удмурт, кыргыз телләрендә дә басылган. Иң отышлы әсәрләре исә кытай һәм төрек телләренә дә тәрҗемә ителгән, чит илләрдә дөнья күргән.

Бүген республикабызда нәшер ителә торган газета һәм журналларны ачсак та, аның исемен еш күрәбез. Мәгъсүм ага үзен борчыган уй-фикерләрен халкыбыз белән уртаклаша, үткен-үткен мәсьәләләрнең уңай хәл ителүе өчен янып-көеп яши. Ул, татар милләтенең киләчәген һәм бүгенге яшь буын язмышын кайгыртып, кызыклы, мәгънәле мәкаләләр яза.

Соңгы биш ел эчендә генә дә ул, үзенең барлыгы егерме ике китаптан гыйбарәт мул иҗатына өстәп, дүрт яңа китап чыгарды, 38 хикәя, очерклар язды. М.Насыйбуллинның иҗаты 122 мәртәбә вакытлы матбугат, фәнни хезмәтләрдә яктыртыла. Иң мөһиме — ул беркемне дә битараф калдырмый, еш кына бәхәсләр уята, хәрәкәткә өнди.

Әле бит без Мәгъсүм аганың 1943 елдан башлап Бөек Ватан сугышы мәхшәрендә катнашуын әйтмәдек. Япь-яшь килеш сугыш утына барып керү — кеше өчен үзе бер зур һәм гаять мәкерле сынау бит әле ул! Мәгъсүм ага әнә шул олы сынауны исән-сау үтеп кайткан. Аннан соң да озак еллар хокук саклау буенча һәм иҗатта тир түгеп эшләгән, 1975 елда ук аңа «Юстиция өлкән киңәшчесе» дигән югары дәрәҗә бирелү үзе үк күп нәрсә турында сөйли булса кирәк! Хөрмәтле язучыбызның «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исеме дә бар.

...Мәгъсүм ага бүген дә гел хәрәкәттә, һаман нәрсәдер эшли, тик тормый. Аның акыллы, уйчан йөзендә үзенең тынгысыз эчке дөньясы, рухы гына түгел, ә дөньяның бик күп борчулары, гамьнәре дә чагыла төсле.

1987

Ул көннәрдә...

(Әдәби һәм сәяси вакыйгаларга күзәтү)

Кереш сүз

Туксанынчы елларның башы тормышта да, әдәбияттә да вакыйгаларга бик бай булды. 1990 елның 30 августында, Бәйсезлек Декларациясе кабул ителгәннән соң, безнең республикада сәяси көрәш тагын да кыза төште, аңа бик күптөрле көчләр тартылды, бихисап шәхесләр катнашты.

Ә соң безнең язучылар бу көрәштә нинди урын биләде?

Татар милләте өчен, аның бүген языла торган тарихы һәм бигрәк тә киләчәге өчен менә бу сорауга мөмкин кадәр тулырак җавап бирү кирәк.

Әнә шул максат белән «Шәһри Казан» газетасында 1991 елның көзеннән алып 1992 елның язынача алып барылган атналык күзәтүләрне укучыга тәкъдим итәм.

Заманабыз никадәр генә ыгы-зыгылы һәм шау-шулы булса да, без барыбер газета-журналларга күз салырга да, китаплар кулга алып, аннан роман-повестьлар укырга да вакыт табабыз бит. Әйе, укуын укыйбыз без аларны, әмма әнә шул әле генә укып чыгылган әсәрләр турында гәпләшергә, әңгәмә корырга, фикер алышырга ничектер җай таба алмыйбыз. Сөйләшердәй, синең белән чын хисләрен, тәэсирләрен уртаклашырдай кешесе дә гел очрап тормый...

Бүген, милләтебез һәммә яктан уянып килгәндә, татар әдәбияты ни хәлдә яши? Халкыбызның, укучыларның рухи ихтыяҗларын ул ни дәрәҗәдә канәгатьләндерә? Соңгы вакытта укыган әдәби әсәрләр нинди тәэсирләр калдырды? Бүген басылып чыккан әсәрләрдә нәрсәләр ошый, ә ниләр ошап җитми?

Әсәрләр

Мавыгып һәм чын күңелдән сокланып укылган әдәби әсәрләр соңгы вакытта күп очрыймы? Кемгә ничектер, әмма минем үземә андый әсәрләр байтак кына очрады.

Аларның иң беренчесе итеп мин Павел Апушевның «Барма, дисеңмени, бәтием?» исемле хикәясен атар идем. Укучылар хәтерли булыр: бу әсәр «Шәһри Казан»ның 10 октябрь (1991) санында дөнья күрде. «Югары оч Гөлҗамал әби хайваннар телен дә, кошлар телен дә белә икән...» дигән ымсындыргыч сүзләр белән башлана да, бүгенге авыл тормышының иң үткен мәсьәләсе эченә алып кереп китә хикәя. Юк, эш күтәрелгән проблеманың мөһимлегендә генә түгел! Бүгенге өлкән буын кешесенең хисләре гаять нечкә яшәеш алган анда. Һәм колхоз рәисе, бригадир кебек бүгенге колбиләүчеләрнең кансызлыгы, шәфкатьсезлеге. Хикәядәге әби дә үзенең нәни сарык бәрәнен туйдырасы барлыгын уйлап, кешелексез бригадирга каршы дәшмәскә була... Әсәрне укыгач, авылдагы бүгенге хәлләр турында сәгатьләр буе доклад сөйләп тә торасы юк!

Бүгенге профессионал язучыларыбыз күбрәк калын китапларга гына йөз тотып ижат иткән бер чорда, район төбәгендәге авторның аларга матур үрнәк күрсәтүе бу!

Әдипләребезнең зур күләмле әсәрләрен дә яратып укыйбыз без. Ләкин, алар хакында сүз башлаганчы, шулай да Мөхәммәт Мәһдиевнең «Татарстан яшьләре» газетасында басылган (1991.— № 121–123) «Европага тәрәзә тишкәндә...» исемле язмасына тукталмыйча китү мөмкин түгел. Бу әсәр жанры ягыннан истәлек кенә дип куелса да, Балтыйк буена хезмәт итәргә баручы яшь солдатлар турында булганга күрәме, чын хикәя сыман укыла. Безнең илнең, безнең халыкның дөньядан никадәр артта калган, әхлакый яктан түбән җәмгыятьтә яшәве тагын бер мәртәбә йөрәкне әрнетеп ала. Газетаның рәссамы да автор фикерен дөрес тотып алган: әсәрнең исеме янында ук әрсез урыс аюының чырае ыржаеп тора!

М.Мәһдиев ижатын яратучылар өчен тагын бер яңалык. «Казан утлары» журналы үзенең 8 санында (1991) бу язучы белән кызыклы әңгәмә урнаштырган. Шул ук санда чорыбызның күренекле әдибе Нурихан Фәттахның «Кичү» исемле романы да басылып беткән. Ә «Идел» журналы бу язучының «Кырык дүртнең маенда» исемле бик кыю язылган повестен 1990 елгы 1, 2 саннарында бастырган иде. Быел бу язучының «Шәҗәрә» дигән яңа китабы да дөнья күрде. Соңгы елларда бик тә актив ижат иткән һәм

милләтебезнең кыю көрәшчесе булган бу әдипкә быел, инһаять, Габдулла Тукай исемендәге республика бүләген бирү кирәктер бит инде?!

Зур тырышлык белән яулап алынган «Идел» яшьләр журналы әле хәзер дә күп кыенлыклар күреп яши, көрәш алып бара. Бәлки, әнә шуңа күрәдер дә, анда заман рухы бик көчле чагыла. Алтынчы санның (1991) тышында, мисал өчен, чиркәү белән мәчет рәсеме янәшә бирелгән. Каршы тору идеясе эчтәге бик күп язмаларда да уңышлы нигезләнә. Яшь язучы З.Мәхмүдинең мажаралы повесте да шунда ук урын алган.

Ә күренекле каләм остасы Әхсән Баянның «Соңгы имтихан» дигән хикәясе укытучысы сүзен тыңлап йөрәгенә мәңге төзәлмәслек яра ясаган бер егет турында. Күптән түгел без бу әдипнең «Җәй белән җәй арасы» дигән кайнар мәхәббәт турындагы повестен «Казан утлары»ның 6 саныннан укыган идек.

Әйе, язучыларыбызның мәхәббәт, әхлак кебек мәңгелек темаларга ешрак мөрәҗәгать итүләре һәм без яратып укырдай әсәрләрне күбрәк яза башлаулары күңелле күренеш. Күптән түгел генә «нефть темасы», «эшчеләр темасы» дип баш әйләнгән чаклар да бар иде бит әле. Шайтан вәсвәсәсеннән котылып киләбез, ахрысы!

Вакыйгалар...

Узган атнада гына да мин 3 яңа журнал күрдем. Аларның беренчесе — «Аргамак» исемлесе һәм Чаллыда чыкканы — материалларының кыюлыгы, үткенлеге белән аерылып тора. Менә карагыз: беренче санда гына да Башкортстан өлкә комитетында озак еллар буе идеология секретаре булып эшләгән Т.Ахунҗанов язмалары, Сәйфи Кудашның шовинистларга ачык хаты, Вахит Имамовның «Кәнәфи» исемле повесте... Ә соңгы битләрдәге «Чүплек» бүлеге безне адаштыручы китапларга, язмаларга багышланган... Кыскасы, баш редактор Айдар Хәлим җитәкчелегендәге коллектив укучылар өметен аклау өчен нык тырышкан. Кайберәүләр көнләшерлек журнал туган!

Зеленодольскида нәшер ителә торган «Ажаган» белән күптән көтелгән «Мирас»ның беренче саннары да әйбәт тәэсир калдыра. Әле бит Чаллыда һәм Казанда нәшриятлар да оешып килә!

Безгә, озак еллар буена бер нәшрият һәм бер әдәби журнал белән яшәгән кешеләргә, болар күбрәк тә булып тоелырга мөмкин. Ләкин бездән күпкә азрак санлы Балтыйк буе милләтләрендә журналлар саны йөзәрләп, ә нәшриятлар исә дистәләп исәпләнә. Әнә шуңа күрә алар — алга киткән милләтләр. Димәк, бу елларда ачылган бер-ике нәшрият һәм берничә әдәби журнал әле безнең өчен чик булмаска тиеш! Безгә әле сәнгать журналы кирәк. Сүз уңаенда әйтеп китик: Яшь тамашачылар театры да бик кирәк!

Язучылар әдәби газета оештыра икән дигән сүз күптән чыккан иде инде. Дөресрәге, Татарстан язучыларының 1989 елда булып узган съезды кабул иткән резолюциядә мондый юллар бар:

Татарстан Язучылар союзының «Язучы» нәшриятын ачу;

Республикада атналык әдәби газета булдыру;

Татарстан Язучылар союзы каршында китап кибете оештыру;

Подписка буенча таратыла торган китапларны булдыруда язучыларга ярдәм итү.

Янәшәдә үк тагын менә мондый пункт та бар:

«Ике елдан соң (ягъни 1991 елда) язучыларның гомуми җыелышында идарә председателенең һәм «Казан утлары» журналы баш редакторының XI съезд карарларын үтәү буенча отчетларын тыңларга, аларга ышаныч белдерү-белдермәү мәсьәләсен карарга». Язучылар съездының бу резолюциясе «Казан утлары»ның 1989 елгы 11 санында басылып та чыккан. Күрүебезчә, союз җитәкчелегенең үз каләмдәшләре алдында хисап бирер чагы җиткән, ә резолюция үтәлмәгән!

Шуңа күрә хәзер күп кенә язучыларда шик туа — әдәби газета турындагы сүз инде бу юлы дөрескә чыгар микән? Язучылар союзы җитәкчелеге әдәби газета булдыру эшенә чынлап торып тотыныр микән? Әллә бу шагыйрь һәм идарә әгъзасы Ркаил Зәйдулла белдерүеннән соң эш күрсәткән булып кылану гынамы? Газетабызны укучылар хәтерли булыр: Р.Зәйдулла күптән түгел Татарстан Язучылар союзы җитәкчелеген эшлексезлектә гаепләп чыккан иде.

Соңгы идарә утырышында әдәби газетаны оештыручы редактор итеп тынгысыз җанлы шагыйрь Рафис Корбановның билгеләнүе күпмедер ышаныч уята уятуын. Ләкин әгәр дә идарә җитәкчелегенең ният җитди икән, бу очракта яшь һәм тәҗрибәсез иптәшкә нык һәм реаль ярдәм күрсәтү кирәк. Шулай эшләмәгәндә, яшь иптәшнең эшен сылтау итеп, әдәби газета булдыруны тагын әллә ничә елга сузарга мөмкин бит!

Әсәрләр...

Узган атна сәяси вакыйгаларга бик тә бай булды — анысын барыбыз да белә. Ә менә әдәбиятта нинди яңалыклар күренде соң? Сәяси өлкәдәге шикелле биредә дә тормышның кайнар сулышы сизеләме, еллар узгачтын да үз көчләрен җуймастай рухи хакыйкатьләр укучы күңеленә барып ирешәме?

Сүзебезне шигърияттән башлыйк. Безнең бик тә зур талантка ия шагыйребез Мөдәррис Әгъләмов үткән атнада газеталарда ике әсәр бастырды. «Аргамак» журналы чыга башлауга багышланган шигырендә менә мондый юллар бар:

Һәр татарда егылып ат ята,
Атын җуйган өчен оят ята —
Аның атын яулап ал кабат!
Шундый теләктә без, «Аргамак».

Милләтнең бүгенгесе, аның халәте һәм хәтта аның киләчәк язмышы да ничек оста итеп әйтеп бирелгән! Безне уятырдай, оялтырдай итеп әйтелгән! Чыннан да, бүген атын җуйган татарлар бит без!

Татарның бик күп әдипләре чит төбәкләрдә яши. Чиләбе шәһәрендә иҗат итүче Салисә Гәрәеваның «Болгар хатыннары», «Арыш бөртеге» дигән һәм башка шигырьләрен «Шәһри Казан» үзенең 18 октябрь санында урнаштырган. «Монастырьда Болгар хатыннарын Диннән яздырмакчы булганнар...» Шагыйрә халык язмышындагы иң трагик, иң үзәк өзгеч вакыйгаларга таяна. Шул рәвешчә, безгә бүгенге көн күренешләре дә ачыграк булып күренә башлый. Чөнки автор үзенең икенче бер әсәрендә язганча:

Тамырларга балта чабылса да,
Өзелмичә калган җепләр без!

Хәзер әйтеләсе сүзебезнең шигърият белән уртаклыгы булмаса да, Әхәт Гаффарның «Күңел аҗаганнары» тышкы рәвеше шигырьгә охшаганга күрә бу хакта да фикерне белдерми китү мөмкин түгел. Язучы үзенең бу исемдәге язмаларын еш һәм төрле газеталарда бастыра. «Шәһри Казан»ның 16 октябрь санында чыкканында исә менә мондый юллар бар: «Сары яулык яба инде Ак каеннар чугын. Нигә көнли торганнардыр Ак чәчләрем югын...» «Җимерелгән мунча кебек Аунап ята бу җан...» «Сулар сибеп сүндерәләр Күмерләр ялкынын...»

Газета укучыларга мөрәҗәгать итәсе килә — татарча дөрес сөйләшкән кеше болай дип әйтә аламы? Язучы кешедән без мондый гарип җөмләләр көтәбезме? Бүген милләтебез мәдәнияте, әдәбияты тернәкләнеп килгәндә, безнең һәммәбез дә үз-үзенә булган таләпне арттырырга тиеш бит!

Шигърият турындагы сүзгә әйләнеп кайтып, аны нечкә тоючылар барлыгына ихлас сөенүебезне дә әйтәсе килә. Мисал өчен И.Иксанованың поэтик китабы чыгу уңаеннан Р.Әхмәтҗанова дигән бер яңа автор газетабызда үзенең уй-фикерләрен бастырды. Авторның тирән хискә ия һәм шигъриятне нечкә тоемлаучы шәхес булуы ул язмадан бик ачык күренә. Аңа хәзер ижади активлык телисе килә. Чөнки безгә яшь тәнкыйтьчеләр дә бик кирәк!

Үткән атнада фельетоннар, памфлетлар да байтак кына дөнья күрде. Тукайча туры фикер һәм ачы тел белән бу өлкәдә әле һаман Фәнзаман Баттал беренче урынны тота. «Татарстан яшьләре»нең 15 октябрь санында ул «Имамның иманын укыту» исемле бик тә үткен темага караган фельетон бастырды. Анда партия чиновникларының чын асыллары үтә дөрес ачылган. Шул ук газетаның 19 октябрь санындагы «Мал» дигән әсәр исә артисткаларны тышкы кыяфәт буенча гына сайлау турындагы көлке. Чынлап та, сәхнәне дә, телевизорны да тавышсыз «җырчы»лар басты бит! Бу күренеш — буталыш чорының бер җимешедер инде, мөгаен! Черек җимеше! Ф.Баттал моңа шәп төрттергән.

Нияз Акмал «Чүмечләп чөмерегез...» дигән памфлетын «Татарстан хәбәрләре»нең 6 санында чыгарган. Образлы итеп, кайнар сулыштан язылган әсәр. Табып, һичшиксез, укыгыз сез аны!

Әхәт Гаффарның «Социалистик Татарстан»да дөнья күргән «Матри, малай» дип исемләнгән памфлеты да үткен мәсьәләгә багышланган. Биредә авторның әйтер сүзе ачык, фикере эзлекле рәвештә үсә бара. «Шәһри Казан»дагы «Тел» памфлетында да мөһим нәрсә хакында сүз бара, ләкин биредә шунысы күзгә ташлана: РСФСР депутатларында ачык күренгән күпсүзлелек авыруы авторның үзендә дә бар, ахрысы... Югыйсә памфлет болай ук озын килеп чыкмас иде. Ә нигездә дөрес памфлет!

Узган атнаның тагын бер яңалыгы шул — укучыларга «Казан утлары»ның 9 саны килде. Анда Батулланың «Сөембикә кыйссасы» басылып беткән. Бу әсәрне без барыбыз да бик көтеп алдык, шуңа күрә, бәлки, газетабыз битендә кыйсса турында аерым сөйләшербез? Хәзер инде бакча эшләре бетте дияргә була. Менә шушы әсәр буенча бер кызыклы сөйләшү үткәрсәк, бик яхшы эш чыгарга мөмкин бит. Кыйсса хакында сезнең фикерләрне көтеп калам.

«Зәйтүнәкәй, акчарлагым» дип исемләнгән хикәя бүгенге бер гүзәл турындагы роман сыман укыла. Аның авторы Фәрит Гыйльми безгә берничә повесть белән билгеле. Әмма хикәяләренең һәммәсе коеп куйган була! Аның күмәк җыентыкта дөнья күргән «Салават күпере» хикәясе турында мин моннан егерме ел элек түбәндәге сүзләрне язган идем: «...хикәя геройларының сулышын сүзләр музыкальлеге аша да, якты буяулар белән ясалган гүзәл картиналардан да, әдәби детальләрнең мәгънәле торышлары һәм куелышлары аша да, аларны бәйләүче күзгә күренмәгән җепләрнең нәфис яңгыравында да тоябыз». Бу сүзләр Ф.Гыйльминең соңгы әсәренә дә бик туры килә!

Әлеге санда халкыбызның яраткан әдибе Фәнис Яруллин үзенең ике әсәре белән катнаша. Аларның берсе «Коткарыгыз!» дип атала һәм кыерсытылган кешеләр турында сөйли, ә икенчесе сөекле җырчыбыз Гөлзада Сафиуллинага багышланган. Һәр икесе мавыгып укыла! Фәнис абый күпләрне көнләштерерлек итеп яши һәм иҗат итә! Күз тимәсен!

Вакыйгалар...

Бу көннәрнең төп вакыйгасы, әлбәттә, Ирек мәйданында — Азатлык яулау мәйданында бара. Сессиядә катнашучы депутатлар да калын стена эченә кереп кенә халык тавышыннан котыла алмыйлар. Көрәш бер, мәйдан бер! Язучы депутатлардан иң фидакаре булып әле һаман Фәүзия Бәйрәмова исемен әйтәбез. Аның исемен мәйдандагы күпмеңләгән халык та кабатлый. Ирексездән чагыштыру ясала: олы-олы гәүдәле, әмма куркак җанлы түрәләр һәм безнең милләтебезнең менә шушы кечкенә генә гәүдәле, ләкин олы йөрәкле, үз халкына тугры җанлы кызы... Күрәсең, безнең татар, әнә шундый көрәшчеләрне истә тотып, карама беләккә, кара йөрәккә! дигәндер инде. Әйе, бүген йөрәклеләр җитми, бик тә җитми! Һәркайсы — хәтта зур-зур исем йөрткәннәре дә — көн һәм төн як-ягына карана, курка, шикләнә, дер калтырый! Аңа үз башы, үзенең урындыгы кадерле!

Фәүзия Бәйрәмова матбугатта да үзенең политик белдерүен бастырды һәм «Ач күзеңне, күр үзеңне!» дигән үткен публицистик мәкалә белән чыгыш ясады («Татарстан яшьләре».— № 124; «Социалистик Татарстан».— № 210).

Ә мәйданда язучы Батулланың булмавы шактый нык сизелә. Ишетелгән сүзләргә караганда, ул — әлегә шифаханәдә. Әйе, моңа кадәрге митингларда без аның чын мәгънәсендә җан аямыйча көрәшүен күрдек шул...

Зәки Зәйнуллин белән Әбрар Кәримуллин чираттагы ялларыннан кайту белән үк мәйданга халык янына килделәр. Алар авызыннан һәрчак милләт өчен мөһим фикер, акыллы киңәш сүзләре чыга. Әбрар ага «Татарстан яшьләре»нең 17 октябрь санында «Менә без дә «бүки»гә әйләндек» дигән үткен эчтәлекле мәкаләсен бастырды. Бу язма бүгенге көрәштә күпләр өчен юл күрсәткеч ролен үти. «Нәрсә генә булмасын, азатлык җиңәчәк. Чөнки хаклык, дөреслек аның ягында»,— дип бетерә күренекле галим һәм әдип үз язмасын.

Үткән атнада шулай ук М.Гали, Р.Миңнуллин һ.б.ларның да кызыклы язмалары матбугатта дөнья күрде. Болары яхшы. Ләкин безнең 200 кешене берләштергән оешмабызда әле тагын күпме иҗатчы бар бит. Мондый хәлиткеч көннәрдә алар нишләп дәшми соң? ГКЧП килеп чыгу аларны тәмам җиргә сеңдердеме икән әллә?

Иҗат берлеге дигәннән, тагын бер мөһим вакыйгага тукталу кирәк, 10 октябрь көнне Россия Язучылар берлеге белән Татарстан Язучылар берлеге тигез шартларда килешүгә кул куйганнар иде. Ягъни икесе дә мөстәкыйль иҗат берлеге буларак. Әлеге факт — азатлык яулаучы Татарстан өчен гаять мөһим күренеш бит. Ләкин бу факт республиканың урыс матбугатында бөтенләй әйтелмәде. Ни өчен тормыш фактын урыс матбугаты күрми? Ни өчен без биредә тиешле таләпчәнлек күрсәтмибез?

Язучыларның әдәби газетасына исем эзләү буенча конкурс игълан ителгән иде. Бу әле газета булды дигән сүз түгел, ә бәлки эшне башлау гына. Чөнки исемнән башка яңа газетаны теркәмиләр. Укучылар нинди исемгә тукталыр икән? Сезнең активрак булуыгызны көтәбез! Ә минем фикергә килсәк — «Җомга» дигән исем ничек булыр икән? Безнең милләт өчен бик тә якын һәм кадерле исем бит ул. Яңа басма бит саф әдәбият-сәнгать газетасы гына булмаячак, анда милләтебезнең иң үткен мәсьәләләре кыю рәвештә һәм беркемнән курыкмыйча яктыртылачак. Шуңа күрә «Җомга» дигән исем безгә һәммә яктан көч бирер, иманыбызны ныгытыр, гамәлләребезне арттырыр иде!

Турыдан-туры әдәбиятка карамаса да, «Татарстан хәбәрләре»нең 7 санында басылган «Чакыру ташланды. Кабул ит, Татарстан!» дигән мәкаләне укырга һәммәгезгә дә киңәш итәм. Безнең бик акыллы журналистыбыз Тәлгать Бариев фикерләре укучылар өчен генә түгел, ә дәүләтебез җитәкчеләренә дә, Президентка да файдалы.

Әсәрләр...

Көндәлек матбугатта үткән атнада дөнья күргән әсәрләрдән иң зур күләмлесе — Мәгъсүм Хуҗинның «Шәһри Казан»да басылган «Ак төенчек» исемле хикәясе. Бу әсәр газетада 19 октябрьдән башлап 24 енә кадәр, ягъни рәттән 4 санда бирелде.

Элеккерәк елларда кечерәк күләмле хикәяләр генә иҗат иткән М.Хуҗин соңгы вакытта «Казан утлары» журналында повестьлар да бастырды. Ләкин миңа, аның берничә хикәя китабы белән таныш булган кешегә, М.Хуҗинның кечерәк күләмле әсәрләре якынрак тоела иде. Һәм менә хәзер безнең алда авторның яңа хикәясе. Ягъни язучының үз кишәрлегенә әйләнеп кайтуы дип тә карарга була төсле.

Моннан ун ел чамасы элек матбугатта М.Хуҗин хикәяләрен мактап язган булсам да, хәзер менә бу хикәя уңаеннан җылы сүз әйтүе кыен. Ни өчен шулай?

Минемчә, иң төп сәбәп шунда: автор соңгы елларда, роман-повестьлар язам дип йөреп, кыска жанрда әйбәт кенә эшләү осталыгын җуйган. Кайбер яшьләр арасында бик көчәеп киткән күләм куу чире, күрәсең, аңа да йоккан. Сүз уңаеннан әйтеп китик — хәзер бездә һәрбер шагыйрь поэма яза, һәр прозаик роман дип тырыша! Торгынлык елларында безнең чынбарлыкта бик көчәйгән «гигантомания» авыруының каләм ияләренә начар тәэсире, ахры, бу күренеш.

Билгеле, М.Хуҗин бу хикәядә әйтергә теләгән ният изге. Ул хәзерге яшьләр алдында торган четерекле сынаулар турында, бүгенге авылның чынбарлыгы хакында әйтергә тели. Автор авылны, аның кешеләрен яхшы белә, аларны эчтән үк тоя, аңлый. Теле дә ипле, сабыр ага...

Ләкин... Ләкин автор, хикәясен язганда, үзенең яшь геройларының язмышы белән чын-чынлап дулкынлана алмаган. Аларны укучы күңелен дә гаять сизгер итүче, авторның үзен дә битараф стильдән саклаучы мәхәббәт һәм нәфрәт күперенә күтәрә алмаган. Әйе, бер-берсен яраткан Гайфар белән Сәрвиназ үлә, икесе дә суга бата. Әмма тормышның менә шушы трагик күренеше әсәрдәге сәнгать чынбарлыгының бер олы, мәгънәле һәм тетрәндергеч вакыйгасы булып чыкмаган. Күпсанлы катнашучылар, әһәмияте булмаган сөйләшүләр һәм авторның үзенең шактый сүлпән хикәяләү рәвеше хикәянең тәэсирен киметә, авторның идеясен югалта. Геройларның сөйләшүләренә дә чын диеп ышануы кыен, ул ясалмарак сыман тоела.

М.Хуҗинның элекке хикәяләрендәге ихласлыкны, гади тирәнлекне һәм сәнгатьчә эзлеклелекне сагына-сагына укыдым мин бу әсәрне. Ә бәлки, укучылар минем белән килешмәсләр? Ул чагында, әйдәгез, хикәя турында сез дә үз фикерегезне язып җибәрегез. Без аларны да, һичшиксез, бастырырбыз.

Узган атнада Башкортстандагы татар шагыйрьләренең иҗаты Нәҗибә Сафинаның «Чишмәләргә тел тәкъдим итмиләр» дигән бик мәгънәле кереш сүзе белән укучыларга тәкъдим ителде. Арада Филүс Нагаев һәм Кәүсәрия Шәфикованыкы кебек йөрәккә үтә торган шигырьләр дә бар. «Күңелемдә гөл үстерәм, Ямьнәре сезнең өчен. Әллә ниләр эшләр идем, Җитәрлек булса көчем»,— ди, мәсәлән, Кәүсәрия «Сезгә» дигән шигырендә.

Башкортстандагы татар шагыйрьләренең әсәрләре «Казан утлары»ның 9 санында да дөнья күргән иде. Аларда безнең өчен яңа аһәңнәр ишетелә, күңелгә яңа төрле ямь өстәлә.

Әмма бу уңайдан бер фикер дә әйтергә кирәк. Башкортстанда татарлар бик күп. Талантлы әдипләр дә күп. Ә ни өчен татарча әдәби журнал юк? Безнең әле генә макталган авторларыбыз ни өчен моны таләп итмиләр, артыннан йөрмиләр? Чаллыда чыга башлаган «Аргамак» шикелле, Зеленодольскидагы «Ажаган» кебек бер әдәби журнал Уфада да булырга тиеш бит инде! Ләкин Уфа ягыннан мондый сүзләр әлегә ишетелми. Эшнең шулай торуында каләм ияләренең үзләренең дә гаебе зур. Чөнки без көн дә мактый торган Тукайлар, Әмирханнар әдәби басмаларны үзләре оештырганнар һәм аның үзәгендә кайнаганнар! Иҗатчы шәхесе чыннан да зур булса, ул язу бүлмәсенә генә сыя алмый. Ул милләтнең иң мөһим эшләренә дә кыю рәвештә алына һәм аны гадел рәвештә чишү өчен җанын да аямыйча көрәшә! Әйе, әйе, көрәшә!

Вакыйгалар...

Үткән атнада республиканың Югары Советы сессиясендә бәйсезлек өчен көрәш барды. Ирек мәйданы да халык белән тулып торды. Һәркем бәйсезлек көтте, таләп итте.

Безнең язучы депутатларыбыз бу сессиядә бәйсезлек өчен ничек көрәштеләр соң?

Бик кызганыч: безнең язучыларыбыз әлегә Штаниннар, Грачевлар шикелле кыю һәм патриот булып чыкмадылар! Болар үтә зур активлык белән, хәтта әрсезләнә-әрсезләнә (ә болай эшләү көрәш вакытында бик кирәк!), үз фикерләрен үткәрергә, үз позицияләрен ныгытырга тырыштылар, ә безнең язучылар тыныч кыяфәттә үз урыннарында утыра бирделәр! Гүяки милләт язмышы хәл ителми, әйтерсең лә милләт бүген кыл өстендә түгел! Бөтен авырлык һаман да шул Фәүзия белән Марат абыйга калды.

Ә нишләп соң бу сессиядә Роберт Миңнуллинның да, Равил Фәйзуллинның да, Разил Вәлиевнең дә тавышы ишетелмәде?! Сорауга бер җавап күренеп үк тора. Безнең бу язучы дигән депутатларыбыз да элеккеге номенклатура кешеләре икән бит! Алар югары оешмалар тарафыннан зур-зур урыннарга утыртылганнар! Нинди урыннарга дисезме? Роберт Миңнуллин — «Сабантуй» газетасы редакторы һәм Югары Советның Президиум члены, Равил Фәйзуллин — «Казан утлары» журналы баш редакторы, Ренат Харис — «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш редакторы, Разил Вәлиев — Республика китапханәсенең директоры.

Күрдегезме инде — болар барысы да түрәләр бит! Ә түрә кешегә беренче чиратта нәрсә кирәк? Милләтнең бәйсезлегеме, азатлыкмы?

Юк, аңа иң беренче чиратта үзенең урындыгы кадерле! Ул иң элек әнә шул җылы урынны югалтудан курка! Һәм әле тагын да җылырак, акчалырак урынга күтәрелү турында уйлый! Ә инде болай уйлаган кеше Фәүзия кебек яки Штанин сыман үз фикерен, үз милләтен яклап көрәшкә ташланмый!

«Милләт өчен әнә мәйданда Батулла, Зәки Зәйнуллин яисә Әбрар Кәримуллин көрәшсен!» ди алар эчтән генә.

Чыннан да, алдагы сайлауларда, бәлки, безгә әнә шулар кебек чын батырларга ышанырга кирәктер?! Бу сессиядә безнең яктан чын патриотлар катнашкан булса, бәлки, бәйсезлек яулап та алынган булыр иде. Ә әлегә анда түрәләр психологиясе генә хакимлек итте. Шуңа күрә бәйсезлек турындагы акт та киләчәк эше булып кала бирә. Эшнең шулай булып чыгуында язучы депутатларның гаебе бик зур!

Ә матбугатта үткен язмалар шактый чыкты. Узган атнада әдипләребез активлаша төште дияргә була. Шулай да иң беренче итеп, Әбрар ага Кәримуллинның «Кая китә бу татар?» дигән ялкынлы мәкаләсен әйтергә кирәк. Ул «Шәһри Казан»ның 26 октябрь санында басылган. Уртак никахлар турындагы фикере өчен күпләр Фәүзия Бәйрәмованы гаепләгән иде. Әмма биредә Әбрар ага аны бихисап мисаллар һәм көчле логика белән ышанырлык итеп дәлилли. Мәкалә милләт өчен чын йөрәктән әрнеп, тирән борчылып, нык уйланып язылган. Галим һәм әдипнең бер генә фикере белән дә килешми калу мөмкин түгел. Ул йөрәк түреннән чыккан һәм күңел түренә үтә! Анда ачы хакыйкать тә, чирне дәвалау чаралары да ап-ачык әйтелә.

Әмирхан ага Еники 25 октябрь санында «Борчылу» дигән язмасын бастырды. Бик вакытлы һәм чын күңелдән язылган мәкалә. Әдипнең төп фикере дөрес — республикада иминлек бетсә, ул безнең үзебез өчен үк начар булыр иде.

Ләкин бер урында Әмирхан ага болай ди: «Бер уңайдан бездәге җәмәгать оешмаларының җитәкчеләренә дә турысын гына әйтәсе килә: алар митингларда «толпа»ны котырту белән мавыкмасыннар иде...» Укучы белә булыр, сессия барганда, Штаниннар, Грачевлар да нәкъ әнә шундый гаеп ташладылар. Янәсе, халык үзе теләп әйтми сүзен, ә Фәүзияләр, Маратлар, Зәкиләргә карап кына әйтә. Димәк, котырту буенча гына...

Бер дә митингта булмаган кеше генә болай дип гаепли ала халыкны. Ә чынлыкта, Ирек мәйданындагы һәм башка урындагы татар митинглары милләтнең бик тә көчле шәхесләре катнашында бара. Күп чагында чыгышлар ике телдә дә була. Анда милли мәсьәләдә иң дөрес фикерләр әйтелә. Чөнки сөйләүчеләрнең күбесе фикерле кешеләр, алдынгы карашлы шәхесләр! Кыскасы, анда халык парламенты эшли! Юк, кемдер котыртуы түгел бу! Ә халык фикере, тормыш таләбе бу!

Аннан соң газетада бик дөрес әйтелде бит инде: ни өчен Мәскәүдә урамга чыккан халык — халык дип санала, ә Казанда шулай ук урамга чыкса, ул — толпа була? Менә бит эш нәрсәдә! Эш халыкны, милләтне санга сукмаска теләүдә! Бу мәсьәләдә без кем тегермәненә су коюыбызны төгәл чамаларга тиеш!

Аннан соң «Комсомолец Татарстана» газетасының 25 октябрь санында Тәлгать Бариев бу эшнең чын асылын бик әйбәт ача. Кемнең кулы уйнау әйтелгән анда. «Тбилиси, Баку, Вильнюс... Казан — сценарий бер үк» дигән исем үзе әйтеп тора.

Әсәрләр...

Узган атнада мин үзем Зиннур Хөсниярның «Зөләйха кыйссасы»н яратып укыдым. Ул әсәр газетабызның 31 октябрь һәм 1, 2 ноябрь саннарында дөнья күргән иде. Ни өчен ошады соң бу кыйсса?

Әсәрнең исеменә үк игътибар иткәнсездер: ул татар халкының йөрәк түрендә меңләп ел онытылмый яшәгән «Йосыф-Зөләйха»ны искә төшерә, шуңа якын хатирәләр уята. Чыннан да, исем белән генә түгел, ә тулаем әсәре белән дә автор бүгенге укучы күңеленә дөрес юлны тапкан. Авыл кызы Зөләйханың язмышы шәһәр җиренә бик тә хас булган күңелсез, драматик вакыйгалар аша бирелә.

Әлбәттә, З.Хөсният үзенең элекке әсәрләренә дә хас алымда, бераз озынгарак сузып, иркенләп һәм тормышта очраган күп нәрсәне әсәренә кертеп, аларны һәр урында да сәнгать иләге аша үткәрмичәрәк яза. Бу — безнең татар прозасының «милли» җитешсезлеге бугай инде.

Ләкин «Зөләйха кыйссасы»нда яңа һәм кызыклы як шунысы: атасы һәм анасы аша күптөрле милләтләр, каннар кушылудан яралган Марлен Абдрахманович дигән тип игътибарга алына анда. Мондый кешенең физик һәм рухи сәламәтлеге күрсәтелә.

Кайберәүләр моңа, бәлки: «Бәхәсле идея!» — дияр. Әмма аларның игътибарын күптән түгел үзәк телевидение аша күрсәтелгән бер Америка фильмына юнәлтер идем мин. «Кызыл кояш» дигән фильмга. Анда япон кешесе белән Америка тибы янәшә куеп тасвирлана да, менә мондый нәтиҗә ясала. Япон кешесе рухи яктан да, физик яктан да көчлерәк, сәламәтрәк! Ул — кеше, шәхес буларак та ышанычлырак, кешелеклерәк! Димәк, безнең язучыбыз да әхлакый эзләнүләрнең дөрес юлыннан бара.

Үткән атнада басылган зур күләмле әсәрләрнең икенчесе шагыйрь Әхмәт Гаделнең «Ут-ялкын» исемле шигъри язмасы. Ул күләм ягыннан шулкадәр озын, газетаның бер битенә генә сыя да алмаган... Ә укылышы ничегрәк соң? Дүрт кисәктән торган бу әсәрнең «Ана монологы» дигәне әйбәт кенә укыла. Улларын югалткан ананың хәсрәте, кайгылы хисләре тирәннән һәм образлы күренешләр аша ачыла. Әсәрнең аһәңе, ритмикасы да үзенчә, сүзләре йөрәккә үтә.

Әмма калган өч өлеш укылмый. Ни өчен? Чөнки аларда моңа кадәр күп әйтелгән фикерләр, язылган хисләр генә кабатлана. Эзлекле рәвештә үсә һәм тыгызлана барган яңа кичереш, яңа идея юк аларда. «Ана монологы» үзе генә басылган тәкъдирдә уңышлы әсәр дип кабул ителер иде дә бит...

Шигъри әсәрләрдән тагын Йосыф Хәнәфиевнең юмористик шигырьләре «Шәһри Казан»ның 30 октябрь санында дөнья күрде. Автор юмор җәтмәсен матур гына үрә, әсәрен җайлап кына, оста гына үстерә. Әмма ул да күләм мәсьәләсендә чама хисен югалта сыман, әсәрләрен шактый озынга суза. Нәтиҗәдә тулаем тәэсир кими, әйтергә теләгән уй-ният тә тоныклана төшә.

Менә без ике авторның шигырьләрен күздән кичердек. Аларны соңгы елларда барган бәхәс фонына куеп карасак, шул ачыклана: шигъри язмаларны дөньяга чыгарганда, без тиешле таләпчәнлек күрсәтмибез, ахрысы. Әнә шуңа күрә байтак кына укучыларда шигырьгә карата «буш сүз» дигән фикер кала. Ә бит чын шигырьләр бер дә андый түгел! М.Әгъләмов, Г.Афзал шигырьләре бер дә буш түгел бит! Димәк...

Фәнзаман Батталның узган атнада басылган ике әсәре дә нәкъ үзенчә. Алар безнең бүгенге яшәүгә усал, ачы сатира! Беренче хикәясен «Социалистик Татарстан»ның 1 ноябрь саныннан карагыз, ә «Әтәчегез күкәй саламы?» дигәнен «Татарстан яшьләре»нең 31 октябрь санында таба алырсыз. Бу авторга берүк күз генә тия күрмәсен! Көлү дигәндә, атаклы Гамил Афзалдан да уздыра бит. Тукайның үзенә үк якынлаша түгелме?!

Ә бүтән юмористлар, сатириклар ни карый? Ярышка бер генә кеше чыгу күңелле түгел бит.

Вакыйгалар...

Үткән атнаның иң күренекле вакыйгасы дип нәрсәне санарга? Татарстан Язучылар берлегендә булган секция утырышынмы яисә Нурихан Фәттахның «Татарстан яшьләре» газетасында (31 октябрь саны) басылган «Каләм кем кулында?» исемле язмасынмы? Әйдәгез, бу хакта бергәләп уйлашыйк.

Язучылар берлегендә хәзер иҗатчыларның секция утырышлары бик сирәк була, шуңа күрә шагыйрьләрнең 1 ноябрь көнне үткән мәҗлесен вакыйга дип санарга да мөмкин. Анда шагыйрь Наис Гамбәровның «Баш очымда — кояш» дигән китабы һәм «Идел» журналында чыккан шигырьләре, әдәби тәнкыйть мәкаләләре, мөхәррирлек эшчәнлеге турында кызыклы сөйләшү барды. Әңгәмәдә күренекле каләм ияләре Әхсән Баян, Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт һ.б.лар катнашты. Наис Гамбәр Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим ителде.

Билгеле булганча, хәзер без Язучылар берлегенә әгъзаларны үзебез кабул итәбез. Мәскәүнең раслаганын көтеп тормыйбыз. Ә элек Мәскәү татар әдибенең кем икәнен беләме-белмиме, раслап яки расламыйча тота иде. Мондый бәйсезлеккә ирешү сыйфатка сукмас дип ышанырга була, чөнки кабул итү комиссиясендә Аяз Гыйләҗев, Фәрваз Миңнуллин кебек «усал» әдипләр эшли.

Ә инде «Каләм кем кулында?» дигән язмага килсәк, биредә әллә ни гаҗәпләнерлек урын да юк кебек. Чынлап та, сүз һәм матбугат иреге яшәгән җәмгыятьтә теләсә кем теләсә нинди шәхес турында үз фикерләрен белдереп чыга ала бит. Бу очракта да Н.Фәттахның Аяз Гыйләҗевкә карата кискен сүз әйтүе аңлашыла, бу — табигый күренеш.

Кайбер укучылар моның ише хәлләрне язучыларның шәхси мөнәсәбәт ачыклаулары дип карый, очрашкан чагында бездән: «Бер-берсендә нинди үчләре бар соң аларның?» — дип сорый.

Шундый теләкләргә, шикләнүләргә җавап бирү дә булыр, хәлгә бераз ачыклык кертеп үтик. Минемчә, биредә төрле яшәү рәвешләре бәрелешә. Бу иҗатчыларның охшашлыгы һәм капма-каршылыгы нәрсәдә соң?

Моңа кадәр без ике әдипне дә татар милләте өчен тырышучылар дип белә идек. Аларның иҗат иткән әсәрләре чыннан да шуны раслый, шуңа ышандыра. Бу — ике әдипне берләштергән як, аларның уртак максаты. Һәм әнә шул яклары белән алар безгә кыйммәт, кадерле.

Ә икенче яктан карасак, шәхес культы һәм торгынлык чорында аларның икесе ике төрле яшәү рәвеше сайлаган, күрәсең. Әнә шул хакта аларның бер-берсенә сүз әйтерлек урыннары бар бугай... Нишлисең, хакыйкатьне яшереп калдыру беркемнең дә көченнән килми шул!

Бары тик шуны гына басым ясап әйтәсе килә: иҗатчылар да, шәхесләр дә бары тик үз милләтеңә хезмәт итү һәм иман ныклыгы, гадел яшәү, намус җирлегендә генә татулык таба ала. Халык хәтеренә керү юлы да әнә шул олы таләпләр аша гына!

Бу — сыналган хакыйкать! Хәйлә кулланып алдый алмыйсың аны! Монысын яшь иҗатчылар да яхшы үзләштерсен иде!

Язучы Диас Вәлиев «Суверенитет» газетасын судка биреп, үзен татар милләтенә каршы куйган иде инде. Үткән атнада ул «Казанские ведомости»да интервью бастырды һәм безнең язмышны бөтенләй аңламавын күрсәтте. Урыс телле язучы болай ди: «И чтобы отвлечь людей от того социального ужаса, который надвигается, нам бросают национальную карту, чтобы наши мозги были заняты этой проблемой». Ягъни, аның уйлавынча, татар теле бетү алдында тормаган, милләт һәммә яктан кысылмаган! Болар барысы да — кемдер уйлап чыгарган проблема, янәсе! Үз халкыңнан аерылу менә бит нинди су-

кырлыкка китерә. Мәктәпләр буенча гына карасак та, башкалабыз Казанда бер генә татар мәктәбе дә юк иде бит әле! Ә Диас Вәлиев моны проблема түгел димәкче! Үзе урысча язуга күчкәч тә, әллә бөтен кеше дә шулай дип уйлый микән ул?!

Бу кеше мисалында без урыс халкының да иң йомшак ягын күрәбез. Үз җилкәләрендә татымагач, алар да безнең проблемаларны бар дип танымый. Шулай шул: әгәр дә суларга һаваң бар икән — аның кирәклеген тоймыйсың, аңа күнегәсең. Бүгенге урыслар һәм урыс теллеләр — әнә шул хәлдә. Кемнәргәдер суларга һава җитмәвен алар башларына да китермиләр!

Шул ук газетадагы Рафаэль Мостафин фикере дә әйбәт тәэсир калдырмый. Тикшерү органнарының игътибарын ул «Иттифак» партиясенә юнәлдермәкче була. Татар милләтен саклап калу өчен көрәшүчеләрне кулга алдырмакчымы әллә ул?

Урыс телле язучылар белән радио аша Эльза Гобәйдуллина тапшырулар алып бара. Һәр тапшыруында диярлек ул «бүленмәс Россия кирәк» дигән фикер үткәрә. Татарстан радиосының башка дәүләткә хезмәт итүе кайчангача барыр икән? Ислам динен сүккән язучы Гариф Гобәйнең кызы әтисе ялгышын кабатлый түгелме соң?!

Әсәрләр...

«Татарстан яшьләре»нең 9 ноябрь санында күренекле әдибебез Барлас Камаловның «Гөнаһ һәм җәза» исемле тетрәндергеч хикәясе басылды. Биредә барысы да бар: ятим калган кыз язмышы да, көчле мәхәббәт тә, явыз кешенең яшь кызны көчләве дә, шуның үчен алу өчен үтерү дә, төрмәгә ябылу да һәм ахырдан кавышу да... Кыскасы, бармактан суырып язылган әсәр түгел, тормышның үзеннән алынган хикәя! Укымый калган кеше булса, һичшиксез табып алыгыз — үкенмәссез! Минемчә, нәкъ менә шундый: әхлакый сабак, гыйбрәт бирә торган әсәрләр безне кеше булырга өйрәтә.

Өлкән яшьтәге автор Касыйм ага Хәмзинның «Социалистик Татарстан»да дөнья күргән (7 ноябрь саны) «Язмыш» дигән хикәясе дә эчтәлек тирәнлеге белән истә кала. Яшьләй ятимлеккә дучар булып, аннары Сак-Сок кебек гомере буе аерым яшәгән туганнар тәкъдире нык тәэсир итә. Моның ише язмалар кешеләрне бер-берсенә карата һәм, гомумән, тормышка игътибарлырак итә.

Менә шушы ике әсәр яшьрәк буын иҗатчыларны да әдәбият серләре турында тагын бер кат уйландырыр кебек. Кешеләрнең үзәгенә үткән, аларның язмышларында зур-зур борылыш ясаган драматик вакыйгалар безнең яшь авторларыбыз әсәрләренә кыюрак үтеп керер дип ышанасы килә. Әнә шул чагында әдәбиятның әһәмияте тагын да арта.

Әмма әле генә искә алган мактаулы газетабызның шул ук 7 ноябрь саны Рәмзи Ногъмани дигән иптәшнең «Безнең юл» исемле язмасын шигырь дип тәкъдим итә. Әлбәттә, анда дөрес фикерләр әйтелә, иптәш үзе дә милләт өчен тырышып йөри. Ләкин бит бу язма шигырьгә якын да килми! Поэтик әсәргә куела торган иң гади таләпләргә дә җавап бирә алмый ич ул! Җитмәсә, әле беренче биттә үк бирелгән, күзгә иң ташлана торган урында.

Ә менә Шамил Маннаповның «Бүре хәйләсе» дип аталган мәсәлен «Социалистик Татарстан» 5 ноябрь санында урнаштырган. Биредә бүгенге көн өчен гаять тә үткен эчтәлек бар. Ул мәгънә мәсәлнең беренче юлларыннан ук шәйләнә:

— Сарык көтүенә башлык итеп калдырсагыз,
Бүрелегемне ташлар идем»,—

дип әйтте ди Бүре.

Таныйсызмы боларның кем икәнлекләрен? Аңлыйсызмы моның нинди хәлләргә киная икәнен? Шулар бит инде — безнең кичәге юлбашчыларыбыз — ул Бүре дигәне. Алар элегрәк партия башында торып, «бердәнбер дөрес юлдан барабыз» дия-дия, безне бүгенге тупикка алып килделәр. Хәзер инде юлның тупик икәне бөтен кешегә ачык булып аңлашылгач, алар партия дигән калканны ташлап, яңадан да власть башына менеп кунакладылар... Бу — ерактагы Мәскәүдә генә түгел, үзебезнең Казанда да, район үзәкләрендә дә нәкъ шулай булды!

Тик менә шушы бик тә үткен әсәрне газета ни өчендер яшереп кенә, «Мең дә бер кичә» дигән борынгы исемгә төрелгән вак-төяк мәзәкләр арасында гына бирә! «Укучы күрмәсен иде» дигән шикелле генә!

Ә бит егерменче елларда безнең газеталарыбыз моның ише үткен әдәби әсәрләрне иң беренче биткә урнаштырганнар! Шуның белән газетаның да, әдәбиятның да тәэсирлелеге, сугышчанлыгы, ахыр чиктә көче билгеләнгән!

Укучы буларак та, әдәби тәнкыйтьче буларак та, хөрмәтле газетабызны мин кыюрак булырга чакырыр идем. Тормыш хакыйкате халыкчан матбугат өчен төп юнәлеш булырга тиеш!

Газетабызда даими рәвештә бирелә башлаган «Әдәбият хәлләре» турында байтак кына укучылар үз фикерләрен язып җибәргәннәр. Телефоннан һәм күрешкәндә әйтүчеләр дә шактый булды. Бөгелмә шәһәреннән Сәлах әфәнде Шәриф болай дип яза: «Аянычка каршы, язучылар белән укучылар арасында

шушы бик кирәкле бәйләнеш юк. Һәрбер әдәби әсәр меңләгән укучы өчен языла бит. Шулай булгач, теге яки бу әсәр турында газета-журнал битләрендә укучылар белән фикер алышу бик тә зарури... Мин әдәби әсәрләрнең ышандыру көченә ия булганнарын хөрмәт итәм...» Бу әфәнде бик фидакарь җанлы кеше икән: үз хатында ул үгетләп байтак кына дусларын «Шәһри Казан»га яздыруын да әйткән. Менә шундыйлар милләтебездә күбрәк булсын иде! Икенче хатында Сәлах әфәнде Фәрит Гыйльминең «Зәйтүнәкәй, акчарлагым» хикәясенә җентекле анализ ясаган, анда уңай яклар белән бергә байтак кына җитешсезлек тә (мәсәлән, геройларның фамилияләре буталу һ.б.) тапкан. Үзебезнең әдәби газетабыз булса, әлеге авторның мәкаләсен тулысынча да баскан булыр идек тә бит...

Казаннан Миңлегөл апа Рәфыйкова да безгә бик җентекләп язылган хат җибәргән. Ул Фәнис Яруллин, Фәүзия Бәйрәмова, Әбрар Кәримуллин әсәрләрен яратып укуын хәбәр итә. Аннары язучылар тормышына кагылган бик җитди сораулар куя. Безнең киләсе очрашуларда алар да чагылыш табар.

Вакыйгалар...

Узган атнада булган яңалыклардан кайсы бигрәк тә мөһим икән? Мөгаен, татарча яшь тамашачылар театрын булдыру турындагы карардыр. Урыс телендә спектакльләр куючы мондый театр — ТЮЗ — Казанда инде күптән бар иде. Безнең балаларны милли сәнгатьтән биздерү буенча ул актив эшләде. Ә менә хәзер яшьләр өчен үзебезнең театр булачак! Милләтнең киләчәк язмышына бик тә нык тәэсир ясаячак факт бу. Соңга калмыйча, тизрәк кенә ачыла күрсен иде!

Әһәмияте ягыннан тагын да ныграк игътибар сорый торган проблема — Республика китапханәсенең язмышы. Үткән атнада күп кенә галимнәр һәм язучылар кул куйган мөрәҗәгать матбугатта басылды. Чыннан да, безнең меңләгән еллар буена җентекләп тупланган хәзинәбез юкка чыгу алдында тора икән! Хөкүмәтебез комсомол бинасын тулысы белән китапханәгә бирсә — бүгенге тормыш таләбе үтәлер иде. Күпмеңләгән укучылар шулай булыр дип ышана!

Сүз уңаенда язучы Разил Вәлиевнең китапханәне коткару өчен чын мәгънәсендә егетләрчә көрәшүен укучыларга әйтеп үтәргә кирәк. Директор булып ул эшли башлагач, шул юнәлештә зур-зур адымнар ясалды. Үткән атнада китапханәгә «милли китапханә» статусы да бирелде. Белүемчә, болай дип аталуның безнең өчен уңай яклары бар. Шуны ачыклап бетерү өчен, бәлки, газета хәбәрчеләре Разил Вәлиевтән интервью алыр.

Күренекле галимебез Марсель Әхмәтҗанов та узган атнада мәдәниятебезнең гаять үткен мәсьәләсен күтәргән кайнар рухлы мәкалә белән «Социалистик Татарстан»ның 7 ноябрь санында чыгыш ясады. Чыннан да, татар әдәбияты һәм сәнгате җәүһәрләре тупланган махсус музей кирәклеге инде көн кебек ачык. Әмма республикадагы шовинистлар моңа төрлечә аяк чалалар. Элек КПССның политик мәгариф йортында эшләгән Муханов дигән бәндә моңа иң нык каршы төшүче икән... Менә шуннан соң уйлап кара инде син ике милләт арасындагы мөнәсәбәтләрне кем кыздырганын! Гомумән, Казан һәм республика мәктәпләрен алсак та, шундый хәл күрәбез: теге милләт вәкилләре югары урынга яисә директор постына менеп кунаклаган да, татар мәктәбен ачарга һич кенә дә теләмиләр. Шуннан соң инде «мәгарифне һәм мәдәниятне ике тармакка аерырга кирәк» диючеләрнең сүзенә дә ышанмыйча булмый. Тегеләрнең милли эшкә таяк тыгулары мәңге дәвам итәчәк бит ул!

Вакыйгалар дигәндә, әйтмичә үтү һич тә мөмкин булмаган яңалык: «Татарстан яшьләре» үзенең 7 ноябрь санында татар шагыйрьләре парадын оештырган. Дөресрәге, аны Госман Садә төзегән. Торгынлык елларында безнең шагыйрьләр Ленинны, Октябрьне мактап нәрсә генә язмаган икән! Бу парадның исеме генә дә ни тора — «Ленин бабай юл сызмаса, бу көнне күрмәс идек!» Кеше көлдергеч парадта бик күп авторның әсәрләре кергән... Нишлисең, барыбыз да ышандык шул. Тышкы дөньядан хәбәрдар булмыйча, бары тик юлбашчылар авызына гына карап яшәгәч — шулай килеп чыга инде ул! Бөтен дөнья алга таба атлаганда, без, «бердәнбер дөрес юл — безнеке!» дип, киregә таба киткәнбез икән шул... Сүз һәм фикер иреге булмаса, буйсыну һәм ялагайлык кына тантана итсә — һәр урында, һәр кешене әнә шундый кызганыч язмыш көтүен истән чыгармасак иде без!

10 ноябрь көнне, бәйсезлекне яклап, митинг узды. Халык күп иде. Мәгънәле һәм үткен чыгышлар байтак булды. Милләтебезнең күренекле шәхесе, җырчы Вафирә Гыйззәтуллина исә ялкынлы итеп сүз дә әйтте, җырлап та бирде. Без кечкенә чакта җырлап үскән «Туганнар, тыңлагыз, кушылып җырлагыз» дигән әсәрне бүгенге көн таләпләренә яраклаштырып башкару сөекле артистканы халык йөрәгенә тагын да якынайтты.

Халык арасында депутатлар турында сүз күп йөри. Алар митингта да байтак әйтелде. Ризасызлык сүзләре болар. Ә депутатлар үзләре «эшлибез» дип ышандырырга тели. Бәлки, аларның һәрберсе газета битендә язып чыгар? Сайлаучыларның гозерен үтәү буенча нинди адымнар ясалганы матбугат аша халыкка ирешсә, шикле сүзләр тумас иде бит! Бүгенге көнгә иң демократик булган газеталар шушы эшне кузгатса, милләткә файда гына килер кебек. Матбугат фикер алышу урыны ич инде ул!

Әсәрләр...

Үткән атнада «Ялкын» журналының 10 саны дөнья күрде. Бусында безнең язучылар бигрәк тә актив катнашкан. Флүс Латыйфиның тарихи әсәре, Рафаил Газизовның хикәясе һәм Гәрәй Рәхим белән Солтан Шәмсинең мәкаләләре — һәммәсе дә кызыксынып укыла. Ә менә Мөдәррис Әгъләмовның «Белмисездер әле сез...» дигән шигыренә аерым тукталырга да була. Бер караганда, бу әсәрдәге әби сәеррәк тә кебек: башта ул, мал-туарым, кош-кортым бар, дип, шәһәргә, малайлары-оныклары янына күчмичә йөдәтә; ә аннары, шәһәргә килеп таш читлектә яши башлагач, үзе сыман карчыклар белән Азатлык мәйданына йөрергә ияләнеп китә... Өйдәгеләр исә берни аңламый!

Шагыйрьнең фикере бик ачык: әлеге әби кебек табигать белән бер сүздә яшәгәндә генә, үз милләтеңнең иң матур гореф-гадәтләренә тугры калганда гына, иманны һәм азатлыкны югалтмаганда гына безнең юлыбыз уң булачак! Әлеге идея үтә тормышчан да һәм сәнгатьчә дә яңгырый. Яшь буын күңеленә әнә шулай дөрес юлны индерә ул.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Тарих сакалын юа» исемле истәлеге («Социалистик Татарстан») 15 ноябрь зур вакыйгалар шаһиты булган шәхес турында. Чынлап та, язмыш безне кемнәр белән генә очраштырмый бит! Һәр чагында да күңел күзебезне ачып карыйбызмы соң без аларга?! Әдипнең бу әсәрен укыганнан соң да үз күңелеңнең баеганын, тирәнәйгәнен сизәсең.

Шул ук санда Барлас Камаловның күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзи иҗатындагы ак тапларга багышланган язмасы да мавыгып укыла. Биредән кызыклы яңа мәгълүматлар табасың. Әсәрләрнең шомартылган урыннарын күреп шаккатасың!

Ә менә «Татарстан яшьләре»нең 14 ноябрь санында безне Фәнзаман Баттал тәмам гажәпкә калдыра. Ул үзен Казан ханнарының бер варисы дип игълан итә! Чыдасаң, чыда, чыдамасаң, юк! Ләкин хикмәт шунда: сатирикны болай ачы итеп көләргә бүгенге урыс патшалары мәҗбүр иткән икән. Алар бит элеккеге Россия монархларының варисларын чакырып кайтара башлаганнар! Юк әле, Фәнзаман Баттал күршеләрне генә тәнкыйтьләп калмый. Алай булса, ул Баттал була димени?! Үзебезнең лидерларга да каты гына эләгә анда. Хәтта президентны оялтыр, кызартыр урыннар да бар... Шулай булмыйни: аның өчен без кызарабыз бит! Әнә Хасбулатов та сөенә — сезнең лидерларыгыз юк! ди. Бусын ул да дөрес әйтә шул...

Гәрәй Рәхим белән Әхәт Гаффар ярышына килсәк, сүз аларның 13 ноябрь көнне чыккан «Кытык» дигән памфлеты турында бара. Чыннан да, биредә боларның кайсы җиңгән соң?

Иң элек бу язманың нәрсә турында икәнен ачыкларга тырышыйк әле. Байтак кына күләм биләгән әсәрдә ниндидер билгесез Шүрәлеләр җөмһүрияте хакында сүз бара. Баштан ахыргача һич мәгънәсе күренмәгән юк-бар җөмләләр сырлана... Шулай итеп, укыйсың, укыйсың... Әмма берни дә аңлашылмый һаман... Ләкин ниндидер таныш нәрсә дә чагыла сыман үзе. Шулай шактый азаплангач кына төшенеп аласың, «Ә-ә-ә...— дисең,— бу бит Әхәт Гаффарның әнә шундый аңлап булмый торган памфлетларына пародия икән ич!» Ул бит әнә шундый: нәрсә хакында язганлыгы һич тә аңлашылмый торган әсәрләр «иҗат итә». Әйе, биредә, һичшиксез, Гәрәй Рәхим җиңгән. Республика һәм милләт язмышын хәл иткән чорда әнә шундый тозсыз боламыклар ясаучыдан ачы итеп көлгән ул! Биредә, «Кытык» дигән бу памфлеттан, бары тик әнә шундый нәтиҗә генә килеп чыга ала.

Ләкин безгә, укучыларга, хәзер тагын шунысы кызык: Әхәт Гаффар да тапкыр һәм матур итеп җавап бирә алырмы? Әгәр дә иҗат мәйданында аның ягыннан да оста һәм үткен җавап була икән, алдагы очрашуларда без анысына да игътибар итәрбез дип уйлыйм.

Ә шулай да безнең чынбарлыкта чын шигърияткә дә урын табыла икән әле. «Татарстан яшьләре» үзенең 14 ноябрь санында фотоэтюдлар янәшәсендә бер бик матур шигырь биргән. Авторы Флюра Низами.

Инде күмде дисәң фәкыйрьлекне,
Таң атуга чыга җир карасы.
Эремә, кар! Өй син чиста көртләр,
Гүзәллеккә килә алданасы...

Тормыш авырлашып киткән елларда шигъриятнең көчәеп китү гадәте бар. Мондый вакытта кешеләрнең күңелләре нечкәребрәк, сизгерләнебрәк кала кебек...

Вакыйгалар...

Үткән атнада яңа ел өчен газета-журналларга язылуның якынча нәтиҗәләре мәгълүм булды. Байтак кына басмалар узган елгы дәрәҗәдән бер дә ким күренми. Мисал өчен безгә «Татарстан яшьләре» белән «Казан утлары»ның якынча былтыргы күләмдә чыгачагы мәгълүм. Хәзерге авыр чорда бер дә начар түгел бит бу, җегетләр! Милләтебез фидакарьләренә рәхмәт әйтәсе килә. Шулай бергә-бергә булсак, алга таба да эшебез уңар дип ышаныйк.

Республиканың бәйсезлеге өчен көрәш үткән атнада да дәвам итте. Россия прокурорларының Казанга килүенә каршы һәм чечен халкын яклап, митинглар узды. Язучыларыбыз бу көрәштә актив катна-

ша диярга була. Әмир Мәхмүтов — «Суверенитет» комитетын җитәкли, Зәки Зәйнуллин Мәржани исемендәге җәмгыятьтә зур эш һәм көрәш алып бара. Ә шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның ялкынлы шигырьләре тыңлап торган бер генә кешене дә битараф калдырмый.

Халык массалары белән эшләү буенча һәм шулай ук матбугатта катнашып, бүтән каләм ияләре дә изге көрәшкә үз өлешләрен кертсеннәр иде. Халык белән аралашуның әле бер генә иҗат кешесенә дә зыян иткәне юк! Урыслар «толпа» диеп кенә атасалар да, мәйданга безнең милләтнең иң актив, иң фикерле һәм кыю вәкилләре җыйнала. Сез анда, бәлки, үзегезнең булачак геройларыгызны да табарсыз әле, хөрмәтле каләм ияләре!

Ә КГБ турында язучы Мөхәммәт Мәһдиев әйткән сүзләрне сез «Татарстан яшьләре»нең 16 ноябрь саныннан таба аласыз. «Явызлык фәрештәсе җилкәдән төшкәндә» дигән язмада шымчылык итүчеләрнең нинди генә кара эшләре ачылмаган! Әле бит әдип бер генә кеше — Фәхрислам Агеевның язмыш җебе буенча гына эзләнгән. Никадәр әләк, тырнак астыннан кер эзләү, һәммә җирдә күзәтү... Пычрак эш, пычрак алым!

М.Мәһдиев үз язмасын болай бетерә: «Ә безнең заманга килсәк? Безнең турыдагы дәфтәрләрне ачсак, гажәеп бер хәлне күрер идек. КГБ архивын тулысынча ачыйк, бер-беребезнең күзенә туры карап сөйләшик. Мин анда безнең зыялылар турында ниләр барын чама белән беләм...»

Бу язучының менә шушы сүзләренә җавап биргән кебек, «Казан утлары»ның укучыларга әле яңа гына килгән октябрь санында Гурий Тавлин үзенең «Афәт» исемле романын бастырды. Вакыйгалар Сталин хакимлек иткән чорда — илленче елларда бара. Геройлары — Бөек Ватан сугышында гитлерчыларны җиңеп кайткан яшь егетләр, хәзерге студентлар. Әмма зур уйлар, якты өметләр белән йөргән намуслы яшьләр төрмәгә килеп эләгә. Язучы Мәҗит Рафиковны да, бу роман авторы Гурий Тавлинны да бер үк кеше саткан. Әсәрдә аның исеме Риан дип бирелә. Игътибар белән укыган кешеләр бу типның кем икәнлеген бик яхшы белер дип уйлыйм. Сүз бүген дә исән булган, зур-зур дәрәҗәләргә ирешкән язучы турында бара. Шушындый эшләре билгеле булгач, без хәзер аның язганнарына ничек каргага тиеш икән соң?!

Журналның шул ук санында без Нәзифә Кәримова дигән яңа автор белән дә очрашабыз. «Карурманнан чыккан юлчылар» дигән кыйсса бер сихри поэма сыман укыла. Авторның каләме өметле булу хакында сөйли. Талантлы яңа әдип белән очрашу шулай ук зур вакыйга бит инде ул! Хәзер инде без Н.Кәримованың бүтән әсәрләрен көтеп торачакбыз, газета-журналлардан аның исемен эзлиячәкбез!

Элеккеге очрашуларда язучыларның әдәби газетасы хакында сүз барган иде. Соңгы яңалык шул: булачак бу басма «Әдәби җомга» дигән исем белән теркәлде. Димәк, газетабызның исеме «Әдәби җомга» булачак. Инде хәзер аның беренче саны чыкканны көтәсе генә калды! Башланган эшләрнең тиз башкарыла торган чагында яшибез, шуңа күрә әдәби газета да озакламас дигән өмет зур!

Әсәрләр...

Әйе, узган атнада әдәби әсәрләр байтак кына чыкты. Минем үземне бигрәк тә яңа исемнәр җәлеп итте. «Татарстан яшьләре»нең 19 ноябрь санында яшь шагыйрь Азат Мәрдәнов болай дип яза:

Булмас инде еллар аша гына
Яшьлек учагыннан ут алып.
Болыннарны урап кайтыйм дигәч,
Ярты юлда калам тукталып...

Аның бүтән шигырьләрендә дә тормышны тирән тою һәм үзе тойганны укучыга хисле итеп җиткерә алу бар. Бу яңа авторга иҗади кыюлык, тынгысызлык телисе килә. Йөрәк хисләреңне тагын да тулырак ач, Азат!

Ә Резидә Әхтәмова шигырьләре «Социалистик Татарстан»ның 22 ноябрь санында Фәнис Яруллин кереш сүзе белән бирелгән. Чыннан да, биредә укучы яңа шигъри аһәңнәр, үзгә образлар белән очраша. Бер шигырьдә хатын-кыз күңеле болай ачыла:

Син килдең.
Юк, син килмәдең —
Җылы яңгыр килде.
Күк күкрәде.
Яшен чәчкән очкын
Бәгыремә тиде.

«Әллүки» санының бүтәннәренә караганда кызыклырак чыгуын да билгеләп үтәргә кирәк. Әмиржан Моталлаповның «Әфләп абзый мәзәкләре» рәхәтләнеп укыла. Бу каләм иясе үз әйләнә-тирәсендә очраган көлкеле күренешләрне оста тотып алган, аларны кыска гына, ләкин укучыны рәхәтләндереп көлдерә торган итеп яза алган. Тик нигәдер аның әсәрләре матбугатта сирәк күренә. Мондый тормышчан юмор безгә бик тә җитми бит.

Күренекле шагыйребез Кадыйр Сибгатуллинның яңа шигырьләр бәйләмен газетабызның 22 ноябрь санында күреп тә бик сөендек. Шагыйрь үзенең чордашлары турында хикмәтле сүзләр әйтә, үз күңеле-

нең тирәндәге катламнарына алып керә. «Көннәр безгә, шөкер, буш килмиләр... Уйландырмый гына китмиләр». Бүгенге тормышта хиссез-җансыз яшәүче «ясалма» кешеләргә игътибар иттерүе дә бик вакытлы һәм кирәкле адым буларак кабул ителә.

Менә шушындый үткен һәм тирән эчтәлекле шигъри әсәрләрне укыйсың да, аларның ничектер эссез генә үтеп китүенә эч поша башлый. Ниндидер бер бик кирәкле көч, энергия әрәм була, исраф ителә кебек. Җәмгыять, милләт өчен ифрат та кадерле күпме эстетик кыйммәт, әхлакый сабак һәм социаль тәжрибә бит аларда! Берәр нәфис сүз остасы радио яки телевидение аша шундый тапшырулар циклын башлап җибәрсә, ничек әйбәт булыр иде бит, ә?! Шигъри әсәрне уку һәм тулы итеп аңлау турында бик кызыклы дәрес сыман булыр иде бит ул тапшырулар... Шуның берәр остасы табылмас микән?

Чит илдә вафат булган зур язучыбыз Гаяз Исхакыйның яңа әсәрләре укучыга кайта тора. Газетабызның 19 ноябрь санындагы «Калуш» дигән хикәя бүгенге юмористлар өчен менә дигән үрнәк булып тора. Кешенең аяк киеменә бәйле бер очрактан никадәр мәгънә һәм көлке таба оста әдип! Бу хәлләр безнең бүгенгебезгә дә киная түгелме соң әле...

Вакыйгалар...

Газеталарда урнаштырылган мәкаләләрнең кайнарлыгы торган саен арта бара. Узган атнада бу тенденция бигрәк тә ачык чагылды. Ләкин үткән атнаның иң кайнар язмасы итеп, һичшиксез, Айдар Хәлимнең «Вечерняя Казань»га багышланган ачык хаты саналырга тиеш. Ул «Социалистик Татарстан»ның шимбә көнге санында дөнья күрде. Аның әһәмияте нәрсәдә соң? Хатта әлеге газетаның татар милләтенә каршы тоткан юнәлеше күпсанлы мисаллар белән раслана, бу юнәлешнең ызгыш чыгару һәм дошманлык куертуга йөз тотуы ачыла. Гуманизм һәм кешелек нормаларын төп нигез итәргә чакыру бар анда. Айдар Хәлим үзенең бу ялкынлы әсәре белән безнең байтак публицистларыбызга үрнәк күрсәтте. Уфада Башкортстан татарлары өчен көрәшкән әдип инде хәзер Татарстандагы татарларны да якларга мәҗбүр. Калган язучыларга, бигрәк тә милли мәсьәләдә дәшми торучыларга, иң беренче чиратта үз иминлекләре турында уйлаучыларга оят түгелме икән?

Күренекле язучыбыз Рафаэль Мостафин «Шәһри Казан»ның 23 ноябрь санында милләтебезнең сөекле кызы һәм иҗтимагый эшлеклесе Фәүзия Бәйрәмованы сүгеп чыкты. Аның мәкаләсе «Халыкларны мөгезгә-мөгез сөзештерү кемгә кирәк?» дип исемләнгән, һәм бу исемдә авторның позициясе дә ачык чагылган. Янәсе, Фәүзия Бәйрәмова безне урыслар белән бәрелешкә кертә. Хәзер, әйдәгез, бергәләп уйлап карыйк.

Иң башта бүгенге хәлне күрик. Бүген татар милләте белән урыс милләте — икесе ике биеклектә, ике баскычта тора. Урысларның мәктәпләре дә бик күп, телләре дә югалу алдында түгел... Ә татарның мәктәпләре дә юк дәрәҗәсендә, телләре дә югалу мөмкин... Димәк, элементар гуманизм таләп иткәнчә, бу милләтләр тигез булырга тиеш! Фәүзия Бәйрәмова һәм башка фидакарьләр бары тик әнә шуны гына тели. Бары тик тигезлек кенә сорый алар!

Казанда милли мәктәпне торгызу процессын бик яхшы белгәнгә күрә, татар матбугатына урысларның карашын белгәнлектән мин бик күп мисаллардан чыгып әйтә алам: урыслар бу тигезлекне теләмиләр! Безгә тигез хокук бирергә теләмиләр!

Илебезнең башка республикаларында барган хәлләргә генә күз салыгыз. Анда яшәүче урыслар төп милләтнең хәлен аңлыймы соң? Юк, аңламыйлар! Алар бары тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта. Балтыйк буе дәүләтләре тәжрибәсе дә, Молдова һәм Казахстан да шуны раслый.

Димәк, без бүген шундый нәтиҗәгә киләбез. Олы туган бер генә урында да кече туганнары белән тигез булырга теләми. Менә эшнең асылы нәрсәдә, иптәш Мостафин! Олы туган иң гади кешелек нормаларына каршы бара — тигезлектән курка!

Шулай булгач, безгә тигезлек таләп итүдән туктаргамыни инде?! Юк, гадел көрәш туктый алмый! Сез зур закончалыкны күрмисезмени соң: башта бездән социалистик илләр китте, аннары союздаш республикалар китте, хәзер РСФСР таралып ята... Димәк, һәр милләтнең бүтәннәр белән тигезләнү, азатлык алу процессы бара. Моңа каршы килү — тарихка, тормышка каршы бару дигән сүз ул!

Рафаэль Мостафин мәкаләсе уңаеннан тагын шуны әйтәсе килә. Безнең урыс телендә язучы әдипләребез нәкъ урыс кешеләре төсле фикерлиләр икән. Татарның үзәгенә үткән мәсьәләләр аларга һич тә аңлашылмый икән. Шунлыктан алар безнең ни өчен борчылуыбызны, нәрсә өчен көрәшүебезне дә төшенә алмыйлар. Ул көрәшкә бары тик каршы як күзлегеннән генә карый алалар. Гуманизм таләбен — тигезлек кирәклеген алар һич кенә дә төшенми. Әллә, урысча язучы буларак, үз язмышлары өчен борчылалар инде?!

Үткән атна усал мәкаләләргә бай булды, дип әйткән идек. Шагыйрь Роберт Миңнуллинның «Татарстан яшьләре» газетасында басылган «Торгынлыкның соңгы бастионы» исемле язмасы (21 ноябрь саны) әнә шундыйлардан. Биредә Татарстан Язучылар берлеге эшчәнлегенә бәйле берсеннән-берсе үткен мәсьәләләр куела. Ул күп яктан шагыйрь Ркаил Зәйдулланың элегрәк «Шәһри Казан»да басылган белдерүе белән аваздаш та яңгырый. Без әле кайчан гына: «Татарстан Язучылар берлеге кирәкме?» ди-

гән сорау тора алмый, без Мәскәүдәге язучылар сыман икегә бүленә алмыйбыз, дип сөйли идек бит... Мәскәү дулкыннары безгә дә килеп җитә, күрәсең. Әмма, Роберт Миңнуллин әйткәнчә, милли-демократик көрәшне җитәкләүче ижади оешма буларак, Язучылар берлеге кирәк иде бит әле!

Соңгы яңалык итеп шуны да әйтеп китик: «Комсомольская правда»ның 15 һәм 19 ноябрь саннарында Татарстанның азатлыгы турында әйбәт мәкалә басылды. Е.Лосото дигән журналист безнең хәлне аңлап, белеп язган.

Әсәрләр...

Үткән атна дәвамында татар газеталары бер генә хикәя дә урнаштырмады. Моны ничек аңларга? Язучылар арасында бу жанрның хәлләре хөрти булу турында сүзләр күптән йөри иде инде, начар фараз кылу әллә чыннан да дөрескә чыктымы соң? Югыйсә кыска күләм били торган хикәя жанры бүгенге тормыш өчен бик тә кулай алым бит. Әллә инде безнең әдипләребез тыгыз итеп, югары сәнгатьчә яза алу осталыкларын жуйганнармы соң?

Әйе, хәзер күләм артыннан куу чире бик көчле.

Ләкин моның күренеп үк торган зур гына сәбәбе дә бар. Нинди сәбәп? диярсез. Сәбәбе шул — безнең илдә һәм шул исәптән барлык татар матбугатында да, авторларга бары тик күләм буенча гына түләнә. Сыйфат ягына беркемнең дә исе китми! (Укучы белән тәнкыйтьчедән кала.)

Ә бит кеше хезмәтенә гадел рәвештә түли торган редактор кайсыбер очракта хикәягә дә повестька түләгән кадәр гонорар түли алырга тиеш! Чөнки кыска хикәянең чын кыйммәте озын повестьныкыннан бер дә ким булмый! Ләкин безнең газета-журналлар да, хәтта китап нәшрияты да, сыйфатка карап түләмиләр. Кыска жанрның тернәкләнеп китә алмавына бик зур сәбәп менә шул. Менә шушы хәлне үзгәртмәсәк, без никадәр генә зарлансак та, хикәя жанры алга китмәячәк.

Ә публицистика өлкәсендә әдипләребез торган саен активлаша бара. Мәскәүдә эшләүче профессор Әгъдәс әфәнде Борһанов белән язучы Марсель Гали әңгәмәсе мавыгып укыла. Биредә фикер генә түгел, ә чын мәгънәсендә көчле булган галимнең, шәхеснең язмышы да чагыла. Иман өчен күпме кыенлык күрү, әмма сынмау үрнәге анда! Менә шундый кешеләр әдәби әсәр өчен каһарман була алмыймыни?!

Зиннур Хөсниярның «Әллүки» санында урын алган кайнар сүзе бик гыйбрәтле күренеш белән башланып китә. Ике малай дус булганда, аларга усал эт тә ташлана алмаган, ә инде юллары аерылгач — әлеге эт аларны чынлап талый башлый! Менә сезгә сабак, менә сезгә гыйбрәт!

Шушы ук теманы язучы Альберт Хәсәнов та дәвам итә. Төрки республикалардан килгән кунакларга бездә игътибар булмау борчый аны. Чыннан да, бу безнең бик тә авырткан җиребез. Татарстан Язучылар берлеге үткәргән съездларга килеп, ничәмә-ничә әдип безгә, безнең язучыларга, безнең халыкка бик нык үпкәләп китте бит. Моның мисалларын күпләр белә. Ләкин шунысы гажәп: моңа җитәкчеләрдән беркемнең дә артык исе китмәде. Шуңа күрә әле һаман хәл дә үзгәрмәде! Казан төрки республикалардан килгән кунакларны әле һаман үпкәләтә тора! Ә үзебез «алар хәзер безне санга сукмыйлар» дип йөргән булабыз... Сүз кузгалгач, әйтеп китик: язучы Тәүфикъ Әйди Казахстан белән ике араны җылыту буенча күпмедер адым ясаган иде, ләкин ижади берлегебез ул адымнарны дәвам итмәде шикелле... Ә кирәк иде. Дөнья шуңа бара!

Мөхәммәт Мәһдиевнең Ибраһим Салахов юбилее уңаеннан уйлануы да ачы тойгылар уята. Нишләп без шундый соң? Моңа кем гаепле? Эшләр кайчан үзгәрер икән? Күңелдә әнә шундый үткен сораулар кала.

Әйе, сораулар күп, бик күп. Тик аларга җавап бирергә теләүчеләр генә күренми.

Танылган юмористыбыз Камил Кәримовның исеме моңа кадәр газета битләрендә сирәк күренә иде. Үткән атнада ул берьюлы ике әсәр бастырды. «Социалистик Татарстан»дагы (29 ноябрь) «Ирек базары...» без күпме еллар табынган юлбашчының гап-гади адәм икәнлеген искә төшерә. Шуның белән әсәр безнең күңел күзен ача, эш-гамәлләрдә кыюрак һәм егетләрчәрәк булырга куша. Ләкин бераз гына кыскарак булса, әсәр тагын да отмас иде микән?

Узган атнада тагын «Татарстан» журналының 10 саны чыкты. Рафаэль Мостафин җитәкләгән бу журналда Фәүзия Бәйрәмова белән әңгәмә дә бар. Әйбәт һәм үткен әңгәмә. Башка язучылар да актив катнашкан. Журнал бик әйбәт юнәлеш тапты. Аңа тагын да зуррак уңышлар телик!

Вакыйгалар...

Үткән атнада, төгәлрәге 27 ноябрь көнне, Язучылар берлегенең идарә утырышы булып узды. Шагыйрьләр Ркаил Зәйдулла һәм Роберт Миңнуллиннарның матбугаттагы чыгышларыннан соң кайберәүләр бу утырышны бик кызу үтәр дип фараз кылган иде, ләкин ул, гадәттәгечә, тыныч шартларда узды. Ижат берлегенә 6 яңа әгъза кабул ителде. Чаллы җитәкчесе Рахмай Хисмәтуллин үзләрендә яңа авторлар күп булуны, аларның озак еллар дәвамында әгъза итеп алынмавын зарланып сөйләде. Аңа җавап биргәндәй, көн тәртибенә 3 татар, 3 урыс язучысын кабул итү куелган. Җитмәсә әле кабул итү комиссиясе рәисе Аяз Гыйләҗев та: «Мин ижади берлегебездә урыс әдипләре күбәюгә сөенәмен!» — дип әй-

теп ташлады. Моны ничек аңларга икән? Россиянең һәр өлкәсендә әнә шулай безнең кебек: 3 урысны, 3 татарны алалармы соң?! Юк бит! Әлеге күрше милләт авторлары сәләт ягыннан да безнекеләрдән өстен түгелләр кебек. Алайса, эш нәрсәдә соң?

Мәдәният үзәгендә Сибгат Хәкимнең юбилей кичәсе бик тантаналы узды. Аңа Уфадан Нәҗар Нәҗминең килүе нур өстенә нур өстәде. Укылган яңа шигыре дә бик үткен һәм тирән эчтәлекле иде. Дөрес булса, олы шагыйребез Сибгат Хәкимгә багышланган тантаналы кичә әле зуррак күләмдә дә үткәреләчәк, диләр. Хәзерге шартларда мондый әдәби бәйрәмнәр бик кирәк шул.

Сүз уңаенда әйтеп китик: Казан мәктәпләрендә «И туган тел» дигән очрашулар уңышлы гына бара. Әдипләребез һәм сәнгать осталары татар балалары белән шигъри әңгәмәләр үткәрә, күңелләр арасында рухи элемтә урнаштыра. Теләге булган язучыларга мәктәп ишекләре ачык. Эшне Язучылар берлегенең пропаганда бюросы мөдире Рәфкать Кәрами оештыра.

Язучы Фәнис Яруллинның исеме безнең һәммәбезгә яхшы таныш. Аның әсәрләре газета-журнал битләрендә еш басыла. Китаплары да безнең кулга эләгү белән тиз арада укып та чыгыла. Кыскасы, Фәнис Яруллин — яраткан язучыбыз, иң актив язучыбыз!

Сез аның нинди хәлдә язуын беләсез булыр. Совет Армиясе инвалиды булып, урын өстендә бер кыймылдый алмыйча ята ул. Әле җитмәсә, узган ел алар җәмәгате Нурсөя ханым белән юл һәлакәтенә дә очрадылар. Үз машиналары бөтенләй яраксыз хәлгә килде.

Быел менә Татарстан Язучылар берлегенә 5 җиңел машина бүленгән. Аларның берсе инвалид язучы Фәнис Яруллинга бирелер микән? Әллә инде ул машиналар башка язучыларның балаларына булырмы? Шәфкатьлелек, гаделлек җиңсә яхшы булыр иде, билгеле.

Тагын бер яңалык итеп шуны билгеләп үтәсе килә: шагыйребез Илдус Гыйләҗев газетаның үз хәбәрчесе булып эшли башлаган! Димәк, «Шәһри Казан»да кызыклы, тирән эчтәлекле, үткен язмалар тагын да күбрәк булачак. Аның беренче мәкаләсе күңелдә канәгатьлек хисе калдыра. Чыннан да, безнең республикада торгынлык чоры исемнәрен үзгәртү буенча кыл да кыймылдатучы юк бит! Биредә дә хуҗасызлык хөкем сөрә. Бу мәсьәләдә дә беркемгә бернәрсә кирәкми. Чын советча эшләү үрнәге дими ни дисең инде бу коллектив хуҗасызлыкны!

Безнең матбугатта чыккан әнә шундый тәнкыйть мәкаләләренә җаваплар таләп ителә микән соң? Бусы инде үзебезгә, журналистларга кагылган сорау, ахрысы... Һәм депутатларга!

Әсәрләр...

Үткән атнага булган күзәтүебезне караклар турындагы поэмадан башлап китик әле. Сүз шагыйрь Мөхәррәм Каюмовның «Әллүки» санында («Социалистик Татарстан») басылган «Угры»исемле шигъри хикәясе турында бара. Укучыга инде яхшы мәгълүмдер — безнең бу авторыбыз моңа кадәр матбугатта шактый сирәк катнашты. Ләкин шунысы бар: Мөхәррәм Каюмовның басылган һәрбер шигыре диярлек күңелгә уелып кала иде, чын шигърият күренеше була иде. Шагыйрьнең зур күләмле бу әсәре ничегрәк кабул ителә соң?

Алдагы күзәтүләрдә зур күләм биләгән поэтик әсәрләрнең сирәк очракта гына уңышка ирешүен әйткәли килгән идек. Мисаллары да атап үтелде. Ә менә биредә, минемчә, шагыйрьнең уңышы хакында сүз йөртергә мөмкин. Чөнки шигъри хикәянең бер генә юлы да укучыны үзеннән җибәрми, ычкындырмый. Анда драматик вакыйга һәм кайнар кичерешләр бик тә тыгыз итеп үрелгән, үзара керешкән. Бик яшь көенчә угры язмышына дучар булган егет тормышы гаять нечкәлек һәм сизгерлек белән шигъри аһәңдә тасвир ителә. Дөресен әйткәндә, «угры» дигәнебез дә Сталин чорында кушуч бодай белән тотылган малай гына... Әмма бу күренешнең образлы көче, гомумиләштерүе бөтен илне күз алдына китерә, һәр намуслы кешенең бәгырен ача! Талантлы шагыйребез М.Каюмов шушындый трагик вакыйгаларга нигезләнгән поэмаларын әле тагын язар кебек...

Өлкән әдибебез Әмирхан ага Еникинең газетабызда 5 декабрь көнне басылган «Хакыйкать» исемле кыйссасын да бик яратып укыдык. Биредә бик катлаулы дөньяның иң гади хикмәтләре ачыла. «Туу, яшәү, үлү» дигән өч кенә сүзгә сыйса да, һәр кеше гомеренең һич кабатлана алмый торган бер могҗиза булуы, гасырлар тәҗрибәсеннән чыгып, тагын бер мәртәбә раслана.

Гурий Тавлинның «Танымады» дигән кечкенә генә хикәясе мәгънәви көче ягыннан югарыда телгә алынган кыйссага якынлаша кебек. Анда бик кызык күренеш тотып алынган. Бер карчык сугышта яшьли үлеп калган ирен төштә күрә, ә тегесе аны танымыйча узып китә. Карчыкның шуңа бик тә хәтере кала. Кеше күңеленең гаять тә нечкә, нәзберек дөнья булуы менә шушының ише уңышлы әсәрләр белән безгә тагын бер мәртәбә аңлатыла. Безнең аңа бик сак кararга тиеш булуыбыз әйтелә. Әдәбиятның, сәнгатьнең үзенең дә көче әнә шундый нечкәлектә шул аның!

Узган атнада язучы Марсель Галинең газеталарда иң актив катнашкан әдип булуын да әйтеп китәргә кирәк. Мин үзем аның дүрт әсәренә тап булдым. Аларның дүртесе дүрт жанрда һәм иң мөһиме: барысы да мавыгып укыла. «Көл әйдә, көл, маймыл!» дигәне безнең илнең бүгенге аяныч хәле турында, ачыктан-ачык итеп яңа фәлсәфи караш үткәрүе белән истә кала. Безнең бу егерменче гасыр башыннан

ахырына кадәр коточкыч экспериментлар дәвере булып тарихка кереп калыр, ахры! Ә безгә үзебезнең төп юлдан аерылмаска кирәк иде бит...

Күренекле шагыйрь Нәҗар ага Нәҗми белән үткәрелгән әңгәмә дә, Наис Гамбәрнең шигъри җыентыгы чыгу уңаеннан язылган мәкаләсе дә әдәбиятның рухын тирәннән тоеп, аның проблемаларын бүгенге яшәү белән үреп язылганнар. Марсель Гали, нәрсә генә язса да, үзе булып кала — бик тә нәфис, нәзакәтле тел, гаять образлы фикерләүгә таянып яза. «Сәйәр» псевдонимы белән басылган юмореска да кызык, ләкин авторның мәйданга, азатлык өчен көрәшүче халык янына килгән иҗат әһелләренә салкын мөнәсәбәт белдерүе белән генә килешеп булмый. Чөнки үз милләтенең язмышы хәл ителгән чакта, бер генә намуслы иҗатчы да читтә кала алмый!

Вакыйгалар...

Узган күзәтүләрдә язучыларыбызның активлыгы арта баруны билгеләп үткән идек инде, ә бу атнада аларны чын мәгънәсендә «кузгалдылар» дип әйтергә була. Биш көн эчендә чыккан татар газеталарына күз салсаң, бик күп язучыларыбызның исемнәрен күрәсең. Алар берсеннән-берсе үткенрәк мәсьәләләр күтәрәләр, үтә дә кайнарланып язалар. Шушы хәл үзе үк инде бездә әдәби газета чыгаруның тәмам өлгереп җитүен күрсәтә. Әдипләребезнең иҗат җимешләре белән рәттән таныштырып бару өчен хәзер мәйдан гына кирәк. Газета оештыручылар хәзер вакытны сузмасыннар гына!

Ә шулай да конкрет язмалар хакындагы сүзне публицист әдип Альберт Хәсәновның «Халкымның ләгънәте төшсен!» исемле әсәреннән башлыйсы килә. Бу бик тә кайнар рухлы язма «Әллүки» санының үзәгенә үк урнаштырылса да, типография гаебе белән аның авторы әйтелмәгән иде. Ә бит бу язучының соңгы еллардагы иң уңышлы әсәрләреннән берсе! Альберт Хәсәнов бик тә бәгырьгә үткән нәрсә хакында сөйли — безнең милләтне пычратучылар, аңа төрлечә яла ягучыларга каршы протест белдерә. Алай гына да түгел: безнең язучыбыз татарга пычрак аткан белорус әдибенең өенә дә шалтыраткан, аның әшәкелеген күзенә төртеп әйткән. Менә биредә инде без сүз һәм эш берлеген күрәбез. Язучы кеше үз фикерен язып та белдерә, аны үзенең гамәле белән дә ныгыта.

Шимбә санында «Татарстан яшьләре» Мәскәүдә яшәүче язучыбыз Миргазиян Юнысның «Синең көнең килде» исемле хатын бастырды. Ул безнең күренекле әдибебез Мөхәммәт Мәһдиевкә багышланган... Ләкин тукта дисең, бу хатны укыган вакытта, М.Юныс күтәргән мәсьәләләр бер әдипкә генә карамый бугай бит. Бу хат бүгенге бөтен татар язучыларына да юлланган бит.

Ни өчен шулай дибез соң? Чөнки сүз татарның үз тарихын һәм андагы күренекле шәхесләрне белү, аларны онытмау турында бара. Сүз безгә хас булган мокытлыктан, артык тыйнаклыктан котылу хакында бара. Башка милләт вәкилләренә мөкиббән китеп тә, үзебездә булган хәзинәгә игътибар җитмәү өчен борчыла Мәскәүдә яшәүче әдибебез Миргазиян Юныс. Ягъни бу — үз милләтебез турында чын-чыннан кайгырту авазы булып яңгырый!

Менә шушы хат уңае белән тагын бер фикерне ачыклап узу кирәк сыман. Билгеле, үзенең дус әдибе Миргазиян Юныстан матбугат аша мондый хат алуга безнең олы җанлы язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев һич тә үпкәләмәс. Чөнки биредә аңа гына караган нәрсә күтәрелми. Ә тагын да мөһимрәге: хат милләт мәнфәгатен уйлап, шуның өчен борчылып язылган. Әйтәсе килгән сүз шул — язучыларыбыз бер-берсенә карата төрлечә теләк һәм дәгъва белдергәндә дә, тәнкыйтьләшкәндә дә, иң беренче урында милләт һәм әдәбият мәнфәгате торсын иде! Әнә шулар төп максат булсын иде! Милләт һәм әдәбият өчен борчылу гына барлык үпкәләрне һәм хәтер калуларны оныттыра ала.

Зәки Зәйнуллин белән уздырылган һәм «Мин — Көрәшче!» дип исемләнгән әңгәмә журналист Асия Юнысова өчен генә түгел, ә бөтен «Социалистик Татарстан» газетасы өчен дә уңышлы эш дип саналырлык. Мондый фидакарь җаннарыбыз турында язып һәм аларның фикерен халыкка җиткереп, редакция бик дөрес итә. Андый мәкаләләр яшь көрәшчеләр үсүгә дә, безнең рухи ныклыгыбызны арттыруга да булыша.

Ә күренекле язучыбыз Нурихан Фәттахның берәр язмасы битараф калдырганы бармы? Юк бит! Бу закончалык үткән атнада тагын бер кат расланды. «Татарстан яшьләре»ндә «Төркиягә йөз бала» дигән мәкаләсе белән әдип җәмәгатьчелекне икегә аерды: кайсы як дөрес? Нинди юл белән китәргә?

Ләкин бүгенге көндә дәүләтчелеге булган бердәнбер төрки халыкка өмет багламыйча, без кемгә баглыйк соң? Минемчә, башта, аякка басу чорында, безнең Төркия белән бәйләнеш урнаштырырга теләвебез бары тик әнә шул максат белән генә була ала. Ә аннары, тора-бара, әлбәттә, күз күрер... Әмма диннәре һәм тормыш итү рәвешләре, уй-фикер рәвешләре шактый якын булган халыклар бер-берсенә ныграк тартылмыйча нишләсеннәр инде... Бу объектив чынбарлык, табигать законы ич...

Узган атнада шулай ук Нур Әхмәдиевнең шигырьләре һәм Әхмәт Рәшитнең ялкынлы, тирән эчтәлекле мәкаләсе дә азатлык өчен көрәшкә саллы өлеш булып кушылды.

Әсәрләр...

Узган атналар шигъри әсәрләргә бай булды дип сөенергә мөмкин. Чыннан да, татар халкының зур шагыйре Нәҗар Нәҗминең берьюлы сигез шигыре газетада басылу («Социалистик Татарстан».— 13 декабрь) сирәк була торган вакыйга бит ул! Әле шигырьләре дә нинди диген — нәкъ безнең йөрәк сүзләрен әйтеп бирә торганнар! Мисал өчен, үзен «өлкән туган» дип йөргән милләт турында шагыйрь болай ди:

Нигә кирәк бутау кеше йортын,
Үзеңнеке итеп исәпләп?

Бик тә дөрес, бик тә вакытлы әйтелгән сүзләр болар. Фикерен ары таба үстереп, Н.Нәҗми мондый сүз дә әйтә әле: «Азатлыкны да бит, байлыкны да Үз илеңдә кирәк яуларга». Ә без, татарлар исә, азатлыкны үз илебездән үз җиребездә яулыйбыз. Шуңа күрә дөреслек безнең якта!

Шагыйрь Мөхәррәм Каюмов поэмасына үткән күзәтүләрдә кагылган идек, ә менә бу атнада талантлы әдип газетабыз аша шигырьләр бәйләме дә бүләк итте. Әлеге әсәрләр турында кыска гына итеп «чын шигърият» дияргә мөмкин. Чыннан да, озак еллар кеше күңелендә җыелып, тупланып яткан кайнар кичерешләр менә хәзер безнең күз алдында бер шифалы чишмә сыман челтери башлады. Салкын кыш көне шәһәрдә ала каргаларны күзәтеп тора-тора да, шагыйрь болай ди:

Урман койгач балан, миләшләрен,
Сәфәр чыккан алар бу якка.
Салкын вокзалдагы сукбайлардай,
Төн куналар шәрә ботакта.

Аеруча соңгы ике юлга игътибар итсәгез иде. Бүгенге күпме шәхеснең халәте, трагедиясе чагыла бит анда! Бу — тормышның көен таба алмау!.. Бу — яхшы, изге күңелле кешенең ялгызлыгы... Бу — кешенең кадере китү... Хәзерге таш калалардагы, салкын неон утлары янәшәсендәге яшәү еш кына очракларда әнә шундый шыксыз, шәфкатьсез яклары белән дә күз алдына килә. «Кешеләр, бер-берегезнең кадерен белегез!» — дигән сүзләр үзләреннән-үзләре телгә менә... Әйе, чын шигърият белән очрашкач, бездә дә хисләр ташый башлый. Сүздән туктап булмый...

Ә проза әсәрләреннән Марат Әмирхановның «Фетнә» исемле юмористик хикәясе әйбәт тәэсир калдырды («Социалистик Татарстан».— 2 декабрь). Анда бүгенге татар авылы кешеләре дә, сәясәт тә, әхлак та бар. Һәммәсе дә уен-көлке аша, елмаю аша әйтелә.

Йомгаклап шуны билгеләп үтәсе килә: соңгы вакытта газеталарыбызда әдәби әсәрләр күбәйде, аларның сыйфаты да яхшырды кебек.

Вакыйгалар...

Соңгы вакытта нинди вакыйгалар булды дип искә алырга? Милли хәрәкәт җитәкчеләренә судның һәм милициянең чынлап бәйләнә башлавы безнең игътибар үзәгендә торырга тиештер.

Биредә шунысы уйландыра. Элегрәк, Татарстанга союздаш статусы сорап һәм үзебезнең президентыбызны булдыру кирәклеген әйтеп имза җыйган вакытта, милли хәрәкәт җитәкчеләренә кагылучы булмады. Ә хәзер, Президентка ышанмау һәм милли мәҗлес өчен көрәш башлангач, милли хәрәкәт җитәкчеләрен судка ук тарта башладылар. Димәк, республиканың иң югары кешеләре киңәше буенча эшләнә түгелме соң бу? Милли хәрәкәт хәзер аларны куркыта башлады бит... Юллар аерылып бара бит...

«Литературная газета» үзенең 2 декабрь санында безнең Диас Вәлиевне яклаган мәкалә урнаштырды. Авторы Жан Миндубаев. Аныңча, республикада милли хәрәкәтне Д.Вәлиев башлаган икән дә, хәзер инде әлеге «инициаторга» көн күрсәтмиләр икән! Әйтерсең лә татарның азатлык хәрәкәте гасырлар буена бармаган. Гүяки аны татарча укый да, сөйләшә дә белмәгән Д.Вәлиев башлаган!

Жан Миндубаев үзенең фикердәшен — урысча язучы Д.Вәлиевне — яклау өчен моннан 6 ел элек булган хәлләрне бүгенге итеп күрсәтә, бутый, алдый. Кыскасы, бу мәкалә урыс матбугаты өчен традицион булган адым — пычрак адым. Ләкин шунысы да кызганыч: без урыс матбугатына чыгып шул ялганны фаш итмибез. Үзебезнең «Казанда» гына кайный бирәбез. Урысча язучы әдипләребез кайда соң безнең? Чын хакыйкатьне ни өчен әйтми алар?

Инде хәзер үзебезнең язучылар мохитенә килик. Үткән күзәтүләрнең берсендә (5 декабрь санында) Язучылар берлегенең идарә утырышы хакында һәм берлеккә хөкүмәт тарафыннан бүленгән җиңел машиналар турында сүз барган иде. Язучылар берлеге рәисе урынбасары З.Мансуров «Шәһри Казан»га җавап язды да игътибарны бүтән якка борырга теләде. Янәсе, фактлар дөрес түгел!

Әйдәгез, хәлләрне яңадан карыйк. Без газетада язганга кадәр Язучылар берлеге идарәсе членнары да, язучылар үзләре дә берлеккә бирелгән бер генә машина турында да белмиләр иде. Без язгач, ике җиңел машина бирелгәнлеге ачыкланды. Бу инде язучылар белән, идарә белән киңәшеп эшләмәү дигән сүз түгелме соң?!

Аннан соң бит безнең язмада Совет Армиясе инвалиды язучы Фәнис Яруллинга машина бирү турында барды. Аңа исә бары тик 1 машина җитә! Димәк, бусы да җавапсыз калды дигән сүз.

Урыс язучылары хакында мин тулы мәгълүмат бирмәдем, ә бары тик 27 ноябрьдә үткән бер утырышны әйттем. Ул көнне 3 татар, 3 урыс алынды. Ә урысча язучы Ф.Рәсүловага килгәндә, рәис урынбасары үзе соңгы съезд карарларын оныткан икән ләбаса. Анда кайсы телдә язуына карап, каләм иясенең кайсы әдәбиятка каравы хакында махсус карар кабул ителде. Ул карарны безгә М.Зарипов белән бергә әзерләргә туры килгән иде. Әнә шул карар буенча Ф.Рәсүлова һич тә татар язучысы дип санала алмый. Бигайбә!

Әсәрләр...

Үткән елның соңгы атнасы әдәби әсәрләргә дә шактый бай булды. «Социалистик Татарстан» белән «Шәһри Казан» аеруча куандырды үз укучыларын. Бөтенсоюз татар газетасының ял көнгә килеп җитә торган «Әллүки» саннарын чын-чыннан әдәбият-сәнгать атналыгы дияргә мөмкин. 27 декабрь саны исә бигрәк тә өлкән әдибебез һәм торгынлык елларында татар милләте өчен актив көрәшкән шәхес Салих ага Батталның «Өч хатын арасында» исемле шаян хикәясе белән игътибарны җәлеп итә. Август аенда үзенең 86 яшен тутырса да, бу язучыбызның иҗат дәрте һаман сүрелми, көндәлек матбугатта ул шигырьләре белән дә, мәкаләләре белән дә катнашкалап тора. Әлбәттә, андый өлкән әдипләр тагын да бар. Аларның һәммәсенә яңа елда да шундый ук иҗат уңышлары, озын гомер телисе килә.

Ә Салих аганың шаян хикәясе юмор чаткыларын бик мул бөркү, кайчагында аның шаяруы безнең татар тормышына сатира сыман да кабул ителә башлый. «Урыс баеса, чиркәү сала, татар баеса, хатын ала» дигән сүзләр искә төшә.

«Әллүки»нең шул ук санында шагыйрь Эдуард Мостафин да сүз алган. Без моңа кадәрге булган күзәтүләрдә зур күләмле әсәрләрдән алып басылган өзекләргә кагылмый уза идек. Ни өчен дигәндә, бер өзектән чыгып кына тулаем әсәр хакында фикер әйтүе кыен. Ә бу очракта эндәшми калу мөмкин түгел. Татар халкының бик тә талантлы шагыйре Эдуард Мостафинның бер генә яңа әсәре дә укучыны битараф калдыра алмый. Батырша турындагы поэма инде бигрәк тә! Поэманың менә бу юлларын гына карагыз сез:

Русиягә берәр афәт килсә,
Татар кирәк, белегез бу хакта.
Кырылсыннар шунда басурманнар —
Барсын татар беренче сафта.

Озакламый поэма белән тулысынча да танышырга насыйп булсын иде дигән өметтә калабыз.

Яшь шагыйрь Хәбир Ибраһим әсәрләрен үткән җомга көнне бастырып, «Шәһри Казан» да үз укучыларына зур сөенеч китерде. Элегрәк бу автор белән «Идел» журналында очрашкан бар иде, ә биредә инде аның шигъри сәләтенә чынлап ышанасың, талант белән очрашуыңны аңлыйсың. Бу каләм, сизелүенчә — лирик пландагы шагыйрь. Аның иң зур уңышлары да әнә шул юнәлештә.

Шәһәр йоклый. Йортлар утсыз калган.
Буран улый, карлар тузына.
Кич утырып бүген хатлар язам
Мин авылның соңгы кызына.
Күз алдымда көзге зират өсте,
Авыл башы. Көзге яңгырлар.
Күз алдымда аның моңсу йөзе,
Моңсу тормыш, моңсу авыллар.

Менә шушы юлларда күңелнең никадәр сизгерлеге, тоемлау тирәнлеге һәм безнең елларның кеше язмышларын телгәләүче үткен пычагы! Менә шушындый юллар белән очрашкан вакытта чын шигъриятнең асыл билгеләре тагын бер мәртәбә искә төшеп ала. Кайнар хиснең, күңел нечкәлегенең, иң югары кешелеклелекнең шигырь өчен аерылгысыз булуына тагын бер мәртәбә төшенәсең...

Бу каләм иясе үзенең дөрес юлыннан тайпыла гына күрмәсен иде! Тимер-томыр салкынлыгы һәм шәһәр буталчыклыгы аның йөрәген адаштыра гына күрмәсен иде!

Узган елның кыскача йомгакларына килгәндә, иң беренче итеп, әдәбиятта милли рух көчәюен сөенечле күренеш буларак билгеләп үтәргә кирәк. Ниһаять, безнең язучылар бары тик үз йөрәкләре кушуы буенча гына яза башладылар дияргә була. Матбугатта укылырлык, истә калырдай әсәрләр артуны да әнә шул тенденция белән аңлатырга мөмкин. Хәер, йөрәк сүзе һәм йөрәк хисләре алар гомер-гомергә әдәбиятның төп нигезе булып килгән бит инде. Безнең әдипләр совет чорында гына шактый буталып алдылар. Мондый ялгышуга, әлбәттә, Язучылар берлеге килеп чыгу да байтак кына ярдәм итте.

Үткән елның тагын бер куанычлы күренеше: элек читтәрәк йөргән байтак кына талант ияләре матбугатыбызда яңадан күренә башлады. Торгынлык чорында аларның байтагы шома шагыйрьләр тарафыннан читкәрәк тибәрелгәннәр иде бугай.

Үзебезнең милләтнең, үзебезнең татар әдәбиятының төп юлына, үзенең ышанычлы юлына кайту безне һәммә яктан да көчәйтәчәк. Намуслы көчләр әле алга таба да безнең тирәгә тупланачак, милли әдәбиятның куәтен арттырачак!

Вакыйгалар...

Татар язучыларының халык белән элемтәсе начар дип булмый. Беренчедән, аларның һәммәсе дияр-лек авыл баласы, димәк, ул инде яшьтән үк чын тормышны күреп үскән. Ә икенчедән, безнең язучылар районнарга бик еш чыгып йөриләр. Иҗат берлегендә пропаганда буенча махсус бюро бар. Узган декабрь аенда гына да, мисал өчен, безнең язучылар Буа, Кукмара, Мөслим һәм Әгерҗе районнарында булып кайттылар. Күпсанлы очрашулар үткәрделәр.

Әгерҗе районына килгән язучылар исә шушы якта туган һәм озак еллар буе балалар укыткан драматург Юныс Әминовның тууына 70 ел тулуны да билгеләп үттеләр. Район үзәгендә булган кичәдә драматурглар Таһир Закиров, Габдулла Галиев һәм Казаннан килгән әдипләр Мөсәгыйт Хәбибуллин, Рәшит Гәрәй чыгыш ясады. Бу төбәкнең Салагыш һәм Исәнбай урта мәктәпләрендә әдәбият укытуга зур игътибар бирү, яшь каләмнәр белән даими эшләү киләчәктә яңа иҗат көчләре тууга булган өметне көчәйтә. Район авылларында татар әдәбиятына һәм язучыларга да игътибар зур.

Декабрь ахырында Татарстан Язучылар берлегенең идарә утырышы булып узды. Россиядән бәйсез-лек алгач, иҗат берлегенә кабул ителгән язучылардан Сафуан Мулла Галигә, Асия Минһаҗевага, Гу-рий Тавлинга, Флүс Латыйфига, Фәнзаман Батталга әгъзалык билетлары тапшырылды. Кызлар тара-фыннан чәчәкләр дә бүләк ителү бу вакыйгага тәмам бәйрәм төсе бирде.

Март аенда Мәскәүдә бәйсез иҗат берлекләренең оештыру съезды булырга тиеш. Безнең язучылар аңа делегатлар сайлаган иделәр инде. Идарә утырышында бу делегациягә тагын берничә язучы өстәлде. Агымдагы сәяси эшләр белән шөгыльләнү өчен иҗтимагый-сәяси совет та сайланды. Аңа Әбрар Кәри-муллин, Рабит Батулла һ.б. керә.

Идарә утырышында республиканың бәйсезлеген нығытуда язучыларның активлыгын арттыру ки-рәклеге хакында җитди сөйләшү булды. Күп кенә мәсьәләләрне Президент белән очрашу вакытында күтәрергә карар кылынды.

Китап нәшриятының һәм әдәби басмаларның базар чорындагы хәле аеруча зур борчылу тудырды. Аларны яклау буенча аерым чаралар күрү кирәклеге басым ясап әйтелде... Нишлисең, шундый еллар, шундый дәвер!

Әсәрләр...

Кемгә ничектер, әмма минем өчен Яңа ел әдәбияттагы куанычлы күренеш белән очрашудан башла-нып китте. Яңа елның беренче көннәрендә үк мин яңа романчының яңа романын укып, чын күңелдән шатландым. Флүс Латыйфиның «Хыянәт» дип исемләнгән һәм «Казан утлары» журналының 11, 12 саннарында дөнья күргән романы ул.

Бу әсәрдән алынган тәэсирләр шундый мул, күңелдә туган уйлар шулкадәр күп — аларның бары-сын кыска гына бер күзәтүдә әйтеп бирүе дә кыен. Ләкин иң элек шуны белдерәсе килә: безнең укучы бу әсәрне һичшиксез табып укырга тиеш!

Романны укып өлгермәгән кешеләр өчен «бу әсәрнең вакыйгасы Казан ханлыгы алынган елларда бара...» дип кенә әйтеп китәр идек, ләкин кайсыбер укучылар: «әһә, тагын тарихи әсәр икән» дип, читкә борылырга мөмкин... Ә бит чынлыкта бу һич тә тарихи роман түгел. Ул чын мәгънәсендәге әдәби әсәр булып чыккан!

Аны бүгенге тормыш хакындагы әсәр укыгандай мавыгып, онытылып укыйсың — вакыт һәм ерак чорлар киртәсен һич тә тоймыйсың. Ә болай булу әсәрнең эчтәлеген укучыга тагын да якынайта, роман кешенең күңел дөньясы аша шунда эретелеп кабул ителә.

Романда иң элек кешелек хисләре һәм омтылышлары өстенлек итә. Урыс егете Александрның татар кызы Гөлйөземгә булган көчле һәм саф мәхәббәте төп сюжет сызыгын тәзи. Әнә шул мәхәббәт, көчле омтылыш янында хәтта зур-зур тарихи вакыйгалар да кечерәебрәк кала сыман. Әсәрнең төп идеясе дә әнә шундый мәхәббәтне, тыныч-имин тормышны, милләтләрнең туганлашуын мактауга, шуның бәрә-кәтен күрсәтүгә кайтып кала. Каһарманнары да сугышчылар түгел, ә сәүдәгәрләр һәм башка тыныч һө-нәр кешеләре.

Романның соңгы өлеше бик гыйбрәтле. Анда Казан янындагы сугыш тасвирлана. Әмма ләкин баш-каланың урыс тарафыннан алынуы күрсәтелми, ә бик мәгънәле итеп: ике якта сугышкан бертуганнар-ның берсен-берсе үтерүе тасвирлана.

«Хыянәт» моңа кадәр яшь язучы саналып килгән Флүс Латыйфиның зур уңышы. Аның җитди, зур күләмле жанр биеклеген уңышлы яулау мисалы. Элегрәк безнең кайбер яшь язучыларыбыз, ашык-пошык кына язып, гаять озын әсәрләр бастырдылар да шул язмаларын «роман» диеп йөрделәр. Аларны укып, безнең укучы әллә ни куана алмады. Хәтта әле укый да алмады. Ә менә биредә без иҗат эшенә

чын-чыннан намуслы мөнәсәбәт мисалын күрәбез. Романның һәр өлеше, хәтта һәр җөмләсе нык уйланып, зур көч салып иҗат ителгән. Латыйфи әфәнде шушы дәрәҗәне алдагы иҗатында да саклый алсын иде!

Поэзиябездә дә зур сөенеч бар.

Ел башында ук безнең кулга атаклы шагыйребез Мөдәррис Әгъләмовның «Мин әйттем...» исемле яңа китабы килеп керде.

Алып китте башта әниемне,
Ә аннары килде әтигә.
Башына уй төшкән бер яшүсмер
Йоклый алмый ятам сәкедә.
Тәрәзәдән өйгә якты сузып,
Мин тилмереп көткән ай чыга:
Ак кәгазьгә ачы юллар тама,
Шул юллардай ачы тамчылар...

Менә шушындый юллар — чын тормыш һәм тирән шигърият күренешләре белән — без бу китапта бик еш очрашабыз. Яшәүдәге буталышларны, көрәшләрне уйлаганнан соң, үз халкыбыз талантларының һич тә икеләнмичә, адашмыйча үз юлларыннан ышанычлы адымнар белән атлавын күрәсең дә тагын бер кат сөенеп куясың! Әйе, үз йөрәгеңә һәм аның аша үз милләтеңә тугры булсаң, сиңа бернинди давыллар да куркыныч түгел шул, талант! Ләкин узып барган елларда үз халкыннан бигрәк, күрше милләтләрдә басылуны күздә тотып язган каләм ияләре дә юк түгел иде... Инде хәзер алар да татар укучысының йөрәгенә үтеп керә алу хакында уйлана башласыннар иде... Аларны да татар халкы тудырган бит. Алар да татар шагыйре дип санала бит...

Вакыйгалар...

Матбугатыбызда бер-берсенә каршы килүче язмалар күбәю — начар күренеш түгел. Бу матбугат өчен гадәти хәл. Чөнки әнә шундый каршылыклар ачылмыйча һәм хәл ителмичә, җәмгыятьнең аңы һәм фикере үсә алмый. Чит илдә инде бу күптән шулай.

Шушы яктан караганда «Татарстан» журналы күпләргә үрнәк күрсәтә. Анда үткен мәкаләләр бик күп басыла. Укучылар саны да гел арта бара.

Журналның күптән түгел дөнья күргән 12 саны да үткен эчтәлекле мәкаләләргә бик бай. «Академик Сәгъдиевнең үз халкы каршында ни гаебе бар?» дигән исем үзе генә дә ни тора?! Биредә автор Рафаэль Мостафинның публицистик таланты да, журналистлык тәжрибәсе дә ачык чагыла. Укучылар бу санны табып танышсыннар иде.

Ә шулай да бер-ике мәсьәләдә автор белән килешмәүне белдерәсе килә.

Вакытлы матбугатта академик Сәгъдиевне мораль яктан гаепләп чыккан авторларга Р.Мостафин биредә каршы төшә. Академикның бер гөнаһы да юклыкка ышандырырга тели. Ә минемчә, укучыларда хаклык зуррак. Ни өчен?

Башта бер чагыштыру китерик. Мисал өчен, бер кешенең әнисе авырый ди. Ә ул кеше әнисен терелтү турында уйламыйча, моңа исе дә китмичә йөри, моны шулай булырга тиеш кебек саный. Ул эшли, дөнья куа... Әйтегез әле, бу кеше мораль яктан гаеплеме? Әлбәттә, ул бик тә гаепле!

Ә бит академик Сәгъдиевнең моңа кадәрге тәртибе татар халкына карата әнә шундый булды. Матбугатта һәм башка кайбер чыгышларында ул үзен милләтсез кеше итебрәк күрсәтергә теләде. Тудырган милләтенә — анасына — әнә шундый мөнәсәбәттә булды. Безнең халык вәкилләре аңа шуның өчен үпкә сүзләре әйтәләр. Әлбәттә, милләт үзенең андый улларына карата үпкәсен белдерергә бик тә хаклы! Чөнки Р.Сәгъдиев ишеләр әле тагын да бар. Урысча сөйләшүче һәм уйлаучылар арасында тагын да күбрәк андыйлар.

Икенче мәсьәлә Р.Мостафин шовинизмга да, милләтчелеккә дә тигез карарга тырыша кебек. Әмма чынлыкта нәрсә килеп чыга соң?

Чынлык менә мондый. Бик күп кабатланган мисалларны алыйк. Казандагы 160 мәктәпнең бары тик 9 ы гына татарныкы. Казандагы бөтен эш бары тик урыс телендә генә алып барыла. Телевидение һәм радио тапшырулары көне-төне урысча бара.

Димәк, урыс белән татар дөньясы икесе ике үсеш дәрәҗәсендә тора. Шуңа күрә бу ике халыкка мөнәсәбәт тә бертигез була алмый. Татар милләтенең хәле бүген авыру кешенеке кебек. Ә бит авыру кешегә һәрвакыт аерым мөнәсәбәт сорала.

Р.Мостафин «милләтче» дип гаепләгән кешеләр бары тик әнә шундый мөнәсәбәт таләп итүчеләр алар. Татарны да урыс белән тигез дәрәҗәдә итеп күрергә теләүчеләр алар.

Инде тагын да аңлаешлырак булсын өчен, янә бер чагыштыру китерик. Бетә, югала баручы үсемлекләрне, җан ияләрен саклау өчен табигатьтә тыюлыклар (заповедниклар) төзелә. Безнең Татарстан — татар милләтен саклап калу өчен әнә шундый урын кебек бит инде ул!

«Татарстан» журналының шул ук санында Тәлгать Галиуллинның «Чор чыбыркысы астында» исемле кайнар рухлы мәкаләсе дә урын алган. Анда совет чоры татар поэзиясен яңача өйрәнү мәсьәләләре күтәрелә. Сүз уңаенда бу тәнкыйтьчебезнең соңгы вакытта ижади активлыгы артуны сөенеп әйтәсе килә. «Казан утлары» журналының 11 санында аның «Замана балалары» исемле язмасы торгынлык чоры түрәләре тормышын бик кызыклы һәм гыйбрәтле күренешләр аша ачып салган иде. Сүз уңаенда әйтеп үтик, Т.Галиуллинның мондый язмалары журналда әле тагын басылачак.

Әйе, рухи тормышыбыз җанлану — уртак шатлык ул!

Әсәрләр...

Революция елларында һәм шундый давыллы, дәһшәтле чорларда шагыйрьләр актив була дигән закончалыкны ишеткән бар иде. Безнең заман шуны тагын бер мәртәбә раслый, ахрысы. Үткән ике атнаның газеталары, аларда дөнья күргән әдәби әсәрләр дә әнә шул хакта сөйли. Проза әсәрләре һәм бигрәк тә хикәяләр түгел, ә шигырьләр ешрак күзгә ташлана.

Әйе, кайнар хисле, тирән кичерешле поэтик әсәрләр бүген күңелгә бик теләп кабул ителә. Шагыйрь Илдус Гыйләҗевнең моңа кадәр басылып чыккан ике китабын без яратып укыган идек. Шуңа күрә «Социалистик Татарстан»ның 24 январь санында аның исеме игътибарны тиз тартты. Дүрт шигырьнең берсе «Пөхтәлек чишмәсе» дип исемләнгән.

Намазлыкка баскан әбкәй төсле,
Алмагачлар ап-ак чәчәктә...

Менә шушы ике юлда да безнең татар рухы тансыклаган күпме изгелек, пакьлек, никадәр матурлык чагыла! Чагылу гына да түгел — алар нәкъ менә үзебезчә, милли яшәеш ала, безнең кандагы һәм җандагы дулкыннарга гаять ятышлы булып тоташып, ялганып китә... Гамил Афзал һәм Сажидә Сөләйманова төбәге тагын бер төпле, тирән шагыйрь ижаты хисабына байый, ахрысы.

Нәҗибә Сафинаның газетабызда 17 январь көнне чыккан шигырьләр бәйләме дә өр-яңа поэтик аһәң булып ишетелә. «Сары яфрак җиргә төшкән саен Өзелергә, ләкин түзәргә...», «Күңелемнең төпләрендә йөзгән Үземнән дә яшерен аккош бар».

Юк, бу юллар, бу шигырьләр дөньяны яңача тою, яңача күрү генә түгел. Минемчә, биредә кеше күңелен табигать белән бербөтен итә торган гаять нечкә кыллар, җанның, бәгырьнең гаять тә сизгер халәте табылган. Әнә шуңа күрә әсәрләрдәге җан өзгәләнүләре бөтен яшәеш өчен мөһим һәм кадерле булып ишетелә, шулай аңлашыла.

Бөтен чынбарлыкны политика, сәясәт баскан вакытта әдәбият кына аннан читтә торып кала алмый, күрәсең. Хәтта хикәя дигән чын әдәбият жанрына да сәясәт көчле агым булып бәреп керә башлады. Гадәти хикәяләр түгел, ә сәяси хикәятләр туа, ижат ителә. Күренекле сатирик һәм публицист Фәнзаман Баттал «Социалистик Татарстан»ның берьюлы 3 санында әнә шул яңа жанрга караган әсәрләрен бастырды. «Ватанны югалтудыр бу» дип исемләнгән хикәяткә генә игътибар итегез: «Хак булса, чалбары тезеннән түбән төшкән бу ахмак әле хәзер дә:

— Монысы да минеке, тегесе дә минеке!..— дип, егерме тишек өстендә туп кебек сикереп йөри, имеш...»

Бүгенге урыс шовинисты әнә шулай чагыштырыла. Чынлыкка бик тә туры килгән мәгънә дә бар биредә, әлеге комсызлыкка ачы сатира да мул ишетелә ул юлларда. Үз хәленең никадәр көлке булуын аңламаган кешене күреп гажиз калу да бар... Кыскасы, «өлкән туган»ның бүгенге кыланмышларына карап торганда безнең күңелдә ниләр туса, Ф.Баттал аларны бик кыска итеп кенә үзенең хикәятләренә сыйдыра алган. «Кыскалыкта — осталык!» — дими ни дисең инде тагын.

«Татарстан яшьләре»ннән хикәя ише затлы сәнгать әсәрләрен табып булмый инде хәзер, чөнки аның маңгаена ук «иҗтимагый-сәяси газета» дип куелган. Аның каравы бу басма битләреннән үткен һәм кызыклы язмаларны бик күп укырга мөмкин. «Безнең даими авторыбыз» дигән бүлек тә вакытлы башланды дип уйлыйм. 18 январь санында Вахит Юнысовның «Давыллы диңгездә бер утрау» дигән язмасында бөтен Җир шарын әйләнеп чыккан кеше күзе белән бүгенге Татарстандагы хәлләр тасвирлана. Безнең ышанычны арттыра, күңелне күтәрә торган, тирән эчтәлекле әйбер язган В.Юнысов. Хәер, аның һәр язмасы диярлек шундый гыйбрәтле була бит.

«Чистарыну, яки шуңа омтылыш...» — укучыларның яраткан әдибе Мөхәммәт Мәһдиев әсәре. Яшьләр газетасының ике ягын тулысы белән биләп торса да, ул бер тында укыла. Чөнки анда кызыклы күренешләр. Торгынлык чоры эпизодлары күп. Алар, бу әдипкә хас булганча бераз елмаеп, бераз әрнеп, оста каләм белән ижат ителгәннәр.

Сүз уңаенда әйтеп китик, «Казан утлары» журналының быелгы март санында да күренекле язучыбыз Әмирхан ага Еникиның «Ялганны яклау» исемле бик гыйбрәтле әсәре дөнья күрәчәк.

Нишлисең, чоры шундый — күңелдәгене әйтми калдыру мөмкин түгел! Күңелдә озак еллар буена җыйнала, туплана килгән уйлар, фикерләр әдәби әсәр булып та, төрле характердагы гыйбрәтле язмалар булып та дөньяга чыга тора.

Вакыйгалар...

Әлбәттә, бу көннәрнең иң зур һәм иң әһәмиятле вакыйгасы Милли Мәҗлес. Хәзер аңа һәм аның бүген кирәклегенә караш ике төрле булганга күрә, иң башта, әйдәгез, бу идеянең туу һәм үсеш логикасына игътибар итик. Шуны кыскача гына күздән кичерик.

Билгеле булганча, бу идея Татарстанга союздаш республика статусы бирү өчен барган көрәшнең соңгы этабында туды. Властьның югары даирәләре әле һаман союздашны алу иртә дип саныйлар иде. Ләкин Татар иҗтимагый үзәге һәм башка милли партияләр бу мәсьәләдә икеләнмичә әйттеләр, союздаш статусы һичшиксез кирәклеген расладылар. Суверенлык турындагы Декларация бу юлның логик үсеше булды, әлеге юнәлешнең дөрес икәнлеген раслады... Тормыш һаман алга бара, татар милләтенең иң үткен проблемалары алга һаман үткенрәк хәлдә килеп баса. Ә безнең парламент исә һаман элеккеге (халык союздаш булуны сораган чактагы) власть органы кебек үк, реаль эш эшли алмый, вакыйгалар артыннан ияреп кенә бара. Шул ук вакытта, милләтнең иң мөһим мәсьәләләрен хәл итү өчен кирәкле алтын вакыт кулдан ычкына бара. Димәк, бу очракта да алга бару мәслихәт. Теге чактагы власть ияләре кебек көтеп тик тору дөрес түгел. Милли Мәҗлес җыйнау һәм аңа милләтнең иң үткен мәсьәләләрен хәл итүне йөкләү кирәк. Украиннар шушы көннәрдә милли конгресс җыйнадылар бит әле... Ахыр чиктә Президентыбыз үзе дә аның кирәклеген танырга мәҗбүр булды бит! Башкаларга ияреп һәм инициативаны эләктерү өчен генә булса да...

Менә шушындый логикадан чыгып караганда, Зәки Зәйнуллин, Габделбәр Фәйзерәхманов һәм Фәүзия Бәйрәмова тоткан юнәлеш, әлбәттә, эзлеклерәк һәм ышанычлырак. Бу — милләт көткән юл. Билгеле, бу очракта конфронтацияне артык көчәйтүдән сак булырга кирәк. Вакыйгаларны чама беләп генә ашыктырырга кирәк. Республикадагы сәяси һәм психологик ситуацияне нечкә тоеп кына.

Фәүзия Бәйрәмованың газеталарда урын алган «Милли Мәҗлес бүген кирәк!» дигән язмасы дөрес һәм вакытлы. Ул, күп язучыларыбызга үрнәк күрсәтеп, милли көрәшнең алдында бара. Бүгенге иҗатына тиешле вакытын татар милләте өчен тырышуга, януга бирә. Хәер, озакламый бу кайнар һәм гыйбрәтле көннәр турында язу вакыты да килер бит әле. Ул чагында аныкы сыман ялкынлы һәм тынгысыз гомергә күпләребез көнләшмәс микән?!

Хатын-кыз язучыларыбыздан Ләбибә Ихсановаңың «Чишмәләр кипмәсен!» һәм Бикә Рәхимованың «Исәнме, Әлифба бәйрәме!» исемле мәкаләләре үткән атналарның иң кирәкле язмаларыннан саналырга тиеш. Аларның беренчесендә татар балалары өчен китап басу эшендә килеп туган зур киртәләр хакында сүз бара. Тиешле күләмдә дәреслекләр һәм балалар китаплары булмагач, милли яңарыш хакында ничек сөйләшмәк кирәк? Язучы әнә шуңа борчылып чаң кага. Бу мәсьәлә, әлбәттә, хөкүмәт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиеш. Кызганычка каршы, Халык мәгарифе министрлыгы да үз эшендә тамырдан борылыш ясарга җыенмый. Татар балалары һаман урысча һәм урыс мохитендә укый, тәрбияләнә. Безгә бүләккә яңа Диас Вәлиевләр һәм Жан Миндубаевлар үсә...

Соңгы атналарда язучыларыбызның матбугаттагы бәхәсе тынды кебек. Һәрхәлдә, андый мәкаләләр күзгә чалынмады. Әмма тормышта бәхәсле һәм ачыкланасы нәрсәләр бетмәде бит. Киресенчә, яшәүнең яңа юлына керә барган саен, андый мәсьәләләр каршыбызга күбрәк торып баса. Шуңа күрә язучыларыбыз иң үткен проблемаларга алынудан курыкмасыннар иде.

Бәхәс дигәннән, минемчә, милләтнең һәм әдәбиятның мөһим күренешләре хакында сөйләшү, хәтта кайнар-кайнар бәхәсләшү дә бик кирәк, бик урынлы. Ә инде теге яки бу шәхеснең тырнак астыннан кер эзләүгә корылган бәхәс укучыда чиркану тойгысы гына уята. Газеталарда урын алган укучы хатлары, минемчә, әнә шул соңгысына карый.

Язучыларның үзләренә генә кагылган мәсьәләләр элекке елларда җыелышларда калкып чыга иде, шунда хәл ителә иде. Соңгы вакытта андый җыеннар бик сирәк булганга күрә дә, матбугат битенә бәреп чыкты бугай инде ул эчке мәсьәләләр... Секция эшләре, бәхәс клублары һаман оешып китә алмый бит әле Язучылар берлегендә.

Әсәрләр...

Соңгы ике атнада вакытлы матбугатта әдәби әсәрләр күп басылмады. Казанда татар халкының Корылтае булып узу һәм Югары Совет сессиясе эшләү, күрәсең, каләм ияләренең дә, укучыларның да игътибарын күбрәк җәлеп итте. Ләкин шулай да «Татарстан яшьләре» битендә өр-яңа шагыйрьнең әсәрләрен уку безнең өчен бик күңелле яңалык булды.

Салават әфәнде Рәхмәтулла турында редакция әллә ни мәгълүмат бирмәгән. Бары тик аның атаклы Солтанморат авылыннан — дөньяга Галимҗан Ибраһимовны биргән җирдән икәнен генә әйткән. Авторның ничә яшьтә булуы да билгеле түгел. Әмма мин үзем шигырьләрдән чыгып чамалап карадым: бу инде шактый акыл утырткан һәм дөнья күргән, тәҗрибә туплаган шәхес булырга тиеш. Аның сүз йөртүе дә кеше өчен иң мөһим, иң кадерле нәрсәләр хакында.

Юлларына таулар чыгып бассын!

Алларына язмыш таш өйсен! —
Тик барыбер кеше елына бер
Туган якка кайтып баш исен!..

Күрәсездер, тыгыз фикерле һәм хисле юллар, күңелгә бик тә ятышлы шигъри агым биредә. Каршылыкларның да иң зурысы алына: таулар кебеге, ташлар катылыгындагысы. Чөнки туган җирнең кеше өчен никадәр кирәк, мөһим булуын шунсыз расларга мөмкин түгел!

Бу шагыйрьнең әсәрләрен укып сөенгәннән соң, инде шунысы уйландыра башлый: хәзер аны нинди язмыш, нинди киләчәк көтә инде? Яшьләр газетасында басылганнан соң дәртләнеп, илһамланып ул тагын яңа шигырьләр язар инде... Аларны зур өметләр баглый-баглый тагын газета редакциясенә юллар инде... Ләкин андагылар инде бу юлы Салават әфәндегә яшел урам ачарга бик үк ашыкмаслар, «без әдәби газета түгел бит!» диярләр. Бу шагыйрьнең шигырьләре ятыр-ятыр да, редакция архивына озатылыр... Ә автор үзе башта тилмерә-тилмерә шигырьләренең газетада чыгуын көтәр, аннары өметен өзгәч, Татарстандагы бүтән газеталарның редакцияләренә җибәреп карар. Алары да бастырырга ашыкмас: «Бездә әле бүтән шагыйрьләр дә айлар, еллар буе чират тора»,— дип кенә җибәрерләр... Шулай ук журналлар да яңа шагыйрьне бик үк кочак җәеп каршы алмаслар. Чөнки аларда да еллар буена формалашып, күнегеп беткән калып яши. Йөзләгән тәҗрибәле шагыйрьләрдән хасил булган стена бар. Өстәвенә тагын анда эшләүчеләрнең дусрак күргән шагыйрьләре дә бар — аларны да беренче чиратта үткәрергә кирәк була...

Шул бер «Идел»гә барып чыгалса гына инде безнең яңа шагыйребез. Бердәнбер ышаныч шунда гына инде аңа! Ләкин әле аның анысы да, тарих һәм сәясәт белән артык мавыгып, яшь һәм яңа авторларга аерым бер кайгырту күрсәтәбез дип тормый бит әле...

Кыскасы, бездә, бер караганда, матбугат киңәя бара, басмаларның саны арта. Ә икенче караганда, югарыда күреп киткән хәл бик еш кабатлана. Безнең яшь һәм яңа авторлар турында даими кайгыртучыбыз юк! Шундый бер аерым басмабыз юк! Редакцияләрдә айлар һәм еллар буе яткан әсәрләр барлыгын белгәнгә күрә, әнә шулай дип әйтәм мин. Бу хәл — безнең әдәбият өчен бик начар нәрсә, җегетләр! Әйдәгез, берәр чарасын күрик. Чөнки яшь талантка аңа даими рәвештә һәм тиз арада басылу кирәк! Даими һәм тиз арада басылганга күрә безнең Апушларыбыз бөек Тукайга әйләнгәннәр! Ә андый сәләтләр әле бездә бүген дә юк түгел!

Яшь язучыларыбыз әнә шундый авыр хәлдә булганда, безнең бер редакциядә эшләүче язучыбыз үзенең бер үк язмасын ике газетада бастырды! Җитмәсә, әле ул гаять тә озын һәм бик тә буталчык мәгънәле язма иде. Хәзер инде безнең авыл хәбәрчеләребез дә аннан яхшырак итеп һәм фикерләрен конкрет белдереп язалар. Редакцияләр киләчәктә мондый күренешкә урын бирмәскә тиешләр. Чөнки басылырга чират көткән яшьләребез дә бик күп бит безнең!

Вакыйгалар...

Әлбәттә, безнең тормышта вакыйгалар байтак булып тора. Ләкин язучы кешегә карата прокуратураның материаллар туплавы — бусы инде безнең чор өчен дә гадәттән тыш нәрсә. Биредә кем турында, нинди җинаять эшләгән, кайсы язучы хакында сүз бара соң?

«Казан утлары» һәм «Идел» журналларында чыккан күпләгән әсәрләр авторы, Татарстан китап нәшриятында басылган «Сугыш алды малайлары» исемле китапны язган кеше, милли хәрәкәтебезнең иң актив лидерларыннан берсе булган Зәки ага Зәйнуллин язмышы турында бара сүз. Россия властьларына буйсынган прокуратура соңгы вакытта редакцияләргә шундый хат җибәрде. Анда «нарушение национального и расового равноправия» дип аталган җинаять эшләгән Зәки Зәйнуллинның басылган әсәрләре турында белешмә сорала. Җинаятьнең ни рәвешле әйтелүенә игътибар итегез сез — янәсе, Зәки Зәйнуллин милли тигезсезлек китереп чыгара икән!

Әйдәгез, фактларга — чынбарлыкка мөрәҗәгать итик. Бүгенге көн фактлары бары тик бер тигезсезлек хакында ышандыра: бүген бездә урыс милләте бик тә өстен хәлдә. Казанны алсак, андагы 160 мәктәпнең 150 се урысныкы. Шул ук 160 мәктәпнең бары тик 20 сендә директор булып татар кешесе эшли. Казандагы 7 районның барысында да РОНО мөдирләре урыс кешеләре. ГорОНО мөдире дә урыс кешесе. Казан оешмаларының һәммәсендә эш урыс телендә бара.

Югарыдагы мисаллар күрсәткәнчә, әйе, бездә тигезсезлек бар. Урыс милләте бик тә өстен хәлдә яши. Әнә шундый тигезсезлекне саклаучы кешеләрне бүген хөкемгә тартырга кирәк.

Ә Зәки Зәйнуллинга килсәк — ул татар милләте дә урыс белән тигез хәлдә булсын дип көрәшә. Димәк, гаделлек өчен көрәшә. Татарстан прокуратурасы исә болай да җәберләнгән милләтне тагын да җәберләргә тели. Аның материаллар туплавы әнә шундый максатны гына күздә тота. Димәк, аларның үзләрен хөкемгә тартырга кирәк. Гаделлек шуны таләп итә!

Ай башында булып узган Корылтай турында безнең матбугат әйбәт кенә язды. Әмма радио белән телевидениенең бу зур вакыйгага әһәмият бирмәүләре һич аңлашылмый. Ә бит Россия телевидениесе безнең Корылтай турында нәрсә генә әйтмәде! Әнә шундый вакытта Казан радио-телевидениесенең дәшми торуы бик сәер уйлар уята. Әлбәттә, биредә иң беренче булып «курку» дигән фикер килә. Ра-

дио-телевидение җитәкчеләре үз урыннары өчен куркалар. Югарыдагыларның ачуын китерүдән куркалар. Ләкин бит үз урының өчен курыксаң да, журналистика таләпләре бар бит әле. Ә алар тормыш фактлары турында объектив информация бирүне таләп итә. Аларны тиешенчә яктыртуны таләп итә. Безнең радио-телевидение җитәкчеләре исә үзләренең шәхси мәнфәгатьләрен халык таләбеннән өстенрәк күрәләр икән. Тормыш ничек кенә барса да, алар һаман алгы планга үз максатларын куячаклар икән! Ләкин халыктан, милләттән аерылган радио-телевидение киләчәктә кемгә кирәк булыр соң?! Андагы җитәкчеләр бүген әнә шул сорауны да истән чыгармасыннар иде. Гел куркып яшисең икән, үз халкыңнан оялу һәм соңгы чиктә шул ук курку турында да онытмаска кирәк.

Әсәрләр...

Иртәгә Татарстан язучыларының үткән әдәби ел йомгакларына багышланган традицион җыелышы була. Шуңа күрә без дә 1991 ел эчендә басылган әсәрләргә әйләнеп кайтыйк, кайбер нәтиҗәләр ясыйк. Әдәбиятның иң төп жанры дип саналган проза өлкәсендә үткән ел эчендә нинди үзенчәлекләр күзәтелде соң?

Иң башта бик тә сөенеп шуны билгеләп үтәсе килә: исемнәре соңгы елларда гына күренә башлаган байтак кына авторларның былтыр саллы-саллы проза әсәрләре дөнья күрде. Нәзифә Кәримованың «Карурманнан чыккан юлчылар»ы, Зәки Зәйнуллинның «Сугыш алды малайлары», Флүс Латыйфинең «Хыянәте» — минемчә, әнә шундыйларга керә. Шулай ук Әнәс Галиевнең «Һәр солдатның үз уе» белән Гурий Тавлинның «Афәт»ен дә бу төркемгә кертергә мөмкин. Чөнки бу язучылар да безнең бүгенге укучы тарафыннан өр-яңа әдип итеп кабул ителә.

Ә эчтәлек ягыннан алганда, бу әсәрләрнең барысы да безнең ерактагы һәм якындагы үткәнебезгә караган. Нишлисең, үткәнебез хакында әйтелмичә җыелып килгән сүзләр бик күп шул! Әдипләребезне дә әнә шулар борчый, дулкынландыра, әлбәттә. Ул әсәрләрнең сыйфат ягыннан шактый яхшы язылулары да күңелдәге куаныч хисен арттыра, бу авторларның әле яңа әсәрләр язып безне тагын куандырачагына өмет бирә.

Күренекле әдипләребез Нурихан Фәттах белән Мөхәммәт Мәһдиевнең былтыр басылган әсәрләрендә дә («Кичү» һәм «Ачы тәҗрибә авазы») якындагы үткәнебез чагыла. Әхсән Баянның «Җәй белән җәй арасы» исемле әйбәт повесте да үзәккә сугыштан соңгы елларны алган.

Әйе, боларның һәммәсе бик тә кызыксынып укыла торган һәм тирән эчтәлекле роман-повестьлар. Аерым-аерым алганда аларның берсенә дә авыр сүз әйтеп булмый, уңышлы әсәрләр. Ләкин менә укучы бар бит әле. Аның күңел ихтыяҗлары күптөрле бит. Үткән тормыш турында гына түгел, ә хәзерге чор хакында да кызыклы роман-повестьлар укыйсы килә бит аның!

Әллә соң «бүгенге көн турында бүген әдәби әсәр язу мөмкин түгел» дигән фикер дөресме икән? Шул сәбәпле безнең әдипләр тормыш материалының үз күңелләренә утыра төшүен көтәме әллә?

Алай дисәң, ә нишләп бүтән милли әдәбиятларда чорның рухи ихтыяҗларын бик тә тирән чагылдырган әсәрләр еш күренә тора. Үткен социаль һәм әхлакый конфликтлар киң ачыла.

Менә шундыйрак чагыштырулар ясаганнан соң, «безнең әдипләр бүгенге көн агышына битарафрак, ахрысы» дигән шик туа. Югыйсә Фәрит Гыйльминең «Зәйтүнәкәй, акчарлагым» шикелле гыйбрәтле әсәрләр берәү генә язылмаган булыр иде...

Шушы яктан караганда, Гариф Ахуновның «Гомер юлы» исемле романы кызыклы гына фикерләр кузгата. Ел башында әсәр журналда басылып чыккач, аны укыган кешеләрдән төрле сүзләр ишетергә туры килде. Каршылыклы фикерләр тууга күп очракта төп геройның колхоз председателе булуы сәбәпче дип аңладым. Чөнки Яңарыш чоры башлангач, без җитәкчеләр хакындагы начар сүзләрне бик тә күп ишеттек. Аларның байтагы, чыннан да, шундыйдыр. Торгынлык системасы бик күп очракларда эш эшләмичә тел белән лыгырдап йөрүче, шома кешеләрне генә җитәкче итеп күтәрә иде... Ләкин без тагын шуны да беләбез бит әле: җитәкчеләр арасында, сирәк кенә булса да, чын-чыннан кешелекле шәхесләр дә бар иде бит! Алар халыкны һәм гаделлекне яклап шактый көрәштеләр бит! Андый мисалларны без тормышта күргәләдек ич.

Г.Ахунов романы үзәккә әнә шундый фидакарь жанны алган. Әлбәттә, анда купшы сүзләр һәм әдәби әсәргә берни дә бирми торган арзанлы күренешләр дә бар. Ләкин, нигездә, бу роман халык һәм милләтнең кадерле кешеләре турында дулкынланып язылган әсәр.

Безнең заман әдәбияты өчен мөһим булган тагын бер мәсьәләне ачыклап китәсе килә. Производство романнарына каршы көрәш ачабыз дип, без инде тагын икенче бер чиккә ташлана күрмик. Һәммәбезнең ярты вакыты эштә үтә икән, анда без кеше буларак гаять күп яктан ачылабыз икән, эш дөньясында заманның гаять гыйбрәтле бәрелешләре бара икән, димәк, боларның иң мәгънәлеләре әдәби әсәрләрдә дә чагылырга тиеш. Әнә ич, чит ил язучылары иҗат иткәч, заманында А.Хэйлинең «Аэропорт» һәм «Тәгәрмәчләр» исемле романнары турында күпме шау-шу купты ич!

Кыскасы, чорыбыз кешесен күп яктан һәм тирән чагылдырырга тырышыйк. Әдәбият һәм сәнгать кануннарына хилафлык итмик. Бусы барыбыз өчен дә уртак позициядер, мөгаен...

Вакыйгалар...

Һәрбер татар кешесе кебек үк язучылар өчен дә үткән ел вакыйгаларга бай булды. Ул вакыйгаларның иң зурысы, милләт өчен иң мөһиме, әлбәттә, бәйсезлек өчен көрәш... 1991 елга йомгак ясау уңаеннан әлеге иң җитди көрәшнең дә кайбер сабак һәм нәтиҗәләрен искә алып үтәсе килә.

Иң элек, татар язучылары арасында бәйсезлек көрәшенә карашның ике төрле булуын әйтеп үтәргә кирәк. Берәүләр: язучы бу көрәштә һичшиксез катнашырга, алай гына да түгел, аның иң алгы сафында булырга тиеш дип саный. Ә икенчеләре исә: юк, әдип кешенең төп эше язу булырга тиеш, дип уйлый. Аларча, иҗат кешесе, сәясәт һәм көрәш белән мавыгып, кыйммәтле вакытын әрәм итәргә тиеш түгел!

Язучылар даирәсендә соңгы фикерне яклаучылар бик күп. Мөгаен, барлык әдипләрнең дүрттән өч өлешен тәшкил итәдер болай дип уйлаучылар.

Хәзер, әйдәгез, бергәләп уйлап, чамалап карыйк. Хәлне аңлау өчен бер чагыштыру да китерәсе килә.

Без игенче хезмәтен иң мөһим, иң изге эш, дибез. Ул, чыннан да, шулай. Игенче — дөньядагы барлык һөнәрләрнең иң мактаулысы, иң мөһиме, иң җитдие. Ләкин илгә, милләткә куркыныч яный башласа — иң кирәкле эш эшләүче игенче кеше дә, кулына корал алып, газиз илен дошманнан якларга китә. Димәк, илне, халыкны яклау — игенче эшеннән дә мөһимрәк булып чыга... Кешелек дөньясының бөтен тарихы әнә шуны күп мәртәбәләр һәм ышандырырлык итеп раслый...

Шулай булгач, язучыларыбызның бик күп өлешенең милли азатлык көрәшеннән читтә торуны хуп күрүен нәрсә белән аңлатырга икән соң? Илгә, милләткә куркыныч янаган чагында, хәтта иң җитди эш кешесе булган игенче дә көрәшкә китә, дидек бит...

Күрәсең, биредә бер нәтиҗә килеп чыгадыр инде: иҗатчы буларак өлгергән байтак кына әдипләрнең әле гражданин буларак өлгереп җитәсе бардыр... Шәхес культы һәм торгынлык елларыннан калган курку да үзен нык сиздерәдер...

1991 елда Фәүзия Бәйрәмова, Зәки Зәйнуллин, Әмир Мәхмүтов, Әбрар Кәримуллин, Роберт Батуллин кебек язучыларыбызның көрәш фидакарьлеге безнең сокланuыбызга лаек! Ә бер төркем язучы депутатларыбызга сессиядә Штанин-Грачевлар сыман үтә дә актив булырга нәрсә комачаулый? Язучы һәм депутат исемен йөртү — көрәшче булуны сорый бит.

Базар экономикасына килеп керү нәтиҗәсендә милли матбугат һәм әдәбиятның гаять кыен хәлгә куелуы да әле алда күп фидакарьлек, тырышлык сораячак. Җаваплы урыннарда эшләүче язучы иптәшләребездән дә милләт мәнфәгатьләре өчен ныграк борчылу соралачак. Иң мөһиме — әнә шундый зур максат өчен бергә туплану, киңәшә-киңәшә бергә эшләү һәм иҗат итү кирәк булачак. Милләт һәм әдәбият дигән изге максат быел — 1992 елда — татар язучыларын берләштерсен иде. Киләсе елда сөенеп сөйләрлек зур-зур эшләр, җитди әдәби әсәрләр юлдаш булсын иде!

Әсәрләр...

Тормыш мәсьәләләре нинди генә төс алып куерса да, яз җитү белән, безнең күңелләр барыбер шигъри дулкынга — хис дулкынына көйләнә. Сәясәт давыллары һич кенә дә яшәеш кануннарын боза алмый! Соңгы атналарда дөнья күргән көндәлек матбугат та әнә шуны раслый. Газета битләрендә бер генә хикәя дә юк — гел шигырь хакимлек итә.

Ләкин шунысы бар: ул шигырьләрдә безне бүген иң борчыган уйлар, кичерешләр кайнар дулкын булып яши. Менә Лена Шагыйрьҗанның «Татар хатыны» исемле әсәрен генә карагыз:

Түземлекләр җиткәч чигенә,
Сынау килгәч туган иленә,
Килеп басты татар хатыны
Көрәш сызыгының чигенә,
Ал яулыгын салып иңенә.

Туп-туры итеп әйтмәсә дә, шагыйрәнең бүгенге көрәшләр турында сүз алып баруын бик тә яхшы аңлыйбыз без. Әйе, милләтебезнең Сөембикәләре элек тә булган, хәзер дә бар! Менә шундый ялкынлы шигырьләр иҗат итүче шагыйрәләрне шулай ук алгы сафта дияргә кирәк, чөнки аларның кайнар хисле шигъри сүзләре бүген милләтне берләштерә, алга өнди.

Шагыйрә Флера Гыйззәтуллинаның март башларында радио аша ишетелгән шигырьләрен дә без чын-чыннан мөкиббән китеп тыңладык. Нәкъ менә татар хатынына гына хас булган соклангыч күңел дәрьясы ташыды ул минутларда!

Ә Илсөяр Иксанова исә яралы йөрәкләрне болай тасвирлый:

...Бар өметләр сүнеп беткән мәлдә,
Соңгы яра булып син калыктың.

Бу арада шулай ук Эльмира Шәрифуллинаның, Бикә Рәхимованың, Фәйрүзә Мөслимованың да бик матур шигырьләре дөнья күрде.

Борын заманнардан бирле матур-матур гөлләр үстерә килгән татар шигъриятенең бүген дә «күз тимәсен!» дип әйтерлек уңышлары бар. Зур талантка ия шагыйребез Кадыйр Сибгатуллин да соңгы елларда икенче сулышын тапты бугай:

Әниләрнең шушы мәхәббәте
Уйландыра мине күптәннән.
Җаныбызга бүген җитмәгәнне
Без эзлибез никтер үткәннән.

Аның «Әни мәхәббәте» дигән шигыренең «Гомерләрне кичү кирәк икән Мәхәббәтне чынлап аңларга» дигән юллар белән тәмамлануы шагыйрь иҗатындагы яңа һәм җитди үрләр хакында сөйләүче бер мисал булып тора.

Узган атнада шагыйрь Зәет Мәҗитов та үз лирикасыннан матур бер тәлгәш бүләк итте. Аның хисләрендә яңа үзгәрешкә булган өмет болай чагыла:

Колагымда йөргән әрнүле моң
Гомерем буе җанны өтәрме?
Һаваларда йөзә яңа болыт,
Әллә тагын яумый үтәрме?

Әле алай гына да түгел: укучыларыбыз арасыннан да сәләтле шагыйрьләр табыла тора. Мисал өчен көндәлек матбугатта инде берничә мәртәбә С.Гыйлемханов дигән әфәнденең матур гына шигырьләрен күргәнем бар. Аның «Бетерелгән авылым урынында» дигән шигыре миңа аеруча тәэсир итте.

Кошлар кайтмас, кешеләрне бире
Сагынулары алып килерләр.
Шаулап узган гомер язларыдай,
Мәңге юксындырыр бу җирләр.

Проза әсәрләре укырга теләгән кешеләргә инде бер генә юл кала: журналларга һәм китапларга мөрәҗәгать итү. Ләкин прозаиклар үзләре көндәлек матбугатта кызыклы-кызыклы язмалар белән чыга торалар. Бу арада М.Мәһдиев белән М.Галиев андый әсәрләрне мул бирде. «Татарстан яшьләре»нең 7 март санында бирелгән «Әхлаклы яңа мәгыйшәт кирәк...» дигән мәкаләдә без М.Мәһдиевнең совет идеологиясе хакындагы гыйбрәтле уйлануларын укып фикри дөньябызны баеттык. Болар безнең күңел күзен ача торган әсәрләр.

Вакыйгалар...

Язучылар тормышына кагылышлы бу өлештә игътибарны бүтән вакыйгаларга таркатмыйча, бары тик алда торган референдум турында гына фикер алышасы килә. Чөнки бүген язучы өчен дә, гомумән, һәммә татар кешесе өчен дә, шуннан мөһимрәк бүтән вакыйга юк.

Узган ел булып үткән президент сайлаулар вакытында Казан шәһәрендәге байтак кына сайлау комиссияләренең эшен якыннан күзәткән кеше буларак (ул чагында без шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән сайлау комиссиясендә дежур торган идек), кайбер уй-фикерләр белән уртаклашасы килә. Референдумның гадел узуы өчен түбәндәге хәлләрне белеп тору бик кирәк. Узган еллар тәҗрибәсе әнә шуны күрсәтә.

Беренчесе. Казандагы бик күп сайлау комиссияләрендә өлкән туган вәкилләре өстенлек итә. Күбесендә хәтта туксан процент тәшкил итә. Узган сайлаулар вакытында үз дигәннәренә ирешү өчен алар күптөрле закон бозуларга бардылар. Килгән сайлаучыларны үгетләү, ышандырырга тырышу күренешләре күп мәртәбәләр кабатланды.

Бу юлы да сайлау комиссияләренең составы нәкъ шундый булачак. Җитмәсә әле, ул милләт вәкилләрен читтән бик каты котырту да бара. Быел аларның коткысы былтыргыга караганда бик нык көчле. Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: сайлау комиссияләренең эшенә быел бик нык күзәтчелек итәргә кирәк! Казан шәһәрендә үз дигәннәренә ирешү өчен алар төрле алымнар һәм хәйләләр кулланачаклар. Бигрәк тә өлкән буын вәкилләрен юлдан яздырырга тырышачаклар. Ә безнең өчен һәр кешенең тавышы кадерле. Һәм, гомумән, алдау, хәйлә биредә булмаска тиеш! Безгә артыгы кирәкми!

Икенчесе. Әнә шундый эшне оештыру өчен, ягъни сайлау комиссияләренең гадел эшләвенә күзәтчелек итү өчен, Татар иҗтимагый үзәгендә дә, Татарстан Язучылар берлегендә дә теләгән кешеләрне күзәтче итеп рәсмиләштерү эше бара. Кулында таныклыгы булган андый күзәтчеләр сайлау комиссияләре эшендә баштан алып ахырга кадәр катнаша алалар.

Менә шушы мөмкинлектән файдалансак иде без.

Иң мөһиме «Шәһри Казан»ны укучы бер генә кеше дә бу мөһим эштән читтә калмасын иде! Күрәсезме, «Вечерняя Казань» безнең Татарстанга каршы котырту эшен ничек актив алып бара! Үзләрен туендырган, киендергән республикага каршы алар килешү белмәстәй сугыш ачканнар да, Татарстан бөтен дөнья алдында хур булса, боларның бик тә, бик тә күңелләре булачак, имеш! Әйдәгез, без дә үз дәү-

ләтебезне ятлар каршында оятка калдырмыйк — референдумда җиңеп чыгу өчен, һәр кеше үзеннән өлеш кертсен!

Киңәшеп эшләгәндә һәм бердәм булганда, безнең халык моңа кадәр бик күп кыенлыкларны җиңеп чыга алды. Иншалла, бу юлы да бирешмәбез. Ләкин аның өчен, әйдәгез, бүгеннән үк тырышыйк!

1991–1992

Рухи ныкмы без?

«Аргамак» журналының әле генә безнең кулга килеп кергән 8 нче санында шушындый бер вакыйга турында языла. 1949 елда Ютазы районына Миңнеханов дигән бер адәм җитәкчелек итә. Ул анда чын вәхшиләрчә кылана: үзе һәм аның әшнәләре шашып байый, ә гади халык ачтан интегә, атлар ябык булганга күрә, норма үти алмаучыларга ул: «Себер — каторга!» — дип кенә акыра, күп кешене МВД ярдәмендә юкка да чыгара. Кыскасы, бөтен район моннан кан калтырап тора.

Шулай тулы бер район нишләргә белми тилмергәндә, япь-яшь, әле армиягә да бармаган, кыю бухгалтер егет табыла. Ул көч-хәл белән Казанга килеп җитә, республика газетасының баш мөхәррире Үзбәков янына кереп, Ютазы районындагы хәлне сөйләп бирә. Ә Үзбәков исә партия өлкә комитетына бара, республика прокуратурасы эшкә җигелә, яшь егетне өлкә комитеты бюросында тыңлыйлар. Нәтиҗәдә теге вәхшигә — 15, ә аның берничә әшнәсенә — 10 ел төрмә!

Әнәс Халиков дигән бер яшь егет башлаган эш әнә шулай тәмамлана!

Менә хәзер, безнең көннәрдә, әлеге вакыйга турында укыганда, бу егеткә сокланмый мөмкин түгел. Түрә итеп куелган адәмнең комсызлыгына һәм чамасыз ахмаклыгына каршы, аның күптәнге әшнәләренә каршы япа-ялгыз күтәрелгән намуслы яшь йөрәкнең батырлыгы сокландыра! Әле ул чакта — Сталинның төрмә режимы шартларында да — бу яшь йөрәк җиңеп чыга алган бит!

Кеше рухының көче, аның ныклыгы дигән сүз бу!

Ә менә хәзерге күп укыган һәм үзен бик тә «зыялы» дип санаучы буын рухи яктан ныкмы соң? Тирә-юнебездә әлеге Миңнеханов ише ерткыч ханнар — хамнар һаман ишәя бара бит... Шул ноктадан карап, бүгенге матбугатка күз салыйк әле.

Биредә иң беренче булып Фәнзаман Баттал әсәрләре күзгә ташлана. Юмор-сатирада булсын, публицистикада булсын — ул һәрчак халыкның үзәгенә үткән нәрсәне, чын хакыйкатьне ярып әйтеп бирә ала. Шуңа күрә кайсыбер баш мөхәррирләр аның язганнарын бастырып чыгарырга куркыбрак та калгалыйлар дип ишетәм. Ләкин моңа карап кына чын һәм кыю иҗатчы туктыймыни соң?! Менә «Шәһри Казан»ның 20 сентябрь санында да Ф.Баттал «Чираттагы сугыш кайда башланачак?» дигән бик үткен сораулы мәкалә бастырды. Күршеләребез турында безгә бик җитди мәгълүмат бирде ул, кем белән эш иткәнебезне истән чыгармаска чакырды.

Әдәбият-сәнгать әһелләренең яраткан газетасына әйләнә баручы «Мәдәни җомга» да үткен, бәхәсле язмаларны һаман ешрак бирә башлады. Мисал өчен, Сәрмәдия Сөләйманның 6 сентябрьдә басылган «Исемсезгә инде нишләргә?!» дигән язмасы бик күп намуслы әдипләрнең фикерен чагылдыра. Чыннан да авторның: «Дөньяны исемлеләргә һәм исемсезләргә бүлү ул — иҗат коллективларындагы ызгыш-талашның, кирәкмәс бәхәсләрнең нигезе. Сәнгать, иҗат кешесе максатын яңа биеклекләргә юнәлтәсе урынга исем артыннан чаба башлый»,— дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Аның «Нияз Акмал шигырьләрен тыңлаганда, күзләремә яшь килә, Мөдәррис Әгъләмов шигырьләрен тетрәнми уку мөмкин түгел» дигән сүзләре дә талантлы иҗатчыларны рухландыручы хакыйкать авазы булып яңгырый.

Чаллыда яшәүче һәм гаять үзенчәлекле талантка ия әдип Фаяз Дунай да бу фикерне дәвам итә: «Ихласлык — ихлас шәхескә тормышта күп кыенлыклар, бәлаләр китерсә дә, кешеләр яшәешен һәрдаим балкытып, җемелдәтеп, үзара мөнәсәбәтләр атмосферасын пакьләп, сафландырып торучы садә җил, изге нур ул! Ихлас шәхес теле, гамәлләре белән безгә игелекле тәэсир итеп, каткан күңелләребезне эретеп җибәрә» (Аргамак, 8 нче сан).

Әйе, бу әдипләр чын һәм олы иҗатның нигезе булган ихласлык, намуслык, гаделлек, кыюлык турында сүз алып баралар. Безнең бәхетебезгә, әле генә санап кителгән асыл сыйфатларны үзләрендә гәүдәләндергән тере әдипләребез дә бар. Әле күптән түгел генә арабыздан бер исем дә алмыйча китеп барган Салих Баттал әнә шундый иде... Партия хакимлеге чорында озак еллар буена үзенең ныклы иҗади юлын саклап кала алган һәм соңгы еллар әдәбиятыбызның иң гүзәл әсәрләрен иҗат иткән Әмирхан ага Еникинең рухи батырлыгы да безне сокландыра. Нурихан ага Фәттахның милләтебезгә, әдәбиятка булган фидакарьләрчә олуг хезмәте баш идерә...

Инде яшьрәк буын иҗатчыларга килик. Дөресен әйтим, соңгы елларда менә бу — без әйтергә теләгән мәсьәлә шулкадәр дә нык онытылды, читкә тибәрелде, хәтта хәзер әлеге мәсьәләнең ни икәнен халыкка һәм шул исәптән бик күп иҗатчыларга озаклап, тәфсилләп аңлатып бирү сорала шикелле. Ләкин биредә бүген андый мөмкинлек юк. Бәлки, кыскача болай дип аңлатып караргадыр — сүз иҗатчының фани дөнья алдавычларына кызыкмый торган олы рухи максаты булу-булмау турында бара. Иҗатчы кешенең үз яшәешендә югары әхлаклы олы иҗат таләпләренә тугры кала алуы яисә алмавы хакында бара.

Әйе, бүгенге тормышның алдавычлары күп. Язучының Тукай бүләген аласы да килә, делегация эченә кереп бушлай чит илләргә дә барасы килә... Язучылар берлегеннән акчалата ярдәм дә кирәк, фатир да кирәк...

Менә болар барысы да рухи яктан көчсез булган сәләтле генә әдипләрне «ялагайлану», «гаделлекне сату» дигән түбәнлеккә төшерә. Соңгы еллар әдәби хәрәкәтендә мин бу хәлләрне бик еш күрә башладым. Зур гына әдипләрнең шул хәлгә төшүе — яшьләргә начар үрнәк күрсәтүе бигрәк тә аяныч!

Башка төрле мисаллар да бар. Менә минем алдымда олы галимебез Әбрар ага Кәримуллинның Татарстан китап нәшриятында быел гына басылып чыккан (шушындый шәп җыентык өчен нәшрият җитәкчелегенә рәхмәт!) «Язмыш, язмыш...» китабы. Татар милләтенең зурлыгы, бөеклеге ничек ачык чагыла анда! Әле бу көннәрдә Үзәк телевидение, Америка материгындагы Майя цивилизациясе турында зур тапшыру күрсәтеп, безнең Әбрар ага эзләнүләренең дөньякүләм әһәмиятле икәнлеген тагын бер мәртәбә раслады.

Әйе, татар егетләре бүген дөнья балетында йолдыз булып балкый! Татар егетләре бүген шахматта дөнья беренчелеген дәгъвалый! Татар егете, Рәсәй Президентына операция ясап, аны үлемнән коткарырга җыена һ.б.

Ә менә хәзер милләтнең рухи нигезе булырга тиешле, аңа бүген рухи канат булырга тиешле әдәбиятыбыз һәм аның күренекле әһелләре әлеге егетләр дәрәҗәсендәме соң?! Без әле һаман элеккеге автономияле республика язучылары биеклегендә генә эш һәм фикер йөртәбез түгелме?! Бүген күтәреләм дип торган татар милләтенә көчле рухи канат бик тә, бик тә кирәк бит! *1996*

Төп максатыбыз нәрсә?

Бүген бәйрәм көн булса да, республикабыз тормышының иң мөһим яклары турында уйланмый мөмкин түгел.

Әйе, җитәкчеләребезнең акыллы сәясәте нәтиҗәсендә без «базарга акрынлап, ипләп керүче» буларак танылдык. Күпмедер дәрәҗәдә моның өстенлекләрен дә күрдек...

Әйе, федераль үзәк белән мөнәсәбәттә без «Татарстан моделе»н тудыра алдык һәм, мәгълүм Шартнамәгә кул куеп, республикада тормышның тыныч агуы өчен нигез салдык. Монысында татар халкының элеккеге зур тарихы һәм көчле дәүләтләре булу, гасырлар дәвамында азатлык өчен көрәш бару, сиксәненче еллар ахырында ул көрәшнең тагын да көчәеп китүе, сәяси мәйданга Ф.Бәйрәмова, З.Зәйнуллин кебек фидакарь көрәшчеләр чыгу һәм шулай ук М.Ш.Шәймиевнең сабыр, төпле сәясәте мөһим рольне уйнады, әлбәттә.

Шулай итеп, без хәзер Татарстанны, нигездә, «тыныч чор тормышына кереп китте» дип әйтә алабыз.

Рас шулай икән, димәк, хәзер без әнә шул үзебез төзи башлаган тормышның асылы, аның реаль эчтәлеге турында конкрет уйланырга тиешбез. Аны үзебез өчен ачыклап бетерергә тиешбез.

Бигрәк тә ачыкланырга тиешле сорау: безнең төп максатыбыз нәрсә? Саф капиталистик мөнәсәбәтләргә нигезләнгән көчле икътисад булдырумы? Әллә сәламәт, көчле икътисад нигезендә кешенең иректе, рухи яктан бай һәм гармоник үсешенә ирешүме?

Икенче төрле әйткәндә: үзәккә нәрсәне куярга — икътисадныме, әллә кешенеме?

Минемчә, үтеп киткән 70 ел эчендә ике социаль система әнә шул сорауларга икесе ике төрле җавап табарга тырышты. Ә инде ике системаны үзара килештерергә теләгән теорияләрне (мәсәлән, француз галиме Р.Гароди теориясен) без кискен тәнкыйтьләдек. Тагын бер мәртәбә уйлап карасак, бәлки, хәзер безнең өчен нәкъ әнә шундый өченче юл кулайрактыр? Саф капиталистик юлның кешене, шәхесне ничек ныкызүе шулай ук күз алдында бит.

Аннан соң үзәк матбугат инде берничә ел буена менә бу хакта да яза башлады: бары тик ашау-эчүгә һәм күбрәк куллануга гына нигезләнгән система хәзер Көнбатышны рухи-әхлакый тупикка алып керде.

Димәк, бу яктан караганда да, без үзебездә саф капиталистик мөнәсәбәтләр генә урнаштыра алмыйбыз икән. Ныклап уйларга кирәк!

Бу мәсьәләдә безнең юл Русиянең алдынгы көчләре тәкъдим иткән юлга якынрак тоела. Алар инде байтак вакыттан бирле югары әхлаклы кеше тәрбияләү дәүләтнең иң зур бурычы булырга тиешлеген раслап киләләр. Мондый аек акыл авазын, ниһаять, югарыда да ишеттеләр бугай — соңгы арада Мәскәү даирәсендә идеология буенча зур эш башланырга тора.

Рухи-әхлакый тәрбиянең соңгы елларда онытылуын безнең республика матбугаты да еш язды, бу хакта бездә дә җитди-җитди мәкаләләр басылды. «Әдәбият хәлләре»ндә урын алган язмалар да әлеге гаять үткен мәсьәләгә кабат-кабат басым ясадылар. Ләкин бездә матбугат аша әйтелә торган халык фикерен өйрәнү эше оештырылмаган шул әле. Халык мәкале биргән сабакның — «бер баш әйбәт, ләкин ике баш тагын да яхшырак» дигән акылның кыйммәте бездә әле аңланып җитми шул! Ә бит республика матбугатында әйтелгән уңай фикерләр өйрәнелеп эшкә җигелсә, уртак үсеш өчен никадәр файда булыр иде!

Әмма соңгы арада (әллә инде Мәскәүдә идеология турында сүз кузгалу сәбәпле, әллә безнең зыялыларның еллар буе тилмерү авазларын ишетеп) әхлакый-рухи тармакка күпмедер дәрәҗәдә игътибар арта төште шикелле. Болай дигәндә мин иң элек Президентыбызның яшь язучылар белән очрашуын, «Сөембикә» журналы редакциясендә булуын һәм Министрлар Кабинетының чираттагы утырышында Татарстанда полиграфияне һәм китап бастыруны үстерү программасы проекты тикшерелүне күздә тотам.

Әйе, полиграфия — матбугатның да, әдәбиятның да нигезе. Эшне шуннан башламыйча булмый. Ләкин шуның белән бергә республикадагы китап кибетләренең дә гаять мөшкел хәле онытылмасын иде. Әнә бит «Шәһри Казан» газетабызның 16 август санында Казандагы 18 нче китап кибете директоры Рафилә ханым Харитонова нинди аяныч күренеш турында яза. «Керем бирмисез» дип ябалар икән китап кибетләрен! Китап бит ул — тәрбия чарасы. Ә тәрбиянең ни өчен кирәклеген безнең җитәкчеләр аңламый микәнни?! Хәзер бик үсеп киткән җинаятьчелекне бит милиция белән генә җиңеп булмый. Кешегә яшь чагыннан ук тиешле тәрбия биреп кенә җиңәргә мөмкин бит аны. Комплекслы чаралар белән генә. Ә китап кибетләре әнә шул тәрбия системасында гаять мөһим урын били. Кыскасы, бездә моңа кадәр төзелгән әхлакый тәрбия системасы бүген — безнең көннәрдә җимерелмәсен иде инде! Әгәр шулай булса, бу — милләткә, халыкка каршы эшләнгән зур җинаять дип бәяләнергә тиеш. Һәм аның өчен җавап бирүчеләр дә булырга тиеш!

Милли матбугатыбыз базар стихиясендә батмаска тырыша. Әлегә яшәп ята... Бу көннәрдә кулыма «Аргамак»ның июль саны килеп кереп бик сөендерде. Баш мөхәррир булып М.Мортазин эшли башлагач, ул тагын да җанланып китте сыман. Соңгы саннан мин, мәсәлән, Я.Игънәйнең үткен эчтәлекле язмасын да, Ә.Моталлаповның «Рәнҗеш» повестен да кызыксынып укыдым. Чаллыда яшәп иҗат итүче яшь язучы Факил Әмәкнең уңышын исә аерым билгеләп үтәсе килә. Аның бу сандагы «Аяусыз әүлия» дигән хикәясе кырыс тормыш чынбарлыгын, кеше холкын нечкә чагылдыруы белән истә кала. Алай гына да түгел: Факил Әмәк «Мәдәни җомга»ның үткән санында шагыйрь Зөлфәт иҗаты турында менә дигән әдәби тәнкыйть мәкаләсе бастырып та укучыны нык сөендерде. Үзе дә әдәби әсәр булып чыккан ул язма — шундый тәэсирле һәм тирән эчтәлекле!

Иң милләтпәрвәр язучыларыбыздан берсе Зәки ага Зәйнуллин хәзер әдәби иҗатка муеныннан чумды. Бик гыйбрәтле тормыш юлы үткән бу олы шәхеснең һәр әсәре истә кала торган булып чыга. Менә «Идел»нең июль ае санында да ул, тарихи хикәяләр конкурсында катнашып (әмма ни аяныч — редакция шушы ике сүздә ике хата җибәргән, «тарихи хикәяләр» дип язган!), «Канзәфәр» дигән югары сәнгатьчә эшләнгән, тарихи булса да эчтәлеге белән безнең бүгенге хәлебезгә ишарәләгән әсәр бастырды. «Казан» журналының татарчасында милләтебезнең мәрхүм олы галиме Фуад Вәлиев турында һәм янәшәдә генә аның кызы Гүзәл Вәлиеваның күп язмалары бирелү дә хуплауга лаек күренеш.

Берничә басмада бәхәс рухында язылган мәкаләләр дә дөнья күрде һәм алар, уртак эзләнүләр аша хакыйкатькә бару адымнары буларак, шулай ук хупланып кабул ителергә тиешләр. Бу — республикабызда урнашкан сәламәт климат турында сөйли. Әмма моны нык уйланган һәм системалы яңа карарлар, реаль адымнар белән тагын да ныгытырга иде.

1996

Кемгә иман кирәкми?

Америкача яшәү үрнәге бүгенге яшьләребезнең генә түгел, ә иң югары дәрәҗәдәге җитәкчеләребезнең дә башын әйләндерә бугай. Бу илнең фәнни-техник һәм җитештерү өлкәсендәге казанышларына

кызыгып, ул илнең җирле халыкны кырып бетереп, шуларның сөякләре өстенә салынган дәүләт икәнен уйламый шикелле алар. АКШның төрлесе төрле яктан килгән кансыз һәм имансыз эшкуарлар тарафыннан төзелгән ил икәнлеген истән чыгаралар сыман алар.

Әмма онытмыйк: безнең халыкта «имансыз», «денсез» дигән сүзләр иң әшәке ачулану сүзе булып тора. Бары тик коры исәп-хисапка, хәйләгә һәм ерткычлыкка гына таянган яшәү рәвешен безнең халык кабул итә алмый. Икътисад өлкәсендә «базарга йомшак керү» дип үзенчәлекле юл сайлый алган безнең җитәкчеләр рухи-әхлакый өлкәдә дә үзебезгә генә хас булган һәм дөрес юнәлешне таба алсыннар иде. Җитәкчеләр өчен табылырга тиешле, ә зыялыларыбыз күреп, белеп торган ул юл, ул юнәлеш Американыкы һәм Көнбатыш илләренеке белән һич кенә дә туры килми.

Дәүләт Советы сессияләрендә һәм матбугатта да бу хакта, ягъни рухи-әхлакый өлкәгә игътибар ителмәү турында еш кына әйтелә. Халык депутатлары Т.Миңнуллин, Р.Вәлиев, Р.Мөхәммәдиев, Р.Миңнуллин һәм башкалар мәртәбәле трибунадан инде берничә мәртәбә ул турыда сөйләделәр. Ләкин бу юнәлештә әле бернинди дә кымшану сизелми. Моны ничек аңлатырга мөмкин соң?

Рухи-әхлакый тармакның тормыш өчен ни дәрәҗәдә мөһим икәнлеген аңлый алмау нәтиҗәсеме бу?

Яисә инде дежур җавапка — тимер калканга әйләнгән «акча җитми»гә кайтып каламы моның сере?

Әллә инде... Әллә инде югарыдагылар базарга кергәч, безнең республикага әхлак бөтенләй кирәк булмаячак дип уйлыйлармы икән?

Менә бу соңгы фикерне да нигезсез дип булмый. Чөнки әлегә бездә номенклатура өчен «җаен белеп кенә урла» дигән канун нигез итеп куелган. Алар бер-берсе белән әнә шул нигездә тоташкан, берләшкән. Бәс, эшләр шулай тора икән — алай уйлаучыларга синең гаделлегең, әхлагың нигә кирәк булсын ди?! Андыйларга бик нык комачаулый гына ич ул әлеге без тәкрарлаган сүзләр!

Кыскасы, хәзер республикада рухи-әхлакый тәрбия эшен системалы оештыручы бер зур җитәкче кирәклеге өлгергән мәсьәлә булып алга килеп басты. Күптән түгел генә бездә булган вице-президент посты мондый җитәкче өчен бик кулай булыр сыман. Югыйсә бу тармак тәмам таркалып бара бит.

Ә борчулы хәбәрләр газеталарда бер-бер артлы басыла тора. 24 апрель көнне «Ватаным Татарстан»да опера театрындагы күңелсез хәлләр турында Зилә Сөнгатуллина мәкаләсе... 7 майда «Шәһри Казан»да Әгъзам Фәйзрахмановның «Алар әйбәт кешеләр, ләкин эш тә бар бит әле» дигән тирән эчтәлекле язмасы. 21 май санында шушы ук газетабызда тәҗрибәле журналист Рәисә Яхинаның укытучылар конкурсындагы гаделсезлек турында әрнеп язуы... Болар әле соңгы вакытта гына дөнья күргән мәкаләләр. Академик Флүн Мусинның «Рухи әләм менсен биеккә» дигән зур мәкаләсе дә әнә шул идеяне алга сөрә, фәнни яктан дәлилли.

Юк, татар зыялылары бүген «тәрбия кирәк!» дип кенә утырмыйлар. Көндәлек матбугатны даими укып барган кеше бик яхшы күрә: татар зыялылары халыкны рухи-әхлакый тәрбияләү эшен дә уңышлы гына алып баралар. Хезмәтләре өчен бөтенләй диярлек түләнмәсә дә, алар иманга фидакарьләрчә тугрылык саклап, үзләренең олы вазифаларын җиренә җиткереп үтәргә тырышалар. Менә бер генә мисал. «Казан утлары» журналының апрель санында өлкән әдибебез Әнәс ага Галиевнең «Җимерелгән хыяллар» дигән романы дөнья күрде. Әсәр илленче еллар тормышын бик мавыктыргыч итеп җанландыра, ул чагындагы тәртипләрнең ничек итеп кешене дә, милләтне дә изүен күрсәтеп бирә. Халык өчен дип тырышкан колхоз рәисе Галләмнең бераздан бу эштән китәргә мәҗбүр булуы романның бөтен тукымасы, агышы белән раслана.

Мондый әсәрләрне укыгач, шагыйрь Гадел Низамның түбәндәге шигырен (ул шигырь «Казан» журналының соңгы санында басылды) тагын да тирәнрәк аңлыйсың:

Татар иле. Урыс әкияте.
Үле урман. Тик сазлыгы тере.
Шушы урман — чорлар хәрабәсе,
Шушы сазлык — чирле ил кабере.

Дус-ишеннән калган, адашканның
Котсыз монда язмыш — киләчәге:
Чоңгылына кыстап, кәнтәйләнеп,
Күзгә карап тора саз чәчәге.

Җәмгыятьтәге бүгенге рухи хәлне ничек образлы итеп сурәтләп бирә шагыйрә! Өлкән әдибебез Әмирхан ага Еникинең, алтмышынчы елларда ук «Саз чәчәге» исемле повесть язып, безне алдан искәртүе дә искә килеп тешә. Уйлар, фикерләр тоташа, алар тагын да көчәя төшә. Ә укучы күңелендә исә бу рухи сазлыкка каршы тору тойгысы туа, тормышта үзенә дә, милләтенә дә ныклы, ышанычлы юл булдырасы килү теләге көчәя… Шулай итеп, әдәби әсәр кеше күңеленә тәэсир ясый, әкренләп аны тәрбияли. Шифалы йогынты! Бу арада «Мәдәни җомга»да һәм «Шәһри Казан»да шагыйрәләребез Салисә Гәрәева белән Илсөяр Иксановның да үзенчәлекле хис ташып торган әсәрләре яратып укылды.

Мин офыкка кагылырга тиеш —
Алсу таңнар анда ал йокыда.
Халкым күпме якты таңын көтә,

Очам,
Очам таңны уятырга,—

дип рухлана И.Иксанова.

Әйе, республика халкына рухи-әхлакый тәрбия һәм эстетик ләззәт бирердәй көчләр әле бар, әле исән. Халкыбыз аларның барлыгын күреп сөенә. Җитәкчеләребез дә талантлы кешенең нинди зур хәзинә икәнен акласыннар иде, ниһаять! Техник алгарыш кына бөтен нәрсәне хәл итә алмый бит! Шул ук Көнбатышта да моны аңлый башладылар инде. Матди байлык җитештереп кенә кеше күңелен канәгатьләндерү мөмкин түгеллеген аңлаганнар алар. Һәм бердәнбер дөрес юл рухилыкта икәнен төшенә башлаган Көнбатыш галимнәре. Бу хакта газеталар язды.

Без — элек-электән бай рухи тормыш алып барган халык. Бүгенге шартларда менә шуны аңларга соңармасак иде! Бигрәк тә эшне оештыручыларга, җитәкчеләргә карый бу.

2000

Әдәбият дөньясы: уйлар, фикерләр

Соңгы вакытта булган яңалыклардан игътибарны иң җәлеп иткәне — безнең көннәрдә билгесез рәвештә югалган бик тә талантлы шагыйрь Эдуард Мостафин шигырьләренең «Идел» журналында (10 нчы сан) басылып чыгуыдыр, мөгаен. «Шагыйрьләр яшәгән илдә» дигән гомуми баш белән урнаштырылган бу ялкынлы әсәрләр арасында менә мондый тетрәндергеч юллар да бар:

Кая барып егылырга?
Шундый сорау тора алда.
Урамда шыр торып калгач,
Үз-үзеңне булмый алдап.

Әйе, бу ил үзенең сирәк очрый торган талантка ия улларын гына түгел, ә гомер буена тир түгеп хезмәт иткән фидакарь улларын һәм кызларын да бәхетле итә алмады шул! Яшьләр журналының шул ук санында басылган Рафаэль Мостафинның «Иң авыр елларда» дип аталган язмасы да Хәсән Туфан язмышы аша әлеге фикерне куәтли.

Әмма ни өчен шулай икән соң бу? Гаделлек урнаштыру һич тә мөмкин түгелмени соң? «Казан утлары» журналының әле яңа гына дөнья күргән ноябрь санында язучы Радик Фәизов үзенең «Гаделлек иясе» дигән повесте белән менә шушы үткен сорауга җавап табарга тырыша. Фантастик жанрда язылган бу әсәрдә автор бик үзенчәлекле вакыйгалар тасвирлый: повестьның төп герое Нурул (аның исеменә генә игътибар итегез!) янгын вакытында тәне тулысынча янып беткәч, күзгә күренмәс кешегә әверелеп китә. Шушындый сәләткә ия булганнан соң, ул гаделлек өчен көрәшә башлый — хәзерге байларның хәрәм байлыкларын тартып алып, ярлыларга өләшә, йорт-җирсез калганнарга да булыша... Ләкин барыбер үз максатына ирешә алмый Нурул...

Бу әсәрне укып әнә шундый гаҗәеп герой белән танышканнан соң, укучы күңелендә байтак сорау торып кала: моңа ничек бәя бирергә, Нурул дөрес эшләдеме, мондый көрәш безгә нәрсә бирә ала?

Әйе, социаль гаделлек урнаштырырга теләү, шуңа омтылу соңгы еллар татар әдәбиятының үзәк темасына әверелеп бара. Чаллы шәһәрендә яшәп бик тә актив иҗат итүче Вахит Имамов та үзенең «Могикан» дигән яңа повестеның (Идел.— 2000.— № 10) нигезенә әнә шундый актуаль проблеманы салган. Бу әсәр уңаеннан тагын бер кызыклы яңалык булырга тора. Язучының каләмдәшләре 20 декабрь көнне шушы повесть җирлегендә зур сөйләшү үткәрергә җыеналар. Бу әсәр XX гасыр татар повестеның нинди уңай һәм нинди тискәре якларын чагылдыра? Гасыр ахырында язылган әлеге повесть аша әдәбиятның нинди яңа хасиятләре, яңа тенденцияләре төсмерләнә? Бүгенге прозаиклар, әсәр язганда, күләм ягыннан гына кумыйлармы, әсәрнең эчтәлек тирәнлеге һәм укучыга тәэсир итү көче турында җитәрлек дәрәҗәдә уйланалармы?

Якын көннәрдә Татарстан Язучылар берлегендә узачак бу сөйләшү әнә шундый бик күп сорауларга җавап табарга да булышыр, мөгаен.

* * *

Бу арада кызыклы әдәби әсәрләр дә шактый мул булды, игътибарны җәлеп итәрдәй мәкаләләр дә басылды. Сүзне «Идел» журналының әле яңа гына чыккан 10 нчы саныннан башлап китәсе килә. Безнең көннәрдә хәбәрсез югалган талантлы шагыйрь Эдуард Мостафин шигырьләре белән ачыла ул.

Кая барып егылырга?
Шундый сорау тора алда.
Урамда шыр торып калгач,
Үз-үзеңне булмый алдап,—

диеп ачынып язган икән ул соңгы әсәрләренең берсендә...

Әйе, бу талант иясе озак еллар буена Язучылар берлегенә: «Хет бер генә бүлмә, хет бер генә почмак табып бирегезче»,— дип ялварып йөрде. Ләкин берлекнең ул чактагы рәисе Р.Мөхәммәдиев талант ияләре турында борчылмады шул. Беренче чиратта үзенең һәм әшнәләренең кайгысын кайгыртты. Ә хәзер әнә урыс телле матбугатта: «Татарстанда демократия юк»,— диеп лаф ора. Кызык, Ринат әфәнде соңгы Корылтайда үзенең һәм әшнәләренең ни кыланганын бөтенләй дә онытты микәнни?! Алар бит булдыксыз җитәкчене өченче мәртәбә рәис итеп сайлату өчен нинди генә оятсызлыкка бармадылар! Татарстан язучылары ул әрсез төркемне президиумнан куып ук төшерде бит! Тукай бүләген дә, Н.Фәттах, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов кебек зур талант ияләрен узып, иң башта рәис үзе алды ич! Республика өчен бик авыр булган менә бу чорда Илбашына удар ясарга тырышуы да татар язучылары тарафыннан бик авыр кабул ителә.

Ә яңадан әдәби әсәрләргә кайтсак, Маннур ага Саттаров «Алтын балык әкияте» (Мәдәни җомга.— 2000.— № 46), Флера ханым Гыйззәтуллина «Милләт юлыннан барам» исемле шигырьләр бәйләме (Шәһри Казан.— 2000.— № 42) белән чын-чыннан сокландырды.

Әйе, соңгы елларда әдәбиятыбызның бөтен тармаклары да диярлек матур җанлану кичерә. Ләкин әдәби тәнкыйть кенә әле һаман үзен күрсәтә алмый. Эш нәрсәдә, моның сәбәбе нидә икән соң? Әллә инде безнең әдәбиятта чын тәнкыйть белән шөгыльләнер кеше калмаганмы? Алай ук түгелдер. Соңгы елда остаханәдә матур гына чаралар үткәрелде: поэма һәм рецензия жанры турында сөйләшүләр, аерым тәнкыйтьчеләрнең иҗатын тикшерүләр булды. «Казан утлары» журналында иң яхшы рецензиягә конкурс та барды, киләсе елда исә иң кызыклы әдәби тәнкыйть язмасына бәйге ачылачак.

Ләкин матбугат битләрендә ни өчен җанлы һәм үткен әдәби тәнкыйть юк? Бу өлкәдә һаман да торгынлык чоры дәвам итә сыман.

Гаделлек хакына әйтик: «Идел»дә һәм «Мәдәни җомга»да кайбер әдипләргә төрттерүләр һәм ачы гына фикерләр күренгәләп ала, «Шәһри Казан» кыю гына язмаларга да урын бирә (мисал өчен Рифә Рахман фельетоны) менә «Ватаным Татарстан»да махсус багана булдырды...

Әйе, үткен-үткен әдәби тәнкыйть язмалары да иҗат ителә — монысын да инкарь итеп булмый. Әмма, ни кызганыч, аларның күбесе редакция өстәлләрендә күмелеп кала. Чөнки баш мөхәррирләрнең кайберләре, андый бәхәсле мәсьәләләргә кереп, үз башларын «авырттырырга» теләми, тыныч һәм җиңел юлдан баруны хуп күрә. Шулай булгач, чын әдәби тәнкыйть ничек туа һәм яши алсын соң?! Тукайлар чорында әнә, ирекле басмалар күп булгач, чын тәнкыйть тә яшәгән!

Ә болай, әдипләребезгә һәм тәнкыйтьчеләргә бәхәсләшергә тагын бер җай чыгып тора: 20 декабрьдә Вахит Имамовның «Идел» журналында басылган (10 нчы сан) «Могикан» повесте нигезендә Язучылар берлегендә фикер алышу үткәрелә.

Әйдәгез, әдәби тәнкыйтьне бергә-бергә үстерик!

* * *

Күз генә тия күрмәсен — бу арада өлкән яшьтәге каләм ияләре дә дәртләнә-дәртләнә иҗат итә, яшьләребез дә матбугатта басылган үзенчәлекле әсәрләре белән күңелне сөендерә. Мисал өчен, сатираюмор остасы Маннур ага Саттаров «Мәдәни җомга»ның 46 нчы санында заманча үткен эчтәлекле «Алтын балык турында әкият» һәм «Ватаным Татарстан»ның үткән җомга санындагы шигырьләре белән бер сөендергән булса, аерым китап итеп тупланган «Уйна, дустым, гармуныңны...» исемле юмористик һәм сатирик шигырьләр җыентыгы белән икенче шатландырды. Шулай ук «Шәһри Казан»ның 42 нче санында Флера ханым Гыйззәтуллинаның «Милләт юлыннан барам» исемле шигырьләр бәйләме дә истә кала торган иде. Сафуан ага Мулла Гали дә әле күптән түгел генә «Мәдәни җомга» укучыларын куандырды.

Декабрь ае булгач, инде узып баручы елга кайбер нәтиҗәләр дә ясыйсы килә. Шунысы куанычлы: быел Татарстан Язучылар берлегенә яшь һәм сәләтле каләм ияләре байтак кына кабул ителде. Луиза Янсуар, Сөмбел Гаффарова һәм Лиана Әмирхановаларга өлкән каләмдәшләре зур ышаныч баглый.

Әдәбиятка бәйле тагын бер яңалык: Язучылар берлегендә Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир әфәнде Шакиров һәм «Мәгариф» нәшрияты директоры Мөдәррис әфәнде Вәлиев катнашында татар китабының бүгенге хәле турында эшлекле сөйләшү булып узды. Берлектә матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге оештырылу һәм аның башлыгы итеп яшь драматург Рәдиф Сәгъдинең билгеләнүе дә бу тармактагы эшләрнең җанланып китәчәгенә өмет уята.

Әйе, соңгы елларда Татарстан Язучылар оешмасында эшне җанландыру буенча зур тырышлык куела, ижади остаханәләр дә көздән кызыклы чаралар үткәрергә тотынды. Биредә электән мирас булып калган салкынлык ижади ялкын, кайнарлык белән алышына бара.

Әмма әле уйланырлык мәсьәләләр дә бар икән. Мисал өчен, күптән түгел Нажия Садыйкова исемле автор «Шәһри Казан» газетасы аша татар язучыларына «Кыюлык кирәк!» дигән мәкалә белән мөрәҗәгать итте. Бу мәкалә кызыклысын кызыклы, ләкин андагы кайбер фикерләр белән бик үк килешәсе дә килми. Чөнки авторның тел төбендә ялгыш караш ята. Әдәбиятка мөнәсәбәттә кыргый капитализм кануннары өстенлек итсен димәкче була сыман бу ханым.

Искә төшерик: хәзерге кыргый капитализм шартларында да, һичшиксез, дәүләт яклавына мохтаҗ тармаклар бар. Аларның иң беренчесе — авыл хуҗалыгы. Чөнки биредә чыгым күп, ә табыш аз, ул яшәү өчен мөмкинлек бирерлек дәрәҗәдә түгел.

Ә инде рухи азыкның халык өчен, бигрәк тә безнең татар халкы өчен, ничек кирәк булуын, үтә дә мөһимлеген раслап тору да артык. Рухи азык илгә, халыкка кирәк икән, димәк, аны «җитештерүчеләр» дәүләт яклавына мохтаж дигән сүз бит инде бу!

Минемчә, әлеге мөрәҗәгатьне язган ханым үзе дә моны күңеле белән тоя, йөрәге белән сизә. Ачык хатның икенче өлешендә аның фикер сөреше шул яккарак авыша бара — бусы куанычлы хәл.

Әйе, безнең республикада рухи-әхлакый тәрбияне көчәйтү буенча махсус программа төзелсә һәм шуны тормышка ашыру өчен киң колачлы эш башланса, бик яхшы булыр иде!

* * *

Узып баручы мең ел буена татар халкын әдәбият озата килде. Ул аның якын сердәшенә, иң мөкатдәс хис-кичерешләрен уртаклашучы ышанычлы юлдашына әверелде. Алай гына да түгел, әдәбиятны без хаклы рәвештә милләт тормышының рухи һәм тарихи елъязмачысы да диеп саныйбыз. Бүген меңьеллык татар әдәбияты белән чын-чыннан горурланабыз.

Яңа меңьеллыкта әдәбият язмышы нинди булыр икән соң?

Бу хакта җитди уйландыручы кайбер үзгәрешләр күз алдыбызда. Шушы гасырның икенче яртысында аеруча киң колач алган фән-техника революциясе нәтиҗәсендә хәзер кешелек телевизорга һәм компьютерга мөкиббән китә башлады. Алар исә китапны бик нык кысрыклады... Хәзерге чор өчен хас булган тагын бер үзгәреш: тормышыбызга капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү нәтиҗәсендә элеккеге республикаларда тотрыклы рухи-әхлакый тәрбия системасы җимерелде һәм әлеге тәрбиянең мөһим өлеше булган китапка да әһәмият нык кимеде.

Әйе, болар — аяусыз чынбарлык. Хәзер алар белән санашмыйча һич мөмкин түгел.

Ләкин әле без күчеш чорында яшибез, кайбер нәрсәләр турында уйлану һәм карар кабул итү мөмкинлеге югалмаган.

Шулай булгач, яңа гасыр, яңа меңьеллыкка кергәндә, әйдәгез, уйланыйк: татар милләтенә киләчәктә рухи байлык (җыр-моң, театр, рәсем сәнгате һәм китап) кирәк булачакмы? Халкыбыз киләчәктә шуларсыз тора алачакмы?

Иманым камил, бу сорауга бер генә кеше дә тискәре җавап бирә алмас — адәм баласына рухи азыкның гел кирәк булачагына бернинди дә шик-шөбһә юк.

Халкыбызга рухи азык алдагы елларда да кирәк булачак икән, әлеге мөһим тармак турында бүгенге җитәкчеләребез, хөкүмәтебез кайгыртырга да тиеш бит инде!

Гаделлек хакына әйтик: бу яктан караганда, хәлебез, бүтән республикалардагы сыман, бик үк начар түгел кебек. Китап бастыру мәсьәләсен генә алсак та, Татарстан китап нәшрияты хәзер берүзе генә дә елына алтмыш-җитмеш исемдәге китап чыгарырга тырыша. Соңгы вакытта «Мәгариф» нәшрияты да бу яктан күп көч куя.

Ләкин бездә китапны халыкка җиткерү системасы юк, әлегә бу нәшриятларның үз эше итеп кенә карала кебек. Ә бу исә һич кенә дә дөрес түгел.

Яңа гасыр башыннан ук без республикабызда китапка чын дәүләтчә мөнәсәбәт урнаштыра алсак иде! Үтә җитди кыйммәткә ия бу рухи хәзинәне халыкка җиткерүнең ныклы системасын булдырырга иде! Бу системага авыллардагы һәм район үзәкләрендәге, шәһәрләрдәге китап кибетләре дә һәм барлык китапханәләр дә, рухи-әхлакый тәрбия белән шөгыльләнүче барлык оешмалар да һәм, әлбәттә, нәшриятлар үзләре дә керсен иде.

Бәлки, кайберәүләр: «Капиталистик тәртип урнашып килгәндә, мондый эшне оештырып булырмы икән?» — диеп шик белдерер. Андыйларга мондый җавап бирик:

— Халкыбызга, республикабызга кирәкле, файдалы эш икән, ни өчен ул системаны булдырмаска? Кешене тәрбияләү бер җәмгыятьнең дә көн тәртибеннән төшми торган бурычы ич ул!

Республика халкын рухи-әхлакый тәрбияләү буенча әнә шундый зур эш оештырылса, татар язучылары да җиңел сулап куяр һәм киләчәккә ышаныч белән карар иде!

2000

Сагыш дәрьялары аша

(Шагыйрь Сафуан Мулла Гали иҗаты турында уйлану)

Шагыйрь Сафуан Мулла Галинең 1993 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан китабы «Биздерсәләр туган җиреңнән...» дип исемләнгән.

Чит җир... Читтә яшәү...

Бу хәлне үзе татып карамаган кешегә ничек итеп аңлатырга, төшендерергә икән? Миңа, мисал өчен, Ерак Көнчыгышта ике генә ел яшәргә туры килде. Шул кыска гына вакыт эчендә дә үземне оясыннан егылып төшкән канатсыз кош баласы кебек итеп тойдым. Ун мең чакрымдагы Казан, туган җир, әти-әни, дус-ишләр — боларның һәммәсе искә төшкән саен, үзәкләр өзелә, бәгырьләр телгәләнә иде. Җилдә тибрәнеп утырган киң ябалдашлы өянкеләр дә туган якка очарга җыенган кошлар шикелле күренә иде.

Туган-үскән җирен өзелеп сагынган кешенең рухи халәте әнә шундый була икән ул. Хәер, безнең татар телендә читтәге кешенең андый бәгырь телгәләнүләрен бик тә тирәннән ачучы бер тәкбир бар бит. «Җирсү» дигән сүз бар. Башка халыклар, мәсәлән, урыслар берничә сүз яисә тулы җөмлә белән әйтеп бирә торган фикерне безнең тел бер гыйбарә белән бик тә берәгәйле итеп әйтеп бирә белгән бит! Шушы хәл үзе генә дә безнең милләтнең тарихи язмышы һәм холкы, психологиясе турында бик күпне сөйли түгелме соң?!

«Биздерсәләр туган җиреңнән...» — шигъри повесть ул. Әсәр мондый юллар белән башланып китә:

Син минеке,
Мин синеке, диеп,
Сиңа әйтә алыр идемме —
Сагышыңа чумып йөзмәсәм мин,
Иңләп йөзгән кебек Иделне.

Ләкин бу әле алда тасвирланачак драматик күренешләргә кереш кенә. Ә әсәрнең төп эчтәлеге исә татар кешесенең авыр язмышы турында. Мондый авыр язмышның төп сәбәбе дә тәүге битләрдә үк әйтеп кителә.

Астыртын җил
Татар халкын себерә —
Дәүләтле халык сибелде
Уралларга, Себергә...

Баштагы битләрдә менә шундый юллар аша вакыйгаларның төп нигезе, сәяси сәбәпләре күрсәтелгәннән соң, шигъри повесть үзәк каһарманның язмышын ача башлый. Биредә төп герой эчкерсез күңелле, шигъри җанлы яшь Садыйк. Ата-бабасыннан ук гаделлеккә табындыра торган тәрбия алган бу яшүсмер дөреслек тантана итәргә тиеш дип чын күңеленнән ышана. Авылның өлкәннәре вакыт-вакыт совет тәртибе турында кинаяле сүзләр әйтеп куйса да, Садыйк алар белән килешмичә кайнар бәхәскә ташлана, Советны яклый.

Әмма авылда гаделсезлек көчәя генә бара. Һәм шул чагында яшь Садыйк нишли? Ул авылдагы чын хәлләр турында тота да Сталинга хат яза:

Күкрәгендә аның —
Колхозчының —
Карлы-бозлы хәсрәт бураны...
Алабута җыеп ашыйбыз без,
Ашамыйча яшәп буламы?

Әйе, ихластан ышанган кеше шулай эшләмичә булдыра да алмый шул. Совет Армиясе офицеры булып хезмәт иткәндә, мин үзем дә андагы тәртипсезлек, башбаштаклык турында һәм илгә андый-мондый куркыныч туа калса, мондый армиянең һич тә халыкны яклый алмаячагы турында Мәскәүгә, Оборона министрлыгына хат язарга җыенып йөргән идем. Шул рәвешчә илне, җитәкчеләрне кисәтергә теләгән идем... Яшь Садыйкның Сталинга язган әлеге хатын да мин яшь, фидакарь җанның ихлас һәм эзлекле адымы дип кабул иттем.

Чыннан да, без барыбыз да ышанган идек бит. Ул хәтле куәтле коткы машинасына каршы тору, алар сүзенә ышанмау мөмкин идеме соң?! Әнә бит Гитлер миллионлаган халыкны басып алу сугышына да күтәрә алды хәтта. Димәк, коткы бик күп нәрсә эшли ала икән безнең заманда!

Сафуан Мулла Гали әсәрендә андый коткы белән чынбарлык арасындагы зур аерма да ап-ачык күренә.

«Кем эшләми — шул ашамый» дибез.
Кем эшләми — бездә шул ашый.
Колхоз куштаннары үзләренә
Ярты колхоз уңышын ташый.
Качып-посып түгел,
Көпә-көндез
Колхоз аты белән кайтара...

Менә бу юлларда инде Сталин чоры колхозларының гына түгел, ә бүгенге көн тормышының да кырыс һәм пычрак чынбарлыгы ята. Дөрестән дә, без бер яктан, күмәк тормыш биргән уңайлыкларга куанабыз, бүген аннан аерылырга теләмибез, ә икенче яктан, күпләгән җитәкчеләрнең халык байлыгын талауларын күреп эчтән генә борчылабыз. Үзебездә, бәйсезлек алган Татарстаныбызда, бүгенге җитәкчеләр башбаштаклыгы тагын да көчәеп бара түгелме соң?!

Совет чоры тормышына бәйле әнә шундый үткен-үткен мәсьәләләр күтәрелә «Биздерсәләр туган җиреңнән...» дип исемләнгән бу китапта. Алар һәммәсе дә намус, гаделлек, кешелеклелек дигән мәңге тутыкмас әхлакый бизмәндә үлчәнә. Ә бизмәннең укларын әсәрнең шигъри юллары бик тә төгәл күрсәтә.

Китапта истә калырдай күренешләр байтак. Сталинга язган хаттан соң авыл почтасы яшь Садыйкның редакцияләргә юллаган шигырьләрен дә тотып кала башлый. Шулай итеп, үсмергә бу яклап та богау салына. Аның тынгысыз йөрәгенә дә ирек бирелми.

Ә колхоз аты белән килеп чыккан очраклы бер күңелсезлек аркасында аларның сыерларын да алып чыгып сатып җибәрәләр.

Менә шулай итеп, адәм баласын төрле яктан кысучы кыршау торган саен кысыла, торган саен түзүе кыенрак була бара. Һәм бу хәл Садыйкның Урта Азия якларына китүе белән төгәлләнә.

Юлчыларның күпчелеге татар —
Үз җирендә көн юк татарга.

Бу китапның вакыйгалар канвасы менә шундый.

Китерелгән өзекләрдән укучы инде күргәндер, аңлагандыр: әсәрдә сурәтләнгән хәлләр безнең милләтнең бик күп өлешенә таныш, билгеле хәлләр. Бу яктан караганда, китапны укучылар анда үз язмышларының чагылышын табачаклар. Башкалар өчен дә бик гыйбрәтле булачак «Биздерсәләр туган җиреңнән...» исемле әсәрне уку. Ни өчен дигәндә, биредә безнең халык күргән кайгы-хәсрәт белән бергә һичкайчан онытылмаска тиешле туган җир, аның әйтеп, аңлатып кына бетерә алмастай кадере дә ачыла. Читкә китүчеләр һәм монда калучылар күргән кыенлыклар аша туган җирнең чын бәясе, кеше өчен никадәр мөһим булуы ачыклана. Уку өчен мавыктыргыч вакыйгалар, тормыш хәлләре китапның кызыгын, мәгънәсен арттыра.

Шунысын аеруча билгеләп үтәргә кирәк: «Биздерсәләр туган җиреңнән...» жанр ягыннан да үзенчәлекле әсәр. Безнең әдәбиятта Салих Батталның «Чирмешән якларында» исемле җыр-романыннан һәм «Олы юл буйлап» дигән шигъри повестеннан соң әле мондый зур күләмле шигъри әсәр дөнья күргәне юк иде. Игътибар итик: шагыйрьләрнең икесе дә тормышның ачысын бик күп татыганнан соң әдәбиятка килгән кешеләр. Халыкка әйтер сүзләре күңелдә тәмам тулышкач кына каләм алган затлар. Бу хәл үзе әсәрләр файдасына байтак нәрсә сөйли, ышандыра.

Чыннан да, Сафуан Мулла Гали вакытлы матбугатта халыкчан, җылы, моңлы шигырьләре белән укучы мәхәббәтен яулаган иде инде. Аның моңа кадәр басылган китаплары да китап кибетләре киштәсеннән бик тиз тарала иде. Инде менә мондый шигъри повесть белән өлкән яшьтәге шагыйрь үз иҗатында яңа баскычка күтәрелгән. Татар тормышы турында саллы һәм моңлы шигъри сүзне әйткән.

Тагын шуны онытмыйк — биредә әле без беренче китап белән генә очрашабыз. Әсәр ахырында геройлар Урта Азия җиренә килеп кенә җитәләр. Димәк, алда бүтән өлешләр, яңа әсәрләр булачак.

Шигъри повестьны укыганда, кайбер теләкләр дә туа, билгеле. Мисал өчен, әсәрнең беренче бүлеген тагын да тыгызрак, динамиграк итәргә мөмкин булыр иде кебек. Югыйсә егерменче еллар авылы бераз сүлпәнрәк сурәтләнә шикелле. Төп герой тормышы хакында сүз кузгалгач, әсәрнең мускуллары шундук тыгызланып, сулышы кайнарланып китә, әлбәттә. Һәм мондый кайнар эчке климат ахырга кадәр саклана.

Йомгак ясап әйткәндә, әдәбият сөючеләр кызыксынып укырдай шигъри повесть иҗат ителгән. Бүгенге шигъриятебезнең көчен, куәтен күрсәтүче тагын бер матур мисал ул.

2000

Безнең Габделхәй абый

Әйе, язучы Габделхәй Сабитов турында бүген әнә шулай үз итеп «безнең» дип әйтәсе килә. Ә бит байтак замандашларыбыз турында, бигрәк тә әдип халкы турында без алай дия алмыйбыз. Хәтта кайбер эшлекле һәм талантлы гына иптәшләребез турында да болай әйтеп булмый. Ә менә бу язучы исеме телгә килгәндә исә һәрчакта да сүз «безнең» дип башланадыр төсле.

Нишләп шулай икән? Моның сере нәрсәдә?

Әлбәттә, без иң беренче җавапны аның иҗатыннан табарбыз. Чөнки Габделхәй Сабитов каләме тудырган әсәрләрдә барысы да үзебезчә: табигате дә шундый гүзәл һәм кеше рухына гаҗәеп тәэсир ясый ала торган; язучы үзенең күңел җылысын салып тасвирлаган кешеләр, геройлар да безнең милли холкыбызга шулкадәр дә туры килә торганнар һәм ихласлар, беркатлылар, яхшы күңеллеләр, намуслылар; сурәтләнгән хәл-әхвәлләр дә үзебезнең яшәү-көнкүрештән зур осталык белән сайлап алынганнар.

Укучы күңеленә тирән үтәрдәй әдәбият-сәнгать әсәрләре ничек, ни рәвешле, нинди нигездә туа икән? Чагыштырып карасак — әдәби иҗатка сәләтле кешеләр, каләм ияләре шактый, ә менә ни өчен алардан сирәгенең генә язганнары күпләгән укучыны сөендерә һәм халык, милләт рухын баета ала?

Шул хакта ныклап торып уйлана башлагач, инде байтактан укылган бер китап искә төште. Атаклы итальян скрипкачысы турында иде ул әсәр. Анда автор «Бөек әсәрләр туу өчен нинди шартлар кирәк?» дигән сорауны куя да, дөньяның бик күп иҗатчылары язган әдәби-сәнгать әсәрләрен күздән кичергәннән, хәтердән үткәргәннән соң, менә мондый бер нәтиҗәгә килә:

— Талант янәшәсендә югары кешелек сыйфатлары булырга тиеш икән! Иҗатчы шәхесенең олы гуманизмы — таланттан соң иң мөһим нәрсә, иң кирәкле шарт әнә шул икән.

Безнең замандаш язучыбыз Габделхәй Сабитов әсәрләрен укыганда, әдәбият-сәнгать дөньясының шушы алтын кагыйдәсе дөреслегенә тагын бер мәртәбә ышанасың. Аларда шәхеснең кешелек дәрәҗәсе сынала торган тормыш күренешләре, язучының иманын тирәннән ача торган хәл-әхвәлләр.

«Кояш тамчылары» исемле әсәрдә мондый бер күренеш бар. Үзенең малай чагына хәтердән генә кунакка кайткан язучы яраткан нәни көчеген искә төшерә. Язгы бер көндә ул бәләкәчне ишегалдына чыгаргач, көчеккә усал ата каз ташлана. Моңа кадәр малайның үзенең дә котын алып, куркытып торган, зур гәүдәле, дәһшәтле ата каз! Җитмәсә әле, малайның авырып мәктәпкә дә бара алмый яткан чагы.

Ләкин шуңа да карамастан малай, куркып, дустын калдырып, өйгә кереп китми, яшеренми дә, ярдәмгә әнисен дә чакырмый, ә нәни көчекне яклап, көрәшкә ташлана! Язгы пычрак суга егылса егыла, бөтен өс-башын пычратса пычрата, әмма ул үзенең дустын бу очракта явызлыкны гәүдәләндергән ата каздан саклап кала.

Әдипнең кечкенә чагында булып алган менә шушы бер күренеш безгә «Габделхәй Сабитов» дигән иҗат дөньясының бик күп якларын һәм төп сыйфатларын ачып бирә. «Алтыдагы алтмышта» дигән сүз бу очракта бик тә дөрескә чыга.

Чыннан да, Габделхәй Сабитов — үзенең бөтен иҗат юлы буена иң мөһим һәм иң нечкә кешелек кануннарын яклап, ата-бабаларыбыздан ук килүче ул эчке нормаларның бүген дә, һичшиксез, үтәлергә тиешлеген раслап, олы рухи көрәшкә — иҗаттагы көрәшкә ташланган әдип. Иман ныклыгы, кешенең кешелеген яклау өчен соңгы чиккә кадәр җитеп көрәшә ала торган көчле рухлы әдип ул.

Әйе, намус белән әшәкелек көрәшендә уртаклык була алмый. Биредә конфликттан читтә һәм тынычлыкта калу өчен син урталыкны сайлыйсың икән — әлеге адымың белән инде шунда ук әшәкелеккә юл ачасың дигән сүз. Без сүз алып барган Габделхәй абыйның бөтен вөҗүде исә бары тик намус ягында гына.

Язучы әсәрләрендә үзәккә алынган күренешләр безгә шуның белән кыйммәтле дә — аларда бүгенге замандаш өчен рухи ныклык чыганагы күрсәтелә:

«Күңелемнең моңарчы өнсез торган әллә нинди кыллары әнә шунда зыңлый башлады, ахрысы. Гомерем буена башымны исәр иткән биниһая көчле хис — җиһанга, тереклек ияләренә тыелгысыз мәхәббәт хисе әнә шул мизгелдә уянгандыр, дип уйлыйм...»

Безнең чорда табигать белән, барлык җан ияләре белән дус һәм тату яшәүнең никадәр мөһим булуын кеше, ниһаять, аңлый башлады шикелле. Вакыт узган саен, әлеге хакыйкатьне төшенү тирәнәя генә барачак. Чөнки нәкъ әнә шул изге бәйләнеш, элемтә йомшарганга күрә, әнә шул сәбәпле кешеләребез, бигрәк тә яшьрәк буыннар, ташка һәм тимергә әйләнделәр. Ә күпләребез һаман да берни аңламаган төсле «Каян килә бу каты бәгырьлелек?» дип аптыраган була.

Габделхәй Сабитов исә үзенең әсәрләрендә шундый каты бәгырьлелеккә, шәфкатьсезлеккә каршы тору алымнарын, юлларын тасвирлый. Истә калырдай җанлы күренешләр иҗат итә.

Язучының «Йолдыз яктысы» исемле хикәясендә малайлар башта, су коенырга урын булсын дип, инешне буып куялар. Ләкин шул тирәдәге куаклар арасында кош оялары да була. Төнлә йокыга китәр алдыннан малайларның берсе бу хакта баш вата, аның тәмам йокысы кача. Чөнки ояда нәни кош балалары да бар! Аларны су басачак! Малай төнлә торып буа янына чаба, үзләре үк буган суны ерып җибәрә.

Нәни җан ияләре белән янәшә яшәү бәләкәй малайларда күңел сизгерлеге, кече күңеллелек, шәфкатьлелек тәрбияли, ди язучы. Мондый мисалларны әхлакый үрнәк димичә ни дисең. Әдәбиятның тәрбияви көче нәкъ әнә шундый очракларда ачык чагыла бит инде ул!

Ә инде бу әдипнең «Айбаш» исемле хикәясен ничек телгә алмый үтәргә мөмкин?! Үзенең туып үскән җиреннән аерылган бер малкай турындагы үзәкләрне өзгеч әсәр бит ул.

«Хайван сизми дип уйламагыз сез, сизә ул. Башын җилкәмә салып бик озак торды, китәр алдыннан, үпкән кебек итеп, йомшак ирене белән маңгаемны кытыклап алды. Ә кузгалып киткәч, бер борылып карады да, сау булыгыз, дигән кебек, урам яңгыратып кешнәп җибәрде».

Әнә шулай моңсу аерылышкан хайван бераздан Себердәге яңа хуҗасын ташлап китеп бара. Туган ягына юлны эзли-эзли ел ярым тинтерәп йөри ул. Һәм ахыр чиктә барыбер үзе үскән ишегалдына кайтып егыла! Шунда җан да бирә.

Бу әсәр туган җир һәм аның сихри көче турындагы искиткеч бер поэма шикелле укыла. Күңел аны шулай кабул итә. Чөнки язучы таланты әлеге әсәргә әнә шундый тәэсир байлыгы сыйдырган, салган.

«Өч күңел» дип исемләнгән хикәядә исә, киресенчә, туган ягын оныткан бер жүнсез адәм турында сүз бара. Озак еллар буе читтә акча эшләп йөргәннән соң авылына кайтса да, хәзер инде барысына да җиңел генә ирешә алам дип уйласа да, — юк икән: хәзер инде аны күпләр кабул итә алмый икән! Озак еллар буена үз улыннан бер хәбәр дә алмый яшәгән атасы белән элек сөйгән кызы бигрәк тә! Болар күңелендә ташыган рәнҗешне язучы үз укучысы йөрәгенә оста җиткерә. Андый чакта кеше күңелендә ташыган хис-кичерешләр драматизмы әсәрдә тирәннән ачыла.

Габделхәй Сабитов — кыска күләмле әсәрләр остасы. Хәзерге кайбер яшь язучылар сыман беренче мәртәбә матбугатта басылу белән шундук романга тотынган һәм уңышсызлыкка очраган ижатчы түгел ул. Урысның Антон Чеховы һәм Иван Бунины шикелле, үзебезнең Әмирхан ага Еники сыман, сүзнең бик тә тәмен белеп, кадерен аңлап һәр сүзгә зур тәэсир байлыгы сыйдырып ижат итә ул. Әдәби әсәрнең бөтен хикмәте сүздә, аның тәэсир көчендә икәнлеген ул беркайчан да исеннән чыгармый.

Әнә шуңа күрә Габделхәй Сабитовның кайсы гына әсәрен укый башласаң да, гаять тирән һәм нечкә тойгылар, үткен күңел күзе, хикәяләүнең ипле-җайлылыгы, ятышлылыгы белән очрашасың. Аның җөмләсендәге һәр сүз, һәр ишарә һәм ым билгеле бер хис, кичереш тудыруга хезмәт итә. Шул кичерешнең аерылгысыз өлеше булып тора. Ә моңа бары тик үзе тирән һәм нечкә күңелгә ия булган әдип кенә ирешә ала. Гүя менә бу чагыштыру, менә бу күренеш әдипнең үзе турында язылган:

«...Тал-тирәкләр исә, күл эченә үк кереп, тубык тиңентен суда торалар, әз генә җил исеп куйдымы, иелеп-сыгылып, үзләренең яфракларын юалар...»

Әйтерсең менә шушы бик тә шигъри сурәттә язучы үзе дә тасвирланган. Һәм менә шушы бер җөмләдә аның эчке дөньясы да гаять дөрес чагылыш тапкан.

2001

Тәллитут

...Урманнарда әле билдән кар була, ләкин көннәр әз генә сыну белән, яшь талларда песиләр күренә башлый. Алар, синең балачагыңны, туган ягыңны, алдагы ямьле язларны да искә төшереп, табигать һәм тормышның салкын көннәрендә туңган җаннарны йомшак, җылы канат белән сыйпап алгандай итә.

Тал песиләре...

Язучы Салих Маннаповның моннан нәкъ ун ел элек басылып чыккан «Тамыр тирәнлеген яфрак тоя» исемле китабын укыган чагында безнең һәммәбезгә дә бик таныш һәм кадерле булган әнә шул тал песиләренең Әлки ягында «тәллитут» дип йөртелүен белгәч, бу сүзгә ихластан сокланган идем. Шушы табигать могҗизасының бер генә сүздән ясалган, матур җисеменә бигрәк тә тәңгәл килеп торган үз исеме бар икән ләбаса!

Шушы ук әдипнең (хәзер инде Мөдәррис Вәлиев булып) әле яңа гына Татарстан китап нәшриятында чыккан «Яшьлектән хат» исемле шигырьләр китабын кулга алгач та күңелемә әлеге сокландыргыч яңгырашлы «тәллитут» сүзе килде, ә инде китаптагы шигырьләрне укып, алар тудырган хиссият һәм кичерешләр дөньясында яшәп алганнан соң, бу тылсымлы сүз яшьлек һәм туган як турындагы яңа бер симфониянең гүзәл яңгырашлы исеме булып йөрәк түренә үк кереп урнашты.

...Йолдызлар микән,— ул шулай,
Һәммә өенә ут алып,
Авылым көтә сыман!
. . . . . .
Нинди кырыслану булсын! —
Әнкәй керфекләре төсле
Бәс сырган ылыслары!..

Шигырьдәге һәрбер ым, һәр билге күңелдәге туган якны сагыну, җирсү моңын тудыруга булыша. Шагыйрь «йолдызлар» дип яза, безнең күңелгә яктылык һәм ераклык мәгънәсе килеп сарыла. Чын сагыну хасияте шундый була ич!

Ә инде «Ут» дигән шигырьдә шагыйрь үзенең төш күрүен әйтеп, анда әнисенең янган өй эчендә түшәмне тотып торуын шундый эпик көч белән сурәтли ки, укучы күз алдына хәтта рәссамнар да көнләшерлек дәһшәтле һәм гаять тирән фикерле шигъри картина килеп баса. «Ул ялкында без өстәгән күпме рәнҗүләр бар, бардыр үпкәләр...» дигән фикер исә әлеге драматик күренешне кеше йөрәгенә тагын да якынрак, газизрәк итә.

Шушындый рухтагы шигырьләр аналарның бөек, монументаль образын тудырса, икенче бер төркем әсәрләр әниләребезнең җылы, лирик сурәтләрен күз алдына китереп бастыра.

Күрше апа әйтеп хат яздыра,
бер ашыгып тезә... бер тына.
«Уйлап йөргән сүзем күп иде дә,
хат яздырган чакта онтыла!»
. . . . . .
Буран, арып, бусагага ята.
Утлы күмер мичтә аллана...
Бөтен дөнья тынып тора, ахры,
Хат яздырган чакта аналар...

...Бүген безнең татар шигъриятендә яңадан илленче еллардагы кебек күпсүзлелек, мәгънәви көпшәклек, шомалык шактый еш очрый башлады. Күңелне борчыган әнә шундый начар тенденция янәшәсенә куеп караганда, бу китаптагы аз сүзле, әмма күп һәм тирән мәгънәле чын шигъри әсәрләр бигрәк тә яратып кабул ителә. Музыка дөньясы белән чагыштырып карасак, андагы симфонияләрдә очрый торган полифония, күпмәгънәлелек китапның «Гөнаһлы уй» дип исемләнгән икенче бүлегендә бигрәк тә мул.

Гүя кемдер, изге тәсбих итеп,
Сиңа язган хатларымны тезгән...—
Тезелешеп очкан кыр казлары!
Мин буш оя булып карыйм сезгә.

Безгә таныш бер күренештән нинди яңа мәгънә чыгарды шагыйрь йөрәге! Кыр казларына мөнәсәбәттә бу «буш оя» дигән сүз никадәр сагыну, көтү, ымсыну кичерешләре хасил итә. Мөдәррис Вәлиевтә шундый поэтик рәсемнәр ясый белү сәләте көчле. «Гашыйклар төненә мине бер йолдыз итеп яктың» ди ул икенче бер шигырендә. Сөю халәтен төгәл һәм бик тә үзенчә әйтү бу! Йолдыз дигәннән, безнең шигърияттә «йолдыз чире» дә күренгәләп алды бит әле. Җирдән һәм кешедән артык нык ераклашкан, чынбарлыктагы кешенең күңел яшәешенә тәңгәл килмәгән «тамырсыз» шигырьләр турында шулай дип язылды. Ә минем кулдагы бу китап исә, киресенчә, күк җисемнәрен кеше йөрәгенә, кеше тормышына якынайта.

Беләсезме,
ул йолдызлар
төшләрендә
үзләрен гел
гади учак итеп күрәләр:
Имеш, аларга да
ялгыз юлчыларны
бер җылыту бәхете
насыйп булган...

М.Вәлиев шигырьләрендә җирдәге табигать күренешләре дә бары тик кеше җаны турында гына сөйли. «...синең сүзләр — язгы ташу иде. И орыштың мине, орыштың!» — дип башланган әсәр, мәсәлән, үзенең иң кайнар ноктасын таба:

Инде, ярга ятып калган ләмгә бата-чума,—
әллә китеп бару,
әллә кайтып бару...

Күрәсезме, никадәр экспрессивлык, күп мәгънә һәм шигъри драматизм! Гадәттә, Балтыйк буе халыкларының нәфис фильмнарын караганда, хәтергә әнә шундый тирән фикерле поэтик күренешләр сеңеп кала. Биредә дә шулай. Китап белән очрашу бәхетен кичерәчәк укучыга мин тагын «Юлымны бүлде» дигән шигырьне дә бик тәмләп, ләззәтләнеп укырга киңәш итәр идем. Тәүге мәхәббәт хисеннән башланган тылсымлы һәм гыйбрәтле бер сәхифә сыман килеп чыккан ул.

...Мөдәррис әфәнде моннан алдарак чыккан бер китабындагы «Сүз кадере» дигән әдәби тәнкыйть әсәрендә арабыздан иртәрәк киткән бик әйбәт прозаигыбыз Габдулла Шәрәфи иҗаты турында бик тәфсилле, җитди әңгәмә алып бара, бу язучының иң зур уңышларыннан берсе итеп, әсәрләрендә сүзне гаять урынлы, төгәл кулланыуын билгеләп үтә. Ә инде хәзер кулыбыздагы яңа китапта шагыйрь Мөдәррис Вәлиев үзе дә иҗатта сүз кадерен белүнең бик матур мисалын күрсәтә. Андагы әсәрләрнең барысы да диярлек күләм ягыннан кыска, укучы күңеленә җиткерелергә теләгән хис-кичереш төгәл шигъри сүзләр һәм поэтик ассоциацияләр ярдәмендә тулы килеш ирештерелә. Шигырьләрнең күбесе акварель белән ясалган романтик рухлы, якты рәсемнәр булып күз алдына килә, безгә шигъри энергияне биреп тора.

Китабын ачып җибәргәндә, шагыйрь бик тә тыйнак төстә: «Кош теледәй генә бу китапта «шагыйрьлеккә» дәгъва һәм иң мөһиме андый ихтыяҗ да юк. Бар булганы — бары тик күңел халәте, җан хәрәкәте генә»,— дип яза. Ләкин авторның рухи яшәеше бай булгач, хис-кичерешләре тирәннән аккач, безнең дә иң кадерле, мөкатдәс хисләребезне чагылдыра. Шуңа күрә биредәге шигырьләр укучы тарафыннан үз итеп кабул ителә.

Китапның югары зәвык белән бизәлүен һәм яхшы техник эшләнешен дә искә алсак, аның, чыннан да, ак яулык сыман куен кесәсендә, йөрәк янында гына йөртелердәй бүләк булуына ышанасың. Ләкин тиражы 1 мең генә данә...

Сергей Есенинның «Фарсы мотивлары» дигән шигырь бәйләмендә «Шаһинәм син минем, Шаһинәм» исемле бөек әсәре бар. М.Вәлиевнең бу китабында да әнә шундый тетрәндергеч көчле хисне чагылдырган «Кар кызы» бирелгән. Шул шигырьдән бер кечкенә өзек китерсәм, шигырь сөючеләрнең күңелен җилкендерергә әлегә шул җитәр дип уйлыйм:

Таулар салкын — телен белмәсәң,
Таулар текә — кулың бирмәсәң.
Бер килермен әле, Кар кызы,
Гөрләвекләр юлны бүлмәсә...

Яшьлек һәм туган як хисләрен тирәннән кузгатучы матур тәллитут кебек булып чыккан бу китапның шифасы, назы сезнең җаннарга да барып ирешсен иде, хөрмәтле укучы!

1998

Кешелеклелекнең дәвамы — батырлык!

Калага тартылу... Йоп-йомшак яшел чирәмле гүзәл табигать кочагында бәләкәйдән үк кошлар җырын күңеленә сеңдерә-сеңдерә һәм ул чагында мәңге аерылмас дус сыман тоелган шаян кәҗә бәтиләре белән җылы өй идәнендә уйный-уйный үскән нарасый адәм баласының җанында «шәһәргә тартылу» дигән әнә шул яңа тойгы, ят омтылыш кайчан һәм ничек туа, ни рәвешле барлыкка килә икән?

Калалардан бик-бик ераста, ләкин табигатьнең бик күркәм кочагында урнашкан авылда үткән балачагымны, үсмер елларымны күз алдына китерәм дә хатирәләрне яңарта-яңарта әлеге сорауга бер ышанычлы җавап табарга телим.

Бу чагында авылга электр да кермәгән әле. Шуңа күрә кичләрен өйләрне бик тиз арада эңгер биләп ала.

Әнә шундый моңсу кичләрдә үсмер авыл малае үз өйләренең кояш баешына караган бәләкәй тәрәзәсе янына килеп утыра да, радио тәлинкәсеннән талгын гына агылган симфоник музыка тыңлый. Татар җегетенең күңеленә Вивальди аһәңнәре, гажәеп лирик Свиридовның хис дулкыннары килеп-килеп кагыла...

Калага тартылу тойгысы әнә шундый кичләрдә тәү мәртәбә борын төрттеме икән?

Әллә күрше авылыбызда туып үскән Тажи Гыйззәтнең, үзебезнең укытучыбыз Юныс Әминовның серле, тылсымлы эшләренә кызыга, ымсына башлаганмы күңел дигәнең?

Әллә инде 1968 елны Казаннан килгән шагыйрьләр Равил Фәйзуллин белән Айдар Хәлимне бер матур кышкы көнне ат җигеп үз авылыбыздан күрше авылга хәтле озатып кую, унике чакрым араны үткәндәге сүзләр, әңгәмә, аралашу яшь күңелне җилкендереп калдырганмы?

Әйе, болар барысы да булгандыр... Язмыш юлын сайлаган чагында һәркайсы үз сүзен әйткәндер.

Ләкин шулай да Казан каласына эләгүемә «иң гаепле» кеше Шамил абый Рәкыйпов булды.

Алтмышынчы елларның башы иде ул. Баржы урта мәктәбенең алтынчы-җиденче сыйныфында укыган чагында, мин бик мавыгып, кызыксынып киттем дә, Казандагы «Татарстан яшьләре» редакциясенә «Ничек журналист булырга икән?» дигән — беренче карауга беркатлы, әмма ул вакытта минем өчен үтә мөһим булган ихлас сорау белән хат яздым. Хатым китте Казан тарафына, ә минем көннәр мәктәп ыгы-зыгысы һәм романтикасы белән, китаплар укый-укый һәм кичләрен барыр урын булмаганга күрә, радио тәлинкәсенә кереп китәрдәй булып, әдәби спектакльләр, музыка тыңлый-тыңлый ага бирә... Таң тудымы, хат ташучы апаны көтә башлыйсың — ул сиңа иң-иң мөһим хатны, иң кадерле сүзләрне алып килер шикелле... Ә бераздан күңелне шик тә кимерә башлый: «Минем кебекләр бик күптер бит инде ул, барысына да ничек җавап язып бетерсеннәр алар...» — дисең...

Әмма җавап хаты килеп төште бит! Әле аның да ниндие диген!

Ерак бер татар авылында яшәп ятучы гап-гади бер малайга атап, үз кулы белән һәм матур итеп, һич тә иренмичә биш бит итеп язылган ул хатның авторы Шамил абый Рәкыйпов иде!

Иҗат дөньясының серләре белән таныштырган да, кызыктырган да, үтә мөһим киңәшләрен биргән, беренче адымнарны ничек-ничек атлап китәргә өйрәткән бик тә тәфсилле, бик тә җентекләп язылган хат иде ул!

Менә хәзер — моңа инде бик күп еллар үткәч уйлап утырам: редакция тормышының тынгысыз «кухня»сында кайнаган Шамил абый ул чагында ничек вакыт тапты икән? Бер белмәгән кешегә ничек итеп шундый ихлас, шундый кешелекле хат яза алды икән?

Тумыштан ук, нәселдән үк килгән һәм кан буенча күчә торган кешелеклелек, ярдәмчеллек сыйфаты этәргәнме аны бу эшкә?

Әллә моңа кадәр үзенең тормышта бик күп «кыен ашавы», Урал һәм Себер якларында авыр физик эшләр башкарып, дөнья күргән бик күп агайлар белән аралашып, акыл, сабак, гыйбрәт һәм үрнәк туплау нәтиҗәсе булганмы бу эчкерсез адым?

Яисә иҗат дөньясына бик тә бирелгәнлек, аңа табыну һәм әнә шул юлга азмы-күпме ярдәм итәрдәй һәр адымны, һәр эшне башкарырга теләве булганмы ул аның?

Әллә инде «кеше үтенеченә һәм инде, яшь кеше язмышына бигрәк тә, игътибарлы булу» дигән сыйфатмы икән ул?

Шамил абыйның үзен күргәнче үк күңелдә аңа карата ихтирам уяткан тагын бер очракны әйтеп узасы килә. 1963 елда аның «Барып аласы хат» исемле беренче повесте китап булып басылып чыкты. «...Менә мин тагын Әгерҗе кунакханәсендә...» дигән сүзләр белән ачылып китә ул әсәр. Ләкин биредә хикмәт бу повестьның безнең як кешесенә — ике аяксыз килеш комбайнга утырып эшләгән һәм шуның белән Алексей Мересьев батырлыгын кабатлаган иргә багышланган булуда гына түгел. Ныклап уйласаң, гади кешенең зур рухи көче, ныклыгы турында сүз бара иде биредә. Аның ил ышанырдай, ил таянырдай чын ир булуы хакында иде сүз! Проза өлкәсендәге үзенчә бер «гадиләргә гимн» иде бу повесть! Шуңа әсәрне ул елларның әдәби җәмәгатьчелеге дә бик җылы каршылады.

Ә шәхсән минем өчен бу эш — хат язып күңелгә гомергә кереп калган изге абыйның безнең як кешесе турында шундый шәп әсәр иҗат итүе — миңа тагын да бер мәртәбә канат кую, тагын бер кат олы юлга дәртләндерү кебек иде. Ул чагында мин бу повестьны әнә шулай кабул иттем.

Менә әле без ике генә фактка тукталып үттек. Шамил Рәкыйповның бер белмәгән яшүсмер малайга үтә җитди, үтә кешелекле хат язуына һәм шулай ук гап-гади бер комбайнчы батырлыгына багышлап повесть иҗат итүенә. Ләкин менә шуларда да бу шәхеснең тормышта һәм иҗатта тоткан юнәлеше, кредосы бик ачык чагыла түгелме?

Ә инде 1967 елда татар халкының кыю улы — немец фашизмы белән көрәштә Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллин батырлыгына тиң каһарманлык кылган Барый Шәвәлиев турында «Чәчәкләр сөйли белә» исемле повестен бастырып, Шамил абый Рәкыйпов үзенең иҗади юнәлешен тагын да ныгытты, ачыграк итеп раслады. Дөрес, бу әсәр документаль нигездә язылган. Ләкин укыган чагында аны чын әдәбият җимеше буларак кабул итәсең. Чөнки образлар тулы канлы, тел һәм сурәтләү чаралары да укучыны кызыктырып, мавыктырып барырлык. Ә эчтәлегенең мөһимлеген, тирәнлеген инде әйткән дә юк!

Моннан соңгы елларда Ш.Рәкыйпов безнең Казан шәһәрендә яшәп сугышка алынган белорус егете Иван Кабушкин турында «Кайдан син, Жан?» дигән, татарлардан беренче мәртәбә Советлар Союзы Герое исемен алган Гыйльфан Батыршин һәм аның сугышчан дусты турындагы «Таңнар һаман матурмы?» исемле һәм данлыклы хатын-кыз очучыларыбыз Мәгубә Сыртланова, Ольга Санфирова һәм аларның полкташлары хакында «Кызлар-йолдызлар» дигән, шулай ук «Кипарислар җыры» исемле повесть-

лар да язды. Үз иҗатындагы шушы бәрәкәтле юнәлешне ул соңрак басылган «Геройлар эзеннән», «Геройлар үлмиләр», «Аяз күктә карлыгачлар» кебек җыентыкларда да уңышлы дәвам итте.

Әйе, һичбер шик булырга мөмкин түгел: бу әсәрләр басылып чыккан елларда да укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителделәр, яратып укылдылар. Һәм ышанып әйтергә була — алар хәзер дә еш укыла, хәтердә кала, эзләнеп алына торган әсәрләр рәтендә.

Билгеле, соңгы елларда бездә үткән сугышка һәм аның каһарманнарына карата бүтәнчә фикер белдерүчеләр дә табыла башлады. Ләкин, әйдәгез, менә шушы урында ныклап, ашыкмыйча, җитди итеп уйланып алыйк — ә шулай да дөреслек кайсы якта соң?

Милләтнең көчле уллары, асыл уллары илгә авырлык килгән чакта сынала. Илне һәм ил мәнфәгатен саклаганда сынала! Әнә шундый чакларда инде ихлас күңелле, икейөзләнүне белми торган һәм үз иманнарына тугры кешеләр «туган җирем өчен, гаиләм өчен, үз иманым өчен» дип көрәшкә ташлана. Ә инде бүтән төрле яшәүчеләр — иң беренче чиратта, шәхси иминлек, тамак туклыгы хакына төрле-төрле хәйләгә, сату һәм сатылуга баручылар — алар инде мондый чакларда әллә нинди җайлар таба, әллә нинди хәйләләр куллана һәм кыенлыктан читтәрәк, арттарак калырга тырыша.

Безнең татар халкы тарих буйлап бик озын юл үтеп килә. Кыенлыклар һәм сынаулар тулы авыр юл ул. Әнә шул авыр юлны узу дәверендә — үткәндә, бүгенгедә һәм киләчәктә — әлеге ике төр кешеләрдән кайсылары кадерлерәк соң милләт өчен?

Әлбәттә, көчле, кыю рухлылар! Ил өчен, иман өчен, гаделлек өчен кыю рәвештә алга бара алучылар! Болар — мондыйлар — алар бит кеше җанының, кеше рухының да никадәр көчле һәм бөек була алуын раслый!

Безнең бәйсезлегебез өчен көрәш барган елларда да иң алгы сызыкта әнә шундый ихлас җанлы, шагыйрь йөрәкле, матур күңелле затлар булды бит! Халкыбыз, милләтебез ул вакытта да, хәзер дә аларга сокланып карый!

Әйе, тегесе дә дөрес: яшәү дәвам иткәндә, хәйләкәрләр дә бетмәс. Милләтнең каһарман улларына карата алар чәчә торган төрле гайбәтләр дә тукталмас... Ләкин, һәр иртәне балкып Кояш чыккан һәм дөньяга якты нурын сипкән шикелле, милләтнең батыр, каһарман улларының садә, керсез, фидакарь адымнарына карата да халык мәхәббәте сүрелмәс! Ә куркак хәйләкәрләр сүзе исә ярканат сыман гел күләгәгә, гел караңгыга таба качар... Халык, милләт күзеннән читкәрәк качар.

Менә шушы хакыйкатьне яшьтән үк яхшы аңлаган Шамил Рәкыйпов татар халкының батыр улларын барлауга бөтен иҗатын, гомерен багышлады. Татарстан китап нәшриятында эшләгән чагында, аның, үз хисабына ял алып, ил буенча архивларда йөрүен, анда айлар, атналар буе утыруын бик күп язучылар белә. Шулай ук Язучылар берлегендә оешкан хәрби-патриотик комиссияне җитәкләп тә Шамил абый бик күп яшь иҗатчыларга ярдәм итте, әдәбиятыбызда шушы тармак көчәйсен өчен тырышты.

Ә инде сиксәненче елларда Шамил абый Рәкыйпов үткән сугышның аеруча бер мәгънәгә ия булган эпизодын — Берлиндагы рейхстагка байрак кадау күренешен ачыклау өчен күп көч куйды. Һәм үзенең тынгысызлыгы, тырышлыгы, хәтта үҗәтлеге аркасында, гаделлекнең «Правда» газетасы битләрендә урын алуына иреште! Анда милләттәшебез Гази Заһитовның рейхстагка беренче булып байрак кадавы расланды, шул хакта язып чыгылды! Бу — безнең язучыбызның да зур җиңүе иде.

Шул ук вакытта моны хәрби-патриотик темага каршы сүз сөйләп йөрүчеләрнең борынына чиртү дип тә аңларга кирәк. Чөнки татар халкының асыл уллары зур батырлыгы тагын бер мәртәбә бөтен дөнья каршысында расланды бит!

Әйе, безнең даһи Тукаебыз бер дә юкка гына:

Без тынычта аттан артык эшлибез,
Без сугышта юлбарыстан көчлебез! —

димәгән шул! Милләтнең көче, аның яшәү сәләте һәм ниндилеге чыннан да әнә шундый вакытларда күренә бит ул!

Татарстан китап нәшриятында эшләгән чагында, Шамил абый озак еллар буе яшьләрнең «Идел» альманахының редколлегия әгъзасы булып торды. Кайберәүләр иң беренче таләп итеп югарыдагы түрәләргә ошау принцибын куйган вакытта, Шамил абый әсәрләрнең әдәби сыйфатына, иҗатчының талант дәрәҗәсенә игътибарын юнәлтә иде. Әнә шул чагында мин күп еллар элек үземә дәртләндергеч хат язган бу кешенең чыннан да кешелекле, чыннан да киң күңелле зур шәхес булуына тагын бер мәртәбә ышандым.

Иҗат йортларында да еш кына күрергә туры килде Шамил абыйны. Мәскәү янындагы иҗат йортында якташыбыз татар генералы Гордов турындагы әсәрен язды ул. Кайбер өлешләрен миңа да укып күрсәтте. Аның бу әсәрендә дә кешенең ничек итеп көчле һәм рухи нык була алуы раслана иде. Тормыш вакыйгаларын җиңә алу сәләте ачыла иде.

Әйе, батырлык темасы тормышта да, әдәбиятта да беркайчан да искерәчәк түгел. Хатын-кызларыбызның матурлыгына һәм ирләребезнең батырлыгына халкыбыз һәрчак дан җырлаячак!

1998

Кем нәрсәдән курка?

Торгынлык еллары битарафлыгыннан без, ниһаять, акрынлап булса да арына киләбез. Шуңа күрә тормышыбызның һәр тармагындагы җитешсезлекләр турында ачыктан-ачык әйтәбез, матбугатта да язып чыгабыз. Бу бүгенге татар әдәбиятына да кагыла. Чөнки үткән елларда игътибар ителергә тиешле байтак кына мәсьәләләр җыйналды. Менә хәзер без аларны берәм-берәм күрсәтә, хәл итү өчен тырыша башладык.

Алда торган ул мәсьәләләрнең исә төрлесе бар: оештыру рәвешендәгеләре дә, ижади пландагылары да. Беренче төрдән иң зурысы яшьләр өчен әдәби матбугатның аз булуы иде. Ниһаять, берничә ел элек ул кузгалды. Сугышка кадәр басылган күпсанлы яшьләр журналларыннан берсе яңадан чыга башлады. Башка кайбер омтылышлар да күренә...

Инде ижади яссылыктагы мәсьәләләргә килсәк, монысы безнең үзебезгә кагыла, монысы безнең үзебездән тора.

Сүз нәрсә турында бара соң?

Биредә безнең сүз әдәбиятыбызда чын мәгънәсендә ижади атмосфера булдыру турында бара. Демократия һәм хәбәрдарлык чорына хас булырдай шартлар булдыру хакында.

Эш шунда: баксаң, безнең япь-яшь кенә авторларыбыз да алда торган проблемаларны уртага салып һәм киңәшләшеп хәл итәргә өйрәнмәгән икән әле. Әйтелгән фикер һәм тәкъдимнәргә заманыбызның чын эш кешеләренә хас булганча реаль карап, аларны уртак мәнфәгатьләрдә файдаланырга өйрәнмәгән, күнекмәгән икән әле. «Татарстан яшьләре» газетасында (1988, № 28) һәм «Казан утлары» журналында (1988, № 5) һәм башка матбугат органнарында дөнья күргән кайбер мәкаләләр күңелдә «торгынлык чоры язмалары» дигән тойгы уяталар. Мондый язмаларның төп ялгышы шунда — алар татар поэзиясен кемнәндер саклыйбыз дигән пәрдә астында бүгенге шигырьчеләрне гомумән дә укучы һәм әдәби тәнкыйть күзлегеннән читкә чыгармакчы булалар. Алар бүгенге шигъриятне тәнкыйттән өстен сфера итмәкче булалар.

Мисал өчен, яшьләр газетасының югарыда күрсәтелгән саныннан бер өзек китерик: «Менә берничә ел инде бериш тәнкыйтьчеләр шигырьгә көн күрсәтмиләр. Матбугатта бүгенге татар поэзиясе адресына нинди генә гаепләр ташланмады да, нинди генә авыр сүзләр әйтелмәде. Тик, ни гажәп, арада татар шигырен яклап үзенең саллы сүзен әйтердәй бер генә олпат шагыйрь дә табылмады. Сүз кулуарлардан ары китә алмады.

Хәсән Туфан, Сибгат Хәким исән чакта поэзиягә кизәнергә берәү дә җөрьәт итми иде. Поэзиягә кизәнү Туфанга, Хәкимгә кизәнү белән бер иде ул вакытта».

Менә шушы бер кечкенә өзектә генә дә авторның әллә ничә фикри ялгышы бар. Әйдәгез аларны рәттән тикшерик.

Беренчедән, ул «тәнкыйтьчеләр шигырьгә көн күрсәтмиләр» ди. Белүебезчә, матбугат органнарында шигырьләр нәкъ элекке күләмдә чыга киләләр. Бернинди дә кысу юк. Димәк, беркем тарафыннан да көн күрсәтмәү турында сүз була да алмый.

Икенчедән, тәнкыйтьчеләр һәм укучылар әлегә кадәр бары тик йомшак, начар язмаларны — шигырь булып җитмәгән язмаларны гына тәнкыйть итеп чыктылар бит. Мондый язмаларның «чын шигърият белән уртаклыгы юк» дип әйттеләр. Әлеге мәкалә авторы әнә шул йомшак әйберләрне поэзия дип саный микәнни? Тәнкыйть шуларга гына булган иде бит!

Ә Нури Арслан, Гамил Афзал кебек чын шагыйрьләрне, шулай ук Мөдәррис Әгъләм, Нияз Акмал кебек табигый талантларны исә без һәрвакыт һәм һәркайда бары тик мактап кына киләбез. Без талант белән талантсыз авторны һәрчак аерып карау ягында. Аларны тигезләмәү ягында!

Ә без искә алып киткән мәкаләдән күренгәнчә, автор «шигърият» дигән бер гомуми сүз куллана да бөтен кешене бертигез итеп карый. Аларны тигезли. Ягъни талант белән талантсызны тигезли ул!

Нәкъ әнә шундый аерып карау булмаганга күрә бит инде хәзер безнең байтак кешеләребез (хәтта татар телен юньләп белмәүчеләр дә!), үзләрен чын шагыйрьләр санап, күкрәк киереп йөриләр. Чын, табигый талант ияләре белән бер дәрәҗәдә, ә кайчагында алардан күпкә шәбрәк иттереп китап та чыгара алар. Гонорарны да күбрәк алмаса, азрак алмый!

Безгә бик якын арада талантлар белән талантсызлар отрядын икегә аерып карарга кирәк булачак. Икесенә ике төрле мөнәсәбәт булдыру кирәк булачак. Чөнки әдәбият ул — талантлар юлы!

Өченчедән, әлеге мәкалә авторы, поэзияне якламыйлар дип, өлкәннәрне битәрли. Ә бит монда эш гап-гади тора. Өлкәннәр бит чын поэзиягә кизәнүнең юклыгын, бары тик күпсанлы шигырьчеләрне генә тәнкыйть итү барганын күреп тора. Алар, өлкәннәр, чын шигырьне ясалма шигырьдән бик яхшы ае-

ра бит. Кайбер шигырьчеләрнең робот язган сыман салкын, хиссез һәм ясалма куплет төзүләренең поэзия белән бернинди дә уртаклыгы юклыгын яхшы белә бит алар.

Дүртенчедән, Туфан белән Хәким һәм хәзерге лидерлар мәсьәләсе. Биредә инде үзен шагыйрь санаучы автор үткән чордагыча фикер йөртүен бигрәк тә ачык сиздерә. Алга таба әле ул үзенең мондый уен тагын да көчәйтә һәм болай дип әйтә: «Әйе, поэзия лидерсыз, аксакалсыз яши алмый. Чирүбашсыз калган бүреләр өерен дә сунарчылар җәһәт туздыралар». Менә сиңа мә! Без хәзер бөтен тормышыбызда демократия өчен, халыкның һәм һәр намуслы кешенең актив яшәве өчен көрәшәбез, ә биредәге иптәш исә хәтта поэзиядә дә лидерлар, юлбашчылар идеясен күтәрә. Иң зур җаваплылыкны аларга йөкли. Бу бит шигърияттә, демократик җәмгыять поэзиясендә бигрәк тә көлке яңгырый!

Киресенчә! Без күпсанлы һәм көчле талант ияләренең матур янәшәлегенә омтылырга тиеш! Лидерлар һәм абруйлар турында баш ватмыйча, ижатыбыз турында, яңа ижади эзләнүләр, яңа табышлар, ачышлар турында уйларга тиеш!

Бүгенге татар поэзиясендә яшәп килгән җитешсезлекләр хакында ачыктан-ачык сөйләшүне булдырмаска теләү, поэзиянең бары тик уңай якларын гына күрсәтергә чакыру тормышыбызның икенче бер тармагында булып үткән хәлләрне искә төшерә.

Билгеле булганча, торгынлык чорында зур урын биләп торган түрәләр халыкка каршы байтак кына хилафлыклар кылдылар. Ә яңарыш чоры килеп, халык аларның «койрыгына баса» башлагач, алар «партиянең һәм аның урындагы җитәкчеләренең абруен төшерәсез» дип сакланырга теләделәр. Партия авторитетына ышыкланырга маташтылар башта.

Чынлыкта шигырь мәсьәләсендәге хәйләнең дә нигезе, төбе шул ук: шигъриятнең абруе турында кайгырткан булып күренергә тырышу! Ягъни укучылар үз сүзләрен әйтә-әйтә гаделлеккә кадәр барып җитмәсеннәр. Чөнки бу — талантларны һәм талантсызларны аермачык итеп билгеләү булачак бит!

Кайберәүләр бүген әнә шуннан бик тә курка! Шул курку тойгысы «кизәнү» дигән уйдырма уйлатып чыгара. Шул курку матбугаттагы гадел сөйләшүне туктатырга куша.

Ә поэзияне ярату мәсьәләсен әле шулай ук ачыклап бетерәсе бар. Начар шигырьләр язып, аларны күпләп бастыручы кеше ныграк ярата микән поэзияне, әллә шигъриятне үтә дә ихтирам иткән, аны тирәннән тойган һәм бай күңел дөньясы белән яшәүче меңләгән укучы микән?! Поэзиягә кем кизәнә икән: начар шигырьләр бастырып чыгаручымы, әллә аларны «начар бит» дип әйтүчеме? Безнеңчә, начар шигырьләр бастыручы һәм күкрәк киереп үзен шагыйрь дип йөрүче, чын шигъриятнең данын төшерүче кешеләр поэзиягә ныграк кизәнәләр. Бүгенге татар шигъриятен гадел тәнкыйть сүзеннән түгел, ә әнә шундый мөтәшагыйрьләрдән, ялган шагыйрьләрдән сакларга кирәк!

Х.Туфан белән С.Хәким көнлекче шагыйрьләргә каршы нык көрәштеләр. Чын шигъриятнең абруен вак мәгънәле, көпшәк куплетлар белән төшертмәү өчен гел борчылып яшәделәр. Әрсезлек һәм терсәк белән поэзиягә керергә маташу алар күз алдында иң зур җинаять кебек иде. Ә без югарыда күрсәткән мәкалә авторлары исә «аксакаллар исән булса, шигырьчеләрне яклап чыгарлар иде» дигән фикер үткәрәләр.

Юк, алар көнлекчеләргә ярсып каршы төшәрләр иде!

Шулай итеп, мондый язма авторлары, «поэзияне яклыйбыз» дигән булып, чынлыкта йомшак, җитлекмәгән, талантсыз шигырьләр язу һәм бастыру юлын яклыйлар. Андый буш куплетларга беркем дә тел тидермәсен, диләр.

Ләкин халык үзенең талантлы улларының һәм кызларының гына ижатын ярата шул. Чөнки алар бәгырьгә үтәрдәй итеп язалар. Ә бүгенге кайбер яшьләр кебек шигырь томаны тудырып, күп сүз белән кеше алдарга маташучыларны без шагыйрь дия алмыйбыз.

Бүгенге поэзиянең абруен күтәрү мөмкинлеге — талантларда! Аларга киңрәк мөмкинлек бирүдә, басарга әсәрләр сайлаган вакытта бары тик талантлы авторларга һәм аларның халыкчан әсәрләренә генә йөз тотуда.

Ә тәнкыйть сүзе гадел булса, ул һәрчак эшкә ярдәм итә. Ул үсешкә китерә. Аннан чиста күңелле булмаган кайберәүләр генә куркырга мөмкин.

Тулаем алганда исә бүгенге поэзиябездә чын мәгънәсендә талантлы яшь көчләр байтак. Аларга бүгенге көрәш мәйданының үзәгенәрәк керү генә кирәк. Халык көткән уй-хисләрне тулырак, тәэсирлерәк чагылдыру гына кирәк.

2000

Мизгел

Мәңгелек яшәеш кыска гына кеше гомере. Шул мөнәсәбәттә кеше тормышының мәгънәсен аңларга тырышып тарих буена никадәр акыл ияләре баш ватмаган. Газаплы эзләнүләрдән соң берәүләре тирән ачыну белән:

— Мәңгелек яшәештә кеше гомере мәгънәсез бер мизгел! — дигәннәр һәм үз ирекләре белән дөньядан киткәннәр, яисә бер кайгысыз типтереп яшәү юлына басканнар.

Болары — йомшак җанлылар!

Ә икенче берәүләр:

— Әйе, кеше гомере мәңгелек яшәештә — бер мизгел. Ләкин әнә шул мизгелләр буйлап бөек процесс — тарих ага! — дигәннәр ышанычлы тавыш белән һәм тормышлары белән бергә тарихка исемнәрен дә кертеп калдырганнар.

Болар — көчле кешеләр.

Язучы Кави Латыйповның «Мизгел» хикәясен укыгач, кеше тормышы һәм аның мәгънәлелеге, үз тормышлары белән яшәүнең эчтәлеген баеткан әнә шундый көчле кешеләр турында уйланасың. Мондый уйларга оста төзелгән композиция дә, тирән мәгънәле сүзләр һәм детальләр дә алып килә.

...Җәйге эссе көн. Кешеләр, озын чират булып, квас эчәргә тезелгәннәр. Бер дә ашыкмый-пошынмый, телләренә ни килсә, шуны сөйләшә-сөйләшә, акырын гына кыймылдыйлар. Бу озын чиратның бер дә башы-ахыры юктыр сыман, ул моңарчы да шулай хәрәкәтләнеп торгандыр һәм әле тагын шулай бик озак агар да агар кебек. Шушы чират әйтерсең мәңгелек тормышның гәүдәләнеше. Ләкин башта без чиратның бу олы мәгънәсен аңлап җиткермибез әле. Аның мәгънәсен көтмәгәндә яңгырап киткән бер аваз ачып сала. Бу аваз — ерактагы матәм маршының бирегә килеп җиткән бер бик кыска өзеге генә. Ләкин әнә шул музыка авазының очсыз-кырыйсыз чиратка килеп бәрелүе белән, күз алдына язучы тудырырга теләгән картинаның фоны пәйда була: бер гомер, бер тормыш һәм мәңгелек хәрәкәттәге тормыш. Автор безгә хәзер шул өлкәдә нәрсәдер ачачак, күңел дөньябызны баетачак.

Процессия якыная. Ләкин ул якынайган саен, матәм маршы түгел, ә мәрхүмне озатучы картларның, әле яшәргә калучыларның таяк тавышлары ныграк ишетелә бара. Аларда, кайгы-хәсрәт урынына, аңардан көчлерәк хис, күтәренкерәк аһәңнәр ишетелеп китә, автор тасвирлаган шушы аһәңнәр безнең күз алдында мәрхүм Заһидның ялкынлы тормыш кайтавазы булып кабатлана. Кави Латыйпов безне әнә шулай бу кешенең тормышына алып килә. Без Заһидның бер аягы юк килеш сугышып йөргәнен, сугыш кырыннан яралы шәфкать туташын алып чыгуын, аннары, сугыш беткәч, балалар арасында кайнаганын күрәбез. Ул кайда гына булмасын, тормышны үз дигәненчә, яхшыга таба үзгәртү өчен көрәшкән.

— Нинди әйбәт квас... Инде ул мәрхүм беркайчан да квас эчмәячәк,— дигән сүзләр беренче карашка Заһидның чиратта, димәк, тормышта икәнлеген әйтәләр кебек. Ләкин әсәрнең логикасы белән әзерләнеп килгән фикер кеше үзенең тормышы белән мәңгелекнең үзенә бирелгән бер мизгелен озынайта ала, үзгәртә ала дигән фикер хикәянең төп идеясе булып яңгырый.

Эчтәлеге белән әнә шундый укучыны уйландырырдай хикәяләрне Кави Латыйпов әсәрләре арасыннан тагын табарга мөмкин. Мәсәлән, «Үги ана яфраклары», «Култык таягы» кебек хикәяләр язучыда тормыштагы вакыйгалар чылбырын тотып ала белү сәләте барлыгын күрсәтеп торалар. Бу — Кави Латыйповның озак еллар дәвам иткән иҗади тәжрибәләр нәтиҗәсе, күрәсең. Ләкин язучыга үткер күз булу өстенә чын сәнгатьчә осталык та кирәк бит әле. Эстетик зәвыгы югары булган бүгенге укучы язучының әйтер фикерен шыр ачык вакыйгалар тезмәсе аша гына түгел, ә тормышның табигый үстерелү логикасында, катлаулы диалектика аша кабул итәргә тели. Шундый таләп белән караганда, авторның осталыгы ни дәрәҗәдә соң? Безнең зур әдәбиятыбыз өчен бу хикәяләр нинди мизгел — эзсез югала торганмы, әллә байлыгы, мәгънәлелеге белән аңа яңа көч, төсмер бирә торганымы?

Без карап үткән «Мизгел» хикәясе Кави Латыйпов иҗатында ирешкән иң зур биеклектер, мөгаен. Бу хикәядә без бүгенге әдәбият сулышын тоеп алгандай булабыз — тирәнлек һәм образлылык белән очрашабыз. Ләкин ул хикәя күп кенә хикәяләр арасында якты мизгел булып кына кала. Менә алынган ситуация буенча шактый кызыклы гына булган «Ясалып бетмәгән портрет» хикәясе. Әмма автор шул кызыклы ситуацияне сәнгать чаралары белән тыгызлап үрә алмый. «Мизгел»дәге тирәнлек монда саега, тыгызлык югала, кайнар атмосфера вакыйгаларның өстен һәм туп-туры агышы белән алмашына. Бу куркыныч агым башка хикәяләрдә тагын да ныграк сизелә. Хәрби темага багышланган хикәяләр турында исә аерып әйтмичә дә булмый.

Билгеле булганча, сугыш темасы инде безнең әдәбиятта шактый күп һәм тирән яктыртылды. Хәзер яңадан аңа алынган автордан без шаккатырырлык вакыйгалар түгел, ә кеше характерының тагын да тирәнрәк ачылуын көтәбез. Ләкин Кави Латыйпов үз хикәяләрендә характер, кешенең психологик кичерешләрен ачудан әллә ни яңалыкка ирешә алмый. Автор, игътибар үзәгендә вакыйгалар барышын тотып, геройларның үз-үзләрен ачуына, образ тудыруга әһәмият бирми. «Самавыр» хикәясе моңа ачык мисал. Анда гитлерчылар тарафыннан оккупацияләнгән Донбасста фюрерга дип халыктан налог җыеп йөргән бер сатлык җан язмышы сурәтләнә. Сугыш беткәч, аның үзе талап алган самавырларын бирергә самавыр ияләрен эзләп йөрүен тасвирлап, автор бу кешенең мескенлеген ачарга тели, күрәсең. Ләкин аны автор шулкадәр мескенәйтә, әсәрдә бу кешенең җаны калмый, ул образ буларак үзенә йөкләнгән

фикерне укучыга илтеп җиткерә алмый. Аннан соң хикәячегә нәкъ менә самавыр алынуы да ачык түгел. Чехов әйткәнчә, әлеге предмет бу урында «атмый».

«Солдат хат яза» хикәясе автор ижаты өчен күп яктан характерлы. Менә аның сюжеты: армиядә хезмәт итүче Җәмил дигән егет ял иткән вакытта сөйгән кызы белән утрауга бара һәм анда балалар йортында үзен тәрбияләгән Газзә апасы улының каберен таба. Ул көнне Җәмил Газзә апага хат салырга өлгерә алмый. Ә икенче көнне ни күрсен, Газзә апа үзе килеп җиткән. Җәмилгә белгертми генә, аңа сөйгән кызы хәбәр иткән икән. Хикәя ананың улы кабере өстендә сурәтләү белән тәмамлана.

Хикәяне укып чыккач, иң башта бу сюжетның инде әдәбиятта, бигрәк тә балалар әдәбиятында күп тапталган булуы һәм шуңа яңадан бер авторның хикәя язарга утыруы кәефне боза. Аннан соң ул бик күп очраклы хәлләргә корылган булуы белән ышандырмый. Кабер ташының нәкъ менә Җәмилгә очравы, Җәмилнең ничә мәртәбә утырып та хатны тәмамлый алмавы, Газзә апаның икенче көнне үк килеп җитүе — болар бар да хикәядәге вакыйгалар агышы белән нигытылмаган очраклылык, автор валюнтаризмы. Хикәяне әдәби әсәр итмәгән тагын бер сыйфат — үзенең калган әсәрләрендәге кебек бу хикәядә дә автор геройның һәрбер хәрәкәтен теркәп, солдат тормышының әсәр идеясе өчен бөтенләй әһәмияте булмаган вакытларын да бердәй игътибар белән сурәтләп бара. Ә бу — укучының игътибарын тарката, аңа иң кирәкле вакыйгага тупланырга комачаулый.

Язучының хикәяләрен укыганда, сюжетларның гел хат тирәсендә тезелгән булуы да туйдыра башлый. Бу факт үзе үк Кави Латыйповның әдәби ижатка җиңелчәрәк каравын күрсәтә. Тормышта да, әдәбиятта да мәсьәләне хатлар аша гына хәл кылу иң ансат юл бит ул!

Шулай ук хикәяләрдә бик күптөрле милләт кешеләрен алу да авторның интернациональ рухлы язучы икәнен күрсәтми, хикәяләрнең эчке таләбенә туры килмәгәне артык чуарлык булып кына тора.

Язучының хикәяләрен укып чыккач, яңадан «Мизгел» хикәясе хәтергә төшә. Автор анда мәңгелекнең бер мизгелен озынайта алу турында сөйләгән иде. Аның өчен кешенең тормышта янып яшәве, югары идеаллар өчен көрәшүе кирәк, дигән иде. Ә автор үзе ничек көрәшә соң? Укучы күңелен нинди яңа үрләргә күтәрә, аңа нинди яңа фикер орлыклары ача? Кызганычка каршы, күп хикәяләр укучы күңелен баета да, дулкынландыра да алмыйлар. Аларда тормышны сәнгатьчә тикшерү, аның тирән хакыйкатьләрен образлы итеп ачып бирү юк. Шуңа күрә «Мизгел» хикәясендә сурәтләнгән бәхетле язмыш аларның күбесенә елмаймас шикелле.

Язучыга киләчәктә якты мизгелләр юлдаш булсын иде!

2000

Елларга калсын!

Йөзләрчә, меңнәрчә еллар элек яшәгән бик күп моңлы җаннарның газаплы йөрәк авазлары булып үзәк өзгеч җырлар калган... Без — егерменче гасыр ахырында яшәүчеләр — хәзер ул җырларны тыңлаганда, хискә бирелеп тәмам онытылабыз, эрибез, югалабыз... Юк, гади эрү һәм гади югалу гына түгел бу! Безнең әлеге серле халәтебез — мәңгелектән килеп мәңгелеккә баручы халык рухы чишмәсенә тоташып, ялганып алуыбыз ул. Заманабыз кешесенең нечкә күңеле әнә шулай итеп үзенә ышанычлы юл сала, халык рухы чишмәсенә таба тирәнәя, үзенең рухи кыйбласын дөресли.

Үткәннәрдән безгә сихри моңнар калган...

Безнең чорыбыз да үзеннән соң әнә шундый көчле, әнә шундый яшәүчән моңнар калдырыр микән?

Шигърият бакчасында, бигрәк тә яшьләрнең шигъри мохитендә, бүген нинди җырлар яңгырый, нинди авазлар ишетелә?

Бу сорауга җавап эзләп әле яңа гына беренче китапларын чыгарган ике яшь шагыйрь ижатына мөрәҗәгать итик. Яшьлек булгач — әлбәттә инде, анда көчле хисләр, мәхәббәт зур урын ала. Яшь шагыйрә Шәмсия Җиһангирова «Төсле моң» исемле китабында кызларның мәхәббәт утында януын менә ничек тәэсирле итеп бирә:

Йөрәгемне телем-телем
Кисеп алалармыни,
Телемнәрен дөрләп торган
Утка салалармыни?!

Халыкча гап-гади итеп һәм шул ук вакытта нинди тәэсир көче белән әйтелгән! Бары тик үзе кичергән кешедә генә була торган ихлас интонация дә бар, кайнар хиснең кайнар дулкыны да бар.

Газинур Моратовның «Җир хәтере» исемле китабында яшь лирик герой үзенең идеалын эзләп бара.

...Эзләгәнне җирдә таба алсаң,
Шул — яшәүнең бөек сәгадәте.

Шулай ук кыска һәм үтемле әйтелгән. Гомумән, ике китап та соңгы еллар шигъриятенә хас сыйфатны: кыскалыкны, тыгызлыкны шактый ачык гәүдәләндерә. Һәр ике китапта да озынлыгы белән ялыктырырдай, мәгънә ягыннан көпшәк шигырьләр таба алмыйсың. Замана яшьләренең үзләренә хас сыйфатның — рациональлекнең бер чагылышыдыр бу, күрәсең...

Яшьлек үзенең мәхәббәте, кайнар хисләре белән кабатланмас матурлыкка, бернигә алыштыра алмастай кыйммәткә ия. Ләкин, икенче яктан караганда, яшьлек ул үзенә аерым бер дөньяда яшәми. Олы дөнья, реаль чынбарлык мәшәкатьләре аңа берничек тә ят була алмый. Хәтта әле киресенчә, күпләр яшьлек ялкыны белән үз гомерләренең иң зур һәм халык онытмастай эшләрен эшләп куялар. Заманыбызның атаклы шагыйре Е.Евтушенко «Казан университеты» поэмасында язганны искә төшерик:

Зрелость гения не кается,
А с юностью пересекается...

Әйе, бик дөрес — яшьлектә кешенең язмышы, гомер юлы башлана. Яшь шагыйрьләрнең дә талант көче үз җырларына олы дөнья уйларын сыйдыра алуы белән үлчәнә.

Без хәзер игътибарга алган ике яшь шагыйрь ил күңелен, халык рухын ни дәрәҗәдә чагылдыра соң?

Беркемгә бирәчәк түгелмен
Үз җирем, үз телем, үз илем! —

дип яза яшь шагыйрә. Аның сүзләрендә безнең аналарыбыз һәм апаларыбыз, яшь кызларыбыз тавышы ишетелә, алар күңелендә йөргән иң зур горурлык хисе чагыла. Ш.Җиһангирова иҗатында тормышка, иленә, җиренә гашыйк һәм туган халкын сөюче гади авыл кызы образы матур гәүдәләнә. Ул үзенең ихлас хисләрен сөйли. Гади, әмма бөек эчтәлеккә ия бәхетен җырлый.

Яшь шагыйрь Г.Моратов та үз җирен, үз илен ярата. Әмма ул ир-ат акылы белән язмышын киңрәк итеп билгели:

Бу хәвефле планетаның
Газиз миңа һәр ягы.

Әйе, һәр икесенеке дә аңлашыла. Биредә бернинди дә каршылык юк. Чөнки борын-борыннан шулай килә: хатын-кызларыбыз йорт җылысын, туган учакны сакласа, ир-егетләребез һәрвакыт олы дөнья гаме белән борчылган, гаилә һәм ил иминлеген тәэмин итәргә тырышкан.

Хатын-кыз күңелен җырлаучы яшь шагыйрә үзенең «Күгәрченнәр ашата бер ана» шигыре белән бөтен аналарга гүзәл поэтик һәйкәл сала кебек. Менә анда нинди юллар бар: «Әниләрнең табигате шулай. Гел ашата алар. Гел көтә. Балалары очар кебек бер очып кайта да бер китә». Ә инде соңгы юллар, гомумән, үзәкне өзеп, бәгырьне телгәләп ала:

Әйтерсең лә күгәрченнәр түгел,
Кырык бердә киткән ир-егетләр
Әнкәләрен сагынып кайтканнар...

Г.Моратовның әсәрләрендә исә безнең еллар яшь кешесенең рухи портреты шактый тулы гәүдәләнә. Аның үз яшьтәшләренә карап, менә мондый сорау куюы бүген бик тә актуаль һәм көчле яңгырый:

Рухы ныкмы, түзәрлекме,
Әзерме зур алышка?
Ныклы дәвам булырмы ул
Халкым улы Алыпка?

Китапның икенче бер шигырендәге: «Вөжданнары барлар һәрчак шулай: «Күтәрәләр Намус кушканны» дигән юллар да олы гомумиләштерүгә һәм тирән поэтик образлылыкка, публицистик кайнарлыкка ия.

Күреп торабыз, яшьләр учагыннан төтен шактый туры чыга. Алар ил кичергәнне, халык күңеле тойганны шактый нечкә һәм төгәл язалар. Яшь иҗатчылар өчен бу, әлбәттә, аз түгел. Ләкин иҗатчы шәхес һәрвакыт үсештә, хәрәкәттә булырга тиеш. Хәзер бу ике яшь шагыйрь алдында нинди иҗади бурыч тора соң?

Иң башта сүзебезне халык җырларыннан алып киткән идек. Алар бүген яшьләр өчен генә түгел, һәр иҗатчыга да юнәлеш күрсәтә. Халык җырының мәгънәви тирәнлеге, йөрәккә ятышлы ягымлы аһәңе, чиксез күп күзаллаулар тудыручы матур образлары кемнәрне генә сокландырмый да кайсы гына шагыйрь әнә шундый камиллеккә ирешергә теләми икән!

Ә яшьләребез мондый бәхеткә ничек ирешерләр соң?

Биредә «талант» дигән бер генә сүздә белдерелүче җавапка тукталасы килми. Андый җавап, ул юл мәсьәләне җиңеләйтә. «Талант булса, барысы да үзеннән-үзе хәл ителә, баш ватып тору кирәкми» ди-

гән ялгыш карашны көчәйтә. Хәлбуки бик күп даһилар әйткән: «Бер өлеш талант, туксан тугыз өлеш хезмәт!» — дигәннәр.

Әйе, яшьләребездә талант юк түгел. Халкыбызның талантлар чишмәсе һаман саекмый, мул булып тибә. Ләкин байтак яшьләребездә талант көче янына килеп кушылырга тиешле «хезмәт» дигән икенче бер бөек көч җитенкерәми.

Юк, хезмәт дигәндә биредә язу өстәле янында көн-төн баш ватып, газапланып каләм чәйнәп утыру гына күздә тотылмый. Хәер, эшнең даимилеге, кулның шомалыгы, әдәби осталык — алары да мөһим, алары да кирәк.

Әмма хезмәт дигәндә шагыйрь өчен әле тагын да мөһимрәк икенче бернәрсә күздә тотылырга тиеш. Ул нәрсә? Без әйтергә теләгән ул әйбер — күңелнең һәрчак, һәрдаим актив хәлдә, кайнар хәлдә, кызу ритмда яшәве! Ягъни һәрчак югары поэтик накалда булуы! Домна миче кебек гүләп янган йөрәк кенә укучыны сокландырырдай, аның күңелен айкардай шигъри әсәрләр бирә ала! Шагыйрь өчен иң элек әнә шул ул хезмәт! «Душа обязана трудиться!» дигән канатлы сүз дә әнә шул фикерне куәтли.

Әнә шулай яшәүче кайнар йөрәк булганда, безнең яшь шагыйрьләребез дә чорыбыз тормышы тудырган иң мөһим, иң кадерле кичерешләр тирәнлегенә үтеп керә алачаклар. Үз иҗатлары аша ул хискичерешләргә озын гомер бирәчәкләр. Елларга калачак җырлар әнә шулай туачак.

2000

Әнә шундый йөрәк!

...Сиксәненче еллар ахырында һәм туксанынчы еллар башында башкалабыз Казан урамнары «Азатлык» дигән мәгърур сүзнең куәтле дулкыннарыннан гүләп торды...

Әйе, халыкның, милләтебезнең көчен тагын бер мәртәбә ачык итеп раслаган ул көннәр, ул эпизодлар күңелләргә мәңгегә сеңеп калды. Уянып мәйданнарга чыккан халыкның иң алдында баручы Фәүзия Бәйрәмова исеме ул елларда «Азатлык» дигән әлеге бөек сүз белән янәшә йөри иде.

Ә соң аның үзен бу изге көрәшкә нинди юллар алып килде икән?

Фәүзия Әүхәди кызы Бәйрәмова 1950 елның 5 декабрендә Саба районының Сабай авылында, ун балалы гаиләдә туа. Әтисе Бөек Ватан сугышы инвалиды булганлыктан, ул кечкенәдән үк авыл тормышының авыр эшләрен эшләп, дөньяның ачысын-төчесен татып үсә.

1966 елда Олы Шыңар сигезьеллык мәктәбен тәмамлагач, аны, яшьтән актив хәбәрче булуын искә алып, Саба районында чыга торган «Җиңү байрагы» газетасы редакциясенә эшкә чакыралар. Ул шунда ике ел эшләп Саба урта мәктәбен кичен тәмамлый. Мәктәп яшеннән үк инде пьесалар, әдәби сценарийлар яза башлаган Фәүзия Бәйрәмова 1968 елда Казан театр училищесының режиссерлык бүлегенә укырга керә һәм аны 1971 елда уңышлы тәмамлап чыга. Аннары ул алган белеме буенча Казан телевидение студиясендә эшли, 1975 — 1978 елларда гаиләсе белән Монголия Халык Республикасында яши, анда эшче һөнәрен үзләштереп, төзелештә эшли.

Казанга кайткач, Фәүзия Бәйрәмова газета-журнал редакцияләрендә үзен сынап карый. 1979 – 1984 елларда «Казан утлары» журналында корректор булып эшли башлый һәм шул чагында үзе дә актив рәвештә каләм тибрәтергә тотына. 1983 елда Фәүзия Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән торып укырга керә, 1989 елда аны тәмамлап филолог дипломы ала.

Иҗатка мәхәббәт, халыкка якын булырга омтылу Фәүзия Бәйрәмованы республикада чыга торган газета редакцияләрендә профессиональ рәвештә эшләүгә китерә. Ул 1985 –1986 елларда «Татарстан яшьләре» газетасында, 1986 – 1987 елларда «Социалистик Татарстан» газеталарында эшли, газета битләрендә милләт тормышына багышланган күләмле публицистик язмалар белән чыгыш ясый. Аның әлеге язмалары ул еллар татар журналистикасында, халык арасында зур җанлану уята, кешеләрне гаделлек өчен көрәшкә өнди.

1987 елда Фәүзия Бәйрәмова Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият бүлегенә мөхәррир булып эшкә урнаша һәм 1998 елга кадәр шул эшен (соңрак штаттан тыш) дәвам итә.

Фәүзия Бәйрәмова зур иҗатка сиксәненче еллар башында килә. Аның беренче күләмле әсәре «Болын» повесте 1983 елны «Казан утлары» журналында басылып чыга һәм әдәби җәмәгатьчелектә бик тә җылы кабул ителә. Әдәбиятыбыз аксакаллары Әмирхан Еники, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Фәрваз Миңнуллин яшь язучының тәүге адымнарын хуплыйлар.

Менә, мисал өчен, Әмирхан Еники фикере: «...Фәүзия бик талантлы, һәм аның таланты гаять үзенчәлекле... ул үзен һич аямыйча, гүя бөтен нервлары белән бик кабынып-кайнарланып яза... Көчле яза. Аны укыганда инде салкын, битараф калу мөмкин дә түгел. Килешәсеңме-килешмисеңме, яратасыңмыяратмыйсыңмы, ләкин барыбер аңардан аерыла алмыйсың. Укучы кәефенә җайлашып тормый ул! Күн-

тәргән проблемасы һәм алган вакыйгасы белән дә ул, әйтергә кирәк, укучының йокысын качыра... Кыю керә тормышка Бәйрәмова, һәр әсәрендә диярлек кеше язмышының фаҗигале якларын ача. ...ул укучыны да аяп тормыйча кешенең эчке җанына бик тирән үтеп керә».

Олы иҗаттагы әнә шундый тәүге уңышлары белән канатланган Фәүзия Бәйрәмова сиксәненче елларда тагын «Чакрым баганалары», «Битлек», «Кем?», «Күл балыгы», «Кыңгырау», «Канатсыз акчарлаклар» повестьларын яза. 1986 елда аның «Болын» дип аталган беренче китабы Әмирхан Еники кереш сүзе белән дөнья күрә, 1991 елда «Моң» исеме белән икенче китабы басыла.

Шул ук сиксәненче елларда Фәүзия Бәйрәмова драматургия өлкәсендә дә актив эшли. Бу вакыт аралыгында аның «Аллалар ялгышы яки яңа матриархат», «Һәркемгә бер кояш», «Атылган йолдыз», «Сандугачның балалары», «Безне онытмагыз», «Вакыйга җүләрләр йортында бара» һ.б. драма әсәрләре языла. Бу әсәрләр Минзәлә татар дәүләт драма театрында, Казандагы яшьләр театрында һ.б. куела, Казан телевидениесеннән күрсәтелә. 1998 елда авторның «Безне онытмагыз» дип аталган пьесалар җыентыгы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрә.

Сиксәненче еллар ахыры... Совет империясе таркалу... Аңа кергән республикаларның ашыга-ашыга бәйсезлек алырга тырышуы... Автономиянең бик тә тар кысаларында яшәгән Татарстан да, татар халкы да үз азатлыгы өчен көрәш башлый. Кайнар йөрәкле иҗатчы Фәүзия Бәйрәмова бу көрәшнең үзәгендә кайный, аны әйдәүчеләрнең берсенә әверелә. Бер төркем милләтпәрвәрләр белән бергә алар 1988 елда Татар иҗтимагый үзәген оештыра. Фәүзия Бәйрәмова 1991 елга кадәр бу оешманың рәис-координаторларыннан берсе була. Ә инде 1991 елда ул «Иттифак» милли бәйсезлек партиясенең рәисе итеп сайлана. 1994 – 1997 елларда ул Милли Мәҗлес рәисе булып эшли. Бу елларда аның инициативасы һәм җитәкчелеге белән «Татар кануны», «Гаилә кодексы» кебек милләт өчен мөһим булган зур хезмәтләр эшләнә һәм халыкка җиткерелә.

1990 елда Фәүзия Бәйрәмова үзе туган Саба районыннан Татарстан Югары Советына депутат булып сайлана һәм 1995 елга кадәр республика парламентында тынгысыз эшчәнлек алып бара. Шул елларда аның байтак кына публицистик язмалары һәм китаплары да басылып чыга.

1994 – 1995 елларда «Аргамак» журналы битләрендә Фәүзия Бәйрәмованың «Кара урман» исемле күләмле әсәре дөнья күрә. Бу әсәре өчен автор Сажидә Сөләйманова исемендәге бүләккә ия була.

Соңгы елларда ул төрки-мөселман халыклары мәсьәләләре буенча уздырыла торган зур халыкара корылтайларда, конгрессларда катнашты һәм чыгышлар ясады. 1990 елда Германиядә, 1991 елда Бельгиядә һәм Голландиядә, 1992 елда Америка Кушма Штатларында, 1991 – 1998 елларда Төркиядә һәм Кипрда, 1996 елда Даниядә уздырылган форумнарда делегатлар аның чыгышын тыңладылар. Фәүзия Бәйрәмова бүген дә Кавказ, Кырым, Себер, Алтай, Идел буе төркиләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Үзенчәлекле иҗади талантка ия язучы һәм кайнар йөрәкле, фидакарь җанлы сәясәтче бүген дә актив иҗади тормыш белән яши, иҗтимагый-сәяси вакыйгаларда катнаша, һаман да милләтебез мәнфәгатен кайгыртып йөри.

2000

Зурлык

Моннан ун ел элек республикабыз горур рәвештә үзенең бәйсезлеген игълан иткәч һәм исеменең татарча да, урысча да «Татарстан» диеп йөртеләчәген белдергәч — Мәскәү һәм аның биредәге куштаннары, безгә ачу итеп, гел дә гел «Татария» диеп кабатлый иде. Янәсе, бу инде аларның: «Сез элек ничек бәләкәй булсагыз, һаман да шул килеш кала бирәсез — юкка көчәнмәгез!» — диюе кебек иде.

Менә вакыт уза тора. Ә татар иле, дусларын сөендерә-сөендерә, бөтен дөнья күләмендә үзен һәммә яктан матур күрсәтә килә. Шуларның нәтиҗәсе буларак әлеге «Татария» диеп йөрүчеләрнең дә ризасызлык авазлары тоныклана бара түгелме соң?!

Әйе, без хәзер авыз тутырып:

— Татарстан! — диеп әйтәбез. Горурлык белән!

Республикабыз матбугаты битләрендә һәм радио белән телевидениедә соңгы елларда бу юнәлештә байтак эшләр эшләнә. Әле менә «Мирас» журналы битләрендә дә үткән елның 8—9 нчы һәм быелның 1 нче санында бик кызыклы хезмәт дөнья күрде. Ул «Татарлар һәм Европа» диеп исемләнгән. Авторы филология фәннәре кандидаты, Казан дәүләт университеты доценты Энгель Нигъмәтуллин.

Бу хезмәттә Европа галимнәренең һәм күренекле шәхесләрнең татарлар турында әйтелгән, язып чыгылган бик күп фикерләре китерелгән тарихи вакыйгалар тасвирланган. Ә алынган чыганакларның яңалыгына һәм үзенчәлегенә исләрең китәрлек! Монда инглизчә, немецчә, французча басылган китаплар

да бар, шулай ук бик күп илләрнең һәм шәһәрләрнең борынгы хәзинәләрен саклап ятучы серле архивлар, фәнни китапханәләр дә.

Ул өзекләрне укыган чагында, кайчандыр Европа һәм Азия киңлекләрен бер итеп яшәгән зур халык — уңган һәм тырыш, тынгысыз һәм батыр халык күз алдына килеп баса. Аның тормышын һәм көнкүрешен тагын да ачыклый төшкән байтак кызыклы яңалыклар, фактлар мәгълүм була. Ирексездән күңелне горурлык хисе били.

Әйе, халкыбыз турында, аның олы дөнья белән киң бәйләнеше турында шушындый бай һәм тирән эчтәлекле хезмәт язган Энгель ага үзе дә олуг шәхес. Ә аның әтисе исә — атаклы әдәбият галиме һәм педагог Галимҗан Нигъмәти.

Менә шушындый гаиләдә туган Энгель, әлбәттә, кечкенәдән үк бәрәкәтле рухи туфракка эләгә. Бу гаиләгә шул чорның күренекле әдипләре һәм галимнәре еш килеп йөри. Галимҗан Нигъмәтинең хатыны, Энгельнең әнисе Жанна (мулла кушкан исеме Mahиҗиһан) ханымның ачык йөзле, киң күңелле һәм зыялы зат булуы кунакларны тагын да күбәйтә. Кичләрен бу йортта кызыклы әңгәмәләр куерып китә торган була, музыка коралларында да уйнап җибәрәләр. Нигъмәтиләрдә атаклы шагыйрьләр Такташ белән Туфанның да еш булуы билгеле.

Болар барысы да, билгеле, бәләкәй Энгельгә дә, аның апасы хәзер атаклы галимә, филология фәннәре докторы Йолдыз Нигъмәтуллинага да нык тәэсир иткәндер. Аларның барыр юлларын әнә шул чагыннан ук билгеләп куйгандыр.

...1930 елның 6 ноябрендә туган Энгель 1948 елда урта мәктәпне тәмамлый һәм Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Аннары ул Алтай краенда һәм Новосибирск, Казан мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Ә инде 1972 елда Энгель Нигъмәтуллин филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый, Казан дәүләт университетының рус һәм чит илләр әдәбияты кафедрасына ассистент итеп билгеләнә. 1977 елдан шул ук кафедрада доцент булып эшли башлый.

Яшь галим 1968 елда, читтән торып, М.Торез исемендәге Мәскәү чит телләр институтын да тәмамлый.

Энгель Нигъмәтуллинның чит телләрне яхшы белүе башта аның уй-фикер офыкларын киңәйтә, тора-бара ул Европа әдипләренең һәм фикер ияләренең татар рухи дөньясына тәэсирен өйрәнә башлый. Бигрәк тә гасыр башында яшәгән татар әдипләре иҗатына мөрәҗәгать итә. Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан иҗатларын ул әнә шул күзлектән карап тикшерә, бу проблеманы үзәккә куйган мәкаләләр язып, аларны матбугатта бастыра. Ә инде 1977 елда Татарстан китап нәшриятында Энгель Нигъмәтуллинның «Раздвигая века и границы: к вопросу о связях татарской литературы первой половины XX века с литературой Западной Европы» дигән күләмле генә китабы басылып чыга.

Галимнең шушындый яңа һәм кызыклы юнәлештәге эшчәнлеге республикабыз зыялылары арасында зур яклау таба, 1981 елда аны Татарстан язучылары үз сафларына кабул итәләр. Иҗади берлеккә әгъза булып алынгач, Энгель Нигъмәтуллин хәзерге әдипләр иҗаты турында да байтак кына әдәби тәнкыйть мәкаләләре бастырды һәм язучылар алдында әдәбиятның төрле җитди мәсьәләләренә багышланган чыгышлар ясады. Шул ук вакытта Казан дәүләт университетында укытуын да дәвам итте, яшь буынга әдәбият серләрен өйрәтте.

Яше инде шактый өлкән булса да, Энгель ага хәзер дә актив иҗади тормыш белән яши. Ул күптән түгел Гайша Рорлихның «Идел буе татарлары» дигән хезмәтен, инглизчәдән турыдан-туры татарчага тәрҗемә итеп, «Мирас» журналында бастырды. Шулай ук «Фәнни Татарстан» журналындагы ул әзерләгән «Пушкин турында татарлар» дигән язма да кызыклы иде. «Мирас» журналын алдыручылар аның күренекле әдип Мөсәгыйт Хәбибуллин иҗатына багышланган хезмәтен дә яратып кабул иттеләр.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: татар мәдәнияте күгендә Нигъмәтиләр йолдызы бүген дә якты яна. Егерменче-утызынчы елларда танылган галим һәм педагог булган Галимҗан Нигъмәтинең кызы Йолдыз ханым Нигъмәтуллина да, улы Энгель Нигъмәтуллин да әтиләренең юлын лаеклы дәвам иттерәләр.

2001

«Кайда минем илем?»

«Безнең бу дөнья шуның кадәр дә нык үзгәрдемени соң? Әнә бит — фидакарьлек, батырлык темасына гомере буена түбәнсетеп, көлемсерәп караган язучы Марсель Галиев тә җәлилчеләргә багышлап китап чыгарган...» дигән икеләнүле уйлар белән кулыма алган идем мин бу өр-яңа җыентыкны. Ләкин мәсьәлә катлаулырак булып чыкты. Татарстан китап нәшриятында шушы көннәрдә генә дөнья күргән

«Кайда минем илем?» дигән җыентык ул, асылда, тоткыннар турында икән бит! Гитлер һәм Сталин бергәләп төзегән ике системаның тоткыннары хакында икән бу китап!

Әйе, танылган җәлилче-әдип Рафаэль Мостафинның кереш сүзе булу, эчтә исә Муса Җәлилнең көрәштәшләре Гарәф Фәхретдинов, Рушад Хисаметдинов һәм Фәрит Солтанбәковларның шактый иркен язылган истәлекләре китерелү бу җыентыкны җәлилчеләр батырлыгы турындагы китап дип әйтергә дә мөмкинлек бирә. Ләкин болай дип әйтү ул барыбер мәсьәләнең өске катламы гына сыман тәэсир калдырачак. Аннан соң без бу яссылыкта элек тә байтак кына фикер йөрттек, шактый гына сүзләр сөйләдек бит инде.

Җыентыкның исеме итеп «Кайда минем илем?» дигән үтә үткен сорау куелу да аның төп темасының тоткыннар турында икәнлеген әйтеп тора. Андагы иң уңышлы язма — Мияссәр Хафизов әсәренең баштагы исеме «Ике җәһәннәм» дип куелу да бик мәгънәле! Чыннан да, Гитлер концлагерьлары белән янәшә куеп караганда, Сталин концлагерьлары нәрсә белән аерыла соң?! Юк, алар берсеннән берсе һич тә аерылмый! Икесе дә намуслы һәм гаепсез адәм балалары өчен чын җәһәннәм булган!

Яңадан җәлилчеләр батырлыгына әйләнеп кайтыйк әле.

Аларның батырлыгы татар милләте өчен йөз аклыгы булу турында инде байтак язылды. Һәм бу чыннан да шулай. Җәлилчеләр әгәр киресен эшләгән булсалар, безнең тырнак астыннан кер табарга үтә дә атлыгып торучы күршеләребез — «өлкән туганыбыз» — моңа кадәр дә, бүген дә безнең күзебезне дә ачырмаган булырлар иде. Хәзер Жириновский эшләргә теләгән эшне, бәлки инде, күптән Сталин яисә бүтән бер «бөек юлбашчы» башкарган булыр иде.

Аннары шагыйрь Ренат Харис тарафыннан әйтелгән (ул моны берчакны телдән әңгәмә вакытында белдергән иде) тагын бер фикер кызыклы, җәлилчеләр кебек күмәк төстә эшләнгән бүтән андый батырлыкны белми икән тарих! «Үткән чорларда кайарман шәхесләрнең аерым-аерым эшләгән батырлыклары бик күп — ә менә җәлилчеләр шикелле күмәкләшеп башкарылган батырлык юк!» дигән иде Р.Харис.

Чыннан да, инде язмыш тарафыннан безгә шушы гаять ышанычсыз Рәсәй иле белән бергә яшәргә язган икән (1812 елгы сугышта бергәләп французга каршы көрәшү дә булды бит әле), җәлилчеләр алар — безнең татар халкының нинди икәнлеген раслап торучы визиткабыз булды. Егерменче гасыр өчен исбатлау булды!

Шуңа күрә милләтебезнең рухи көчен белгертү ягыннан «җәлилчеләр батырлыгы» дигән бөек күренеш һичкайчан искермәячәк һәм үзенең рухи-әхлакый әһәмиятен киметмәячәк!

Хәзер инде тоткыннар турында — Гитлер әсирлегеннән кайткач, Сталин әсирлегенә эләккән гаепсез адәм балаларының газаплы авыр язмышы турында уйланыйк.

Әйе, бу китапта, аларның батырлыгыннан бигрәк, әнә шул күргән газаплары күбрәк яктыртыла. Чынлыкта да шулай булган инде ул — нишлисең!

Һәм ике якта да җәһәннәм газаплары кичергән тоткыннар авызыннан бик табигый рәвештә:

— Кайда минем илем? — дигән бер олы сорау килеп чыга.

Бу сорауның мәгънә төбен аңлыйсыздыр, монда инде «минем үз илем түгелмени соң берсе дә...» дигән әрнүле уй ярылып ята.

Әйе, татарның әлегә үз иле юк. Каныбызга, геннарыбызга үтә дә нык сеңгән күңел тарлыгы аркасында күп гасырлар элек без олы-олы дәүләтләребезне җуйганбыз. Хәзер дә «күңел тарлыгы» дигән әнә шул зәхмәт безгә бик зур киртә булып тора.

Әлеге китапка тупланган газаплы хатирәләр әнә шул үз иле булмаган татар егетләренең башыннан кичкән мәхшәрләр дип кабул ителә.

Инде ил мәсьәләсенә килик. Күп гасырлар элек югалган ул илебезне ничек табарга?

Хәзер иң төпкә безнең акыл, саф-таза әхлак, тырышлык җигелергә тиеш! Менә бу хәзерге Рәсәй иле киңлеге безнең сыман зур һәм күпсанлы халык өчен нәкъ кирәк кадәр генә дип әйтерлек. Һәрхәлдә, безгә шушы ил мәйданында эш йөртмичә һич кенә дә мөмкин түгеллеге инде торган саен ныграк аңлашыла бара төсле. Аннан соң, элеккеге бөек дәүләтләребез дә якынча шушы нигездә яшәгән бит әле! Ул яктан алып караганда да, без үзебезнең киләчәк тормышыбызны бүтән төрле нигезгә кора алмыйбыз булып чыга ич әле.

Шуңа күрә бу әрнү тулы китапның буеннан-буена лейтмотив булып сузылып барган «Кайда минем илем?» дигән сорау бүген безне әнә шул илдә милләтебезне тизрәк тергезү максаты белән зуррак эшләргә, олырак һәм файдалырак чараларга тартырга тиеш дип беләм.

Ә әлегә... Ә әлегә безгә байтак еллар буена үз эчебездән генә әнә шул утлы сорауны бик еш кабатларга туры киләчәк... Чөнки ул сорауда безнең үткән чорларда ясалган олы-олы хаталарыбыз авазы ярылып ята. Тарих бездән әнә шул олы хаталар өчен түләтә!

1995

Ырыс егете

Быел көзен без — бер төркем татар язучылары — Удмуртиянең башкаласы Ижау шәһәрендә булып, андагы милли-мәдәни җанланышка сөенеп кайткан идек. Чынлап та, биредә татар иҗтимагый үзәгенең республика һәм шәһәр оешмасы бик яхшы эшли, 10 меңгә якын тираж белән «Яңарыш» газетасы басыла, милли классик гимназия (бусы аерым) һәм күп мәктәпләрдә татар сыйныфлары бар, дәүләт университетында татар бүлеге һәм кафедрасы яшәп килә, зур-зур мәчетләргә халык күп йөри, мәдәният сарайларында онытылмаслык милли кичәләр еш уздырыла... Ижаулылар алга таба да зур максатларга омтылып яшиләр. Мәсәлән, алар Ижауда хәрби заводлар күп булуын һәм бирегә көнчыгыш илләреннән делегацияләр еш килүен, аралашу нык көчәюен искә алып, Ижауның дәүләт университетында Көнчыгыш факультеты ачу идеясе белән дә дәртләнгәннәр. Моңа «бик хуп!» димичә нәрсә дисең инде тагын?!

Әдәби иҗат ягыннан да җанланыш бара Ижау каласында. Биредә яшәүче яшь һәм башлап язучыларның күмәк җыентыклары да, аерым авторларның кызыклы-кызыклы китаплары да дөнья күрә тора.

Әле менә күптән түгел генә китап сөючеләр кулына Ижауда яшәүче шагыйрь, бик тә милләт җанлы шәхес Ринат әфәнде Батталның «Агымсуда — акчарлак» исемле шигырьләр һәм хикәяләр җыентыгы килеп керде.

Кайсыбер китапларда тышлыкка ясалган рәсем белән әсәрләрнең эчтәлеге шулкадәр тәңгәл була: рәсем турында сөйли башласаң, әсәрләр телгә килә, ә шигырьләргә тукталсаң, күз алдында әлеге сурәт тора! Менә биредә дә шундый бәхетле очрак килеп чыккан: тышлыкта — кара-кучкыл шомлы дулкыннар, ә алар өстендә ялгыз акчарлак оча...

Кырларны, урман, күлләрне
Кем уйлаган — су басар?
Төйнәде юлга төенчек
Өч йөз җитмеш биш татар.

Калды бит, суга күмелеп,
Урта болын, Таңатар...
Кайда тилмереп йөрисез,
Өч йөз җитмеш биш татар?

Әйе, Ринат әфәнде — безнең Иж елгасы буендагы Ырыс авылы егете. Җитмешенче елларда Түбән Кама ГЭСы төзелү нәтиҗәсендә аларның авылын да су басты, халык әнә шулай төрле якларга таралышты... Ә күңелләр, китап тышындагы ялгыз акчарлак сыман, су астында ятып калган туып үскән нигезне эзли... Тәү мәртәбә аяк баскан сукмакларны, тәпи йөреп киткән изге туфракны юксына...

Сүз уңаенда шунысын да искәртеп үтәсе килә: Ринат әфәнденең туган авылына бер дә юкка гына Ырыс дип исем кушмаганнар икән ич! Моннан күп еллар элек, төгәлрәге 1300 еллар тирәсендә, Алтын Урда дәүләтендә Ырыс исемле бик тә танылган бәк булган. Чулман һәм Иж сулары буендагы Ырыс авылы, бәлки, нәкъ менә шушы бәк хөрмәтенә аталгандыр?!

Әгәр дә чыннан да шулай икән, мондый авылларның Мәскәү сәясәте аркасында юкка чыгарылуы — су астында калдырылуы — бигрәк тә фаҗигаи төс, мәгънә ала! Һәм әле тагын йөзләгән татар авылларын юкка чыгарырга кыҗрап йөриләр! Фаҗигане тагын да көчәйтмәкчеләр!

Ләкин Ринат Баттал әлеге шигырен оптимистик аһәңдә тәмамлый:

Табышыйк, дуслар, киңәшик —
Кемнәр юкса баш ватар?
Илне дә саклыйк, динне дә,
Мең татар, миллион татар!!!

Бу китапның авторы Ринат Баттал өчен дә, минем өчен дә күрше авыл булган — удмурт авылы Гөлширмә бар иде. Шулай ук ямьле Иж тугаенда урнашкан иде ул, соңрак безнең авыллар сыман ук Гөлширмә дә фаҗигале язмышка дучар булды — күчерелде, юкка чыкты.

Менә шул Гөлширмә, әллә инде базарлы, зур авыл булганга, әллә инде якшәмбе саен базар җыелганга күрә, әллә анда бүтән төрле милләт кешеләре яшәгәнлектән — ни өчендер бер романтик җир сыман тоела иде: безне — «сәпид»ле малайларны — гел дә үзенә тартып тора иде... Ә өлкәннәр әнә үзләренчә аралашкан икән. Ринат Баттал аны болай яза:

— Печән бетте, Хасан,— дип елмаеп,
Егор ага килә аръяктан.
Икесе дә сугыш ветераны —
Икесе дә сыңар аяктан.

Куеныннан мөгез бокал алып,
Чиста спирт сала туп-тулы.
Печән төйи атка ике Батыр,
Онытыла аяк юклыгы.

Әйе, Ринат Батталда тормышны лирик һәм лиро-эпик яссылыкта күрү көчле. Китапта урын алган хикәяләрдә дә әлеге сыйфат ачык чагыла. Бигрәк тә «Шәфкатьле җан иясе» дигән әсәр сурәтләнгән вакыйгаларның драматизмы белән аерылып тора, ул чәчмә рәвештә язылган поэма кебек кабул ителә.

Ә кем белә: бәлки әле, безнең Ринат Батталыбыз якын арада поэмалар да яза башлар? Вакыйгалы, сюжетлы поэмаларга хәзерге укучы күңелендә зур ихтыяҗ яши ич. Тормыш авырлыгын күргән егетләр, кызлар язмыйча кем язсын аны!

Бу китапны укып чыгу Ижаудагы якташларым өчен тагын бер мәртәбә куандырды. Уңыш арты уңыш килсен аларга!

1998

Горур кораб кебек

Кешеләр төрле... Аларның язмышлары да бер-берсенә охшамаган.

Берәүләргә язмыш гомер буе иркәләп, шәфкать белән карый — тормышларын да һәммә яктан җитеш, түгәрәк итә. Андыйлар турында «майда гына йөзә инде» дип сөйлиләр...

Ә икенче берәүләрне язмыш алай иркәләми. Аларга ул үзенең сынауларын бер-бер артлы яудырып кына тора. Каршылыкларның да торган саен зурракларын, җитдирәкләрен китереп куя.

Рәнифнең дә язмышы әнә шундый булды. Тоташтан диярлек сынаулар, гел каршылыклар аша бара торган сикәлтәле юл булды аның гомер юлы... Кукмара районының Аман-Оштарма авылында туган егет бәләкәйдән үк ятим кала.

«Ятим бала моңлы була»,— дигән халык. Ә халык хак әйтә. Рәнифнең язмышы бу хакыйкатькә мисал була ала.

Әнисе аңа үләр алдыннан: «Улым, курыкма, хөкүмәт ташламас сине»,— ди... Еллар үтә, Арча районының Субаш Аты авылында урта мәктәпне тәмамлау, балалар йорты белән саубуллашу көннәре дә җитә...

Ил саклау өчен менә дигән солдат булып өлгереп җиткән тәвәккәл егетне хәрби хезмәткә алалар.

Хәрби кораб хезмәте үзе җиңел түгел иде. Рәниф өстенә йөкләнгән вазифа бигрәк тә. Чөнки ул бит — корабның сигнал отделениесе командиры. Аңа тәүлекнең бик күп өлешен күперчектә, төрле яктан өскә су бәреп торучы салкын дулкыннар арасында булырга туры килә.

Ләкин тормыш авырлыкларына баш имәскә күнеккән егет табигать кырыслыгы алдында да үзен егетләрчә тотты, сер бирмәде. Үзенә ничек кенә авырга килсә дә, корабны ышанычлы элемтә белән тәэмин итте.

Ләкин Рәнифне тагын бер усал сынау сагалап торган икән. Сынауның чыннан да усалы, мәкерлесе, көчлесе. Кешене, хәтта япь-яшь егетне аяктан ега торганы.

Рәнифнең аяк буыннары бик каты авырта һәм акрынлап бөгелми үк башлады. Куркыныч авыру аңа акрын-акрын, әмма үзенең куркыныч чынбарлыгы белән ачыктан-ачык аңлашылып якынлашты.

Уйламаганда үз юлына килеп чыккан бу яңа дошманга бирешмәү өчен, Рәниф бөтен көчен куйды: физик күнегүләрнең ниндиләре белән генә шөгыльләнмәде, врачларның да бик күптөрлесенә күренде, дәва чараларының да кайсысын гына кабул итмәде!

Гомер юлының башында — яшьлек корабы гел алга гына ашкынып яшәгәндә — кеше башына килеп төшкән бу бәла зур иде. Барысын да уйлап китсәң, ул куркытып, шөлләтеп тә калдыра иде...

Ул чакны, ул елларны Рәнифкә нәрсә көч биргән соң? Аның рухын сындырмый тоткан көч нинди булган?

Апасы Люция һәрчак Рәниф янәшәсендә торды, аның беренче ярдәмчесе, киңәшчесе дә булды. Аңа рәхмәт. Шулай ук ярдәмчел күршеләре, күпсанлы дуслары бар иде. Алар күңелгә сынарга ирек бирмәде.

Ләкин барыбер иң башта Рәниф үзе егет булып кала алды. Тешен кысып булса да түзде. Теге чакны салкын Баренц дулкыннарына чыдаган кебек чыдады, сыкранмады, зарланмады.

Әнә шул вакытта Рәнифнең күңел төшерми, яшәү дәртен сүндермәү тотучы көчләрнең берсе әдәбият булды. Рәниф кечкенәдән бик күп укыды, китаплардан беркайчан да аерылмады. Болар барысы да аңа җиңелеп калмаска ярдәм итәргә генә түгел, ә үз күңелендә туган уй-фикерләрне дөньяга чыгара башларга да ярдәм итте. Рәниф үзе дә күңел хисләрен кәгазьгә төшерә башлады.

Хәер, шигърият аның күңелендә балачактан ук яши иде. Беренче класска кергәнче үк, басма хәрефләр белән язган сигез юллык шигырен әнисенә кычкырып укыганын әле дә хәтерли Рәниф. Балалар

йортында язган кайбер шигырьләрен Казандагы кайсыдыр редакциягә дә җибәргәне бар. Шулай итеп, җитмешенче елларда Рәнифнең корабы икенче бер көчле дәрьяга— шигърият диңгезенә кереп китте.

Беренче көн бүген без диңгездә,
Бу мәхшәргә ничек түзәргә?
Әллә диңгез суы, әллә маңгай тире
Әчеттереп керә күзләргә.
Баштанаяк каплап китә дулкын,
Тозлы сулар тама иреннән,
Диңгез суын ясаганнар кебек
Күз яшеннән, маңгай тиреннән.

Әйе, бу диңгез дә элек Рәниф йөзгән Баренц диңгезеннән ким түгел, хәтта аннан да тынгысызрактыр әле ул, чагыштырып карасаң. Бөек Тукайлар, Такташлар, Туфаннар шаулаган диңгез бит ул!

...Рәниф белән мин «Идел»дә эшләгән елларда таныштым. Шулай беркөнне яшьләр өчен һәм яшьләр көче белән чыгарыла торган бу әдәби альманах турында без Татарстан радиосы аша махсус тапшыру оештырдык. Тапшыру ахырында яшь язучыларга активрак язышыгыз дип мөрәҗәгать тә иттек. Һәм беркадәр вакыттан соң безгә хатлар да килә башлады.

«Идел» альманахы редакциясенә килгән әнә шул хатларның берсе Казан шәһәрендә яшәүче яшь шагыйрь Рәниф Шәриповтан иде. Шуннан соң мин Рәнифләрнең фатирларында булдым. Рәнифнең үзе белән, аның апасы һәм җизнәсе белән якыннан таныштым.

Ике бүлмәле фатирның иң якты бүлмәсе — Рәнифнеке. Тагын шунысы гажәп: ул бүлмә үз хуҗасының нинди генә мавыгулары, күңел омтылышлары хакында сөйләми! Анда Рәниф үз кулы белән җыйган радиоалгыч та, тавыш көчәйткечләре дә бар. Анда дөньяның әллә ничә телендә басылып чыккан китаплар, альбомнар!

Яшь шагыйрьнең беренче адымнарын искә төшерү белән, шунда ук Сибгат ага Хәким күз алдына килеп баса. Һәрбер яңа иҗатчыга гаять зур игътибар белән карый торган Сибгат ага бу егетнең язмышын һәм иҗатын аеруча якын кабул итте. Миңа ул Рәниф турында бик күп сораулар бирде. Ә көннәрдән бер көнне Сибгат ага, үзе белән Илдар Юзеевны, Ризван Хәмидне һәм мине дә алып, Рәнифнең үзе янына, аның өенә дә килде. Бу көнне без ихлас күңелдән бик озак сөйләшеп утырдык.

Рәнифкә бик файдалы киңәшләр биргән Илдар Юзеев аннан соң да яшь шагыйрьгә һәр яклап ярдәм итте. Мәсәлән, Рәнифнең беренче китабы аның хәер-фатихасы белән укучыларга юл алды.

Рәнифнең әсәрләре, иң беренче чиратта, кешеләргә әйтәсе килгән мөһим сүзнең булуы, шигъри эчтәлекнең тирәнлеге белән үзләренә җәлеп итәләр. Моның сере, билгеле, бер дә ерак ятмый. Чөнки Рәнифнең үзенең четерекле вакыйгаларга гаять бай булган язмышы бар. Әнә шуңа күрә Рәниф Шәрипов иҗаты соңгы елларда безнең яшьләр поэзиясенә үзенчәлекле яңа агым сыман килеп керде.

Р.Шәриповның 1983 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан бастырып чыгарылган «Тәрәзәмдә ут» исемле китабы укучылар арасында да, әдәби җәмәгатьчелектә дә зур кызыксыну тудырды, җыентык турында матбугат битләрендә хупланган рецензияләр басылды.

Ләкин ярсу кораб сыман алга ашкынып яшәгән йөрәк урын өстендә яту, гел бер бүлмәдә булу белән генә канәгатьләнеп кала аламыни соң ул?! Рәниф озак уйлаганнан соң, үз авыруы хакында күп китаплар укыгач һәм байтак белгечләр белән киңәшкәч, аякларына бик тә авыр операция ясатырга риза булды.

1982 елда ясалган бу авыр һәм озакка сузылган операция алдыннан да, операция булып үтү белән дә мин Рәниф янында — М.Горький урамындагы больницада — еш булдым. Аның авыртудан аңын югалткалаган чаклары да булды. Ләкин мин беркайчан да Рәнифнең күз яшен, сыкрануын күрмәдем. Ул үзенә иң авыр чагында да елмаерга тырышты, кеше белән ипле итеп сөйләште, үз эчендәге газапларны тышка чыгармады...

Рәниф әлеге гаять авыр операцияне уңышлы кичерде. Шуннан соң күпмедер гомер үткәч, ике култык таягына таянып, азлап-азлап кына акрын-акрын гына йөри дә башлады.

Соңгы берничә елда Рәниф Шәрипов үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен матур-матур сценарийлар да иҗат итте. Халык авыз иҗатын да, шагыйрьнең үзенең шигъри җимешләрен дә оста файдаланып язылганнар алар. Биредә, мөгаен, Рәнифнең туган ягы сабантуйларына кайтып йөри башлавы да бик зур роль уйный торгандыр. Җәйге ямьле вакытлар җитү белән, ул — авыл табигате кочагында аунап үскән малай — туган як болыннарына ашкына.

Рәниф Шәрипов турында сүз алып барганда, менә нәрсә турында да әйтми үтү мөмкин түгел. Ул, нигездә, үз бүлмәсендә генә яши торган кеше, шәһәрдәге, халыктагы һәм илдәге яңалыклардан һәрчак хәбәрдар була. Нинди генә яңалык белән гажәпләндерим диеп сүз башласаң да, Рәниф инде ул турыда белә, ишеткән һәм ул вакыйга хакында инде аның үз уе, фикере, хөкеме бар. Бу, күрәсең, Рәнифнең дуслары, аралаша торган танышлары күпкәдер. Чыннан да, кайчан гына барма — аның янында һәрчак кеше була, күңелле генә әңгәмә бара. Тагын шунысы кызык: байтак кына кеше Рәнифтән киңәш, ярдәм сорап та килә.

Без, Казанда яшәүче яшь язучылар, үзебезнең чираттагы киңәшмәбезне башлап җибәрер алдыннан кемнәрнең килүен, кайсыларыбызның кайларда командировкаларда икәнен барлап алабыз. Әнә шундый вакытлар Рәниф Шәрипов исеме чыгуга, аның яшь каләмдәшләре бер дә шаяруга охшамаган тавыш белән:

— Ул алгы сызыкта! — диләр. Фронтовиклар телендәге әнә шул «алгы сызык» сүзе белән алар Рәниф Шәриповның бүгенге урынын бик тә дөрес билгелиләр.

Чыннан да, зур дөнья һәм олы көрәшләр эчендә, үз замандашлары белән бергә алгы сафта атлый бүген Рәниф.

...Ә кораб һаман алга бара. Давылларга исе китми аның! Аларга бирешми, баш бирми ул! Чөнки халкыбызның бер бик матур җыры белән әйткәндә:

Без давылдан курыкмыйбыз,
Үзебез давылдай булгач!

2000

Соклану

Җәйге авыл күренешләре... Авыл табигате... Барыбызның да йөрәк түрендәге хатирәләр... Гомергә онытылмастай кадерле хатирәләр...

Ни өчен әнә шундый бер дә җуелмастай истәлек булып хәтергә уела алар? Ни өчен без гомер буена аларны оныта алмыйбыз?

Юк, биредә җавап бик гади генә түгелдер! Аерым кешегә хас булган хис-кичерешләр генә, һәркемнең үз яшьлеген сагынуы гына түгелдер бу! Биредә сер, мөгаен, тирәндәрәк ятадыр...

Авыл һәм аның табигате кеше өчен бердәнбер дөрес яшәү җирлеге булганга күрә әнә шулайдыр бу, мөгаен. Кешенең иң түгәрәк, иң камил бәхете бары тик табигать эчендә, табигать белән бергә генә була алганга күрә шулайдыр бу! Әнә шуңа күрә бер дә безнең хәтеребездән, исебездән чыкмыйдыр ул табигать һәм авыл тормышы!

Тик менә шунысы бар: бүгенге шау-шулы олы шәһәрләрдә яшәүче күпләгән замандашларыбыз андый бәхеткә ничек, нинди юл белән ирешә ала соң?

Шагыйрь Зәет Мәҗитов бүгенге яшәештә андый бәхеткә бару юлы итеп безгә «Чыклы сукмак» тәкъдим итә.

Әй, туган җир, әй, син,
газиз туфрак!
Нинди шифаң,
нинди даруың
Бер мизгелдә җуя
сагышларны,
Сырхауларны,
тәннәр аруын?!

Әйе, «Чыклы сукмак» — ул әле яңа гына безнең китап киштәләребезгә килеп урнашкан яңа китап. Шагыйрь Зәет Мәҗитовның 40 еллык иҗат чорында язылган иң яхшы шигырьләрен һәм поэмаларын бергә туплаган матур җыентык.

Бу китапка кергән шигъри әсәрләр бүгенге укучыга бик тә тансык булган очрашулар, вакыйгалар, кичерешләр бүләк итә. Аларда безнең туган җиребезнең сихри көче, тиңсез гүзәллеге... Шагыйрь Зәет Мәҗитов бик дөрес чагылдырганча, хәтта шәһәр җирендә яшәп ятканда да, бүгенге кеше табигатьне, җирне, туган ягын сагына икән:

Үзе — шәһәр.
Авылдагы сыман.
Этләр өрә никтер бу төндә.
Этләр булып минем сагыш мәллә
Йокы тапмый шәһәр читендә?!

Бер шигырьне башлап киткән биш юлда, күрәсезме, күпме эчтәлек, күпме кичереш, күпме уй! Нәкъ менә безнең замандашыбыз күңелендәге кебек... Безнең күпләребез дә бит бүген ике арада, авыл белән шәһәр арасында, шагыйрь әйткәнчә, «шәһәр читендә»...

Барыбызның да уртак уй-хисләрен чагылдырган әлеге шигырь менә мондый юллар белән төгәлләнә:

Сәер дә соң адәми зат күңеле:
Барын сизә, тоя, хис итә.
Зур замана шаулап барган мәлдә
Эт өрүдән ник моң ишетә?

Шулай итеп шагыйрь үз күңелендәге кичерешне укучы йөрәгенә оста күчерә. Мондый шигъри әсәрләр укыганнан соң инде, без «шәһәрләрдә эт өрүдән ник моң ишетелгәнен» бик яхшы аңлый башлыйбыз...

Шагыйрьнең «Чыклы сукмагы» өчен бик тә характерлы булган әсәр бу. Зәет Мәҗитовның бүтән шигырьләре дә әнә шундый матур сукмаклар буйлап безне зур уйлар, зур кичерешләр юлына алып чыга. «Календарьның гади бер бите», «Туган авыл», «Сискәнү» исемле шигырьләр һәм «Һәйкәл янында», «Кайту» дигән тирән мәгънәле поэмалар һәммәсе дә кешелек тормышының олы юлы хакында сөйли.

Бу китапка кадәр дә безнең укучыга дистәләп җыентык бүләк иткән Зәет Мәҗитовның ягымлы лирик поэзиясе халыкка билгеле иде инде, әлбәттә. Замандаш күңелендә ул үзенең урынын алган иде инде. Әмма яңа китап бүген алтмыш яшен тутыра торган шагыйрьнең иҗатын тагын да калку итеп күрсәтә, иҗади үзенчәлекләрен бигрәк тә төгәл билгели.

Ә шагыйрьнең үз тормышы белән якыннанрак танышсак, бу иҗади уңышларның бер дә җиңел генә килмәгәнен яхшы аңлыйсың... Актаныш районының Иске Айман авылында туган шагыйрьнең әтисе 1943 елда Сталинград фронтында һәлак була... Ләкин моңа карап яшүсмер Зәет төшенкелеккә бирелми: ул башта урта мәктәпне, аннан соң Казан дәүләт университетын уңышлы тәмамлый. Аннары «Фатих Кәрим поэзиясе» дигән темага диссертация яклый... Фәннәр кандидаты була. 1953 елда исә яшь шагыйрьнең «Таңгы җыр» исеме белән беренче китабы да басылып чыга. Ул ышанычлы адымнар белән поэзия дөньясына кереп китә. Хәзер инде аның дистәдән артык китабы бар.

Зәет Мәҗитовның поэтик иҗаты Ватанга, туган җиргә мәхәббәт хисләрен чагылдырган әсәрләре белән кыйммәт. Аларда олы-олы фикерләр гаять җылы һәм кешелекле хис аша укучы йөрәгенә төгәл илтеп җиткерелә. Әсәрләрдә бик тә гади, эчкерсез, риясыз кеше күңеле яши. Әнә шуның аркасында укучы белән автор арасында үзара ышаныч туа, бернинди киртә, каршылык калмый. Әлеге яңа китапның бер бүлеген тәмамлап килгән «Яшәү яме» шигыре моны тагын бер мәртәбә раслый:

Шулдыр бу, шул — башланудыр
Тагын язның бәйрәме!
Шушыдыр, язны тоюдыр,
Яшәүнең олы яме!

...Әнә шулай һәр якты көнгә ихлас күңелдән сокланып яши шагыйрь! Әнә шулай итеп аның керсез күңеленнән дәртле һәм моңлы шигырьләр агыла. Ул әсәрләр бик күп укучылар өчен гүзәллек дөньясына илтүче сукмак булып торалар.

1987

Тукайга тугрылык

Сөекле шагыйребезнең олы юбилее якынлашкан саен, без аның исемен ешрак телгә алабыз. Ләкин бүген бу кадерле исемне әйткәндә, Тукайның гаять тирән мәгънәле тормышын, дөнья караңгылыгы белән кискен рәвештә бәрелешкән тетрәндергеч язмышын исебездә тотабызмы? Без, бүгенге рәхәт тормышта яшәп, әлеге исемне еш кабатлаучылар, Тукай язмышының, Тукай шәхесенең иң асыл, иң төп сыйфатларын онытмадыкмы, аларны хәтердән чыгармадыкмы? Без бүген Тукай юлына, Тукай рухына тугрымы?

Танылган шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның әле күптән түгел генә «Казан утлары» журналында басылып чыккан (2 нче сан) «Тукайдан хатлар» исемле яңа поэмасы да үзенең эчтәлеге һәм кузгаткан уйхисләре белән чорларны, елларны, кешеләрне бергә тоташтыра.

Поэма өчен реаль җирлек булып бөек шагыйрьнең төрле елларда төрле кешеләргә язган хатлары хезмәт итә. Унбер хаттан алынган унбер өзек поэма бүлекләренә рухи кереш ролен үти...

«Тукайдан хатлар» поэмасы белән танышканнан соң, күңелдә туган иң беренче фикер шундый: әсәр бөек шагыйрь образын аңлауда, күзаллауда алга таба зур бер адым булып тора. Чөнки бу әсәрдә Тукай образы бер үк вакытта үз чорының конкрет җирлегендә һәм күп чорлар, күп гасырлар өчен хас булган, искерми торган мөнәсәбәт-конфликтлар эчендә дә карала. Әсәрдә реаль Тукай образы белән лирик герой образы (ул да шагыйрь кеше) бергә кушылып китү әнә шундый киң масштаблылык, монументальлек хасил итә. Поэманың төп уңышы — халык шагыйренең идеалга якын җанлы образын тудыруда.

Тагын шунысы да игътибарга лаек: күп гасырларга халык шагыйре булып калырдай андый образның нигезе өчен Тукайның үз сүзләре җирлек — «Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы».

Менә бу юлларда халыкның чын шагыйре булып туган моңлы җанның бар булган бәхете дә һәм бүгенге көннән генә канәгать кала алмыйча гел алга, гел яңа матурлыкка ашкынган, шуңа күрә үзен җиһанга ят итеп тойган трагик җан да!

Әсәр Тукай гомереннән, аның ялкынлы хатларыннан кузгалып китә дә, сәнгатьлелекнең бөек көче ярдәмендә халкыбызның Тукайга хәтле булган уллары язмышын да, аннан соң яшәгән моңлы җаннар тормышын да бергә колачлый һәм шуның аркасында үзәктә торган Тукай образының эчтәлеге байый, аның мәгънәсе тирәнәя.

Тукай ераклашкан заманда
Азмыни ул
көлеп йөрүчеләр
Тик шүрәле кытыклаганга.

Күргәнегезчә, поэмада «Тукайдан ераклашу» дигән төшенчә ул һич тә вакыт узуны, күп еллар үтүне генә белгертми. Бу сүз чын, олы шагыйрьлекнең үзәк юлыннан читләшү, шуннан ераклашу дигән сүз.

Әсәрнең тагын бер зур уңышы шунда: ул бөек шагыйрьнең бөек батырлыгын үз халкының авыр һәм катлаулы көрәше процессында ача. Бу — самодержавиегә каршы көрәш, социаль гаделлек, чын ирек, рухи яңарыш өчен көрәш.

Автор халык тормышын киң планда тасвирлый, социаль күренеш һәм тенденцияләрне бар катлаулылыгында аңлый:

Исереге дә шул, аегы да,
Казаны да шул ук.
Җаегы да.
Баер өчен җанын
фида кылыр,
Җае гына чыксын.
Җае гына...

Поэманың «Учак сүнеп, тимер калачак» һәм «Җирдә апрель» дип исемләнгән бүлекләре халыкның революцион көрәшен югары шигърилек дулкынында сурәтләү белән аерылып торалар. Аларда бер яктан: «Ничә гасыр буе агып килгән Чүп тыгылган. Азмы шакшылар?!» — булса, икенче яктан: «Син агымны туктатырмын димә. Актарылып чыкса, бер бәреп!» — дигән юллар.

Шагыйрь Тукай әнә шул көрәш, әнә шул ташкын эчендә, шулар уртасында булуы белән бөек һәм көчле!

Чын шигъриятне, шигърияттәге чын олылыкны аңларга теләгән яшь ижатчыларга менә ул иң ышанычлы җавап кайда: Шагыйрь олы көрәш эчендә генә олы шәхес булып өлгерә, җитлегә ала! Тукайның апрельдә — бөек уяну вакытында башланып, апрельдә өзелгән гомере дә тоташы белән язгы ташкын ул! Тормышны, дөньяны чистартучы, яңартучы, уятучы, сугаручы куәтле язгы ташкын ул Тукай үзе һәм Тукай рухы! Поэма герое да нәкъ әнә шундый. Юк, бу поэма шагыйрь хатлары турында гына түгел. Поэма — шагыйрьнең бүгенгә адресланган рухы, йөрәге, күңеле һәм аны бүгенге көнгә кадәр китереп җиткерергә тырышу.

Шагыйрь М.Әгъләмов үз алдына куйган ижади максатына ирешкән. Әсәрне укыганда, чыннан да, безнең күңелләрне Тукай рухы биләп ала, без бөек шагыйрь дөньясында яшибез. Ул шагыйрь образы аша чорлар, еллар дәвамында кыйммәтен, әһәмиятен югалтмаячак хисләр, уй-кичерешләр уята.

1986

Каләм — гомер озайта!

Халкыбызның гаять күпкырлы һәм бай тормышын матбугатта чагылдырып бару өчен, байтак каләм ияләре көч куя. Ул каләм ияләренең һәммәсенең исемнәрен дә хәтердә калдыру мөмкин түгел, әмма әнә шулай — барыбыз бергә, уртак тырышлык белән дигәндәй — ижат аша без чорыбыз елъязмасын теркәп бару өчен тырышабыз, гасырларда сакланырдай уртак келәм тукыйбыз...

Журналист һәм язучы Харис Закиров исеме алтмышынчы елларда Әгерҗе районы газетасында күренә башлады. Бу районда чыга торган «Җиңү юлы» газетасын укучылар аның авыл тормышы турындагы, кызыклы язмышка ия шәхесләр хакындагы матур-матур язмалары белән еш очраша иделәр.

Соңгы елларда инде ул бөтен республика күләмендәге танылган каләм иясенә әверелде. Хәзер без аның кызыклы язмаларын «Ватаным Татарстан» һәм «Шәһри Казан» битләрендә дә, «Мәгърифәт» сәхифәләрендә дә еш очратабыз. Бүгенге көндә ул «Мәгърифәт» газетасында бүлек мөхәррире булып эшли, укытучыларның, мәгариф хезмәткәрләренең эшчәнлеген киң яктырта. Озак елларга сузылган тынгысыз журналистлык эшчәнлеге өчен Харис Закировка 1998 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем дә бирелде.

Харис Закиров язган очерк һәм мәкаләләрне барысын бергә тупласаң, калын-калын томнар хасил булыр иде, аларда егерменче гасырның икенче яртысында яшәгән татар кешесенең ифрат бай һәм кызыклы тормышы күренер иде.

Ләкин безнең бу авторыбыз соңгы елларда әдәбият кишәрлекләрен дә уңышлы гына үзләштерә башлады бит әле! «Харис әфәндене моңа нәрсә этәрде микән?» — дип уйлап куям. Бусы аның тагын да авыррак өлкә, монда тагын да күбрәк көч һәм фидакарьлек сорала ич!

Шактый гына уйлангач, аның әдәбият юлына аяк басу сәбәпләре миңа аңлашыла башлый сыман.

Якташым Харис Закиров белән икебез дә белгән уртак дусларыбыз — бик сәләтле, бик моңлы егетләр бар иде безнең... Иңне-иңгә куеп бергә яшәгән һәм эшләгән, күп серләрне һәм кайгы-шатлыкларны уртаклашкан егетләр иде алар... Менә хәзер инде аларның кайберләре бу дөньяда юк...

Менә шул чагында мин кешелек дөньясының «әдәбият» дигән тылсымлы мохитне уйлап чыгаруына чиксез рәхмәтләр укыйм. Кешеләргә икенче яшәү бирә, адәм баласына икенче гомер бүләк итә икән ич ул әдәбият!

Харис Закиров үзенең «Гармунчы гозере» исемле зур булмаган хикәясен матбугатта бастыргач, без анда бу дөньядан бик тә иртә китеп барган якты күңелле шәхес, талантлы композитор һәм шагыйрь Әнвәр ага Закировның сөйкемле образы белән очрашкан идек. Казандагы зыялылар да, Әгерҗе төбәге халкы да яхшы белгән бу фидакарь җанга әдәбиятта матур һәйкәл кую иде бу әсәр!

Икенче бер дустыбызны мин бер новелламда чагылдырырга тырышкан идем. «Икенче каттагы бүлмә» дип атала иде ул әсәр. Үзе баянчы, үзе җырчы булган Ринат Булатовны сагынудан, бик тә юксынудан туган иде ул әсәр!

Әйе, әдәби геройлар бер дә әллә каян, ниндидер серле биеклектән килеп төшмиләр. Алар безнең арада яши, янәшәбездә генә көн күреп яталар... Әмма күңел күзеңне ачыбрак, игътибар беләнрәк карасаң, аларның — булачак әдәби геройларның — тормышта ихласрак һәм гаделрәк, газаплырак һәм сафрак, башкалардан нык кына аерылып торган гомер юлы узуларын күрәсең. Әнә шуңа күрә, мөгаен, аларның гомере янәшәдәгеләрнең исендә ныграк кала. Шуңа күрә аларның якты образлары әдәбият-сәнгать әсәрләренең үзәгенә килеп керә.

Әле генә телгә алынган «Гармунчы гозере» хикәясендәге җыр да үзенчәлекле һәм кабатланмас моңы белән күңелемдә еш яңгырый. Сүз уңаеннан шуны әйтеп узу кирәктер: бу матур хикәяне язган Харис Закиров үзе дә әлеге җырны күңелләрне тетрәндererлек итеп башкара. Аны хәтта сәхнәләрдән дә җырлый!

Әйе, журналистикада заман елъязмасын язып барса, әдәби әсәрләр иҗат итеп Харис әфәнде тормышыбыздагы тирән мәгънәле күренешләрне, кызыклы һәм гыйбрәтле язмышлы кешеләрне сизгер һәм үткен күңел күзе белән күрә белә. Аның «Чәч бөртеге» дип аталган хикәясе шул хакта сөйли. Бу әсәрен ул ни өчендер «хикәя» дип кенә бастырды, ә бит бу әйбер вакыйгаларның эзлекле дәвамлылыгы һәм геройлар язмышының яктыртылу тулылыгы, тирәнлеге ягыннан повесть янәшәсендә торырлык!

Иҗатчы дустыбыз соңгы елларда аеруча матур уңышлар яулый.

Ул 2000 елда «Керпе мыегы» исемле матур гына китап бастырып чыгарды. Әлеге китап шул елның иң күп укыла торган җыентыклар конкурсында алдынгы урынны алды һәм республика Милли китапханәсе белән Татарстан Язучылар берлегенең Дипломына да лаек булды. Шушы факт үзе генә дә күп нәрсә хакында сөйли.

Күптән түгел миңа Харис әфәнденең ике яңа әсәрен укып чыгарга туры килде. Аның берсе «Әрәмәдә карама» дип, ә икенчесе «Ләхет» дип исемләнгән. Әлеге әсәрләрнең исемнәре үк бик тә җитди нәрсәләр хакында сөйләвен безнең укучы сизенәдер, билгеле. Әйе, аларда автор бүгенге көн, гомумән, яшәү өчен хәлиткеч проблемаларны үзәккә куя. Алар — гаилә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре һәм шәхеснең, кешеләрнең тере килеш «ләхет»кә керергә — изелергә, сытылырга мәҗбүр булулары. Бу әсәрләрнең кайсы газета-журналда басылачагын мин әлегә әйтә алмыйм, әмма шунысы ачык: аларны укыгач, кеше тирән уйга талачак, күңелен баетачак.

Харис Закиров язган әсәрләрне укыганда, аның күңел офыкларының киңлеге күзгә чалына. Ул бүгенге тормыштагы драматик ситуацияләрне дә, трагик коллизияләрне дә уңышлы колачлый, шул ук вакытта игътибарыннан янәшәбездәге кызыклы күренешләр дә читтә калмый. Югарыда без телгә алып үткән «Керпе мыегы» исемле җыентыкта байтак кына юмористик хикәяләр урын алган икән, алар менә нәкъ шул хакта сөйләп тора!

Татар баласына тырышлык хас! Моның дөреслеген Харис Закиров тормышы раслый кебек. Ул ерак Әгерҗе төбәгендәге Иске Аккуҗа авылында туа, аннары атаклы Иж-Бубый мәктәбендә урта белем ала,

шуннан соң хәзер Лаешта урнашкан Казан авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый, Әгерҗе ягы колхозларында экономист булып эшли. Байтак еллар район газетасы хезмәткәре, аннары партия райкомы инструкторы, Казан дәүләт университеты студенты, аннары тагын журналистика: «Социалистик Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Мәдәни җомга» газеталарында рус һәм инглиз телләрендә басылучы «Деловой Татарстан» журналында эшләү...

Әйе, сафларыбызда тынгысыз җанлы, зур максатлар белән яшәүче каләмдәшебез бар. Шушы мәкаләмә нокта куйганда гына аның тагын бер хикәясе дөнья күрүе билгеле булды. Анысы «Идел» журналының 10 октябрь санында басылган. «Мунча һәм Твикс» исемле бу хикәясендә дә автор бүгенге көндәге бик тә актуаль мәсьәләне читләтеп үтмәгән, кечкенә генә малай образы аша Чечнядагы сугышка карата мөнәсәбәтен белдергән.

Аңа тормышында һәм иҗатында яңа уңышлар телик!

2002

Күрик әле әйбәт басмаларны!

Барыбыз да күреп-белеп тора: бүгенге әдәбиятыбызның хәле кызыклы да, кызганыч та. Чөнки, бер яктан, хәзер әдәбиятта сурәтләнгән тормыш бик тә киңәйде, төрлеләнде. Безнең татар укучысы да хәзер, бүтән ирекле ил кешеләре кебек, үз күңеле теләгән, төрле темаларга язылган әдәби әсәрләрне табып укый ала. Әмма, икенче яктан, хәзер эчтәлек бик тә саекты, сыйфат ягы үтә аксый башлады... Монысын демократия чоры билгесе дип санаучылар да бар. Кайчак алар белән дә килешергә туры килә, чөнки соңгы елларда күренгән бер төр авторлар тел матурлыгы һәм сурәтләү чаралары ягыннан әллә ни мактана алмасалар да, үз әсәрләре белән әдәбиятка кызыклы гына геройлар алып килде, яңа актуаль проблемалар күтәрде. Аларның үз укучылары булуы билгеле, яклаучылары да күренеп тора.

Әлбәттә, төрле зәвыктагы укучының үзе теләгән китапны укырга, һичшиксез, хакы бар. Без аңа андый мөмкинлекне, шундый шартны тудырырга, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Ләкин әйбәтлеге беркемдә дә шик-шөбһә тудырмаган китаплар да басыла тора бит әле, егетләр!

Менә күптән түгел генә кулыма шундый китапларның берсе килеп керде. Исеме генә дә ни тора — «Ак вә кара»!

Без мәңгегә, без мәңгегә монда!
Эх, бу җирне күпме таптады
Безнең йөрәк бәйрәмнәренең
Кыңгыраулар таккан атлары.

Гаять тә зур талантка ия булып та, мактаулы исемнәр һәм дан-дәрәҗә артыннан чапмаган, бик иртә үлеп киткән олы шагыйребез Рәшит Әхмәтҗанның «Бәйрәм» исемле шигыреннән бу.

Шигырьдәге рухи көч, эчке азатлык, эчке горурлык ташкынына игътибар итегез. Әсәрнең иң тәүге, иң беренче юлына ук кайнар вулкан сыман, ялкын шикелле бәреп чыга ул көчле пафос, ул титаник хискичереш! Ә инде татар күңеле турында ничек төгәл һәм матур итеп әйтелгән: «Безнең йөрәк бәйрәмнәренең...» Бер яктан, монда коллык хәлендәге халыкның бәйрәме күздә тотыла, эчтән генә, тышка чыгармыйча, чит-ятка белдермичә генә уздырыла торган бәйрәм... Ә инде икенче мәгънәсе: бу — чын бәйрәм, бөтен җаның-тәнең, бөтен йөрәгең белән тантана итеп, ихластан шатланып, горурланып үткәрелә торган бәйрәм! Көчле талант иясенең бер әсәрендә әнә шундый мәгънә катламнары — һәр икесе дә дөрес һәм гадел булган фикерләр — бергә үрелеп, бер шигъри тән, бер җан булып яши.

Мондый шигърият үрнәкләре безнең татар халкының күңел түренә шундук үтә. Андый чын әсәрләр язмыш юлларын аның белән бергә уза.

Талантлы шагыйрәбез Лена Шагыйрьҗан үзенең шушы күмәк җыентыкка кергән «Кошка канат нәрсәгә?» дигән шигыренә эпиграф итеп урыс шагыйре Н.А.Некрасовның «Кому на Руси жить хорошо?» дигән поэмасыннан юллар китерә дә, әсәрендә үткән гасыр шагыйренең сүзләрен бөтенләй яңача яңгырата.

Рус илендә яшәү кемгә рәхәт?
Кемгә рәхәт, шулар беләдер...
Үз җиреңдә яшәп, илсез калсаң,
Үзәк-бәгырьләрне теләдер...

Әйе, безнең иң мөкатдәс, иң изге хисебез биредә үзәккә үтәрдәй итеп әйтелгән. Монда инде кайбер «шигырьләр»дәге кебек коры фикер, лозунг түгел, ә йөрәк түреннән кайнап, ургылып чыккан чын хис!

Аның кайнарлыгы укучының йөрәген, хисен җылыта, аны да тынгысызлык, ярсу, борчылу учагына сала.

Әйе, менә шушындый чын шигырь — милли рухлы шигырь үрнәкләреннән төзелгән тылсымлы бер китап ул «Ак вә кара». Аны җыйнап, туплап, төзеп чыгаручы фидакарь җан — Илдус әфәнде Алмаз. Моңа кадәр без бу шәхесне үз эшенә нык бирелгән педагог, озак еллар буе музыка мәктәбе һәм училищелары директоры булып эшләгән, яшь буынны милли музыкага якынайту буенча гаять зур эшләр башкарган кеше буларак белә, ихлас күңелдән милләт мәнфәгатен кайгыртып яшәвен күрә идек. Бу китабы белән ул безнең күңелләргә тагын бер якты сукмак салды.

«Ак вә кара» китабына язылган кереш сүзендә Фәнзаман Баттал да мондый чын милли әсәрләрнең әһәмиятен бик югары бәяли. «Йөзләрчә авторларның меңнәрчә мәҗмугаларын актарырга, актарганчы ук алардан нәрсә табачагыңны да белеп торырга кирәк! Тапканнан соң әле аларның иң мөһимнәрен сайлау, мәгънәви яки хронологик сафка тезү таләп ителә... Мондый хезмәткә тотынган кешегә Ходай сабырлык та, түземлек тә бирсен! Ә ул сыйфатлар Илдус әфәндедә җитәрлек. Шулар өстенә тагын да кыйммәтрәге — һәрдаим милләт файдасын кайгыртуга этәрә торган иманы бар. Әнә шул иман белән ныгытылган китап бу».

Чыннан да, җыентык безнең милләт өчен рухи компас булырдай китап булып чыккан. Яшь буын белән төрле тәрбияви чаралар үткәргәндә, үзеңә кирәкле милли рухлы шигырьне нәкъ менә шушы китаптан табып була бит! «Ак вә кара» китабы өстәлеңдә булса — шул җиткән!

Бүген шушындый изге бурычлар үтәрдәй әйбәт китап төзегән Илдус әфәнде Алмазга һәм аны бастырып чыгару мөмкинлеге тапкан Татарстан китап нәшриятына олы рәхмәт сүзен әйтәбез.

2000

Кызлар йөрәге

Кайчак: «Хатын-кыз шигърияте булмый!» — дигән кискен раслаулар белән очрашырга туры килә. Янәсе, шигъриятнең таләпләре дә, кануннары да уртак, поэзияне җенесләргә карап бүлү сыйфат начараюга китерәчәк, анда бүтән мәнфәгатьләр өстенлек итә башлаячак. Аларның борчылуларын аңлап була булуын, ләкин барыбер ялгыш карашта торганлыкларын әйтмичә ярамас. Чөнки, игътибар белән-рәк караганда, биредә объектив чынбарлыкны санга сукмау күренә. Табигатьнең үз тарафыннан дөнья әнә шулай икегә бүлеп яратылган икән, бу хакыйкатьне ничек күрмичә һәм исәпкә алмыйча калырга мөмкин?! Фәлсәфәчеләр теле белән әйткән чагында, капма-каршы көчләрнең бердәмлеген һәм көрәшен нәкъ менә шул ир-ат белән хатын-кыз гәүдәләндерә ич инде!

Ничек кенә сәер тоелса да, әйтеп үтик: шигърияттәге мондый бүленешне күрмәскә тырышу ул советлар вакытындагы милли аерымлыкларны онытырга, бетерергә омтылу сыманрак.

Мин сине шундый сагындым,
Беләсең микән шуны?
Кар-бураннар каплап китсә,
Табарсың микән юлны?

Йөрәкнең иң түренә үк үтеп кереп, бөтен җаныңны, бәгыреңне айкый торган шундый тирән моңга, сагышка ия юлларны бары тик хатын-кыз шагыйрә генә яза ала. Шуның кадәр сагыну, көтү, зарыгу, юксыну, ымсыну, омтылу — бу гаҗәеп серле хасият бары тик хатын-кыз табигатенә генә хас тойгы ич!

Ул шигъри юлларны укыганда, ирексездән буранлы авыл киче күз алдына килә... Тәрәзәдән тонык кына булып ут сибелә... Һәм бу утка таба берәү бик тә, бик тә ерактан ашкына-ашкына кайтып килә... Җылы өйдәге, лампа янындагы Гүзәл җанның да йөрәге — юлда, сөйгәне, көткәне янында... «Табарсың микән юлны?» дия-дия гүя каршы алырга ук чыккан ул аны...

Якты кояш, ал гөлләргә
Килә һаман сөенәсе,
Елый-көлә, яна-көя
Яратасы-сөеләсе.

Бусы без яраткан «Китмим әле яшьлегемнән» җыры. Йөрәктән үзеннән-үзе ургылып, чишмә суы сыман челтери-челтери чыга сыман ул җыр. Әнә шуңа ул һаман яшьләрнең дә, картларның да телендә — аны һәммәсе дә яратып, үз күреп, ихластан дулкынланып җырлый.

Безгә әнә шундый көчле, тирән хисле шигырьләр бүләк итүче шагыйрә — Фирая Зыятдинова. Күптән түгел аның «Мин кояшка елмаям» исемле яңа китабы басылып чыкты.

Югарыда искә алынган һәм әле без әйтеп китмәгән күпсанлы җырлар тексты авторы Фирая Зыятдинованың моңа кадәр «Матур буласым килә», «Язгы ярсу», «Ташкын», «Айнур» исемле матур-матур шигырь китаплары бар иде инде. Шулай ук аның тәрҗемә өлкәсендәге хезмәтләре дә мәгълүм. Урыс

язучысы К.Паустовскийның романтик эчтәлекле хикәяләрен ул моннан күп еллар элек үк үзенең бөтен шигъри җанын салып, зур тырышлык куеп тәрҗемә иткән һәм бу хезмәте турында җылы фикерләр ишеткән иде.

Шагыйрьнең яңа китабы нинди хис-кичерешләр бүләк итә соң?

Ах, шушы күңел кайтулар —
Йөрәкне елатулар...
Аннары, үтәр бар да, дип,
Үзеңне юатулар...

Бу шигырь нәкъ менә шигъриятнең үзәгенә булган төенне — кеше җанының әрни-әрни, газаплана-газаплана булса да һаман бирешмәскә, яшәргә һәм хәтта елмаерга тырышуын әйтеп бирә! Үзенең эчкерсез, ихлас, ачык, садә, самими табигыйлеге белән күңелне били. «Йөрәк түреннән чыккан гына йөрәк түренә үтә» дигән гыйбарә, күрәсең, нәкъ менә шуның ише очракларны күздә тотып әйтелгәндер дә инде.

Әйе, Фирая Зыятдинова — бик тә моңлы, хискә гаять тә бай шагыйрә!

Яуганда ак булалар ич,
Ник карала бу карлар?!

Шагыйрәнең менә шушы аз санлы сүзләренә сыйган тирән хисси эчтәлекне бирү өчен, минемчә, бер симфония язып булыр иде кебек... Шуның кадәр киң диапазонлы, тирән тамырлы мәгънә бәйләнешләре ята бит анда! Үзешчән композитор Роза Мөхетдинова матур гына көйгә салырга тырышкан аны. Әмма... әмма бу шагыйрәнең моң катламнары бик тә калын һәм бай шул! Сүз уңаеннан шунысын да әйтеп үтик: күп композиторларның Фирая Зыятдинова ижатына мөрәҗәгать итүе үзе үк бу поэзиянең хискә, моңга бай булуы турында сөйли.

Тын гына моңланамын да
Тын гына сагынамын.
Сизеп йөрим күңелемдә
Ярсу бер агым барын...

Хисләрнең никадәр нечкәлеге, нәзакәтлеге, тирәнлеге биредә! Ничек дип әйтергә икән: акварель белән ясалган матур рәсем кебек, дияргәме бу шигырьне? Ап-аяз күк йөзендәге ап-ак болыт каурые сыман гына сагыш, дияргәме? Яисә инде яшерен бер дәрт ишетелгән моңсу романс шикеллерәк, диеп әйтергәме?

Болыт канаты тия дә
Кояш нурын чылата.
Шул бер кара болыт инде —
Кояшны шул елата...

Менә шушы дүрт юлга бу дөньяның әллә нихәтле фаҗигасе сыеп беткән бит! Моны да шушылай нечкә итеп, образлы итеп бары тик хатын-кыз йөрәге генә әйтеп бирә ала!

Безне әнә шундый яңа һәм тирән кичерешләр белән очраштырганы өчен бу эчкерсез, самими, ялкынлы Шигърият алдында олы хөрмәт белән башыбызны иябез.

2000

Ныклыгыбыз туган җирдә!

Соңгы арадагы хәлләрне күздән кичергәч, күңелдә иректән: «Кая бара бу дөнья? Кая бара бу ил?» — дигән сораулар туа. Телевизор экраннарыннан көне-төне үтереш-атыш күрсәтелә...

Бүген яшь буынга менә шушындый тәрбия — бары тик физик көчне генә таныган яшәү рәвеше гадәти норма итеп сеңдерелә килә.

Өстебезгә ябырылган шушы явыз агрессиягә бүген нәрсәне каршы куя алабыз соң?

Рухилыкны, югары әхлакны. Чын әдәбият-сәнгать әсәрләрен!

Әйе, безнең әдәбиятыбыз борын-борыннан ук кеше күңеленең матурлыгы өчен көрәшә. Аның иң гүзәл әсәрләре әнә шуны раслап тора. Сүз уңаеннан әйтик: әле менә К.Тинчурин исемендәге театр да Илдар Юзеевның атаклы әсәре «Сандугачлар килгән безгә»не яңартып куйды. Бүген безгә, аеруча яшьләргә, бик тә тансык тамаша шул ул.

Өлкән буын каләм ияләре язганнарга тагын да игътибарлырак булырга тиешбез, чөнки аларда бүгенге боевикларга һәм бандитларга каршы тора алырдай рухи-әхлакый көч бар.

Шушы арада өлкән яшьтәге шагыйрь Гарәфи ага Әгъләмҗанның «Урак өсте» дигән шигырьләр китабын укып чыктым да тагын бер мәртәбә сөендем.

Тау буе яшел наратлык,

Тау асты салкын чишмә.
Яшьлектә без дә яраттык,
Хәзер теләсәң нишлә...

Менә шушындый, беренче карашка бик тә гади һәм гадәти булып тоелган шигъри юллар күп Гарәфи ага китабында. Болар туган ягыбыздагы чишмәләр, җанны иркәләп искән җилләр кебек, беркайчан да тәэсир сәләтен югалтмый торган матурлыклар! «Хәзер теләсәң нишлә...» дип, бик тә ихлас һәм мәгънәле сүзләрен генә карагыз.

Бүтәнчәрәк тә яза белә Гарәфи ага:

Таң шәфәгын бөре тоя башлап,
Карт тупылга дәшә: мең яшә!
Кучкыл биләү, өстен тибеп ташлап:
«Ирек!» — диеп, илгә эндәшә.

Менә шушы бер күренешкә күпме матурлык, ямь, мәгънә һәм сүзләр белән генә әйтеп бетерүе кыен булган тагын әллә нинди тылсымлы ымнар да сыйган түгелме?!

Югалтулар бардыр, табышларым...
Ә авылым — иң зур табышым.
Авылыма бер мәдхия итеп
Кабул итәм кошлар тавышын.

Әйе, Гарәфи ага Әгъләмҗанны чын мәгънәсендә безнең туган ягыбызга, туган җиребезгә дан җырлаучы, дип әйтергә була. Халкыбыз өчен алыштыргысыз дәрәҗәдә кыйммәтле рухи һәм матди хәзинәләр турында гади генә сүзләр белән тәэсирле итеп яза ул.

Казандагы «Матбугат йорты» нәшриятында моннан бер ел чамасы элек басылып чыккан бу китап турында газета-журналларда сүз әйтелмәде. Ә бит безнең каршыда талантлы шагыйрь әсәрләре ята, алар хәзерге яшь буын өчен аеруча кадерле булырга тиеш.

1994 елда Гарәфи аганың әсәрләре «Аргамак» журналында дөнья күргәч, аларга Башкортстанның халык шагыйре атаклы Нәҗар Нәҗми үзәге игътибар иткән булган икән. «Шигырьләрегез минем күңелгә бик тә хуш килде. Карт сөякне җылытуы авыр булган шикелле, карт йөрәкне дә эретүе җиңел түгел. Әйе, шигырьләрегез минем күңелне бик тә эреттеләр»,— дип, кабат-кабат басым ясап язган Нәҗар Нәҗми бу шагыйребезгә җибәргән хатында.

Талантлы каләм белән язылган шигырьләр китабын укып чыккач, күңел яңадан бүгенге шомлы дөньяга кайта... Һәм бераздан менә шушындый иҗат, шушындый әдәбият-сәнгать әсәрләренең хәзерге кеше күңеле өчен иң дөрес юл булуына тагын бер мәртәбә ныклап ышанасың. Үз эченнән генә: «Юк,— дисең,— мондый баскычны бандитлар чоры бервакыт үтәр әле ул. Адәм баласы үзенең бәхете һәм иминлеге бары тик туган җирендә генә була алуын барыбер аңлар әле... Чөнки алдынгы карашлы кешеләрнең күңел күзләре барыбер менә шушы якка — Гарәфи ага Әгъләмҗан чакырган юнәлешкә карый, шуңа ымсына!»

2003

Эзләгән — таба!

Герой эзлим!
Р.Харис

Шулай кызыклы туры килүләр булгалый бит ул!

Без — «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре Татарстан Язучылар берлегенең әдәби тәнкыйть остаханәсе белән бергәләп якын араларда дәвамлы һәм зур сөйләшү башлап җибәрергә уй-ният корып йөри идек. 2004 елның гыйнварыннан ел ахырынача журнал битләрендә барачак ул дискуссиянең тема юнәлешен озак кына киңәшкәннән соң, «Безнең заман герое» дип билгеләдек. Бу сөйләшүгә юнәлеш бирердәй сораулар исә журналның октябрь санында басылып чыкты.

Шундый мәшәкатьләр белән йөргәндә, «Мәдәни җомга» битләрендә «Исемсезләр» дигән шигъри роман басыла башлады, дөресрәге, аның өч санында өч өзек дөнья күрде. Шагыйрь Ренат Харис тарафыннан иҗат ителгән бу әсәр бик күпләрнең игътибарын җәлеп итте. Беренчедән, атналык әдәби газетабыз үзе унбер меңнән артык данәдә халыкка тарала һәм безнең барыбызның да яраткан басмаларыбыздан берсе булып тора. Икенчедән, без Р.Харисның үзен дә күп кенә кызыклы поэмалар авторы буларак беләбез бит инде. Минем үземә бигрәк тә «Рәссам» белән «Бүре күзе» һәм «Шөкер!» ошаган иде. Байтак еллар элек аларның беренчесе басылгач, без Язучылар берлегендә күп кенә күренекле әдипләр

катнашында бик җанлы, кызыклы һәм мәгънәле сөйләшү дә үткәргән идек. Шулай ук шагыйрьнең «Һарут белән Марут» поэмасын язып бетерү белән үз каләмдәшләренә кычкырып укуы, алардан фикерләр ишетүе дә мәгълүм. Дөрес, минем үземә шәхсән бу әсәр турында бераз бүтәнчәрәк фикер язып чыгарга туры килде. «Ватаным Татарстан» газетасын укучылар аны хәтерлидер. Ә менә өлкән шагыйребез Кави ага Латыйп, минем белән килешмичә, «Һарут белән Марут»ка уңай бәя биргән мәкалә бастырды. Ниш-лисең, «зәвыклар хакында бәхәсләшмиләр» дип әйтәләрме әле?

Ренат Харисның бу яңа әсәренә зур-зур шагыйрьләрдән берьюлы дүрт авторның сүзләре эпиграф итеп алынган: инглизнең — Байроны, урысның — Пушкин белән Лермонтовы, ә татарның Салих Баталы безнең шагыйребезгә рухи эзләнүләренә юлдаш булырдай канатлы сүзләр биргәннәр.

Эпиграфка алынган шигъри юлларның барысы да Замана героена багышланган. Арада берсе минем күңелемә бигрәк тә хуш килде. «Герой Нашего Времени, милостивые государи мои, точно портрет, но не одного человека: этот портрет, составленный из пороков всего нашего поколения, в полном их развитии...» — дип яза М.Ю.Лермонтов үзенең бу әсәрендә.

Р.Харис романының игътибарыбызны җәлеп итүенә тагын бер сәбәп — әсәрнең исеме! Йә, әйтегез — кем инде роман хәтле романга «Исемсезләр» дигән баш куя?! Аны иҗат итү өчен никадәр рухи һәм физик көч салганнан соң, никадәр иҗади газаплар кичергәннән соң, шуларның бер татлы җимеше булып өлгергән үз әсәреңә ничек инде шундый сәер исем куясың ди?!

Әмма...

Әмма чын иҗат, зур иҗат әнә шундый көтелмәгән яңалыктан, яңалыклардан башлана түгелме соң инде ул! Биредә дә, «Исемсезләр» дип уку белән, безнең күңелләрдә «кемнәр икән соң алар?» дигән табигый сорау, кызыксыну туа.

Шигъри роман болай башланып китә:

Герой эзлим! Герой эзлим!
Күз бетереп, җир ертып.
Әйтерсең лә татарда мин
Байрон, Пушкин, Лермонтов!..

Шагыйрь «герой эзлим» ди... Тукта! Бу теләк, бу максат безгә — югарыда әйтеп кителгән «Безнең заман герое» дигән темага дискуссия оештырып йөрүчеләргә генә түгел, ә бәлки бүгенге бөтен алдынгы фикер ияләренә дә хас булган, аларның да акылларын, зиһеннәрен биләгән омтылыш түгелме соң әле?! Ләкин монда без «герой» дигәндә, әлбәттә, әдәби әсәр каһарманнарын гына түгел, ә киңрәк мәгънәдә карыйбыз — чор кешеләренең иң асыл сыйфатларын үзендә туплаган, чагылдырган бер типик зат турында уйланабыз. Тормыштагы Герой, чынбарлыктагы бер Каһарман рәвешендә.

Соңгы елларда (1985 еллардан башлап дип әйтүем), чыннан да, бөтен илебез, җәмгыятебез белән Герой эзлибез түгелме соң?! Ил, халык көткән эшләрне эшләрдәй Геройны! Үзенең кешелек, рухи сыйфатлары белән безнең күңел омтылышларына җавап бирә алырдай Геройны!

Акыллы фикерләр сөйләп йөрүче генә түгел, өйрәтеп йөрүче генә түгел — ә үзенең бөтен асылы, холкы-табигате, кешелек сыйфатлары белән безнеңчә, үзебезчә булган Геройны!

Икенче төрле әйткәндә, безнең бу халәтебез социализмнан аерылып китәргә теләгән җәмгыятьнең, бигрәк тә аның рухи юлбашчыларының — әдипләренең һәм философларының диярге дә ярыйдыр — ил һәм халык өчен алга таба дөрес бару юлын табарга, рухи һәм әхлакый яктан да дөрес булган, зур киләчәгә булган юлны табарга һәм шул юлга реаль рәвештә аяк басарга теләү бугай ул.

Менә шушындый эзләнү халәтендә яшәгәндә — социализм белән капитализм арасында торганда — безнең өчен коммунистик идеаллар һич кенә дә ят түгел! Чөнки кешелек җәмгыяте үзенең миллионлаган еллык үсеш чорында әле алардан да югарырак, кешелеклерәк идеал тудыра алмаган! Алар бүген дә яши һәм без кереп баручы җәмгыятьнең ерткычлык, кешелексезлек билгеләре кискенәйгән, көчәйгән саен, әлеге идеаллар һаман актуальләшә.

«Герой эзлим!» Бу дәртле сүзләр романның башыннан алып ахырынача кызыл җеп, якты максатлы юл булып сузылып бара. Автор белән бергә укучы да герой эзли, герой көтә.

Менә безнең лирик героебыз Мәскәүдә командировкада:

Чөнки башкала ул чакта
үрмәкүч кебек иде —
үрмәкүчнең җепләрен
илдә һәр кеше тойды.

Совет империясенең асылы бер чагыштыру аша дөп-дөрес ачып салынган түгелме?! Романның башында ук менә шундый зур гомумиләштерү көченә ия фәлсәфи-шигъри детальләр күз алдында кала.

Мәскәү урамыннан барганда, ул очраклы рәвештә үзенең Ташкентта яшәүче абзасын очрата, һәм инде... гадәттәгечә, күбебезнең башыннан кичкән нәрсә: «Мәскәү» кунакханәсенең җиденче катындагы ресторан!

Романның төп геройлары менә шушында ачыла башлый да инде.

Шагыйрь белән аның абзасы утырган өстәл янында тагын бер урын әлегә буш тора, әмма аның хуҗасы бар: ул кичә официанткалар белән бәхәсләшеп, берүзенә 3 ярты аракы эчеп бетергән! Һәм бүген аны җиңүче буларак бушлай сыйлыйлар икән!

Шушы эпизод, геройның үзен күргәнче үк, аның турында тулы бер кыйсса сөйли, безгә аның холык-табигатен ача.

— Якташлар, татарлар икән...

— Табын — минем хисапка!..

Әлеге герой-җиңүче Әлмәттән килгән тәэминатчы булып чыга. Җиңүчегә, әлбәттә, барысы да рөхсәт ителә: ул әмер генә биреп тора, уртага чыгып биегәндә дә аңа сырылып берьюлы өч кыз бии!

Бу эпизодта да татар кешесенең байтак типик сыйфатлары: аның тәвәккәллеге дә, хәтта дуамаллыгы да, үз сүзенә тугрылыклылыгы һәм үҗәтлеге дә, хатын-кыз гүзәллегенә мөкиббән булуы да һәм чамасыз юмартлыгы да! Үзенең бу героен тасвирлаганда, шагыйрь ир-ат психологиясенең шундый тирән, катлаулы нечкәлекләренә кереп китә һәм аларны укучы йөрәге өчен тәэсирле шигъри сүзләр белән әйтеп бирә, андый юлларны ирексездән куен дәфтәренә күчереп аласы килә.

Баш югалткан мизгел белән
акыл җыйган мизгелнең
бергә туры килгән чагы
беркайчан да сизелми...

Әйе, бу — Әлмәт абзый тәэминатчы. Әйе, нефтьчеләр аңа, Мәскәүгә килеп, зур-зур мәсьәләләрне хәл итәр өчен (Мәскәү түрәләрен «майлау» өчен дип аңла), меңләгән сум акча биреп җибәргәннәр. Һәм Әлмәт абзый боларын бик әйбәтләп хәл итәчәк тә! Ләкин ул барыннан да бигрәк кеше бит әле! Р.Харисның андый типларны кеше буларак ачуы, югарыда күренгәнчә, ачылу халәтләрен тотып ала белүе, шундый күренешләрне җанлы итеп укучы күз алдына китереп бастыруы һәр яктан хуплауга лаек. Әлеге строфадагы «баш югалткан мизгел белән акыл җыйган мизгелнең бергә туры килгән чагы» исә, чынлап та, көчле булган Шәхеснең асыл, нигез сыйфатларыннан берсе буларак, шулай ук шагыйрь каләменең казанышы дип бәһаләнергә тиеш. Аны хәтта психологик, рухи ачыш дияргә дә мөмкин.

Шигъри роман геройлары эпизодтан эпизодка һәм янәшә рәвештә ачыла баралар. Әле генә без күреп киткәне Әлмәт абзый иде, ә Ташкент абзый исә тагын да шигърирәк җанлы. Аның табигатен ача-ача, лирик герой — Шагыйрь абзый — үзе дә шактый ук тирәннән чыккан, йөрәк түрендәге менә мондый сүзләре аша гәүдәләнә:

Күңелдәге иң нечкә хис
бердәнбер сүзен тапсын...
шул сүз тормоз-тоткарлыксыз
килеп телеңә ятсын,
ә телең аны уйнатсын
шәп эквилибрист сыман:
күккә чөеп йолдыз итсен,
һавага өреп — томан,
суга салып дулкын итсен,
утларга ташлап — очкын,
ә очкын... мәхәббәт нуры
булып дөньяны кочсын...

Ана телебезгә, бөек Шигърияткә карата нечкә тоем һәм югары таләпчәнлек белән сугарылган мондый асыл сүзләргә «Афәрин!» диясе килә. Әсәр герое Ташкент абзыйның шигырьләр язгалавы уңаеннан әйтелгәнгә күрә ул сүзләр роман тукымасына бик тә үз булып кереп урнаша, романның мәгънәви байлыгын, эчтәлек тирәнлеген арттыра.

Тел, шигърият һәм шагыйрьлек хакындагы фикерләр телгә килгәч, романдагы менә мондый хикмәтле юлларны да мисал итеп китермичә узып китү мөмкин түгел:

Ә бит шагыйрь булып була,
була иң ким дигәндә,
Телең — Ана, үзең — Бала
булып сөтен имгәндә!

Әсәрдә менә шушындый афоризм булып яңгыраучы юллар бик күп. Шагыйрьнең: «Аң һәм Хисне берләштергән Урын бар ул... Ул — күңел!» — дип башланган строфалары исә аерым бер шигырь сыман кабул ителә. Андый урыннар романда мул очрый.

Ләкин игътибар үзәгендә кеше язмышлары. Менә Ташкент абзый:

Канда — татар, телдә — урыс
Ә тәрбиядә — үзбәк.
. . . . . .
өч тарафка тартылуны
авыр кичерә иде,
аракыдан — аек булды,
җырдан исерә иде.

Романның иң фаҗигале һәм шул ук вакытта үз язмышы белән иң колоритлы фигурасы ул — Ташкент абзый! Әсәрне укып барганда, аның язмышын күреп: «Йа Хода! Бер кеше йөрәгенә шуның хәтле күп һәм зур фаҗигаләр салсаң да салырсың икән!» — дия-дия әрнеп, уфтанып барасың. Аның хәзер туган иле, туган җире юк! Ә Үзбәкстаннан аларны куалар! Ул татарча белми. Аның туган теле, ана теле юк. Бу яктан да ул үксез, ул ятим!

Шуның өстәвенә аның хатыны балага уза алмый. Романда моның сәбәбе бик әйбәт аңлатыла: бу ханым яшь чагында Ташкент абзый белән артыграк «шаярып» ташлаган... Бала булмагач, гаиләнең җылысы, ныклыгы, үзәге дә юк. Әнә шуңа күрә Ташкент абзыйны нахак бәла белән партиядән чыгаргач та хатыны аны якламый, ә, киресенчә, каршы якка баса — аның өстенә яңа гаепләр өя башлый! Ничә ел бергә яшәгән кешесе!

Әмма дөньяда шәфкатьле җаннар да бар... Менә шушы урында романга бик тә серле, кызыклы образ — яңа бер героиня килеп керә. Әлеге хатынның сеңлесе ул...

Хәер, без биредә бу романның бөтен эчтәлеген сөйләп бетермик. Укучы нәүмиз калмасын өчен бары тик шунысын гына әйтик: балага уза алмаган үз апасының гозерләп үтенүе буенча әлеге гаиләгә бала табып бирә ул. Ташкент абзыйдан! Бу бала үскәч булган хәлләр шулай ук бик тә драматик һәм гыйбрәтле.

Шушы урында укучыга бер серемне дә чишим инде: «Мәдәни җомга»дагы өзекләрне укыгач, мине әсәрдәге вакыйгалар, геройларның язмышлары, әсәрнең киң сулыш белән табигый-иркен агуы һәм тагын байтак сыйфатлары җәлеп итте һәм мин, бу шигъри романны тулы килеш укыйсы килү теләгемне җиңә алмыйча, шагыйрьнең үзенә мөрәҗәгать иттем. Романның тулы нөсхәсен сорап алдым. Шуңа күрә, бәлки, бу язмамда роман геройлары тормышына күбрәк тә кереп киткәнмендер... Алардан, алар кичергән вакыйгалардан аерыла алмыйча.

Әйе, роман безнең заман кешеләре турында зур сүз әйтә алган. Шуның өстәвенә анда соңгы елларның сәяси һәм икътисади хәлләре дә, кешеләрнең холкы-психологиясе дә, тормышта күпләр тарыйюлыга торган фаҗигаләре дә бар. Шулай да «бу шигъри романның иң көчле ягы нәрсәдә?» дип сорасалар:

— Заманыбыз кешеләренең бәгырьләрен телгәләгән фаҗигаләрнең психологик яктан тирән һәм шигъри яктан тәэсирле итеп тасвирлануы! — дип җавап бирер идем.

Исемсезләр... Чыннан да, әйләнә-тирәбездә никадәр кызыклы шәхесләр, гыйбрәтле язмышка ия затлар бар. «Беркемнең дә сарае буш түгел инде...» — дип куябыз без еш кына, андыйлар хакында сүз чыкса. Ә менә шагыйрь алай гына узып китә алмаган — безнең заман геройлары хакында әйбәт әдәби әсәр туган.

Әйе, тормышта да, әдәбиятта да бар ул Безнең Заман Герое!

2003

Күңел кемне көтә?

Соңгы егерме елда бик тә нәтиҗәле иҗат итүче әдибебез Фоат Садриевның 1992 елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Таң җиле» романыннан Нуриасма образы хәтергә уелып калган. Үзенә бик тә кыен килгән беркөнне, газаплы һәм әрнүле кичерешләрдән соң, күңеленнән генә ул менә мондый нәтиҗә ясый: «Аны кемнәр генә нинди генә хурлыклы сүзләр белән тамгаласалар да, кемнәр генә нинди генә ачулы күз карашлары белән чәнчесәләр дә, Нуриасма үзенең алар өчен буй җитмәс биеклектә торуын аңлады. Бу — аның күптәннән төзегән сафлык дөньясы, аңа ул үзе генә патша, күпме генә, ничек кенә һөҗүм итмәсеннәр — бу патшалыкка беркемнең дә теле дә, кулы да зарар сала алмаячак иде».

Менә шушы кыска гына бер өзектә безнең заман героена хас булган үтә мөһим сыйфат: рухи сафлык һәм рухи ныклык ачык чагыла. Чыннан да, бүгенге тормышта (соңгы елларда бигрәк тә!) нык күбәеп, көчәеп киткән эреле-ваклы әшәкелек ташкынына каршы тора алу, шундый мохиттә яшәп тә буялмый, пычранмый кала алу — үзе бик тә зур батырлык, ныклык сорый бит! Ә Нуриасма исә буялмау гына түгел, ул вак-төяк әшәкелек ташкыныннан өстен, якты, көчле образ булып истә кала.

«Безнең заман герое» дип әйткәндә, иң башта әдәбиятыбыздагы әнә шундый — рухи яктан көчле, әхлакый яктан пакь образлар күз алдына килә.

«Казан утлары»ның 2002 елгы 11—12 саннарында басылып чыккан «Өермә» әсәрендә Мәдинә Маликова үзәккә шагыйрә Җәүһәрия образын куйган. Юк, Җәүһәрия: «Иҗат кешесенең эше — язу өстәле янында, яңа әсәрләр иҗат итү!» — диеп кенә яшәми. Ул үзенең инициативасы белән «Хәйрия җәмгыяте» оештыра, шәһәрдәге ярдәмгә мохтаҗ картларны, авыруларны барлап чыга, аларның исемлеген төзи һәм үзе төрле-төрле оешмаларга, бизнесменнарга барып, ялына-ялына, акча яисә азык-төлек таба да аларны әлеге кешеләргә илтеп бирә, өләшә. Авторның үзәккә, әлеге җәмгыять башына шагыйрәне —

нечкә күңелле һәм гаять дәрәҗәдә саф вөҗданлы затны куюы бер дә юкка түгел, билгеле. «Тулаем ил, җәмгыять башында да әнә шундый шәфкатьле, изге күңелле кешеләр торсын иде!» дигән фикер ярылып ята анда.

Әмма, әсәр героинясы Җәүһәриянең ният-максатлары изге булса да, аның әйләнә тирәсендә ерткыч табигатьле адәмнәр күп. Алар яңа байлык туплау өчен бернәрсәдән дә чирканып тормыйлар һәм... Җәүһәриянең яшь гомере әнә шулар кулы белән үзелә. Әсәр бик тә фаҗигале тәмамлана. Әмма иң соңгы биттә безнең күңелгә өмет нуры да төшеп куя. Әсәр буена Җәүһәрияне яклап, аңа булдыра алганча ярдәм итәргә теләп яшәгән Харис иң соңыннан, Җәүһәрия үлгәч, болай ди:

— Нигә булмасын? — диде Харис.— Халыкның уллары-кызлары җитәрлек. Бәяли генә белмибез. Кеше кадерен белү юк бездә. Кайчан да булса зурга омтыла торган, көчле, кыю шәхесләр табылыр, җәмгыять яңадан ачылыр. Менә дигән бинага ия булыр. Түбәсендә Кызыл Ай балкып торыр...

Бу сүзләр укучыга тулаем ил, тулаем җәмгыять турындагы фикер булып аңлашыла һәм киләчәккә карата оптимистик уйлар уята.

Әйе, соңгы елларда иҗат итүче проза осталары безнең игътибарга әнә шундый — сокланырдай уңай геройлар образларын куя алдылар. Ә бераз гына ераккарак карасак, без Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн кич белән» повестендагы Бибинурны, Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять»ендәге Акъәбине күрербез. Үзләренең рухи ныклыклары, сафлыклары һәм фидакарьлекләре белән алар безнең хәтердә Габдрахман Әпсәләмов геройларына һәм Нәфисәләргә (Г.Бәширов), Миңлекамалларга (М.Әмир) килеп ялганалар. Алар шул ук вакытта хатын-кызның бөеклеген, аның яшәештәге төп ролен күрсәтү ягыннан безнең татар әдәбиятының зур казанышы булып та торалар. Ә Акъәби белән Бибинур исә — дөнья әдәбияты өчен дә кызыклы ачыш.

Татар прозасының танылган осталары XX гасыр дәвамында салган, төзегән төп юл әнә шундый иде. Югарыда без кыскача гына тукталып үткән образлар алар, әлеге олы юлның якты маяклары сыман еллар аша да балкып, нур чәчеп торалар. Алар әдәбиятыбызның көчен һәм шул ук вакытта халкыбызның рухи-әхлакый йөзен, характерын да күрсәтәләр. Милләтебезнең тулы вәкаләтле вәкилләре булып яшиләр.

Герой. Безнең заман герое.

Ә соңгы елларның реаль чынбарлыгында нинди соң ул безнең еллар герое? Бүгенге тормышта без кемнәргә, нинди типларга чыннан да «герой» дип әйтә алабыз?

Юк, үзләре бик тә кукраеп йөрсәләр дә, күпләгән сандагы үтергеч коралларга ия булсалар да, хәтта кайсыбер вакытларда байтак кына кешене куркытып тота алсалар да — төрле-төрле мафия корольләрен без герой дип әйтә алмыйбыз. Шулай ук төрле яшерен юллар һәм астыртын хәйләкәрлек белән дәүләт, ил, халык акчасын урлап хәрам байлык туплаучыларны, ил халкының иң зур күпчелеге тормышның очын очка ялгый алмыйча тилмергәндә, «герой» диярга тел бармый.

Хакимиятнең төрле җылы кәнәфиләренә менеп утырып, ил, халык мәнфәгатеннән алда үзенең кесәсе турында уйларга ашыккан һәм шул максат белән көн-төн баш ваткан, кесә калынайтуның төрле ысулларын тапкан вак җаннар да «герой» дигән югары исемне, әлбәттә, күтәрә алмый.

Герой исеме ул, һичшиксез, зур батырлык, зур фидакарьлек белән бәйле.

Ә батырлык, фидакарьлек дигәндә минем күңелгә иң башта сугыш елларыннан Шакиржан Мөхәммәтҗанов, Газинур Гафиятуллин кебекләр, сиксәненче еллар армиясе тормышыннан Рифкать Миргазизов сыман асыл, кыю егетләр килә.

Бу егетләр кылган батырлыкның, алар геройлыгының нигезе, мәгънәсе, әһәмияте нәрсәдә соң?

Соңгы елларда без менә бу сораулар турында бөтенләй сөйләшмибез, хәтта уйламыйбыз да бугай. Шуңа күрә, әйдәгез, алдагы фикерләргә күчкәнче, иң башта әлеге сорауларга җавапны ачыклап китик.

Иң башта шуны искә алыйк: Туган илне, Туган җирне дошманнан саклау өчен барган сугыштагы батырлык бу! Әнә шул изге көрәш вакытында Газинур да, Шакиржан да үз иптәшләренең гомерен саклап калу, алар исән калсын өчен газиз тормышларын корбан итәләр. Әлбәттә, бүген безнең яшәештә эгоизм, хәтта ерткычлык инстинкты буенча гына эш итү үтә нык көчәйгән чагында, күпләр өчен менә мондый фидакарьлекне аңлау бик тә кыенлашты. Андыйлар өчен Газинур белән Шакиржан батырлыгы бик зур бер ахмаклык шикелле генә тоела. Иң алга үз мәнфәгатен, һәм бары тик үз мәнфәгатен генә куеп яшәүчеләр өчен бу шулай. Ләкин бит әле Ил мәнфәгате дә бар. Ил мәнфәгатен алга куеп фикер йөртеп карасак (хәзер андыйлар бик тә сирәк билгеле — әнә шул Газинурлар, Шакиржаннар кебек бик аз алар. Һәм нәкъ менә шул сәбәптән: ягъни, андыйлар бик тә аз булганга күрә, Ил менә шушы көлке хәлгә килеп төште дә бит инде безнең!), без кемнең кем икәнен бик яхшы аңларбыз.

Бусы Газинурлар батырлыгының практик яктан карагандагы кыйммәте, әһәмияте булды. Әле бит тагын, моннан кала, әлеге фидакарьлекнең рухи яктан, фәлсәфи мәгънәдәге әһәмияте дә бар. Сөйләшүебезнең темасы геройлар һәм геройлык турында булгач, анысын да биредә ачыклап китү сорала, билгеле.

Кыскача гына итеп әйткәндә: алар, әлеге күренешләр, кеше табигатенең нинди зур рухи, әхлакый потенциалга ия булуын раслый. Физика галимнәре теге яки бу матдәнең асыл сыйфатларын ныклап бе-

лү, аңлау, төшенү өчен гаять зур тизлек хасил итә торган синхрофазотроннар кулланалар бит әле — шуның шикелле, сугыш чорында адәм баласы килеп эләккән критик, кискен ситуацияләрдә алар Кешенең кем икәнен, нинди икәнен ныклап белергә ярдәм итә.

Юк, сугыш чорында гына түгел. Әнә Казаныбызның очучы егетләре, Михаил Девятаев батырлыгын кабатлап, әфган әсирлегеннән самолетка утырып качтылар бит әле!

Карапетян дигән егет пассажирлары-ние белән су төбенә төшеп киткән троллейбус эченнән берүзе 18 кешене алып чыкты!

Ә гадәттән тыш хәлләр хезмәтендәге кыю, тәвәккәл егетләр үз гомерләрен куркыныч астына куеп, көн саен ничәмә батырлык кылалар!

Без бүген, «капитализм» дигән кара урман ерткычлары арасына барып кергәч, кешене югары күтәрә, аны рухи һәм әхлакый яктан балкытып, нурландырып күрсәтә торган андый матур күренешләр турында уйламаска да күнегеп киләбез.

Ә соң үзебезнең әдәбият дөньясына килсәк, совет хакимияте елларында нинди каты сәяси һәм рухи басымга да бирешмичә, үзләренең эчке иманнарына, үзләренең олуг иҗат һәм намус юлларына бөек тугрылык саклап кала алган Әмирхан ага Еники һәм Нурихан ага Фәттах — алар безнең чорның геройлары түгел идемени?! Күпчелек иҗатчылар партиянең өлкә комитетыннан өркеп яшәгәндә, хәйләкәррәк иҗатчылар үзләренә шәхси уңышлар яулау (һәм рәхәт тормышка ирешү өчен!) андагы түрәләр белән турыдан-туры яисә «интеллигентлар»ча әшнәлек иткәндә һәм алар кулыннан төрледән төрле медальләр алганда — болар бит бары тик милләт, халык хакына олуг Иҗат дигән Иманны гына таныдылар! Шуңа гына хезмәт иттеләр.

Язмабызның башында Фоат Садриевның роман героинясы Нуриасма уйлаган уйлар — алар нәкъ менә Әмирхан Еники белән Нурихан Фәттахка да төп-төгәл туры килә түгелмени?! Алар, әлеге сүзләр, бу әдипләрнең дә асыл табигатен, төп холкын, алар мәсләгенең, Иманының мәгънәсен ачып бирә түгелмени?!

Үз гомерләренең, үз иҗатларының иң калку, иң зур казанышы итеп, алар — бу ике әдип — берсе гасырлар буена үлмәстәй Акъәби образын, икенчесе ерак гасырлар төпкеленнән үлемсез рәвештә, данлы рәвештә атлап килүче татар кешесе, татар милләте образын тудырмадылармыни?!

Күптән түгел, ә төгәлрәк итеп әйтсәк, «Казан утлары»ның быелгы 1—2 саннарында, Аяз Гыйләҗевнең «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» дигән язылып бетмичә калган романын укыдык. Танылган халык язучысының яшьрәк буын прозаикларга үзенчә бертөрле васыяте кебегрәк кабул ителә бу әсәр. Романның эчке энергетикасының, рухи куәтенең көче сокландыра. Ә үзәккә салынган идеясе! Министр дәрәҗәсенә күтәрелгән Асаф Сәхипович һәм аның яшьлек дусты Фаязны икесен янәшә куеп караганда, бигрәк тә ачык аңлашыла ул идея, ул мәгънә.

Министр кәнәфиенә утырыр өчен, Асаф Сәхипович кемнәргә генә нинди генә ялагайлыклар кылмаган да, кемнәрне генә сатмаган. Яшьлек мәхәббәтеннән алып үз әтисенә булган мөнәсәбәткә кадәр — бөтен яшәү дәверендә һәммә изге, саф нәрсә изеп, таптап үтелгән. Әсәр ахырында, әтисе дөнья куйгач, министр улына хәбәр дә иттермәве, үз җәсәден җиргә иңдергәндә, малаеның булмавын, катнашмавын теләү — үтә зур мәгънә, символика ала. Ягъни бу: министр кеше атасы-анасы юлыннан, үзенең иле, милләте юлыннан аерылды дигән сүз инде. Төгәлрәк итеп әйткәндә: ата-ананың һәм илнең әлеге министрны кире кагуы булып чыга бу күренеш. Әнә шундый министрлар бит инде илдә һәм җәмгыятьтә революцион ситуация китереп чыгаралар һәм ахыр чиктә тәхеттән туп-туры тарих чүплегенә очалар.

Тәҗрибәле әдип А.Гыйләҗев әлеге типка Фаяз кебек эчкерсез һәм ныклы җирлеккә ия шәхесне каршы куеп, яшәешнең олы юлы кайда икәнен күрсәтә. Фаяз, дан-дәрәҗә артыннан кумыйча, тыйнак кына эшләп йөри. Аның каравы Фаязның менә дигән гаиләсе, туганнары бар. Министр дустының үткәндәге вак-төяк әшәкелекләрен дә оныткан инде ул — бу аның киң күңеле өчен бер ваклык кына кебек кабул ителә, күрәсең.

Язучы үзенең әсәренә исемне «Кылдан нәзек, кылычтан үткен» дип куйганда да олы яшәешнең катгый рухи-әхлакый кануннарын күздә тоткан, ахрысы. Әйе, ил күзен, халык күңелен син алдый, хәйләли алмыйсың. Ил күзе синең кем икәнеңне, асылыңны белеп тора ул. Аның ышанычын, хөрмәтен казаныр өчен, югары дәрәҗәләр һәм затлы кәнәфиләр мөһим түгел — ә намуслы яшәлгән гомер юлы мөһим. Ил күңеле үзенең һәр улын әнә шундый «кылдан нәзек, кылычтан үткен» рухи-әхлакый үлчәүгә салып үлчи һәм үзенең төгәл бәһасен бирә ул.

Әйе, Аяз Гыйләҗев үзенең тирән фәлсәфи мәгънәле әсәрләре белән дә һәм бер үк вакытта әдәбиятка кагылышлы мәкаләләре белән дә «заман герое» мәсьәләсенә зур өлеш кертте. Минем үземә дә аның белән бу хакта әңгәмә корырга (ул басылып та чыкты) туры килгән иде.

Аяз ага бигрәк тә гыйбрәтле геройлар иҗат итәргә яратты. Ул мондый фикерне мәкаләләрендә һәм әңгәмәләрендә дә байтак кабатлады. Мисал өчен без аның белән 1972 елда үткәргән әңгәмәдә ул әлеге проблемага кагылып болай дип язган: «Шәхсән минем үземне «гыйбрәтле» геройлар кызыксындыра. Мин шундый кешеләрне яратам. Үзләре яшәгән чорга битараф булмаган, мәхәббәтне һәм нәфрәтне сиземли торган кешеләр... Уйлана һәм уйландыра торган кешеләр! Коммунизм идеалларына турылыклы

кешеләр... Шул ук вакытта үз турылыкларын лозунг итеп күтәреп йөрми торган тыйнак кешеләр... Киң күңелле кешеләр... Сатылмаслар, алдашмаслар, дус-дошманны аера белә торган кешеләр!..»

Әйе, үзенең әлеге принцибына туры калырга тырышып ижат итте Аяз ага һәм безгә журналист Идрис («Урамнар артында яшел болын»), Исхак («Берәү»), Бибинур («Җомга көн кич белән») кебек онытылмас геройлар калдырды.

Ә инде әҥгәмәбезнең икенче бер өлешендә ул әдәби геройларның укучылар күңелендә озак яши алу-алмавына бәйле уйлары белән уртаклашты: «Бүгенге көн героена минем мәгълүм таләбем бар — герой икән, аның киләчәге булсын!

Теге яки бу герой язучы күңеле аша тормыштан китапка үтеп керә. Кем ул, нинди ул, үз чорының кадерле һәм онытылмаслык асыл сыйфатларына ияме ул — аның гомеренең озынлыгы шушы сорауларга бәйләнгән. Безнең китапларда еш кына бер көнлек персонажлар гомер итәләр һәм китап үзе тузганчы ук искерәләр, онытылалар... Димәк, язучы бүгенге көндә үз янәшәсендә ижат итүче, көрәшүче, тормыш төзүче геройларга хыянәт итте дигән сүз. Ул бүгенге көн геройларын эстафета итеп алдагы буыннарга ялгый алмады».

Әйе, замана яшәеше китереп чыгарган зур-зур проблемаларны үзе язган әсәрләрнең үзәгенә куя иде Аяз ага. Аның башта Мәскәүдә генә басыла алган «Өч аршын җир» повестен аласыҥмы яисә «Эҥермеҥгер» белән «Җиргә тапшырылган серләр» драмаларын искә төшерәсеҥме, аларда иң элек социаль эчтәлекнең үткенлеге, актуальлеге һәм гаять зур проблемалылык күзгә ташлана. Нәкъ әнә шул проблемалылык аркасында инде — юллар арасына гына яшеренеп, качып кала алмаган үткен проблемалылык аркасында — Аяз Гыйләҗев үзе дә КПСС өлкә комитетының «сөекле» кешесенә әверелгән иде бит!

Ә.Еникиләр, Н.Фәттахлар, А.Гыйләҗевләр тоткан олы юлны дәвам итүче, безне мавыктырырдай кызыклы геройлар ижат итүче прозаикларыбыз тагын да бар, билгеле. Язмабызның башында Ф.Садриев һәм М.Маликова исемен әйтеп үткән идек. Соңгы елларда шулай ук нәтиҗәле ижат иткән Радик Фәизовның оригиналь проблемалар күтәргән әдәби геройлары булды. Аның бигрәк тә «Телсез» һәм «Көнбагыш чәчәкләре» дигән хикәяләре истә калган. Алардагы кичерешләр драматизмы, алынган ситуациянең яңалыгы һәм тирән рухи мәгънәгә ия булуы, язучы теленең үз геройларының күңел халәтенә тәңгәл рәвештә гаять тә музыкаль һәм югары зәвыклы булуы — болар соңгы еллар прозасының тулаем алганда да уңышы булып тора.

Ә шул ук Радик Фәизовның «Тәҥре хөкеме» дигән фантастик повестен алып карагыз сез (Казан утлары.— 1999.— № 4). Аның төп герое Сәетҗан аганы искә төшерегез. Бүген безнең татар халкы өчен генә түгел, бөтен кешелек җәмгыяте өчен гаять мөһим, гаять актуаль булган идеяләр белән мавыгып йөри бит ул.

«Һәр көн иртән кояш белән бергә тордылар, урман аланына чыктылар. Иртәнге тынлыкта, моңлы һәм тантаналы булып, еракларга кадәр адәм балаларының тавышы яңгырады:

— Исәнме, Табигать! Безне бу дөньяда яшәтүче, тамагыбызны туйдыручы, җаныбызга һәм тәнебезгә сихәт бирүче мәрхәмәтле табигать. Исәнме, Кояш! Барча-барча тереклек ияләрен, тере булмаганнарны да бердәй күреп яраткан, аларга тормыш биргән Кояш. Зәңгәр күк йөзе, яшел урман, агачлар, үләннәр, чәчәкләр — саумысез! Без, кешеләр, сезнең барчагызны да яңа туган көн белән тәбрик итәбез. Сезгә дуслык, туганлык сәламе җибәрәбез!

Шушындый ихлас күңелдән сәламләүдән соң, һаваның нинди булуына карамастан, хәтта өстән явып торса да, бергәләп иртәнге гимнастика ясыйлар, елга буена төшеп су керәләр. Аннары инде көндәлек эшләр башлана».

Болар — Җир шарындагы тормыш техника артык көчәю сәбәпле юкка чыкканнан соң, Табигать кочагында яңа тормыш башлап җибәрүчеләр. Сәетҗан ага — алар арасында иң өлкәне, остаз.

Бу остазның югарыда без укып үткән сүзләре бүген бөтен кешелек дөньясы өчен дә үтә мөһим. Чөнки хәзер кешелек дөньясы, әлеге дә баягы техник үсеш аркасында, Олы Һәлакәт каршына килеп басты — тәмам якынлашты. Сәетҗан аганың әлеге сүзләре акыллы кешенең дөрес юлга чакырып безгә дәшүе дә һәм шул ук вакытта бөек кисәтү дә булып яңгырый.

Менә шушы гаять актуаль темага безнең татар әдәбиятында уңышлы әсәрләр, геройлар ижат ителү — уртак горурлыгыбыз ул.

Ә шулай да без бүгенге күпчелек геройларыбыздан канәгать, дия алмыйбыз.

Ни өчен?

Чөнки аларның күбесе әсәр дәвамында әллә никадәр, бик күптөрле күренешләрдә катнаша, башыннан әллә нәрсәләр кичерә — ә менә шул хәл-әхвәлләрнең чын мәгънәсендә вакыйга булырдайлары яисә бөтенләй дә булмый, яисә бик тә, бик тә аз була. Әсәрнең күләме белән чагыштырып караганда, үтә дә аз табыла алар.

Ә бу хәл үзе нилектән, ни сәбәпле килеп чыга соң?

Минемчә, моның иң төп һәм иң беренче сәбәбе — язучыларыбызның (биредә, әлбәттә, проза тармагында каләм тибрәтүчеләр күздә тотыла) игътибары, нигездә, тышкы дөнья вакыйгаларына, күренешләренә юнәлгән булуы. Ә күренеш һәм вакыйгаларның рухи һәм фәлсәфи асылы аларны аз кызыксын-

дыру. Яисә бөтенләй дә кызыксындырмау, уйландырмау. Үз чиратында бусының сәбәбе — безнең прозаикларыбызның интеллектуаль дәрәҗәләренә, шул эчке рухи көчнең куәтенә, аның шәхес эчендәге потенциалына, аның ни күләмдә булуына килеп ялгана. Әнә шул сәбәпле безнең проза әсәрләрендә күренешләр бик күп, ә чын вакыйгалар — истә калырдай, әдәби геройның үзен дә безнең каршыда югары күтәрердәй тирән мәгънәле вакыйгалар бик аз була. Соңгы елларда мафия һәм аның төрле-төрле вәкилләре турында язылган бик күпсанлы роман-повестьларның барысы да диярлек (Мәскәүдә яшәүче авторыбыз Р.Мирхәйдәровныкыннан кала) бу очракта мисал була ала.

Юк, биредә безнең күпчелек язучыларыбызны интеллектуаль, рухи көч җитмәүдә гаепләгәндә, без аларның барысын да әлеге Мәскәү авторы Р.Мирхәйдәров яки үзебезнең М.Галиев кебек язарга чакырмыйбыз. Мондый юлга басу прозаның колачын гаять тә тарайтыр, аның эчтәлеген саектырыр, халыкчанлыгын киметер иде. Без биредә Әмирхан ага Еники әсәрләрендәге сыман рухи куәт, эчке энергия, тирән мәгънә турында сүз алып барабыз. Әнә бит: мәрхүм Әмирхан агабызның тылсымлы күңеле гапгади татар сүзләре белән бөтен дөнья әдәбиятының иң югары сәнгать әсәрләре янәшәсендә тора алырдай бөек проза әсәрләре иҗат итте.

Минем нык инануымча, ул — үз әсәрләренең рухи-фәлсәфи һәм сәнгати көче белән, аларның һәммә яктан камиллеге белән үткән XX гасыр прозаиклары арасында аеруча зур биеклекләр яулаганы, бигрәк тә биек үрләр яулаганы. Татар әдәбиятында үткән гасырның иң көчле, иң талантлы прозаигы кем дип сорасалар, мин, мәсәлән, «Әмирхан Еники» дип җавап бирәчәкмен!

Мондый мисаллар безгә, бигрәк тә яшь буын прозаикларга, әле яңа башланып киткән XXI гасырда да якты үрнәк булып торачак.

Әлбәттә, чын реалистик прозаның Еникилар тоткан төп юлын дәвам иттерүчеләр яшьрәк буын каләм ияләре арасында да бар. Мәсәлән, Чаллыда яшәп иҗат итүче каләмдәшебез Вахит Имамов соңгы елларда иҗади үсеш кичерә. Бигрәк тә аның тарихи темага язылган әсәрләре киң популярлык казанды. Әмма биредә, безнең көн тәртибендә заман герое проблемасы торгач, бу әдипнең заман темасына язылган әсәрләренә тукталасы килә. Алар арасында иң уңышлысы һәм уку өчен дә кызыклысы, минемчә, «Могикан» повесте булды (Идел.— 2000.— № 10).

Кайсы ягы белән кызыклы иде соң бу әсәр?

Минемчә, татар халкы, татар җире соңгы елларда дучар булган фаҗигане геройлар язмышы аша тәэсирле итеп тасвирлавы белән, әнә шул тетрәндергеч хәлне үзәккә куюы белән игътибарга лаек бу повесть.

Әсәрнең төп герое — «Могикан» исемле чабышкы ат. Аңа исем сайлау, исем кушу повестьта шулай ук ышандырырлык итеп һәм бик тә мәгънәле күренешләр аша тасвирлана. Вәлит исемле яшүсмер һәм аның дуслары Америка язучысы Фенимор Купер әсәрләрен укып җенләнеп йөриләр. Аларның теллә рендә дә Чингачгук, мустанг һ.б. шуның ише сүзләр. Ф.Купер китабындагы вакыйгалар Америка җирлегендә бара: биредә яшәп яткан индиан кабиләләрен буйсындыру, тез чүктерү, юк итү өчен аяусыз көрәш бара.

Менә шушы урында әдип каләме татар укучысы өчен гаять мөһим булган эчке мәгънә катламын хасил итә. Укучы күңеленә бик тә таныш хис-кичерешләр агымын тудыра. Мондый эчке агым пәйда булуга күп фактлар ярдәм итә. Иң башта автор Могикан исемле яңа гына туган бу колынның әнисе Шоңкар исемле атаклы чабышкы булуын әйтеп уза. Бу момент укучы күңелендә татар халкының, төрки кавемнең данлы үткәненә, ерак тарих юллары буйлап узган язмышына бик ачык ишарә ясый, шулар хакында уйландыра.

Төгәл генә һәм төбәп әйтелмәгән очракта да ни өчен безнең күңелләрдә әнә шундый ассоциатив уйлар, фикерләр туа соң? Күрәсең, биредә безнең халык авыз иҗатында һәм соңрак дәверләрдә шигъриятебездә атның милли символга әйләнүе зур роль уйный торгандыр. Шагыйрьләребезнең ул хакта әллә никадәр шәп шигырьләре бар бит. Аннан соң ат ул үзенең холкы-табигате белән дә безнең милләткә, холкыбызга бик тә охшаш, бик тә үз түгелме соң әле?! Ул — эшчән һәм күндәм дә, бер үк вакытта чыдам һәм көчле дә, ә инде ярышларда баш бирергә яратмаучым карап торганда, сокландырып чаба алучы менә дигән чабышкы да.

Могикан дигән яшь чабышкы белән якыннан танышканчы, Вахит Имамов безнең күңелләргә әнә шундый уй-тойгылар, әнә шундый мәгънәле-хисле дулкыннар сала.

Ә инде әсәр геройлары Могикан белән яшүсмер Вәлитнең дуслыгы, аларның беренче чабышка чыгулары — болар, шигырь дәрәҗәсенә күтәрелеп, автор үзе дә чын-чыннан илһамланып иҗат иткән урыннар! Биредә В.Имамов «Алмачуар»ны тудырган Г.Ибраһимовлар, ат турында берничә гүзәл повесть («Хуш, Гөлсары» һ.б.) язган Ч.Айтматовлар дәрәҗәсенә үк күтәрелә.

Әмма вакыйга татар җирлегендә бара... Узган гасырның җитмешенче елларында... Татарларның тарихи ватаны булган оҗмах кебек җирләрдә КамАЗ дигән гигант завод кору башлана.

Милләтнең гасырлар буена оешып, ныгып, үсеп килгән табигый җирлегенең җимерелүе, юкка чыгарылуы бу әсәрдә бик тәэсирле, тетрәндергеч күренешләр аша ачыла: күлләр-чишмәләр, авыллар юкка

чыга, әйберләр югала-талана-урлана башлый, кешеләр арасында сугыш-үтереш күбәя, күпләр үзенә-үзе кул сала, асылына...

Вәлитнең күз салып йөрегән кызы Мәрьямне көчлиләр... Аннары инде Вәлиттән бүтән кешегә баш бирергә теләмәгән — биленә ияр салдырмаган Могикан әрәм була... Иң соңында яшүсмер егет Вәлит яңа каланың иң биек йорты түбәсенә менеп аска ташлана!

Шулай итеп, әлеге зур завод, яңа кала әсәрдә фаҗига чыганагы — бөтен кешелеккә, кешелеклелеккә, бигрәк тә татар милләтенә зур зыян китерүче Кара көч рәвешендә чагылыш таба. Алдарак Р.Фәизовның «Тәңре хөкеме» исемле фантастик повестен карап узган идек бит әле — ул әсәрдә бөтен Җир шарындагы тереклекне зур һәлакәткә алып килгән техника прогрессы — нәкъ менә шушы инде! Ул бүген безнең борын төбебездә, күз алдыбызда.

Әсәрдә безне сокландырган Могиканның үлеме, керсез күңелле яшүсмер егет Вәлитнең үз-үзен үтерүе — болар барысы да уяу җаннар өчен бүген зур кисәтү, ныклы искәртү.

Талантлы әдип В.Имамовның шундый тирән мәгънәгә һәм зур тәэсир көченә ия әсәр иҗат итүе — әдәби герой тудыруы — соңгы елларның кызыклы образлар галлереясын тагын да баетты.

Сүземнең ахырында тагын бер мәсьәләгә тукталып узасы килә.

Безнең әдәбиятыбыз бүген, Көнбатыш һәм бигрәк тә Америка идеологиясенә каршы позициягә басып, рухи яктан бай булган, чын кешелек сыйфатларына ия Кеше образын расласын, шуның өчен көрәшсен иде. Югыйсә хәзер Рәсәй сәясәтчеләре дә, Америка үрнәгенә ияреп, күбрәк физик көчне генә танымакчылар бит! Бөтен бәхәсле мәсьәләләрне бары тик физик көч ярдәмендә генә хәл итмәкчеләр. («Будем мочить!» дигән девиз белән.) Ә шул ук вакытта үзләре: «Каян килеп чыга бу терроризм?» — дип аптыраган, гажәпләнгән кыланалар! Соң, бәхәсле мәсьәләләрне гаделлеккә таянып һәм сөйләшү-аңлашулар ярдәмендә, бары тик шулар нигезендә хәл итәргә теләмәгәч, каршы якны бөтенләй тыңларга да, ишетергә дә теләмәгәч, әлбәттә, терроризм килеп чыга инде ул!

Биредә, әдәбият турында сүз барганда, сәясәткә кереп чыгуның максаты шул иде: без, безнең халык аларга каршы бары тик рухилыкны гына куя ала. Ә физик көчкә генә таяну исә аерым шәхесне дә, илне дә, тулаем дөньяны да бары тик тупикка гына алып бара. Ул — терроризмны барлыкка китерү һәм аны даими үсендереп, дәртләндереп тору юлы. Безнеке кебек чагыштырмача күпсанлы булмаган милләтләр өчен ул бигрәк тә ялгыш һәм куркыныч юл.

Безгә исә бүген әдәбият аша гына түгел, ә бөтен матбугат һәм радио-телевидение аша, рухи яктан бай, гармоник үсешкә ия Кеше тәрбияләү эшен оештырып җибәрәсе иде. Ягъни яшьләрне дә, тулаем милләтебезне дә рухи-әхлакый яктан тәрбияләү турында сүз бара биредә. Совет хакимияте елларында һәр мәктәптә һәм җәмәгать урыннарында «Коммунизм төзүченең әхлак кодексы» эленеп тора иде бит әле. Шуларны тормышка ашыру буенча байтак кына чаралар да үткәрелә иде. Бу яктан караганда «Идел» журналында быел январь аеннан башлап басыла килүче «Татарның әхлак кодексы» (аны Т.Миңнуллин алып бара) һәр яктан хуплауга лаек. Инде хәзер мондый эшне республика күләмендә әһәмиятле программа буларак кабул итәргә һәм төрле оешмаларны (иҗат берлекләрен дә кертеп) колачлаган системалы чаралар рәвешендә тергезеп җибәрергә кирәк.

Заманыбызның уңай героен тәрбияләп үстерү — әдипләребезнең генә түгел, ә бөтен җәмгыятебезнең уртак максатына әверелсен иде.

2004

Тәкъдир юллары

Бүген безнең өмет һәм ышаныч тулы карашларыбыз татар әдәбиятының проза тармагына юнәлгән...

Ә ни өчен нәкъ менә прозага?

Иң башта шушы сорауга җавапны ачыклап китик.

Проза тармагының аерым бер игътибарга дучар булуына иң төп сәбәпләрдән берсе шулдыр: соңгы дистә елларда илдә вакыйгалар бик тә куерып китте, адәм балаларының язмышлары да нык кына катлауланды, алар алдына килеп баскан четерекле хәлләр, ситуацияләр күбәйде. Россиядә бер иҗтимагый формациянең икенчесе белән алышына башлавы үзе генә дә ни тора! Кеше өчен никадәр психологик кичереш дигән сүз бит бу!

Менә шушы вакыйгаларны, аларның дәвамлы драматизмын, кеше язмышларына тәэсирен бары тик киң колачлы проза әсәрләре генә хәрәкәттә, үсештә күреп һәм тирәннән алып чагылдыра, тасвирлый ала. Безнең әдәбият сөюче замандашларыбыз, үзләренең әйләнә-тирәләрендә күпләгән гыйбрәтле язмышлар күргәннән соң, чын йөрәктән әрниләр һәм еш кына, четерекле хәлләрдән чыгу юлларын эзләгәндә, үзләренә рухи ярдәм, күп кенә сорауларга җавап көтеп, кеше күңеленең инженерлары булган

әдипләргә күз текиләр икән — биредә, әлбәттә, иң беренче чиратта, прозаик әдипләр, алар иҗат итә торган роман һәм повестьлар күздә тотыла.

Шушы ук сәбәпкә ялганып, аның белән органик рәвештә тоташып китә торган тагын бер фактор: безнеке шикелле буталчык, адаштыргыч елларда — тормышның полюслары алышынган елларда — кеше үзен еш кына куе томан эчендә яисә сазлыкта калгандай тоя һәм үзенә күңел тынычлыгы, ышаныч бирердәй рухи көч, мохит, яшәеш дөньясын кирәксенә. Кеше җанын, күңелен шактый гомер биләп тора алучы, аны байтак вакыт билгеле бер образлар, каһарманнар арасында яшәтә алучы рухи дөнья, әлбәттә, шул ук проза әсәрләре.

Проза тармагының хәзер аерымрак, үзгәрәк хәлдә калуына тагын бер сәбәп: татар әдәбиятының шигърият һәм драматургия өлкәләре, күз тимәсен, әлегә әйбәт кенә үсеш кичерә. Ә менә проза тармагы турында әле андый сүзне әйтүе кыен. Соңгы дистә елларда проза әсәрләренең сыйфат ягы шактый түбәнәйде. Аның конкрет сәбәпләре (тормышта тотрыклылыкның — басылып һәм чын профессиональ кимәлдә иҗат белән шөгыльләнү өчен кирәкле рухи-әхлакый климатның югалуы, җәмгыятьнең әдәбиятка булган игътибары кимү, проза тармагында зур тәҗрибә туплаган талантлы өлкән буынның китүе, бары тик иҗат белән генә шөгыльләнергә мөмкинлек бирердәй каләмхак түләнмәү һ.б.) турында безнең матбугатта инде байтак кына сүзләр булды. Ләкин хәлне аңлау һәм аңлату белән генә проза тармагын тиз арада үстерү, аны башка жанрлар янәшәсендә күрү мөмкин түгел шул.

Үткән XX гасырда татар прозасының бөтен дөнья күләмендә мактана алырдай сәнгати-фәлсәфи казанышлары булу һәм әлеге йөзьеллыкның ахырына таба прозабызның ул биеклекләрдән түбәнәюе, еш куандыра алмавы да бу тармакны укучылар каршында үзгә хәлгә — «бурычлы» хәлгә куя. Элегрәк татар прозасының татлы җимешләрен татыган укучының соңгы елларда да аннан тиешле рухи җимешләр көтәргә хакы бар, әлбәттә.

Әйе, югарыда санап кителгән һәм әле әйтеп бетерелмәгән башка кайбер сәбәпләр аркасында бүген безнең прозага карата әнә шундый аерым бер мөнәсәбәт хасил булды. Газета-журналларда басылган яисә нәшриятларда аерым китап булып дөнья күргән проза әсәрләрен әнә шуңа күрә без аеруча зур өметләр белән кулга алабыз.

Марат Әмирханов — үткән елларда безне «Гөлнәзирә», «Дөя муены» һәм башка повестьлары белән сөендергән язучы. Аның соңгы елларда иҗат ителгән «Тәкъдир» романы, «Казан утлары» журналында басылып чыккач, кызыклы фикерләр уяткан иде. Менә хәзер шул роман Татарстан китап нәшриятында матур гына бизәлештә дөнья күрде.

Әсәр, роман диеп аталса да, күләм ягыннан артык калын түгел — 13 нәшер-хисап табагын тәшкил итә. Килешегез: бүгенге су буе романнар белән чагыштырганда, бу инде «түзәрлек».

Хәзер кыскача гына романның эчтәлеге белән танышып үтик.

Студент чагында танышып өйләнешкән Мансур белән Җәмилә Корбаш дигән бистә мәктәбендә укыта башлыйлар. Әсәр геройлары тормышы белән яшәп, без җитмешенче еллар мәктәбенең типик күренешләре белән очрашабыз. Биредә татар теленең кысыла баруы да, яңа алым дигән булып техник чаралар белән артык мавыгу да, авыл укытучыларының урындагы эреле-ваклы җитәкчеләр тарафыннан кирәксә дә, кирәкмәсә дә төрле эшләргә тартылуы да, укытучылар арасында булгалап тора торган гаугалар да — барысы да бар. Романның бу битләрен укыганда, без авторның үзенең дә электә педагог булуына ышанабыз, ул мәктәп тормышын, укытучы дөньясын эчтән дә, тыштан да нык белеп, аңлап, кичереп яза.

Төп геройның, мәктәпкә килү белән балаларга белем бирүдә генә тукталып калмыйча, аларны яхшы кеше дә итәргә тырышуы, мисал өчен, мәктәптә тәмәкегә каршы көрәш башлап җибәрүе күңелгә хуш килә. Бу уңайдан Муса исемле яшүсмер һәм аның тол калган әнисенең язмышы да дулкынландыра, истә кала. Коллективтагы карт кызларга бәйле күренешләр дә Мансурның холык-табигатен ачуда уңышлы роль уйный, тиешле тәэсир тудыра.

Романның сюжеты алга таба үсә барган саен, яшь гаилә өстендә фаҗига болыты куера — Җәмиләдә яман авыру билгеләре табыла... Күп кешегә хас булганча, яшь хатынның башта моңа исе дә китми, ә аннары, эшнең ни дәрәҗәдә җитди икәнен аңлап алгач, Җәмиләнең эчке дөньясында туган үтә киренке хәлне, олы фаҗигане, аның үзен кая куярга да белмичә газаплануын тасвирлаганда, автор каләм иясе буларак кына түгел, ә олы фаҗига белән күзгә-күз очрашкан нечкә күңелле кеше буларак та, укучы зиһенен һәм игътибарын биләп, аны үзеннән аермыйча алып бара.

Мансурның шәхсән үз юлында да уңышсызлыклар килеп чыга: кафедра җитәкчесенең гаебе белән ул диссертациясен яклый алмый, мәктәптә дә өлкән сыйныфларны урысча укыта башлыйлар... Безнең герой, үзенең яраткан эшен калдырып, журналистикага күчәргә мәҗбүр... Җәмилә исә операциягә керергә тиеш... Аның бер күкрәген кисеп алалар. Хатын-кыз өчен бик зур тетрәнү булган бу вакыйганы тасвирлаган битләр һәм әлеге хәлнең ир-атка тәэсире — аеруча зур тәэсир көче белән язылган.

Ул арада гаиләнең бердәнбер һәм сөекле баласы — кызлары Ләйсән үлеп китә. Яшәү газапка әверелә, алар хәтта икесе бергә дөнья белән хушлашырга да уйлый — бу адымнан дуслары гына саклап кала.

Әмма ахыр чиктә яман авыру Җәмиләне барыбер җиңә... Мансур әсәр ахырында ялгызы кала...

Роман менә шундый фаҗигале аһаңнәр белән тәмамлана... Кеше, яраткан хатынын һәм газиз баласын югалтып, Җир йөзендә берүзе, берьялгызы торып кала... Ләкин автор тормыш чынбарлыгына хыянәт итми, адәм балаларына салынган яшәү көченең күңел төпкелләрендә көйрәп яткан күмерләренә ул өмет тулы күзләр белән бага: вафат булган Җәмиләнең сеңлесе Рәхиләнең назлы һәм кешелекле йөрәге аша җылытмакчы була дөнья Мансурны.

Романның соңгы битләрен япкач, күңелдәге тирән моңсулык аша бер зур һәм җитди сорау калка:

— Әсәр белән танышу безгә нәрсә бирде? Ул безнең рухыбызны ни дәрәҗәдә баетты?

«Тәкъдир» романы үз битләрендә җитмешенче елларның тормышын гына түгел, ә шул чорда тәкъдир куйган сынауларын уза-уза, намусларын пычратмыйча яшәргә омтылган шәхесләрне сурәтли. Әсәрнең төп каһарманнары булган Мансур белән Җәмилә, иң беренче чиратта, эшчән һәм намуслы гаиләдә үскән авыл балалары итеп бирелә. Язучы аларның туып үскән якларын да шигъри чагыштырулар аша сурәтли. Туган өйгә кайту бәхете һаман болай бирелә: «Мансурның күңеленә балачакны хәтерләтүче ниндидер саф, аһәңле, моңлы тавыш иңде. Сихри, җылы, йомшак, ләззәтле тавыш. Ул аның җанын, тәнен, рухын берьюлы биләп алды. Бишектә тибрәлгәндәй тибрәлде. Өнме бу, төшме, йоклыймы ул, уяумы? Ләкин ничек булса да Мансур бу халәтнең озак, бик озак дәвам итүен тели».

Төп геройның намуслы булып үсүен автор романда тагын бер яктан сипләп, нигезләп куя — ул затлы нәселдән икән: «Һы, кара син аны, мулла нәселеннән икәнен оныткан икән шельма малай. Бабай Әмиржан да бик гыйлем кеше ие. Искечәне дә, яңачаны да су кебек эчә иде. Эткәсе, минем каенатам Әкрам картның туганы Әхмәтҗан абый, сәүит вакытында да хәдрәт булып торды әле. Халык бик ярата иде. Себергә сөреп кенә башын ашадылар...» Геройның әнисе Мәдинә апа менә шундый сүзләр белән үз улына нәселен искә төшерә. Җәмиләнең әтисе Нурулла абзый исә әсәрдә елдамлык, хәрәкәтчән эш-мәкәрлек мисалы итеп бирелә.

Ләкин роман каһарманнарына бүтән төрле затлар белән очрашырга, эш итәргә туры килә. Менә мәктәптәге рус теле укытучысы Фирая Сабировна:

— Бөек рус телен, Пушкин, Маяковскийлар телен мин соңгы сулышыма чаклы пропагандалаячакмын!

Педсовет утырышында әйтелгән шушы кыска гына бер җөмләдә никадәр ышаныч, пафос, усаллык, ярсу һәм... һәм — ялагайлык! Олы ялагайлык, чөнки җитмешенче елларда яшәүче бу ханым илдәге көчнең кемнәр кулында икәнен бик яхшы белә. Һәрбер тармак буенча (бигрәк тә идеологиядә) орден-медальләрнең дә иң башта кемнәр түшенә менеп кунаклавын бик яхшы аңлый. Ләкин менә бүтән милләтләрнең дә Тукайлар, Райнислар, Байроннар кебек бөек шагыйрьләр тудыра һәм үстерә алуын ул ни өчендер «оныта». Бер генә телне яшәтеп калдырырга теләүнең «табигатьтә бары тик бер генә агач калсын» дигән омтылыш сыман ук ахмак идея булуын ул чагында (һәм әле хәзер дә!) бик күп «акыллы» кешеләр оныттылар шул!

Югары уку йортына керә алмавы аркасында мәктәпне гаепләп үпкә хаты язган Гүзәл исемле кыз сәбәпче булган әлеге вакыйга безнең бүгенгебез өчен дә үтә актуаль түгелмени?! Югары белем бирү үз телебездә булмагач, бүген дә бик күп әти-әниләр үз балаларын татарча укытудан баш тарта бит! Әле һаман шушы ук «таш кыя»га килеп төртелә бит милләтебез корабы!

Шул уңайдан романда бирелгән мәгариф министры образы да кызыклы. Ул, урыннарда булганда, укытучылар белән очрашкан чакларында, үзен бик гади, чын кешеләрчә тота, алдынгы карашларны чын күңелдән яклый, җирле түрәләрне тәнкыйтьли, чибәр-чибәр укытучы кызлар белән шәхси «дуслык» та урнаштыра, милли мәсьәләдә дә «үзебезнеке» булып күренергә тырыша... Әмма шул ук вакытта бу министр әфәнде әкрен-әкрен рус мәктәпләрен, сыйныфларын да күбәйтә бара. Башкаладагы зур түрәнең менә шушындый «ике яклы пычак» булуы романда бик реаль рәвештә һәм ышандырырлык итеп тасвирлана.

Тагын бер түрә, өлкә комитетында бүлек мөдире урынын биләүче Сафа дигән тип, элеккеге танышы Мансурга болай ди:

— Мансур иптәш, без агай-энеләр белән ресторанда утырмыйбыз. Бу — обком! Монда фәкать эш турында гына сөйләшәләр. Сез дә эш буенча чакырулы...

Сафа бераздан болай дип тә дәвам итә:

— Мөштәри, Камай ише милләтчеләргә без партия матбугатында урын бирә алмыйбыз!

Совет империясендә урнаштырылган әнә шундый сәяси һәм рухи климат романдагы һәрбер геройның яшәешендә чагыла. Төп каһарман Мансурныкында бигрәк тә. Яшүсмер вакытта, күрше авылга йөреп укыганда ук, аның куркып калуы әсәрдә хәтта аллегорик мәгънә дә ала. Аның бөтен рухын әлеге кышкы кичтә очраган өрәкләр басып, изеп тора сыман. Чыннан да, безнең барыбызны да кечкенәдән үк «сүзне тыңламасаң, тәртипле булмасаң — урыс апкитәр!» дип өйрәттеләр бит! Яшүсмернең башта авылда ук куркып калуы, аннары яраткан эшенә — туган телен укытырга керешкәчтен, тулы бер система тарафыннан кысылуы, диссертациясенең дә яклана алмавы, шәхси тормышындагы бүтән фаҗигаләр — боларның барысы да романда тирән мәгънә ала. Чын ирекле ил, ирекле яшәү, туган телеңнең ирекле халәте хакында янәдән-янәдән уйландыра.

Ә шулай да бу романдагы иң зур мәгънәгә ия аллегорик образ ул — Тума кош. Ягъни җитлекмичә туган бала символы. Тумакау романның беренче битләрендә үк күренә һәм, әсәрне укыганда, ара-тирә искә төшә-төшә, үзенчә бер мәгънәви фон ясап, ахыргача озата бара... Әсәрнең иң соңында мондый җөмлә бар: «Тагын алты айдан баш очындагы Тума кошның канатлары киселеп төште».

Романның беренче битләрендә Зур Авыл мулласы әйткән менә мондый сүзләр дә бар иде бит әле:

— Тума үлмәсә, илгә бәла кала!

Шулай итеп, романда сурәтләнгән җитмешенче еллар тормышы һәм әсәрдә геройларны баштан алып ахыргача озата барган Тума кош — җитлекми туган бала образы — сәнгати һәм фәлсәфи яктан төгәлләнү таба. «Җитлеккән социализм» белән «җитлекмәгән бала» бергә килеп ялгана. Һәм менә шушы тоташу, мәгънәви ялгану фонында геройлар башыннан кичкән фаҗигаләр...

Ләкин шуның белән бергә Тума кош уңаеннан күңелдә бераз гына шикләнү дә бар: романга бик уңышлы кереп урнашуга карамастан, укучы аны аңлап, төшенеп җитәрме икән? Автор, билгеле, бу идеяне бәләкәй кыз Ләйсән язмышы белән дә көчәйтә һәм ассызыклый ассызыклавын — ул да елан елында һәм җитлекмичә туа, шулай ук иртә вафат була... Боларга да карамастан авторга, бәлки, әлеге мәгънәне тагын да ныграк ачу юнәлешендә тагын бер-ике киная кирәк булгандыр диясе килә.

Минемчә, «Тәкъдир» романының мәгънәви яктан тирән һәм актуаль эчтәлеккә ия икәнлеген раслау белән бергә, шулай ук аны сәнгати яктан тагын да камилрәк итүдә файдаланып бетерелмәгән урыннар калган әле.

Романның беренче бүлеге сугыш башланган елның печән өстенә, печән өмәсенә багышланган. Гәрчә бу Җәмиләнең туган елы һәм автор алган идеягә булыша торган елан елы булса да әйтмичә кала алмыйбыз: ул елның печән өмәсе безнең әсәрләрдә йөзләгән мәртәбә язылды бит инде! Җәмиләнең елан елында һәм җитлекмичә тууы, минемчә, тәэсирлерәк итеп, бүтәнчәрәк бирелергә тиеш иде романда.

Шулай ук төп герой Мансурның үз диссертациясенең яклана алмаячагын белгәч, аңа телефоннан шылтыратып кына мыскыллавы ничектер бу образның романда без белгән холык-табигатенә ят сыман тоела. Аннары, гомумән, фәнни эш бу кеше өчен артык мөһим дә түгел бит әле. Без Мансурның яшәешендә диссертациягә бәйле уйларны, фикерләрне, проблемаларны бөтенләй күрмибез дә диярлек.

Романны укыганда бик тә «тешкә тия» торган тагын бернәрсә бар, ул да булса әсәр тукымасына һич тә ябышмый торган публицистик стильнең килеп керүе. Китапның 17 нче битендә мондый сүзләр урын ала: «Шулай булмыйча, нинди иләк аша узды бит. Бик нык сайладылар. Гимнастика белән шәһәр кызларыннан күпкә соң шөгыльләнә башлаган Җәмилә өчен бу киртәне үтү җиңел булмады. Көч күп сарыф итүне сорый торган снарядларда ул үзен иркен хис итә. Бу яктан аны уздыручы юк. Ә менә сыгылмалылыкта башкалардан калыша. Шуңа күрә әлеге аерманы бетерү, һич югы, киметү өчен һәр мөмкинлектән файдаланырга тырыша... Спортка кагылышсыз каршылыклар да килеп чыкты».

Алга таба китсәк, 37 нче биттәге: «Мирзанур Мостафин алтмышынчы еллар дулкынында күтәрелгән демократик карашлы кеше...» — дип башланып киткән абзац исә нәкъ менә шушы коры рухта бара һәм китап битенең яртысын алып тора! Мондый урыннар китапның беренче яртысында аеруча күп очрый һәм кәефне кыра.

Ә бит романда безне шигърилеге, тәэсир көче белән сокландырган менә мондый урыннар да бар: «Тел өсте баллы булса да, тел асты тозлы икән апабызның» (38 бит), «Бәхетленең көймәсе корыдан йөри» (57 бит), «Төртмә кода, үзем беләм, үлсәм дә хак сүземне әйтеп үләм» (62 бит), «Язбикә үзе дә хатын-кызга Зөһрә сылуның затлы шәлен яба. Хатын-кыз күзгә күренеп нурлана, мөлаемлана, чибәрләнә, атлап йөрүләре үк үзгәрә. Бөреле агачтай эче-тышы мәхәббәт суты белән тула...» (92 бит), «Җәмилә, җил җилфердәткән ефәк шәл шикелле, янә иренә уралды» (135 бит) һ.б.

Менә шушындый чын әдәби тел белән яза алган авторның әсәренә алдарак күреп киткән җөмләләр ни өчен килеп кергән микән соң?

Күрәсең, мондый очраклар соңгы елларда безнең прозада шактый еш күзәтелә торган бер тенденциянең типик чагылышы булып тора. Беренче чиратта, әлбәттә, авторның үз-үзләренә, үз ижатларына таләпчәнлеге кимү дип әйтергә туры килә. Аннары, әдәби жанрларның үзара кушылып китүе турында матбугатта күренгәләп ала торган фикерләр дә кайсыбер каләм ияләренә аклану өчен җирлек, нигез бирә кебек. Озын-озын шигырьләрне «поэма» дип билгеләп редакцияләргә алып килү дә әнә шул тенденциянең начар бер җимеше шикелле. Роман һәм повестьларда исә бу «авыру» сюжет җебенең ныклы булмавы, эчтәлекнең көпшәклеге һәм нәтиҗәдә әсәрләрдә күләмнең бүселүе, башка әдәби җитешсезлекләр булып чагыла.

Марат Әмирхановның без сүз алып барган «Тәкъдир» романында әлеге җитешсезлекләр күп күренә дип әйтә алмыйм, әмма вакыйгалар чылбырын төзегрәк һәм киеренкерәк итү, шул максаттан диссертация җитәкчесе Габбас Ярмиевич кебек кайсыбер кирәкмәгән персонажлардан арыну турында ныклап торып уйларга җирлек бар.

Ә роман хәтле роман турындагы бу кыскача сүзгә йомгак ясап әйткәндә, ул үткән гасырның җитмешенче еллары тормышының социаль һәм рухи-психологик панорамасын җанландыруда җитди бер

адым булып тора. Марат Әмирханов каләменең «роман» дип аталган җитди жанрда тәҗрибәсе һаман арта баруын, эпик әсәрләр иҗат итүдә торган саен уңышлырак адымнар ясавын раслый.

Ә күңел... Ә күңел дигәнең исә безнең проза жанрында Әмирхан Еникиләрнеке, Мөхәммәт Мәһдиевләрнеке шикелле онытылып, сәнгать көче белән чын-чыннан тылсымланып укырдай әсәрләр көтә. Без биредә сүз алып барган Марат әфәнде Әмирхановның үз иҗаты белән әлеге әдипләр янәшәсенә басарга бөтен мөмкинлеге дә бар.

2004

Җан яралары

...1957 ел. Әле генә үтеп киткән зур сугышта үзенең Муса Җәлиле һәм аның көрәштәшләре батырлыгы белән, Газинур Гафиятуллин һәм тагын йөзләгән егетләр каһарманлыгы белән дан казанган татар халкы, Мәскәүдә декада уздырып, милләтнең рухи һәм иҗади якта да көчле икәнлеген бөтен илгә күрсәтергә тели. Шундый олы максат белән әсәрләр сайлаганда, драматург Юныс Әминевнең Минзәлә театры тарафыннан уйнала торган «Язылмаган законнар» спектакленә тукталалар. Һәм аны сайлап ялгышмыйлар — Мәскәүнең таләпчән тамашачысы спектакльне бик тә җылы кабул итә. Әсәрнең тормышчанлыгы, күтәрелгән әхлакый мәсьәләләрнең кеше күңеленә бик тә якын булуы зур уңышка китерә.

Драматургның «Тамырлар», «Өти балак», «Гөлҗәннәтнең җәннәте» һәм башка әсәрләре дә алтмышынчы, җитмешенче елларда һәм аннан соңрак та республикабыз театрлары сәхнәләрендә уңыш белән бара. Татар әдәбиятының күренекле әһелләре драматург Юныс Әминев иҗаты турында түбәндәге матур фикерләрне язып чыгалар. «Миңа калса, бүгенге драматургиядә яшьләрнең иң ышанычлысы — Юныс Әминев. Аңарда сәхнә кешеләре — характерлар бар, аңарда халык аңында меңәр ел дәвамында чарланган бик үткен тел бар, аңарда тормыш чынлыгы бар» (Нәкый Исәнбәт. Ватаным Татарстан.— 1993.— 24 март). «Кеше күңеленең нечкәлекләрен белеп язу — иң авыры. Бу авыр һәм мактаулы хезмәтне Юныс ага Әминев башкарды. Ул аз сүзле кеше. Сүз юктан сүз булсын өчен генә теләсә нәрсә сөйләп утырырга яратмады. Ә очрашып сөйләшәсең икән инде, үзеңнең дә күңелең йомшарып, эченә җылы керә» (Туфан Миңнуллин. Ялкын.— 1971.— № 12). «Юныс Әминев 30 еллык иҗат гомерендә зур мирас калдырды. Егермедән артык пьеса язды, җыр текстлары иҗат итте, мәкаләләр, очерклар, чыгышлары белән әдәби процесста актив катнашты» (Азат Әхмәдуллин. Социалистик Татарстан.— 1991.— 30 ноябрь).

Әйе, гомеренең икенче өлешендә әдип әнә шундый зур уңышларга иреште һәм татар әдәбияты тарихында онытылмаслык якты эз калдырды. Әмма Юныс Әминевкә башта бик зур кыенлыклар аша узарга туры килә. Сугышта контузия алып әсир төшкән Юныс аганы түрәләр: «Син әсирлектә булган!» — дип, адым саен мыскыллый, түбәнсетеп тора. Гәрчә Юныс ага, әсирлектән котылганнан соң яңадан үзебезнең гаскәрләр сафында сугышып, илгә җиңү яулашып йөрсә дә!

Драматург Юныс ага Әминевнең хәзерге вакытта Әлмәт шәһәрендә яшәүче җәмәгате Фәһимә апа язган истәлектә әдипнең сугыштан соңгы әнә шундый авыр чоры яктыртыла. Әгерҗе районының Баржы авылында әйбәт кенә балалар укытып йөрегән Юныс аганы авыл советындагы бер әшәке кеше әләкләве аркасында яраткан эшеннән чыгаралар һәм ул, мәктәптән, туган ягыннан аерылып, ерак Пермь якларына эш эзләп китәргә мәҗбүр була. Бик күп татар әдипләре сөрелгән якларга... Әнә шул яклардан Юныс ага Фәһимә апага менә мондый ялкынлы шигъри хатлар яза.

Чиккән хәсрәтләреңә, кайгыларың
Миннән күбрәк икән, күз нурым.
Киләчәкне бергә итәрбезме,
Ходай биреп безгә бер урын.
Кавышканга әле кичә генә,
Бүген инде аерым яшибез.
Күздән сыгылып ага башлады
Кибеп өлгермәгән яшебез.
Нигә шулай һаман кире килә,
Ник якты юк безнең юлларга?
Һичкемгә дә зыян китермәдек,
Ярдәм иттек мөмкин булганда.
Олыларны зурлап эндәштек,
Кечеләрне туктап сөйдек без.
Үз көчебез белән гади
Һәм тук тормыш тели идек без.
Киләчәкне әле беркем белми,

Үткәннәре — авыр, караңгы...
Бүгенгесе сасы зиндан кебек,
Туктарбызмы шулай —
баралмый...
Хәерле булсын!
Җаным яна, бәгърем әрнеп корый,
Эчем поша, сүнәм, бетәм мин.
Җәберләнгән килеш, әрни-әрни
Туган илкәемнән китәм мин.

* * *

Көннәрем тыныч хәзергә,
Икмәгем дә алдымда.
Әмма сине сагыну хисе
Дулап ага канымда.
Күрсәм әгәр сине минут
Кочар идем санамый.
Карар идем йөзләреңә,
Күзләремне алалмый.
«Икмәк» дидем, эзләдем мин.
Аны таптым, алдымда.
Тик ярсыган күңел һаман
Сине өзелеп сагына.
Син булмагач, тамагым ач,
Толып киеп өшим мин.
Өзелеп сөйгән җан дустымнан
Ничек аерым яшим мин?!
Пар булып бергә яшәсәң,
Тормыш гөл һәм ал икән.
Кабарга икмәк булмаса да,
Бергә яшәп кал икән!
Ник җылытмый җирне кояш,
Ник бу төннәр айсыз соң?
Ник бу кадәр җанга авыр,
Суларга уңайсыз соң?
Чөнки мин Барҗыны сөям,
Анда минем алтыным.
Аның белән бергә калган
Йөрәктәге ялкыным.

Чит җирләрдә бүтән түзә алмыйча шул елның декабрендә Юныс ага Барҗыга кайта. Ул чагында инде мәктәп директоры да яңа кеше — үзе дә сугышта катнашкан һәм үз сүзен әйтә белә торган, үз принципларын яклый белә торган Хәким Солтанов. Ул булачак әдип Юныс Әминевне, әсирлектә булуына карамастан, мәктәпкә укытучы итеп ала. Әнә шул елдан башлап авылны су басканчыга кадәр Юныс ага безнең Барҗы урта мәктәбендә балалар укытты, бик күп җәмәгать эшләре алып барды. Шулар өстенә әле, әдәби иҗат түгәрәге оештырып, анда безнең белән шөгыльләнергә дә вакыт тапты! Ә төннәрен, ялгызы калып, үзенең гүзәл әсәрләрен иҗат итте ул!

Юныс Әминев драмалары һәм комедияләре бүген дә күпләгән театрларыбыз сәхнәләрендә уйнала, басылып чыккан китаплары халык тарафыннан яратып укыла. Ә үзенең якты образы, күңелләрне җылытып, гел безнең күз алдыбызда тора. Чыннан да, олы әдип һәм сизгер җанлы, бик ярдәмчел, кешелекле Шәхес иде шул ул Юныс абый!

2001

«...Мәңгелек дип гүя пышылдый»

Язучылар арасында шундый бер кыйсса йөри. Рафис Корбанның яңа гына Казанга укырга килгән елында ул тулай торакта Хәйдәр дигән озын гына бер егетнең күршесендә яшәгән.

Хәйдәр көн саен, стена аша ишетелерлек итеп, «Кор-ба-нов!»— дип кычкырып, Рафисны бүлмәсенә чакырып кертә икән.

Бәләкәй генә, буе җирдән метр ярымнан чак кына өскәрәк күтәрелгән Рафис, курка-курка гына моның бүлмәсенә кереп:

— Нәрсә бар, Хәйдәр абый? — дип сорый.

— Дөньяда барлыгыңны гына белергә теләдем. Берни дә юк, бар, бар, дәресеңне әзерлә,— ди Хәйдәр.

Әмма бермәлне... Әмма бер көзне Хәйдәр дигән әлеге егетебез тәмам хәйран кала.

Сентябрь башы, студентларның әле генә авыллардан килгән чагы була бу. Элекке гадәтенчә күрше бүлмәгә карап, боерган тавыш белән аваз сала Хәйдәр:

— Корбанов!

Көтә Хәйдәр, әмма җавап юк. Тагын бер мәртәбә кабатларга туры килә моңа:

— Корбанов, дим мин!

Һаман тынлык — ым-шым ишетелми. Тик тагын бераздан гына Хәйдәрнең ишеге ачылып китә дә бусагада бер пәһлеван гәүдәсе пәйда була:

— Кем шаулый анда?!

Хәйдәр, ишектән керүче бу егетне күрүгә, шундук һушыннан яза! Чөнки... Чөнки ишек авызында бер җәй эчендә великандай үсеп, калынаеп киткән, тавышына ирләр ныклыгы иңгән Рафис Корбан басып тора!

Бу кыйсса чыккан еллардан соң инде әллә никадәр вакыт узды, тормышлар да байтак яктан үзгәрде, өметләребез дә бер яңарды, бер сүрелде, әдәбият мәйданында да шактый гына кызыклы яңалыклар булып алды — ләкин теге яки бу уңайдан «Рафис Корбан» дип әйткәндә, әлеге кыйсса килә дә төшә, килә дә төшә искә! Бусы һич кенә дә үзгәрми менә!

Чыннан да, хәзер безнең әдәбиятыбызда да әлеге кыйссадагы кебек бер күренеш күзәтелә түгелме соң? Без күп еллар буена «сәләтле балалар шагыйре» диеп йөреткән Рафисыбыз соңгы чорда үз иҗатында җитди үзгәрешләр кичереп, чын шагыйрь булып үсеп җиткән түгелме соң?! Тәмам «пешеп», өлгереп җиткән түгелме соң ул?! Аның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Яра» исемле шигырьләр җыентыгындагы әсәрләр белән танышу миндә әнә шундый тәэсир калдырды.

Шагыйрьнең кемлеген, ниндилеген яхшырак аңлар өчен, әйдәгез, иң еш кабатланган темага — Сабан туе темасына язылган шигырьгә мөрәҗәгать итик:

Соңгы көрәш менә, ләкин билдән кысып
Алучы мин булмасам да һич көрсенмим.
Шул батырны, сөкланып көч-кодрәтенә,
Зурлап күккә чөйгәннәрнең бит берсе — мин!

Менә шушы дүрт юлда Рафис Корбан шигъри «мин»енең характеры, табигате шактый ук ачык чагыла. Дөрестән дә, ул сикереп алга, уртага чыгарга бик үк яратмый, әмма аның йөрәге, күңеле һәрчак көрәшчеләр янында, көрәш мәйданында! Равил Фәйзуллин да үзенең бер шигырендә әнә шундый нечкә, әмма тирәндәге бәйләнеш турында болай дип язган иде бит әле:

Куллардан бигрәк җан белән
Бәйләнгән без балачакның
Әйләп-бәйләннәренә.

Шуның шикелле, Рафис Корбан да җаны, йөрәге белән һәрчак көрәшчеләр, тынгысызлар, фидакарьләр арасында яши. Ә бу шигырь исә безгә үзенә бертөрле әхлакый сабак та бирә кебек. «Син үзеңнең көрәшчеләреңне гел күз уңында тот, аларның кадерен бел, аларга тиешле хөрмәтен дә күрсәтеп бар»,— ди кебек ул. Татар халкының соңгы гасырлардагы таркаулыгы һәм иң мөһим чорларда бердәм була алмавы турында уйлаганда, мондый фикер тагын да актуальләшә төшә. Бу шигырьнең лирик герое исә мәйдан тоткан көрәшчегә сокланып карый, аның белән горурлана. Кайсыберәүләр кебек ул кеше уңышына көнләшми, көенми. Яшьләребезне дә менә шушындый матур үрнәкләр яктылыгында киң күңелле итеп тәрбияли алсаң, бәлки, киләчәктә безнең татар милләте дә тар күңеллелектән, хөсетлектән арынып, үсеп, күтәрелеп китәр әле? дигән оптимистик уйлар туа, бу шигырьне укып чыкканнан соң хискичерешкә бирелеп утырганда.

Әйе, бу китаптагы иң мөкатдәс, иң җитди уйлар халык, милләт турында. Казан Кремлендә йөрегәндә Рафис Корбан болай уйлана:

Ачсаң монда ишекләрне
Ханнар чыгар күк килеп.

Ә хәзерге Татарстан картасын ул менә мондый сүзләр белән күзли:

Һай кысыла, кысыла йөрәгем,
Кысылгандай синең чикләрең.
. . . . . .
Татарстан — йөрәк ярам минем,
Төзәтергә сине юк чарам.

Бүгенге чынбарлык, милләтнең хәзерге яшәеше китапта күз алдында калырдай күренешләр булып җанлана. Бер яктан:

Бишек җыры — иң бөек җыр җирдә,
Гомерләрне башлый безнең ул.

Ә икенче яктан исә чиркәү чаңы гел яңгырап тора:

Ил өстендә бүген ачы көлү!
Чикләр дә юк аңа, киртә дә.
Бүген ул — чаң... матәм маршы булып,
Ул яңгырар сыман иртәгә...

Әнә шундый киң масштаблы сәяси һәм социаль күренешләр белән бергә китапта гап-гади авыл эпизодлары да урын ала, әмма шунысы мөһим: шагыйрь боларыннан да тирән фикер, зур мәгънә чыгара ала:

Мин дә, әти, синең арттан барам,
Уйлый күрмә туктап калырга.

Яисә менә мондый строфа:

Ә бер көнне арып, хәлдән таеп
Кайтып аусак туган нигезгә,
Салмак кына Ашыт агып ята,
«Ашыгып ни кырдың?» — дип, безгә.

Мәхәббәт турында язганда да шагыйрь үзенең төп холкына хыянәт итми.

Һаман да шул мин, кыюсыз.
Ләкин кайбер кыюлар
Сөю юк, дип кычкырганда,
Кабатлыйм:
Бар сөю, бар!

Биредә дә без чын ир-ат холкына хас булган сабырлыкны, түземлекне, әмма принципиаль сүз яки бәхәс чыккан очракта иң әһәмиятле саналган үрләрне яклап көрәшә, сугыша алырдай затны да күрәбез. Р.Корбанның мәхәббәт лирикасында аеруча истә кала торган шигъри табышлар да бар. Менә шулардан берсе:

Яши идем туган ягымда мин,
Тыныч кына үскән тал кебек.
Талга оялаган сандугачтай,
Күңелемә урнаштың кереп.

Нурга тулы, моңга тулы хәзер
Минем өчен таңнар-иртәләр.
Кешеләр дә миңа карап, гүя,
Сандугачлы тал, дип үтәләр.

Кеше күңеленә оялый торган сөю, мәхәббәт хисе әнә ничек матур итеп әйтеп бирелгән шигырьдә! Әсәрдә кулланылган шигъри детальләр, образлар барысы да бик табигый һәм нәкъ үзебезчә: талы да ягымлы һәм назлы, иркә бер агач; оясы да күп мәгънәләр сыйдыра торган үтә шигъри төшенчә; ә инде сандугачы турында әйтеп тә торасы юк! Нәтиҗәдә гашыйк егет турында «сандугачлы тал» дигән бик тә тәэсирле, образлы һәм шигъри сурәт пәйда була. Әле бит ул, җитмәсә, халкыбызның меңәр еллык шигъри фикерләү, тоюына, сиземләвенә нигезләнгән авыз иҗаты традицияләренә дә бик органик рәвештә тоташып, ялганып китә. Шулардагы моң, хис ташкыны белән кушылып тагын да көчәя, тулылана.

Бу китапта әнә шундый матур шигъри табышларны шактый еш очратасың. Бер шигырендә шагыйрь:

Үргә акмаса да инеш,
Барыбер коя Иделгә!—

дип, зур гомумиләштерүләрне үзенә сыйдырган, киң ассоциацияләр тудыра торган шигъри күренешне бирсә, икенче әсәрендә исә үзенең гашыйк булу халәтен болай дип белдерә:

Әйтерсең лә яшен суккан
Агач кебек кабындым.

Шулай ук көчле һәм зур тәэсир куәтенә ия чагыштыру түгелмени?! Мәхәббәт әнә шундый була бит инде ул!

Яисә менә мондый юллар:

Казан!
Мин бит син кайнасын өчен
Учагыңда утын икәнмен!

Ә фаҗигале рәвештә һәлак булган дусты, «Идел» журналының баш мөхәррире Фәез Зөлкарнәй турында шагыйрь болай дип әйтә:

Кораблары сайга утырмасмы? —
Бер маягы сүнде Иделнең.

Үзенә исә ул менә мондый бер караш ташлый:

Мин — бердәнбер пуля мылтыкта,
. . . . . .
ул иң соңгы чиккә җиткәч кенә,
кирәк чакта гына атыла.

Яисә:
Әле бер тауга әйләнеп
Болытка тия түбәм.
Йә бер шарлавык булам да
Ташланам таудан түбән.

Күрәсез, шагыйрь зур төшенчәләр, олы мәгънәләр белән эш итә һәм, аларны белдерү өчен, шулай ук калку, шундук истә кала торган детальләр, образлар (яшен суккан агач, кораблар, пуля, тау, шарлавык һ.б.) куллана.

Рафис Корбан иҗатында туган җир һәм әти-әни темасы үзәк урыннарның берсен биләп тора. Шагыйрь биредә дә үзенә генә хас булган шигъри аһәңнәр, поэтик нюанслар таба. «Ак болыт» дип исемләнгән шигырендә ул башта борынгы риваятьләрне искә төшерә: ир балалар, имеш, ерак юлга чыгып киткән чакларында өй матчасына ак каурый кыстырып калдыра торган булганнар. Аларның әниләре һәр таң саен, килеп, иң башта әнә шул каурыйга карый — улы исән-сау икән, каурый чиста була, ә инде авыр хәлдә калса, аннан кан саркый башлый. Шагыйрь, безгә иң элек менә шушы риваятьне сөйләп, үзенең әсәре өчен кирәкле мәгънәви җирлекне, фонны тудыра да, аннары инде хәзерге яшьләре һәм, аерым алганда, үз буынының язмышына күчә:

Каурыйлар кадап калдырмадык
Җиткерергә сәлам-хәбәрне.
Ак болытка карап белә микән
Әнкәйләр соң безнең хәлләрне?

Күрәсезме, шигырьдә нинди үзгәреш барлыкка килде: элек — ак каурый, ә хәзер исә — ак болыт! Беренчесе — конкрет бер өй эчендәге матчада, күз алдында, якында; ә икенчесе исә — әллә кайда һавада, ераста, өстә. Әйтерсең лә ике чор яшьләренең ата-анага булган мөнәсәбәте әнә шулай контраст итеп куела, чагыштырып карала. Шунда ук хәзергеләр файдасына булмаган мәгънә дә килеп чыга.

Ләкин шигырь әле алга таба дәвам итә:

Әнкәйләр соң менә ниләр генә
Уйлый икән шушы минутта —
Саркыганда шәфәкъ кызыллыгы
Баш очыннан узган болытта?

Балалар кайчандыр битараф төстә генә өйдән чыгып киткән иделәр, ә аналар әнә баш очыннан үткән ак болытлар алсуланып торса да хафага төшә — ерактагы баласы турында уйлап борчыла. Шигырь тәэсире поэтик сынландыру, чагыштыру аша безнең күңелләргә әнә шундый хис-кичереш орлыгын салып куя. Ә хәзерге яшь буынга андый кичерешләр бигрәк тә нык тәэсир итәргә тиеш.

Кайсыбер әсәрләрендә Р.Корбан әниләр темасын тирән мәгънәле поэтик чагыштырулар аша түгел, ә туп-туры мәгънәле ихлас сүз ярдәмендә — кайнарлыгы бөркеп, көче ташып торган сүз ярдәмендә белдерә. Ягъни бернинди «киемгә» төренмәгән гап-гади, ләкин хисле, тәэсирле сүз ярдәмендә!

Бөтен дөнья мине сөймәгәндә,
Мине күреп йөзен чытканда,
Ялa ягып, өскә пычрак атып,
Һәр сүземә каршы чыкканда,
Ташлап китсә хәтта иң якын дус
Йә сөйгән яр итсә хыянәт,
Кояш сүнеп кара көнем килсә,
Тормышымда җитсә кыяmәт,
Инде тәмам беткән кеше булып
Саналырга тиешменмени?!

Юк, барыбер, барыбер бар җирдә
Барып сыеныр кешем!
Ул — Әни!

Туып үскән җире дә шагыйрьгә үз әнисе кебек үк якын һәм кадерле. Ә укучы өчен ул үзенчәлекле күренешләр аша истә кала торган урын булып аңлашыла, һәм, әлбәттә, биредә ата-баба нигезе, үткәннәр рухын саклаган изге җир иң алгы планга чыга:

Өч карт нарат зират уртасында —
Бабамнарның изге рухына
Дога кылып гүя оеп киткән
Өч хәзрәт кебек утыра.

Бу күренештән борынгылык рухы, ерак үткәннәр рухы ташып тора, дисәк тә хата булмас. Әнә шуңа күрә аның укучыга тәэсире дә көчле.

Рафис Корбанның бу китабында сәяси яшәеш тә киң һәм күпьяклы чагылыш таба. Әлбәттә, биредә иң элек үзебезнең Татарстаныбыз һәм аның Рәсәй Федерациясендәге статусы мәгънәсе кузгатыла. Шагыйрь бу хакта нәрсә уйлый соң?

Дәүләт эчләрендә дәүләт...
Шул мәзәкме — көлмәгәч!
Шулай яши икән халык,
Үз кадерен белмәгәч.

Бу шигырьдә шагыйрь үз фикерен декларация юлы белән, турыдан-туры белдергән булса, янәшә үк урнаштырылган икенче бер әсәрдә инде уй-фикерен тирәннәнрәк ача:

Байлык дигәнне аңлата
Татарда дәүләт сүзе.
Дәүләте инде күптән юк,
Баймы соң татар үзе?

Шагыйрьнең әнә шул ике төшенчәне — «байлык»ны һәм «дәүләт»не янәшә куюы, аларның мәгънәви якынлыгын, хәтта телебездәге тәңгәллеген табуы бездә бик актуаль уйланулар уята, бүгенге социаль һәм сәяси вакыйгаларга, күренешләргә яңача караш барлыкка китерә. Чыннан да, дисең, Татарстан республикасы никадәр байлыкка: җир астындагы һәм җир өстендәге күпме хәзинәгә ия, ә үзенең халкы ничәмә-ничә еллар тормышының очын-очка ялгый алмый интегә. Өлкән буын пенсия тиеннәрен тартып суза, яшьләр шулай ук хәерчелектән һәм яшәү өчен почмак, бүлмә булмаудан газаплана.

Ә бәйсез илләрдәге кебек Татарстан халкы үз байлыгына үзе хуҗа булса, нинди могҗиза килеп басар иде бит безнең алдыбызга! Яшәү ничек рәтләнеп китәр иде ич!

Шуңа күрә шагыйрьнең түбәндәге юллары укучы хәтеренә озакка сеңеп, берегеп кала:

Бай дип әйтеп буламы соң
Дәүләте юк халыкны?
Эх, татарым, бутагансың
Дәүләт белән байлыкны.

Шулай шул: чын байлык ул үз дәүләтең булса гына кулда була, сине һәм халыкны сөендерә ала!

«Яра» китабын укыганда, күңел бик күптөрле хис-кичерешләргә байый. Анда тормышка, яшәешкә киң караш, киң күңел барлыгын күп әсәрдә күрәсең, тоясың.

«Елмаю» дип аталган шигырь андый халәтне бигрәк тә ачык чагылдыра.

Юлыгызда каршылыклар туып,
Кәефегез әгәр кырылса,
Бәхет кошы бүген сезнең якка
Яны белән әгәр борылса,
Борчылмагыз, барыр юлыгызда
Очырамый калмас, мөгаен,
Кояш кебек балкып кем дә булса
Яныгыздан үтәр елмаеп.

Әйе, шәһәр урамнарында йөрегәндә, мондый елмаюларны без һәммәбез дә күрәбез, ләкин аларга шагыйрь төсле игътибар бирәбезме соң? Рафис Корбан исә әлеге шигырен менә болай дип дәвам итә:

Таныш түгел үтеп баручының
Елмаюын күңел кабатлар.
Шул елмаю балкыр йөзегездә,
Иңегездә үсәр канатлар.

Елмаюның кешегә булган шифалы тәэсирен шагыйрь әнә ничек матур әйтә: «елмаюын күңел кабатлар». Чын шагыйрьләрчә, образлы итеп, тәэсирле итеп әйтелгән! Әйе, китапта менә шундый уңышлы мисаллар бик күп.

Тулаем алганда да шагыйрьнең бу яңа китабы безнең чорыбыз язмышында хәлиткеч борылыш кичерүче милләтебез, кешенең күңел халәте һәм аңа тәэсир ясаучы җитди мәсьәләләр турында тирән уйлануларга бай булып чыккан. Алда китерелгән күпсанлы мисалларга таянып һәм китапта урын алган, чын шигърият үрнәге булган уңышлы әсәрләр нигезендә без бу җыентыкны Рафис Корбанның иҗади үсеш баскычында игътибарны җәлеп итәрдәй биеклек, дип әйтә алабыз.

Шул ук вакытта биредә безне икенчерәк юнәлештә уйландыра торган яклар булу турында әйтмичә узарга ярамас, мөгаен. Аларның иң беренчесе һәм соңгы еллар шигъриятенең үзенә бертөрле чиренә әйләнеп бара торганы, ул — озынга сузылган, эчтәлек ягыннан шактый ук көпшәк әсәрләр. Китапның 24 нче битендә урнаштырылган «Зират» шигыре, мисал өчен, 60 юлдан тора. «Сабан туе» дигәне исә хәтта 171гә үк сузылган. Шулай ук «Казан кирмәне» (57 бит), «Ризамын» (73 бит), «Сабакташларыма» (103 бит), «Яшьлегем» (124 бит) кебек әсәрләрне дә нәкъ менә тиешле күләмдә язылган, диеп әйтүе кы-

ен. Менә шушындый артык озынга сузылган шигырьләр уңаеннан матбугатта соңгы елларда шактый ук күп күренә башлаган поэмалар да искә төшә. Гадәттә, алар да гап-гади шигырь була, ләкин аларның авторлары ни өчендер, туктый алмыйча, үз әсәрләрен бик озынга сузалар да аңа, һич тә тартынмыйча, «поэма» мөһерен сугып та куялар! Бу китабында Рафис Корбан андый адымны атламый атлавын — монда поэмалар юк, ләкин озын шигырьләр үзләре дә шактый ук «тешкә тия».

Аннары шагыйрь кайсыбер әсәрләрендә кабатланып куя. Китапның 45 нче битендә урнаштырылган «Җыен» шигыре, «Мин бер генә яшим дөньяда (100), «Синең күзләр» (154), «Онытмам» (167), минемчә, әнә шундыйлардан.

Без моңа кадәр сүз йөреткән әсәрләр китапның баштагы ике бүлегендә урын алганнар. Ә җыентыкның өченче бүлеге исә җыр сүзләреннән тора. Без хәзергә тикле «балалар шагыйре» дип йөреткән Рафис Корбан байтак кына билгеле җырларның авторы да икән бит әле! «Уян, татар!», «Татарстан гимны», «Мәңгелек мәхәббәт», «Калыр сөю йөрәктә», «Онытма», «Кайларда йөрисең сөйгән яр?» — әнә шундый әсәрләрнең кайберләре генә.

Китапның соңгы бүлеген тәрҗемә әсәрләр тәшкил итә. Без соңгы елларда тәрҗемә эше һәм тәрҗемә ителгән әсәрләр турында бөтенләй дә диярлек сөйләшми, язмый башладык. Әлбәттә, моның бер яктан караганда объектив сәбәбе дә бар: чөнки хәзер милли яшәеш һәм милли әдәбият мәсьәләләре үзәккә чыкты. Ләкин нәкъ менә шул милли әдәбиятны үстерү ихтыяҗыннан чыгып караганда да тәрҗемә эшенә игътибарны арттыру кирәклеге сорала түгелме соң?! Аерым алганда милли әдәбиятыбыз җәүһәрләрен дөньяга таныту сорала түгелме? Татарстанны һәм татар халкын икътисад ягыннан гына: КамАЗлары һәм нефте белән генә түгел, ә әдипләре һәм башка сәнгатькәрләре аша да белергә тиеш бит дөнья.

Шулай ук бүтән халыкларның әдәбият үрнәкләре белән танышу кирәклеге дә бәхәс уятмыйдыр. Алар безнең дөньяга карашыбызны киңәйтә, рухи яшәешебезне баета, иҗат мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә ич.

Рафис Корбан исә биредә тәрҗемә өчен С.Капутикян, Н.Шәмсетдинов, Р.Кутуй һәм Сәгъди әсәрләрен сайлаган. Аларның күбесе безнең татар теле стихиясенә органик рәвештә ялганып китә, үзебезнеке сыман кабул ителә, күңелне дә кузгата. Мәсәлән, атаклы шагыйрә Сильва Капутикянның Рафис Корбан йөрәге һәм каләме аша узган түбәндәге юллары кемне генә битараф калдырыр икән:

Шаулап урман, мең кулларын сузып,
Авыр сулап дәшә — килсәнә!

Кайнап-кайнап дәрьяларга аккан
Язгы сулар дәшә — килсәнә!

Мең авазлы җиһан бердәм булып
Кабатлый бер сүзне — килсәнә!

Яисә менә Себердә яшәүче милләттәшебез Николай Шәмсетдиновның «Болан» дигән шигыреннән бер строфа:

Чапты хайван, өркеп, өскә килгән
Үлем машинасы — вертолеттан.
Һәм дөньяга чиксез курку акты
Күзләренә төшкән кызыллыктан.

Биредә безне әсәрдәге драматизм да, аның татар телендә адекват бирелеше дә җәлеп итә, күңелдә канәгатьлек хисе тудыра.

Шулай ук Рөстәм Кутуйның тирән һәм шул ук вакытта катлаулы лирикасын да Рафис Корбан үзебезчә уңышлы «сөйләштерә».

Ә менә атаклы Сәгъди әсәрләре тәрҗемәсендә мин ни өчендер кытыршы урыннарны ешрак тойдым. Анда хәтта менә мондый сәер юллар да очрый:

...Хәтта богаулы килеш тә
якын җанга дусларың,
Гөлбакчада булуыңнан,
йөрсә янда дошманың.

Биредә нәрсәдер төшеп, бер шигъри юл онытылып калган, ахрысы.

Китаптагы әсәрләрне укып бетереп, соңгы битне ябып куйгач, яңадан аның исеменә игътибар итәсең — «Яра». Әйе, соңгы елларда кешелек тормышында яралар һаман күбәя бара шул. Һәм алар тирәнәя, җитдиләнә дә. Техника үсешен туктата алмаганга күрә, тулаем кешелек җәмгыяте үзе дә соңгы һәм аяныч Ярага таба — һәлакәтенә таба якыная.

Әнә шуларның фажигаи халәтен тоеп, сизеп торган укучы Рафис Корбанның китабына исем биргән «Яра» шигырендәге түбәндәге юлларны йөрәгенә аеруча якын кабул итә:

Йөрәгемдә әрни күптән
Иске бер ярам.

Басылмасмы дип, шул ярам,
Җырлар чыгарам.

Чыннан да, шагыйрь язганча, бәлки, әле киләчәктә безнең дөньябызда да техника һәм аның җимергеч тавышы түгел, бәлки җыр-моң һәм гармония тантана итәр.

Без, кешелек җәмгыятенең матур киләчәген күрергә теләп, табигатьнең исән калуына, җирдә гармония югалмауга өметләнеп, кешеләрнең кешелеклелеге артачагына ышаныч баглап, Рафис Корбан китабындагы түбәндәге юлларның чынга ашуын ихластан телибез:

Ә каләмем миңа, синең гомер
Мәңгелек дип гүя пышылдый.

Яралар күп һәм җитди булса да, тормышның һәм яшәүнең мәңгелегенә ышаныйк әле без!
2004

Алда безне ни көтә?

Кайсы юллар, нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!
(Дәрдмәнд. «Кораб»)

Бу арада язучылар ике мәртәбә җыйналып, үзләрен борчыган иң үткен мәсьәләләр хакында киңәшеп алды. Иң башта Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясендә булып узган очрашу турында әйтик. Бирегә күренекле әдипләр һәм галимнәр, сәясәтчеләр килгән иде. Утырышны даими комиссия рәисе шагыйрь Разил Вәлиев алып барды. Килгән шәхесләрнең һәммәсен дә соңгы вакытта ил тормышында күзгә бәрелә башлаган бер тенденция борчый: бу — илдә вертикаль хакимиятне ныгыту сылтавы белән Россияне чын унитар дәүләткә әверелдерергә ашкыну.

Чыннан да, Мәскәүдә чыга торган газета-журналларны кулга аласыңмы яисә радио-телевизорны кабызасыңмы — бик еш әнә шул рухтагы язмаларга, тапшыруларга юлыгасың. Әйтерсең лә Россиянең «Федерация» дигән законлы икенче атамасы бөтенләй дә юк! Гомум кабул ителгән нормаларны күзгә карап бозарга маташалар. Ләкин бит федерация бар һәм ул киләчәктә дә калырга, тик заманча һәм законлы рәвеш алырга тиеш. Аның күпсанлы субъектлары да, «бергә яшибез» дип килешү төзегән республикалары да алга таба тиешенчә яшәү өчен сулыш, тын алырга тиеш. Мәскәүгә карап кына яшәгән һәм кызганыч хәлгә төшкән Приморье дәрәҗәсендә калырга тиеш түгел.

Язучыларны һәм бүтән зыялыларны борчыган тагын бер мәсьәлә: Россиядә яшәүче халыклардан бары тик берсе турында гына дәүләт кайгыртуы булу. Хәзерге Федерацияне бары тик рус иле генә итәргә тырышу. Россия матбугаты белән телевидениесен инде әйткән дә юк, хәтта Президент В.Путин үзе дә гел әнә шуңа басым ясый бит. Хәрбиләр белән очрашкан чакларда ул еш кына: «Бу — рус армиясе!» — диеп әйтә. Ә бүтән милләттән булган хәрбиләр бу сүзләрне ишеткәч нишләргә тиеш? Ил башының мондый тәкәллефсез чыгышы аларның йөрәгендәге патриотик хисләрен шактый суыта түгелме соң? Ә чын патриотик хискә, ныклы ышануга таянмаган армия нинди көч була инде ул?

Һәм әнә шундый армиягә, җитмәсә, әле поплар, христиан дине вәкилләре генә килеп йөри торган армиягә безнең мөселман егетләре ничек атлыгып барсыннар инде?! Болай да куркытып торган «дедовщина» өстенә әнә шундый милли изү дә чәчәк аткан армия әллә ни ерак китә алмаячак, билгеле.

Әйе, Россия тормышының күп якларында сизелә бүтән милләтләрне санга сукмау. Без, язучылар, Мәскәүдә басылучы «Литературная Россия» атналык газетасын карап барырга тырышабыз. (Сүз уңаеннан әйтеп китик: анда ни өчендер Ринат Мөхәммәдиев әле һаман редколлегия әгъзасы булып тора. Бирегә аны кем тәкъдим иткән? Ул анда кем буларак катнаша икән?) Әмма болай үзе кызык кына чыга торган әнә шул газетада ни өчендер татар һәм башкорт әдәбияты турында бик тә сирәк язалар — елга бер кечкенә информация күләмендә генә! Ә бит аның исеме «Бөтен Россия әдәбияты» дигәнне аңлата. Шулай булгач, ягъни Россия дигән төшенчәгә бүтән милләтләрне кертмәгәч, аларны үги иткәч, һәркем дә суверенлык идеясе, үз кадереңне үзең белергә теләү хисе ничек тумыйча кала алсын соң инде?! Мәскәү үзе мәҗбүри рәвештә дигәндәй уята бит ул тойгыны.

Әлеге очрашуга килгән язучылар һәм башка зыялылар тагын бер фикергә тукталды. Россия телевидениесенең бөтен каналларында да диярлек физик көчне, үтерү-көчләүне, куркытуны һ.б. шуның ише тискәре күренешләрне пропагандалау үтә дә актив рәвештә бара. Гомумиләштереп алганда, менә бу тенденция дә Россиядә бары тик буйсынуны һәм диктатка гына нигезләнгән яшәү рәвеше урнаштырырга, ягъни кечкенә халыкларны санга сукмауны психологик яктан аклый торган караш урнашуга булыша.

Мәскәү куллана торган мондый актив сәясәткә нәрсәне каршы куеп була соң?

Әлбәттә, иң беренче чиратта, гадел, кешелекле законнар кабул итү һәм шуларның чынлыкта, реаль тормышта үтәлүенә ирешү. Бусы — иң зур максат!

Безнеңчә, аңа ярдәм итә торган тагын бер мөһим киңлек бар. Без үзебезнең Татарстан Республикасында «Татарстан халыкларын әхлакый тәрбияләү» дигән зур программа төзесәк һәм шуның буенча яши башласак иде. Югыйсә хәзер безнең телевидение һәм матбугат кеше үтерүне, көчләүне һәм тупаслыкны, ерткычлыкны яшәү нормасы итеп раслап килә. Хәзер безнең иң кечкенә балаларыбыз да, телевизордан көне буена күренеп торгач, «тупаслык, ерткычлык, үтереш-кыйнаш дөрес яшәү рәвеше икән» дигән ышаныч белән үсә. Безнең балаларга әнә шундый юнәлеш бирелә. Димәк, болай барса, бик якын киләчәктә үзебез үк тәрбияләп үстергән бандитлар бездә бик күп дәрәҗәдә артачак. Шуңа күрә моңа бүгеннән үк ныклы киртә куярга тиешбез!

Әгәр дә без әнә шул «Татарстан халыкларын әхлакый тәрбияләү» программасын төзесәк, аңа мәктәпләрне һәм тулаем белем бирү системасын да, әдәбият-сәнгатьне, клуб-китапханәләрне дә, бөтен ял итү чараларын да кертеп, зур система барлыкка китерә алыр идек. Әнә шул законнар, программа нигезендә бүгенге кешегә начар тәэсир итүче кайбер тапшыруларны (закон нигезендә) тыя да алыр идек.

Милләт язмышы турында борчулы сөйләшү Татарстан язучыларының 20 июнь көнне булган идарә утырышында да дәвам итте. Киләсе елга билгеләнгән халык исәбен алу уңаеннан безне хәвефкә төшерердәй күренешләр дә бар икән. Мисал өчен, соңгы вакытта татар милләтен төрле этник төркемнәргә бүлеп йөртү һаман ешрак күзгә чалына башлады: «себер татарлары», «әстерхан татарлары», «мишәрләр» һ.б. Билгеле, кайбер үзенчәлеккә ия мондый төркемнәрнең булуы — тарихи факт. Ләкин алда торган ил күләмендә халык санын алу вакытында моны безнең үзебезгә каршы файдаланырга җыеналар бит әле. Бу төркемнәрнең һәрберсен аерым милләт буларак теркәргә уйлаучылар бар. Шулай итеп, татар халкының санын бик нык киметү һәм нәтиҗәдә аны бөтен Россия күләмендә тагын да мескенрәк хәлгә төшерү. Моның кем өчен файдалы булуын, кемнәргә бик тә кирәклеген барыбыз да белеп тора, әлбәттә. Ләкин безгә яхшылык теләмәүче кешеләрне сөендермәскә иде бит, җәмәгать. Шуңа күрә язучылар да халыкка бу хакта аңлату эшләрен көчәйтергә кирәк дип саныйлар. Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы башлыгы драматург Рәдиф Сәгъдинең үткән эшләр турында хисабын тыңлагач, аларның мондый фикере тагын да ныгый төште.

Бу утырышта республика халкын әхлакый тәрбияләү эшен көчәйтү кирәклегенә тагын бер мәртәбә басым ясап әйтелде. Билгеле, Россия күләмендә патриотик тәрбия дигән эш бара. Ләкин алар башлаган ул эш күп очракта милләтләрне үзара ызгыштыруга, бер генә милләтне югары күтәрүгә кайтып кала. Шуңа күрә бүгенге патриотик тәрбия дигән бу акция миңа бик тә шикле булып тоела. Ә менә без үз республикабызда махсус әхлакый тәрбия программасын төзесәк һәм шул юнәлештә эшне башлап җибәрсәк, Россия идеологларын күпкә узып киткән булыр идек. Ә тагын да мөһимрәге — андый программа була калса, үз республикабызда ерткычлык тәрбияләүгә чик куя алачакбыз!

Әхлакый тәрбия хакында сүз алып барганда, үзеннән-үзе диярлек ул эшне ничек итеп дөрес оештыру һәм бу юнәлештә тырышучылар хезмәтен тиешенчә бәяләү мәсьәләсе дә алга килеп баса. Ә хәзергә әле бездә бу эш бик тә аксый. Мәсәлән, талантлы язучы 3 — 4 ел буена, көне-төне язу өстәле янында утырып, 400 — 500 биттән торган әдәби әсәр иҗат итә һәм шуның өчен... 15 мең сум чамасы каләм хакы ала. Моның белән бит ул гаиләсен түгел, ә шәхсән үзенең дә тамагын туйдыра алмый.

Ләкин шуңа да карамастан татар халкының талантлар чишмәсе һаман саекмый, иҗат дөньясына яңадан-яңа көчләр килә тора. Бу утырышта да Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп сәләтле каләм ияләре Локман Закир, Җәүдәт Сөләйман һәм Нияз Вәли кабул ителде.

Республикабызның каләм әһелләре тынгы белми. Милләт алдына килеп баскан үткен проблемалар аларны нык уйландыра. Заман куйган яңа сынауларны татар халкы бердәм булып, ятлар каршында сер бирмичә уза алсын иде дип тырыша һәм шуның өчен көч куя алар.

2001

Әңгәмәләр

Давылның үзәге буламы?

Танылган әдәби тәнкыйтьче һәм прозаик Мансур Вәли-Баржылы турында татар матбугатында «Давыллы Мансур» дип язып чыкканнар иде. Чыннан да, әлеге билгеләмә безнең бу тәнкыйтьчебезгә

бик тә туры килә. Ләкин әнә шул давылның эчендә, уртасында ниләр бар икән соң? Нинди эчке хасият, эчке хәрәкәт, эчке бәхәсләр җирлегендә барлыкка килә икән ул давыл?

Бүген безнең алда элекке яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев белән хәзерге Мансур Вәли-Баржҗылы фикер алыша.

— Мансур, син әдәби тәнкыйткә килеп кергәндә (бу үткән гасырның җитмешенче еллары иде), байтак кына язучыларга «Ачык хат»лар язып, аларны матбугатта бастырдың. Фатих Хөснигә, Тәүфыйк Камалиевка, Кадыйр Сибгатуллинга, Әхәт Гаффарга аталганнары бигрәк тә укучы хәтерендә калды кебек. Үзара сөйләшкән чакларда, аларны бүген дә еш кына искә төшерәләр... Ә менә хәзер — ул «Ачык хат»лар язылуга һәм басылуга күп еллар узганнан соң — синең үзеңнең ул «Хатлар»га мөнәсәбәтең үзгәрмәдеме икән?

— Әйе, яшьлек дәрте, яшьлек кайнарлыгы белән язылган ул «Ачык хат»лар үземә дә бик якын, бик кадерле. Аннары шунысы да бик кызыклы бит: аларның һәркайсында бер мөһим, актуаль мәсьәлә күтәрелгән. Мисал өчен, атаклы язучы, Дәүләт бүләге лауреаты булган Фатих Хөснигә аталган хатны алсак — анда чынбарлыкны артык бизәп, тормышка «алсу күзлек» аша карап язу турында сүз бара. Ә Тәүфыйк Камалиевка багышланганы исә шигырьләрдәге иҗади үсеш, мәгънәви яктан яңалык булу, җитди эчтәлеккә ия булу, активлык һәм җитдилек хакында әйтелә. Кадыйр Сибгатуллин иҗаты исә мине үзебезнең табигый һәм рухи, милли асылыбызны онытмау хакында уйланырга этәргән — онытмыйк: биредә вакыйга сиксәненче еллар башында бара, әле илгә Яңарыш килгәнче, ягъни безнең матбугат КамАЗ диеп, Татарстан атом станциясе дип шаулаган чорда бара!

Әхәт Гаффарга аталган хатта исә кино карап һәм чит ил әдәбиятын укып кына, алардан сюжет алып кына әдәби әсәр язуның дөрес түгеллеге турында әйткәнмен...

Үзең күреп торасың: болар әдәби иҗат өчен бик җитди мәсьәләләр. Ул «Ачык хат»ларда күтәрелгән мәсьәләләр һич тә искермәделәр.

Ләкин менә шунысы гына бар — хәзерге күзлектән һәм инде бүгенге илле яшен узган шәхес акылы белән караганда, аларда проблемага киңрәк караш җитенкерәмәве үзен бераз сиздерә сиздерүен. Кайбер фикерләрне тулыландырасы килгән урыннар очрый ул хатларда. Икенче төрле итеп әйткәндә, ул чагында мин бик җитди проблеманың бер кабыргасын гына эләктергәнмен кебегрәк тоелып китә вакыт-вакыт. Һәрхәлдә, бүген, менә бу соңгы елларда язылган булсалар, ул «Ачык хат»лар шактый тирәнрәк һәм күләм ягыннан да зуррак килеп чыгарлар иде...

— Аннан соң синең хат адресатлары — барысы да талантлы, сәләтле иҗатчылар бит әле алар. Синең аларга каршы «Ачык хат» язып бастыруың ул чагында, гомумән, талантка каршы чыгу диеп аңлашылмады микән соң?

— Әйе, бәлки, яшьлек ашыгуы, киң уйлап бетермәвем белән мин ул чакта язмаларымның башында аларның, һичшиксез, талантлы әдипләр булуын әйтеп тә бетермәгәнмендер, бәлки. Аларга книксен ясап башламаганмындыр. Этикет саклап бетермәгәнмендер. Аларның талантлы икәнлеген белү — аныcы минем үз күңелемдә генә торып калгандыр, кәгазьгә төшмәгәндер. Шуңа күрә дә, бәлки, минем ул «Хатлар» кайберәүләр өчен берьяклырак, хәтта тенденциоз да күренгән булуы мөмкин. Ләкин, әйткәнемчә, алардагы күтәрелгән төп проблемадан — иң төп таләптән — мин бүген дә баш тартмыйм.

— Ягъни, бүген дә шундый әсәрләр басыла калса, син «Ачык хат»ларны язар идең диеп аңларгамы инде бу сүзләрне...

— Ә нигә?! Торгынлык чорында дистәгә якын кешегә — әле, җитмәсә, атаклы әдипләргә каршы төшә алганны, хәзер генә моңа кыюлыгым җитмәс иде микәнни?! Җитәр иде, дип уйлыйм мин.

— Бәлки, шулайдар да анысы... Ләкин әдәби чынбарлыгыбызда йомшак әсәрләр һаман да басыла тора. Хәзер, акча түләп кенә китап бастыру чоры килгәч, түбән сыйфатлы әсәрләр бигрәк тә күбәйде. Әмма синең теге еллардагы шикелле ярсып каршы чыгуың күренми бит әле. Ачык хатлар да матбугаттан югалды дияргә була.

— Соң, мине дә аңларга кирәктер инде: гел-гел ачык хат кына язып тормам ич инде мин! Әйтәм ич, болай да дистәгә якын әдипкә язылган ич инде алар! Барлык татар язучыларын үземә каршы куя алмыйм бит инде мин! Син аның әнә шул ягын да уйла әле. Аннары, әдәби тәнкыйтьтә жанрларны төрләндерү дә булырга тиеш, дип уйлыйм.

— «Шәһри Казан» газетасы битләрендә алып барган «Әдәбият хәлләре» дигән атналык күзәтүләрне искә алырга телисең инде син, алайса.

— Нигә, шактый усал сүзләр әйтелде, байтак кына зур әдипләр һәм олы түрәләр тәнкыйть утына тотылды бит анда. Мин хәзер ул сүзләрнең берсеннән дә кире кайтырга җыенмыйм. Нигездә, әлбәттә, тулаем алганда.

— Әйе, бу күзәтүләрне бик күпләр яратып укуларын әйтә иделәр. «Хәзерге әдәбият һәм әдәби процесс белән танышу өчен кирәк иде ул» диләр... Ләкин... Ләкин Чаллы шәһәрендә яшәүче бер бәләкәй түрә синең ул «күзәтүләр»ең турында: «Гел мактап кына язасың» — дип чыкты түгелме

соң әле? Син үзең ул авторга матбугат аша җавап биреп тормадың. Аның белән килешү булдымы соң бу? Ничек аңларга моны? Яшь чагындагы Мансурга охшамаган ич мондый холык!

— Әйе, син мәсьәләне кабыргасы белән куйдың. Һәм бу шактый җитди нәрсә. Шуңа күрә, әйдә әле, ачыклабрак сөйләшик. Беренчедән, яшь чагында кеше максималистрак була. Бусы инде — тормышның объектив законы. Димәк, минем яшь чагында әлеге ачык хатларны күп язуымны һәм хәзер бераз басыла төшүемне табигый бер үзгәреш дип кабул итәргә кирәк. Тере кеше үзгәрмичә тора алмый. Югыйсә ул катып калган була... Икенчедән, мин ачык хатларны күпләп язган дәвер — җитмешенче һәм сиксәненче еллар иде. Безнең татар әдәбиятының иң көчле дәвере иде. Дистәләгән классикларыбызның исән чагы, актив иҗат иткән чагы! Димәк, ул вакытта безнең әдәбиятка бер дә курыкмыйча иң зур таләпләрне куеп була иде. Хәтта минеке сыман яшьлек максимализмы да аклана иде кебек. Ә хәзер безнең әдәбиятта хәлләр ничек соң? Бигрәк тә прозада? Хәлләр бер дә әйбәт түгел шул! Нәкъ әнә шуңа күрә дә бүген безгә — әдәбиятка кагылышы булган кешеләргә — авыру кеше яисә кечкенә бала белән эш иткәндәй: саграк, иплерәк, кайгыртучанрак, җылы сүзгә юмартрак булырга кирәк. Димәк, бу яктан алып караганда да, минем хәзер күбрәк мактап язарга тырышуым аклана булып чыга түгелме соң?!

— Менә шушы фикерләрне ачыктан-ачык әйтеп, матбугатта чыгарып, теге авторга җавап бирергә ярамый идемени соң?! Газета битендә җавап бирүнең шундый әйбәт ягы бар бит аның: хакыйкать тулырак, киңрәк яктыртыла кебек алай иткәндә.

— Бәлки, шулайдыр да, ләкин ул чагында — миңа адресланган әлеге хат басылган вакытта — мин аны теге авторның үзен мактамаганга күрә борчылуы дип кенә кабул иттем. Матбугатта аның күп дошманнарын мактадым, ә аны, түрә булуга да карамастан, мактап телгә алырдай мөмкинлек тапмадым. Ягъни мәсәлән: башта мин аның кем икәнен сиздердем, ул миңа җайлап кына үз мөнәсәбәтен белдерде.

— Бәй, шәхси мөнәсәбәтләр дигән гап-гади нәрсәгә кайтып каламыни бу?!

— Юк, алай түгел! Киресенчә, эш һәм иҗат мәнфәгатьләре аркасында шәхси мөнәсәбәтләр үзгәрүдер бу. Шуның мисалыдыр.

— Шәхси мөнәсәбәтләр дигәннән, безнең татар әдипләре арасындагы үзара мөнәсәбәтләр нишләп соң бик сәер ул. Мин шундый бер закончалыкны күзәтәм: түрә булган әдипне татар язучыларының барысы да ярата, аны мактап чыга. Ә түрә булмаганнар исә күбесе бер-берсе белән тыныша алмый. Мондый ямьсез хәл матбугатка да үтеп керә. Нишләп, нилектән болай соң ул?

— Әйе, укучыга аңлаешлырак булсын өчен бер мисалын да китереп үтик инде. Гәрчә андый очраклар күп булса да, биредә аларның берсенә генә тукталыйк. Күптән түгел бер өлкән әдибебез үзенең хатларын бастырды. Әнә шул хатларында инде ул үзенә кордаш әдипләрне — шулай ук танылган язучыларны изепме-изә, шуннан рәхәт таба. Янәсе, бу нинди уңышка ирешкән дә, тегеләр әнә нинди генә! Карагыз, күрегез, янәсе!

— Бу инде нәкъ безнеңчә: чып-чын татарлык булып чыккан! Бер-береңне батырырга теләү хәтта өлкән яшькә җиткәчтен дә бетми!

— Әйе, башка милләт әдипләре бер-берсен «олы әдип», «бөек язучы» дигән сүзләр белән зурласа һәм чынлыкка туры килсә дә, килмәсә дә, җай чыккан саен бер-берсен гел мактарга тырышса, безнекеләр бик еш кына очракларда шуның киресен эшлиләр. Хәтта олы яшьтә дә әлеге пычрактан арына алмыйлар.

— Ә моннан ничек итеп котылырга соң? Гомумән, менә шундый ямьсез «татарлык»тан котылып буламы икән? Булса, нинди юл белән?

— Зыялыларыбыз матур үрнәк күрсәтергә тиеш! Алар үзләренең тормышы, яшәү рәвеше белән дә, иҗат иткән әсәрләре белән дә халыкны, милләтне тәрбияләргә тиеш! Җитәкчеләребез дә моны күз уңында тотарга тиештер.

— Шулай диеп әйткәндә, тагын тәнкыйтькә мөнәсәбәт, аны дөрес аңлау дигән нәрсә калкып чыга бит әле. Чынлап торып уйлаганда, тәнкыйтьне тыныч кына кабул итүне көтү — бу үзе идеализм түгелме икән соң? Бәлки, безгә гомумән тәнкыйттән баш тартыргадыр?

— Сталин һәм Брежнев чорларында без моны күреп уздык ич инде, ул юл белән ерак китеп булмавын аңладык бит инде! Димәк, бары тик бер генә юл кала: тәнкыйтьне дөрес кабул итәргә өйрәнү.

— Кеше психологиясе аны яратмаса, кабул итмәсә дәме?

— Әйе, нәкъ менә психологик яктан дөрес ачкыч таба белү турында уйларга кирәктер монда. Бу мәсьәләдә.

— Алайса, без тәнкыйтьсез яшәп булмый, дибез инде... Ләкин тагын менә шунысы бар: аларны — тәнкыйтьчеләрне — каян табарга соң?

— Халыкта теге яки бу эшкә сәләте булган кешеләр бер генә вакытта да бетеп тормыйдыр инде ул. Аларга бары тик игътибар итү генә кирәк. Мисал өчен минем үземә студент чагымда күренекле тәнкыйтьче, бик күпләрнең остазы Фәрваз абый Миңнуллин җылы карашын кызганмады. Таләпчәнлеген дә күрсәтте, кирәк хәтле үсендереп, дәртләндереп тә торды. Аларның Гариф ага Ахунов белән бергә мине студент чагымда ук «Казан утлары» журналына эшкә алулары, аннан соң Мәскәүгә яшь тәнкыйтьчеләр семинарына җибәрүләре, минем анда бер бүлмәдә берүзем һәм тулы ай буена олы язучы-

лар арасында, чын иҗат дөньясында яшәвем — менә боларның һәммәсе яшь чагында бик көчле канат иде миңа.

— Андый игътибар күрсәтүче табылса, хәзер дә көчле яшь тәнкыйтьчеләр күтәрелер иде дип уйлыйсыңмы син?

— Уйлыйм гына түгел, андый яшь тәнкыйтьчеләр бар да инде. Мисал өчен Фәрит Бәширов, Рәшит Фәтхерәхманов кебекләр бүгенге иң җитди таләпләргә җавап бирердәй мәкаләләр язалар. Бәлки, аларның вакытлы матбугатта күренү активлыгы гына җитмидер? Бәлки, без, редакцияләрдә эшләүчеләр, аларның язмаларына тиешле «яшел юлны» вакытында ачып өлгерә алмыйбыздыр? Шулай итеп аларның иҗади дөньясын кайнар, югары температурада тота алмыйбыздыр, бәлки? Болары инде без — «нишләп соң тәнкыйтьчеләр күренми?» дип зарланырга тырышучылар уйланырга тиешле сорау! Шулайдыр шул. Теге яки бу басма оештырган әдәби бәхәсләр, дискуссияләр вакытында да кызыклы гына авторлар килеп чыга бит. Әле менә күптән түгел «Шәһри Казан» газетасы битләрендә Тәлгат Галиуллин әсәрләре уңаеннан нинди кызыклы һәм бик күпләр өчен гыйбрәтле булган хатлар басылды. Димәк, бездә әдәбиятны тирәннән, нечкәләп аңлаучы шәхесләр, укучылар бар. Аларның фикерен, уйларын әдәби тәнкыйть өлкәсенә тарта белү генә кирәк. Халыкның эстетик, интеллектуаль сәләтен әнә шулай азлап-азлап, ипләп-ипләп кенә уята, үстерә, күтәрә бару гына кирәк безгә.

— Ә үзең менә шулай, киңәш биреп утыручы булып кына каласыңмыни инде хәзер? Илле яшь тулды дигәч тә, син үзеңне аксакал дип санамыйсыңдыр ич әле? Түр башында киңәш биреп утыручы итеп кенә...

— Нишләп алай саныйм ди! Әле яңа гына «Казан утлары» журналында бүгенге проза турында барган (ел буена барган!) зур дискуссияне төгәлләдек ич! Әнә шундый кызыклы бәхәсләрне алда тагын оештырырбыз әле, Алла бирсә.

— Ә әдәби тәнкыйть дигән иҗатта... Анда эшләр ничегрәк барыр диеп чамалыйсың? Әллә инде хәзер проза ягы баса төшәрме икән? «Казан утлары»нда басылган «Мәхәббәт мажаралары» кебек әсәрләр «бик мавыгып укыла» диеп, укучылар да дәртләндереп тора бит әле. Күңелең әлеге теләккә каршы тора алыр микән соң? Әллә әдәби тәнкыйть читтәрәк торып калырмы икән?

— Чыннан да, иҗат дигән нәрсә күңел таләбенә буйсына инде ул. Акыл хөкеме белән генә җиңүе кыен аны. Кайвакытларда ниндидер бер ихтыяҗ буенча берәр китапка рецензия яисә фикер язарга кирәк була, ләкин әнә шул эшне башлый алмыйча, айлар буена сузып йөрисең. Үзеңне-үзең өстәл янына утырта алмыйча йөдисең... Ә кайчагында, газетадан яисә журналдан берәр бик кызыклы әсәр укып чыккач, үзең дә сизмәстән аның турында кайнар гына мәкаләне язып та ташлыйсың. Әле ул, җитмәсә, бик шәп тә килеп чыккан була — үзең дә сокланасың хәтта! Шуңа күрә бу хакта алдан нинди дә булса сүз әйтү, вәгъдә бирү дөрес булмас сыман тоела.

— Ә шулай да... Ә шулай да синең (һәм бүтәннәрнең дә) әдәби тәнкыйть иҗатын активлаштыру өчен нәрсә эшләп булыр иде икән? Мисал өчен, хыял өчен генә әйтеп карыйк әле: нинди шартлар булса син яңадан дәртләнеп, яшь чагыңдагы шикелле вакыт-вакыт максималист булып (иң зур таләп куя укучыны да уятып җибәрә бит әле ул!) яза башлар идең икән, ә?

— Хыял, теләк төсендә генә дисәң, әйтеп карарга була инде аныны. Мисал өчен берәр басма миңа сан саен даими рәвештә урын биреп бара алса һәм минем фикерләремне үзгәртмичә дөньяга чыгарса (укучы өчен шунысы кызык ич инде аның!), андый очракта укучы белән ике арада матур гына бер күпер салып булыр иде, дип уйлыйм.

— Ә новеллалар? Аларны онытасыңмыни?

— Юк инде! Аларны онытырга тормыш үзе кушмый, рөхсәт итми.

— Димәк, яшьлек белән җитдилек янәшә атлый, дибез алайса.

— Киләчәктә шулай булырга язсын иде!

Замана ахырымы?

«Гасыр ахырында» исемле яңа китабы басылып чыгу уңаеннан тәнкыйтьче Мансур Вәли-Баржылы белән әңгәмә

— Әле яңа гына басылып чыккан китабыгызның исемен «Гасыр ахырында» дип куйгансыз. Ә бит бу тәкбир халык телендә инде күптәннән йөргән сүзне — «замана ахыры» дигән сүзне хәтерләтә. Моны махсус шулай эшләдегезме? Безне бераз куркыту, шомландыру өченме?

— Ә нигә, менә бу соңгы еллар, чыннан да, әби-бабайлар әйткән «замана ахырын» хәтерләтә түгелме соң? Ата — улны, ана кызны белмәс чорны! Бүгенге тормышыбызның кайсы гына ягына күз салсаң да, әнә шундый нәтиҗәгә киләсең бит. Хәтта бу хактагы ah-зар белән инде бөтен газета-журналлар тулган! Хәтта бу турыда укыйсы да, сөйләшәсе дә килми. Чөнки моның начар икәнен күбесе аңлый... Лә-

кин мин шунысына гына төшенеп җитә алмыйм: ни өчен бу тормышны гадел хезмәт һәм таза әхлак нигезендә рәткә салырга теләүчеләр күренми? Безнең татар халкының элек-электән бирле тоткан төп юлы әнә шундый иде бит!

— Сезнең бу китабыгызда, әдәби проблемалар белән бергә, тормыш мәсьәләләре дә байтак кына урын алган. Ә бит сез — әдәби тәнкыйтьче. Моны да югарыда әйтелгәннәрдән чыгып аңлатасызмы?

— Шулайдыр, күрәсең... Тормышның үзендә кайнаган мәсьәләләр һәр тармакка да үтеп керә бит инде ул. Бүгенге әдәби әсәрләр хакында сүз йөртүче әдәби тәнкыйтькә бигрәк тә! Чөнки анда урысның революцион-демократ тәнкыйтьчеләре Белинскийлар, Добролюбовлардан килгән матур традиция бар. Мин бүгенге әдәби тәнкыйтьнең дә гражданлык мәсьәләләрендә тормышка мөнәсәбәттә актив булуын нык яклыйм. Бүгенге киң катлам укучыларны, тулаем җәмгыятьне уйландырган, борчыган мәсьәләләр әдәби тәнкыйтьнең дә үзәгендә торырга тиеш дип саныйм! Әдәби тәнкыйтьнең биләгән урыны да тормыш белән әдәбият арасында бит аның! Ә инде кайберәүләр таләп иткән саф әдәбият мәсьәләләре белән генә шөгыльләнү — монысы инде аның әдәбият белеме дигән бер фән предметы буладыр! Әдәби тәнкыйть исә һәрчак әсәрне тормыш белән бәйләнештә генә тикшерергә тиештер! Әлеге дә баягы Белинскийлар чорындагы әдәби тәнкыйть әсәрләренең киң катлам укучылар тарафыннан яратып һәм көтеп алынып укылуы да, минемчә, әнә шуннан килә: алар өчен кызыклы, кирәкле булудан килә!

— Анысы шулаен шулай да, ә менә соңгы елларда көндәлек матбугатка карасаң, ни өчендер әдәби тәнкыйтьчеләр бик сирәк күренә башлады түгелме соң? Сез теләгәннәре, сез күздә тоткаларын инде әйткән дә юк! Сез бу хәлне нәрсә белән аңлатыр идегез икән?

— Биредә иң төп сәбәп шулдыр дип уйлыйм: газета-журнал редакцияләре дә, авторлар үзләре дә хәзер сәяси мәсьәләләр белән мавыгып киттеләр. Ягъни тормышта хәл итәсе проблемалар артык күбәеп киткәнлектән, безнең бөтен интеллектуаль көчебез дә диярлек әнә шул өлгергән мәсьәләләрне хәл итәргә ташланды, шул хакта кызып-кызып бәхәсләшә, уйлана, фикер алыша башлады. Әлеге — моннан алдарак биргән соравыгызга биргән җавапта мин безнең кайбер әдәби тәнкыйтьчеләрнең тормыш куйган проблемаларга игътибар итмәүләрен, әсәрне бары тик әдәби кысаларда гына карауларын әйтергә һәм моны күпмедер дәрәҗәдә әдәби тәнкыйтьнең җитешсезлеге итеп тә күрсәтергә теләгән идем. Һәрхәлдә, шул турыда әйтә башлаган идем. Менә без хәзер яңадан, сезнең бу соравыгызга җавап эзли-эзли, шул уйларга әйләнеп кайттык. Хәер, әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен хәзер тормыш үзе үзәккә куя башлады кебек. Элегрәк — без сәясәт белән мавыгып яшәгән елларда — күпмедер онытылыбрак торган әлеге серле һәм кызыклы дөнья яңадан да безнең йөрәкләрне һәм акылларны били башлады сыман.

Сез матбугатның ничектер бу төбәкне азрак яктыртуын әйтеп уздыгыз... Чыннан да, монда бик күп нәрсә редакцияләрнең үзләреннән дә тора бит. Алар бит чынбарлыкка ияреп кенә барырга, андагы хәлләхвәлләрне чагылдыру белән генә канәгатьләнергә тиеш түгелләр. Алар, ягъни безнең редакцияләр, дип әйтүем, бүгенге яшәешкә актив рәвештә тәэсир дә итәргә тиешләр! Укучыларның аңын, зәвыгын, хискичереш юнәлешен формалаштыру, аларны тәрбияләү һәм үстерү-үсендерү аша тәэсир итәргә тиешләр алар бүгенге тормышка! Безнең «Казан утлары» журналы мисал өчен соңгы вакытта ел саен диярлек «Түгәрәк өстәл» сөйләшүләре, дискуссияләр оештырып килә. Шулардан берсе — «Туксанынчы еллар» әдәбияты» дигәне бигрәк тә кызыклы һәм мәгънәле килеп чыкты аның. Анда катнашучылар бик күп булды. Гади укучылар да сүз алып мөһим генә фикерләр әйттеләр — уртак эшкә өлеш керттеләр.

Минемчә, безнең көн саен чыга торган басмаларыбыз моның ише сөйләшүләрне — хәзерге укучыларны борчый һәм уйландыра торган дискуссияләрне — ешрак уздырырга тиешләр. Яшерен-батырын түгел: без хәзер сүгә торган совет чорында газеталар андый чараларны яхшы оештыра иделәр һәм моның беркемгә дә зыяны юк иде. Хәзер дә әнә шундый бер тотрыклы, стабиль чорның беренче чаткылары күренә кебек. Шуңа күрә моның ише оештыру эшләре яңадан безнең редакцияләрнең эш тәртибенә әверелергә тиеш дип саныйм мин.

— Сез ничек уйлыйсыз: илгә Яңарыш чоры килгәчтен, безнең каләм әһелләренең байтагы ничектер каушабрак, югалыбрак калды түгелме? Кайсыбер ижатчылар үзләренең моңа кадәрге юлларын, юнәлешләрен югалтып, бераз адашкандайрак хәлдә калды түгелме?

— Чыннан да, андый хәл булды шул! Моны берничек тә яшереп булмый торгандыр инде. Ә ни өчен шулай килеп чыкты соң? Җавап артык катлаулы түгел, минемчә. Чөнки совет чорында җитәкчеләр әдәбиятка бары тик идеологик корал итеп кенә карыйлар сыман иде. Ә байтак язучы үзен әнә шул идеология машинасындагы бер шөреп, бер шестерня кебек иде. Һәм күпләр моның белән ризалашкан да иде... Менә шундый ижатчылар өчен, әлбәттә, теге системаның җимерелүе шәхси фаҗига сыман кабул ителде, аларның бөтен язмышлары бозылды... Ә инде моңа кадәр дә, ягъни совет чорында да, үзләренең тотрыклы ижади юллары һәм ныклы иманнары, ышанычлы юнәлешләре булган язучылар өчен илдәге мондый зур үзгәреш һич кенә дә фаҗига түгел иде. Андыйлар, киресенчә, иркен сулап куйды. Чөнки теге система ул икенче яктан алсаң, ижат иреген кыса, аны бик тә чикли иде бит.

— Мин бу урында сезнең белән бик килешеп бетмәс идем. Ягъни болай дип әйтмәкче булам: алайса әнә шул ижат иреген кыскан совет чорында ничек итеп Әмирхан Еникинең, Мөхәммәт

Мәһдиевнең, Фуат Садриевнең һ.б. күренекле әдипләрнең чын халыкча, чын сәнгатьчә булган әсәрләре языла һәм басылып чыга алды соң?

— Әйе, сезнең бу сорау алдагысының дәвамы кебегрәк тә килеп чыга. Чыннан да, әгәр дә иҗатчы шәхесе рухи яктан көчле икән, ник икән, аның эчке иманы таза икән — ул чагында әлеге әдип төрле кысуларга, тышкы тәэсирләргә бирешмәскә мөмкин. Ул үзенең ныклы юлын саклап калырга мөмкин. Әлеге система куйган каршылыкларны, кыенлыкларны ул уңышлы рәвештә үтеп китәргә мөмкин. Безнең җитмешенче, сиксәненче еллар әдәбиятында андый көчле рухлы әдипләр байтак булды. Шул ук Әмирхан ага Еники, Нурихан ага Фәттах, Салих ага Баттал үз юлларыннан беркайчан да тайпылмадылар — үз кыйблаларына тугры калдылар. Нәтиҗәдә менә бүген без аларны татар халкының чиста, саф күңелле һәм керсез язмышлы әдипләре буларак искә алабыз...

Сез әйткән чын әдәбият әсәрләре дә, нигездә, әнә шундый әдипләрнеке булып чыга...

Аннары тагын бер мөһим фактны истән чыгармаска кирәктер: ул чорда җәмгыять һәм дәүләт әдәбиятка бик зур игътибар күрсәтә иде, шуңа бәйле рәвештә таләпчәнлек тә көчле иде. Менә болар барысы да әсәрләрнең сыйфат ягыннан югары дәрәҗәдә булуына китерде. Язучылар да үз эшләренә күпкә җаваплырак карыйлар иде. Безнең әдәби тәнкыйть тә көчлерәк иде.

— Ләкин ул совет чорында цензура дигән киртә дә бар иде бит әле. Бу хакта да истән чыгармаска кирәктер, минемчә.

— Әйе, цензура бик куркыныч нәрсә иде инде ул... Ләкин менә еллар үтте. Ә цензурадан узмаган менә дигән әдәби әсәрләр күп булып чыктымы соң бездә? Бер дә күп түгел бит! Ибраһим Салахов һәм Гурий Тавлин романнары... Ә тагын нәрсә бар соң? Табылса, тагын бер-ике әсәр, китап килеп чыгар инде... Моннан әйтергә теләгәнем шул: чын әдәби әсәр ул бернинди цензурага да карамыйча бәреп чыга! Барыбер җиңеп чыга! Менә бездә чын әдәби әсәрләр бик аз языла — шунысы иң авыр мәсьәлә! Иң зур мәсьәлә!

Давыллы Мансур

— Мансур әфәнде, синең белән уздырыласы шушы әңгәмәгә әзерләнеп кергәндә, минем хәтергә үткәндә булган кызыклы бер вакыйга килде. Торгынлык заманы дип аталган елларда, төгәлрәк итеп әйтсәк, 1971 елда, әле ул чагында Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә укучы Мансур Вәлиев дигән егет — «Социалистик Татарстан» газетасында атаклы язучы. Тукай бүләге лауреаты Фатих Хөснигә «Ачык хат» бастырган иде. Өлкән яшьтәге һәм танылган әдипкә: «Тормышны алсу төскә генә буяп, бизәп язасыз!» — дип әйтә алган иде ул. Ул елларда мондый хәлнең була алуына хәзер ышануы да кыен кебек.

— Чыннан да, әлеге «Ачык хат»ка килсәк, ул чагында язучыларның күбесе, Мансур Вәлиев дигән кешенең барлыгына ышанмыйча, аны берәр әдипнең ялган исеме, ягъни псевдонимы дип уйлаганнар иде. Соңыннан, мине белә башлагач, бу хакта байтак кешенең әйткәне булды.

— Ә Фатих ага үзе үпкәләмәдеме соң?

— Дөресен әйткәндә, безнең аның белән бу хакта беркайчан да сөйләшкәнебез булмады. Аралашу, сөйләшү вакытында («Идел» альманахында эшли башлагач, әдипләр белән еш аралаша идем) аның миңа каш җимереп, йөз бозып йөрүен һич кенә хәтерләмим. Хәзер менә мондый сүзләрне Фатих Хөсни кебек олы әдип исеме белән янәшә язу үзе генә дә хилаф эш шикелле тоела.

Аннары чын, җитди әдәбиятта шундый бер язылмаган канун яши шикелле: әдипнең таланты зуррак, шәхес олырак булган саен, аның күңеле дә киңрәк, кешелеклерәк була бара сыман. Ул үзе хакында әйтелгән теге яки бу сүзне дөрес кабул итә ала. Чөнки аның эчке дөньясы, чыннан да, зур әдипләрчә, ә рухи дөньясы көчле, тирән була.

— Хәзерге яшь язучылар да шулаймы соң?

— Алай ук түгел шул... Хәзер кечкенә генә тәнкыйть сүзе өчен дә кан дошманга әйләнүең мөмкин. Ә бит тәнкыйть сүзе язучының шәхесе турында түгел, иҗаты хакында әйтелгән була. Сүз бары тик әдәбият хакында, әсәрнең уңышлы һәм уңышсыз яклары турында бара.

— Матбугатта син даими рәвештә алып барган «Әдәбият хәлләре» дигән күзәтүләр әллә шул сәбәпле туктап калдымы? Югыйсә аны бик күпләр кызыксынып укый, татар әдәбиятының соңгы яңалыклары белән даими танышып бара иде.

— Әлеге язмаларда әйтелгән фикерләр өчен үпкәләүчеләр булды булуын (күпләр үзенең шәхси иминлеге хакында гына уйлый бит), ләкин ул күзәтүләрнең тукталып калуы үпкәләшүләр белән һич тә бәйле түгел. «Әдәбият хәлләре»н язу өчен миңа бик тиз арада бөтен татар матбугатын укып барырга кирәк була иде. Өч-дүрт җөмлә фикер әйтү өчен, тулы романнар укырга һәм тиз укырга кирәк! Өч ел дәвамында мин әнә шундый кызу ритмда эшли алдым, ә аннары арыта башлады.

— «Идел» альманахында эшләгән чагында, синең Мәскәүне штурмлавың турында төрле легендалар йөри...

— Без, татар телендә яшьләр журналы нәшер итүне сорап, Сусловка керү өчен язучылар делегациясе оештырган идек. Ләкин бераздан үзебез үк анда кермәскә булдык, көтәргә карар кылдык.

— Татар яшьләренә журнал сорап озак еллар буена барган көрәшкә ул чактагы партия лидеры Ф.Табеев та кушылып киткән, дип сөйлиләр. Ә анысы ничек булды соң?

— Анысы 1979 елда булды аның. Безнең көрәшнең иң кызган чагы. Татарча яшьләр журналы сорап, илнең күп почмакларыннан КПСС Үзәк Комитетына хатлар ява. Үзебезнең Казанда идеология секретаре М.Вәлиевкә делегацияләр оештырабыз. ВЛКСМ ҮКна күп үтенечләр китә...

Менә шундый бер мәлдә Татарстан язучыларының чираттагы съездын үткәрер вакыт җитте. Ә анда катнашу өчен Мәскәүдән Россия язучылары башлыгы, абруйлы әдип Сергей Михалков киләчәк, дигән хәбәр чыкты. Бу әдип татар язучыларына бик җылы карый. Без, дүрт язучы, аның янында да булган идек. РСФСР Язучылар союзының безне яклаган карары да чыккан иде. Менә хәзер, Казанга съездга килгәч, Михалковны ничек итеп Табеев белән шушы мәсьәләдә сөйләштерергә мөмкин? Уйлана торгач, тиз арада Табеевка мөрәҗәгать итәргә кирәк, дигән фикергә килдек. Ләкин, субординация кушканча, һич кенә дә культура бүлеге аша да түгел, идеология секретаре аша да түгел! Туп-туры үзенә!

Хатны мин яздым. Кыска гына итеп, билгеле. Мондый мәсьәләдә бик оста Альберт Нарбеков бар бит, аның белән дә киңәштем. Ул минем хатны шактый төзәтте. Машинкада бастырып алдык та, шуннан соң өлкән язучыларның өйләренә киттем. Гомер ага Бәширов, Хәсән ага Туфан, Нури ага Арсланов, Нәби ага Дәүли кебек аксакаллар бу хатка бик горурланып кул куйды. Алар 15ләп әдип иде.

Хәзер инде бу хатны Табеевка тапшырырга кирәк! Бер көннән Михалков киләсе. Үзем ул чагында КПСС әгъзасы да түгел идем, партиягә соңрак кердем.

Иң башта өлкә комитетының культура бүлегенә шалтыратып: «Сезгә Язучылар союзы йомышы белән керәсе бар иде, пропуск әзерләгез әле»,— дидем. Шул документ белән өлкә комитетына керә алдым. Яшьлегем, тәжрибәсезлегем аркасында башта гомуми бүлек мөдире Рәимов бүлмәсенә килеп кердем. Эшне аңлатырга тырыштым. Ә ул җүнләп сөйләшеп тә тормый: «Әнә культура бүлегенә бар!» — дип кенә җибәрә. Шуннан соң инде чыгып китеп, бүлмә артыннан бүлмәне күзли-күзли, Табеев утырган кабинетны эзләдем. Ә үзем куркам һәм дулкынланам!

Минем бәхеткә, Табеевның кабул итү бүлмәсендәге егет бик кешелекле булып чыкты. Ул минем сүзне тиз аңлап алды. Эшне кызу тотарга кирәклеген дә төшенде.

«Мин бу хатны Фикрәт Әхмәтҗановичка тапшырырмын»,— диде. Кызганыч, ул чагында мин ул егетнең исем-фамилиясен сорарга онытканмын. Менә хәзер күрсәм, кулын кысып, бик зур рәхмәт әйтер идем.

Бу егет безнең хатны, чыннан да, Табеевка тапшырган. Икенче көнне инде безнең Язучылар союзы белән өлкә комитетының культура бүлеге ду килеп документлар әзерли башлаган иде.

Әлеге хатның нәтиҗәсе шул булды: язучылар съезды барган чагында Табеев һәм Михалков исемennән КПСС ҮК секретаре М.Сусловка хат әзерләнде. Шуннан соң Табеев ул хат белән Суслов янына кергән, нигездә, аның ризалыгын да алган. ҮКның культура бүлеге белән пропаганда бүлегенә документлар әзерләргә кушылган. Шунда аларның беренчесе безне яклый, әмма Тяжельников җитәкләгән пропаганда бүлеге безгә каршы чыга һәм... мәсьәлә тагын сүтелә. Менә шул!

— Син үзең дә КПСС Үзәк Комитетына барган дип сөйлиләр. Ул сүз ни дәрәҗәдә дөрес?

— Мин ул елларда, чыннан да, КПСС Үзәк Комитетында булдым. Матбугат секторы мөдире ун гына минутка дип кабул иткән иде, мин бер сәгатькә якын булдым. Үзебезнең дөреслекне раслаган өр-яңа документлар һәм аргументлар белән таныштырдым. Матбугат секторы мөдире исә миңа мондый яңа информация бирде. Безнең татарча яшьләр журналы чыгару мәсьәләсе КПСС ҮКның кече политбюросы утырышына куелган булган. Ләкин анда бик җаваплы бер иптәш (аның кем икәнен мин сезгә әйтә алмыйм, диде мөдир) бу мәсьәләне әлегә калдырып торырга кирәк, дигән сүз әйткән. Шунлыктан мине кабул иткән иптәш сөйләшүен бик җылы һәм хәлне аңлап сөйләшсә дә, ахырда ихлас итеп: «Әлегә көтмичә ярамый шул, тагын бераз көтегез инде»,— диде.

Менә шулай итә-итә, яңарыш чоры башланганчы көттек инде «Идел»не...

— Әңгәмәбез ахырында үзеңнең нинди уй-хыяллар белән яшәвеңне дә әйтеп узарсың, бәлки? «Казан утлары» журналының 1997 елгы саннарында синең «Иртәнге пароход» һәм «Мәхәббәт мажаралары» дигән әсәрләреңне яратып укыган идек. Әдәби тәнкыйтьне ташлап, шул яккарак кереп китәргәме соң әллә исәпләр?

— Тәнкыйть тармагын ташлап булмастыр инде аны. Җан шундый бит: әдәбияттагы кызыклы күренешләр турында сүз әйтмичә калуы бик кыен. Аннан соң әле бүген синең белән сөйләшкән нәрсәләр турында тәфсилләп язган «Идел» өчен көрәш» дигән китап та бар. Аны да дөньяга чыгарасы иде. Безнең милли көрәшнең шактый кызыклы чагылышы бит инде ул... Шулай ук син әйткән тармакны — прозаны да онытырга исәп юк.

— Шулай булсын! Йөрәгеңдә яшьлек уты сүнмәсен!

1998

Эчтәлек

Алмагачлар чәчәктә .....
Ир-ат турында .....
Каргышлы еллар .....
Яңа исемнәр, яңа әсәрләр... .....
Америкада татар әдибәсе .....
Оя тойгысы .....
Халыкчанлык .....
Еники дәресләре .....
Яктырта да яшен, яндыра да... .....
Бергәлек бәхете .....
Туксанынчы еллар әдәбияты .....
Мулла абзый китап яза .....
Сатира батыры .....
Якты эз .....
Ул көннәрдә... .....
Рухи ныкмы без? .....
Төп максатыбыз нәрсә? .....
Кемгә иман кирәкми? .....
Әдәбият дөньясы: уйлар, фикерләр .....
Сагыш дәрьялары аша .....
Безнең Габделхәй абый .....
Тәллитут .....
Кешелеклелекнең дәвамы — батырлык! .....
Кем нәрсәдән курка? .....
Мизгел .....
Елларга калсын! .....
Әнә шундый йөрәк! .....
Зурлык .....
«Кайда минем илем?» .....
Ырыс егете .....
Горур кораб кебек .....
Соклану .....
Тукайга тугрылык .....
Каләм — гомер озайта! .....
Күрик әле әйбәт басмаларны! .....
Кызлар йөрәге .....
Ныклыгыбыз туган җирдә! .....
Эзләгән — таба! .....
Күңел кемне көтә? .....
Тәкъдир юллары .....
Җан яралары... .....
«...Мәңгелек дип гүя пышылдый» .....
Алда безне ни көтә? .....

Әңгәмәләр

Давылның үзәге буламы? .....
Замана ахырымы? .....
Давыллы Мансур .....

Научно-популярное издание

Валиев Мансур Хазиевич

Волны жизни

Литературно-критические статьи

(на татарском языке)

Мөхәррире *И.Г.Ногманов.*
Рәссамы *Г.Ж.Хисмәтуллина*.
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов.*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*.
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Л.З.Шиһапова, Г.М.Хәбибуллина*.

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.02.2005. Формат 84x108$^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 15,12 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 16,28. Нәшер-хисап табагы 17,04 + форз.0,36. Тиражы 2000 экз. Заказ А-91.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
http://www.tatarstan.ru/books/
E-mail: tki@books.kazan.ru.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahat™.

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.